
ISSN 0206—4189

# Казан утлары

2. 1997





Бакый УРМАНЧЕ
(1897—1990)

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**2**

**(892)**

**1997**

КАЗАН

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

К. МИҢЛЕБАЕВ. Бакый. *Роман* ........ 3
А. ХӘЛИМ. Кипарис кайтты иленә... *Шигырьләр* ........ 76
Р. НИЗАМИЕВ. Кайтарыгыз! *Хикәя* ........ 83
Р. ГАТАШ. Гөлбалага хатлар. *Газәлләр* ........ 93
Ә. БАЯН. Очу, төшү... *Шигырьләр* ........ 100
М. ӘХМӘТҖАН. Тормыш мизгелләре. *Парчалар* ........ 126

ДРАМАТУРГИЯ

Ш. ХӨСӘЕНОВ. Безнең подъезд төбе. *Бер пәрдәле драма* ........ 106

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

М. ХУҖИН. Ул — түрдә ........ 119
И. ГАЗИ. Тургай картаямы икән. *Хикәя* ........ 120
И. ГАЗИ. Ерганак юл ала ........ 122

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Проза турында сөйләшү ........ 147

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

Ә. КӘРИМУЛЛИН. Төркиядә «Казан» журналы ........ 155
Р. КАШАПОВ. Польша-литва татарлары һәм Татарстан ........ 170

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Д. РАМАЗАНОВА. Пермь татарларының теле һәм тарихы ........ 173

ӘЗ-МӘЗ ГЕНӘ МӘЗӘК

Ш. МАННАП мәзәкләре ........ 184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Наҗар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Камил Сәгадәт**
*(җаваплы сәркатип)*
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа К. МИННЕБАЕВА «Баки», рассказ Р. НИЗАМИЕВА «Верните!», этюды М. АХМЕТЗЯНОВА «Мгновения жизни», стихи А. ХАЛИМА, Р. ГАТАША, А. БАЯНА.
«Драматургия»: драма Ш. ХУСАИНОВА «У нашего подъезда».
«Из сокровищницы татарских рассказов»: рассказ И. ГАЗИ.
«Литературная критика»: разговор о современной прозе.
«Страницы истории»: статьи А. КАРИМУЛЛИНА «Журнал «Казан» в Турции», Р. КАШАПОВА «Польско-литовские татары и Татарстан».
«К истории народа»: статья Д. РАМАЗАНОВОЙ «Язык и история пермских татар».
Забавные истории Ш. МАННАПОВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
«На наших обложках»: «Зимнее утро» — фоторепродукция из картины Б. Урманче; известный литературный критик и писатель Мансур Вали.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 27.12.96 ел. Басарга кул куелды 1.02.97 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 12 384. Заказ Е-633.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.
© «Казан утлары», 1997 ел.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



# Кыям Миңлебаев

# БАКЫЙ

РОМАН

*Бакый ага Урманченың
якты истәлегенә багышлана.*

## Автордан

Бакый ага Урманче, авыр туфрагы җиңел булсын, чын сәнгатькәр иде, соклангыч бер шәхес иде. Соңгы 10—15 ел дәвамында аның белән күрешү-аралашу, төрле темаларга әңгәмә кору-гәпләшү нәтиҗәсендә — сәнгатькәрнең үз-үзен тотышы, сөйләү рәвеше, әңгәмәләрдән алган тәэссорат күңелемә тирән уелды. Гали затның кыяфәте һәрчак күз алдымда, тавышын да гүя һәрдаим ишетәм, гаять үзенчәлекле бай лексиконы, әйткән сүзләре һәм дә хәтеремдә.

Бакый Урманче олуг талант вә кодрәт иясе буларак дөньяга килә: шагыйрь дә ул, җырчы да ул, рәссам да ул. Кайсы гына юлны сайласа да, һичшиксез, гаҗәеп зур уңышларга ирешеп, дан вә шөһрәт казанган булыр иде. Игътибарга шунысы лаек: гәрчә ул гомерен шигъриятькә багышламаса да — аның әсәрләрендә шигърилек һәрдаим чагыла; гәрчә гомерен җыр-моңга багышламаса да — аның иҗатында моң вә аһәң яңгырап тора. Даһи сәнгатькәрнең иҗат лабораториясе — үзе бер дөнья. Гүзәллек дөньясы, бай дөнья.

Бакый ага Урманче образын иҗат итү нияте без фәкыйрегездә кинәт кенә тумады. Әңгәмәләр вакытында аксакал үзе генә шул фикерне куәтләде, ара-тирә нәкышь сәнгатенә, уем-скульптурага булган карашын тәгаенләргә үзе үк булышты, афоризмнарын кәгазьгә төшергәнемне сабыр гына көтеп утыра торган булды.

Бакый ага Урманченың бай вә талантлы иҗатын яхшы белгән тәкъдирдә дә аны тулаем чагылдыру, сәнгатькәрнең йөзләгән-меңләгән әсәрен тасвирлап бетерү һич мөмкин эш түгел. Аксакал үзе исән чакта альбомы чыгып калды, шушы елларда гына А. Новицкийның аңа багышланган урысча монографиясе дөнья күрде. Гали зат Бакый Урманче хакында киләчәктә бик күп әсәрләр иҗат ителер әле. Бу роман шул юнәлештә беренче адым гынадыр.

Без фәкыйрегез сәнгатькәрнең колач җитмәслек иҗатыннан фәкать үзенең күңеленә аеруча хуш килгән, эшләнешләре белән бигрәк камил дип, сынлы

---

Кыям МИҢЛЕБАЕВ (1929) — *язучы, тәрҗемәче. Ике дистәдән артык тәрҗемә китаплар авторы. «Бакый» романы — аның беренче зур күләмле әсәре. Казанда яши.*

сәнгатебездә гүзәллек өлгесе дип саналган, Урманченың даһилыгын исбатлаган нәкышь, уем-скульптура вә графика әсәрләренең дә кайсыберләренә генә мөрәҗәгать итте һәм шуларга таянып аның иҗат лабораториясенә-остаханәсенә укучыларны да алып керергә тырышты: сәнгать әсәренең ничегрәк туына — иҗат ителүен төшендереп бирергә омтылды; моның белән генә чикләнмичә, кадәри хәл аны тәфсилләп тә күрсәтмәкче, ягъни сынлы сәнгать әсәрен укырга-танырга өйрәтмәкче булды. Безнең әлеге әсәрләргә биргән бәябез дә, сәнгатькәрнең шул дәвердә кичергән хисләрен вә хәсрәтләрен, зарурияте вә мәҗбүриятен, холкын-фигылен тасвирлавыбыз да, әлбәттә, субъектив: без бар нәрсәне дә фәкать үзебез аңлаганча, колагыбыз ишеткәнчә, күңел күзебез күргәнчә генә сурәтләргә хакыбыз бар дип саныйбыз. Тагын да яхшырак белгәннәр, һичшиксез, бүтәнчәрәк тасвирлап язарлар, иҗат итәрләр. Татарстанның халык язучысы Гомәр ага Бәширов сүзләре белән әйткәндә, без үзебезнең карашыбызга хыянәт итмәдек, кемнәргәдер ярарга тырышып, милли сәнгатебезнең йөзек кашы булган шәхескә мөнәсәбәтебезне үзгәртмәдек.

Ә инде романдагы башка образларга килгәндә, аларны без фәкать даһи сәнгатькәрне җанландырып-тулыландырып күрсәтү максатыннан чыгып кына, төп каһарманны гәүдәләндерү өчен фон буларак кына «уйлап» чыгардык, иҗат иттек. Әгәр бу әсәрдә кайберәүләр үзләренең теге яки бу сыйфатларын күрсәләр — нигә алай күрсәттең, дип, янсә, үзләрен күрмәсәләр — нигә мине читләтеп үттең, дип дәгъвалашмасыннар, ул образларны фәкать авторның хыялында туган иҗат җимешләре буларак кабул итсеннәр иде.

Татар халкының нинди бай әдәбияты вә гүзәл сәнгате була торып та, аларны иҗат итүчеләргә багышланган китаплар бармак белән генә санарлык. Бүгенге көндә каләм тибрәткән әдипләребез бу хакта да уйласыннар иде. Эшкә тотынсыннар иде.

Ничәмә-ничә сират күперен кичеп, үзенең иҗатында гаҗәеп зур уңышлар казанган сәнгатькәребез Бакый ага Урманченың күпкырлы хезмәтенә татар халкының хөрмәт белән каравына ирешә алса, укучыларның күңелендә сәнгатькә мәхәббәт уята алса, автор үзен бәхетле дип санар иде.

# I баб

## Күл-Черкен

*«Иң әйбәт, иң матур тел — ана теле!»*
Бакый Урманче,
*1978 ел, 10 август.*

*«Мин үзем тәмам разый түгел разыйлыгын,*
*әмма күңелдән шулай чыккан инде ул...»*
Бакый Урманче,
*1977 ел, 27 апрель.*
*«Күл-Черкен» картинасының*
*эскизына үзе биргән бәһа.*

Өстендәге киемен малайлар җитезлеге белән сыдырып атты да, аны-моны уйлап тормастан, Габделбакый суга сикерде, кай арада чумып, өскә калыкты, елганың уртасына таба колач җәйде. Авылдашлары аны-моны аңышкалаганчы, ул инде алардан ераклашып та өлгерде. Әмма, көчле куллары белән колачларын киң-киң алдырса да, кызу агымга һич кенә дә каршы торырлык түгел иде — Зөя суы аны ярыйсы ук түбәнгә агызып алып китте. Ләкин бу хәл һич тә кәефен

кырмады, күнелен төшермәде. Туйганчы йөзеп-уйнап арыганнан соң, чирәмле ярга менеп үзе дә сизмәстән, күнелендәген әйтеп салды:

— Һәй, Зөям — балачак бишегем, ихласлар сагынып кайттым бит үзенне! Нинди генә дәрьяларда коенсам да, кин Иделләрне ингләсәм дә, үземне гел синдә коенгандай хис итә идем. Бер генә инеш тә, бер генә елга да тизлектә синең белән ярыша алмыйдыр, Зөям. Тау елгасы булган Алмата елгасы да сиңа тиң түгел, нык калышадыр, Зөям-Зөякәем!

— Бардыр инде ул мондый кызу ага торганнары да...

Әллә ишетеп тә илтифат итмәде бу сүзләргә кунак, әллә бөтенләй ишетмәде, сокланып сөйләнүен дәвам иттерде:

— Бер генә елганың суы да синең суың кебек саф түгел, Зөям-Зөякәем, синдәй татлы түгел!..

Габделбакыйны туган авылында гомер итүче сабакташлары-кордашлары үзләре эзләп таптылар. Ничәмә-ничә еллар күзгә-башка күренмәгән данлыклы авылдашларын алар туганнары шикелле якын итеп, сагынып өлгергәннәр. Шулай булмаса, кайтканын ишетү белән, өчәүләшеп килеп җитмәсләр иде. Әйе, җитмәсләр иде...

Нәҗметдин карт — Габделбакый белән бер елгы. Малай чакны идәнгә янәшә утырып, береннән-бере уздырырга тырышып, калын тавышлар белән кычкырып «Иман шарты»н укыганнары әле дә исендә-хәтерендәдер. Күрешкәч тә, утырышып бер дога кылу белән, шуны исенә төшерде:

— Йә, әйтеп бир әле, Габделбакый: кяферме сән, мөселманмы сән? — дип, кунакка төбәлде. Янәсе, илле-алтмыш ел буена кяферләр арасында йөргән сабакташы диненнән-иманыннан язмаганмы?

Габделбакыйның түм-түгәрәк чыраена елмаю җәелде, гайрәтле генә итеп, тамак кырды да:

— Әлхәмде лил-лаһи, мөселманмын! — дип, нәкъ «Иман шарты»ндагыча җавап кайтарды.

Авылдашларының тәмам күңелләре булды, авызлары ерылды. Нәҗметдин генә үз итеп, якын күреп бәйләнүдән туктамады:

— Ул чагында синең тавышың тагын да матуррак иде. Көчле мәкам бар иде синең тавышыңда. Без инде сине, Идрис хәзрәт шикелле, мулла булырга әзерләнә, дип йөргән идек. Хәйран шәп мулла чыгасы иде бит үзеңнән! — диде.

Сөттәй ак чәчле Зәйнетдин дә башын чайкап алды:

— Ну, тавыш та иде соң үзендә! Безнең сыйныф малайлары да, сабакларын онытып, авызларын ачып, сине тыңлыйлар иде.

Габделбакый Зәйнетдингә төбәп карады. Имән кебек икән әле, үзе карсаграк кына булса да, гаять калын җилкәле икән, таза дию генә аз булыр, Сабантуй батыры диген дә — вәссәлам! Алты дистәне тутырганы сизелми дә. Чәче генә... әүвәл агарып, аннары сизелер-сизелмәс кенә булып зәңгәрсулана башлаган. Рәссам күзе аны шунда ук хәтеренә сеңдереп куйды:

— Туктале, Зәйнетдин, син бит Нәҗметдин белән бездән ике-өч яшькә кечерәк. Ни рәвешле чәчең болай агарып-зәңгәрсуланып өлгерде? Гәүдәңә карарганда, бер дә бирешкәнгә охшамыйсың болай үзең, һич тә, күз тия күрмәсен. Яшьрәк чакларда Сабан туенда бил алышкан булды булуын, шунда да синдәй батырга каршы чыга алмас идем шикелле.

Зәйнетдин болай гәүдәгә таза, эшкә уңган булса да, сүзгә саранрак икән:

— Кая инде ул безгә синең белән ярышырга! Син бит яшең белән дә, һөнәрең белән дә бездән олуг-өлкән, Габделбакый... — дип әйтүдән узмады.

Өченче карт Сәйфетдин алай дию генә әзсендә, ахры, озынчарак башын чайкап алды да:

— Сиңа кул күтәрү, тел тидерү — гөнаһы кәбаир булыр иде,— дип өстәде.

Нәҗметдин дә сүзсез калмады:

— Шулай, кордаш, олы кунагыбыз син безнең,— дип, ияк какты.

Габделбакыйның көләч йөзе тәмам нурланып-балкып китте:

— Дөр-р-ес! Дөп-дөрес сукалыйсыз, егетләр! Хәким хәзрәттән сабак алган, бергә-бергә уйнап үскән кордашлар бит без...— дип, күңеле нечкәреп куйды.

Нәҗметдин карт барысы өчен дә җавапны үзе бирү ягын карады — ни дисәң дә, яшь ягыннан да бераз өлкәнрәк, аучылар-балыкчылар бригадасының бригадиры да, Күл-Черкендә генә түгел, бөтен әйләнә-тирә халкы үзен аксакал дип хөрмәт итә икән.

— Хак сөйлисең, кордаш. Нәкъ без уйлаганча уйлыйсың. Болай килеп чыкты бит ахырзаман вакытында. Без инде шул раскулачивание, теләсә кемгә «халык дошманы» дигән тамга салу заманнарын шулай атыйбыз. Тирә-якта шактый кеше читкә сөрелде. Безнең Күл-Черкендә, әлхәмделилла, беркем икенче берәүне чакмады, шикаять язмады. Шуңа һичбер хуҗалык каза кичермәде.

Зәйнетдин исә:

— Минем энекәш кенә харап булды, бичара...— дип, эчендәге әрнүен әйтеп куйды.

Ул сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, Сәйфетдин, күзләрендә ут уйнатып, чәчрәп чыкты:

— Энекәшең Ярулланың бит аның гөнаһлары да хәтсез күп булды. Шулар харап итте аны, берәүгә дә киная ташлыйсы түгел,— диде.

— Киная ташларга уйламыйм, җәлләп кенә әйтүем...

Әңгәмәнең андый борылыш алуына авылның аксакалы булган Нәҗметдин карт һич тә риза-бәхил түгел иде. Җитмәсә, хөрмәтле кунак алдында.

— Ипле генә, җәмәгать,— диде ул,— кызмагыз. Мин хагын әйттем. Үзегез уйлап карагыз: Апас-Буа-Чүпрәле тирәләрендә барча халык ду килде, тик безнең авыл халкы сынатмады. Хәтта әле ике мәчетебезнең манараларын кисеп, авылыбызны зар елаткач та, гауга купмый калды. Мисный влачтан каза күрмәдек. Авыл советының рәисе олыны олы итә белә иде. Ә бит үзе кырыс кеше иде болай.

— Карт-корыга хәер хаһ булды, дисең инде алайса?

— Әйе-е-е! Киңәш-табыш итеп яшәде гел. Яшьләрне дингә бик әгитләмәсәгез, үзегезне диннән яздырасым юк, сез миңа мишәйт итмисез, укый бирегез намазыгызны, ди торган иде.

— Мәчетне мәктәп иттергәч тә әле, безнең сүзгә колак салды. Һичбер комачаулык китермәде.

— Аннан соңгы башлыкларыбыз да юньле булды, Аллага шөкер. Колхозга гына һәммәбезне куып керттеләр...

Сәйфетдин янә чәчрәп чыкты:

— Колхозга тел тидерүегез урынсыз, агайне. Элекләре бит ничек иде: язга хәтле күп кешенең ашарына бетә иде. Шуннан бара инде хәллерәк крәстиannan әҗәткә икмәк сорарга.

— Яисә орлык...

— Анысын, орлыкны әйткән дә юк инде! Һәммәбез язгы чәчүне бурычка алып чәчә идек. Әле алай гынамы! Капчык асып, хәер сорарга чыгучылар күпме иде бит! Колхоз гына арындырды безне хәерчелектән. Минем сүзем шул.

Габделбакый көлеп җибәрде:

— Син бигрәк саллы басасың икән пичәтне,— диде.

— Һе, син белмисеңдер шул әле. Сәйфетдин бит писер. Пичәт басып утыра.

— Бер дә писер-бисер түгел. Колхозның счетоводы-бухгалтеры булыр абзагыз.

— Ху-у-уш! Бик әйбәт! Әфарин! — дип җупләүне кулай тапты кунак.

Аның кордашы буларак, Нәҗметдин карт дилбегәне үз кулына алу ягын карады:

— Эш болай тора, җәмәгать. Монда сөйләшеп кенә безнең сүз бетмәс, ахры. Без болай итик. Хәзер җыйнаулашып Зөя буйларыннан һәйбәтләп бер йөреп килик. Юл уңаенда гына минем өйгә сугылып, җәтмәсен-фәләнен дә ала чыгарбыз, аз-маз балыгын да чүпләштерербез.

Сәйфетдин чәнчеп алу форсатын ычкындырмады:

— Нәҗметдин абзый балыксыз яши алмый инде ул, — дигән булды.

Аучы-балыкчы Нәҗметдин карт, зур коңгырт күзләрен чак кына кыса төшеп, көлемсерәде дә:

— Әлхәмделилла, ходайның биргәненә шөкер, сый-нигъмәтнең бетәсе юк әле. Габделбакый кордашка берсен дә кызганып тормабыз. Су буйларын буйлагач, миңа кайтырбыз. Өемдә балы да, балыгы да җитәрлек булыр. Кузгалыйкмы? Ничек уйлыйсың, кордаш, сиңа кызык булырмы? — дип олы кунакка — Габделбакыйга текәлде.

Кунак исә эшләп ныгыган, көрәктәй кулы белән һаваны ярып:

— Инде, кордаш! Атлар коендырып, чыр-чу килеп, су чәчрәтеп уйнаган урыннар кызык булмаган кая инде! — диде дә, аягүрә торып басты: — Әйдәгез, киттек Зөя буена! Кайтарыйк шул гамьсез, шаян бала чакларны, — дип дәртләндереп куйды.

Сабый чакларын искә төшергәндә тәмам олыгаеп җиткән агайлар да күңелләре белән яшәреп китә икән. Зөя буенда авылдашларның күңелле гөрләшүләре еракларга яңгырап торды. Олы кунакның бәрхет-баритон тавышы су өсләрендә аеруча нык тибрәлде шикелле.

— Һәй, Зөям-Зөякәем! Балыгың һаман да элеккечә мулмы-түгелме? Бәхетне, Зөям, синдә сынап карыйбыз!..

— Нәҗметдин аның серен-сихерен белә. Коры кул белән дә эләктерә ул балыкны.

— Монда бит, кордаш, син югында шул балык белән генә туенган чаклар да булды, — дип өстәде бригадир. — Зөябез, рәхмәт төшкере, ачка үтермәде үзебезне...

Кунак, сыегая башлаган чәчен тараштырып:

— Хәтерлисеңме икән, кордаш, авылыбызга кырык тартмачы озаграк килми торса, кармакны кадактан ясый идек, ә? — диде.

— Онытып була димени андый хәлләрне...

Зәйнетдин дә сүзгә катнашты:

— Әле сез аны әйтәсез. Менә сугыш елларында минем малайлар да шулай кадактан әмәлләгәннәр ул кармакны. Балык хәтсез эләгә иде, ди, шундый кармакка да.

— Авыр еллар иде инде, авыр еллар, әйтәсе дә түгел...

Нәҗметдин карт ул арада сабакташына үзенең һөнәрен күрсәтергә теләде. Җәтмәсен чирәмгә җәеп салды да, җәһәт кенә барып, казыкка бәйләнгән көймәсен алып килде. Зәйнетдин аңа булышырга алынды. Кызык кешеләр була бит бу дөньяда: үзе күп сүзле дә түгел, чәчрәп тә чыкмас, ә үзе имән төбедәй таза гәүдәсен житез йөртеп, кирәкле эшен жиренә җиткереп эшләр дә куяр ул.

Авылдашларының җәтмә белән шундый да оста эш итүләренә хәйран калып, шактый карап торганнан соң гына рәссам гүя һушына килде, зиһенен җыйды, вакытны бушка, авыз ачып уздыруына ачынып мы, куен кесәсеннән блокнот белән карандаш чыгарды да, балыкчыларның сурәтләрен кәгазьгә төшерә башлады.

Һай дөнья, вай дөнья!

Шул чагында, чирәмгә утырган хәлендә көймәчеләрнең сурәтен төшереп бетерер-бетермәс, Габделбакыйның зәңгәр күзләре бер читтәге басмада кер чайкап маташучы ике хатынны шәйләп алды. Озын-озакка сузмыйча, рәссам аларның да кыяфәт-сурәтләрен кәгазьгә теркәде.

Ул да булмады, бу очтагы болыннан дөбердәшеп-мәэлдәшеп сарык көтүе су эчәргә төшеп җитте. Бу хәлне күреп, Нәҗметдин көймәсеннән көтүчегә тавыш бирде:

— Сибгатулла, син бу малларыңны бераз түбәнгәрәк алып төшәр идең, олан.

Кай арада чатан аяклы көтүче үзе дә күренде диген, түгәрәк койрыклы алабаена сызгырып ниндидер әмерен бирде. Алабай атылып су буена төште, анда су эчәргә ябышкан сарыкларны ду кубарып яр буйлата куып алып китте. Иясенең әмерен үтәгәннән соң гына, бая күзенә чалынган олы гәүдәле, түм-түгәрәк көләч йөзле чит кеше янына мыштым гына килеп иснәде дә, аның болай сарык көтүенә зыян китерерлек зат булмавына тәмам инанганнан соң, үз юлына элдертте.

Рәссам ул гөмбәче шикеллерәк. Гөмбәче бит нишли? Әле генә тапкан гөмбәне пәке белән кисеп алган арада аның күзе әйләнә-тирәне айкый — тагын да матуррак гөмбәләрне эзли. Рәссамыбызның да холкы-гадәте нәкъ шундый. Әле генә көймә белән балык тотарга Зөя суына кереп киткән сабакташларын-кордашларын кәгазьгә төшерә башлаган иде — Зөя суында кер чайкарга хатыннар килеп төште; аларның рәсемнәрен ясарга гына тотынган иде — сарык көтүе белән аждаһа-алабай дөбер-шатыр кузгатты; бу мал-туарны кәгазьгә терки генә башлаган иде — суның түбән агымында күпер калкып чыкты; шуннан инде сәнгатькәрнең хыялы, икенче төрле итеп әйткәндә — күңел күзе ачылды, эшкә җигелде: имештер, авылның сугышсыз-хәвефсез, имин генә яшәп яткан чаклары; йорт саен ат-сыер; әнә түбән очтагы күпердән печән олауларын җиңел генә тартып атлар кайтып килә; күпердән дә арырак — әтисенең мәчете пәйда була, имештер, әле аның манарасын да кисеп төшермәгәннәр; Зөя буенда, имештер, вак мал-туар түгел, береннән-бере таза вә көр мал-туар утлап йөри; имештер, кәгазьгә рәсем ясаучы да, аның авылдаш-кордашлары да башларына көмеш карлар яуган аксакаллар түгел, бәлки ат коендыручы малай-шалай... һи, алай гынамы соң: әле менә читтә гомер кичереп, Күл-Черкенен сагынып, Зөя буйларындагы илаһи матурлыкны бер күрергә зарыгып кайткан сәнгатькәр үзе дә, имештер, җирән кашкага атланган малай икән ләбаса!..

Беләк буе сазаннарны шундук чистартып, яр буеннан бераз читкәрәк китеп, казан аскан араларда авыл өстенә кичке эңгер җәелеп өлгерде. Колхоз эшеннән кайткан яшьрәк ир-ат та килеп кушылды. Хәл белешергә килүчеләр арасында Нәҗметдиннең ут күзле, чибәр йөзле улы Нәҗип белән Зәйнетдиннең сабыр холыклы улы Нуретдин да булып, анысы уңганлыгын шундук исбат итте: ике кулына ике сумка белән икмәген-яшелчәсен, кашыгын-савытын, ак башлы шешәсен-чокырын эләктерә килгән булып чыкты.

Авыл кешеләре гаять кызык бит алар: һәркайсы үзе бер җанлы тарих була торып, олылар алдында башлап сүз кузгатмас, әдәп саклар, әгәр инде читтән килгәнме-кайтканмы берәр зат булса, дөньясын онытып, аның авызына текәлер.

Хәер, кунагы да алай ук төшеп калганнардан түгел бит әле. Күл-Черкендә туып, ун яшенә чаклы беркая чыкмыйча шушында яшәгән. Хәким хәзрәт мәдрәсәсендә әлеге картлар белән бергә-бергә укыган, әтисен Кече Салтыкка имам-хатиб итеп чакыртып алганнан соң да әле, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем алган чакларында да, Мәскәүләрдә укып, зур кеше булгачтын да әле, үзенең ялан тәпи чирәм өстеннән йөргән җирен һичбер вакыт исеннән чыгармаган, ара-тирә авылны да, авылдашларын да сагынып кайткалаган сәнгатькәр сөйләгәндә авызына карата белә иде анысы.

— Һәй, авылдашлар, туганнар, бер генә җирдә дә юк бит шушы Зөя буендагы ямьлелек! Болай бит ул. Дөньяга килгәч тә, иң әүвәл әнкәңнең нурлы йөзен күрәсең. Гомерең буе аның бәхетле чагы, сиңа, син туганга сөенүләре хәтереңнән чыкмый. Туган авылың да нәкъ шулай, һич арт-

тырып әйтүем түгел. Монда инде авылның кара туфрагы да, яшел чирәме дә, салкын суы да, сиңа ачык йөз күрсәткән кешеләре дә һәркайсы үзенчә тәэссоратка иядер. Сагындыра гына бит шулар һәммәсе! Кайларда гына булынмады инде бу озын гомердә, кемнәр белән генә очраштырмады инде бу язмыш дигән кара сакалың! Урысы да булды аның, яһүде дә, казахы-үзбәге дә, немече-французы да. Әмма хакыйкать дигәнең бер генә: кая барып чыксаң да — туган ягыңны искә төшерәсең, табигатьнең гүзәллеген иң әүвәл Зөя буйлары, менә әле без рәхәтләнеп утырган чирәмле яр белән чагыштырасың; нинди генә асыл затларны очратсаң да — син аны, әлбәттә инде, берәр авылдашыңа тиңлисең, кыяфәтендәме-холкындамы шуның чалымнарын табасың.

— Син күргән кешеләр бит, кордаш, безнең авылга гына сыеп бетәрдәй түгелләр. Элекләре бездә ике мөхәллә иде, бүгенге көндә җәмгысе бер колхоз...

— Каян өйрәндең әле син, Нәҗметдин абзый, бу чаклы тыйнаклыкка? Үзең җитәкләгән әртилне кая куясың? Балыкчылар-аучылар әртилен?

— Шул да булдымы сүз? Аучылар-балыкчылар дигәнең шул ук колхозчылар, бер җәмәгать кешеләре ләбаса. Һөнәр ияләрен туплаган оешма гына бит ул зурдан кубып әртил дигәнең, олан.

— Мин кубаммыни зурдан? Район башлыклары куба. Ауга чыгасынитәсе икән — гел сиңа елышалар. Үзең дә әртил, өең дә.

— Өйнең ишеге һәр кешегә ачык, оланнар. Теләсәгез кайчан килегез дә керегез. Әлхәмделилла, ким-хур итмәм, ризык җәлләмәм. Әлегә минем кадерле кордашымны тыңлыйк.

— Әйе, күпме генә ягада йөрсә дә, үзебезнең ана телен онытмаган авылдашларыбызны, дип җиппәр. Хәер, әнкәйне, Күл-Черкенне гомер буена хәтерләгән кебек үк, телебезне дә ятратудан туктамадым. Юкса бит инде француз теле үзе матур, үзе бай, ул телдә укуы кызык булса, чын француз белән сөйләшүе нинди рәхәт. Барлык телләрдән дә матуррак сыман тоела ул миңа. Тик инде безнең телгә җитми. Татар теле бит ул үзе көйле-аһәңле тел, шул ук вакытта үзе кодрәтле-бай, теләсәң нинди фикерне аңлатырлык, сүзгә бик бай бит ул. Һәрнәрсә чагыштыруда беленә, диләр бугай. Иллә мәгәр, иң бай, иң кадерле тел — үзеңнең ана телең ул, дусларым. Иң әйбәте инде аның — үз ана телеңне белү!

— Абразауный кешеләр теле байдыр инде анысы. Алар шул телне китаптан өйрәнә, язучылардан. Безнең ише авыл халкы һаман шул бер балык башын чәйни инде, каян килеп бай булсын, ди, җитмәсә әле матур булсын, ди?

— Сез бер хакыйкатьне исегездә тотсагыз иде: бер генә әдип тә, ягъни язучы да телне үзе уйлап чыгармый, бәлки халыктан ала. Ихлас матур итеп, гыйбрәтле итеп сөйләүчеләр исә халыктан чыга, алар — авыл кешеләре. Әдипләр дә авылдан, шул ук татар халкы арасыннан чыга.

— Бусы инде, кордаш, салпы якка салам кыстыруыңдыр.

— Бер дә түгел. Мин үзем, әйтик, сезнең сөйләгәнегезне кич буе тыңларга әзермен.

— Нәстә генә сөйләрбез икән соң син белмәгәнне?

— Әйтик, менә миңа авылыбызның исеме каян килеп чыкканы мәгълүм түгел. Тотыгыз да шуны сөйләгез.

— Аның нәстәсен сөйлисең инде? «Күл» дигән сүз әйтеп тора бит каян алынганын.

— «Күл» дигәч, аның чынлап та үзенең күле булырга тиештер бит?

— Син безне бик бетереп ташлама, кордаш. Булган ул күлләр бу тирәдә. Ихтимал, безнең авыл халкы, борынгы бабаларыбыз шул күлләрнең берсе янына, олырагы янына килеп төпләнгәндер. Черкеннәр ишле бит алар, шул исемдәге авыллар саны, ачуым да бер килмәгәе, унга җитәдер — Буада гына түгел, Апас, Кама Тамагы районнарында да бар.

— Ху-у-уш! Анысы нидән килеп чыкты икән соң аның? «Черки» сүзеннән түгелләр бит?

— Күле булгач, сазлыгы да, черкие дә булгандыр анысы, булмый калмагандыр. Әмма ләкин «Черкен» сүзе кеше исеменнән, фамилиядән килеп чыкмады микән, диебрәк фикер йөртәм мин үзем.

Яшьләрдән берсе түзмәде:

— Кушамат булгандыр әле! — дип ярып салды.

— Анысы да бик ихтимал. Миңа калса, шундый фамилиядәге ишләрәк бер гаиләдән чыккан егетләр шушы төбәктәге урман арасындагы аланмы-күлме тирәсенә төпләнгәннәрдер. «Черкен» дигәне шуннан калгандыр. Ә менә «Күл» дигәне болай булган. Иманым камил монысына.

— Йә, йә, сөйләп кара, тыңлаек.

— Элегрәк бит безнең Зөя ә-ә-әнә теге урманлы яр тирәсеннән ага торган була. Шуннан Кият алпавыты, — ул чагында совхоз булмый бит әле, йөз илле еллар элек була бу хәл, — ауга чыкканда уйга кала бер заман. Зөя суы әллә каян ага, биш-алты чакрымнан. Бу тирәдәге авыллар һәммәсе дә күл буйларына утырган. Әгәр дә әлеге дә баягы күлләрне һәммәсен бергә тоташтырсаң, елганы яңа юлга салып була икән ич!

Тыңлаучылар:

— Менә сиңа алпавыт!

— Менә сиңа авыл бае! — диештеләр.

Олы кунак исә бик игътибар белән тыңлый иде.

— Йә, йә, шуннан?

— Шуннан бу Сембердәнме, бүтән берәр җирдәнме китертә зур укымышлы инженерны. Атларга атланалар да китәләр болар күл карарга. Күлләр чыннан да озынчарак, аралары бик якын була. Инженер алына бу эшкә. Алпавыт аны ашатып-эчертеп асрый инде, зур акча түлим, дип вәгъдә итә. Планнары тәгаен әзер булгач, губернатордан пичәт суктыралар да тотыналар авыл халкын эшләтергә.

Зәйнетдиннең үзе шикелле үк аз сүзле Нуретдине:

— Ул заманнарда бит техника булмаган, көрәк тә балта. Хәзер булса, экскаватор, грейдер белән күз ачып йомганчы актарып ташлар идек, — дип үз фикерен әйтүне кирәк тапты.

— Син алай димә, Нуретдин олан. Халык дәррәү кузгалса — әллә ниләреңне эшләп ташлый. Монда да шул: урманны кисәләр, агачларын төплиләр, туфрагын казыйлар, тырыша торгач күлләрне көзге суыкларга чаклы тоташтырып өлгерәләр бит, әй! Инженер шунда йөри инде, карап эшләтә, күз-колак була. Көздән үк ә-ә-әнә тегендә Зөягә илтеп җиткерәләр болар канауларын. Язны дулкынланып көтәләр шуннан соң. Күбесе ышанмый елганы турыдан агызып булырына.

— Ышанырлык та түгел бит.

— Язгы ташу хәл итә һәммәкиен. Бозлар берсен-берсе җимерә-вата башлагач, ташу суы болайгарак авыша. Ташулар авылның яныннан гына ургылыпмы-ургыла. Атна-ун көн дигәндә, ни күрсеннәр — Зөй суы рәхәтләнеп агып ята икән яңа юлыннан! Шулай итеп, бер акыллы кешенең башы җитә шул Зөяне ничәмә-ничә авылга якынайтырга.

— Ярын биегрәк иттерәсе калган, югыйсә бит ара-тирә безнең урамны су баскалый.

— Анысы аның әллә нигә бер була торган хәл инде...

— Нәҗметдин абзый, урманны кая барып кистеләр икән соң? Зөянең бу ягында бичара таллар, теге якта да болын гына...

— Оланнар, сез белмисез генә. Безнең бу төбәктә калын кue урман үсә иде. Әле урам уртасында калын-калын имәннәр шаулап утыра иде. Габделбакый кордаш белән без җиләккә йөри торган идек.

Рәссам да кордашының сүзен хуплады:

— Дәр-р-рес! Нәкъ шулай, дустым. Хәтерлисеңме әле бер мәлне адашып яңгырга эләккәнебезне?

— Булды бугай андый хәл.

— Булды гынамы соң! Олылар үзебезне көчкә эзләп таптылар.

Яшьләр мәзәккә бору ягын карадылар:

— Ышануы авыррак: үзе Урманче булсын да, үзе урманда адашсын, имеш.

— Әйе, булмагандыр ул хәл...— диештеләр.

— Безгә бит нибары җиде-сигез яшь иде. Әлеге акыл юк иде. Ә безнең фамилиягә килгәндә, кайсыдыр бер бабабыз чынлап та урман кисеп, ат белән калага утын ташый торган булган. Урыслар шул кушаматны фамилиягә әйләндереп, волость писерьләре кәгазьгә шулай терки башлаганнар. Шул рәвешле билгеле бер кәсепкә, һөнәр иясенә бирелгән исем бөтен нәселебезгә фамилия булып киткән. Әтигә ошый иде фамилиябез, мин дә үзгәртмәдем. Хикмәт бит исемдә түгел, дусларым, газизләрем, хикмәт җисемдә, хикмәт синең үзеңдә,— дип олы кунак әңгәмәгә нокта куйды.

Нәҗметдин улы Нәҗип, көлемсерәп:

— Сиңа бит, Бакый абзый, һичьюгы шүрәлеләр килеп юл күрсәтергә тиеш иделәр,— дигәч, яше-картының авызы ерылды.

— Киләсе иде шүрәлеләр, әлбәттә, киләсе иде! Тик минем әткәй өлгеррәк булып чыкты.

Ул арада Нуретдиннар табынны да әзерләп өлгерделәр. Яшелле-кызыллы бизәкләр төшерелгән бердәнбер таштабакны олы кунак алдына куйдылар.

— Сиңа, рәссам кешегә шундыен куйыйк әле,— диделәр.

Кунакның кәефе тагын да ныграк күтәрелде.

— Һай, рәхмәт, егетләр! Тамам күңелне күтәреп җибәрдегез бит әле,— дигән булды.

Сәйфетдин генә тамагын кыргалады, картларны күздән кичерде, яшьләр алып килгән күн сумка ягына карангалады.

— Синең күтәрелгәндер дә бит, менә минем күңел бик төшенке бит әле.

— Нәрсә булды соң?

— Ни хикмәт икән ул алай?— диештеләр.

— Ухагыз тамактан үтми. Бик коры булган. Шуны бераз чылатып җибәрергә җае юк микән, дип өметләнеп утырган көнем.

— Балык су ярата инде ул яратуын... Тик менә, өлкәннәр ничек карар икән, диебрәк кенә, тартыныбрак торабыз.

Нәҗметдин карт мыек астыннан гына елмайды, Зәйнетдин аш бүлү белән мәш килә иде, дәшмәде. Сәйфетдин исә үзен алар өчен җавап бирергә хаклы санады:

— Уха булсын да, шуның янына ярты куелмасын икән. Әпитит күтәрергә ярап куяр ул.

Нәҗметдин картның үзе шикелле үк уңган улы атасына төбәлде:

— Әткәй, дим, ничегрәк булыр икән соң?

Аксакал аңа ым какты. Нәҗип күн сумкадан гәҗиткә төрелгән шешә чыгарды. Нуретдин дә үзенә эш тапты: картлар алдына чокырлар тезеп чыкты. Кунакның:

— Барыбызга да булмады бит әле, үзегезне дә рәнҗетмәскә идегез,— дигәнен ишеткәч, тыйнак кына:

— Авылның аксакаллары алдында авыз күтәреп аракы чөмереп утырмабыз инде,— дип җавап кайтарды.

Кыстаганга үпкә белдерү чагылган мондый тыйнаклык олы кунакның күңеленә хуш килде:

— Дөре-е-ес! Бик матур әйттең бит әле, Нуретдинҗан, егет икәнсең!— дип хуплады.

Сәйфетдин исә, шешәне үз кулына төшергәч, елмаеп-көлеп сөйләшер хәлгә килде:

— Сыерлар су эчкәндә бозаулар боз ялый. Бер дә кайгырма син, үзебезгә күбрәк тияр,— диде. Чокырларга бүлеп чыккач:— Әйдәгез, абзыкайлар, тотып сөйләшегез әле,— дип эчәргә кыстады.

Рәссам, авызын бөреп, кулына чокырны алды, чыраен сытыбрак:

— Бу юньсез нәрсә белән әлләни дуслыгым юк югын да... Әмма ләкин бүген көчне сынап карарга, хәерсез белән алышырга исәп... Дөньяда иң ямьле елга булган Зөя хөрмәтенә! Сез дусларым исәнлегенә! — дип, сыйдан бераз авыз итеп куйды.

Ашаган-эчкән арада әңгәмә бүленеп калган иде. Моны килештереп бетермичә, кунак дилбегәне үз кулына алды.

— Беләсезме, дусларым, сезнең белән бергә-бергә утыру, әлеге мәҗлес минем күңелдә әллә нинди хатирәләр уятты, әллә кайларга алып китте бит әле...

Рәссам оеткыны шулай гаять оста сала торган иде. Аның хикмәтле-гыйбрәтле хәлләр сөйләргә ниятләвен абайлап, табын янындагылар сулу алырга да курыккандай, тынып калдылар. Кунак ашыкмады, тамагын кыргалады, аннары инде мәһабәт чал башкаен артка ташлап, мәгърур кыяфәт белән сөйләп алып китте:

— Казакъ далаларында көн буена бернинди тавыш-тын ишетмәссең, һәркем үз эше белән мәшгуль. Менә бер заман дала өстенә эленә башлый кечке эңгер. Көтү кайта. Шунда бит, дусларым, әйтсәм — ышанмассыз: гүя бөтен дала, тоташы белән, җанлана-тернәкләнә, өйләр бит анда киездән әмәлләнә. Тирмә диләр үзләренә. Шул тирмәләр янына асып җибәрәләр иләмсез олы казаннар. Анда пешә куй ите. Симез ит, яман симез. Хатыннар, бала-чагалар мәш килә инде менә учак янында. Кайсы корыган дала үләне китерә, кайсылары кипкән тизәк ташый...

Рәссам, тыңлыйсызмы-юкмы, әллә тикмәгә сөйләп сүз генә әрәм итәмме, дигәндәй, уңга-сулга күз йөртеп чыкты да, игътибарлы булуларыннан, сүзнең кадерен белүләреннән канәгать калып, тамагын кыргалап, әңгәмәне дәвам иттерде:

— Ир-ат халкы инде вак-төяк эштән азат анда. Ир-ат халкы шушылай түгәрәкләп утыра да гәп корып җибәрә. Гыйбрәтлерәк хәлләр сөйләнгәннән соң арада бер осталары кулына думбрасын ала соң. Шуннан илаһи бер дәрт белән кылларны чиртә башламасынмы! Учак янына җыелган халык кына тыңламый останың уйнаганын. Кичке эңгергә иңгән-чумган далага, киездән корылган тирмәләр өстенә озын моңлы көй канат җәя. Бөтен җиһан, тоташы белән, гүя моңга туена, көйгә төренә...

Кордашының ай-ваена карамыйча, Нәҗметдин карт су буеннан олы кунакны үз өенә алып кайтты. Каршы торудан файда чыкмаслыгын аңлагач, Габделбакый артык сүз озайтып маташмады, тар гына тыкрыктан, бәрәңге бакчасы буйлап тыныч кына атлады.

— Һәй, сездә сукыр кычыткан хәтсез икән! Йөрәктән бик файдалы бит ул,— диде.

Авылдашы ана:

— Җитмеш яшемнән үк йөрәк даруы эчәргә исәбем юк югын да... Сукыр кычыткан ярап куя ул кайчагында,— дип җавап кайтарды.

Бәрәңге бакчасы Зөягә караган ихатага өр-яңа ян капкадан олы кунак көләч йөз белән килеп керде. Иң әүвәл эшләнеп бетеп яткан зур яңа капкага хәйран калды. Калмаслык та түгел иде шул: биек имән баганалар тутыкмый торган калай белән тышланган; күгәннәре үзенә бер ямьле; такталары һәйбәтләп ышкыланган, берберенә сылангандай тоела иде. Кунакның соклануын күреп, хуҗа тыныч кына:

— Әллә ние юк инде болай үзе. Минем малай маташтырган була шунда,— дип куйды.

— Әлеге дә баягы Нәҗибеңме?

— Шул инде, шул. Төпчек малай булгач, йортта ул торып калды.

Ихатадагы пөхтәлек янә дә исеңне-акылыңны китәрерлек иде. Гәрчә капканың әлегә эше бетмәгән булса да, киң-иркен ихатада ник бер йомычка әсәре күренсен. Хуҗа көлемсерәде дә:

— Йорт тирәсен пөхтә тотуны анысы берәүгә дә биргән юк әлегә. Әлхәмделиллә, үземнең әүкәтем бар анлык кына,— дип төшендерү ягын карады.

Түрдә, капкага каршы, түбәсе ак калай белән тоташтан ябылган каралты-кура сузылган. Сул якта эре-эре бүрәнәдән өелгән, тәрәзә башлары-яңаклары бизәкләп эшләнгән, өстәвенә майлы буяу белән зәңгәрсу-акка буялган, үзе хәтсез биек, үзе мәһабәт өй шыңгырдап тора иде. Өйалларын аргы буйга ук узып, каралты-курага каратып салганнар. Шул тарафларга житеп, гарәбәдәй болдыр алдына барып туктагач та, хуҗа үзе тавыш бирүне урынлы тапты:

— Өйдәләрме сез, Шәмсенур?— диде.

Олы яшькә житүенә карамастан, әле камыр шикелле изрәп төшмәгән, ачык йөзле хуҗабикә болдырда күренде. Кунак, гореф-гадәт кушканча, тыйнаклык-әдәплелек күрсәтеп:

— Исән-имин генә яшисезме? Хәл белеп кенә чыгыйм дип сугылыр булдым әле менә,— диде.

Хуҗабикә балкып:

— Әйдәгез, хуш киләсез,— диде. Аннары картына мөрәҗәгать итте:— Сиңа әйтәм, әтисе, жинел кулдан гына мунча өлгерткән идем. Бераз юынып-пакьләнеп алмассызмы, дим. Нишләрсез икән?

— Һәй, карчык, бигрәк әйбәт иткәнсең! Нишләрсез, дип сорап торасы да юк. Сабакташның әле ни гомердән бирле үзебезнең авыл мунчасында юынганы юктыр.

Кунак артык кыстатырга исәбе юк икәнне сиздереп:

— Юыну түгел, кордаш, күргәнем дә юк, авыл мунчасының нинди икәнен үк онытттым инде,— диде.

Өйгә каршы юкарак бүрәнәдән салынган, җыйнак кына мунчага таш баскыч буйлап менделәр. Алгы бүлемәнә кергәч тә, кулдан тукыган паласлар җәелгәнен күреп, кунакның исе китте. Элеккеге замандагы, ул белгән авыл мунчасының эзе дә, исе дә юк иде биредә.

Чишенеп, бусаганы атлап узу белән, кунак янә дә хәйран калды. Сул кулда калай белән тышланган мич; аннан ары биек ләүкә; ләүкә асты конус сыман чокыраеп тора, цементланган; сайгаклары тимердән булып, калын тар идән такталары матурлап түшәлгән; ян-якта сәкеләр; ул сәкеләрдә зур-зур ике таз; киштәдә сабын-мунчала.

— Күңеленә хуш килгәнен сайлап ал, кордаш. Себеркеләр әнә парланып ята. Бөтнегә, сукыр кычытканы шунда ук хушлана. Кайнар су шушы краннан ага, салкыны менә бусыннан.

— Һай, рәхмәт! Һай, булдыргансың барын да.

— Минем малай маташтырган булды шунда мунчасын да.

— Суларын да үзе керттеме?

— Үзе әмәлләде һәммәкиен дә. Бурасын үзе бурады, куйды; мичен үзе чыгарды; утын-суын үзе кертте — электр белән яга торган иттерде. Эссесен әзсенәсең икән инде, менә шушы төймәгә генә басабыз да — момент кыза аның миче.

— Һай, уңган икән дә соң улкаең!

Мунчада ашыкмыйча гына чабынып-юынып, тәмам әлсерәп, кызарынып-бүртенеп өйгә кергәч, кунак янә дә хәйранга калды шул. Өйнең эче үзе биек, үзе иркен; гаять калын бүрәнәләр эчке яктан юнылган да шомартылган, гәрәбәдәй тезелешеп, араларына чигеш сыман иттереп сүстән юллар сузылган; түрдә зур өстәл, аның тирәсендә авыр имән урындыклар; тәрәзә араларында лаклы комод-мазар; залдан уң кулда йокы бүлмәләре; анда дивар буйларында саллы караватлар...

— Һай, дустым, бигрәкләр хәлле яшисез икән, күз тимәсен.

— Кордаш, монда бит бер генә дә кибеттән алган әйбер юк. Малай маташтыра минем...

— Бу чаклы булса да булыр икән! Күр әле син аның агачны оста сайлавын! Бу имән комодның сызыгы сызыкка ябышып тора. Имәнне

төсенә-сурәтенә карап сайлый белгәч, ул инде рәссам дигән сүз. Шундый уңган, алтын куллы, игелекле егет үстергән өчен әтисе белән әнисенә рәхмәт яусын!

Хуҗа үзе сер бирмәде, мәгәр аның карчыгы чаршау артыннан нурлы йөзен күрсәтте:

— Яхшы сүзеңә рәхмәт инде, авылдаш,— диде.— Әтисе, табын әзер, утырышыгыз, мунчадан сусап чыккансыз,— дияргә дә онытмады.

Өйдә әзерләнгән токмачка ни җитә? Берни җитми. Катык та катып җибәрсәң, бигрәкләр әйбәт була. Габделбакый токмачына ике-өч кашык салып кына калмады, каймаклы катыкны алдынарак тартты да мактый-мактый ашап ташлады. Хуҗалар сөенделәр генә. Хуҗабикә табын янына, әлбәттә, утырмады — әле тегесен, әле монысын ташудан бушамады. Бәрәңге белән бергә өелгән сыер ите бигрәк яшь һәм дә тәмле булып чыкты. Шуннан соң инде кунакның кабарга да урыны калмагандай тоелган иде, ә менә татарның милли ризыкларыннан йөзек кашы саналган чәкчәк белән балга чират җиткәч тә, сынатырга уйламады. Чынлап та ризыкларның һәркайсы тәмле һәм үзенчәлекле иде. Кунак ихластан яратып ашады-эчте.

Хуҗабикә генә улының озаклап тоткарлануына борчыла башлады бугай. Әмма хуҗа үзе хафалануын сиздермәде:

— Йөреп калсын, карчык, аягына сыер баскач, йөри алмас,— дип кенә җибәрде.

Кунак әлеге хәлне тәгаенләргә ниятләп:

— Нәрсә, башлы-күзле итәргә мәллә исәбегез?— дип кызыксынуын белдерде.

Хуҗа аңа шундук хәлне аңлатып бирде:

— Әйе. Әллә кайчан вакыт инде югыйсә. Әрмиядән кайтканына биш былтыр. Һаман суза килә. Ярты авылны өйле итте инде. Йөргән кызы да оялып кына безгә сугылгалый: әле бер йомыш тапкан була, әле икенчесен...

— Син, атасы, бигрәкләр инде турыдан сукалыйсың. Күрше булгач, керми ни хәл итсен инде ул кыз бала?

— Нәрсә, күрше-коланмыни? Белгән-күргән кешемени? Әти-әниләре юньле кешеләрме соң?

— Һәй, кордаш, әйттең сүз! Син дә беләсең әтисен. Бая гына бергә утырдык бит үзе белән. Зәйнетдин кызын алырга исәбе. Шуның белән йөргән була, Мөнҗия белән.

— Зәйнетдин үзе болай каршы түгелдер бит?

— Шундый алтын куллы егеткә нишләп каршы булсын ди әле Зәйнетдин? Башына тай типмәгән лә. Мөнҗиясе дә ихлас яратып йөри. Бер көн күрешмәсәләр, хәзер йомыш тапкан була да кереп җитә. Минем малай гына суза. Ашыгу гадәте юк шуның. Бер генә эшен дә кабаланып, ашык-пошык эшләп ташламас.

— Мин күргән кадәресе һич тә ашык-пошык, җиңел кулдан эшләгәнгә охшамаган. Маладис, карап туймаслык. Ул капкасы гына ни тора.

— Капка дигәннән... Әле теге эшенә сылтый, әле монысына. Атна кич корырак кына сөйләшеп караган идем үзе белән. Көлә генә, хәерсез. Капканы бетерми торып, авыз ачма, әткәй, дигән була. Әйтерсең лә күрше авылдан, пар атлар җиктереп килен төшерәсе бар инде! Ике йорт аша гына бит Зәйнетдиннәр, төтен күршебез...

— Син кызма алай, дустым. Тәртәгә тибүдән бертөрле дә файда чыкмас. Киленебез төкле аягы белән яңа капкабыздан атлап керсен дә, пар күгәрчендәй гөрләшеп, иминлек белән тигез гомер кичерсеннәр, диген. Бездән дә картраклар нинди васыять әйтеп калдырганнар әле безгә? Сабыр иткән — морадына җиткән, дигәннәр түгелме? «Вә ас-бир»,— дия иде минем әткәй.

— Анысы шулай, кордаш, сабыр төбе — сары алтын инде анысы,— дип ризалыгын белдерде дә тавышын бераз күтәрә төшеп хатынына эндәште хуҗа:— Карчык дим, кунакны каярак яткырырбыз икән соң?

Хужабикә җавап бирергә өлгермәде, рәссам:

— Сез нәрсә, дусларым, мине үзегездә кундырырга ук уйладыгызмыни әле? — дип, көлеп җибәрде.

— Кордаш, синең кодаларыңда җыен хатын-кыз гына. Сиңа анда куна калу килешеп бетмәс. Аларны иртәгә боерган булса, бергә-бергә кереп күрербез, хәлләрен белербез. Хәзер карчык аларга хәбәр биреп кенә чыгар.

— Сездә куна-төнә ятарга соң инде... Бүләк-фәлән дә алып кайтмаган идем бит ичмасам...

— Син безгә үзең бүләкнең дә иң олысы. Авыз да ачасы булма. Карчык, урынны кая җәярсең икән, дим?

— Җәй көне өйдә бөркү булмагае дип, мин аңа, атасы, Нәҗип янына чоланга җәйгән идем урынны. Райком сикритәре дә бик ошаткан иде бит чоланны.

Чолан дигәннәре юка тактадан ырмаулап корылган, бәләкәйрәк кенә тәрәзәле, пөхтә генә бүлмә булып чыкты. Хуҗа үзе электр лампочкасын яндырып җибәргәч, кунак монысына да сокланып туя алмады. Агачтан ясалган ике караватның түрдәгесенә зәңгәрсу буй-буй җәймә җәелгән, береннән-бере ныграк кабарып торган ике мендәр аслы-өсле салынган, аяк очында исә мамык юрган. Укып ятарга исәбең булса — баш турысына электр лампочкалы бра көйләнгән...

Бүген хәтсез күп йөрелде, мендәргә башым тию белән, йоклап китәрмен, дигән кеше тиз генә оныта алмады. Болай да хискә бирелүчән шәхескә авылына исән-имин кайтып житүләр; сабый чакларында таптаган туфракны, каймактай үзле, галәмәт кара туфракны яңадан күрү бәхетенә ирешүләр; Зөя буйларында коенып та сыйланып алулар; авылның терәге булган яшьләрне очратып, алар белән гәпләшүләр; һәркайсының үзенә карата дустанә мөгамәләдә булуын тоюлар; ахыр килеп, кордашының йортын-дөньясын, ни рәвешле көн итүен күреп сөенүләр — болар барысы да биниһая нык тәэсир иткән иде. Сәнгатькәр һәммә нәрсәне төрле-төрле төсләрдә күрергә, моңлы көй буларак ишетергә күнегеп-гадәтләнеп беткән иде инде. Шуңа күрә тәэссорат көче, әле мамык мендәрләргә яткач та, салмак кына моңлы көй булып яңгырап торды, аңа оеп китәргә һич кенә дә ирек бирмәде. Ара-тирә әлеге талгын-сабыр көйне ул үзе сузадыр сыман тоелгалады; әмма яңадан-яңа истәлекләр өелеп, аны бу уйдан кайтырга мәҗбүр итәләр, сабый чакларга өстериләр иде...

Туган як хатирәләрен һәркем гомере буена саклый булыр, оныта алмыйдыр. Габделбакыйның да исендә-хәтерендә Буа яклары, туган авылы Күл-Черкендә сабый чакны күргән-кичергәннәре: ике гасырның арасында яткан киртәне үрмәләп-мүкәләп чыккалаганчы байтак сабак алды бугай ул Күл-Черкендә... Менә бүген дә ап-ачык, жете буяулар белән язган картиналардай, күз алдында әле берсе, әле икенчесе... әле йөзенчесе пәйда була.

Идрис хәзрәт белән Мәһзүбә абыстайның ишле гаиләсендә туып, җыен апа-сеңел арасында үсте Габделбакый. Алты кыз, өч малай. Хәзрәт өендә шау-шу купмый, гауга чыкмый, бала-чага искиткеч әдәпле, тәүфыйклы, итагатьле — анысы шулай. Әмма бере арты бере агылган әнә шул тыныч көннәрдә дә балкып киткән, жете буяуларга бай картинага әверелеп, күңелендә мәңгегә уелып калган хәлләр-вакыйгалар була торды. Габделбакыйның газиз истәлекләре әнә шунда башланды. Хәзер инде һәркайсы төрле сихри төсләргә буялган картина буларак гәүдәләнде, ягымлы-моңлы көй буларак яңгырап ишетелде.

## Менә бер картина-манзара

...Әллә аш өендә урын житмәде, әллә аякларын чалыш-чолыш китереп йөрүче кызыл бозау ялгыш имгәтмәгәе үзләрен, диделәр инде — сарык бәрәннәрен олы өйгә күтәреп керделәр дә, зур мич арасына салам түшәп, шунда салдылар. Бала-чага йокларга ятып өлгергәнлектән, егермеле лампаны кабызып тормадылар. Тыштагы суыктан котылгач, нәп-нәни бәрәннәр саламга чумып, йомылып кына яттылар. Әйе, кичтән бернинди тавыш-тын чыгармадылар, ә инде таң беленүгә...

Габделбакый үзенең корсагы өстеннән нинди җан ияләре йөгерешеп үтеп киткәнен һич аңлый алмыйча ятты. Әбисе атна-ун көн элегрәк кенә сөйләгән әкияттәге җен-пәриләр түгелдер ләбаса? Әгәр дә шулар булса?

Малай җен-пәриләрне качыра торган доганы авыз эченнән генә укыды да укыды, аннан соң инде, юрганын башыннан ук ябынып, тынычлап кына йокларга ниятләде. Мәгәр авыз эченнән укыган доганың нишләптер файдасы тимәде: җен-пәриләр янә дә тыпырдашып аның өстеннән йөгерешеп үттеләр. Эш болай зурга киткәч, доганы кычкырыбрак укырга туры килде — малайның башка чарасы калмады.

Шул чагында апаларының пырхылдашып куйганы колагына чалынды. Юрган астыннан башын чыгарып, күзен тутырып ачып карады. Мәгәр сәкенең аргы башында яткан апаларын, бик тырышса да, күрә алмады. Өй эче караңгы иде әле. Күрүен күрмәсә дә, апаларының уяу икәннәрен шәйләгәч, күңеленә җылы керде тагын. Шайтаннар алар ялгыз чагыңны сагалыйлар. Димәк, алар түгел дигән сүз. Ниндирәк җан ияләре икән соң алайса?

Күзгә төртсәң дә күренми. Сәке өстендә янә тыпыр-тыпыр шайтаннар биегәне ишетелде. Малай зиһенен җыярга өлгергәнче, янбашын нииндидер очлы нәрсәләр көйдереп алды. Габделбакый, апалары йокламаганны аңышкач, кыюланып китеп, юрган астыннан кулын да чыгарып карады — шайтан әләксә шайтанның үзен әләктерергә иде исәбе, тоттырмады гына...

## Янә дә манзара

Атка бик иртә ияләште Габделбакый. Әүвәлге атлануы ике-өч яшендә булды. Андый хәлне гомереӊ буена онытa алмассың.

Идрис хәзрәт, авыл кешеләренә хас булганча, атлы-сыерлы крәстиән тормышы белән яшәде. Иманасын үзе сукалады, чәчте, урды, хуҗалык эшләрен бик теләп үзе башкарды: читтән килеп садакага эшләүләрен күңеле өнәмәде, чынлап торып хезмәт хакын түләргә-бәхилләтергә исә — ишле гаиләдән һич кенә дә арттыра алмады.

Язгы кыр эшләрен башкаруда буаз биясенә ышанып җитмичә, раштуа суыклары узу белән, Буа базарыннан картрак кына алаша сатып алып кайтты. Әле ярый, алып калды, югыйсә язга таба ат сатучыны көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Кадер-тәрбия килеште, кабыргалары күренми башлады, ит кунды үзенә.

Ул арада бия дә колынлады. Озын торыклы, зур башлы җирән колын ике яшьлек Габделбакыйга гына түгел, апаларына да ошады. Малай тәмам аранга күченеп, көнен-төнен шунда уздырырга әзер иде. Әтисенең кырыс карашыннан гына шүрләде һәм ара-тирә олыларга ияреп керү, колынның маңгаена төшкән ак йолдызын сыйпау белән канәгатьләнде.

Идрис мулла баштарак бияне борчымаска уйлаган иде, кыр эшләрен алаша белән генә башкарып чыгарга ниятләгән иде. Әмма ике-өч көн рәттән сукада йөреп, карт алашаның ярыйсы ук өшәнүен күрде. Шуннан

инде бияне дә кыр һавасын иснәтергә туры киләчәген шәйләде. Ни хәл итмәк кирәк, бияне саклыйм дип, карт алашаны күрәләтә аяктан егып гөнаһлы булмас ич инде. Җинелрәк эшләргә бия дә ярап куяр. Әйтик, тырмалау-мазарга...

Остабикәсе белән дә киңәшләшкәч, хәзрәт нәкъ шулай эшләргә катгый карар кылды. Өйләдән соң колыны белән бергә бияне җитәкләп кенә ике чакрымдагы кишәрлеккә илтергә кушып, алашасын җикте дә, агач тешле тырманы да арбага салып, басуга китеп барды.

Өйлә җитәр-җитмәс үк Мәһзүбә остабикә, әгузе-бисмилласын әйтәәйтә, биясен йөгәнләп алды, ихатага чыгарды, өр-янадан ашатты-эчертте, елкылдап торган сыртыннан тузанын каккалады. Анасы агач тагарактан ашаган арада җирән кашка колын, тавыкларны пыр туздырып, йортны берәр мәртәбә әйләнеп чыкты, аннары анасы янына барып, тагаракка борынын төртте, әмма андагы ризыктан әллә ни тәм тапмыйча, имәргә ябышты.

Байталны җитәкләгән көе сабыр гына атлатып авылны чыккач, аннан соң да шактый юл алгач, Мәһзүбә остабикә артына борылып карады. Колыныбыз артка калмагае, дип шикләнгән иде. Борылып каравы булды, баскан урынында егылып китә язды: атының тезгенен ычкындырмый гына, йөгән каешына тотынып, көч-хәл белән аяк өстендә калды. Аптырамаслык түгел иде шул: колынга тагылып, ялан аяклары белән чирәмле юлдан чаштыр-чоштыр атлап аның өченче яшькә генә чыккан багалмасы килә түгелме соң? Апалары алай-болай килгән арада, аларга сиздермичә генә чыгып сызган булырга охшый. Ачуланудан файда юк. Авылга кайтарып маташу вакытны алачак — хәзрәт болай да дүрт күз белән көтә булыр.

Улы пестер-пестер атлап үз янына килеп җиткәләгәнче остабикә нишләргә икәнен уйлап та өлгерде. Бу сабыйның адымына-жаена барсаң — атасы янына ахшамсыз барып җитә алмассың. Күтәреп кенә барыр иде — үзе йөкле; хәзергә әллә ни сизелми сизелүен, тик менә хәзрәтнең кәефе кырылуы бар, һич тә килештереп бетермәс. Берләнбер чарасы — атка атландыру кала. Сабыйның коты алыныр инде. Хәер, үз гаебен белә бит, кырысрак торсаң — башка барыр җире юк.

— Һай, улым! Син дә әтиең янына барырга булдыңмыни? — дип сөйләнә-сөйләнә, остабикә үзенең олы малаен (иншалла, бусы да малай булыр, хәзердән үк кыланышлары шуңа тарта!) күтәреп тә алды. Кәшимир яулыгының чите белән битен сөртеп җибәрде. — Тик, улым, балакаем, егет кешегә болай, хатыннар шикелле, җәяү йөрү килешмәс. Биягә атланырсың, балакаем.

Малай башын борды, бармаклары тырпаешып торган йомшак кулларын атның колагына сузды:

— Атка атланам! — дип ике генә сүз әйтте.

Остабикәнең әлеге сүзләрдән көләселәре килсә дә, борчылуы һич тә кимемәде. Байталның тыныч кына торганын абайлап, малайны ике култык астыннан алды да җайлап кына атның сыртына атландырды, сыңар кулы белән аркасыннан сөеп тоткан хәлдә, икенчесе белән сабыена ат ялына ябышу әмәлен күрсәтте.

— Ныклап тот, улым, куш учлап ябыш! Габделбакыем егет икән дип, әткәң сөенерлек булсын!

Кызык икән, атка бер атлангач, гел атланасың килеп тора икән. Габделбакый тәмам дөньясын онытты, ничек тә ихатада, ат янында чуалырга тырышты. Әткәсе ат җиккәндә тезгенен тотып торды, йөгереп кенә барып, чыбыркыны алып килгәләде, әткәсе дилбегәнең очларын йөгән алкасына бәйләгән арада арбага менеп кунаклый торган булды. Апаларының атка исләре китмәгәч, улының һаман ат янында чуалуын күреп, Идрис мулланың чыраена елмаю чыкты. Малайны ерак алып бармаса да, тыкрыкка чаклы утыртып алып бара да иңләп кенә үзе күтәреп төшерә, йөгереп киткәнен карап кала торган булды. Ә инде атны

коендырырга алып барганда, әлбәттә, улын атландырмыйча калмады. Баштарак аны беләгеннән тотса да, тора-бара сабыйның ат ялына чытырдап ябышканын, курыкмавын абайлап, тезгенне тотып алдан атлады.

Ел башы — елга башында, диләр. Язгы ташулар узып, урамда чирәмнәр баш калкыту белән, үрдәк-каз бәбкәләре алпан-тилпән килеп инешкә юллану белән, ялан тәпиле малайлар да авыл урамына сибелеп, чирәмдә әүмәкләшә-уйный башлау белән, Габделбакый да үзен дәүрәк итеп тойды, аяк-кулында күбрәк егәр сизде — йөгергәндә үз урамнарындагы малайлардан кызурак чапты, берсен-бер уздырмады; чирәм өстендә көрәшергә тотынсалар, берсеннән-бер җиңдермәде. Узган-барган олылар авызыннан:

— Мулла малае шул ул, тәрбиясе әйбәт,— дигән хуплау сүзләре дә колагына чалынгалады. Әмма уен кызыгыннан башы-күзе әйләнгән мәхдүмнең андый «хуплауны» аңлап торырга вакыты юк иде, шуңа бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты.

Урамдагы уеннар ничек кенә кызык булмасын, Габделбакый өчен җир йөзендә күңелен иң-иң нык җәлеп иткән нәрсә ат янында әвәрә килү, җае чыкканда исә атланып йөрү булды. Тора-бара малай олыларның үзен күтәреп атландырганнарын да көтми башлады — тезгенне учына кысып тотар иде дә, үрмәләп арбага менәр иде, шуннан атлану әмәленә өйрәнде.

Улының тырышып-тырышып атка атлануын күреп торган Идрис хәзрәтнең авызы колагына җитә, күңеле тәмам эри торган булды. Ул инде хәзер, басудан эштән кайткач, атын тугарып, кичен бераз ашатып кайту нияте белән, улына ышанып, болынга да җибәргәләде.

Болынга җитү белән, малай ат өстеннән, ялга ябышып, акрынлап кына шуып төште. Кулыннан тезгенне җибәрмичә генә, үлән куерак үскән урыннарга җитәкләп алып баргалады. Атның иреннәрен кыймылдата-кыймылдата үлән кертләвен биһуш китеп күзәтүен белде. Тышаулап җибәргән башка атлардан ераграк булу ягын карады: тибешә башламагайлары, дип сагайды. Хәер, басудан арып кайткан атларда тибешү кайгысы калмый торгандыр инде. Шуңа күрә малайның кичләре тыныч кына уза торган иде. Ә инде малкай ашап туйгач, эңгер-меңгер тәмам куерып җиткәч, атны елга буена алып төшә иде. Һәйбәтләп эчертә дә, корсагы мичкәдәй кабарып киткән атны түмгәкләнеп торган җиргә алып бара да шуннан сыртына менеп атлана иде.

Ә бер көнне, ахшам намазыннан соң улын каршыларга төшкән Идрис мулла, аның атка ничек итеп атлануын күреп, зирәк вә тапкыр булуына янә дә сөенде. Шунда ук аттан саклык белән генә күтәреп җиргә төшерде дә атка атлануның өр-яңа ысулын өйрәтергә кереште:

— Син, улым, болай ит... Менә шушылай тезгенне атыңның башына кигез дә, муен астыннан тезгененнең ике җәбен дә эләктереп ал, шуңа сыңар аягың белән бас, кулың белән ялыннан эләктереп ал. Ат акыллы хайван ул, атланырга сиңа үзе үк булышыр,— диде һәм атның башын чөеп җибәрүен дә, улының ялга ябышкан, тезген очын кысып тоткан килеш, ат өстенә очып кына менеп атлануын да бәхетле елмаеп карап торды.

Габделбакыйның да авызы колагына җитте, юл буена тәтелдәп кайтты...

## Янә бер манзара-картина

Авыл малайларына хас булганча, Габделбакыйның тавышы бик иртә ачыла. Хәер, хикмәт аның ачылуында түгел, хикмәт кече яшьтән җырга әвәслек сизүендә. Өлкәннәр алдында авыз күтәреп җырлауның әдәпсезлек икәнен чамалаганга, малай хәтта апалары янын-

да да тыелырга тырыша. Ә менә ялгызы торып калган чакларында форсатны ычкындырмау ягын чамалый. Тамак кырып ала да басынкы гына тавыш белән, тәмам җиренә җиткереп җырлап та җибәрә:

Утыртмале читән, ник утырттың,
Арасында үзең булмагач?!
Минем күнелем ник ярсыттың,
Үз күңелләреңдә булмагач?!
Ай, булмагач?!

Үзен егет кеше дип хис иткәч, ниләр генә җырламас Габделбакый! Ул тагын суза, җырдан тәм таба, күңелләре тәмам рәхәтләнеп китә:

Кызыл төлке бармы, ай, жирендә?
Матур ярлар бармы сон илендә?
Матур ярлар бармы үз илендә?
Сөюләрең бармы соң күңлендә?
Ай, күңлендә...

Тик менә шушы җырны апалары ишетеп алалар бит, гөнаһ шомлыгы, бәйләнеп теңкәсенә тияләр генә бит:

— Нинди яр ул, Габделбакый, без дә белик әле,— дигән булалар.

Дүрт-биш яшьлек малай аны бик әйтер иде — мәгәр үзе дә белми. Тик инде «белмим» сүзен ишетсәләр, күзенне ачырмаслар. Шуңа тәвәккәлли егетебез:

— Нинди булсын, җыр яры! — дип куя.

Апалары һаман бәйләнәләр генә бит:

— Каян беләсең андый җырны, Габделбакый, кем өйрәтте? — диләр.

Ике дә уйламый егет, бертөрле горурлану хисе белән:

— Кем өйрәтсен, Әти өйрәтте! — дип ярып сала...

## Тагын бер картина-манзара

Жәй кердеме — Габделбакый иркенгә чыга. Сарык бәрәннәре кебек үк, иркенгә чыга. Көрән бозау койрыгын чәнчеп, сыйракларын озын-озын алдырып чаба, малай аның артыннан элдертә. Ничек тә уҗымга кертмәскә иде дә бит теге хәерсезне, тик менә әйткәнне аңлыймыни ул хайван! Син аңа:

— Тукта! — дисең, ә ул сиңа бер акаеп карап кына ала да, койрык чәнчеп, алга томырыла.

Малайның кулында үзе үргән көтүче чыбыркысы. Чирәм эченнән елан сыман шуыша. Мондый чыбыркыны беренче үрүе әле Габделбакыйның. Ә үрергә аны көтүче Әхмүш бабай үзе өйрәтте. Дөресрәге, көтүче искергән-сүсәргән чыбыркысын сүтеп, яңартып-сипләп үрде. Малай шуны карап торды. Картның катып беткән бармаклары белән нәп-нәзек җиде бауны һәйбәтләп аралаштыра-аралаштыра, ныклап тарткалый-тарткалый, хәйран тырышып үргәнен күзәтеп, аның ыргактай бармаклары житез йөргәненә таң калып торды.

Малайның күзен дә йоммыйча карап торганы көтүчегә кызык тоелды, йөзенә елмаю чыкты:

— Нәрсә, мәхдүм, һөнәргә өйрәнәсеңме? — дип куйды ул.— Көтүче буласың юк инде югын, шулай да зыян итми ул һөнәр дигәнең. Ничек диләр әле: эшләгәнең байга булса, өйрәнгәнең үзеңә булыр, диләрме? Өйрән әйдә, мәхдүм, өйрән. Кайчан да булса бер ярап куюы бар.

Кайчан да булсаны көтеп ятмады малай. Бәрәңге бакчалары артыннан болынга чыкты да еpактан ялтырап күренгән күлгә йөгерде. Анда

үзләренең киндераш көлтәләрен эзләп тапты да ашык-пошык сүсен аерып алырга кереште.

Өйгә ул караңгы төшкәч кенә кайта алды. Ындыр ягыннан кайтып, мыштым гына лапаска керде, алып кайткан байлыгын ян буйда яткан колгалар астына кыстырды. Аннары читкәрәк китте дә, күренмиме дип, караштырып маташты. Караңгыда берни күренмәде. Малай, бик тә канәгать булып, өйгә керде.

Өйдә әллә кайчан ашап-эчкәннәр, табынны җыештырганнар иде инде. Идрис хәзрәт үзе түр якта гадәтенчә китап укып утыра булса кирәк, Мәһзүбә остабикә исә, кызларын җыеп, кул эшенә чумып утыра иде. Башы-күзе тонган, ыштан балаклары лачма су олы малаен күргәч, кул эшен сәкегә генә куйды да улы янына ашыкты.

— Кайда йөрисең шул чаклы, балакаем? Ашамый-эчми йөриләр димени шулай? Иртәгә дә качмас иде әле уеның, бая ук өйгә кайтасың бар иде...

Әнкәсенең нәфис тавышында кичтәге генә дә үпкә-тиргәү сизмәде Габделбакый. Фәкать борчылу бар иде ананың күз карашында да, тавышында да. Әкрен сөйләвенең сәбәбе — хәзрәткә комачау кылмау ниятеннән генә иде. Малай борынын тартып куйды, түр тәрәзә буенда утырган апаларына күз ташлады. Аларның елмаюын абайлап, кыюлана төште. Әнкәсе пешергән тары боткасын кич сауган сөт белән тәмләп ашап җибәрде.

Габделбакый иртә белән йокыдан уянып киткәндә, энесе Габделһади үзе белән янәшә үк сәкедә йоклап ята иде әле.

— Һәй, миннән иртә яткан идең бит, җитәр инде, мәрткә китәрсең,— дип, күпме генә төрткәләсә дә, теге һич уяна белмәде.

Уята алуга тәмам өметен өзеп, сәкедән шуып төшкәч кенә:

— Әйдә, үзеңә бер әйбер күрсәтәм,— дип әйтергә өлгермәде, энесе ялт итеп сикереп торды, абыйсына тагылды.

Бәләкәй әле Габделһади, өч-дүрт яшендә генә, шуңа абыйсына тагылып йөрергә бик тә ярата иде. Абый кешегә дә бергә-бергә йөрүләре бик рәхәт иде. Әле менә кичтән алып кайткан хәзинәне иң әүвәл энесенә күрсәтергә ниятләде һәм аны җилтерәтеп туп-туры лапаска табан юлланды.

Әгүзе-бисмилласын әйтеп кенә, кичә кич яшергән хәзинәне тартып чыгарды. Аны ике куллап югары күтәргән килеш, бик мәгънәле итеп:

— Менә! — диде.

Әмма киндер сүсен туку станында күргән энесе берни аңламады, күкле-яшелле тавышы белән:

— Абыем, нәрсә тукыйбыз? — дип мәгънәсез генә сорау бирде.

Ләкин абый кеше аңа ачуланмады, басынкы гына тавыш белән аңлатырга тотынды:

— Юк, энем, бернәрсә дә тукымыйбыз. Әниләр тукыганы җитәр, без синең белән чыбыркы ишәбез! — диде.

Иртәнге намаздан кайтып килүче Идрис мулла, ян капканы ачып керү белән, ике улының да болдыр буенда мәш килеп нидер эшләп утыруын күреп алды, күңелләре тәмам эреп китәргә җитеште. Әмма үзе елмаюын сиздермәскә, сабыйларга кырысрак булып күренергә тырышты. Югыйсә бит ир балаларның азынып-узынып китүләре дә ихтимал, ходай үзе сакласын! Кызлары тәүфыйклы-инсафлы гына булып үсеп киләләр, остабикәнең кул арасына да керәләр бугай да бит... Болары тиз генә буразнага төшәрләрме, юкмы — бер Аллаһы тәгаләгә мәгълүм. Һәрхәлдә, остабикәң үзе артык назлы, йомшак күңелле булгач, мулланың талканы корырак булуы хәерле.

Үз эшләре белән мавыккан сабыйлар әтиләренең капканы ачып кергәнен дә, үзләре янына килгәнен дә абайлап өлгермәделәр.

— Минем улларым иртә таңнан эшкә тотынганнар түгелме соң? — дигәнне ишеткәч кенә, икәве бердәм башларын күтәрделәр.

Мулла алдында утырып тору гөнаһка санала иде, икәве дә сикерешеп урыныннан калыкты. Бәләкәйрәге, кояшка күзе камашып, нәзек кенә беләгеннән маңгаена күтәрде, әтиләренә тизрәк төшендереп бирәсе итте:

— Без чыбыркы үрәбез әткәй, чыбыркы! — дип тәтелдәде.

Идрис мулла иркле-ирексез елмаеп куйды, башыннан чалмасын салып, өйдән каршыларга чыккан ун яшьлек Мөхсинә кызына сузды.

— Әллә югыйсә остабикә үзегезгә бирәр эш куштымы, дип торам. Чыбыркы үргәч, һәйбәт инде ул, ходай уң кылсын шөгылегезне. Чыбыркы үрерлек булгач, тәмам егет икәнсез инде,— дип сөйләнә-сөйләнә, кызлары ялт иттереп юып чыгарган болдырга аяк атлады.

Абыйлы-энеле малайлар иң әүвәл сүстән озын-озын баулар ишеп, аларның өчесен бергә чыбыркы сабы булырдай таякка ныгытып бәйләделәр дә үрергә тотындылар. Әллә баулары калынрак булды, әллә инде әүвәлгеләрен озынрак итеп үреп ташладылар, мәгәр өченчесен үрә башлагач та, сүснең җидегә дә, бишкә дә җитмәячәге ачыкланды. Ярар соң! Өчтән үрсәләр дә, бу юлы җитеп торыр, киләсе юлы өстәрләр. Каян беләсең бит аның күпме кирәген!

Әмма үреп бетергәч тә әле, сабыйларга сөенеч килмәде. Һәр икәве көтүче Әхмүш бабай шикелле иттереп болгап торып җиргә ничек кенә китереп сукмасыннар — чыбыркы шартламады.

— Кая, мин!

— Кая, үзем! — дип күпме генә чиләнмәсеннәр, чыбыркылары барыбер шартламады. Аптырагач-йөдәгәч, Габделбакый, гарьләнеп:

— Әхмүш бабай шул аны җиде катлы итеп үрде. Шунсыз шартламый икән...— диде.

Ул арада кулына дүрт җәпле тимер сәнәк тоткан, сыер абзарындагы тиресне бакча ягына чыгарган Идрис мулла сабыйларының боегып калуын абайлап алды да яннарына килде.

— Нәрсә, улларым, шартлата алмыйсызмы әллә? Кая, бирегез әле, карыйм әле... Иһи! — Идрис мулла сабыйлар сыек кына итеп үргән озын чыбыркыны кулында әйләндереп-тулгандырып карады, улларының күңелләрен төшермәскә тырышып кына: — Шәп итеп үргәнсез, кулыгыздан эш килә икән. Бу чыбыркының очына кыл да кушсагыз, көтүче чыбыркысыннан бер дә ким булмас,— диде.

Малайларның күзләре балкып китте. Габделбакый шунда ук:

— Каян алыйк соң без ул кылны? — дип кызыксынды.

Идрис мулла көлемсерәде:

— Көтү кергәч, сыерның койрыгыннан тотасыз да йолкасыз. Тик аңкәгез генә күрмәсен...

Малайлар көтү кайтканны көчкә көтеп алдылар. Әмма бер учма кылны йолкып алырга куллары бармады. Әллә сыерларының койрыгы болай да бик сыек булуы, әллә аның арыклыгы, әллә мүкләк башын болар ягына борып, зур-зур күзләре белән томырылып каравы хәл итте инде — ничек булса булды, мүкләкнең койрыгы йолкынмый калды. Башка сыер да ярыйдыр лабаса? Малайлар урамга омтылдылар. Анда Хәсәнша абзыйларның мунчадай сыерларын күреп, шуның себерке хәтле койрыгыннан бер учма йолкырга булдылар. Кеше-кара күргәләгәнче, Габделбакый бер учманы эләктереп тә алды, тартып йолыкты да.

Шундый көр сыерның койрыгыннан йолыккач, шартламый хәле юк чыбыркының! Бик нык шартлый торган булды. Тик менә көрән бозау гына аңгыра булып чыкты: сыртына чыбыркының очы тиюгә, корт чаккандай, сикертә-сикертә чабып китте. Югыйсә бит аңа туктарга кушылган иде. Хайван димәсәң хайван инде...

Һәй, бетәсе юк икән ул картина-манзараларның. Берәве әнә моңлы көй булып күңелгә килде. Югыйсә бит кич буена бер генә җыр да ишетелмәде. Егетләр түгел, малай-шалай да урамнан җырлап узмады. Әһә, җырны, туган авылында җырлана торган җырларны юксына икән

ич кунагыбыз! Әтисенең хәлен әле менә хәзер генә аңлады. Әйе, әйе, олы урамнан матур итеп җырлап, гадәттә озын, моңлы көйне сузып килүче егетләр, хәтта никрутлар булса да, мулла өенә җитәрәк шып туктый торганнар иде. Шундый чакларның берсендә Идрис хәзрәт, иненә җиләнен салып, башына да түбәтәен генә кигән килеш, ян капкадан урамга чыкты; җырлаудан нигә туктауларын сорады; егетләр аны олылап сәламләделәр дә шәригатьнең шулай кушуын әйттеләр; шуннан Идрис хәзрәт аянычлы тавыш белән: «Мулла да кеше ләбаса! Аның да җаны бар ләбаса! Моннан ары җырлап уза торган булыгыз минем өй турысыннан!» — дип ялварган иде. Ул чагында әле җиде-сигез яшьлек малай әткәсенең хисләрен, әлбәттә, аңламады. Кызык инде: илле-алтмыш ел буена күңеленең кайсыдыр киштәсендә тыныч кына, бимазаламый-нитми генә яткан хатирә әле менә хәзер, авылга кабат, олыгаеп кайткач, кинәт кенә уянды. Тик бу юлы инде Габделбакый теге чакны әткәсе әйткән сүзләрнең серенә төшенде.

Шулай хискә бирелеп ятканда, аның колагына шыгырдамый-нитми генә тышкы ишек ачылганы ишетелде. Озак та узмады, чолан ишеге дә акрын гына ачылды, яшь хуҗа сагаеп кына керде дә, караңгыда чишенеп, тиз үк ишек буендагы караватка сузылды. Шунда гына кунак аңа:

— Исән-имин кайттыңмы, Нәҗипҗан? — дип эндәште.

Егет дерт итеп сискәнеп китте, башын калкытты:

— Мин уяттым бугай сине? — диде.

— Юкка хафаланма. Йокламый ята идем әле.

— Таң беленеп килә бит. Нишләп йокламыйсың инде?

— Уйланып ятам шунда. Әйтик менә, каян бу чаклы ныклап өйрәнгән мондый һөнәргә, дип сине дә уйладым.

Егетнең авызы ерылды булса кирәк, яткан җирендә кыбырсып алды.

— Каян өйрәнгән, дип инде... Солдатта чакны аз-маз өйрәнеп кайтылды шунда. Барган көнне үк взвод командирына, балта эшен яратам, шунда билгели алмассызмы, дидем. Частьта полковой мастерской бар иде. Бу мине шунда җибәрде. Хәйран зур балта остасы кул астында берәр атна йөрдек тә, бер взводтан бу нибары дүртебезне сайлап калдырды, башкаларны стройга җибәрде.

— Боларыннан рәт чыгар, дип, үз һөнәренә куллары аз-маз яткан солдатларны сайлап алып калдырган инде ул алайса...

— Шулайрак булгандыр, күрәсең. Ну, үзебез дә тырыштык инде. Частьнең бөтен заказын үтәп бардык. Без эшләгәнне старшина үзе һәрвакыт ныклап карый, күздән кичерә, җиренә җиткерә алмаганыбызны күрсә — шундук сүттерә торган иде. «Ярый әле, минер булмаганыгыз, мондый ялгыш белән күккә очасы идегез бит!» — ди иде. Бигрәк бәйләнчек иде инде...

— Әнә шул бәйләнчеклеге, юк, һич тә алай түгел, таләпчәнлеге аркасында эшне печеп эшләргә өйрәткән дә инде ул үзегезне.

— Баштагы айларда гарьләнә идек, тора-бара күзебез ачылды тагын, акны карадан аера башладык.

— Авылга кайткач, өйләр сала башладыңмы?

— Өйләр соңыннан алары. Иң әүвәл струмент ясарга тотындым.

— Дөре-е-ес, дустым! Һәрбер һөнәр иясе барыннан да элек үз кулы белән эш кораллары булдырырга тиеш, Нәҗипҗан.

— Менә шулай тотындым инде мин дә. Әгәр дә мәгәр үз кулым белән струмент, эш кораллары ясый алсам, шул чагында гына балта остасы булып эшләргә алынам, дидем. Эш коралың да булмагач, син нинди оста инде! Кибеттә син юньле струмент таба аласыңмыни. Шуларны җиткергәч тә, әйттем бригадирга, мин балта эшенә күчәр идем, дип. Авылда андый эшләр баштан ашкан бит ул. Тора-бара яңа бригада барлыкка килде. Бер өйдә ике бригадир: әткәй аучылар-балыкчылар әртиле бригадиры, мин исә балта осталарыныкы. Егетләр нык минем. Теләсә нинди эшне булдыралар. Тик кайчагында гына кушкан эшне

тизрәк очлау ягын чамалыйлар. Нигә шулчаклы вак бизәкләр төшереп азапланасың инде, дип теңкәгә тияләр.

— Тик син инде, үз почеркыңны булдыргач, уңга-сулга авышырга уйламыйсың. Дөре-е-ес, дустым!

— Көлә үземнән әткәй: син инде ярты авылны өйле иттең, кайсы урамга борылсаң да — синең кул, дигән була.

Кунак тынып калганны абайлап, Нәҗип сайраудан туктады, телемә артыграк салындым бугай, дип үзен битәрләп тә алды. Әмма аксакал ару-талуның ни икәнен гомерендә дә белмәде, дөресрәге, аңа гына бирешмәде. Әле хәзер дә кунак уйланып ята иде. Ярый, туган авылыма кайттым да, диик. Тәпи йөреп киткән, сабый чагым үткән төп нигезебез сакланмаган. Дөнья бит, берәүне дә гаепләү, кинә саклау мөмкин түгел. Әмма ләкин, гәрчә үткәнеңне кайтара алмасаң да, ата-анага ихтирам күрсәтү йөзеннән бер-бер нәрсә эшләргә тиешсең. Идрис хәзрәтнең исән калган малайларыннан син бит берүзең. Әткәң, гомумән, сиңа зур өметләр баглый иде. Үзеннән дә галимрәк, укымышлырак мулла итү нияте белән сине шөһрәтле «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга илтте, зиһенле бала булуыңа, тырышлык күрсәтүеңә сөенеп бетә алмады. Әнкәң исә әдәпле-инсафлы булуыңа бер яктан шатланса, аның үз һөнәренә күңел бирүеңә, акшарлаган мичкә күмер белән каз-үрдәк сурәтен ясавыңа янә дә куанды, рәсемдәге маһирлыгыңны күреп горурланды. Баланың һәркайсы да якын ул ата-анага. Замананың-дөньяның кай тарафка борылганын абайлап, башка балаларына да дөньяви белем бирү максатын күздә тотып, әткәң Сафыя белән Нәҗибә сеңелләреңне һәм Габделбари энеңне дә Казан каласына юллады. Ә инде газиз әнкәң вафатыннан соңра, үзе дә, Мөхсинә апаңны баласы-чагасы белән ияртеп, синең яныңа Казанга килеп төпләнде. Күл-Черкеннән Кече Салтыкка күченүе карт хәзрәтнең хөсетлегеннән-гайбәтеннән арынуны, үз хакын яклап Ходай алдында гөнаһлы булудан, низаглашудан котылуны күздә тотса, имам-хатиб вазифасын үтәүдән бөтенләйгә баш тартып, Казанга күчеп килүе — мәхшәр купкалаганчы улларын-кызларын канат астына алып, ничек тә саклап калу ниятеннән чыгып эшләнде. Аңа ансат булмагандыр үзе корган нигезләрдән аерылулары... Ә соң мәчете?! Күл-Черкендә булсын, Кече Салтыкта булсын михрабтан торып куе баритон тавышы белән көйләп торып халыкка намаз укыткан, фани дөньядагы оҗмах урынына күргән мәчеткәеннән аерылулары, елый-елый аны ташлап китүләре ансат булгандыр дисеңме? Әле ярый бер игелекле җан мәрхәмәт күрсәткән — колагына пышылдаган хәзрәтнең, мәркәздән әмер килгәнен сиздергән. Шуннан инде мәчетенең манарасын кискәнне көтеп тормаган Идрис мулла, балалары янына ашыккан...

Дөньяда зилзилә кубуын да, искиткеч тату гомер кичергән сөекле карчыгының вафат булуын да, инсафлы-миһербанлы, зур укымышлы, береннән-бере матур ике газиз баласын, ике улын-дәвамын, халык дошманы дип атап, иректән мәхрүм итүләрен дә, шуннан соңра үзләрен урамга сөреп чыгаруларын да күтәрә алмагандыр инде, бичаракаем... Аны игелекле бәндәләр, чит кешеләр җирләгәннәр. Инде хәзер син ичмаса каберен генә дә белмисең, олы бәйрәмнәрдә Яңа бистә зиратына барып, анда яткан мөселманнарның барчасын зыярәт кылгалыйсың... Әткәң кайдадыр шунда гүр иясе булып ята инде, син аны һич тә онытмыйча, аңа хөрмәт күрсәтү йөзеннән бер кочак алсу-кызыл чәчәк күтәреп барасың, шунда сибәсең, әткәң белән сөйләшәсең-серләшәсең, эчеңнән генә дога кыласың, фәкыйрь-фокраны күргән саен сәдакаңны бирәсең... Ә менә берәр сизелерлек, газиз әткәң-әнкәңә лаек изгелек эшли алганың бармы соң? Ә бит шуны эшләми торып синең вазифаң үтәлмәгән санала, дөньядан китәргә хакың юк!

Әйе, әйе! Үләргә дә хакың юк. Моңа хәтле чит-ят җирләрдә йөреп гомер уздырдың, туган авылыңа аяк басарга да батырчылыгың җитмәде, шунда кайтып, ичмаса бер зыярәт кенә дә кылганың булмады. Чамадан

тыш куркак булып чыктың түгелме соң, Бакыйҗан дустым? Бер чиркан-чык алганнан соң кирәксә-кирәкмәсә дә гел уңны-сулны карый торган булып калдың. Мулла малае икәнеңне фаш итүдән котың алынып яшә-дең. Юклы-б... хатыннар идарәгә яисә парткомга барып зарланса, кая керер тишек тапмадың. Гарьлек бит, Бакыйҗан дустым, гарьлек! Инде менә, куркуларың җиңеп, дан-шөһрәткә күмелеп, туган авылыңа кайтып егылдың. Фәкать, Бакыйҗан дустым, авыл чирәмен модалы яңа ботинка-ларың белән таптап йөрү туган авылыңа ясалган иң зур бүләгең булма-сын иде. Әби-бабаларың, әнкәң-әткәң исеменә вә җисеменә лаек булыр-дай берәр төрле эш майтара алсаң иде, егетем. Әйе, әйе, нәкъ менә шуны эшлисе! Иртәгә калдырмыйча, коммунистлар әйтмешли, массакүләм агитация-пропаганда эшләрен җәелдереп җибәрү мәгъкуль булырдыр...

Шактый озак үрсәләнеп ятканнан соңра, картлачның йокыга талуына тәмам инанганнан соңра, әңгәмәнең кинәт киселүенә күңеле кителгән егет инде тәмам тынычланып, кузгатылган сәвальләрдән арынып, сөйгәне белән хыялында серләшә, үбә-назлый башлагач кына, һич көтмәгәндә генә кунак сүз башламасынмы:

— Ярты авылны өйле итүең шәп булган, дустым, әйбәт булган. Әмма ләкин синең вазифаң моның белән генә тәгалләнми бит әле, дустым Нәҗипҗан!

Кунагы тын алырга туктау белән, үзенең уяу икәнен сиздереп, Нәҗип тә:

— Үзебезгә дә өй җиткердем ич. Менә койма-капканың гына эшен бетерәсем калды,— дип әйтә куйды.

— Юк шул, дустым, белмәдең! Өеңне һәйбәт бүрәнәдән коргансың, әфарин, сүз дә юк. Үзеңә шушында башлы-күзле булып, бала-чага үсте-реп, имин генә яшәргә, муллыкта рәхәт сөрергә Алла насыйп итсен. Кулың алтын икәнлеген өй эчендәге караватдиваннарың, комод-шкаф-ларың, өстәл-урындыкларың да исбатлый-раслый. Молодец икәнсең, булдыра аласың. Шундый да уңган егет үстергән өчен әти-әниеңә рәхмәт.

— Үзеңә рәхмәт инде, Бакый абзый, матур сүзләреңә.

— Безнең рәссамнар иҗатында эшләр болай тора, дустым. Кая гына барса да, сәнгатькәрнең кулыннан кыл-каләме яисә карандашы төшми. Эскизлар ясый рәссам. Аннары инде, өенә кайткач, остаханәсендә шулар-га карап, бөтен күргәннәрен искә төшереп, картина яза. Әмма ләкин сизә рәссам: аның таланты-сәләте вак-төяк картиналар язып ташлау белән генә тулаем чагылмый әле, моның өчен бер генә булса да зур әсәр язарга кирәк. Бер генә, әмма инде берәгәйле картина иҗат итәргә тиеш. Чөнки тарихта һәр әдипнең бер генә күркәм романы торып калган кебек, рәссамның да фәкать бер генә, тик инде иң камил картинасы торып кала—анысы аның киләчәк буыннарга бүләге, иҗади мирасы була.

— Кызык икән бу художниклар тормышы.

— Син үзең дә рәссам бит, үз эшеңнең остасы, художнигы! Сиңа да яшь буыннарга мирас итеп калдырырлык бер илаһи күркәм эш, синең талантыңны тулаем чагылдырырлык иҗади хезмәтне башкарып чыгу лазем, Нәҗипҗан!

— Һе, нindирәк нәрсә икән инде ул?

— Улмы? Ул, дустым, авылыбызның күрке булырдай, бизәп торыр-дай, һәйбәт кенә бер мәчет җиткезү!

Килер заман, Урманче дөнья куеп өлгергән булыр, алтын куллы Нәҗип авызыннан мондыйрак сүзләр чыгар:

— Мәчетебез әйбәт булды инде, урыны да килешле, үзе иркен дә. Иң беренче нигез салучы мин булдым. Үзебезнең авыл халкы тырышты, шулай булды. Вич үзебез. Унөч кеше идек, үзебез эшләдек. Манарасына хәтле. Аен да үзебезнең авыл кешесе ясады. Башлап йөрүчебез үк авыл агае. Агачын-мазарын табучы шул булды. Маридан да ташыды, төрлесен төрле җирдән алып кайтты. Бурасын үзе бурашты. Үзе дә яшь кеше түгел

инде, әмма изге юлда яшәреп киткәндәй булды... Аннары инде миңа калды. Картлар килделәр дә әйттеләр: әйдә, эшкә алын, диделәр. Авыз ачып каршы сүз әйтмәдем. Прораб та үзем, бригадир да. Унөч кеше идек. Башкарып чыктык шул. Безнең хәлдән килә. Изге эш бит...

Урманче картның хыялы әнә шул рәвешле гамәлгә аша, авылдашлары аның сүзенә колак сала, гали затның ышанычын аклый. Тик һәрчак сөенеп яшәү адәм балаларына, гомумән, насыйп түгелдер, мөгаен. Даһи сәнгатькәрнең иҗади мирасына күз салганда, бүген бер гаять аянычлы хәлне күрмичә калу мөмкин түгел.

Ничәмә-ничә ел дәвамында, хәтта әле сиксән белән туксан арасында да үз-үзенә мәрхәмәт күрсәтмәгән, ал-ял белмичә, көн-төн эшләгән кыл-каләм остасы дөнья хәтле эскизларын зурайтып картиналар яза. Болай үҗәтләнеп эшләвен:

— Бер генә символ веры — бетерәсе бар! Бетерәсе! Бер генә иман...— дип аңлата.

Ләкин сәнгатькәр, кызганычка каршы, һәр әсәрен дә «игә китереп», картина итеп язарга өлгерә алмый. Иң аянычлысы — туган авылы Кул-Черкенгә багышланган бердәнбер әсәре эскиз хәлендә торып кала...

Моның сәбәпләре җитәрлек булса кирәк. Әсәрне күчереп язарга вакыт җитмәүдә генә түгел хикмәт. Һич юк! Бу эскизны рәссам бервакытта да киштәсенең аргы башына атмый, аны югалтмый-онытмый, һәрчак күз угында тота. Әмма шушы әсәрне тәмам җиренә җиткерү авторга насыйп булмый. Бу очракта иң әүвәлге сәбәп дип сәнгатькәрнең үз эшеннән бик үк канәгать булып җитмәвен әйтергә кирәктер. Гәрчә аксакал:

—' үзем тәмам разый түгел разыйлыгын, әмма шул эшләнгән нәрсә инде ул бер, күңелдән чыккан нәрсә...— дип, бөтенләй үк бетереп ташламаса да, нәкышь остасының тәҗрибәле күзе бүтәннәр күреп җиткермәгән кимчелекләрен дә күрә-сизә, эскизындагы беркадәр таркаулык-сүлпәнлеккә чик куярга хыяллана, өр-яңа вариантын язарга өметләнә, күз алдында торган әзер эскиздан шул килеш кенә күчереп язарга, олы картина сыйфатында халыкка тәкъдим итәргә таләпчән рәссамның кулы бармый.

Иҗат кешеләренең үз-үзләренә куйган таләпләреннән хәйран мәзәк хәлләр килеп чыккалый шул. Арада берсе моннан гыйбарәт. Әйтик, әдип үзенең күңелендә тәмам өлгереп җиткән берәр вакыйганы ясканып-дәртләнеп кәгазьгә төшерә. Күп көч куеп эшләгәч, үзе канәгать калган сыман тоела. Атна-ун көннән укып караса — язганы пүчтәк икән! Мавыгып китеп, әллә күпме көч сарыф иткән, әмма юньле нәрсә китереп чыгара алмаган. Инде ни хәл итәргә? Ничек итеп әлеге чиле-пешле нәрсәне әйбәтләп әвәләргә? Әнә шунда башлана да инде иҗатчының җан газабы. Язганына кул да куя алмый, бу хәлендә матбугатка тапшырырга ярамаганын да аңлый, әмма ни рәвешле үзгәртергә икәнен һич кенә дә хәл итә алмый. Өр-яңадан эшләп ташларга бүгенге осталыгы-сәләте җитенкерәми; ихтимал, берәр вакыт, ходай кушып, яңа вариантын язып ташлый алыр, әмма бүген әле моңарга кодрәте җитми.

«Кул-Черкен» әсәрен үзгәртеп язарга, шул яңа вариантны картина итеп зурайтырга һәм, әүвәл уйлаганча, «Салтык болыны» белән «Уралтау эргәсендә» дигән мәшһүр картиналарының алдына чыгарып куярлык дәрәҗәдә язарга авторның үз иҗатына артыграк таләпчән килүе комачаулый. Туган авылына бер дигән һәйкәл корып калдырырга ничек кенә хыялланмасын, кабат-кабат талпынып карамасын, даһи сәнгатькәрнең әлеге хыялын тормышка ашырырга гомеркәе җитми кала...

Һа-а-ай!
Урманченың хыялы —
бигрәк йөгерек фал инде.
Күпме ниятен Урманче
гамәлгә ашырмас җан инде...—

дип ачынып әйтүләре тикмәгә түгел инде, түгел.

Хәер, «Күл-Черкен» әсәре шушы эскиз хәлендә дә алай ук хурларлык, бетереп ташларлык түгел.

Әлбәттә, реалистик рухта иҗат ителгән әсәргә автор, һичшиксез, кайчандыр күргәннәренә үзенең хыялындагы детальләрне дә өстәгән, шулар исәбенә баета төшкән. Бу очракта иң әһәмиятлесе шулдыр — монда тасвирланган барча нәрсәне, һәрбер җан иясен тамашачы нәкъ шулай булган дип, ышанып кабул итә. Гәрчә автор үзе бик үк канәгать булмаса да, «Күл-Черкен»нең шушы хәлендә дә сәнгать әсәре буларак яшәргә хакы бар: ул ике гасыр арасындагы татар авылын тормышчан иттереп гәүдәләндерә. Андагы буяуларның һәркайсының нәкъ менә кирәкле урынга ятуы безне сокландыра.

Сюжет ягыннан эскиз болай үзе гаять кызыклы уйланган. Иң әүвәл шунысын әйтергә кирәк: суны бирә белү — үзе бер осталык, гаҗәеп зур осталык сорый бит әле. Менә-менә Иделгә барып кушылам, кавышкачыннан соң олы вә киң дәрьяга әйләнәм, дип ашкына, дуамалланып, хәйран кызу ага алкын Зөя. Әнә шул кызулыкны, тулгын суның ашкынуын гәүдәләндерә алган бит рәссам. Шуның нәтиҗәсендә автор алкын суның ашкынып агуына тамашачыны ышандыру бәхетенә ирешкән. Ә инде әсәрдәге иң төп нәрсәгә, суның шулай кызуланып агуына ышанган икән, тамашачы үзе күргән бүтән детальләргә дә ышана, аларны булган хәл дип кабул итә, аермачык күз алдына китерә. Мул сулы, тулгын сулы Зөя чирәмле вә куаклы сөзәк ярларына ябырылыр сыман тоела, гүя шуңа омтыла, шуңа талпына, әледән-әле су чәчрәтә. Өлкәннәр моңа күнеккәннәр инде, бала-чага шуннан кызык таба, чыр-чу килә. Хәер, бала-чага суны үзе күбрәк чәчрәтә икән әле. Әнә, берәүләре коена, йөзә; икенчеләре ат сугарырга, ат коендырырга килгән. Җиде-сигез яшьлек яланаяклы малайлар өсләреннән киемнәрен сыдырып кына салалар да иярсез-нисез атларның сыртларына менеп тә атланалар. Габделбакыйның дуслары алар — Нәҗметдин, Зәйнетдин, Фәсхетдин, Гыйльметдиннәр. Мәхдүм үзе җирән кашкага, бергә үскән, җаныннан да якынрак күргән атына атланган. Алар шулай көн саен атларын чаптырып, узыша-узыша киләләр дә суга томырылалар. Атын тыя алмаганы өстендәге күлмәген-ыштанын салырга да өлгерми кала, аннары инде кызыктан иптәшләре белән бергә үзе дә көлеп рәхәтләнә. Малайларның ярты көне Зөя буенда уза: шунда куыш уйныйлар, йөгерәләр, көрәшәләр — бер дә тик тормыйлар. Коенуны әйткән дә юк инде аны: чумалар да йөзәләр, бер-беренә су чәчрәтеп уйныйлар. Кызу агымлы алкын су аларның кавырсыны катып өлгермәгән, йомычкадай җиңел гәүдәләрен әллә кайларга агызып алып китә. Берәү дә каршы тора алмый Зөянең агымына, берәү дә...

Әнә, Зөя аркылы салынган күпердән печән төягән олау узганы күренә; яшь киленнәр әнә кер чайкау белән мәшгуль; яр буена, су эчертү нияте белән, көтүне куып төшергәннәр; бөдрә таллар әйләнә-тирәгә ямь биреп тын гына утыралар; мөселман авылының фәкыйрь өйләре өстендә мәгъ-рур мәчет манарасы нурланып күренә; гүя бала-чаганың су чапылдатуы, чыр-чу килүе генә түгел, мәчет манарасыннан мәзиннең азан әйткәне дә аермачык ишетелә...

**Күл-Черкен**[1]

Елганың бер ягы ком,
бер ягы яр.
Аркылы келтерәвек
күпер салган.
Сабыйлыгым узды ич
кармак белән
Алабуга, бәртәс тотып
шушы ярдан.

[1] Б. Урманче шигыре.

Комлыктан елганың
уртасына
Җитәрлек бер-ике
басма салган.
Шул басма өстендә
сарылы күлмәк,
Каракаш матурлар
кер чайкаган...

# II баб

## «Салтык болыны»

*«Кешенең сәләте — һәр өлкәдә чиксездер. Шул сәләтне кече яшьтән, сабый чактан үстерергә-үрчетергә тиешле!»*

Бакый Урманче,
*1982 ел.*

*«Менә монда музыка кануннары тәнбиһ ителә: беренче планда алынган төсләр, гамма — бөтен картинага музыканы әйтеп торалар: төсләр шундый булырга тиеш, диләр».*

Бакый Урманче,
*1978 ел, 7 декабрь.*

«Салтык болыны» картинасын зурайтып язган чагында әйткән сүзләре.

Салтыкны кабат күрүләр Габделбакыйга фәкать алтмышны узгач кына насыйп булды. Ә бит «гәрчә анда тумаса да» дигәндәй, кече яшьтән шунда үскән иде. Аңа нибарысы ун яшь тулган елны, әтисенә имам-хатиб урынын тәкъдим иткәч, Күл-Черкеннән әлеге Кече Салтыкка гаиләләре, бөтен өй кирәк-яраклары, мал-туарлары белән күчеп килгәннәр иде. Күченгән елны күңеле дә рәтләп утырырга, малай-шалай белән дә аралашырга өлгерми калды: улына зур гыйлем чишмәсеннән эчерүне күздә тотып, Идрис мулла Габделбакыйны заманның мактаулы уку йорты саналган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә үз кулы белән илтеп тапшырды.

Бер ел укып кайткач кына, дуслаша-аралаша алды Габделбакый ишләре-тиңнәре белән. Гәрчә үзен мәхдүм дип зурлап йөртсәләр дә, хәтсез күп китап укыган булса да, малай һич тә эреләнә белмәде. Югары очтан ялгыз башы кайтып килгәндә, тыкрыктан кемдер үзенә таш ыргыткач, бер дә икеләнеп тормады, ырынтын эш кылучыны куа китте, артыннан бик тиз җитеп, барган шәпкә иңсәсенә берне китереп тә тондырды.

Теге малай чирәмнән торып, аңына-исенә килгәләгәнче, кай арада боларның тиңнәре җыелып та өлгерде. Габделбакый аларны гүя күрмәде:

— Башка тидерден, таш бит ул... Үзең гаепле, таш атмыйлар аны... — дип тегене әллә битәрләде, әллә акланып маташты, әллә инде еламаска үгетләде.

Һич уйламаганда-көтмәгәндә малайлар мәхдүм ягына авыштылар.

— Хәйрушнең холкы шул аның, искәрмәстән берәрсенә этлек эшләргә генә тора, — диештеләр.

Малайлар чирәмгә янтайгач, Габделбакыйның да кукраеп торасы килмәде, шундук чирәмгә чүкте. Ләкин әле моның белән генә эш бетмәгәнне, ничек тә җаен туры китереп аның көчен сынап карыйсылары килүен шәкерт сизенә иде. Ни дәрәҗәдә көчле вә саллы икәнеңне күрми

торып, гомерләреңдә дә сине үз итмәячәкләр. Габделбакый сабыр кылырга булды, шулай да уңны-сулны абайлабрак утыра бирде.

Сынау минутлары озак көттермәде. Менә бер-берсенә кара-каршы утырган ике малай тибешә башладылар, болай әдәп өчен генә сүз көрәштереп алдылар. Аннары капыл гына сикерешеп тордылар да көрәшергә үк тотындылар. Мондый чакта инде бер кырыйда утырып калырмын димә. Әлеге икәүнең чандыр гәүдәлесе чаярак булып чыкты, Габделбакый сыман таза гына күренгән тәбәнәгрәк буйлы малайга бер генә аяк чалды — тегесе чапкан үләндәй барып та төште.

Малайлар моны күреп торсалар да, хәрәмләшүгә санамадылар: бәхәсләшеп-нитеп вакыт әрәм итәргә түгел исәпләре, тизрәк мәхдүмне сынап карыйсылары килә.

— Синең белән дә көрәшергә магу! — диде җиңүче әтәч.

Габделбакый бераз кыстатырга уйлады, елмайгандай булып, шүрләп калгандайрак:

— Батырга каршы чыгу кая инде ул миңа! Бигайбә, егетләр, булмый ул миннән,— дип сөйләде.

Нәкъ шуны гына көткән шикелле, ике малай ике беләгеннән эләктереп, аны әлеге дә баягы чая батырга табарак, бераз алгарак этәрделәр.

Кыстату шунда тәмам. Габделбакый сул кулы белән теге чая малайның корсак турысыннан, уңы белән сыртыннан эләктерде дә Сабан туендагыча салмак кына йөренә башлады. Чая малай ул арада ике-өч мәртәбә аяк чалып карады. Алай берни майтара алмаганын күреп, башкалар:

— Хәрәмләштән түгел! Аяк чалмыйча гына мәтәлдерәсе! — диештеләр.

Габделбакый аның ише аяк чалуларны үз гомерендә күп күргән инде, һич бирешәсе юк. Тыныч йөрүнең сере бар: бөтенләй көрәшә белми икән бу мәхдүм, дип уйласыннар әле, шулай фикер йөртүләре хәерле, бик кирәк. Менә бер заман йөрүдән туктады, капылт кына дошманын кысып тотты, үз өстенә тартты да чалкан ятып, баш аркылы тондырды. Теге бичара, юньләп абайларга өлгергәләгәнче, әллә кайларга ларсылдап барып төште.

Хәер, мондый хәлне бүтәннәр дә көтмәгән иде бугай — мәхдүмнең кинәт кенә йөрүдән туктавын да, чалкан китә биреп, чая малайны ялт иттереп күтәрүен дә, чөеп җибәрүен дә төштәгедәй генә күреп өлгерделәр. Исләрендә калса, фәкать чая бичараның ялан тәпиләре күккә чөелгәне сәер бер күренеш буларак уелып калгандыр. Малайлар аңнарына килгәләгәнче, шәкертебез ялт кына сикереп торып, чирәмгә барып утырырга өлгерде. Түгәрәк уртасында чая малай гына ятып калды. Шуннан инде аның дус-ишләре әкренләп телгә килделәр:

— Нәрсә, тора аласыңмы, Сәлим?

— Без бит сине Олы Салтыкка ук очып киткәнсең дип торабыз!

— Бу инде сиңа аяк чалып егу түгел!

— Юк, юк, хәрәм юк монда! — дип дөреслекне каердылар.

— Бигрәк саллы ыргытты бит әле бу!

— Егетлеген күрсәтте!

— Казан каласындагыча иттерде!

— Юкка гына укып йөрмисең икән, мәхдүм! — диештеләр һәм тел шартлаттылар, баш чайкадылар.

Тыныч кына утырган тыйнак малайга каршы чыгарга берәүнең дә егетлеге җитмәде, берсенең дә түгәрәк уртасында болай миңгерәп ятасы килмәде. Әнә шул рәвешле мулла малае Габделбакый бер селтәнүдә үзенең көчен-сәләтен күрсәтте, үзенә Кече Салтык авылы чирәмен таптарга хокук яулап алды.

Габделбакый гомере буе беренчелеккә омтылды. Еш кына аңа мулла гаиләсендә тәрбияләнү азынырга-узынырга ирек бирмәсә, әдәп сакларга өндәсә дә, җае чыкканда һич кимен куймады. Салтык чирәменә кырын

яткач та, Казан хәлләрен, мәдрәсә шәкертләрен, үзенең Габделәхәт Боһданов дигән сабакташы белән дус булуын, тагын әле хәтсез күп нәрсәләрне сөйләде, җәелеп китеп сөйләве белән һәркемне үзенең авызына каратты.

Әрбәлек ермаклары ягыннан иләмсез зур яу булып, мөгрәп тә бәэлдәп, кайтып килүче көтүне күргәч кенә көтүгә каршы йөгерделәр.

Зур укымышлы, указлы мулла була Идрис хәзрәт. Өстәвенә чиксез уңган, йортны-җирне үзе алып бара. Кул-Черкендә башлы-күзле булгач, шунда бала-чага үстерә. Ике мәхәлләнең берсендә хәзрәт вазифасын башкара, мәдрәсәдә балаларга дин сабагы укыта. Ачык чырайлы, киң күңелле, ярдәмчел хәзрәтне барысы да үз итә. Фәкать берәү генә көнләшеп карый. Әүвәл тату гына яшиләр болар. Идрис мулла карт хәзрәтне олылый, аның киңәшләрен кире какмый, гайбәтен сатмый. Тик менә карт хәзрәтне бер заман хөсетлек корты кимерә башлый. Өлкән яшьтәге кешенең нәфрәтле карашын күрү Идрис хәзрәткә бер дә рәхәт китерми. Ике генә юл кала: йә бөтенләй күрмәмешкә салышып, башыңны диванага салып яшәү, йә инде низаглашып гөнаһлы булу... Ходай алдында гөнаһлы, авыл халкы алдында мордар булудан аптыраган-йөдәгән чагында аны күрше волостька имам-хатиб иттереп чакыралар. Бу яңа урынны Ходайның әмере дип кабул итә яшь хәзрәт һәм тиз арада Кече Салтык авылына бөтен гаиләсе белән күченеп китә.

Идрис мулла халыктан килгән хәер-садакага гына салынып ятмады, дәрманы-әүкате бар чагында йорт белән яшәде, мал-туарны мул асрады. Мәхәллә халкы аның хезмәтче тотмавына да, төрле эшкә кулы ятуына да, башкаларга надан мажиклар дип карамавына да, һәр кешене кеше итеп таный белүенә дә, улларын кече яшьтән крәстиян эшенә өйрәтүенә дә сөенеп бетә алмады.

Урманче дигән фамилияне Идрис мулла гомер буе аклады — кулыннан балтаны төшермәде. Кая ул каралты-кураны үз кулы белән кору гына! Койма-киртәләрне дә үзе рәтләде, казыкларын да үзе ерак урманнан барып алды, үзе юнды-яраклаштырды, алма бакчасын да, бәрәңге бакчасын да кура койма белән уратып алды, мал-туар якын бармаслык иттерде. Гәрчә коймасы аварга җыенмаса да, аңа юан-юан имән баганалар утыртып, өр-яңа тактадан үз кулы белән капка ясады, коеп куйгандай иттерде.

Ат асрагач бит арбасы-чанасы кирәк. Идрис мулланың андый нәрсәгә дә кулы ята иде. Тәгәрмәчне-дуганы базардан сатып алса да, калганын үзе майтарды. Кышын ихатадагы карны көрәү белән генә чикләнмичә, ат дирбияләрен һәйбәтләп, ашыкмыйча гына, иркенләп кенә үзе рәткә китерә иде. Агачы гына түгел, күне-каешы да, киезе-тиресе дә хәзрәтне тыңлый торган иде.

Мулла булгач, мәхәллә халкына ашка-фәләнгә җәяү йөрмәс ич инде. Үз кулы белән читән тарантас ясады, аны һәйбәтләп карага буяп җибәрде. Атны җигеп, остабикәсен янәшәсенә утыртып, ашка баруы җанга рәхәт иде. Бернинди мохтаҗлыкка тарымаска өйрәтте хәзрәт үзенең балаларын да.

Габделбакый телефон дигән иске яңалыкны артык өнәп бетерми, телефонга аптыраган чакларында гына мөрәҗәгать итә иде. Ә инде таныш-белешләре, дус-ишләре чылтыратып, чыбык аша озын-озак гәп сатарга чамаласа, әңгәмәне үзе дә өенә чакырып ала, шулай ук барып кайтырдай җае булганда телефоннан сорашып-белешеп тормый, җәяүләп булса да торып чаба иде.

Бу юлы да холкына-фигыленә һич хыянәт итмәде: Кече Салтыкны күрергә ниятләгәч, телефоннан белешеп-нитеп маташмады — тотты да биштәренә ватман кәгазьле башламаган альбом, икеме-өчме «кохинор» карандашы, Риза Фәхретдиннең бер китабын, авылдашларына вак-төяк күчтәнәч салды да, иртәнге сәгать алтыда ук, тәвәккәлләп, сәфәргә кузгалды.

Рәссам Елга портына җитеп, расписание-мазарны белешкәләгәнче, билетын алгалаганчы бәләкәй генә ак пароходның кузгалып китәр вакытлары да җитте. Һәрхәлдә, ул иң соңгы пассажир булып суднога аяк басты.

Урманченың түбәнгә төшеп, арткы залдагы буш урыннарның берсенә, тәрәзәгә якынрак елышып утырганын көткән шикелле, бәләкәй пароход тавыш-тынсыз гына кузгалыр булды. Чал чәчле пассажир әүвәл елга порты бинасына — пыяла белән бетон катнашмасының гармониясенә сокланып-сөенеп карады. Аннары Идел панорамасына күз йөртеп чыкты, аның өстендәге илаһи бер гүзәллек өлгесенә — Сөембикә манарасына төбәлде. Манара-һәйкәл кечерәйгәннән-кечерәя барып, тәмам күздән язгач кына, Иделнең хәйран ераклашкан сул ярына текәлде. Кай арада әллә кайларга качып өлгерде соң әле бу яр? Һич юньләп күрермен димә. Иртәнге томанда ерактагы урман сызыгы зәңгәрсуланып, тар гына тасма булып сузыла. Төсләр искиткеч бер самими табигыйлектә алмашына, берсеннән икенчесенә күчә дә сизелми-нитми генә Идел өстен, урманны, күк гөмбәзен бергә тоташтыра, бер бөтен симфония итә, нәкышь әсәре итә...

Уң як ярлар әле ерагая, әле аксыл известь ташлары белән якында ук пәйда була, өстенә ажгырып килә. Буй-буй кызгылт-көрән сызыклар җирнең төрле катламнардан торганын исбатлый. Әнә текә яр үзе дә, өстендәге наратлыгы да яргалана башлады, чокырлар, кыялар хасил булды.

Таш кыядагы аксыл юллар әнә бер өйнең контурын билгели. Юк-юк, өй генә түгел, һичшиксез, хан сарае! Тәрәзәләре хәтсез биек, түбәсенең кыегы шундый текә — исең дә, акылың да китәр инде менә. Бигрәк зиннәтле икән ханның сарае! Бу якта әнә болдыры тырпаеп тора, баскычлары — әбәү озын! Мондый хикмәтле күренешләрне кайчан да булса вакыт табып, әлбәттә, язарга кирәк булыр...

Әнә әкияттәге урман пәйда була. Куактан-агачтан да әрсез нәрсә юктыр ла бу дөньяда. Карыйсың да тәмам хәйран каласың: тау-таш бит инде югыйсә, тимеренә дә бирешкесез, ә менә шунда каяндыр берәр генә уч туфрак килеп эләккән, әрсез үлән кыяклары тезелгән, шуның бер читенә бәләкәй генә имән агачы сыенган. Тегенди-мондый агач ише түгел, имәннең бернинди җил-яңгырга да бирешергә исәбе юк. Үзенең күңеленә аеруча хуш килгән манзараны хәтеренә әйбәтләп сеңдерү нияте белән, Габделбакый бер тәрәзәдән икенчесенә, өченчесенә күчте. Салондагы пассажирларга ошыймы бу, әллә юкмы — анысын уйларга, бүтәннәргә яраклашырга Урманченың вакыты чамалы: аны иҗат дәрте бөтереп алды, шуңа буйсынмый гына бер сәгатен дә яши алмый. Хәер, пассажирларда рәссамның эше булмаган кебек, тегеләрнең дә гамьнәрендә юк, һәркайсы үз эше белән мәшгуль: бер ишеләре гәҗит яисә китап укый; икенчеләре җан дуслары белән чүкердәшә; өченчеләре исә балачага белән әвәрә килә. Олы яшьтәге, алыптай гәүдәле абзыйның тәрәзәдән тәрәзәгә йөренүен фәкать бер хатын гына ошатмады. Туктамасмы, дип өметләнеп, ул апасы шактый түзде, пароходка утырганчы ук башлаган батонының икенче башына җитте, шунда инде сабыры бетте бичараның, түземе төкәнде:

— Утыр инде шунда, вәт сине, карале!.. дип ычкындырганын үзе дә сизми калды.

Ул апасы белән бәхәсләшеп иҗади мизгелләрен вәйран итәргә исәбе юк иде аксакалның. Ак та димәде, кара да димәде, акаеп бер генә карап алды да өске катка, ачык һавага күтәрелде. Моннан күк йөзе бигрәк ямьле күренә икән.

Ни хикмәттер, болытлар кайчан карасаң да җигүле атны хәтерләтә. Әнә бу юлы да парлы кара туры ат, икесе дә ялларын дулкынландырып, башларын болгап, җилдереп киләләр. Башлары икесенең ике якка ныклап каерылган, күзләре әллә шәмәхә, әллә кызгылт инде? Тояклары бигрәк

саллы, яман саллы, аларга кургашын койгандай тоела. Кучеры гына күренми. Бәй, Бакыйҗан үзе кучер түгелмени? Күкләрне гизгән әкияттәге атларга ул үзе кучер икән ләбаса.

Габделбакый пароходтан, иске гадәтен куып, Тенеш кичүендә төшеп калды. Басмадан дебаркадерга аяк басу белән, портфель тоткан яшь-яшь бер егет аның янына килеп:

— Абый, сезне каршы алалармы? Машина-фәлән киләсеме? — дип кызыксынды.

— Юк, бернинди ат та, машина да килми, егетем. Боерган булса, менә шушы үз аягым белән тәпи-тәпи кайтырга исәп,— дигәнне ишеткәч, дөресрәге, чал чәчле, калку маңгайлы, зәңгәр күзле, түгәрәк йөзле сәер агайның сайраганын тыңлап та бетермичә, егетебез алга ыргылды. Аны тыңлап торырга егетнең вакыты юк иде. Озын аяклары белән җәһәт-җәһәт алдырып, һәммә кешене узып, яр буенда калкынып торган бердән-бер мотоцикл янына очып кына барды да, аның хуҗасы белән ике-өч кенә сүз алышып, ияренә менеп тә атланды.

Габделбакый туган якның яр буена сузылган үзле кызгылт балчыгына аяк басты. Як-ягына карангалап алгач, ашыкмыйча гына кузгалды, үрне менә башлады. Кызгылт балчык гүя шунда яр буенда ук торып калды, аның ары барасы, кырларга-басуларга җәеләсе бер дә килмәде. Үрне менеп җитәр-җитмәс үк туфрак күзгә күренеп үзгәрде.

Гәрчә җиденче дистәне башласа да, Габделбакыйның аяк-кулы таза, җәяү йөрүне әле хәзер дә мәгькуль күрә иде. Тик менә кичүнең үре генә бераз текәрәк һәм озынрак булып тоелды. Әллә суза төшкәннәр инде моны, дигән шаян уй да килде рәссамның башына. Һәрхәлдә, азмы-күпме тыны кысыла башлаганны абайлап, картыбыз юл кырыена утырып ял итәргә ниятләде.

Чирәмгә утыргач, җаны рәхәтләнеп китте. Күз ирексездән үзе әле генә калдырган пристаньгә, иксез-чиксез киңәеп, диңгездәй җәйрәп яткан Иделгә текәлде, уйлары-фикерләре элеккеге заманга, яшь чакларына юлланды.

Һай, бар иде лә аның типсә тимер өзәрдәй таза вә нык чаклары. Җәяү йөргән чагында да бернинди бүредән яисә юлбасардан курка белмәде, сәфәргә һәрвакыт таң алдыннан чыгып китәр иде. Әүвәлрәк, дөрес, шайтан-җен вәсвәсәсе бимазаламый калмагандыр анысы, мәгәр еллар үтү белән алары да коелып төшеп калды, җаны тынычланды. Йөреп тә күрсәтте инде үзе дә, хәйран кызу йөри иде. Артыннан атлы да җитмәс, дип тикмәгә әйтмәгәннәрдер, белеп әйткәннәрдер. Биштәре дә әлеге хәтле биш-ун була торган иде. Бу юлы бит күчтәнәчен-бүләген дә болай гына, күнел өчен генә алгандай булды. Атап алырдай кешесе юк. Ярый да бит кордашларыннан берәрсе авылда исән-имин генә яшәп ятса... Замандашлары сугыш вакытында кайсы кайда шәһит киткән булса, ни хәл итәрсең? Бернинди хат-хәбәр алышмагач, каян белмәк кирәк!..

Шушы озын гомерендә хәтсез күп хата кылган булса да, аларның казасы һәрчак үз җилкәсенә төшсә дә, һич үкенә белмәде Урманче, ник алай эшләдем икән дип, үзен битәрләмәде. Фәкать, бер авызы пешкәч, салкын суны да өреп каба торган булды, нәкъ шундый хаталарны ясамаска тырышты. Менә бит, хикмәте хода, бер ишесен кабатламаган белән, хаталары һич кимеми: яңалары өстәлә, җиллерәкләре...

Ныклабрак уйлап карасаң, аларның берсе дә сәбәпсез-нисез генә, тиктомалга эшләнмәгән. Һәркайсының сәбәбе булган. Менә әлеге дә баягы Салтык белән ара өзелүгә дә сәбәп булды: юньле генә эшләп килгәндә, җаны-тәне белән сәнгатькә илаһи өметләр баглап, гомерен шуңарга багышлап, тугрылыклы хезмәт иткәндә, кемнәрнеңдер хөсетлеге аркасында кулга алдылар, Соловкиларга сөреп, вакытын әрәм, гомерен вәйран иттеләр; аннан соң да әле Казанга кайтып урнашырга ирек бирмәделәр...

Уйлана торгач, бер заман сәнгатькәр үзенең шактый мавыкканын абайлап алды. Әмма үзен битәрләмәде, китәргә ашыкмады, чирәм өстендә яткан биштәреннән папкасын чыгарды да, аны тез өстенә куеп, карандаш белән генә җиңелчә этюдлар сызгаларга керешге. Сул кулдагы чокыр-чакырдан, тигезле-тигезсез яшеллектән башлаган иде, берочтан дебаркадер тирәләрен дә эләктерде, Идел кинлегендә акчарлактай булып күренгән ак пароходны да ярыйсы ук мәһабәт иттереп кәгазьгә төшерде, аргы сөзәк ярларга барып җитте, иртәнге кояшта чак кына алсуланып күренгән ак болытларны алды, карандаш белән төсне бирү мөмкинлеге булмаганга, болытның бер канатына гарәп хәрефләрен матур вә төгәл чыгарып: «Болары алсу!» — дип өстәп тә куйды, аннары уң кулдагы куаклык тирәсендәге рудник биләмәләрен җиңелчә тасвирлады. Аннары эскизларын барлап, күздән кичереп алды да:

— Булган бу! Мал ич болар! — дип үзалдына бәяләп куйды. Сокланып кабат караштырды да, кайчан да булса вакыт табып, майлы буяу белән киндергә күчереп язарга өметләнеп, биштәренә салып куйды.

— Кайткач та зурайтып язам, Аллаһы боерган булса! — дип фикеренә нокта төртте.

Ашыкмыйча гына атлый-атлый, Кутыр бакчасын узды, олы юлга чыкты, сул кулдагы Кама Тамагына баручы тасма-юлга рәссам буларак кызыгып-кызыксынып бераз карап торды да саллы адымнар белән уң кулга, Кече Салтык ягына тәвәккәл генә бордырып алды.

Арышлар серкә очыра түгелме соң?! Димәк, тиздән уракка төшәселәр. Матур гына күренә болай башаклар, береннән-бере тулырак, саллырак. Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламасын инде авыл халкын, ике бите белән җир себергән иген игүчеләрне! Югыйсә бит түрә-мүрәләр ике елның берендә табигатьне хурлап, сыныкка сылтау табып, быел эшләребез харап, диләр, үз көчләре белән, моңарчы күренмәгән техника җигеп тә, уңышны җыеп ала, амбарга сала алмыйлар. Быел андый хәл кабатланмасын иде инде. Шәһәрнекеләрне өмәгә чакырулары начар түгел анысы: таш диварлардан арынып, саф һаваны сулап, басуда кыймылдау сәламәт кешегә берни түгел. Ичмасам, ипекәйнең агач башында яисә кибет киштәсендә үсмәгәнен күрерләр, кадерен белерләр.

Башын югары тотып атласа да, уйланып барганлыктан, куе-зәңгәр җиңел машинаны ул, тәгәрмәчләрен шыгырдатып янына ук килеп туктаганчы, күрмәде-ишетмәде.

Машинаның алгы ишеге шыртлап ачылып китте, урта яшьләрдәге шофер ике дә уйларга урын калдырмый торган ныклы тавыш белән:

— Әйдә, утыр, абзый! Ничу монда җәяү йөрергә, машина барында! — диде.

Әмма сәнгатькәр бирешмәде. Шофер ягына борылып:

— Һай, дустым, егет икәнсең! Мең рәхмәт үзеңә, тик инде җәяүләп кайтырга исәп, ник дигәндә — күптән булганым юк туган-үскән якларда. Алланың рәхмәте яусын, иминлек үзеңә! — дип котылмакчы булды.

— Малай-шалай кебек сөйләшеп яткан була бит әле тагын! Курыкма бер дә, акча сорамам.

— Сорасаң-сорамасаң да, бу юлы утырмаска булдым әле, дустым.

— Чәчең агарган бит инде, биштәрең дә бар.

— Анысы авыр түгел аның.

— Җәяүлегә янчык та авыр, диләр. Кайсы авылга кайтасың инде?

— Салтыкны сагындым, бала вакытларымны...

— Ярый, алайса, гаепләмә. Каратунга барышым. Сөйләшеп барырбыз дигән идем...

Әле моннан соң да Кече Салтыкка чаклы ике мотоцикл туктады, берсенең бишегә дә бар иде. Ләкин рәссам нык торды, үзе шулай да Тау ягы халкының шәфкатьле-миһербанлы булуына сөенеп бетә алмады.

Шулай рухланып-канатланып кайта торгач, тагын үр менгәнен, Кече Салтык борылышына җиткәнен сизми дә калды. Артына борылып кара-

са — юл бөтенләй түбәндә, зиннәтле яшел keлəмне инләгән карасу-соры тасмадай, матур булып сузыла, югала икән. Рәссам иген басуларына озаклап кызыгып карап торды, аннары уйсулы-чокырлы, тигезле-тигез-сез, әмма күңеленә искиткеч якын Салтык юлына борылды. Юк, ял итеп тормады сәнгатькәр, базардан яисә ярминкәдән кайтучы ат, авылы өстенә күтәрелгән төтенне шәйләп, җиллерәк кайта башлаган кебек, ул да кадәри хәл адымын кызулый төште бугай әле.

Кече Салтык бит ул уйсу җиргә утырган. Авылның өстенә килеп чыкмый торып, син аны күрермен димә. Әле авылга кергәч тә, өйләр тезелешеп киткән татар авылына хас булган төп-төз урам-тыкрыкларны күрмәссең. Хәер, өйләр тагын да сирәкләнә төшкән сыман тоела. Булыр ул андый хәл, булыр, һи-и-и! Тәмам беткән икән безнең Салтык! Элеккеге кыяфәте һич калмаган. Ай-һай ла!..

Җанга якынлык, күңелгә куаныч бирердәй нәрсә — ул да булса бакчалары. Елга-ерынты арасыннан, әрсезләнеп дигәндәй, олы бер бакча калкынып чыга. Юк, чишмә буендагы, юл кырыендагы тал-тирәкләр түгел бу, һич юк. Яман нык үсеп киткән алмагачлар, чияләр, сливалар. Нинди генә сортлары юк монда! Җиләк-җимешкә тиенә икән халык. Авыл башыннан караганда өйләре гел күренми дә. Әһә, исән калган өйләрнең күбесе бакчага сыенып, умарта оясы кебек кенә утыра икән. Хәер, үләне мул булып үскән, чәчәкләр ямьләндереп җибәргән бакчаларда умарта оялары да күренгәли икән. Һай, рәхәтләнә булыр бал кортлары, бәләкәч уңганнар.

Әнә бормалы да сырмалы инеш кисәге — Ылгама. Антоновка авылы белән ике арадагы барлык чишмәләрнең суын үзенә җыеп утыра. Шул чишмәләрдән хасил булган инеш, дисәң дә, һич хата булмас. Ничек дип җырлыйлар иде әле? Әһә, болай икән:

Безнең авыл Ылгамасы
Абзавылга Үләмә...

Сабый чагында ишеткән генә түгел, үзе дә җырлап йөргән җырны әле менә хәзер исенә төшерүдән бик тә күңеле булды сәнгатькәрнең. Һәй ул сабый чаклар, малай вакытлар! Салтыкка бөтен гаиләләре белән күченгәннән соң, гәрчә авыл мәдрәсәсенә йөрмичә, «Мөхәммәдия» шәкертенә әйләнсә дә, каникулга кайткан саен, җәйнең буеннан-буена малай-шалай белән йөгерешеп тә көрәшеп йөрде, чирәм таптады, якын-тирәдәге елга-ерынтыгы айкады, атларга атланып, төнгелеккә чыккалады; бераз үсәнгый төшкәч кенә әтисе белән печән чапты, аны киптерде һәм җыештырды, кибәнен куйды, олау-олау алып кайта торган иде. Сука сукалау әллә ни күп тимәде Габделбакыйга: җир сөрү вакытында ешрак читтә, мәдрәсәдә торып калды.

Әнә мәчет... мәчетнең урыны. Әһә, клуб салып куйганнар икән. Анысы да ярый. Клубның зыяны юк, ул да агартырга тиеш халыкны.

Әнә аларның өйләре торган урын. Мәчет каршында иде шул, мәчет каршында. Олы гына, кабак башлы йорт иде. Бүтән якларда шатрун (шатром) диләр бугай, шундый иде өйләренең түбәсе. Биек иде, иркен иде өйләренең эчә дә. Ул яктылык дисәң... Сафыялар, Нәҗибәләр гөр килер иде ахирәт кызлары белән. Әтиләре буш вакытларын йорт тирәсендә, мал-туар янында уздырыр иде. Әниләре өй эчендәге эшләргә, пешерү-төшерүгә дә, туку-чигүенә дә өлгерә иде. Бала-чага кыен ашамады инде, ашамады. Гупчем мулла йорты димәссең. Өйдә берниндн акыл сату, орышу-тиргәү булмады; ә инде һәркайсындагы әдәп-тәүфыйк — анысы тумыштан; өйдә хөкем сөргән үзара мөнәсәбәтнең дә тәэсире-йогынтысы булмый калмагандыр.

Нәрсә дип гаҗәпләнә соң әле Габделбакый үзләренең йортлары шул урында сакланмаганга? Мулла йортын кем сакласын ди инде? Бөтен каралты-куралары белән бергә алып киткәннәр. Ә бит нинди матур итеп

житештергән иде әтисе, үз кулы белән житештергән иде. Кулыннан килмәгән эше юк иде хәзрәт кешенең. Һәммәсен дә булдыра иде... Нигезләрен пыран-заран китергәннәр, тулаем вәйран иткәннәр. Бакчаларын да юкка чыгарганнар, ник бер агач утырып калсын. Аның урынына иплән кенә кибет корыштырып куйганнар. Анысы да ярый, ни әйтсәң дә, халыкка хезмәт күрсәтә.

Һәй, моннан авылыбыз уч төбендәгедәй күренә икән! Менә генә Ылгама суында каз-үрдәк бәбкәләре болгана; камыш арасында куышлымы, качышлымы уйныйлар, ахрысы. Ылгама Антоннардан ук килә, әнә бит ярлары уемлы-чокырлы булып еракка сузылган, инеш гел чишмәдән җыела, без үскәндә хәтсез күп иде ул чишмәләр, кругом чишмә иде. Бу тирәләрдә, авылның эчендә үк Изгеләр чишмәсе дип аталганы бар иде; хәйран тамаша инде — суы тамып кына тора. Чокыр эченнән чыга ул, су тамып кына тора, гел акмады; шуның суын алып, учына җыеп, күзеңне юсаң, шифасы тия, диләр иде. Ата-бабадан, буыннан-буынга мирас булып, юк, алай гына түгел, васыять булып кала килгән әлеге изгеләр чишмәсе; борынгылардан безгә васыять булып кала килгән изгеләр зираты — шунда күмелгән аларның җәсәдләре... Кем белә инде кайсының нинди шифасы тигәнен. Һәрхәлдә, Идрис хәзрәт өендә авырып-иза чигеп яткан кеше булмады. Остабикә бер яктан кул эшләренә өйрәтеп тәрбияләсә, хәзрәт үзе егетләрен йорт эшенә дә, кыр эшенә дә йөрәтә торган иде. Авыр туфраклары җиңел булсын, гомер эчендә бер каты бәрелгәннәре, авыр сүз әйткәннәре булмады...

Ихтимал, читтән килгән кешегә Кече Салтыкның матурлыгы алай тиз генә күренми дә торгандыр. Йә, нинди ямьлелек күрәсең инде бер генә дә тигез һәм юньле урамы булмаган, елга-ерынтылы авылның? Ә менә үзең шушында үскәч, менә шушы чирәмендә аунагач, һәр чишмәсенең суын эчкәч, болынында ат саклагач, печәнен чапкач, күңелгә бик якын, әйтеп бетергесез якын була икән шул. Урта Азиянең гүзәллеге дә, Казагыстанның муллыгы да, Алма-Атаның алмасы-хөрмәсе дә ярыша алмый икән туган-үскән авылыңның ямьлелеге белән.

Һай, тел белән генә әйтеп бетерерлекмени Кече Салтыкның ямьлелеген, күңелгә якынлыгын! Һәр төбәкнең үзенең тарихы-дастаны, алай гынамы, һәр күлнең, һәр ермакның үзенең исеме-даны бар.

Әнә генә искитәрлек матур яшеллек — Бибиҗамал чокыры. Аннан өстәрәк янә бер илаһи матурлыкка күмелгән Әрбәлек ермаклары; ул кура җиләге, ул чиясе, ул алмасы дисеңме син Әрбәлек ермакларының! Антоновка урыслары тикмәгә генә шунда кадәр килеп яшелчә утыртмагannardыр инде. Хәер, Антоновка урманы тирәсе дә, Иске Антон ермаклары да борын-борыннан килгән зур байлык инде алар.

Халык телендә «Кутыр бакчасы» дип йөртелгәне «хутор» сүзеннән азган булса кирәк. Анда кайчандыр алпавыт утары булган бугай. Бакчаның тирә-ягында әле кайчан гына үр дә чокыр саклана иде.

Хөсәен тавы башы моннан юньләп күренми бугай. Аның да тарихы бар: имештер, басудан кайткан чагында Хөсәен атлы бер агай, шул тирәгә утырып, чабатасын каккан — шул вакыттан соң түм-түгәрәк тау хасил булып калган.

Авылның икенче ягында Тирән чокыр бар иде шикелле. Түгәрәк чирәм дигән җирдә, искиткеч матур иңкүл урында малайларның көтүләре белән җыелганын, хәтфәңә бирешкесез ямь-яшел чирәмгә ятып, әкият сөйләүләрне ничек онытмак кирәк?

Ә соң Казенный урман? Петр заманында шул урманга килеп, корабның кайсыдыр төшенә яраклы табып, шул урманда үсеп утырган имәннәрнең һәркайсыннан берәр генә буй кисеп ала торган булганнар.

Олы Салтык ягында тагын әле Чүп елгасы дигәне дә бар. Аннан килеп Каратун ермаклары исендә рәссамның. Ике Салтык арасында да Изгеләр зираты бар иде шикелле. Аннан өстәрәк Лашман юлы дип атала торган юл бар, анысы Олы Салтыктан Каратунга илтә. Гап-гади юл инде үзе, ә

менә халык теленә зәхмәтле юл дигән яманаты белән кереп калган бит, нихәл итәсең!..

Урманченың уйлары күпме генә әйләнә-тирәдә уралмасын, барыбер төп йорт нигезенә әйләнеп кайта иде. Хәер, үзе дә бит, уй-фикерләренә ияргәндәй, ни чаклы гомерен чит-ят җирләрдә уздырмасын, нинди генә ямьле төбәкләрне гизмәсен, һәрчак андагы матурлыкны Күл-Черкен белән, Кече Салтык белән чагыштырыр иде. Шул үзе нәкъ менә туган якларны сагыну, ичмасам бер генә исән-имин кайтып күрергә зарыгу билгесе түгелмени?

Әткәй, әнкәй! Шушы нигезне юктан бар иттердегез, шушы нигездә безне тәрбия кылып үстердегез. Какмадыгыз-сукмадыгыз, бер авыр сүз әйтмәдегез, укырга-язарга һәммәбезне үзегез өйрәттегез, әдәпле-инсафлы, шәфкатьле-миһербанлы булуның үрнәген үзегез күрсәттегез. Та кыямәт сезнең алда бурычлыбыз. Рәхмәтле бәндәләр буларак, инде тыныч йоклагыз. Оланнарыгызның шактые, сезнең фатиха белән, Ходайның биргәненә мең шөкер, исән-имин генә яшәп яталар. Мөхсинәгез Сәмаркандта гөрләтеп яши, үзенең өе бар, кызы белән кияве мәктәптә балалар укыта. Сафыягыз Казанда төпләнеп калды, хәсрәт чиксә, кыен ашаса да, гомере буе фармацевт булып эшләде, хәзер тыныч кына яшәп ята; аның улы талантлы рәссам: дөрес, ул урысның телен дә, кайсыбер яман гадәтләрен дә кирәгеннән артыграк үзләштергән, дөньяга яраклашкан бала, әмма күңеле искиткеч әйбәт егет. Төпчегегез Нәҗибә Мәскәү каласына барып урнашты, финанс эшендә, ягъни исәп-хисапны яхшы белә; киявегез безнең Күл-Черкен егете, язмыш аларны шулай кавыштырды. Инде үземә килсәк... Минем дә гаиләм Мәскәүдә яшәп ята; күпме генә кыстасам да, киленегез Сара минем янга кайтмады Казанга. Аны да гаепләп булмый инде: шунда консерваторияләр бетергән — пианист һөнәренә өйрәнеп, гомер буе шунда эшләгән; ничекләр итеп аерылсын ди ул үз шәһәреннән? Юк, аерыла гына алмый шул, алмый. Анда күчәнсәм, улыбыз нишләр, дип тә куя. Оныгыгыз Илдар болай өметле генә рәссам булып килә. Нәрсә дияр бит әле дөнья, нәрсә дияр... Әгәр дә мәгәр икебезнең һөнәрендә мине уздыра икән, бер сүзем юк, сөенермен генә. Сез дә сөенерсез, газизләрем, минем белән бергә, сез дә... Инде тыныч йоклагыз!..

Килер вакыт, даһи рәссам үзенең мулла гаиләсендә тууын яшерүдән туктар. Югыйсә бит автобиографияләрендә җае чыкса — әйтми калдыру, сыйпап-сылап кына узу, ә инде «тотса мәскәүләр якаң» — мөгаллим гаиләсендә тудым, дип ялганлау тәмам гадәтенә кереп, канына сеңеп беткән иде. Чит шәһәрләрдә моңа бәйләнүче-мазар булмаса да, авылдашларыңны бит алдый алмыйсың. Алар телендә «Идрис хәлфә» дигән төшенчә бөтенләй юк, алар телендә әлегәчә фәкать «Идрис мулла» гына яшәп килә. Хәтерләре әйбәт, рәхмәт төшкерләре, кирәгеннән артык әйбәт.

Ярый да бит ике-өч авылда гына шулай дисәләр. Әле бит, дөнья куа-куа, аның авылдашлары Казанга килеп төпләнгәннәр, Мәскәвенә кадәр барып җиткәннәр. Әйтик, гыйлем йортында хәйран иплe-мәгънәле әңгәмәдән күңелләре тәмам эреп, галим-голяма белән чүкердәшеп, кызкыркынның арка буйларын сыйпаштырып кына ләззәт диңгезендә йөзгән бер мизгелдә... Күрер күзгә үсмер булудан узмаган, егет булып җитмәгән бер дивана сүз кушмасынмы! Нәрсә ди бит, каһәрем-зәһәрем:

— Без бит авылдашлар, Бакый абый. Минем хатын Кече Салтыктан. Хатынның әтисе авыл Советында рәис чагында Идрис мулла белән бик дус булган. Икесе дә укымышлы кеше. Идрис хәзрәткә дөньяның кайсы якка авышканын, бөтен ил күләмендә дингә каршы көрәш җәеләсен, мәчетләрнең манаралары киселәсен, дин әһелләренең янә бер сират күпере кичәсен шул әйткән бит. Әйтеп кенә калмаган, муллалыктан ваз кичәргә киңәш биргән. Югыйсә балаларына кыен ашарга туры киләсен әйбәтләп төшендереп биргән...— дип теленә салына.

Авызың тулы кан булса да, кеше алдында төкермә, дигәнне исендә тотып, аксакал шулчагында коты алынганын тышка чыгармады, эчке халәтен һичберәүгә сиздермәде, теге бәндәнең авызын бик оста япты ябуын, әмма... Әмма төне буе керфек какмады, тыштагы шылт иткән тавышка да колак салып ятты. Ходайның һәр бирмеш көнендә кара фургон белән «утырмага» алып китүләрен көтеп, дер калтырап утыру алай ансат фал түгел шул.

Инде заманалар янә үзгәрде. Хәзер инде Идрис хәзрәтнең тирәюньдә, Тау ягында иң зур укымышлы шәхес булганын, мәшһүр мулла булганын авыз тутырып әйтә аласың.

Үз дөньясына чумып шактый вакыт шулай торганнан соң сәнгатькәр, инде хәзер кая барырга, дип уйлана калды. Үзе кыен ашаган, авыркараңгы елларда кайткан булса, алай-болай күренеп йөрмәс, әштерөштер генә җыенып иде дә китеп тә барыр иде. Хәзер инде инкогнито йөри торган заман түгел. Үтте андый заманалар, үтте. Бүген ул бөтен илгә мәһшүр иҗатчы, сәнгатькәр. Аның берәүдән дә куркырлыгы юк. Ул халык шагыйре бөек Тукай исемен йөрткән Дәүләт бүләгенә лаек табылган шәхес. Бүген аның белән аралашуны авылның хуҗалары да үзләре өчен мәртәбәгә-данга санарлар.

Авыл Советында пәһлеван гәүдәле, чал чәчле, мөлаем йөзле рәссамны дүрт куллап каршы алдылар. Биштәрен һәм эшләпәсен эләргә ике имән чөй таптылар, үзен олылап түргә, рәис янына китереп утырттылар.

Хәл-әхвәл сорашкан арада рәис тиз генә телефоннан кемгәдер хәбәр бирергә дә өлгерде.

— Әйе, үзем генә түгел, олуг кунак белән,— дип сүзен очлады.

Авыл Советында озын-озак юанмадылар. Урамга чыгып, җәяүләп кенә юл алгач, рәссам авыл башлыгын зиратка сугыла чыгарга күндерде. Зиратның кайда икәнен аксакал болай да белә иде, ялгызы гына да тапкыр булыр иде. Тик инде хуҗаның үзе белән бергә зыярат кылуны мәгъкульрәк күрде.

Әмма ләкин рәссамның андый өметләре акланмаска язган булып чыкты. Зиратка җитәбез дигәндә генә аларның алдында... сыер көтүе пәйда булды. Моны күреп, кунак тораташтай катып калды. Авыз ачып сүз әйтерлеге юк иде аның. Атлап китәрлек хәле дә юк иде. Аяктан язып егылу, шунда, газиз әнкәсе, туганнары яткан изге җиргә мәңгелеккә түнү, ятып калу аның өчен иң ансаты иде. Ихтимал, иң кулае да шул булгандыр, тик ул егылмады, бирешмәде — изге җирне сыер көтүеннән аралыйсы, тәмам арындырасы бар иде әле.

Юлдашының шулай миңгерәүләнеп китүе авыл башлыгын тәмам аптырашта калдырды. Мөгаен, бу мизгелдә алар икесе дә бер үк хәлдәчамада булганнардыр. Шулай да яшьрәк кеше тизрәк аңына-акылына килде. Моның сәбәбе, ихтимал, аның аксакалдан ике тапкыр яшьрәк булуында түгелдер, бәлки олы кунакның иминлеге өчен үзен җаваплы санавындадыр. Ул җиңелчә генә аксакалның беләгенә орынды, күзенә карап:

— Нәрсә, Бакый абзый, хәлең китте мәллә? Кояш сукмагандыр бит? Яман кыздыра. Әнә көтү дә ышыграк урынны сайлап бик дөрес иткән,— диде.

Авыл башлыгының шул рәвешле теленә салынуы аксакалны айнытып җибәргәндәй булды.

— Мине Ходай кояшы сукмады, синең көтүең сукты,— диде ул.— Син соң, кем, персидәтел иптәш, үзең шушы авыл малаемы? — дип тупас кына сорап куйды.— Әллә берәр килмешәкме?

Рәис елмайгандай итте:

— Шушы авыл малае булмый тагын... Югары оч малае мин.

— Димәк, син Кече Салтыкта туып-үскән хода бәндәсе?

Рәис яңадан елмаерга тырышты:

— Нәкъ өстенә бастың.
— Атаң-анаң да бар идеме?
Рәис көләргә үк чамалады:
— Бар идеме, дип... Әле дә исән алар, беркая китмәделәр.
— Атаң-анаң үлгәч, син аларны шушы зиратка китереп күмәрсеңме?
Рәис көлеп кенә җавап бирде:
— Мин депутат, мин башлык дип кенә алар өчен махсус мавзолей төздерә алмыйм ич инде мин.
— Аларга атап мавзолей кордыру хәлеңнән килмәгәч, нишләп әле син, авыл башлыгы була торып, изге урынны сыерларыңнан таптаттырасың? Монда яткан бабаларыңның сөякләрен таптатасың, рухларын-әрвахларын рәнҗетәсең ләбаса! Шуңа койма кордыру гына хәлеңнән киләдер ләбаса, мавзолей кору түгел!
Рәис үзен райком бюросы алдында торган шикелле хис итте, кай арада җитдиләнеп өлгерде:
— Ни бит ул, Бакый абзый иптәш, теге... ни чакны, сугыш вакытында авылга чегәннәр килеп оялаган. Зират киртәсен шулар шудырган, ни... урлап алып киткән... ягып бетергән...
— Кем рөхсәт итте икән соң авыл зиратын койма-курасыз калдырырга?
— Кем дип... Ни инде... Атта да бар гаеп, тәртәдә дә.
Шулай дип әйтә алуыннан биниһая канәгать булып, башлык хәтта иләктәй авызын ерды. Әмма ашыга төшкән булып чыкты — кунагы аның сүзенә ялгап ук:
— Гаеп монда синең үзеңдә дә сыерда гына, башкаларга сылама үз гаебеңне! — дип ярып салды.
Рәис райком бюросындагыдай акланып маташты:
— Ни бит, Бакый абзый, акча ягы такыр бит безнең.
Аксакалның андый дәлилне ишетәсе дә килмәде:
— Син бер нәрсәне аңла, хакыйкать буларак кабул кыл. Авылның бәясе, аның хуҗаларының абруе, гомумән һәркемнең абруе ата-бабага хөрмәт саклауга карап йөри.
— Хөрмәтне саклыйбыз инде анысы...
— Дәшмә, тыңлап бетер! Күл-Черкендә булдым, үземнең туган авылымда. Менә анда авыл халкы, ата-анага хөрмәт саклыйбыз, дисә дә була. Сугыштан соңгы биниһая авыр елларда нишләгәннәр дисеңме? Агач рәшәткәнең ташыннан тимер рәшәткә белән уратып алганнар, әле шушы елларда гына тагын бер кат, бу юлы да тегеләрен сүтмичә, — изге әйберне җимерергә кемнең кулы барыр икән! — янә тышкы яктан ныклап тимер койма корып куйганнар.
Әллә рәиснең күзенә сыер йоны-төге керде инде, әллә баш чүмече үтәли кояш нуры сукты — нигәдер күзен челт-челт иттереп алды:
— Бездән булмый шул андый зур эш... Тимерне каян табасың... — дип сөйләнде.
Аксакал гайрәтле генә:
— Тимер булмаса, агач булсын. Фәкать мондый башбаштаклыкка юл куярга ярамый. Син хәзер үк сыерлар полководецы янына барасың да моннан соң изге җирне таптатуга чик куясың, хәзер үк чик куясың! Югыйсә, безнең юллар минуты белән аерыла.
Килер вакыт, Урманче исән чакта ук, авыл Советы зиратта көтү йөртү кебек сантыйлыкка чик куяр: халыктан акча җыеп, авылда яшәүчеләреннән генә түгел, Кече Салтыктан читкә китеп яшәүчеләренең дә хакыйкатьне, ягъни ата-бабаларыбыз яткан зиратның коймасы юк, мал-туар таптый, дип хәтерләренә төшереп, әкренләп кенә мая туплап, шушы зур эшне башкарып чыгар әле — койманы койдырып, җеназага кирәкле асбапларны кую-саклау өчен сарай кордырып ташлар әле.

Рәссамнан Рәҗип егерме-утыз яшькә калышрак булса да, алар дуслашып киттеләр. Нәҗибәнең ахирәте Газизә читтән кайткан кунакны чәйгә дәшеп алгач, мәтрүшкәле сөтле чәй эчеп утырган чагында гапләшә торгач, серләре килеште боларның. Кайчагында яшь аермасы комачаулык итми, кешеләр бер сөйләшүдән дуслашып китәләр бит. Монда да шулай килеп чыкты. Рәҗип үзенең мәзәк катнаштырып сөйләве белән дә, эчкерсезлеге белән дә күңеленә хуш килде кунакның.

Рәҗип сигез бала арасында иң олысы икән. Дөресрәге, ул үги малай булып та үзенең үгилеген һич сизмәенчә, олы малай буларак иртә яшьтән кул арасына кереп үскән. Үз әнисеннән ике яшендә калган җитез генә буйчан малайны да, аның әле яңа туган сеңелесен дә Газизә бик тә инде якын күрә. Әллә үзе дә унбер яшеннән ятим калып, дөньяның ачысынтөчесен бик яшьли татыганга, әллә үзенең ирен яратканга, әллә инде унҗиде яшеннән кияүгә чыгып, бер-бер артлы алты бала биләгәнгә, нилектән икәнен тәгаен үзе дә белми, тик менә ике ятим сабыйны Газизә һич кенә дә чит итми, миһербанлы-шәфкатьле була.

Авылларында ничәмә-ничә тегермән булып, Газизәләрнең тегермәне тирә-юньдә дан тоткан: аңа Антоновкадан да, Олы Салтыктан да, башка авыллардан да йөргән халык. Шул тегермәнне болардан тартып алалар.

— Әтиебез үлгәч тә, аңыбызны-һушыбызны җыярга өлгермәдек, ачкычларны килеп алдылар. Үкерешеп еладык шул бөтен өебез белән... аяктан калып еладык...— дип хәзер сөйләве дә җиңел түгелдер.

— Нәҗибә, Пәтиха белән бергә укыдык без. Коръәннән соң инде җәдиткә күчтек... Әле уйласаң, яшь чаклар килеп баса күз алдына. Карасаң — тамаша! Әйбәт гомер иттек без, үрнәк гомер кичердек.

Шул сабыйларым ачтан үлмәсен дип, ике бите белән җир себергән авыл хатынының Нужа бабайдан зарланасы урында шөкерана кылып утыруына сокланмаслык җиреңнән сокланырсың. Кунак уйга бирелеп, тыйнак кына тыңлап утырды.

— Ике мулла иде авылыбызда, ике мәхәллә. Алар йөри иде югары оч мәхәлләсе дип, без йөри идек түбән оч мәхәлләсе дип. Сезнең өегез олы гына, кабак башлы йорт иде, мәчеткә каршы гына. Үзләре йорт тоттылар әтиләрең, үзләре җир чәчтеләр. Бер дә инде нәфесле түгел иделәр. Өмә җыйсалар да — туй мәҗлесе кебек иттерәләр иде. Хөрмәтчән кешеләр иде, ярдәмчел кешеләр. Һич масая белмәделәр инде менә, һәммә кешене дә кеше итеп таный иделәр.

Хуҗабикә хәтеренә гомерлеккә уелган истәлекләрен, әле менә хәзер күз алдыннан агылган вакыйгаларны тасвирлагандай, җиңел генә тезде дә тезде.

— Үзләре ихлас әдәпле, тәртипле кешеләр иде. Бөтен мактаулы сүз булса, аларга тия инде... Дөньялар бозылгач кына, авылыбызда мәхшәр купты. Мәчетебезнең манарасын кисеп һәммәкиебезне елаттылар... Зиһеннәре җитте Идрис хәзрәтнең, Идрис хәзрәт авылдан иртәрәк китте. Мәчетебезне вәйран иткәнне әгәр күрсә, йөрәге ярылып үләсе әүлия иде...

— Әйе, әйе, әниебез дөнья куйганнан соң әткәй, бетте дөньяның яме дип, безнең янга Казанга күченде.

Гәрчә өен һәйбәтләп җыештырып, курчак өедәй иттереп куйса да, табынында ризык-нигъмәтнең төрлесе ямьләнеп торса да, хуҗабикә нишләптер үзен бик иркен тота алмады, нигәдер уңайсызланып, әледән-әле:

— Ашап-эчеп утырыр идең, Бакый абзый. Менә коймагыннан җитеш. Безнең болай ырык-сырык яшәгәнгә исең китмәсен инде,— диеп гафулар үтенде.

Табын янында шактый утырылды. Ул арада әңгәмә куерганнан-куера барды, шунда инде Идрис хәзрәт гаиләсенә карата авыл халкының күңелендә иң матур истәлекләр, иң изге теләкләр сакланганы, аеруча Нәҗибәне сагынып көткәннәре беленде, авыл халкының яшәү-көнкүреш рәвеше дә ачыкланды.

Сугыштан соң авыр елларда яшь-җилкенчәк шәһәргә китү ягын караган, өлкәнрәкләр исә тәвәккәлли алмаган, бәрәңге бакчасына аркаланып, кайчан да булса авылыбыз ипекәйгә туймасмы дип өметләнеп, искечә яшәвен дәвам иттергән.

— Балаларымның һәркайсысын югары белемле итәргә тырыштым шул. Бер Рәҗибем, әтисеннән соң йорт башы булып калган олы малаем, авылдагы җиде класстан ары китә алмады, бичаракаем...

Рәҗип үзен бер дә алай бичара итеп сизми иде бугай: иң авыр чакларда үзләре кичергән михнәтләрне дә хәзер инде мәзәк итебрәк сөйләргә тырышты.

— Сугыштан соңгы еллар, анысы, ярый, азмы-күпме буйга үсеп киттем ичмаса, әллә ни көч булмаса да... Ну, Бакый абзыкаем, сугыш вакытында эләкте дә соң үзебезгә! Бигрәк тә ягарга беткәч, кышкы суыкларда... Әнкәй белән икәүләшеп китәбез Иделнең теге ягына, чана тартып. Шул Тенеш кичүеннән инде. Төйибез урманнан утын. Алай дигәч тә, берәү дә анда безгә хәстәрләп куймаган ул утынны. Үзебез җайлаштырабыз. Чана бит ул хикмәтле нәрсә...

Кунак та үзенең төшеп калган кеше түгеллеген күрсәтергә җаен көтеп утыра иде, әле менә җае чыкты дип уйлап:

— Бик инде, бик тә хикмәтле! — дип аның сүзен җөпләп куйды.

Мөгаен, үзеннән канәгать калды бугай, урындыгына арткарак китеп утырды да бар игътибарын сөйләүчегә юнәлдерде. Рәҗип истәлекләрен дәвам иттерде:

— Чана ул буш чагында бик җиңел, теләсә нинди кар өстеннән элдертә генә. Ә инде бераз утын салсаң, бигрәк тә нәфесеңә бирелеп төясәң — һич тартырмын димә. Бөтен кешенең чанасы урман эчендә тирән карга бата. Бер без генә выжлатып чыгабыз ул урманны. Безнең бит кул чанасы дигәнебез киң табанлы, ат чанасы бераз кыскартып ясалган! Иделне дә ипле генә кичәбез анысы, ярый. Ну инде, Бакый абзыкаем, кичүдән ярга менеп җиткәнче ничекләр интеккәнебезне белсәә-әң! Мин алдан тартам, әнкәй арттан бар куәтенә этә. Киң табанлы чанабызның гына тау менәргә исәбе юк. Артка тарта, хәерсез!..

Сөйләшүдә хуҗабикә улына җитешә алмаса да, тик утырмады — куе итеп чәен ясады, сөтен салырга да онытмады, таба ашларын табагы белән кунакка табарак этәрә торды, яраса, ашатып бетерергә дә риза иде. Әз-мәз булса да сүзгә катнашкалады.

— Шунда утырыплар елый идем Рәҗибемне кызганып. Яшь-яшь көенә иза чигә иде бит балакаем, яшьли биртелә иде.

— Һи, әнкәй, бик тиз онытыла иде бит андагы ару-талулар, утын төяп авылга кайтып җиту белән. Тем более авылга кергәч тә аска таба чана үзе полный ход бара башлый торган иде.

Бераз көлешеп алгандай иттеләр. Шуннан инде хуҗабикә сүзне икенче якка борды:

— И-и-и, асыл затлар иде бит синең әти-әниләрең, Бакый абзый. Аларны мактап кына бетерерлек түгел инде менә.

— Газизә дим, син аларны шулай ук яхшы хәтерлисеңмени?

— Хәтерләмичә теге, без бит ахирәтләр идек Нәҗибә белән, бик якын ахирәтләр. Остабикәдән бергә-бергә сабак алдык. Аннары да сезгә төшәдер идем әле. Нәҗибә белән курчак уйнамый калган көнебез булмагандыр. Курчакларыбызга кием тегүләр, ул «кунакка йөрүләр», сәлам көянтәләр белән «суга барулар», чырык-чырык көлүләр һич исемнән чыкмый. Әле менә кичә генә уйнап үскәнбездер төсле тоела.

— Әткәйләрне дә хәтерлисеңме? Ниндирәк кеше булып исеңдә калган? Килеш-кыяфәте нинди иде?

Бер дә уйланып тормады хуҗабикә, шундук әйтеп алып китте:

— Мин белгәндә хәзрәтебез бераз калынрак-карсаграк буйлы, тазаның гәүдәле, түм-түгәрәк йөзле, мөлаем генә бер абзый иде. Ап-ак сакалы да түгәрәк йөзенә ничектер бигрәкләр килешеп тора иде үзенең.

Чәче минә бер дә исемдә калмаган. Башында чалмасы югында һәрчак хәтфә түбәтәй булыр иде.

— Чәчен алдырып йөри иде әти мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын...

— Шулайдыр, шулайдыр, Бакый абзый, түбәтәй киеп, түр якта зурзур китаплар укып утырганын хәтерлим. Безнең якка да ара-тирә күз сала торган иде. Безнең мәш килеп курчак уйнаганыбызны күреп, елмаер иде, сабый күңеленә якын берәр сүз әйтер иде.

Рәҗип булсын да әңгәмәгә катнашмасын, имеш.

— Юк, әнкәй, син ялгышасыңдыр, аңа бит әле өйдәгеләр белән генә түгел, мәхәллә белән дә управлять итәсе бар,— дип куйды.

Моңа кунак иркенләп җавап кайтарды:

— Ул болай бит, Рәҗипҗан дустым. Безнең әткәй холкы ягыннан һич тә инде минә кырыс булмады . Мәчеттә, мәхәлләдә бит, миңа калса, мулладан усаллык яисә кырыслык таләп ителми, инсафлы-итагатьле булу сорала. Искиткеч дәрәҗәдә гадел кеше иде безнең әткәй. Аннары килеп мәхәллә алдында укыр өчен тавыш кирәк, дустым. Һи-и-и! Тавыш бар иде инде Идрис хәзрәттә, бар иде. Мәкам белән кычкырып укып җибәрсә, тыңлаучылары тәмам оеп китәләр иде.

Рәҗип һаман үзенекен итте:

— Әллә бәлкем, гипноз булгандыр мулла абзыйда, шуның белән алдыргандыр?—дигән сорау куйды.

— Юк, дустым, хикмәте аның гипнозда түгел, һич юк. Сиңа мәгълүмдер инде, Коръән бит ул шигъри әсәр, поэзия, иң зур камиллек дәрәҗәсенә җиткән поэзия. Аны көйләп уку фарыз. Көйләр өчен тавыш кирәк, мәкам кирәк. Безнең әткәйнең тавышына барча кеше таң кала иде. Болай урамда сөйләшүенә дә сокланалар иде. Ә инде мәчеттә бит, дустым, бөтенләй икенче хәл, анда акустика! Мәчеттә гади тавыш белән укыганың да яңгырап ишетелә. Ә инде яңгыравык мәкам белән Коръән сүрәләрен укып җибәргәч, аның тәэссорат көче бермә-бер арта. Аннары хәйран зур укымышлы кеше иде бит безнең әткәй. Коръәнне ул яттан укый торган иде. Тоташы белән, шундый зур китапның башыннан алып ахырына кадәр яттан белә иде.

Хуҗабикә баш кагып алды:

— Булгандыр, булгандыр, безнең әткәй аны бик мактый иде, бик ярата иде. Ашка йөрешәләр иде...

Рәҗипнең һәмишә бирешергә исәбе юк иде әле:

— Мин бит Идрис мулланы бик кырыс, бик усал кеше булган, шуңа күрә оныта алмыйлар, дип тора идем,— диде.

— Болай бит ул, дустым. Син ни чаклы гына усал булсаң да, аның белән берни кыра алмыйсың. Минә мин иҗат кешеләрен беләм, рәссамнарны.

— Безнеңчә әйткәндә, художниклар буламы инде ул, Бакый абзый?

— Әйе, художниклар була. Минә шуларның арада бер талантлылары усаллык белән алдырмаган, дустым, бәлки миһербанлы бәндә булып, азмы-күпме хыялый булып, йөзәр ел, меңәр ел яшәрдәй картиналар язып калдырган. Усал кеше гадәттә комсыз холкына буйсынып яши бит ул. Бүтәннәрдән көнләшеп, алар тапкан малны күпсенеп яши, хөсетлек галәмәтеннән арына алмыйча, гомеркәен әрәм итә, зыяга уздыра.

Рәҗип үзе дә тыңлар өчен генә түгел, сөйләр өчен яратылган зат иде, түзеп тора алмады:

— Көнчелек бар инде ул, баенда да, ярлысында да,— дип үз фикерен кыстырды.

Хуҗабикәгә олы кешенең сүзен белдерү ошамаса да, улына каты бәрелмәде:

— Рәҗип, улым, без бер дә синең белән кунакны кыстый белмибез бит әле. Ашап-эчеп утыр әле, Бакый абзый. Минә балыннан җитеш, вареньесеннән. Үзем кайнаткан идем, җир җиләге бик уңды быел.

— Котырып уңды, диген, әнкәй.

— Рәхмәт, һәммәсе дә бик тәмле, бик тансык. Мин болай сыйланырмын дип уйламаган идем әле. Авыл беткәндер, дип курыккан идем. Бик хәлле яшисез икән, тормышыгызны күреп сөендем, Газизә, сөендем.

— Алланың биргәненә мең шөкер, ипекәйгә тиендек шикелле. Өс-башыбыз да бөтен. Дөньялар гына имин була күрсен инде, бар өметебез шуннан тора.

— Һи-и-и, әнкәй! Безнең илгә каршы кайсы чыга алсын! Атом белән бах-бах бит без аны.

— Син, Рәҗипҗан, алай зурдан купма, дустым. Атом бит ул түгәрәк, теге якка да чәчелә, бу якка да. Әниең дөрес әйтә, бик дөрес. Имин яшәүгә ни җитә.

Кунакның әлеге сүзләре хуҗабикәнең күңеленә бик хуш килде, күрәсең. Әллә кайда яткан бер төргәк фотоларын тартып чыгарды, берәм-берәм күрсәтә-аңлата башлады.

— Менә син күр әле безнең хәлләрне, минем улларымны, кызларымны. Менә монысы туйда төшкәне, төпчегемнең туенда.

— Кая, кая, карыйм әле авылдашларым туйны ничек уздырганны. Әллә биисең дәме, сеңелкәш?

— Әнкәй барын да булдыра ул: җырлый да, бии дә, һәммәбезне уздыра, осталыгы яман зур.

— Осталык дип инде... Туйда тукмак та бии, диләр бит. Киленнәрем бик кыстагач, биеми булдыра алмадым. Хәзер менә шуңа карыймын да сокланып туя алмыймын.

— Сокланырлык икән шул, сокланырлык.

— Киленнәрнең мине яратканын шунда беллем: бишесе дә миңа караган.

— Күршенең әйбәтлеге үзеңнән, диләр бугай?

— Мужыт, үзеңнән дә чыга торгандыр күршеләрнең яхшылыгы. Үземнең кайнанам да асыл кеше иде, үз анаң да андый ук була алмас. Аллага шөкер, инде хәзер киленнәрем. Бишесе дә тәүфыйклы, бишесе дә инсафлы. Тик менә шәһәрдә яшәүләре генә...

— Барысы да шәһәрдәмени?

— Барысы да. Авыл куанмады инде безнең балаларга, куандыра алмадылар. Үземдә булды ялгыш: укытырга тырыштым үзләрен. Укыйбыз, дип китәләр дә баралар. Укып кеше булалар да шул шәһәрдә төпләнеп калалар...

— Үзеңә дә күңелсездер инде авылда?

— Ямансуларга алай вакыт тими шикелле. Өйләгә хәтле ясин укыйм, өйләдән соң гәҗит укыйм, кичен телевизор карыйм. Шунсыз тәмле аш та ашый алмыйм. Эшлә, дигәннәрен генә ишетмим. Югыйсә колак ишетә үзе...

— Әнкәй, никтер синең эшсез утырганыңны күргән юк бит минем. Гел аяк өстендә, гел йөрисең, гомердә тынгы белмисең. Бакча да синең өстә, умарталар да...

— Йөрисең инде җилләмәтләнеп, шуннан җил тия. Үзең сизмисең инде югыйсә, картлык сизә, шуннан — температура...

— Әнкәй, син бит температура булганда да тик кенә утыра алмыйсың. Йә берәр кул эшенә тотынасың, оек-мазар бәйлисең, йә инде укып ятасың.

Хуҗабикәнең болай да мөлаем йөзләре тәмам балкып-нурланып китте.

— Китап яраттым гомеремә. Укыйм-укыйм да кызыгып куям, аптырашта калам: каян белеп язганнар мин белгәннәрне, димен...

Табын янынннан кузгалгач та, Рәҗип кунагына яңа буаны күрсәтергә ниятләде. Әле күреп өлгермәгән икән. Әйбәт булды: Рәҗипкә ничек итеп механизаторларның бульдозерлар белән туфрак өйгәннәрен дә,

Антоновка ягындагы чишмәләрдән хасил булган Ылгаманың суы күзгә күренеп артканын да, колхоз идарәсенең әлеге буада карп балыгы үрчетергә карар чыгарганын да, рәиснең карп маймычларын үз машинасына салып кайтарганын да, аларны буага җибәргәндә Рәҗипне чакыртып алганын да, шуннан боларның әлеге маймычларны суга икәүләшеп җибәргәннәрен дә, ничәмә-ничә капчык фуражга дигән ашлыкны китереп суга бушатканнарын да, тагын әллә нинди хикмәтләрне дә бере арты берен тезде генә.

— Озын койрыклы, бәп-бәләкәй маймычларны беренче күрүем иде. Ышана гына алмыйм бит, Бакый абзыкай. Әллә балык чыга аннан, әллә елан — каян беләсең?! Балыкның да нинди буласын алай ашыгып әйтә алмыйсың бит әле!

— Шула-а-ай, дустым, шула-а-ай.

— Ике-өч айдан соң, кармакка тоткач кына, аларның чынлап та карп икәненә ышандым. Тегенди-мондый гына түгел, Бакый абзыкаем, зеркальный карп! Беләк буе балыкларны буадан сосам гына!

Рәҗипнең балыкка йөри башлавына әллә ни күп түгел, кармагына эләккән тәңкәсез карплар аннан да азрак иде. Әмма ул һөнәрнең үзен юньләп үзләштергәнче үк, балыкчы хикмәтләрен сөйләп кешеләрне дә шаклар катырырга өйрәнеп җиткән иде инде. Хәзер дә кунакның йотлыгып тыңлаганын күреп, чама дигән нәрсәне бөтенләй истән үк чыгарып җибәрде:

— Хәзер анда бишәр килолы зеркальный карплар йөзеп йөри. Кичә генә икене эләктердем. Берсе биш килограмм килде, икенчесе...— Бер исәп белән «өч» дияргә дә әзер иде инде, тик олы кунакның күзендә бертөрле дә шикләнү-мазар сизмәгәч, алай вакланып тормаска булды, беткән баш — беткән дигәндәй, тәвәккәлләп: — Икенчесе — җиде! — дип ычкындырды, шуннан инде үзенә дә уңайсыз булып куйды.

Олы кунак исә аны-моны абайламады:

— Һе, кара син аны! — диюдән узмады.

Рәҗип гаптәшенең балыкчы булмавына, мәгънәсез ялганы өчен битен кызартмавына сөенеп бетә алмады. Ә инде кунагы:

— Дустым, әгәр дә мин Рәҗип-егет буасында коенып алырга ниятләсәм,— дигәнне ишеткәч, тәмам тынычланды.

— Юк, мин коенмаска булдым әле бүген. Лутче мин махра көйрәтәм. Дөньяда бер авыл тәмәкесе, Бакый абзыкаем, самосад! Ә син коен, кәнишне, буаның суы йомшак аның, коенулары бик тә рәхәт. Җитмәсә, үзе тагын җылы була, һәрвакыт җылы.

Яшь дустының соңгы сүзләрен рәссам инде су эчендә тыңлады. Чынлап та җылы икәнлегенә ышангач, эчкәрәк керде, тәвәккәлләп йөзеп китте. Су чынлап та саф, чишмә суыннан бер дә ким түгел, шактый киң мәйданда тармакланып киткән аксыл-яшел махсус үлән мул булып үсеп утыра иде.

Яр буенда рәссамны шау-гөр килеп Рәҗип каршылады:

— Йә, Бакый абзыкаем, суы ошадымы, күңелең булдымы?

— Күңелләрем иллә дә хушланып китте, дустым. Суы чын мәгънәсендә ару-пакъ икән ләбаса. Авылга кайтып яшәсәм әгәр, ходайның һәр бирмеш көнендә ике-өч мәртәбә коенып идем.

— Кайт соң! Йорт салып җибәрерсең, терлек асрарсың.

— Мал-туар асрарга анысы, дустым, безнең авылдан да иплерәк җир, гомумән, юктыр.

— Шулай анысы, кругом печән. Сугыш вакытында да сөрмәгәннәр иде печәнлекләрне, әле хәзер дә сөрмиләр.

— Нәрсә, Рәҗипҗан, Ылгама буе Иске Антонга чаклы шул көе, сөрелмичә калдымыни?

— Антонга шае, чокырның ике ягын да сөрмәделәр. Әле Антонга җитәрәк отыры киңәеп китә печәнлек. Антон урманы тирәсе дә шул көе, Әрбәлек ермаклары да исән...

Борын-борыннан килгән чокыр-чакыр исемнәрен яшь кеше авызыннан ишеткәч, аксакалның җаннарына рәхәт булып китте. Һәм ул моннан ярты гасыр элек үзенең теленә-лексиконына кергән исемнәрне берәмберәм тезә башлады:

— Бибиҗамал чокырын моннан ук күрәм, дустым, чынлап та нәкъ электәгечә калган икән. Ә менә Әрбәлек ермаклары, Чүп елгасы, Каратун ермаклары, Түгәрәк чирәм, Тирән чокыр, Изгеләр зираты буйлары, Хөсәен тавы, Кутыр бакчасы, Казенный урман, ике Салтык арасындагы Изгеләр зираты да шушылай сакландымыни?

Рәҗипнең авызы ерылганнан-ерыла барды, башын чайкап алды.

— Ну хәтер дә икән үзеңдә, Бакый абзыкаем! Үзең дә беләсең икән бит! Гел авылда яшәгән кебек...

— Син, Рәҗипҗан, минем хәтергә мәдхия укыдың, анысы өчен рәхмәт, чыны шулай, һич зарланмыйм, Ходайның биргәненә мең шөкер. Әмма ләкин син бит, дустым, сорауга җавап бирмәдең. Сөрделәрме Түгәрәк чирәмне, Әрбәлек ермакларын, әллә искечә калдырдылармы?

Рәҗип башын кага-кага җавап бирде, олы кунакның җитдиләнеп китүен дә сизмәде-абайламады, үзе исә һәмишә елмаюдан туктамады:

— Берсен дә сөрмиләр, Бакый абзыкаем, һәммәкиен искечә саклыйлар. Шуңа авылыбыз тирәсендә гөрләп печән үсә. Миңа гына ышанмасаң, барып карый алабыз.

— Һичшиксез барып күрербез, дустым.— Аксакал, озаклап нотык сөйләргә җыенгандай, тамак кырып куйды.— Сабый чакта уйнап үскән, мәтрүшкә җыйган, җир җиләге, кура җиләге җыйган җирләрне күрмичә китәсем юк. Әлбәттә, барырбыз, дустым. Әгәр син вакыт тапсаң, бергәбергә йөри алсак, мин бигрәкләр мәмнүн-разый булыр идем.

— Бәлки, берәр төрле рәсем дә ясарсың әле?

Урманченың күңеле булды, һәм ул үзе гомерен багышлаган һөнәре турында бәләкәй генә булса да лекция укып алу форсатын ычкындырмады:

— Менә этюдниклар-мазар алып кайтмадым анысы. Шундый кимчелегем булды, аны яшерүдән файда юк. Авылга кайтуым бит әле, гомумән, разведка боем шикеллерәк килеп чыкты. Син солдат кеше, беләсеңдер аның нинди нәрсә икәнен.

— Беләм, Бакый абзыкаем, аңладым. Син инде беренче кайтуыңда, кайда нәрсә бар дип, разведка гына ясамакчысың, әйеме?

— Дөре-е-ес! Әмма шулай да биштәремә өр-яңа бер альбом салырга зиһенем җитте. Хәзер инде мин бик рәхәтләнеп этюдлар сызгалый алам, шул ук вакытта һәммә нәрсәнең төсен дә карандаш белән генә язып куям. Анысы аның искә төшерү өчен генә, дустым. Болай үземдә рәссам күзе белән бер күреп алган нәрсәне һич онытү гадәте юк югын.

Рәҗип үзенең хәйран калуын белдереп башын кагып алды:

— Хәтер әйбәт синең, Бакый абзыкаем. Миндә генә ул иләк шикелле.

— Менә шул, дустым Рәҗипҗан. Кохинор дигән йомшак карандаш белән генә авылыбызның кайбер күренешләрен рәсемгә төшерәм дә һәркайсының нинди төстә икәнлеген шунда ук теркәп куям. Ә инде остаханәмә кайткач, әлеге рәсемнәрнең эскизларын ясыйм. Ягъни буяу белән күчереп чыгам, боерган булса. Карандаш белән ясаган этюдларымнан беркем берни аңламаса, һич югы акварель белән күчергәч, аның инде төсләре табигый хәленә кайта, үз төсен ала. Шунда инде һәммә нәрсә үзенең урынына кереп утыра, ышандыру көченә ия була. Фәкать ныклы әзерләгән күргәннән соң гына, дистәләгән вариант эскиз ясаганнан соң гына, һәр детален төрле яктан уйлап тәгаенләгәч кенә, картинаның үзен язарга утырасың. Анда да әле зурайтып картина язган чагында күп нәрсә үзгәрә. Безнең Салтыкка багышлап зур картина язмыйча ярамас, дустым.

— Синең бер генә рәсемеңне дә күргән кеше түгел бит мин. Ничек ясаганыңны карап торасыларым килә.

— Сабырың җитсә, торырсың, Аллаһы бирсә. Иртәгә иртүк сәфәр чыгарбыз, иң матур, иң күркәм җирләрне, авылыбызга, әйләнә-тирәгә ямь биреп торган җирләрне рәсемгә төшерү өчен бергәләшеп сайларбыз.

— Помхудожник буласыларым бар икән әле иртәгә! Сугыш вакытында абзаң болай помбригадир булган кеше. Җамали бабай бригадир иде, картайган иде инде, бик нык картайган иде, җиңел арба-двуколкага утырып кына чыга иде басуга да. Ә мин — җиңел. Теләсә кая чабам. Шулчакта бит үземә Куян дигән кушамат тактылар, куян шикелле җәһәт йөгергәнгә. Авылдашларың яратып әйткәч, үпкәли дә алмыйсың бит әле, шунысы мәзәк.

— Бер дә үпкәләрлек яки рәнҗерлек исем түгел ул, дустым. Авылдашлар үзеңне чынлап та яраталар икән шул. Мине менә бик үк яратып бетермичә, үзебезнең рәссам халкы Урванче дип йөртә...

Ул көнне алар якындагы Бибиҗамал чокырына сугылып, тагын бераз арырак Әрбәлек ермакларына гына барып кайтырга өлгерделәр.

Әмма икенче көнне, кояш чыгу белән, икәүләшеп Олы Салтык ягын урап кайтырга ниятләделәр. Хәйран тамаша инде: Тирән чокыр да, Чүп елгасы да, Каратун ермаклары да, Түгәрәк чирәм дә, Изгеләр зираты да, бүтәннәре дә — һәммәсе бер-беренә тартымрак, елга-ерганаклы, шаулап печән үсә торган, аз-маз куаклы, искиткеч ямьле, оҗмахтай урыннар инде югыйсә. Әмма шуларның һәркайсында фәкать аңарда гына очрый торган, үзенә бер мәгънә, үзенә бер гүзәллек бар бит, әй! Берсендә, әйтик, үләне кыска гына булып үсә дә, тора-бара бөтенләй келәмгә әйләнә. Икенчесендә бер дигән җир җиләге, өченчесендә кура җиләге, дүртенчесендә мәтрүшкә үсә... Чия һәм алма бакчалары да бар. Алардан бөтен әйләнә-тирә файдалана.

Әнә тагын бер уем болын. Анысы тегеләренә караганда бераз киңрәк сыман. һәрхәлдә, күрер күзгә килбәтлерәк тоела.

Шушы ерганакларны яңадан күрү Габделбакыйны гүя сабый чакларына очыртып кына алып кайтты. Мәхдүм буларак яланаяк йөрмәсә дә, әлеге ерганаклардагы чирәмен дә, печәнен дә аз таптамады. Ай үсәсен көн үскән баһадирдай, нык гәүдәле малай кече яшьтән әлеге елга-ерынтыда киерелеп печән чапты, аны киптереп, бергә җыеп, кибән куйды...

Балаларының әдәпле вә инсафлы, укымышлы вә уңган булып, оста гына, матур канат җилпүләрен әти-әнисе икәве дә күреп-инанып өлгерәләр. Әмма тугыз бала билгән Мәһзүбә остабикә әлләни озын гомерле булмый шул. Аның вафатыннан соң Идрис хәзрәт өчен дөньяның бернинди яме калмый. Өстәвенә...

Өстәвенә авыл Советы рәисе бермәлне, ахшамнан соң, өенә сугыла. Баллап чәй эчәләр, озаклап сөйләшеп утыралар. Юньле кеше иде авыл Советы рәисе. Хәзрәтне бик тә хөрмәт итә иде. Йөрәге әрнеп килгән икән. Бер дә тел яшермичә, дөньяларның үзгәреп китүен — дин тотуга чик куярга, диндар затларга каршы рәхимсез яу башларга өстән әмер килгәнен чишә. Балаларының иминлеген саклау намена, яшьләрнең киләчәге бәрабәренә муллалыктан ваз кичәргә киңәш итә. Рәиснең дустанә киңәшен тотып, указлы мулла үзенең мәхәлләсе белән бәхилләшә-елаша да калага күченә.

Әмма балалары үз янында икәнлеккә шөкерана кылып кына яшәгәндә... Имин генә яшәү насыйп булмады: газизләрен бинахак рәнҗеттеләр, гаиләне урамга куып чыгардылар... Егерменче елларда ук, гомумән, дингә мөнәсәбәт үзгәрүне, ягъни гаделсезлек-инсафсызлыкны күргән, бергә-бергә тату гына гомер кичергән бердәнбер сөекле карчыгын, җеназалар укып, гүргә иңдергән шәхес өченче афәтне күтәрә алмады, бичаракай... Сагыш кына җитте аның башына, сагыш кына...

Салтыкның биниһая матурлыгын чагылдыру бер вазифа булса, әтиәнисенә рухи һәйкәл булдыру — һөнәр иясенең иңнәренә төшә торган

икенче вазифа. Бик күп эшләрне бүтәннәргә сылап-сылтап булса да, монысын башкарып чыгу — сәнгатькәрнең изге бурычы. Хәер, ул бурычны башка беркем дә туган-үскән якларның илаһи гүзәллегенә тиң иттереп, Идрис муллаларның галимиятенә вә уңганлыгына тиң иттереп башкара да алмаячак бит әле.

Димәк ки рухи һәйкәл?! Моңа сәнгатькәр үзенең вакытын да, тәҗрибәсен-осталыгын да, һөнәрмән буларак кодрәтен дә кызганмас. Әлегә сюжеты уйланмаган. Ихтимал, әтиләренең табигать кочагында бәрәкәтле хезмәт белән мавыккан чаклары булыр... Әллә бәлкем, әтиләреннән башка гына, шушы кабатланмас гүзәл табигатьтәге илаһи бер мизгелне алыр?

Юлдашының уйланып-тынып калуын күреп, Рәҗип аның алдына чыгып:

— Никтер дәшмәс булдың әле, Бакый абзыкаем? — дип үзенең канәгатьсезлеген белдерде.

Рәссамның ай шикелле түгәрәк йөзе балкып китте:

— Бу инде иҗат мизгелләре якынлашу билгесе, дустым! Сөйләшкәндә һәйбәт гәптәш булу бераүгә дә, хәтта әле рәссамга да тыелмый. Тик инде һөнәрмән эшкә тотынды исә, ул, дөньясын онытып, һәммә нәрсәдән ваз кичеп, дәрвиш хәленә төшеп, үзенең бөтен игътибарын, куәт вә кодрәтен объектка, ягъни табигатьтәге берәр күренешкә, портретын язарга алынган кешегә тулаем юнәлдерергә тиеш. Сүз арасында гына эшләгәндәй кыланып бераүнең дә юньле нәрсә майтара алганы юк әле. Иҗат ул, Рәҗипҗан, синең бөтен барлыгыңны даулый.

— Һе, альбомыңны алып, рәсем ясарга тотынсаң әгәр, мин аңлар да идем. Син бит әлегә берни ясамыйсың. Без бит үзебезнең авыл янындагы елга-ерынтыны, овраг-мазарны гына карап йөрибез ләбаса. Хәзергә сөйләшергә дә ярыйдыр, дииюем.

Бу юлы инде сәнгатькәр елмаю белән генә чикләнмәде, кеткелдәп алды:

— Ул бит, дустым Рәҗипҗан, болай була. Иҗат рәссам кулына кыл-каләмен, карандашын алгач кына башланмый. Иҗат процессы әнә шул рәсем ясауга керешкәнче үк башлана. Бүген ясалачак рәсем бит, Рәҗипҗан, без икәүләшеп сәфәр чыккач ук башланды. Юк, буа буендагы сөйләшүдән үк башланды. Алай гына да түгел, монда килү нияте белән без фәкыйрегезнең пароходка аяк баскан минутыннан ук, нәкъ әнә шушы минутта башланды.

— Аңлыйм, Бакый абзыкаем, бик аңлыйм. Шулай да син берсәк булса да сөйләшергә тырыш инде. Югыйсә миңа күңелсез булыр. Бигрәк тә син рәсем ясамаганда. Рәсем ясарга тотынгач, анда инде сүз дә юк...

— Һәй, дустым! Синең бимазалавыңнан гына торса икән эшнең уңышы! Кайчагында япа-ялгыз каласың, тырышасың-интегәсең, әмма юньле нәрсә яза алмыйсың гына бит, дустым.

Рәҗип нинди генә сүзчән булмасын, рәссам эшкә тотынган саен, аның янына аякларын бөкләп утыра да, авызына су капкан шикелле, һичбер төрле сүз әйтми түзеп тора алды. Хәер, алай дип әйтү дөрес үк түгелдер, бәлкем. Чөнки аксакалның сары карандаш тоткан уң кулының ак кәгазь өстеннән йөрүе олуг бер могҗиза тудыра башлады һәм моны күреп торуы үзе бер рәхәт иде. Мондый чакны юлдашы үзе сүз кушып караса да, мөгаен, Рәҗип аңа акыллы-юньле җавап кайтара алмас иде. Һәрхәлдә, соңгы вакытта үзенең шулчаклы да мөкиббән киткәнен хәтерләми. Балык тотып утырганда да болай ук булмагандыр. Анда ул башын уңга да, сулга да боргалый торган иде. Монда бит рәссамның кәрәктәй кулына текәлде дә катты, һичбер кая күзен ала алмый.

Менә рәссам кәгазьнең буеннан-буена, бераз кыйгачлабрак кәкребөкре сызыклар сызгалады да шуның як-ягына нindидер төрткеләр төртте, хикмәтле кыяклар тезде, түгәрәкләр ясады, бер ягын ачыграк

калдырып, икенче ягын исә нығытып буяды — һәм нәтиҗәдә Рәҗипнең күз алдында Чүп елгасы килде дә чыкты.

Хикмәти хода! Ничек алай булдыра икән соң, ә? Рәҗип үзе дә төшеп калганнардан түгел: агачтанмы, калай-мазарданмы, теләсәнәрсәне әмәлли; һәрхәлдә, йорт-җир тирәсендәге вак-төяк ремонтны, каралты-кура ише нәрсәләрнең бөтенлеген саклауны кече яшьтән үз кулында тота. Сугыш вакытында ат җигә торган чананы үзе җигелерлек иттереп ясап бирүне дә күршедән сорамады, үз кулы белән башкарып чыкты. Анысы шулай, кулга тотарлык әйбер булганда, эшлисең аны, берни тормый. Тик инде кулына карандаш алып кына Рәҗип берни майтара алмас иде...

Уйларына мавыгып китеп, сәнгатькәрнең ермак башланган җиргә кай арада биш-алты куак «утыртып» куйганын абайламыйчарак калды. Һәйбәтләбрәк карагач:

— Бакый абзый, боларны каян алдың? Юк ич болары, әнә үзең кара! — дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

— Боларымы? Болары аның сәнгатьтә гармонияне күрсәтү ниятеннән чыгып өстәлде, дустым.

— Ниткән гармония ди инде ул болында гүпчем юк нәрсәләрне китереп тутыргач?!

— Син кызма әле, Рәҗипҗан, кызма. Хикмәт менә бит нәрсәдә. Сабыр итеп тыңласана, дустым.

— Тыңлавын тыңлыйбыз, анысы артык авыр эш түгел.

Рәссам альбомы белән карандашын чирәмгә куйды, ныклап бер тамак кырып алды да, тубал чаклы башын мәгърур тоткан хәлдә, үз һөнәренең гап-гади бер хикмәтен тәфсилләп, иркенләп сөйләргә керешге:

— Болай бит ул, Рәҗипҗан. Бер үк нәрсәне төрле кеше төрлечә, дөресрәге, һәркем үзенчә күрә. Менә бу ерганакны, әйтик, синең белән без икебез ике төрле итеп күрәбез. Әле менә шушы, үзебез җәелеп утырган чирәмнең төсе дә икебезгә ике төрле булып күренә. Син крәстиән егете, чирәмнең син кыягын, сусыллыгын, муллыгын, ягъни сыерга кышлык азык буласы ягын күрәсең. Ә минем ише зимагурга бит ул, дустым, куе яшелгә зәңгәр-сары-кызыл бизәкләр төшкән келәм генә булып күренә. Үзгәчәрәк итеп әйткәндә, чирәмнең сурәте, образы һәркайсыбызга үзенчә тәэсир итә, йогынты ясый. Сиңа ул, ихтимал, Сабан туендагы мажаралар урыны яки инде берәр нечкәбилне әүмәкләгән урын булып күренәдер...

— Кая инде безгә, каткан тезгә!

Аксакал аңа кырыс кына карап алды.

— Син, Рәҗипҗан, сабыррак бул, мине бүтән бүлдермә. Һәрберебез егет булган, кызлар кочкан. Әмма ләкин хикмәт анда түгел. Хикмәт менә бит нәрсәдә, дустым: Салтык тирәсендәге болыннар, мондагы ерганаклар минем хәтергә әткәй белән печән чапкан урын булып мәңгелеккә сеңеп калган. Тагын әле яшьти малайлар белән бергә-бергә төнгелеккә ат сакларга чыгуларны искә төшерә...

Урманченың тагын ачуын китермәгәем, дип, Рәҗип ике-өч минут сүз кушмыйча түзеп утырды. Кунакның сөйләүдән туктаганына тәмам инанганнан соң гына, күңелен кытыклап торган сүзләрен әйтергә тәвәккәлләде:

— Печән чабарга мин дә йөрдем анысы. Тик менә ат сакларга йөри алмадым: сугыш вакытында колхозның атлары күтәрәмгә калды.

Әллә ишетте аксакал аның сүзләрен, әллә истәлекләренә чумган булып, бөтенләй ишетми калды, фәкать ак та димәде, кара да димәде. Бервакыт тынып торганнан соң гына үзенең һөнәренә кагылышлы мәгълүмат бирүен дәвам иттерде:

— Мәсьәләнең икенче ягы да бар бит әле, дустым. Без бит Ходайның һәр бирмеш көнендә күзебезгә чалына торган нәрсәләргә илтифат итмибез. Табигатьнең нинди генә гүзәл почмагына тап булсак та, әүвәл сәерсенәбез, гаҗәпләнәбез, тик инде ул халәтебез әллә ни озакка бармый.

Кызганыч, дустым, ләкин дөреслектән качу һич мөмкин түгел: без бит әле менә шушы оҗмахтан да туябыз, шушы илаһи матурлыкка да әлләни исебез китми.

— Син бераз шыттырыбрак җибәрәсең лә, Бакый абзыкаем. Туган яктан туеп була димени?!

— Бер дә арттырмыйм, дустым, һич юк. Син менә, авыр булса да, ачы хакыйкатьне аңларга тырыш. Әгәр дә мәгәр табигатьнең үзендәге шушы илаһи күренештән йөз чөерә икән адәм баласы, ул инде синең әнә шул күренешне түкми-чәчми генә киндергә күчереп куйган картинаңа әйләнеп тә карамаячак. Шулай, дустым, һич тә бүтәнчә түгел. Чөнки теләсә нинди күренешне яки сурәтне дөп-дөрес итеп кабатлаучы фотография һөнәре яшәп килә. Безнең агай-эне арасында да нәкъ әнә шундый төгәллеккә омтылучылар бар, дустым, дөнья һич тә инде кысыр түгел. Андый рәссамнарны мин үзем фотографлар дип атыйм. Гарьлек бит, билләһи газим! Ходай тәгалә үзләренә азмы-күпме сәләт биргән. Шуны үстерәсе урынга, алар кечтеки генә уңышка ирешәләр дә, үз-үзләреннән канәгать калып, шуңа тәмам инде мөкиббән китәләр.

— Урыслар, довольны донельзя, диләр андый чакта.

— Әйе, Рәҗипҗан, нәкъ шулай диләр. Дөре-е-ес! Минем кыйблам менә нидән гыйбарәт. Әгәр Ходай тәгалә сиңа бүтәннәрдә юк һөнәрне, сәләтне биргән икән, син инде, дустым, аның кадерен бел. Табигатьнең үзен дә, синнән элегрәк яшәгән һөнәрмәннәрне дә кабатлама, үз йөзеңне, үз почеркыңны булдырырга тырыш, бөтен көчеңне куй. Шунда буларсың иҗатчы.

— Аргы яр башына куаклар утыртып куюың шуннан киләме?

— Дөре-е-ес, дустым, шуннан килә. Синең белән без менә хәзер күреп-күзәтеп утырган күренеш артык гүзәл, артык табигый, артык камил. Аны киндердә гәүдәләндергән хәлдә, һичшиксез, берәр чатаклык өстәү зарур. Фәкать шул чагында гына тамашачы иң әүвәл мин үземнән өстәгән әлеге элементны күреп алачак. Аны күрми калу мөмкин түгел, бу деталь һәркемнең күзенә ташланачак, чөнки ул диспропорция китереп чыгара, ягъни күз ияләшкән гадилекне үзгәртеп җибәрә. Шушы чатаклыкны күреп, уйланырга мәҗбүр булачак. Фәкать шуннан соң гына тамашачы картинадагы башка детальләрне абайлап, аларына да игътибар итәчәк. Ә инде игътибар белән караганнан соң картинаның камиллеген аңлаячак, бөтен бер гармонияне шәйләячәк.

— Нәстә, синең иҗат дигәнең шул буламыни инде?

— Дөп-дөрес, дустым! Сәнгатькәрнең картина язуга иҗади килүе нәкъ әнә шуннан гыйбарәт. Хыялга бай булган рәссаммы, язучымы, композиторлы, чынбарлыктагы хәлләрне үзгәртеп, тагын да камилләштереп күрсәтергә сәләтле. Әсәр язуга иҗади килгән сәнгатькәр генә кешеләргә чын-чынлап куаныч-сөенеч китерә ала.

Бу сүзләрне яшь дустына сөйләгәндә, сәнгатькәр әле үзенең «Салтык болыны» дигән эскиз язып, ничәмә-ничә ел буена шуннан аерыла алмаячагын да, тора-бара аны зур бер киндергә күчереп, олуг юбилее хөрмәтенә оешкан күргәзмәсендә, Татарстанның Сәнгать музеена тантанага җыелган барча зыялыны да хәйран калдырасын һич тә башына китерә алмагандыр...

«Салтык болыны» картинасының язмышы «Кул-Черкен» әсәренекеннән бәхетлерәк булды. Әүвәлге эскизында ук сюжетны оста кору бәхетенә ирешкәч, сәнгатькәр инде аны һич үзгәртмәде, фәкать динамиканы гына көчәйтергә, ягъни хәрәкәтне аермачык күрсәтергә тырышты. Ә хәрәкәт-җанлылык бар монда, бар...

Таза-таза ирләр хуш исле ямь-яшел печәнне киерелеп-киерелеп чабалар; бәйрәмчә киенгән зифа буйлы, сылу вә уңган кызлар ул чабылган печәнне киптерү белән мәшгульләр; яшь егетләр исә ул печәнне өемнәргә

тарттыралар; олырак агайлар кибеп өлгергән печәнне кибәнгә үк өеп яталар... Кая гына карасаң да — хезмәт гөрли, картина тулаем хезмәткә хөрмәт вә мәдхия буларак кабул ителә. Ә инде хәрәкәтне бу дәрәҗәдә оста бирү сәнгатькәрнең дәрәҗәсен гаять югары күтәрә.

Бирeдә автор төсләрнең контрастлыгын отышлы файдалана. Бу бигрәк тә болынга сибелеп үскән чәчәкләрдә һәм сылу кызларның алъяпкыч бизәкләрендә нык чагыла. Мәгәр әлеге төсләр әлләни күзгә бәрелми дә сыман, алар үзара ныклы бәйләнештә, бер-берен тулыландырып торалар һәм хәйран матур, моңлы гына симфония китереп чыгаралар. Һәммә нәрсә кояш нурларында коена. Таза беләкле агайлар да гүя кояш нурларын — юк, печән генә түгел, кояш нурларын! — бергә җыеп, кибәнгә өяләр. Яңа чапкан, аяз көндә кибеп өлгергән печәннең хуш исе ерактан ук сизелә...

Картина язган чагында камиллеккә ирешү — алай ансат кына, ордымбәрдем генә эшләп ташлый торган нәрсә түгел, иҗади эзләнүләр белән көн-төн газаплануны сорый, вакыт һәм сабырлык даулый. Тоташы белән алтынсу гаммада язылa торган әсәрдә дә бит әле якын, алгы пландагы бизәкләрне ачыграк, ерактагыларын тоныграк чыгарасы, шул ук вакытта перспективаны да чагылдырасы бар; тырма тоткан кызларны зифа буйлы, ыспай киемле, күркәм йөзле иттерәсе, уңганлыкларына басым ясыйсы бар — аларның нәфислегенә печән чабучы, кипкәнен олау белән ташучы һәм кибән куючы ир-ат, әлбәттә, кызыгырлык, дәртләнеп-гайрәтләнеп эшләрлек чибәр итеп тасвирлыйсы бар. Ә соң аларның буйсыннары зифалыгын, йөзләре гүзәллеген бирү белән бергә, һәркайсын эштә-хәрәкәттә ничегрәк гәүдәләндерәсе икән? Ир-егетләрнең һәркайсын ниндирәк позада алып, бер-берен кабатламыйча, ни рәвешле сурәтлисе — хәрәкәтне ничек итеп бирәсе икән? Ниһаять, бөтен тасвирлаганыңны тамашачы кызыксынып карасын, ышансын, кабул итсен өчен янә дә ниләр эшлисе икән?

Боларның барчасын да картина язу дәверендә фәкать автор гына хәл итә ала, дөресрәге — аның гына хәленнән килә. Татлы иҗат газабын кичерә-кичерә, әлеге алтынсу гаммадагы киндерен тулаем башкарып чыгулары автор өчен, ай-һай ла, егерме-утыз олы-олы печән кибәне кую ише генә булды микән?! Ихтимал, күбрәк көч сарыф итүне сорагандыр, таләп иткәндер, ихтимал, бик ихтимал. Иҗат газабы дип юкка гына әйтмиләрдер...

Күтәренке рух белән яза сәнгатькәр әлеге әсәрен, үҗәтләнеп яза. Тыңлаучы булганда ара-тирә җырлап та җибәргәли:

Ике дә генәй егет печән чаба,
Үтәр-үтмәс аларның чалгысы...

— Әй, болай түгел икән бит әле! Менә болай,— дип, тамак кыргалап, көйне сизелер-сизелмәс кенә үзгәртеп, өр-яңадан сузып җибәрә:

Ике дә генәй егет печән чаба,
Үтәр-үтмәс аларның чалгысы.
Нигә генәй үтсен аларның чалгысы —
Башларында буй кызлар кайгысы.

— Нинди матур җыр бит, син кара әле менә... Вә музыкальлеге, вә шигъриләге! — дип соклануын белдерә дә башын чайкап аянычын әйтергә мәҗбүр була: — Җырламыйлар бит шушы гаҗәеп җырны, җырламыйлар...

Үзе аунап үскән болыннарны киндергә күчереп язган чагында аксакал үзенең хыялын пар ат итеп җигә дә әллә кайларга оча...

## III баб

### «Уралтау эргәсендә»

*«Табигатькә, чынбарлыкка аяк басу — искиткеч зур нәрсә. Менә бу кызның альяпкычына мин әллә нинди бизәкләр төшерә алыр идем, табигатькә тугрылыклы булу ирек бирми...»*

Бакый Урманче.
*1978 ел, 17 май*
*«Уралтау эргәсендә» картинасы янында.*

*«Менә бу инде яшел симфония! Иң салкын яшелләрдән башлап иң җылы яшелләргә кадәр».*

Бакый Урманче,
*1978 ел, 24 декабрь*
*«Уралтау эргәсендә» картинасына карата.*

Халкыбыз Габдулла Тукайның 90 еллык юбилеена әзерләнә. Әле моңарчы бер генә һәйкәлне дә Казанның үз уемчы-скульпторларына тапшырганнары булмый. «Тотса мәскәүләр якаң» дигән курку-өркү саен үзен сиздерә. Җөмһүриятебездән кырып-себереп алып бетергән милектән, янәсе, изгелек күрсәтеп, Мәскәү өлеш чыгара һәм шунда башкаланың булдыклы-өлгер егетләрен дә тага-сылый. Тукайның кем икәнен дә белмәгән скульптор-уемчыларга һәм архитекторларга җөмһүрият җитәкчеләре, мәдәният әһелләре бу юлы аяк терәп каршы тора, алардан баш тарта. Шактый озак дәгъвалашканнан соң, Тукайга Кырлайда һәйкәл салу вазифасы Урманчега йөкләнә.

Бөек шагыйрьнең образын моңарчы да сынлы сәнгатьтә гәүдәләндергәне булгач, Габделбакый Татарстан хөкүмәтенә яңа бер тәкъдим белән керә: һәйкәл — һәйкәл инде; Кырлайда берочтан шагыйрьнең музеен да бурдырырга кирәк, бөек шәхескә багышланган әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен шунда тупларга мөмкинлек туачак.

Музейның бинасына проектны Урманче үзебезнең милли стильгә яраклаштырып эшли: ике катлы бинаның тәрәзәләре мәйданга карап торырга, һәйкәл шуның алдына куелырга тиеш дип саный. Тулаем расланганнан соң да әле музей корыуда катнашкан төзүчеләр проектны җиренә җиткереп бетермиләр. Һәй гарьләнә, һәй борчыла Габделбакый! Сиксәнен тутырып килүче аксакал Кырлайдан бик сирәк кайта, бәрәр төрле хаҗәте чыкса гына. Казандагы төзү оешмаларының әле бер ишеген ача, әле икенчесен. Түрәләрне тинтерәтеп бетерә. Әгәр дә ул безнең кеше булса, Тукай исемен, урыс икән — Пушкин авторитетын калкан итә.

Музей белән генә дә чикләнми сәнгатькәр, әйләнә-тирәдә Шүрәле паркы булдыруга ирешә. Урманы-паркы шагыйрьнең үлмәс бер поэмасындагы персонаж исеме белән атала икән, аның инде үз шүрәлесе дә булмый калмас. «Урман сарыкларын», әлбәттә, агачтан ясарга ниятлиләр. Әлеге эшне оста үзенең шәкерте Дамирга ышанып тапшыра.

Зур-зур чатлы-япьле имәннәрне икәүләшеп сайлыйлар да, егеткәй аларны эшкәртергә керешә: кирәкле ботакларны гына калдырып, башкаларын кисә-кыскарта; аннары инде үзенең каһарманнарына мәзәк кыяфәт бирә. Әмма ничек кенә тырышып эшләмәсен, шәкерткә әләгә тора:

— Син, дустым, — ди аңа аксакал, — эшеңне җиренә җиткереп эшли торган бул. Театр рәссамнары шикелле әпен-төпен генә мәтәштермә.

— Бакый абый, әле моны чып-чын Шүрәле итәргә җае бар. Менә шушы ботагын болайгарак тарттырабыз да — япьле-чатлы кул хасил була.

— Ике кулын ике төрле итәргәмени исәбең?

— Ә нигә, Бакый абый, әкият каһарманы шундый булырга тиеш, аның ике кулы да нәкъ бер озынлыкта, бер-беренә охшаган булырга тиеш дигән закон юктыр ич? — дип, яшь рәссам ачык матур күзләрен хәйлә белән остазына төби.

— Һай, дустым, әллә мәйтәм, сынчы булып ялгыш иттеңме, үзеңнән бер дигән адвокат чыгар иде.

— Юк, Бакый абый, сынчы да үзе иҗат иткән әсәрне кирәк чагында яклый белергә тиеш, туган баласыдай якларга, аның камил икәнен исбатларга тиеш.

— Әйе, дустым, камиллеккә ирешкәнсең икән инде, үз әсәреңне син һичшиксез яклый да бел. Әмма синең Шүрәлең белән камиллекнең арасы чамасыз зур шул әле. Бу хәлендә Шүрәлеңә кул куя алмыйм.

Тарткалашып торудан файда юк, остаң кушкач, яңадан чокчынырга туры килә. Шәкерт һич иренми-нитми эшен дәвам иттерә.

Мемориал комплексын башкаруда иң кыены музей бинасын кору да, башкасы да булмый. Әлбәттә инде, Шүрәле паркы да сокланыч бер әкият кыяфәтенә керә: агачлар арасында иләмсез озын буйлы, шыксыз-мәзәк кыяфәтле, кәкре килбәтсез куллы «урман сарыклары» пәйда була.

Тик менә әзер һәйкәлне кою мәсьәләсе хәерсез бюрократия таутташына килеп терәлә. Әүвәл нәрсәдән коярга дип олуг бәхәс кубаралар. Материал сайлау хәл ителгәч исә, рөхсәт бирмичә интектерәләр. Ике-өч ай буена шул дәгъва сузылгач, юбилейга нибары атна-ун көн вакыт кала. Заводы, имештер риза, материал бар. Эшлисең бик килә икән, машинага утырып Кырлайга бар да кой Тукаеңны, беркем сиңа тоткарлык кылмый...

Менә шунда күрсәтә дә инде Күл-Черкен егете үзенең сәләтен, таутташ актара алуларын. Ярдәмгә уңган-булган ике-өч егетне алып, аксакал көн-төн эшли, ал-ял итүнең ни-нәрсә икәнен һич белми. Рәссам-түрәләр җыены авыз ерырга өлгерми калалар. Юбилей тантасына Казаннан, Мәскәүдән һәм бүтән шәһәрләрдән килүче кунакларны музей алдына чыгып утырган даһи шагыйрь үзенең каһарманнары белән бергә, үз мохитында каршылый. Әлеге эшләрне тулаем һәйбәт башкарып чыккан аксакалның егетлегенә, иҗади колачының киңлегенә һәркем соклана, таңга кала.

Бу хәл Урманченың 80 еллыгын олуг юбилей итеп үткәрүгә юлны ача. Әмма рәссамның шәхси күргәзмәсе зурдан булмый, Актерлар йортында гына уза. Халык шулай да аның әсәрләрен яратып кабул итә. Юбилей тантанасы һәм шәхси күргәзмәсеннән соң аксакал хәйран рухланып, бертөрле яшьлек дәрте белән иҗатын дәвам иттерә.

Юбилейлар, шулай итеп, шаулап уза узуын, әмма аксакалның шәкерте Дамир бик аяныч хәлдә кала. Хәләл көч куеп ясаган шүрәлеләре өчен остазы аңа үзе алган мул гонорарыннан 50 сум гына өлеш чыгара. Еларга да белми егетебез, көләргә дә.

— Нишләп алай бик аз? — дигәч, олпатлы карт сәнгатькәр күзен дә йоммый:

— Эшләгәнең байга булса, өйрәнгәнең үзеңә калыр, — ди.

— Мин бит айлар буе остаханәгездә балчык издем, шагыйрьнең сурәтен ясаштым, Шүрәле паркын башкарып чыктым...

— Син зур оста янында һөнәргә өйрәндең, дустым, һөнәргә. Шуңа сөен.

— Коры сөенү белән генә гаиләмне ничек туйдырыйм? Инде мин нишләргә тиеш хәзер?

— Күбрәк эшләргә тиеш, — дигән киңәш бирә оста, шуның белән бәхәскә чик куя.

Әлбәттә, шуннан соң Дамирның эзе суына. Аксакал күпме генә дәшмәсен-чакырмасын — килми, булышмый башлый...

Бу вакыйганы укыган укучыларда сискәнүле-аптыраулы тойгылар туарга да мөмкин. Әмма аларга чирканчык ала тору зыян итмәстер. Чөнки алга таба гаҗәеп олуг талант иясе Габделбакый Урманченың холык-табигатенә хас байтак сәерлекләрен дә күрергә туры килер әле.

Озак та узмый, Урманче янына заводтан вәкилләр килә, аның остаханәсе урынына тугыз катлы йорт салырга җыенуларын хәбәр итәләр һәм икенче бер җиргә күченүен үтенәләр. Аксакал карышып тормый, фәкать олысымак бер мәгърур кыяфәт белән:

— Мине, шәт, урамга куып чыгармыйсыздыр бит? — дип кенә кызыксына.

Вәкилләр берен-бере бүлдерә-бүлдерә:

— Юк-юк, Бакый абзый, ул турыда сүз булуы да мөмкин түгел, без сезгә зур хөрмәт белән карыйбыз, борчыган өчен гафу үтенәбез, сезне күчереп куярга әзербез,— диешәләр.

— Ху-у-уш! Инде каян бирмәкче буласыз миңа остаханәне?

— Яңа йортның аскы катын ошатырсыз микән?

— Кайсы урамда ул яңа йортыгыз? Трамвайдан еракмы? Әйдәгез, барып карыйк әле, кулай булырлыкмы ул урыныгыз?

Олы юлдан шактый эчкәре кертеп салынган йортка бара-бара хәлдән тайды карт сәнгатькәр. Гәрчә бина үзе бик ошаса да, башын чайкап:

— Һәй, бер егерме-утыз ел элгәрерәк булса мондый җәннәт! Ике дә уйламас идем, кереп оялар идем. Хәзер читенрәк шул минем хәлләр, үзегез күреп торасыз,— диде һәм кулындагы саллы таягын югары күтәреп: — Менә шушы таяк ирек бирми, шушы таякта бар хикмәт,— дип өстәде.

Әйе инде, аксакалның аксый-туксый килүен үз күзләре белән күрделәр, һич сүз әйтергә урын юк. Башка җирдән карарга туры килә, диештеләр.

Ике-өч көннән гомер буе иҗат иткән әсәрләрен барлап, инде ничәмәничә еллар аңа каталог төзеп йөрүче Назимны аксакал кочагын җәеп каршылады. Бу Назим дигәне шигырьләр язадырмы-юкмы, әмма Бакый карт аны шагыйрь дип таный иде. Ул:

— Бигрәк әйбәт булды әле килүең! — диде.— Күченәм бит мин, яңа остаханә бирделәр. Әллә кайларга трамвай белән интегеп йөрисе түгел, үзебезнең урам башында гына. Эш болай тора, дустым. Остаханәдәге әйберләрне күчерергә завод үзе машина бирә, кешеләр бирә. Тик алар артыннан мин бер башым ничек карап-күзәтеп өлгерим? Алар бит завод кешеләре, тимер-томыр белән эш итәргә күнегеп беткәннәр, сәнгать әсәрләренә дә мөнәсәбәтләре тупасрак булыр: сыннарыңны ватып-җимереп, киндерләреңне саксыз кыланып ертып бетерерләр. Син, дустым, шуңа күз-колак булырсың.

— Анысы ярар, Бакый ага, көн безнеке, хәлдән килгәнен эшләрбез. Тик менә кая күченәсез? Юньләбрәк әйтегез әле.

— Менә генә ич инде! Урам башындагы кибетне беләсеңме? Кергәнең бармы? Шуның каршысында мансардалы зур, иркен агач йорт. Анда балалар бакчасы булган. Шуны миңа бирәләр. Мансардасында эшләп утырырга ният. Аскы бүлмәләргә ясаган эшләремне элсәң, музей шикелле килеп чыгачак, Аллаһы боерган булса! Әйләнәсендә бакча, скульптура-сыннарны шунда куярга исәплим.

Хәзер үк, шушы минутта ук остаханә буласы ул бинаны барып күрәсе иттеләр.

Тәбәнәк кенә рәшәткә белән уратып алынган шактый зур мәйданда матур булып чирәм үсә, койма буйларында гөлҗимеш куаклары, бина үзе түрдә утыра — хәйран матур, сәнгать өчен корылган диярсең. Тик менә...

Сөмсере коелып кайткан Назимны күреп, аксакал хафага төште:

— Нәрсә, ошамадымыни, дустым? Бигрәк матур бит. Кәефеңә хуш килмәгән булуы ихтимал. Бакчасын күрдеңме син аның, чирәмле-гөл-

жимешле бакчасын? Скульптураларны куеп җибәрсәң, үзе бер күргәзмәгә әйләнәчәк.

— Күрдем, Бакый ага, бакчасын да күрдем, куак төпләрендәге шешәләрне дә, чүп-чарны да күрдем. Каршыда гына кибет, аракы алып эчәр өчен ипле урын, әйтәсе дә юк...

Назим туктап калды. Һай, сындырасы килми иде аксакалның рухын! Әмма күңелдәге шикне чишмичә дә ярамый. Картның күзен бүген ачтырырга кирәк, чөнки иртәгә соң булуы ихтимал.

— Нәрсә туктап калдың? Әйтеп бетер сүзеңне, дустым, егет бул. Күчерешергә вакытың юк икән, бер дә тартынып торма, күземә карап әйт.

— Юк, Бакый ага, хикмәт анда түгел. Сез дигәндә, вакыт белән исәпләшеп тормыйбыз инде анысы. Тик минә күңелемә шик-шөбһә килде. Ярый, сез анда сәнгать йорты, музей ясадыгыз, ди. Әлеге исерекләр бит эчеп кенә калмыйлар, тәмәке дә көйрәтәләр. Сезнең музеегызны, сәнгать йортын, җир йөзендәге бер оҗмахны көлгә әйләндерү өчен тәмәке төпчеге дә бик җиткән бит.

— Шулай дисеңме? Син инде шагыйрь кеше  бераз арттырыбрак җибәрәсең булыр. Нишләп ул исерекләр минем шикелле бер картның...

— Әүлия картның, дия аласыз, Бакый ага!

— Әйдә, синеңчә булсын, әүлия картның музеена төпчек ташларлар икән, ә?

— Бакый ага, алар аны ялгыш кына да төшереп калдыра алалар. Ә инде берәрсе яннарына килеп, ике шешә аракы да куйса, махсус та эшли алалар. Шул карунның, Урванченың сабагын укытыйк әле, дип лаф орулары да бар.

— Иман юк инде, кыйбла юк инде алкашларда, анысын, яшь кенә булсаң да, дөрес әйтәсең...

Кәефе кырылган чаклар еш булганга, аксакал аны йотарга, беркемгә сиздермәскә гадәтләнгән иде. Әмма бүген нигәдер тыелып кала алмады. Бу хәлнең сәбәбе әллә иртә таңнан куанып-канатланып торганда, Назимның, килеп, бөтен өметләрен актарып ташлавы булдымы, әллә инде әнә шул шигъри җанлы егетне якын күрү, аның самимилеген, фидакярлеген аңлау, ихлас әйткән сүзләренә колак салу сәбәпче булдымы — ничек булса булды, әмма аксакал ярыйсы ук дорфа гына:

— Син инде кешеләрнең гел яман якларын актарып чыгарырга яратасың. Дөньяга артык ачулы син. Минә миңа да «Карун» дип ычкындырдың. Үзең болай ипле генә күренәсең, тик инде бик тиз тәртәдән чыгып, йөгәнеңне ташлыйсың. Алай ук ярамый ул, кем мелла Назимҗан, син бит шагыйрь кеше...— дип әллә ниләр тезеп китте.

— Бакый ага, мин үземне зур шагыйрьгә санамыйм, буласым да юк. Сезгә әйбәт мөнәсәбәттә икәнмен — фәкать сезне сәнгатебезнең йөзек кашы, бисмилласын әйтүче аксакал буларак — хөрмәт-ихтирам белән караганга, бөтен иҗатыгызга гашыйк булганга, мөкиббән  иткәнгә. Күңелегезгә тиярдәй сүз ычкындырган булсам, зинһар, гафу итә күрегез.

— Ярар, ярар... Бик чәпчемик әле. Тик бит сүз минем хакта гына бармый, синең хакта да бара. Нишләп син япь-яшь башың белән кешеләргә ачулы, нигә кинә тотасың?

— Гафу, Бакый ага, алай ук түгел. Һич тә бөтен кешегә ачу сакламыйм, кинә тотмыймын. Сездән үзгә буларак, фәкать төрле кешегә төрлечә бәя бирәмен, төрле мөнәсәбәт тотамын. Сездән аермам шунда гына. Әгәр дә сез һәр кешегә елмаясыз икән, бер үк төрле карыйсыз икән, дустым дисез икән, мин моны булдыра алмыймын, бигайбә, абзыкай.

— Сортларга бүләсең инде, ягъни мәсәләнә?

— Юк шул менә. Фәкать һәркемнең бүтәннәргә нинди рәк мөнәсәбәттә булуыннан чыгып бәя бирәм, эш итәм. Әгәр дә мәгәр берәү,— әдипме ул яки шагыйрьме, рәссаммы яки галимме, композитормы яки артистмы,— үзен Алланың кашка тәкәсе дип уйлый икән, фәкать үз мәнфәгатен

каера икән, бүтәннәргә бернинди изгелеге тими икән, данга-шөһрәткә ирешү өчен башкаларны таптап узарга әзер икән, сез инде гафу кылгайсыз, андый бәндәгә мин елмая алмыймын, бертөрле дә хөрмәтем юк андый затка.

— Без синең белән пар ат икәнбез, мсье поиет! Икәү бергә җигелеп, Урманче картның гомер буе иҗат иткән әсәрләренең тулы бер каталогын тартабыз икән, безгә һич тә бәхәсләшеп азаплану лазем түгел, Назимҗан дустым.

— Каталог анысы — программа минимум, ә инде максимумы — альбом булыр.

— Һай, дустым, фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килсә, ни әйттең иде дә бит... Бер дә күңелем ышанмый шул әле. Бүтән берәүгә рөхсәт итәрләр иде аның альбомын да, монографиясен дә... Яшем сиксәнгә җитте, чәчем коелып бетте, әмма андый хөрмәтне күрергә насыйп булырмы икән?..

— Без мәнә милли рәссамнарыбыз арасында иң зур интернационалист, иң олы гуманистка ясарбыз ул альбомны.

— Авызыңа бал да май, дустым! Альбом чыгара алсаң, иң шәп картиналарымнан үзең берсен сайлап аласың, шагыйрь әфәнде! Портретыңны зур итеп акварель белән, юк, майлы буяу белән киндергә ясаячакмын!

— Анысы ахырдан, Бакый ага, альбомның сигнал нөсхәсен китергәч...

— Шулай да колагын тешләп кую зыян итми, дустым. Исемен әйтеп сөйләш, минем нәкышьне инде син яхшы беләсең. Кайсы әсәрем күңеленә аеруча хуш килә? Кайсын өеңә элеп куяр идең, ә?

— Рәхмәт, Бакый ага, чын күңелдән рәхмәт! Сезнең һәр әсәрегез күзнең явын алып тора. Тик инде мин үз мәнфәгатемне каерып, сезнең әсәрләрегезне бүлгәләү ягында түгел. Бергә яшәсеннәр алар, халыкның күрке булсыннар, музей диварларын бизәсеннәр.

— Болай итәбез аны, дустым. Безнең рәссам халкында «авторский вариант» дигән нәрсә бар бит әле. Исеңдәдер, минем «Алмата елгасы» икәү бит. Әлләни зур да түгел үзе болай, нәкъ синең өеңә эләрлек. Әмма үзе көттә инде. Ул буяулар нәкъ Рерихтагыча: таулар бит, Гималай булмаса, Алатау!..

— Рәхмәттән гайре сүзем юк, Бакый ага. Хәтерлим ул эшегезне. Искиткеч камил әсәр.

— Шулаймы, хуп күрәсеңме? Гомерең буе сакларсың үзен. Истәлегем итеп. Син яшь бит әле. Синең кебек чакта мин... Һәй, бераз олыгая төшкәч тә булды ул хәлләр...

Янә дә бер атнадан заводның профсоюз әһелләре килеп, әйбәтләп кенә сөйләштеләр. Кая гына күчерик икән инде, дип аптырашып утырдылар. Шунда аксакал үзе:

— Мине алай артык еракка күчермәсәгез дә ярар иде ярарын,— дип сүз башлады да үзенең теләгән белдерде: — Менә, әйтик, минем фатир астында, шушындый ук өч бүлмәле фатирда, ялгышмасам, ике гаилә яшәп ята. Гәрчә алар үзләре болай тату яшәсә дә, аерым-аерым квартира тәкъдим иткән очракта, алар, мөгаен, күченергә риза булыр иделәр...

Олы кешенең әнә шулай сабыр гына үзенең теләген белдерүе, гомумән, үзен сокланырлык дәрәҗәдә әдәпле тотуы завод кешеләрен тәмам эретте дә җибәрде. Алар моңа чаклы телевизордан гына күреп белгән бөек замандашлары өчен әллә күпме киртәне җимерергә, каршылыкны җиңәргә әзер иделәр.

— Сез соң үзегез, сез үзегез шундый вариантка риза буласызмы соң? — дип кызыксындылар.

Аксакалның тулы йөзенә елмаю җәелде.

— Болай бит ул, дусларым. Яшьрәк чакта мин җәяү йөрергә ихлас ярата идем. Атка атланып, машинага утырып йөрүнең дә кимен куймадым анысы, тик инде җәяү йөрүдән күбрәк тәм таба идем. Арканы асасың да этюднигыңны, рәхәтләнеп күреп йөрисең табигатьнең гүзәл почмакларын... «Их, белсәгез иде ат урлауның тәмен!» дип әйтеп әйткән ди шул берәү. Нәкъ шуның шикелле, үземнең кәсебем табигатькә мәдхия җырлау булгач, күп йөрелде, бик күп...— Рәссам бераз тынып торды, аннары саллы гына таягын кузгатып куйды да гарьләнеп башын селекте:— Менә шушы таякны бүләк итеп кенә сафтан чыгардылар үземне. Хәзер инде мөмкин кадәр азрак кыймылдау ягын карыйм.

Кунаклар да:

— Анысы бар инде, транспортка утырып әллә кая барасы юк,— диештеләр, баш кактылар.

Аксакал үзенең фикеренә теләсә кемне ризалаштыра ала иде, аның белән берәү дә бәхәсләшә алмады. Заводныкылар, ихтимал, түрәләргә әлеге фикерне үзләренең башларында туган фикер диебрәк әйбәтләп төшендереп биргәннәрдер. Һәрхәлдә, шушы фикергә алар чытырдап ябыштылар һәм бу эшкә мөнәсәбәте булган башкаларны да күндерделәр. Беренче катта яшәүче гаиләләргә аерым-аерым бер бүлмәле һәм ике бүлмәле квартирлар бирергә дигән карар чыкканнан соң, инде эшне тиз тоттылар. Атна-ун көн эчендә сәнгатькәрнең урманга сыяр, кырга сыймас эшләрен, әйберләрен, ташларын кран белән йөк машинасына күтәреп сала торалар, останың үзе яшәгән квартира астындагы, беренче каттагы яңа остаханәгә китерә торалар. Аксакал шунда, башына кәләпүшен кигән һәм саллы таягына таянган килеш, нәрсәне кайсы тирәгә урнаштырырга икәнен әйтеп-күрсәтеп кенә тора. Һай, бу дөнья! Кесәдән бер тиен чыкмый бит, бер тиен! Менә, Алла юк, диген инде шуннан соң...

Югыйсә таларга гына торалар бит җыен миһербансызлар кавеме. Әллә күпме шушындый хәл булды. Хәтердә, һәммәсе дә хәтердә...

Әлегедәй хәтерли, Казанда баш-күз алгач та, шуның икенче елында үзе яшь, үзе физик яктан да көчле бер егет Ленинградтан махсус монументаль скульптураны өйрәнеп кайта. Аксакал аңа ачык йөз күрсәтә, бер күрүдә егет белән дуслашып китә, авызына карата, аны акрынлап канат астына алырга хыяллана, тимерне кызуында сугып калырга ниятләп, егеткә бергә-бергә эшләүне тәкъдим итә.

Елмая гына буйчан егет, ябь-яшь егет:

— Бакый абый, сез бит инде мәшһүр скульптор, әгәр дә мин сезнең ярдәмчегез булып эшлим икән, фәкать сезнеңчә генә эшләргә ияләшеп китәрмен. Җиңел юлдан барасым килми, Бакый абый, ныклап эшкә чумасым, эзләнәсем, үз юлымны, үз сукмагымны табасым килә,— дип оста гына баш тарта.

Шулай да аксакалның гаҗәеп авыр эшләрен Сәнгать музеена күргәзмәгә илткән чагында читтә калмый тагын, яшьрәк рәссамнәр белән бергә икенче катка менгезешә. Үзендә фантазия дә бар икән кире беткәннең: әллә каян озын-озын калын такталар табыштыра; ул такталарны баскычка сузып салган арада тагын аркан өстерәп килә дә, төпкә үзе җигелеп, Тукайның мәрмәр бюстын икенче катка менгезешә.

Әлегедәй хәтерли Габделбакый, такталарны каядыр алып илтеп куйгач, егетләрнең берсе, ике кулын угалап, аксакал янына килә дә:

— Әйдәгез, Бакый Идрисович, юып алыйк инде, өмә тәмам бугай,— дип сүз куша.

— Мин эчмим бит,— ди аксакал коры гына.

— Син эчмәсәң, без эчәрбез, сыйла гына,— ди теге, күзен дә йоммый.

— Сезне әнә Рәссамнәр союзы сыйласын,— ди аксакал тегеңә.

Анысы да аптырап калмый:

— Без бит Художниклар союзына булышмадык, өмәне син җыйдың,— ди.

Һи, дивана! Тапкан савым сыер! Акча түлисе килсә, Бакый абзагыз грузчиклар да яллый алыр иде...

Аксакал янына Назим атна саен, дәресрәге һәр шимбә көн килә торган булды. Аның бу хезмәтенә — җиде-сигез ел буена Урманченың бөтен иҗатын барлап чыгу һәм ныклап өйрәнүенә, альбом дип чиләнүенә — өйдәгеләре ничек карагандыр, анысын ул аксакалга һич сиздермәде, милләт алдында үзенең изге бурычы дип, бары тик ул гына башкарып чыга алырдай, тавык чүпләп бетермәстәй бер эш дип карады. Моның өчен нинди дә булса әҗер дә өмет итмәде, хак-фәлән сорау уе башына да килмәде.

Ул чагында әле әрдәнәләп өелгән нәкышь әсәрләрен берәм-берәм тартып чыгарып, һәркайсының карандаш белән исемен язып, аркылысын-буен үлчәп, аны картинаның сыртына теркәп, иҗат иткән елын да өстәп чыгу алай артык озакка сузылмады — бер елга да бармады. Шул чагында Назим аксакалның хәтеренә хәйран калды. Калмаслык та түгел бит: киндернең артына берни язылмаган — ни исеме, ни елы юк. Иненбуен үлчәве читен түгел, егетнең карандашы кулында, матурлап сырлап куя. Ә менә әсәргә исем табу — анысы инде авторның хокукында. Нәкъ менә яңа туган балага ата-ана үзе яраткан, үзе сайлаган исемне кушкан кебек. Шунда рәссам искиткеч матур исем дә таба, һәркайсының кайсы елны, нинди төбәктә иҗат ителгәнен дә әйтеп сала. Кулыннан каләмен яисә карандашын төшермәгән Назим аксакалның хәтере әйбәт булуына сөенүен һәм соклануын әйтергә дә өлгерми, хәйран калып башын чайкап тик тора... ул арада Габделбакый әнә шул картинаны язган дәвердә булып узган хикмәтле берәр хәлне сөйләп җибәрә. Һәммәсен дә хәтерләсә дә хәтерләр икән адәми зат! Шул чаклы да мавыктыргыч итеп сөйләсә дә сөйләр икән! Талантны шул аны, акча кебек, диләр: йә бар ул синдә, йә юк. Булмаган тәкъдирдә инде бар дип син берәүне дә ышандыра алмыйсың. Ә инде булган тәкъдирдә ул, һичшиксез, гаять күп кырлы булучан. Габделбакый исә үз һөнәренең бик сирәк очрый торган таланты: нәкышь өлкәсендә ул бөек рәссам; уем-скульптурада — ювелирга тиңләшерлек, иң-иң камил әсәрләрнең авторы; графика өлкәсендә — гүзәл әсәрләр иҗат иткән акварель сәнгатенең тиңе юк остасы.

Назим кайчагында моңарчы күрмәгән берәр әсәргә юлыгып, аны әйбәтрәк күренә торган җиргә куя да карап-сокланып туя алмый. Икенче-өченче килүендә янә теге әсәрне тартып чыгара, янә көне буе аерыла алмый. Аның соклануын күреп, аксакал елмая, тыйнаклык йөзеннән:

— Син шагыйрь кеше бит, шигърият күрәсеңдер, бәлки. Мин үзем алай ук югары фикердә түгел бу әсәр хакында, алай ук түгел...— дигән була.

Назим үзе белгән исемнәрне тезеп китә, бәхәсләшә:

— Соңгы егерме-утыз елда моның дәрәҗәсенә җиткән камил әсәрне, ай-һай, тагын берәрсе яза алды микән, юк микән? — ди.

— Алай ук зурдан кубып мактамасаң да була, рәнҗемим. Уем өлкәсендә чынлап та кайбер уңышка ирештем төсле... Нәкышь ул миңа артык бирелмәде никтер... Скульптор булып тугангадыр инде, уемчы булып, һич тә бүтән сәбәптән түгелдер.

— Юк-юк, Бакый ага! Бик нык ялгышасыз! Скульптурадагы уңышларыгыз хәйран зур, анысы бәхәссез. Ә инде нәкышь өлкәсендә — иң оста рәссам сез, тиңегез юк. Мондый гүзәл киндерне тагын кемдә күрермен дисез? Берәүдә дә юк мондый камил әсәр. Чөнки төсләрне бер генә рәссам да — ни яшьләрдән, ни өлкәнрәкләрдән — сезнең кадәр сиземли алмый.

Каршы бер сүз әйтми сәнгатькәр. Аның кулында кыл-каләм, шуны салмак кына йөртеп чыгып-йөртә. Бәләкәй генә альбом кәгазенә карандаш белән ясалган сызым ничәмә-ничә ел үткәннән соң ниһаять киндергә

күчә, сурәтләр тагын да ачыклана төшә — автор аларга ашыкмыйча гына җан өрә...

Менә бер заман аксакал тамак кырып ала да, егет ягына борылып карамыйча гына, кыюсызрак тавыш белән:

— Назимҗан, без нигәдер тынып калдык. Шуннан башыма уй килде. Мин әкрен генә тавыш белән җырлап җибәрсәм, синең эшеңә хилафлык китермәмме? Каршы түгелме син минем эш арасында җырлавыма? — дип өн сала.

— Бик хуп, Бакый ага! Тик нигә әле әкрен генә җырларга икән сезгә, шундый көчле тавышыгыз булганда? Кычкырып торып җырлагыз.

Аксакал тагын тамак кыргалап ала да матур һәм куәтле баритон белән җырлап җибәрә:

> Ике дә генәй буй кыз урак ура,
> үтәр-үтмәс аларның урагы.
> Нигә генәй үтсен аларның урагы —
> башларында буй егет уйлары.
> Ике дә генәй егет печән чаба,
> үтәр-үтмәс аларның чалгысы.
> Нигә генәй үтсен аларның чалгысы —
> башларында буй кызлар кайгысы.

Назим үзе юньләп җырлый белми, бүтәннәрнең җырлавына соклана гына белә.

— Бакый ага, сезне тыңлаганда, тавышыгызның кодрәтенә сокланмый чара калмый. Мәһабәт вә саллы тавыш, һич сүз юктыр. Сез, мөгаен, еш җырлыйсыз булыр... Остаханәдә бит сезгә берәү дә комачаулык кылмый.

— Юк шул, дустым,— дип, рәссам урыныннан куба да аз-маз билен язып, бер-ике гимнастик күнегү ясап ала.— Артист халкы ни өчен сәхнәдә әйбәтрәк җырлый, дип беләсең? Чөнки залда тамашачы утыра. Шуларның күңел кылларын тибрәндерү нияте белән дәртләнеп башкара ул җырын. Үзенең ни дәрәҗәдә әйбәт җырлавын, тамашачыларның ошату-ошатмауларын ул аларның күзләреннән күрә, сулышларыннан ишетә. Йә, үзең уйлап кара, мин ничек итеп җырлыйм ди, тыңлаучым булмагач? Юк, дустым, алай мин рухлана алмыйм, һич! Тыңлаучы булса — анда башкача. Шул инде әнә иҗат кешесенә ләззәт бирә торган нәрсә. Ул үзе шуннан тәм таба, ләззәтләнә...

Аксакал аяк өстендә чакны утырып торуны яхшысынмыйча, Назим да эшен калдырып, елмая-елмая, мольберттагы рәсемгә якынлаша.

Рәссам аны һәр килүендә:

— Йә, белгеч булсаң, әйтеп кара әле, мсье поиет, син күрми торган арада ниләр өстәлгән? — дип шаярта.— Яхшы якка үзгәргәнме, әллә начарлана төшкәнме әсәр?

Шаяртып кына әйтелгән шушы сүзләр егетне үзенә таләпчәнрәк килергә, һәр әсәрне караганда игътибарлырак булырга өйрәтә. Әллә тизрәк каталогын тәмамлатып, альбомын күрәселәре килеп ашыга, әллә остаханәсендә эшләп утырган арада гәптәш булуын ярата, әллә инде беркатлырак, сабый холыклырак Назимны кеше буларак сагына идеме — төгәен әйтү һич мөмкин түгел. Фәкать шунысы хак, аның килгәнен һәр шимбәдә сәнгатькәр дүрт күз белән көтеп ала, кочаклап күрешә дә берәр яңалыкны сөйләп җибәрә торган иде.

Бу юлы да нәкъ шулай булды. Егетне каршысына утыртып, үзе креслога чумды. Елмаеп-балкып:

— Кичә генә бер мактау сүзе ишеттем әле зур Тукайга. Профессиональ кеше биргән бәя. Скульптор Габделһади Абдрахмановтан, Красноярскидан хат килеп төште. Мин аңа Тукай музееның, һәйкәленең рәсемнәрен җибәргән идем... Мә, үзең укы әле менә,— дип, хатны Назимга сузды.

Һәйбәт шома кәгазьгә каллиграфик матур почерк белән язылган хатның сүзләре чынлап та тәэсир итәрлек иде:

«Тукаегыз өчен күп рәхмәт. Г. Тукайга һәйкәл куйганны күптән көткән идем, шуны күрү насыйп булды. Сез иҗат иткән һәйкәл бик тә ошады. Үзе эмоциональ тәэсир итәрлек, үзе бигрәк гади килеп чыккан, моңа ирешү хәйран да читен, мондый уңыш һәр авторга тәтеми. Зур уңышка ирешкәнсез, тәбриклим үзегезне...»

Сәнгатькәрнең күңеле булды, сөенечен гәптәше белән уртаклашырга ниятләде:

— Бик әйбәт кеше бу. Сирәк очрый андый зат. Скульпторлар арасында сирәк очрый, диюем. Икенче берәүнең яхшы әсәр иҗат итүенә сөенә белә, көнләшү дигән нәрсә аңарда гел юк та юк инде. Һич юк андый нәрсә. Ул инде сине мактамас-нитмәс юкка гына, күңеленне күрер өчен генә. Әгәр дә ул мактаса, аны инде комплимент дип кабул итмисең... ышанасың аның әйткәненә. Шундый кеше ул Абдрахманов...

Аксакал юньлерәк кешенең дөньяда булуына шулай чын-чынлап сөенә, тәмам канатланып китә иде. Бу юлы да әллә күпме истәлек сөйләп ташлады.

Бер заман дәртләнеп эшләп утырган җиреннән янә тавыш бирде ул:

— Хәзер киләм синең янына. Бер-ике генә сылыйм да... йә, хуш, булды! — Кузгалып китмәкче иде, бер якка янтайды. Үзе шунда да сер бирмәде, елмаеп, киндер артына сузылды. — Монысы бар бит әле аның. Менә! — дип сөйләнә-сөйләнә, таягын өстерәп чыгарды. Аны җайлап тоткач, шуңа бик нык таянып, аксый-туксый, озын өстәлне урап килә башлады.

Назим, аның газапланып атлаганын күреп, тизрәк иплерәк урындык куярга ашыкты, аннары язып утырган кәгазьләрен читкәрәк шудырды.

Артлы урындыкка иплән кенә утыргач, сәнгатькәр авырткан аягын алга сузды, учы белән сыпыргалады, үзе шунда да сүзсез калмады: дөньясын онытып эшкә бирелгәндә, тик кенә, сөйләшмичә генә утырса, Урманче да булмый ул.

— Синең Ренуар турындагы китапларны укыганың бардыр инде? Ул да бит арбада утырып эшләгән... Аяксыз калгач, әлбәттә, картлык көнендә...— Аягы язылгандай булгач, рәссам өстәлдә яткан көзге этюдларының берсен кулына алды, гүя егетнең эшен калдырып, янына килеп утыруның, әңгәмәгә тартуның сәбәбен төшендереп бирергә итте: — Күз салыйм, дидем шул акварельләргә. Карыйсым бик килде шуларны... Чуковскийдагы кыз бала ничек дигән әле әбисенә? Син үлгәч, ну әйләндерәм икән рәхәтләнеп синең тегү машинаңны, дигәнме? Шул сабый кебек, мин дә инде син өеңә кайтып киткәч тә, карый алам инде югыйсә... Тик менә синең алда, бергә-бергә карыйсым бик килде.— Күзен алмыйча шактый вакыт шулай карап торганнан соң: — Ни генә әйтсәң дә, көз җырчысы шул Урманче, көзге матурлыкка мәдхия җырлаучы... Бәхәссез, шулай...— дип нәтиҗәсен ясап куйды.— Һич риясыз...

Икенче атнада сәнгатькәр үзенең ярдәмчесен яңа хәбәр белән каршылады:

— Мин әле бик зур эш майтарып ятам бу арада. Сәнгать өлкәсендә түгел түгелен...— дип, гафу үтенгәндәй итеп әйтеп куйды. Шулай да көр тавыш белән серен чишәте: — Массаж ясатам. Безнең туганнар арасыннан килеп чыкты шундый бер кеше. Укыга-а-ан! Ышандым шуңа. Ну, каты ясый да инде. Акырта үземне. Шулай булганы хәерле. Югыйсә миңа элекләре сыйпап-нитеп кенә массаж ясаганнары бар иде...

Янә бер килүендә, күрешкәч тә, бөтенләй көтелмәгән мәгълүматны бирде:

— Син, гарәп хәрефләре белән укый белмәгәч, Риза Фәхретдинне укыганың юктыр?..— дип башлады да бүленеп калган эшенә утырды, кулына кыл-каләмен алды, үзенә генә күренгән, бүтән беркем күрә алмастай кимчелекләрдән арынырга тырышкан ювелир сыман, җентекләп

карый-карый, анда бер яфрак сылады, тегендә үлән кыягын чыгарды, бередә чәчәкне ямьләндереп җибәрде. Әңгәмәне ул әнә шулай тырышып-тырышып эшләгән арада гына дәвам иттерде.— Шунын бюстын ясарга хыялланып йөрим күптән. Риза Фәхретдиннең бюстын ясамыйча торып— үләргә дә хакым юк минем!..— Тагын берәр чәчәк ясады, яфрак сылады, башлык кигән чал башын селкеп алды.— Гаҗәп тә халык инде! Алардагы намус, алардагы ихлас...

Назим шулчак:

— Нигә әле сез «алар» дисез?— дип ачыклык кертү өчен үзенең соравын кыстырмыйча кала алмады.

Аксакалның кыяфәтендә, бигрәк надан икәнсең, шуны да аңлый алмыйсың, дигән гарьлек, кимсетеп карау сизелсә дә, телдән моны әйтмәде, сабыр гына төшендерү юлына басты:

— Чөнки бер мәсләктәге кешеләрне, бер төбәк, бер тирә (Оренбур халкы алар), бергә эшләгән кешеләрне шулай карарга кирәк, Назыйм җан.

— Ху-у-уш, кемнәр дисез инде?

— Риза Фәхретдин, Дәрдмәнд, Фатих Кәрими... Башкалары тагын...— Сәнгатькәр баштарак бармагын бөгә-бөгә санамакчы булган иде дә, аннары ике кулын югарыга күтәреп, җәеп җибәрде.— Риза Фәхретдин бик күп язган бит. Әгәр аның язган нәрсәләрен укысаң, үтәли күренеп тора аның нинди кеше булганлыгы. Әлбәттә, ул динле. Әмма аның дине схоластик, догмага гына корылган дин түгел. Һәм ул үзе схоластикага каршы һаман көрәшкән шәхес: акылны алга сөргән, фикерне. Аны укырга кирәк, дустым, шунсыз аны белү мөмкин түгел. Менә мин үзем аны хәзер генә ачам әле.— Сүземнең тәэсире нинди рәк икән, үтемле микән, юк микән, әллә мин суны комга сибәм микән, дип, гаптәшенә күзләрен кысыбрак карап алды ул.— Искиткеч галим кеше булган шул, эрудицияле. Гарәпчәне, фарсыны ана теленнән яхшырак белгән, камил рәвештә. Һәм шул телләрдә язган галимнәрнең кимчелекләре хакында фикер йөртерлек рәвештә...

Назим үз сүзен кыстырып җибәрергә җай тапты:

— Прогресска файдасы тигән, дисез инде?

— Һи-и-и! Инде гаҗәп! Һич риясыз, һәрвакыт турысын әйтә торган кеше...

Сәнгатькәр тынып калды. Озын өстәлдә тау хәтле булып өелеп яткан вак-төяк эшләрне берәмтекләп, ашыкмыйча гына барлап, үлчәвен алып, мәгълүматны кәгазьгә теркәү белән мәшгуль булган Назимга күз төшереп алды да сүзсез генә мольберты янына барып утырды.

«Уралтау эргәсендә», бер караганда, тәмамланган да кебек иде. Әмма кырысрак күз белән караган саен аның кимчелекләре табыла тора. Назим шуңа аптырый. Камиллекнең чиге юк икәнне дә белә бит инде югыйсә, шулай да аксакалның торган саен берәр кимчелек табып, шуны сылаштырып утыруына ихлас гаҗәпсенә.

Әле бүген дә сәнгатькәр янына килде дә:

— Нәрсә, Бакый ага, тагын берәр бәйләнер урын таптыгызмыни?— дип кызыксынды, үзе ирексездән көлемсерәп куйды.

Мәгәр аксакал аның соравына җавап биреп тормады, шушы мизгелдә күңеленә килгән фикерләрне бәян итүне кулайрак күрде:

— Татар сәнгате бит, дустым, түгәрәк формалардан тора...

Габделбакый тикмәгә сөйли торган кеше түгел. Һич юк! Сүземнең кадерен беләсеңме, дигәндәй, гаптәшенә төбәп карады һәм тегенең, үз хәтеренә генә ышанмыйча, аксакалның сүзләрен теркәвен күреп, тәмам нурланып-балкып алды:

— Татар кешесе, Назимҗан дустым, җырында да бит:

Йомры тояк тайларда,
Матур кызлар байларда...—

дип йомрыны матурлык белән янәшә китереп әйтә!— диде.

Киндергә янә бер яфрак өстәде.

— «Уралтау эргәсендә», дустым, ул әле яралгы хәлендә генә иде. 1927 елны башланган, диюем. Ул чагында мин яшьрәк идем әле, сәфәр кылудан һич курыкмый идем. Техникумга сәләтлерәк яшьләрне эзләп табу нияте белән командировкага йөри торган идем. Әнә шул елны Башкортстанга барудан соң, шул вакытта калган тәэссорат нәтиҗәсендә туган бер күренеш бу.

— Әлегә хәтле шуны исегездә тоттыгызмы?

— Болай бит ул, Назимҗан,— диде сәнгатькәр,— һәркем табигатьтә әзер сюжет күрә, шуңа соклана.

— Рәссамнар бигрәк тә инде, Бакый ага, иеме?

— Рас әйтәсең, дустым, нәкъ шулай. Безнең һөнәр кешеләре табигатьнең ямьле төбәкләрен гадәттә, үзләре язарга тиеш булып та, әле һич вакыт тапмаган, өлгерә генә алмаган картиналар сыйфатында күрүчән.

— Сез дә Урал таулары башланган җирне ямьле бер картина итеп күргәнсездер инде.

— Дөп-дөрес, дустым Назимҗан, дөп-дөрес. Әнә шунда алган тәэссоратның көче бүгенге көнгәчә сакланган. Ләкин мин кайчандыр үзем күргән хәлләрне гәүдәләндермим, бәлки шуларга тәңгәл килердәй күренешләр, образлар минем күңелемдә туа...

— Әнә шуларны кәгазьгә төшерәсезме?

Сәнгатькәр елмаеп, башын кагып куйды:

— Табигатьтә күргәнемне тасвирлаган очракта, дустым, ул бит натурализм килеп чыга. Телисеңме син аны, теләмисеңме — барыбер котылгысыз рәвештә. Йә, үзең уйлап кара хәзер: мин шундый картиналар гына язсам, халык афәрин дияр идеме? Һич тә! Андый эшеңнең кыйммәте Буа базарында да тишек бер тиен.

— Буа базары да хәтерегезгә уелып калган икән, Бакый ага,— диюе белән Назим аксакалны елмаерга мәҗбүр итте.

Триптих, ягъни өч кисәктән торган әсәр итеп эшләргә ниятләгән, дивар буена тезеп куйган «Күл-Черкен», «Салтык болыны», «Уралтау эргәсендә» картиналарының эскизлары ягына чал башы белән ымлап:

— Менә боларга карасаң, боларның берсендә дә мул күләгә белән (светотень) модельләштерү юк, натуралистик хәл итү юк. Монда кояш та, башкасы да бары төсләрнең катнашы белән генә бирелә,— дип Назимга төшендереп бирүне кирәк санады ул.

Картинага текәлебрәк карагач, гүя сәнгатькәрнең хәтерендә һәр нәрсә нәкъ ярты гасыр элегрәк булып узган халәтендә яңарды, гүя картинадагы су алырга килгән ахирәт кызлар да, арттарак шәйләнгән җайдак егетләр дә җанланды, гүя үзе дә сиксән яшен тутырган көмеш чәчле карт булмыйча, утыз яшьлек, җирән сакаллы чагына әйләнеп кайтты. Шуңа да ирексездән:

— Яшьлекнең бит мәхәббәт вакыты җыр белән, музыка белән бәйле була. Гаҗәп!..— дип үзалдына сөйләнгәндәй итеп кенә әйтә куйды.— Мин сине хафалыйм инде хафалавын... Минем дә бит күңел бар...

Гәрчә сәнгатькәр үзе триптих итеп зур-зур күләмле киндерләргә өч әсәрен күчереп язарга ниятләсә дә, озак еллар дәвамында ошбу изге эшне башкарып чыгарга хыялланса да, туган авылы Күл-Черкенне, Зөя буен тасвирлаган бердәнбер эскизыннан үзе бер дә канәгать булмады, яңа вариант иҗат итә алмады, шуны очлап чыга алмады — ул триптихны күрү насыйп булмады...

Ә менә «Салтык болыны» шикелле үк, «Уралтау эргәсендә» әсәренең дә язмышы кулайрак булып, зур киндергә (биеклеге — 2 метр) күчереп язганнан соң, гаҗәеп матур вә камил әсәр барлыкка килде. Карап туймаслык әсәр.

Әмма үз-үзенә гаҗәеп дәрәҗәдә таләпчән сәнгатькәр әлеге күчереп кую эшен дә әштер-әштер генә башкарып ташламады. Миннән киткәнче, нисенә җиткәнче, дип кенә эшләүне белми иде ул. Шуңа күрә, тәмам эше

бетте инде, дигәннән соң да бу ике-өч әсәрен читкә алып куймады. Ара-тирә шулар ягына күз салгалап, куанычы тышка бәреп чыккан чакларда Назимга һәр деталең сөйләп-аңлатудан да үзенә бертөрле тәм таба торган булды:

— Монда, дустым, тональносте дөрес алынды. Кайвакытны була бит шундый бер этәргеч — табыла да куя иң кирәкле төсе, аннары инде шуның белән җайлы гына бара, иплe генә... Бу әйберләр бит зурлыгы-күләме белән бер чамада, әмма инде төсләре белән, тональность белән алар бер-берсеннән аерылып торырга тиеш. «Уралтау» бит әнә тоташы белән салкын тонда язылды, ә монысы (ягъни «Салтык») — җылырак!

Назимның үз кайгысы кайгы — аңа каталогны тизрәк очлап чыгарга кирәк:

— Монысын бетергәч, «Кул-Черкен»гә тотынырсыз инде, Бакый ага, әйеме?

— Шула-а-ай!

— Өчесен дә 1978 белән билгеләп куйсак, әйбәт була ул аннары.

— Начар булмый...

Шулай дип әйтүен әйтсә дә, сәнгатькәр үзенең ниятләрен гамәлгә ашыру, меңләгән эскизларын адәм рәтле кыяфәткә кертү, зур күләмле әсәр иттерү өчен генә дә янә 80 ел кирәк буласын, әлбәттә, шәйләде. Аның уфтанып куюы да, чал башын чайкап:

— Ничек алырга тагы бер гомер?— дип әйтүе дә тикмәгә түгелдер.

Ә бер килүендә Назим мольберттагы «Уралтау эргәсендә» әсәрен озаклап күздән кичерде — һәр деталең бәйләнчек «искусствовед» булып карады-төпченде, әмма бәйләнерлек җирен тапмады. Шуннан инде соклануын яшермәде:

— Бакый ага! Тәмамлагансыз икән моны! Афәрин! Хәзер инде уң ягындагы табигать күренешләре тәгаен тоташа: күге дә, таулары да, күле дә, агачлар да, җир дә...

Яраткан «баласын» мактагач, сәнгатькәрнең авызы ерылды, үзе дә мең дә беренче мәртәбә дигәндәй тамаша кыла башлады.

— Әйе шул, тоташа хәзер. Ул бит, мсье поиет, башта ук шулай уйланган.

Гәптәшләрнең күзләре — киндердә, бер-беренә һич карау-мазар юк.

— Бакый ага, болай караганда ул үзе ике өлештән — аскы һәм өске өлешләрдән — генә торадыр кебек. Чынлабрак карасаң, сулдан уңга таба да өлешләп тикшерергә мөмкин икән...

Габделбакый:

— Дөп-дөрес! Тулы бер ай монда. Шулай уйлап ясалган. Ай эчендә — бу ике сылу,— дип шәрехләүне урынлы санады.

Әмма Назим да төшеп калганнардан түгел икәнлеген күрсәтергә ашыкты:

— Айдагы көянтәле Айсылу. Әмма берәү генә дә түгел, икәү!— диде. Яңалык ачкан сыман, зур бер тантана белән әйтте.

— Шул шул менә!— дип раслады рәссам. Мәгәр аның күзе күбрәк, әйтеп бетергесез күбрәк күрә иде.— Кызларның берсен үзгәртәсем бар әле тик,— диде ул, гәптәшенең аптыраулы карашын абайлап:— Алъяпкычын...— дип төшендереп бирде.

Әмма егет моны аңлап бетермәде:

— Нигә үзгәртәсез аны?— дип төпченде, иңнәрен җыерып куйды. Сәнгатькәрнең җавабын көтте.

— Артык җете. Күзгә кереп тора. Сарысын сары булып кала ул, тик инде бераз фонга тартымрак, башка төсләргә бәйләнешлерәк итәчәкмен. Ат бармы әнә? Акмы ул? Ак ат бит. Ә бит ул ак буяу белән язылмаган!.. Музыкаль гына нәкышь килеп чыккан бит, ә...

Гүя Назимның әле генә күзе ачылды, гүя ул менә хәзер генә кайбер нәрсәләрне күрә башлады. Әлеге ачышын ул сәнгатькәрдән яшереп тормады, акыллы булып күренергә тырышмады.

— Бакый ага-а-а! Казлар да зәңгәрсу буяу белән язылган түгелме соң?— дип кычкырыбрак әйтә куйды.— Ә үзләре... ә үзләре ак булып күренә...

Сәнгатькәрнең ай кебек түгәрәк йөзе елмаюдан җәелде.

— Шунда шул бөтен хикмәт тә!..

Әйе, игезәк әсәрләр уңышлы чыкты, моңа аксакалның үзенең дә иманы камил. Язмышыннан канәгать бер кыяфәт белән ул:

— Ходай тәгалә, ничек кенә булмасын, миңа яхшы күз белән караган...— дип куйды, аннары соклануының сәбәбен әйтеп бирүне кирәк тапты:— Шигърият булырга тиеш монда. Ызгыш-талаш кына түгел бит әле дөньяда. Шигърият тә бар. Табигатькә гашыйк булу бар бит әле. Үзең тыныч-тату булсаң, табигать-ананы иркәли белсәң, ул да сине иркәли аннан соң...

Аяк өсте озаклап тору, мөгаен, авырга килгәндер, чак кына арткарак чигеп, кәнәфигә утырды да авырткан аягын ике кулы белән иплебрәк урнаштырды.

— Күзегез үткен сезнең, Бакый ага,— дип сокланды егет,— дөресе шул. Табигатьнең гаҗәеп кызыклы төбәкләрен сайлап алгансыз.

— Әйтәсе дә юк! Пейзаж хәйран гына үз урынына керде дә ятты. Аннары төсләр йомшак монда. Күчереп кенә язармын инде әзер әйберләрне, дип тотынган идем мин... Копия ясый алмый шул иҗат кешесе: һәрвакыт үзгәртә тора...

Габделбакый үзенең шәкертләреннән китап укуны, күбрәк ана телендә укуларын таләп итә иде. Кергән саен үзенең бүгеннәрге нинди китапка табынуын әйтмичә, аны шәкертенә күрсәтмичә, шуннан берәр гыйбрәтле кыйссаны сөйләмичә калмас иде.

— Рәссам халкына китап укуга караганда аны укымау хас,— дип зарлангалап та куя.— Гадәттә эш күплеккә сылтыйлар. Ә бит салып утырырга, сафсата корырга вакыт табалалар. Шул вакытларын китапка сарыф итсәләр, бөтенләй дә зыялы булып китүдән котлары алына, диярсең...

Бүген менә яшь рәссам Җәббар килеп кергәч тә, сүзне шуннан башлады:

— Әлерәк кенә бер әдип булып китте хөҗрәмдә... Ну, укый да икән соң! Китап укыган кеше белән сөйләшүләре үзе бер рәхәт бит аның. Фикерләве үзгә аның, лексиконы бай булучан.

Яшь рәссам елмаеп кына:

— Сездән уздыручы юктыр инде китап уку мәсьәләсендә,— диган булды, өстәлдә ачык яткан китап ягына ымлады.

Аксакал китапны кулына алды, кай арада күз салып өлгерде.

— Бу бит, дустым Җәббарҗан, һәрвакыт минем алда булырга тиешле китап. Степан Нефедов картлачның тормыш юлы язылган монда. Әлбәттә, игътибар үзәгендә — аның иҗаты. Нәкышь әсәрләреннән бөтенләй үк читләшмәсә дә, ул үзе болай скульптор буларак танылган. Степан Эрьзя диләр аны. Бөтен дөньяга мәшһүр. Кечерәк кенә эрзя диган халыктан чыккан ул үзе, мордва була, ягъни мәсәлән.

Шәкерте дә остазына тиң зыялы булырга теләде:

— Безнеңчә әйткәндә, мукшы була инде ул, ягъни мәсәлән,— дип төзәтте.

Ләкин аксакал моңа каршы елмаеп җавап кайтарды:

— Юк шул, дустым, алай ук түгел. Мордва халкы үзе икегә бүленә: берсе — эрзя, икенчесе — мукшы. Алатыр янында үскән шул тынгысыз җан Казанда да һөнәргә өйрәнә, Мәскәүдә дә укый. Аның белән генә калмый әле, Италияне, Францияне айкый, Латин Америкасына, Аргентинага барып чыга. Шул егет, беренче скульптураларны күргәзмәгә куярга димләгәч, Идел буенда яшәгән халкымны белсеннәр әле дип, Эрьзя диган псевдоним ала.

— Безнең Курсави, Болгарилар кебек икән алайса.

— Нәкъ өстенә бастың, дустым. Шунысына игътибар ит син, мелла, бик тә инде эш сөя торган шәхес була Эрьзя. Җитмешне узгачыннан илгә кайтып егыла. Даны да кирәкми аңа, малы да — эшләвен генә белә. Сиксән яшендә үзенең иҗат иткән әсәрләре язмышын кайгыртырга шулай да башы җитә бит останың. Инде дә акчага кызыкмый торган зат була. Меңнәрне инде анысын әйткән дә юк, АКШтан Аргентинага килгән бер эшкуар бай аның күргәзмәдәге эшләренә миллион доллар тәкъдим итә, бер «Моисей» өчен йөз меңне бирә — сынчы кызыкмый. Эшләгән эшләрен пароходка төяп илгә алып кайта. Туган-тумачасы вәйран итеп бетермәсен өчен, беләсеңме, нишли? Музейга бүләк итә!

— Бер дә бала-чагасы булмаган микәнни?

— Юк шул менә! Баласы да, чагасы да булмаган.

— Сезнең бит Мәскәүдә улыгыз бар, сезне ул кайгыртыр.

— Һай, дустым, аны әйтәсең син! Илдар бит үзе дә рәссам, минем һөнәрне дәвам итә. Сабый чагында әнкәсе үзен музыкага да өйрәтеп карады каравын, тик менә рәсем сәнгате җиңде. Егерме биш яшеннән — Рәссамнар союзы әгъзасы. Халыкара күргәзмәләрдә премияләр алган зат — Венециядә, Парижда, Лейпцигта... Ләкин ул мине, болай улым булырак яратса да, иҗатыма, әсәрләремә алай ук мөкиббән китми. Искергәнсең, заманадан артта каласың, бераз өлгеррәк булырга кирәк иде, синең талантың миндә булса, әллә ниләр эшләр идем, ди. Бәхәсләшмим, елмаям гына.

— Бәхәсләшүдән файда юк инде, Бакый абый.

— Рас әйтәсең, юк шул, юк! Инде минем хыялымны тыңла. Бирсеннәр иде минем үземә бер музей! Шунда куяр идем мин үзем эшләгән барлык иҗат җимешемне дә!

— Андый музей ясасалар, барыбыз да илтер идек әле әсәрләребезне.

— Юк, алай түгел шул, Җәббарҗан дустым. Анда фәкать Урманче иҗат иткән әсәрләр генә куелырга тиеш. Нәкыше дә, уемнары да, график эшләре дә — һәммәкие бергә җыелырга, тупланырга тиеш.

— Болай матур икән ниятегез. Ничек соң, ул эшләрегезне сатып бирмәкчесезме?

— Юк шул менә! Татарстан Республикасына, халкыма бүләк итмәкче булам җәмгысен! Менә күр, нинди язу илттем мин үзебезнең хөкүмәткә,— дип сөйли-сөйли, аксакал өстәл тартмасыннан уңып беткән иске бер папка чыгарды, аннан бөкләми-нитми сакланган табаклы кәгазь алып, шәкертенең кулына тоттырды.

Җәббар кәгазьдәге язуны игътибар белән укып чыкты, хәйранга калды. Барыбызга да карттан үрнәк алырга туры килер микәнни, дип уйлап өлгермәде, шундук башыннан яшен тизлеге белән, һәй, безгә кем бирә соң әле музей, дигән фикер йөгереп узды. Аннары инде үзенә текәлеп торган олы кешегә ничек тә иплерәк әйтергә тырышып:

— Бу инде әйбәт була, бик әйбәт!— дип, кәгазьне хөрмәт белән генә иясенә сузды.

Әмма сәнгатькәрнең күптәнге уе бар иде, күрәсең. Ул артык ачылып китмәде, боек кына тавыш белән:

— Син әйбәт дисең дә бит менә... Бик алай атлыгып тормыйлар шул, дустым,— диде. Үзе язган кәгазьне беренче мәртәбә күргән шикелле, сәерсенеп карап торды да:— Беркемгә берни кирәкми бит, дустым, син шуны беләсең микән... Кеше үзләренә йөзләгән, меңләгән иҗат җимешен, гомере буе күзенең нурын салып язган булсын анда, уеп ясаган булсын, акварель, темпера, гуашь, пастель белән язган эшләрен булсын — барысын бергә туплап, халык рәхәтләнеп күрсен өченгә бүләк итә, ә алар аңа әйләнеп тә карамыйлар...— диде.

Яшь рәссам әңгәмәнең андый төс алуын көтмәгән иде, күзе дүрт булды:

— Алай ук түгелдер инде? Неужели шулай?— дигәнен сизми дә калды.

Остазның, оеп киткәндәй, күзен йомып, кымшанмыйча да утыруын күргәч, ирексездән йөрәге әрнеп алды. Картны өметсезлектән ничек кенә булса да чыгарырга кирәк иде, тик яшь рәссам шундый чакта әйтелергә тиеш сүзне алай тиз генә тапмады, төртелеп калды. Фәкать аксакалның:

— Шундый-шундый эшләр, Җәббарҗан...— дигәнен ишеткәч кенә, җанланып киткәндәй сыман:

— Бакый абый, музейны аны сездәй аксакалга да ясамагач, кемгә генә ясарлар икән аннары соң?!— диде. Ул арада баш мие ачылып киткәндәй булды, фикерләре сүзгә әйләнде, бере арты бере тезелде:— Һичшиксез, житкезерләр сезгә музей! Сез бит карап торган бер аксакалыбыз, Тукаена иш бит сез татар халкының! Булырга тиеш сезгә музей, булырга тиеш! Үзем шунда каравылчымы, дворникмы булып урнашам.

Бу сүзләрдән аксакал рәхәтләнеп бер көлеп җибәрде. Моны күреп, яшь рәссамның да күңеле булды. Язучы, композитор, рәссам дөньядан киткәч, аларның төсләре булып иҗат иткән әсәрләре кала, дибез. Алай гына да түгел икән әле. Остазларның шәкертләре дә кала икән! Алар остазның ният-теләкләрен гамәлгә ашыру өчен көчләрен кызганмаячаклар. Өстәвенә әле үзләренең шәкертләренә дә нәкъ әнә шуларны дәрес саен, очрашкан саен тукып торачаклар, башларына сеңдерәчәкләр. Бәс шулай икән, иҗат кешесенең гомере аның әсәрләрендә, шәкертләренең иҗатында дәвам итәчәк. Монысы инде — мәңгелек!

Күзгә күренерлек әсәрләр калган очракта, әлбәттә, музей булдыручы халыклар да бар бу дөньяда. Андый халыкның әдәбияты вә сәнгате бик нык үсеп китүе — бәхәссез. Халык күңеленә хуш килердәй иҗат җимешләрен мирас итеп калдырган сәнгатькәрнең даны-шөһрәте мәңгелек.

Ике дә генә буй кыз урак ура,
Үтәр-үтмәс аларның урагы.
Нигә үтсен аларның урагы —
Башларында буй егет уйлары.
Ике дә генә егет печән чаба,
Үтәр-үтмәс аларның чалгысы.
Нигә үтсен аларның чалгысы —
Башларында буй кызлар кайгысы...

## IV баб

### «Кичү»

*«Һәй! Кем белгән инде!*
*Замана тәкъдир итә, дустым, замана...»*
Бакый Урманче,
*1978 ел, 24 декабрь.*

*«Шул гади халык килә инде...*
*Борынгы дуслар килсә-күренсә,*
*күңелле булып китә».*
Бакый Урманче,
*1989 ел, 23 февраль,*
*92 яшь тулган көн.*

Төрле төбәкләрдән, чит-ят өлкәләрдән Казанга килеп, Сәнгать-педагогия техникумына укырга кергән татар малайларын беренче лекцияләрдән соң ук завуч кабинетына чакырдылар. Лекциядән миңгерәүләнеп чыккан студентлар, нәрсәгә чакырганны да сорап-нитеп

тормадылар, завучның иркен бүлмәсенә көндәм генә килеп керделәр. Анда аларны көрәктәй җирән сакаллы, мәһабәт чырайлы, алыптай гәүдәле татар агае әңгәмәгә көтә икән. Авылдан килгән, төрлесе төрлечә киенгән яшьләрне ул ачык чырай белән, нурланып-балкып каршылады, урындыкларга утырышырга кушты. Аннары өстәл өстендә яткан кәгазьләрне әрле-бирле китергәләп:

— Һай, мәхәббәтле егетләр җыелган икән безнең Академиягә!— дип сүз башлады.— Димәк ки, рәссам һөнәрен үзләштерү инде исәбегез? Әфарин! Безгә милли кадрлар бик кирәк. Шунсыз төзеп булмаячак социализмны. Юлбашчыбыз шулай куша. Тик менә әзерлек ягы бик сай икән бит сезнең, белемегез җитәрлек түгел икән, егеткәйләрем... Кәгазьләрегезне игътибар белән карап чыктым чыгуын, ләкин бер дә сөенә алмадым. Тугыз сыйныфны тәмамлаучыларыгыз икәү генә, калганнарыгыз җидене генә бетергән булып чыкты.— Җирән сакал уфтанулы кыяфәт белән беравык башын селкеп алды, аннары инде йомшак түшәп, катыга яткыру хикмәтенә керешге:— Күңелегезгә авыр алмагыз, егеткәйләрем, тик мин сезгә дөресен әйтеп хәлне төшендереп бирергә, турыдан ярдырып сөйләргә тиешмен. Җиде сыйныфта алган белем белән сез бит, газизләрем, лекцияләрне аңлый алмаячаксыз. Моңа, шәт, бүген үк ышангансыздыр. Аптырап утырырсыз, утырырсыз да, берни майтара алмыйча, хыял-ниятләрегезне гамәлгә ашырудан баш тартып, авылларыгызга кайтып китәргә мәҗбүр булырсыз...

Түгәрәк йөзле завуч калын-калын бармаклары белән сакалын аралаштырды, алдында утыручыларны күздән кичерде. Яшьләрнең башлары иелгән иде. Җирән сакал да, уйга-кайгыга калгандай, оеп кына утырды. Аннары тамак кырып алды да нотыгын дәвам иттерде:

— Әмма сезнең өметсезләнеп, өйләрегезгә кайтып китүегез хата булыр иде. Әти-әниләрегез дә сөенмәячәк андый хәлгә, педагогларыгыз да куанмаячак...— Шуннан соң сакалбайның мөлаем тыныч тавышы кырысланып китте, һәркемнең игътибарын җәлеп итәрлек булып ныгыды, көчәйде.— Егетлек булмас иде алай эшләү, күңелегезгә хуш килгән рәссам һөнәреннән, гаять күркәм профессиядән, сәнгатьнең гүзәллегеннән ваз кичү егетлек булмас иде... Алай эшләгән тәкъдирдә, газизләрем, бөтен гомерегез буена үкенеп яшәр идегез... Инде нишләргә? Без менә техникумның директоры белән киңәшләштек тә мондыйрак фикергә килдек.— Завуч, уйланып алгандай, беравык тынып торды, янә шаулатып тамагын кырып алды.— Без болай итик, дусларым. Иртәгәдән сез фәкать рәсем дәресләренә генә йөрерсез. Лекцияләргә кермичә, анын урынына, өстәмә рәвештә оештырылган курсларга йөреп, гомуми белем алырсыз. Мәгәр шуны аңларга тырышыгыз: нәкъ менә сезнең кебек белемгә сусаган яшьләр өчен оештырылган интенсив, ягъни, кыска вакыт эчендә үткәреләчәк әлеге курсларда намус белән, ныгытып укырга тиешсез. Шуны бетергәннән соң, урта мәктәпне тәмамлады дип, һәркайсыгызның кулына таныклык тоттырачакбыз. Шуннан инде икенче семестрда лекцияләргә йөри башларсыз. Янә дә өч-дүрт елдан, иншалла, татар халкының дистәләрчә үз рәссамы булыр. Шуннан инде гомерегезне сәнгатькә багышларсыз...

Булачак рәссамнарның күңелләрендә өмет чаткысы чагылып китте, алар башларын күтәреп җирән сакалга текәлделәр. Завучның ачык зәңгәр күзләре балкып яна иде. Шәхес буларак әнә шул балкуы, дәртләнеп сөйләве белән шәкертләренең хәтерләренә мәңгелеккә сеңеп калды куе җирән сакаллы завуч, мәркәздә сәнгать Академиясендә белем алган, берьюлы ике факультетны тәмамлаган, талантлы сәнгатькәр Бакый Урманче.

Үз гомерендә бер генә эш белән мавыгып, шуңа гына күңел бәйләп, шөкрана кылып ятканы булмады Урманченың. Әле Идрис хәзрәт исән чакта ук Габделбакыйның җырчы булып китәргә нияте юк түгел иде. Чынлап та, шундый көчле мәһабәт тавышын әрәм итеп яткырмыйча,

халыкка илтеп җиткерүе гөнаһ та, гаеп тә саналмас иде. Ләкин олуг хәзрәт өендә укуга — белем алуга аеруча нык игътибар бирелгәнлектән, ун яшеннән үк Казан каласына килеп, мәшһүр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку бәхетенә ирешкән, гәүдәгә таза, типсә тимеренне өзәрлек егет махсус белемсез-нисез генә сәхнәгә чыгып халыкны шаккатыру юлына басмады, андый юлны үзе өчен хурлык санады. Ә инде Мәскәүләргә барып, андагы консерваторияләргә укырга керим микән, юк микән, дип баш ватарлыгы бик бар иде: кече яшьтән үк рәсем ясарга ярата, акшарлы мичне буямый калган көне булмагандыр... Боларның кайсысына өстенлек бирергә? Бүтәннәр җиңелрәк юлны сайлаганда Габделбакый үзе өчен гомерлек хезмәтнең читенрәген, авыррагын сайлады. Укыган чагында да, эшли башлагач та умыртка сөякләрен шытырдап торсын, шунда килер эштән ләззәт, шунда булыр җанга рәхәт!

Инде рәсем сәнгатен сайлаганнан соң да әле моның белән генә чикләнә белмәде: көндезен үзе укыса, лекцияләр беткәч, К. Маркс урамындагы, ул чагында Кахутемас дип йөртелгән Сәнгать мәктәбеннән тиз-тиз алдырып Яңа Бистәгә йөгерде — анда сабыйларны укытты. Сәләтле вә тырыш егетне Мәскәүгә җибәрделәр. Ул анда ВХУТЕМАСта берьюлы нәкышь вә скульптура факультетларында белем алды. Моның белән генә дә чикләнәсе килмичә, шул тирәдәге чит телләр институтына барып, анда инглиз, француз телләрен әйбәтләп үзләштерде.

Казанга кайткач, аны элекләре үзе укыган, ул арада исеме Сәнгать-педагогия техникумына алышынган Сәнгать мәктәбенә эшкә чакыралар. Бер уйлап карасаң, завучның эше генә дә баштин ашкан инде югыйсә, әмма ул әле өстәвенә дәресләр дә бирә: нәкышь һөнәренә өйрәтә. Әле моның белән генә дә чикләнми аның эшчәнлеге, һәм ул университетка укырга керә, җәмәгать эшләренә баштанаяк чума, төрле диспутларда чыгышлар ясый. Аның нотыкларын тыңлаучылар һәрвакыт эрудициясенә, төрле өлкәдән мәгълүматлы булуына, матур тавыш белән, дәртләнеп, искиткеч оста итеп сөйләвенә сокланалар, хәйран калалар.

Нәкъ шушы елларда, СССРның төрки мөселман халыклары латин алфавитына күчәргә тиеш, дигән хөкүмәт карары килә. Безнең җөмһүриятгә моңа җәмәгатьчелек каршы төшә. Җыелышларда трибунага менеп, аеруча дәртләнеп сөйләүче зыялыларның берсе Бакый Урманче була. Аның фикере бик ачык: каллиграф буларак, ул җыйнак, матур, йөгерек гарәп алфавитын яклый, катып калган латин алфавитына каршы чыга. Менә бер заман хөкүмәт карарына каршы авыз ачып сүз әйтергә ярамаганын аңарга ныклап аңлаталар, тәмам төшендереп бирәләр: Сәнгать-педагогия техникумының завучын биш елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәләр. Уттан алып суга салгандай, туп-туры төньякка, Соловкига сөрәләр үзен. Төрле төбәкләргә чыгып, аз-маз рәсем ясаштырып татар малайларын Сәнгать мәктәбенә укырга өндәп йөрүләре дә, ул малайларга олуг өметләр баглап, аларны кадәри хәл милли рухта, үзебезнең сәнгать әһелләре итеп тәрбияләргә омтылуы да, авылның кием-салымнарын, чигүле сөлгеләрен әледән-әле кәгазьгә төшерергә кирәклеген искәрүе-әйтүе дә, җыелышларда Коръән язуы «табагачны» яклап нотык сөйләве дә — болар һәммәсе милләтчелек дип бәяләнә...

Хөкем ителеп, Архангельск янындагы Соловкига барып эләккәч, рәссамны авыр уйлар биләп ала. Шулай бит ул, гәүдәгә нык, дәү кешеләр көтелмәгән хәлләрдән аеруча нык биртеләләр-өшәнәләр.

— Нинди гөнаһ эш кылдым соң әле мин туган илдән шулай ерак сөрелерлек: берәрсен алдадыммы, таладыммы, кибет-мазар бастыммы, кеше үтердемме, җан кыйдыммы? Нинди бәндәгә зыяным тиде икән? Югыйсә бит әдәпле-инсафлы, тәүфыйклы-шәфкатьле яшәдем, гел игелектә иде күңелем...

Тәмам кайгыга сабыша сәнгатькәр, төннәрен күзенә йокы эленми. Беркем белән юньләп сөйләшми, берсе белән дә аралашмый. Гәүдәгә нык, таза булганга аның үзенә дә бәйләнүче-рәнҗетүче күренми. Хәер,

килгән мәлгә бер урыс егете, авызыннан тәмәкесен алмыйча гына, Габделбакыйга сүз кушып карый да соң, юньле җавап ала алмый.

— Син, такыр баш, нигә килдең безнең урыс жиренә? Яулап алырга дип килгәнсең әле!— дип ыржаерга да өлгерми, ларсылдап юеш җиргә барып төшә.

Кәмит карарга яратучылар, бу хәлне күреп, үҗәтләнүче егетнең үзеннән көләләр:

— Нәрсә, жирне үптерәме? Шул кирәк сиңа! Суга алмаган — кусәкнең олысына ябышкан,— диләр.— Икенче бәйләнмәссең кешегә.

Шуннан соң ник берәү бәйләнсен. Ә инде юньле адәмнәр белән ипле генә сөйләшә рәссам, үзен гаять дәрәҗәдә әдәпле тота. Сүз иярә сүз чыгып, үзе дә ачылып киткәли, гәпләшләренең дә кем икәнлекләрен, кайсысының ни хак торганын бик тиз абайлап ала. Бар иде монда тарихтан һәм бүгенге сәясәттән хәбәрдар агайлар да, мәшһүр нәселдән чыгучылар да, бөтендөнья әдәбиятын су урынына эчүчеләр дә, сәнгатьне тирәнтен аңлаучылар да... Вакытын бушка уздырырга яратмаучы Габделбакый анда үткән елларын хәйран оста файдалана — сәнгать Академиясендә алып өлгермәгән белемне шунда ала, тарихны, әдәбиятны шунда өйрәнә, искиткеч зур мәгълүмат туплый; французчаны үзенең ана теленнән әйбәтрәк белгән бер гали зат белән аралашу-сөйләшү нәтиҗәсендә зур практика уза — «телен чарлый». Янә дә бер чөй сакаллы агай аның тавышына игътибар итеп:

— Сезнең тавышыгыз музыкаль, анда вибрация бар. Сөйләшкәндә үк шундый матур тавыш җырлаган чагында бөтенләй үк ачылып китәргә тиеш,— дигән нәтиҗә ясый.

Габделбакый үзендә җырлау сәләте барын һич яшерми, шуңа ук өстәп үзенә махсус музыкаль белем алырга насыйп булмаганын да әйтә. Әллә моңа өлгерми калуына уфтану инде бу, әллә сүз уңаенда тыйнаклык йөзеннән генә ычкындыра, мәгәр чөй сакалның бер дә моңа исе китми. Ул Мәскәү консерваториясенең профессоры икән. Габделбакый татарның ике-өч озын көен сузып кына җырлап күрсәткәч, тәмам сихерләнә картлач, зур дулкынлану белән:

— Моннан киткәндә, егетем, консерватория белемен-культурасын туплап китәрсез. Вакытым җитәрлек моның өчен, теләгегез дә булса, мин сездән бер дигән җырчы әзерлим,— дип вәгъдә итә.— Сездә бит сирәк очрый торган матур бизәкле баритон, үзегез белеп кенә җиткермисез булыр тавышыгызның матурлыгын, кыйммәтен!— дип тә өсти.

Гәрчә әнә шундый талантлы шәхесләр белән аралашса да, туган илкәйдән, гаиләсеннән, яраткан эшеннән аерылып, тоткынлыкта яшәүләре бер дә рәхәт түгел иде, һәркөн җан газаплары китерә. Анда күпме кыен ашаганын Габделбакый үзе генә белә, кичерешләрен берәүгә дә сөйләми, зарланмый. Зарланудан һичбер төрле файда юк. Гәүдәгә саллытаза Габделбакыйга һич кенә ашарга җитми, ул ачыга, ябыга. Тоткыннарның хәллерәкләренә, өеннән ара-тирә передача алганнарына йә рәсем-сурәтләрен ясап бирә, йә башкача күңелләрен күрә, аны да буш итмиләр: ипиеннән булса да өлеш чыгаралар. Габделбакый күчтәнәчкә эләккән ипекәйләрен яшереп, кеше-кара күрмәслек итеп сакларга тырыша иде. Әмма, гөнаһ шомлыгына каршы, әле яңарак кына китерелгән бер тоткын, Габделбакыйның холкын-гадәтен белеп бетермәгәнме, әллә ачлыктан тәкате беткәнме — җирән сакал татарның яшергән ипиенә кул суза бит. Сузуын суза, әмма ник туганына үкенерлек итә аны Габделбакый: измәсен изеп ташлый. Башкалар аралап алмаса, кем белә... эш нәрсә белән беткән булыр иде икән?.. Әйе, Габделбакыйда кысмырсаранлык бар иде, ул үзенекен беркайчан да бирмәс, җае чыкканда, киресенчә, кешенекеннән файдаланырга тырышыр иде. Аның бу сыйфаты, рәссам картая барган саен көчәеп-тирәнәеп, соңгы елларында ямьсез бер күренешкә әйләнәчәген, башка рәссамнарның, аны өнәмичә,

«урвать» сүзенә ишарәләп урванче карт дип урысча йөртәчәкләрен Габделбакый уена да китерә алмый иде, әлбәттә.

Шулай шул... Бөекләрнең, даһиларның еш кына ямьсез-яман сыйфатлы шәхесләр булуы — Табигать-ананың кешеләр аңлап бетермәслек бер середер, мөгаен...

Ел башы — елга башында, дисәләр дә, газаплы еллар ифрат авыр уза. Сабак алырлык иде акылы бар затка, алырлык иде. Һәм Габделбакый ала да. Бу бәләдән котылган тәкъдирдә сәнгатькәр инде бүтән иске ялгышларын кабатламас: үзен мәсхәрә итүгә, бинахак рәнҗетүгә юл куймас, зәһәр ниятле бәндәләрнең кармагына эләкмәс, трибуналарга менеп лаф ору белән һич мавыкмас, яраткан эшен тыныч кына башкарыр — шәкертләренә белем бирер, буш вакытында картина язар, кыскасы, баш-аягы белән иҗат эшенә чумар...

Казанга шундый изге ниятләр, якты өметләр белән кайтып төшә сәнгатькәр. Ул чагында инде әтиләре вафат булып өлгергән, туганнары, гүя очар кошлар, кайсы кай тарафларга очып киткән, монда бер Сафыя гына торып калган иде. Ике абыйсы кулга алынганнан соң күргән-кичергәннәрен Сафыя елый-елый сөйләде. Аның ире дә ачык чырайлы кеше булып чыкты. Ике-өч яшьлек буйчан малайлары дәү абыйсының кулыннан төшмәде. Шулай итеп, Габделбакый сеңелләрендә кунак булды — элекләре үз өйләрендә яратып ашаган ризыкларга тиенде, ичмаса бер күңелләре булганчы сеңелкәе белән сөйләште дә серләште.

Иртәгесен Габделбакый шәһәр буйлап йөрергә дип чыгып китә. Бакчаларны карап йөри, элек үзе таптаган урамнарны җәяүләп кенә әйләнә. Юк, этюд-мазар өчен сюжет эзләми сәнгатькәр, әлегә болай гына йөри. Әмма шулай, кулны кесәгә тыгып йөри торгач, бер заман Кремль янына барып чыкканын абайлап ала. Кремльнең диварларын күрергәме? Сөембикә манарасының гүзәллегенә сокланыргамы? Юк, аларны күреп сокланыр өчен түгел. Һич юк. Хәер, аларны күрү зыян итми инде итүен. Әмма бүген күңелне кытыклап тынгы бирмәгән нәрсә — музей иде, әлбәттә. Әле бер сәгать элек кенә сәнгатькәр моның шулай икәнен тәгаен белсә дә, башын диванага салып, акрын гына атлау ягын карады. Ул чагында әле «музей» сүзен авыз ачып әйтмәскә мөмкин иде. Ә менә хәзер, музейның имән ишеге төбенә килеп җиткәч, диварына килеп төртелгәч, тартәнне кирегә бора алмыйсың. Максатыңны аермачык әйтергә туры килә. Имән ишекне ачып, эчкә үтми хәлең юк. Әлләни зур өмет багламасаң да, сорашу-белешү — бердәнбер юл. Кем белә бит, кем белә! Берәр караңгы почмакта, баскыч астында-мазарда элеккеге берәр эшең аунап ятса, һич югы адашып калган булса... Һай, ни әйттең иде дә бит!

Гәрчә Сабан туенда көрәшкән чакларын онытмаган, хәле-дәрманы булса да, көч-хәл белән генә ача Габделбакый әлеге имән ишекне. Бисмилланы әйтә-әйтә генә, тәти аягы белән атлап керә ул музей бинасына. Кергәч тә әле, беравык туктап хәл ала, башын күтәреп диварларга, мәрмәр баскычларга күз сала. Шул баскычтан кыюсыз гына югарыга атлый.

Анда ул ашыкмыйча гына залдан залга һәммә нәрсәне карап йөри, кечтеки генә үзгәрешне дә сизә, яңа экспонатларны абайлап ала. Шулай акрын-акрын бара торгач, рәссам иң түрдәге киң вә озын залга якынлаша. Йөрәге бер дә урынында түгел, дөп-дөп тибә, күкрәк читлеген җимереп-ватып чыгарга җыенгандай маташа. Акыл белән эш йөрткәндә ул үзенең әсәрләрен күрергә һич өметләнми, фәкать залга аяк басып, киң вә биек диварда аларның эленеп торган урыннарына гына күз салып чыгарга ниятли.

Башын аска иеп кенә түрдәге сәнгать залына уза рәссам. Һәй, бар иде бит бай чаклар, кесә тулы борчаклар дигәндәй, ике-өч көннең берендә менә шушында килеп, иркенләп йөргән заманалар!..

Аның әсәрләре диварда юк, биек вә киң диварда аларга урын калмаган, әлбәттә. Ни хәл итәсең бит?! Кеше үзе өмет итә, замана тәкъдир

итә. Әнә Фешин белән Тимофеевның гүзәл киндерләренә тимәгәннәр, элек элгән көе тора бирәләр, гүя вакытның аларга тәэсире бөтенләй дә юк. Ә менә алар белән янәшә генә иң мактаулы урыннарда эленеп торган «Сепаратор янында» картинасындагы кызыл күлмәкле уңган хатын да, «Сары күлмәкле кыз» да, һич югы Бикбулатов картның портреты да күренми. Алар урынында бөтенләй бүтән, яңа картиналар. Һәммәсе дә сәләтсез түгел икән болай үзе. Әнә ич берәве хәйран ипле генә күренә. Гади генә сюжетны шулай башкарып чыккач, ярый инде ул, авторның киләчәге өметле дигән сүз...

Әнә шул рәвешле, үзенең хезмәтләре вәйран ителүенә тәмам инанып, авыр булса да сабыр гына шушы казаны күтәреп, күңел төшенкелеге белән, гамьсез генә бернинди нәрсәгә юньләп карамыйча гына, зур залны урап чыкты Габделбакый. Янә дә бер-ике адым ясыйм да моннан чыгам инде, дип кенә торганда, имәнеп китә язды. Юк, авторның исеме күрсәтелмәсә дә, әлеге киндернең бер чите күзенә чалыну белән, әллә нәрсә булды Габделбакыйга. Авторы күрсәтелмәгән әлеге картина, һичшиксез, «Кичү» иде. Ана да бит үзенең сабыен тәпиеннән дә танып ала.

Мондый хәлətне шушы көнгә хәтле кичергәне булмый әле Габделбакыйның, гомерендә дә булмый. Шуңа ул хәзер, бөтен җаны-табигате актарылып, үзен күкләргә ашкандай бәхетле хис итә, башлары әйләнеп китә. Гәрчә аяктан егылмый калса да, акылына-исенә килгәндә үзенең елап торганын шәйләп ала. Әйе, үзе моннан алты-җиде ел элек дәртләнеп иҗат иткән, сәнгатькәрләр һәммәсе дә камил дип тапкан, ничәмә-ничә елдан бирле күрергә зар-интизар булып тоткынлыкта яшәгән, әле менә күреп түбәсе тәмам күккә тигән картинасы алдында күз яшьләре түгеп елап тора икән ләбаса!..

Килер вакыт...

Ул вакытларда Габделбакый үзенең озын гомерле буласын да, бинигһая катлаулы иҗат юлын исән-имин узып, сынлы сәнгатьнең төрле жанрларында илаһи зур уңышка-дәрәҗәгә ирешәсен дә, халкым мине үзенең рәссамы буларак таныймы, юкмы, дип аптырабрак яшәгәндә, янә дә илле-алтмыш елдан соң олуг сөенечләр киләсен дә белми әле. Сиксән алты яшен тутырганда нәшрият альбом кадәр альбом чыгарып биргәч, сөенеченнән янә елап җибәрәчәк әле ул! Хәзер инде аның әсәрләре мәңгелек һәм аларны иҗат итүче үзе — үлемсез! Янә дә 90 еллык юбилеен шундый да зурлап Татар академия театрында уздыргач, күңеле тулып елаячак әле сәнгатькәр, елаячак. Халыкның үзен эшкә сәләтле уемчы вә рәссам итеп тануына тәмам инангач, әле ун-унбиш ел элек кенә «Урманче — татар совет сынлы сәнгатенең классигы» дип язган өчен генә дә түрәләр мөхәррирнең күзен ачырмасалар, юбилейда иң дәрәҗәле сәнгать әһелләре дә, иң олы түрәләр дә рәссамны олылап, барысы бер авыздан шул ук сүзне кабатлаячаклар әле, даһи сәнгатькәр диячәкләр әле! Килер вакыт...

Хәзергә утызынчы еллар гына. Һәм рәссам Бакый Урманче музейда үзенең картинасы алдында елап тора.

— И-и-и, газизләрем! Үзегезне сагынып, үләр дәрәҗәдә сагынып кайтканымны каян белдегез? Күр инде, каршыларга көймә белән чыккансыз бит, Идел кичкәнсез бит...

Киңме Идел, тармы — ул барыбер агым су, ул барыбер агудан туктый белмәгән тормыш үзе шул...

Иске Идел үзе тар гына сурәтләнгән. Әллә рәссам сабый чагыннан Зөя суында коенып үскәнгә, аны артык еш иңләгәнгә Иделне дә шундый итеп кенә күрәме, әллә инде пәһлеван гәүдәле, типсә тимер өзәрлек егет Идел хәтле Иделне үзе шулай чамалыймы — әйтүе кыен. Ул заманнардан бирле натурадан ясаган эскизлары, әлбәттә, сакланмаган. Ярый әле картина үзе Черек күлгә төшеп батмаган, исән калган, шунысына сөенергә кирәк. Батса, ни хәл итәр идең? Авторның өметен тәмам өзүе тикмәгәмени?

Иделне көймә белән кичәргә ниятләгән кешеләрне автор үзе өч-дүрт төркемгә бүлгән. Игътибар үзәгендә — әңгәмә корып җибәргән егет белән кыз. Егетнең башында кара кәләпүш, өстендә чем-кара казакин, сау-сәламәт алсу чырайлы, мәһабәт кыяфәтле; кыз яланбаш, ике чәч толымы күкрәгенә төшкән, өстендә ак күлмәк, аягында затлы кара туфли, кулына коңгырт төстәге ридикюль тоткан. Ихтимал, болар бер-берен күптәннән белгән танышлардыр; ихтимал, ирле-хатынлыдыр; ихтимал, очраклы рәвештә генә танышып киткәннәрдер — ничек кенә булмасын, бу парның эшләре инде җайга салынган булырга охшый. һәрхәлдә болар инде парлашып өлгергәннәр һәм Идел-тормышта япа-ялгыз түгелләр, бергә-бергә кичәргә хәстәрләнгәннәр. Икенче төркемдә — башына ак яулык бәйләгән, өстенә сары күлмәк кигән, аягына коңгырт төстәге кәвеш элгән, сул кулына әллә чиләк-мазар, әллә тырыс шикеллерәк бер нәрсә тоткан, уңы белән сабыйны җитәкләгән хатын; малайның түбәсендә коңгырт кәләпүш, колаклары тырпаеп тора, өстендә аксыл күлмәк; зәңгәрсу кыска чалбар; малайның су янына барырга ашкынып тормавын рәссам тартылып баруында күрсәтә. һәрхәлдә, әлеге икәү хәрәкәттә бирелгән; малай — киләчәк кешесе: димәк, әлләни өметсез үк түгел икән әле; көймәче агай болар ышыгында калган, юньләп күренми дә шикелле. Өченче төркем — көймәгә кереп утырган хатын-кызлар; өсбашларын автор контраст төсләрдә биргән; шулар кулындагы кызыл зонтикны да рәссам тикмәгә күрсәтмәгән: ачык зонтик көннең ярыйсы ук эссе икәнен исбатлый, өстәвенә әле ул бердәнбер җете-кызыл, кояшлы тап буларак та хәйран матур вазифа үти. Хәрәкәтне тулырак чагылдыру нияте белән автор болайга табан килүче көймәне дә тасвирлаган; ак пароход та азмы-күпме җанлану өстәү өчен бирелгән.

Бүгенге көндә әлеге киндергә кызыкмаган кеше юк. Хәтта әле рәссамнар да кызыгып куйгалыйлар. Чынлап та җанлы әсәр, бар детале дә җиренә җиткереп эшләнгән киндер. Ә бит рәссам ул чагында утыз яшендә генә була. Әмма инде сабый чакта акшарлаган мичкә мал-туар сурәтен төшерүдән башлап җибәргән, Сәнгать мәктәбендә генә түгел, ВХУТЕМАСларда белем алган, берьюлы икешәр факультетта һөнәргә өйрәнгән, шуннан соң үзенең белгәннәрен Сәнгать мәктәбенә килүче яшьләргә дәртләнеп сөйләгән сакалбай шул заманнарда ук инде профессиональ рәссам буларак тәмам өлгереп җиткәнлеген исбатлап өлгерә.

— Ялкауның аның сүзе күп булыр... Сылтавын табар ул... Юк, бер көн дә эшсез торырга ярамый,— дип авыз тутырып әйтәчәк әле рәссам янә дә илле елдан.

Күргәзмәсенә куелган әлеге хезмәте хакында сүз кузгалса, бүген бәйге тотучы рәссамнарның:

— Бакый абый матур бер пейзажны тоткан да ясаган, философ түгел иде ул!— дигәнен ишеткәч, гарьләнми түзә алмыйсың.

Әйе, Бакый Урманче гүзәллекне күрә дә белгән, үзе күргәнне искиткеч матур итеп тасвирлап күрсәтә дә белгән. Ә бит моның өчен гүзәллекне күреп гашыйк булу, мөкиббән китү генә җитми әле. Моның өчен сиңа зур философ булу, шуннан чыгып фикер йөртү, дөнья вә тормыш кануннарына каршы килмәстәй өр-яңа сюжет кору осталыгына ия булу, янә дә күп нәрсәләр, һичшиксез, зарур. Фәкать шунда гына син тамашачының игътибарын җәлеп итәрдәй камил вә үлемсез әсәр иҗат итә аласың. Шунсыз синең сюжетың котылгысыз рәвештә йә фотографиягә тартым, йә инде бөтенләй фальш, ясалма килеп чыгачак, тамашачы синең эшеңне кабул кылмаячак, ул аңа, гади генә итеп әйткәндә, ышанмаячак.

Әлеге «Кичү» әсәрендә һәр деталь ныклап уйланылган, үз урынына кереп утырган. Төсләр гаҗәеп оста сайланган һәм шуның нәтиҗәсендә табигый бер күренешкә, ягъни сәнгатьчә дөреслеккә ирешелгән. Тамашачы әнә шуңа ышана, рәссам тасвирлаган күренешне тормышта булган хәл дип кабул итә, детальләре хакында уйлана, камиллеккә соклана.

Исенә килгәч, сәнгатькәр ашыкмыйча гына як-ягына күз салды. Аңа игътибар итәрлек, шикләнеп карарлык зат күренмәде. Шуннан соң гына тынычланып калды, иркенрәк сулады, газиз картинасына зәңгәр күзләрен тутырып тагын бер карап алды да чыгу ягына юлланды.

Ул көнне өстенә тау хәтле бәхет ишелеп төшкәч, Габделбакый берәр кешегә сүз кушарлык, музейда эшләүчеләрне күреп, алардан башка киндерләренең хәлен-язмышын сорашыр-белешер хәлдә түгел иде әле. Сөенечен тизрәк өйгә алып кайту һәм сеңлесенә сөйләп бирүдән гайре берни дә килмәде аның башына. Язмыштан һәрчак яманлыклар гына күреп өйрәнгән рәссам шатлыкны күтәрә алмады — күңеле йомшарды, таштай каткан бәгыре балавыздай эреде, күзенә яшьләр килде...

Икенче көнне исә тәртәне туп-туры музейга юнәлдерде, бер дә кыек юллардан бармады, үзен-үзе алдап маташмады. Хәер, моның кирәге дә калмаган иде инде. Музейның авыр имән ишеген җиңел генә ачып керү белән, ишек төбен саклаучы хатынга баш иеп сәлам бирде дә тиз-тиз атлап, өч-дүрт басманы бер итеп, киң мәрмәр баскычтан югарыгы катка менеп китте.

Габделбакый киндергә хәйран ипле салынган буяуның контраст китереп чыгаруына сокlануын яшермичә, бөтенләй яңа, чит кеше язган әсәргә юлыккандай, мөкиббән китеп озаклап карап торды. Ераграк китеп тә, якыннанрак та, уңнан да, сулдан да карады, кеймә белән Идел кичәргә җыенучы каһарманнарына сүз кушты, әңгәмә корып җибәрде.

Тәмам күңеле булганчы «сөйләшкәннән» соң гына, иртән иртүк уйлап куйганча, музейның директорын эзләп китте. Үзгә кеше, бөтенләй күз күрмәгән абзый утыра иде кабинетта. Рәссам гадәтенчә сүзне еракtан башлады, гыйбрәтле бер мәзәк хәл сөйләп түрәне көлдерде. Шуннан соң гына үзенең кем икәнлеген, әле менә сеңелләренә кунакка килгәч тә, музейга сугылмыйча кала алмаганын, яңа экспозицияне бик ошатуын, рәсем сәнгате залында үзенең дә бер әсәрен күреп хәйран калганын сөйләп җибәрде. Иң ахырдан:

— Минем бит сездә янә өч-дүрт картинам булырга тиеш, аларының язмышы ничегрәк икән?— дип кызыксынды.

Әңгәмәдән ихлас канәгать директор:

— Ул сынлы сәнгать белән Алевтина Евлампиевна шөгыльләнә, мин үзем бөтенесенә өлгерә алмыйм, хуҗалык эшләре аяктан ега, аның белән киңәшеп карыйк әле,— дип зарланып алды, бүлек мөдирен телефоннан дәшеп алды.

Кыска чәчен сарыга буяган, өлкән яшьләрдәге ханым Урманчены бер күрүдә танып алды, бик мөлаем елмаеп, йомшак кулын сузды:

— Иске дустыбыз икән ич!— дип рәссамның күңелен үсендереп җибәрде.— Әйдәгез, безнең бүлеккә рәхим итегез, директорда эшегез беткән булса, алып чыгыйм үзегезне,— дип тә өстәде.

Рәссам өстәл аша сузылып хуҗаның кулын каты итеп кысты, рәхмәтен әйтте дә ханымга иярде. Караңгырак коридордан бераз баргач, алар гаҗәеп якты, иркен бер бүлмәгә килеп керделәр. Бүлмәнең тәрәзәләргә каршы ягындагы киң диварны идәннән түшәмгә чаклы тутырып киштәләр, стеллажлар ясалган, аларның төрлесенә төрле зурлыктагы картиналар, рамсыз картон һәм кәгазьләр куелган; урта бер җирдә иләмсез зур өстәл, тәрәзә буенда язу өстәлләре күзгә ташлана иде. Бүлмәдә биш-алты кеше булып, һәркайсы үз эше белән мәшгуль иде.

Габделбакый матур вә көр тавыш белән сәлам биргәч, барысы да башын күтәрде, сәламне алып, ияк какты, сабыр гына җавап кайтарды, кабат үз эшенә күмелде. Бүлек мөдире кунакны култыклап алып, тәрәзәгә кырын куелган, башкаларыннан читтәрәк кукыраеп утырган саллы имән өстәл янына алып килде, биек артлы авыр имән урындыктан урын тәкъдим итте, үзе өстәлнең икенче ягына җайлап кына узып урнашты. Фәкать шуннан соң гына:

— Күрешмәгәнебезгә байтак вакыт узды бугай инде,— дип эшлекле житди кыяфәт белән әңгәмәне башлап жибәрде.— Сезнең кайда булганыгыз, ниләр кичергәнегез, ихтимал, мине бик тә кызыксындырадыр. Әмма ул хакта сораштырып маташу әдәпсезлек булыр иде. Бүген үзегезне иректә күреп сөендем.

Мулла өендә тәрбияләнеп үскән Габделбакый аңа баш ия-ия рәхмәтен белдермичә кала алмады, билгеле.

— Чын-чынлап сөендем, мәһабәт гәүдәгезне күргәч тә,— дип сүзен дәвам иттерде мөлаем ханым.— Казанга кайту хәбәрегезне ишетмәгән идем әле. Туп-туры үзебезгә килүегез өчен рәхмәт. Димәк ки, еллар юшкыны безнең дуслыкка бертөрле дә зыян китерә алмаган. Димәк ки, сез безнең хөрмәтле авторыбыз булып калгансыз. Тик сезнең «Кичү» дигән картинагызда исем-фамилиягез күренмәгәнгә бер дә аптырамагыз, безне гафу итегез. Бүген язуын алмаштырырбыз. Бик сөенеп язып куярбыз исемегезне.

Рәссам шул чагында тыйнак кына елмаеп, моңа үзенең мөнәсәбәтен белдерүне кирәк тапты:

— Алевтина ханым, хөрмәтлем, мине бүген бүтән әсәрләрем, музеегызда калган картиналарым, аларның язмышы борчый. Ә инде исемем язылу-язылмауга килгәндә... мин бит Сөләйман патша кебегрәк фикер йөртәм.

— Без дә белик инде ике бөек шәхеснең сәнгатькә ничегрәк карaганын,— дип елмайды ханым, урындыгында кымшанып алды.

Рәссам рәхәтләнеп елмая-елмая:

— Ихтимал, бик үк сәнгать тә түгелдер инде ул,— дип төшендереп бирергә, тәмам сөйләргә әзерләнде. Бу хәлне күреп, якындарак эшләп утыручы кызлар колакларын торгызды.— Ике хатын килә Сөләйман патша янына, бер бала өчен тарткалашалар икән болар. Минеке дә минеке, диләр икән. Хөкем итүне өметләнеп килгән кешеләрнең гозерен тыңламый кая барасың ди! Бигрәк тә берсеннән-берсе чәрелдәвегрәк хатыннар булганда! Тыныч кына тыңлап утыра Сөләйман патша, үз сабыр гына сакалын сыйпаштыра. Хатыннарның туктарга исәпләре юклыгына тәмам инангач, Сөләйман патша:

— Җәллад!— дип телгә килә.— Чап урталай баланы, икесенә дә тигез итеп бүлеп бир!— ди.

Шулчак хатыннарның берсе:

— Менә әйбәт! Миңа булмаса, аңа да булмасын!— дип каһкаһә белән көлеп жибәрә.

Икенчесе патшаның аяк астына сыгылып төшә:

— Зинһар, һәлак иттерә күрмә баламны! Миңа булмаса булмас, тик исән-имин яшәсен,— дип зар елый...

Бүлек мөдире:

— Димәк, исем-фамилиядә түгел хикмәт, картинаның исән калуында, дип әйтәсездер инде?— дип үзенчә нәтиҗә ясады.

— Рас әйтәсез! Нәкъ шулай. Мине хәзер бер генә әйбер кызыксындыра: музей сатып алган башка әсәрләремнең язмышы ничегрәк икән?— дип, рәссам күңел түрендә яткан борчуны әйтеп салды.

Ханым кунакның хәлен аңлый иде, аны тынычландыру ягын карады:

— Әсәрләрегез исән, бер дә хафаланмагыз,— диде.

Габделбакыйның гәүдәсенә рәхәт бер талгынлык җәелде. Бүлек мөдиренең күзенә карап, житди төс белән:

— Мең яшәгез, Алевтина ханым! Зур сөенеч бу минем өчен, зур сөенеч. Мин ничек тә сезнең алда бурычлы булып калмаска тырышырмын. Безнең халыкта сөенеч дигән сүз — бик олы сүз. Миннән бер этюд үзегезгә! Мең рәхмәт, Алевтина ханым!— диде, нык итеп кулын кысты.

Бүлек мөдире:

— Ай! Кулымны сындырасыз!— дип кычкырып жибәрде, уң кулын беравык селкеп торды, аннары:— Бу чаклы авырттырасыгызны белгән

булсам, авызымны да ачмый утырыр идем,— диде.— Дөресен әйткәндә, миңа әйтергә тиеш түгел сез рәхмәтне, фотографка әйтергә тиеш. Ул егет саклап калды картиналарыгызны. Тагын башка әйберләрегезне дә җыештырып куйды бугай әле...

Габделбакый җанланып:

— Кайсы фотограф? Алар өчәү иде шикелле, хәтерем алдамаса,— диде һәм җавап көтеп ханымның күзләренә текәлде.

— Әйе, өчәү иделәр. Хәтерегез әйбәт, күз тимәсен. Мөхәммәтша дигәнен хәтерлисезме? Әнә шул егет йөрде... сезне кулга алган көннәрдә. Бигрәк тәвәккәл булып чыкты ул егет...

— Хәзер кайда соң ул үзе? Күрәсе иде бит аны.

— Ике көн элек Свияжскига эш белән киткән иде. Бүген кайтырга тиеш иде, нишләптер күренми әле...

Беләгендәге ярыйсы ук зур, хан заманыннан калган сәгатенә күз салып алды да ханым үзенең кунагына:

— Бүген көтүдән мәгънә чыкмас, ахры. Сез аны иртәгә күреп сөйләшерсез. Ә хәзер әйдәгез, әсәрләрегезне күрсәтим,— дип, урыныннан кузгалды.

Әүвәл «Сары күлмәкле кыз»ны таптылар. Анысына сокланып туя алмый гына карап торганда, Бикбулат картның сурәтен шуның янәшәсенә китереп куйдылар. Озакламый «Сепаратор янында» дигән зуррагын да каяндыр тартып чыгардылар.

Габделбакый аларның һәркайсына аерым сөенде. Шуны язгандагы хәлләр исенә төште, натура хәзергедәй күз алдына килеп басты. Әнә «Сары күлмәкле»се — озын итәкле, ачык сары күлмәк киеп, ак алъяпкыч бәйләгән яшь-яшь таза гына кыз; шуның башына бәйләгән яулыгын чиштерү бер газап, җиңнәрен сызгандырту ике, ә инде салам эшләпә кигезү өч газап булды; күзләре бик тере чыккан бит Гыйльменисаның, бит алмалары да бөтен тулылыгы белән, матур гына язылган; кулы да эш кешесе икәненә ишарә; гомумән, кыяфәте килешле генә күренә шикелле... Эчке дөньясы да аңлашыла бугай: эшсез утыру — газап аның өчен, менә хәзер сикереп торыр да йөгереп китәр сыман тоела, һич тә иркенләп, җәелеп утырган тәэсире калмый. Башына бәйләгән чәчәкле-чуклы шәлъяулыгын тоташы белән җете-кызыл итеп алырга туры килде; төсләрнең чарпалашуына ирешә ирешүен, әмма бите бераз тупасрак чыгу ихтималы бар иде, шуңа үзенең салам эшләпәсен кигезеп карарга туры килде һәм әнә шул кечерәк кенә деталь картинаны үзгәртте дә җибәрде, кабатланмас типаж иҗат итү мөмкинлеген тудырды.

Шул чагында салам эшләпә кидермәсә, аннан ике-өч ел гына элек язган, мәшһүрлек яулап өлгергән «Сепаратор янында» картинасындагы сурәтне кабатлыйсы була икән, ә!..

Әле шөкер, интуиция дигән нәрсә кабатланудан качуга этәргән, чибәркәй өчен бөтенләй бүтән позиция сайлауга, өр-яңа сюжет корып җибәрүгә мөмкинлек биргән.

Хәер, «Сепаратор янында»гысы аяк өстендә, яшь ягыннан да шактый олырак. Әмма төсләр ягыннан караганда бу хатынның сурәтендә гармониягә күбрәк ирешелгән — кызыл яулыгы алсу күлмәгенә бигрәкләр килешеп тора.

Бикбулат абзый исән-имин генә йөри микән? Моннан тугыз-ун ел элек үк дәрмансыз бер карт иде инде... Мәгърурлык хисе белән генә берешмичә яши иде.

Музейдан ул көнне бик соң кузгалды сәнгатькәр. Әсәрләрен бер рәткә тезеп куеп, һәркайсының һәр бизәген, һәр ноктасын кабат-кабат җентекләп күздән кичергәннән соң җаннарына рәхәт булып китте. Шуннан инде бүлек мөдиренә рәхмәт хисен белдермичә, күңел түрендә әле бүген баш калкыткан кызыклы бер фикерне әйтмичә калдырасы килмәде:

— Бөтенләй мин иҗат иткән төсле дә түгел боларны. Артык нәфисләр, диимме? Хәзер минем хәлдән килә торган эш түгел мондый картиналар язу...— диде, башын чайкап куйды.

Сәнгатькәрнең эчке халәтен аңлады өлкән яшьтәге, дөнья күргән ханым. Шундый зур укымышлы кеше, олуг талант иясе үзен бүтәнчә тота алмыйдыр инде, дип уйлады. Мөлаем генә елмаеп, ягымлы матур тавыш белән:

— Менә хәзер, үзегезнең иҗат җимешләрегезне кабат күргәннән соң, һичшиксез канатланып китәрсез. Тагын да катлаулырак, тагын да матуррак, тагын да камилрәк картиналар иҗат итәрсез, безне сөендерерсез әле,— диде.

Музей хәтле музейда, сәнгать дөньясында кайнаучы киң күңелле ханымның шулай зур өметләр баглавы рәссамның бәгырьләренә үтеп керде, кай арада күңелләре тулып өлгерде. Әнә шул ягымлы-мәрхәмәтле сүзләр гүя аңарга канатлар үстереп җибәрде: киләчәген нәкышь сәнгатенә багышларга, дәртләнеп эшләргә этәрде.

Яңа көн тугач, ул тагын музейга табан юл тотты. Фотограф егет белән кочаклашып күреште, салпы ягына бераз салам да кыстырып куйгалады — экспозициядәге фоторәсемнәрен күккә чөеп мактады, син хәйран да тирән зәвыклы, ерактан күрә торган фотограф-художник икәнсең, диде. Гәптәшенең түбәсе түшәмгә тигәч кенә, әкренләп үз эшләренә күчте.

Мөхәммәтша киек-җанвар җитезлеге белән әллә кайлардан, киштә башларыннан бер кочак картондыр, кәгазьдер алып төште дә өстәле өстенә, рәссамның алдына китереп салды. Автор аларны саклык белән генә, берәм-берәм генә кулына алды, әйләндереп-тулгандырып карады. Бу юлы да һәр рәсемне, хәтта әле карандаш белән җиңел кулдан ясап ташлаган эскизын караганда да шуны ясаган чактагы хәлләр күз алдында пәйда булды.

Иҗаты киң колач белән гөрләп барган чакта, үз халкыбыздан чыккан яшь егетләрне яраткан һөнәренә чын күңелдән, зур тырышлык белән өйрәтеп ятканда, милли мәдәниятне үстерү юлында армый-талмый чапканда — зинданга яптылар, читкә сөрделәр...

Шул булды эш — сынды кылыч...

Инде менә хәзер, сират күперләрен кичеп, күпме хәсрәт-михнәт чигеп, илгә әйләнеп кайтты Габделбакый. Нияте — янадан Сәнгать мәктәбенә эшкә урнашып, яшь буынны үзенең һөнәренә өйрәтү, милли кадрлар тәрбияләү иде. Сайланып тормаска, нинди эш тәкъдим итсәләр, шуңа риза булырга иде исәбе. Нәкышь һөнәренә генә түгел, Урманче бит әле уем-скульптурага да, шулай ук графикага да өйрәтә ала. Сәнгать мәктәбенә зур өметләр баглап, үзенең бик тә инде менә кирәкле, коеп куйган педагог икәненә ышанган хәлдә барып керә. Әмма сәнгатькәрне яхшы белгән һәм аның сирәк очрый торган күпкырлы һөнәр иясе икәнлегенә инанган түрәләр аны Сәнгать мәктәбенә якын да җибәрмиләр. Эш юк, диләр. Бер генә урыныбыз да буш түгел, диләр — шуның белән вәссәлам!

«Утырмадан» кайтканнан соң Сәнгать мәктәбенә эшкә алмаулары яңадан уйланырга мәҗбүр итә сәнгатькәрне. Еларга да белми Габделбакый, көләргә дә.

— Шулай ук бөтенләй кирәксезгә чыктым микәнни?— ди.

Юньлерәк берәр эш табылмасмы, дип өметләнеп, анда сугыла рәссам, монда сугыла, тик бер җирдә дә рәтле-башлы җавап ала алмый. Аннан-моннан килгән вак-төяк заказларны үтәп, аз-маз гына мая туплый да «чабатасын киенә» башлый: кулларыннан берни килмәгән, эчләре тулы хәсетлек вә явызлык саклаган бу бәндәләр үземне янә мәсхәрә итмәгәйләре, бинахак рәнҗетмәгәйләре, башымны кабат ашамагайлары дип, Казаннан китү ягын карый.

Шуннан ул башкалага барып урнаша, ныгытып эшкә ябыша. Мәскәүдә эш җитәрлек, берсеннән дә йөз чөерми сәнгатькәр, тегә әрәм киткән вакытның үчен тулаем алу өчен, аңарга җиң сызганып, көн-төн эшләргә

туры килсә дә, бирешмәс, гомерен багышлаган сәнгатьтә, һичшиксез, үзенең сүзен әйтер! Коллегаларын хәйран калдырып ул киндерләр яза, картонга акварель белән төрле рәсемнәр ясый, кәгазьгә карандаш яки тушь белән әллә күпме эскиз сызып ата.

Шул замандагы бер вакыйга рәссамның күңеленә бигрәкләр инде хуш килә: тау белән тау очрашмаса да, адәм белән адәм очраша икән ләбаса. Шәрык халыклары сәнгате музеенда ул үзенең яраткан бер шәкертенә тап була.

Ялгышмыйммы, шулмы, дип егетне урап әйләнеп чыга. Тәгаен шул икәненә һичбер төрле шиге калмагач, дөньясын онытып, башын югары күтәреп сәнгать әсәрләрен озаклап караган тәбәнәгрәк егетнең артына төшә дә ике учы белән тегенең күзен томалый. Монда кем булыр икән болай, дип кымшанмыйча да беравык торганнан соң, егет аның кулларыннан арынмакчы да булып карый, тик берни булдыра алмый. Көрәктәй зур кул кемдә булыр? Зәйни абый Солтанов белән Мохтар Мутинда булса булыр. Тик алар бу тирәдә нишләп йөрсен икән? Үзебезнең рәссамфәлән түгелме? Әһә!..

— Бакый абый, син бу, һич тә бүтән берәү түгел!— дип кычкырып җибәргәнен сизми дә кала егетебез.

Музейда кычкырып сөйләшергә ярамаганны исләренә төшерергә килеп җиткән хезмәткәр ханым боларның кочаклашып күрешкәненә шаһит була һәм, авыз ачарга да кыймыйча, үз урынына барып утыра. Остаз белән шәкерт тизрәк урамга чыгу ягын карыйлар.

— Сине күрмәгәнгә мең ел бардыр, Бакый абый. Казанга кабат кайтмадың бугай?— дип остазының кылын тартып карый шәкерт.

Әмма Урманче сер бирүчеләрдән түгел, сынатмый:

— Булмады шул, кайтып җитеп булмады, юк-бар эш белән мātавыкланып калдым шунда...— дигән була, тегенең дә хәлен сораша:— Син соң ниләр бетерәсең мәркәздә? Академиягә-фәлән кермәгәнсеңдер бит, Мирзаҗан?

— Юк, андый зурысына ук үрмәли алмадым үрмәләвен, тик шулай да Сәнгать исемле саллы агачның кечтеки генә бер ботагына ябышып маташам. Казанда бит үзебезнең киностудия ачылырга тора. Шуңа режиссерлар кирәк булачак. Без фәкыйрегез шуңа укып маташа.

— Соң әйбәт ич, дустым! Бик мәгкуль. Татардан беренче режиссер, димәк. Афәрин! Хәзер әйт инде, Мирзаҗан дустым, буш вакытың каламы? Синең белән тел яшереп торып булмас, турысын әйтеп сөйләшик. Миңа ВДНХдан бер бүлекне бизәү эшен йөкләделәр. Әҗере була, әлбәттә, бушлай түгел. Мәгәр бер башыма кыенгарак килгәли, ярдәмчем юк. Буш вакытың калса, дустым, шунда килеп, миңа бераз булышыр идең, димен.

— Һи, Бакый абый, табабыз андый эшкә вакытны. Юк җирдән табабыз. Кайчан килим, иртәгә ярыймы?

Мирза болай үзе, бер яктан күндәм егет булса, икенче яктан, Урманченың үзе шикелле үк уңган булып чыга. ВДНХны бизәгәндә остазына искиткеч нык ярдәм итә. Иң кызыгы шунда, теләсә нинди эшне башкарганда ул укытучысына ярар өчен генә эшләми, бәлки чын-чынлап күңел салып, бик тырышып-үҗәтләнеп башкара. Җитмәсә үзенең белмәгән һөнәре юк: ул сызымны да, уемны да булдыра, карандашны да, кылкаләмне дә иплe йөртә, агач эшләре килеп чыкса — балтага да кулы ята. Аның шулай һәр эшне җиренә җиткереп эшләве Габделбакыйның күңеленә хуш килә. Инде бүлекне һәйбәтләп бизәгәннән соң күп итеп акча алгач, сәнгатькәр дә «егетлек» күрсәтә:

— Син шәкерт кеше, Мирзаҗан, стипендиягә яшисең, читенгә киләдер...— дип, аңа да бераз гына өлеш чыгара.

Шәкертнең фидакярлегенә һәм уңганлыгына мөкиббән китү гомер буена дәвам итәме, үзен аның алдында бурычлы-гаепле итеп тоямы, әллә инде үзен һәрчак өстенрәк, баерак итеп күрсәтергә теләвеме — шулай да

ни сәбәпледер Габделбакый шәкертенең үз акчасына сатып алып китергән һәр нәрсәсенә хакын түләүне исеннән чыгармый. Мирза берәр төрле эш коралы, йә буяу-мазар алып килсә, шундук бирәүдән дә оялып-нитеп тормый, озын-озак сузмыйча:

— Моның хакы ничек булды инде, Мирзаҗан? Ягъни мәсәлән, кесәңнән күпме акча чыкты?— дип төпченә.

Шәкерт исә:

— Аның хакы алай хәтәр түгел, Бакый абый, шалкан бәясе, фәлән тәңкә генә,— дип тиененә хәтле әйткәч, шундук аны бәхилләтә.

Фани дөньядан киткән чагында бала-чага калдырып китүче кеше бик бәхетле: нәселен дәвам иттерәселәренә инана, һөнәрен дәвам иттерүләренә өметләнә. Ә инде шәкертләрен, ягъни дәвамчыларын-варисларын калдырып китүче янә дә бәхетле: үзе гомерен багышлаган хезмәтне-һөнәрне дәвам иттерәчәкләренә, изге ниятләрен халыкка җиткерәчәкләренә — иманы камил.

Кояшның нурларында коенырга
Күнелендә төгәнмәс дәрт бар иде.
Җиһанның шатлыгын күкрәгенә
Туплап, илгә күрсәтерлек шат яр иде.
Җаны саф яуган гына ак кар иде.
Күкрәгендә ташкынлы көч бар иде.
Тоткынлык, түбәнлеккә зур нәфрәт,
Хыянәтче дошманнарга үч бар иде[1].

*Дәвамы бар.*



[1] Б. Урманче шигыре.

# ШИГЪРИЯТ



## Айдар Хәлим

### КИПАРИС КАЙТТЫ ИЛЕНӘ...

**Кырым. Таң ата. Беренче күрешү**

Уянам да... Зәңгәр, зәңгәр!
Таумы шулай, әллә таңмы?
Сикереп торам — һәм җылыймын:
Алда — диңгез, артта — пальма...

Поезд килә оетып кына,
Оетып кына ал таң ата...
Агач уяу: анда төнен
Ишек каккан тавыш ята.

Болыт бушак, галәм кысыр,
Диңгез ятим, хуҗасыз яр.
Хуҗасыз яр — нужасы бар,
Нужасының узасы бар...

Таңга нәрсә? Кысрыклый да,
Болыттан буш сал агыза.
Чәчкәләрнең авызын ябып,
Алдаткыч балын тамыза...

...Кара диңгез оеп кына
Кичәге чүп-чарны «көри».
Кәрзин аскан урыс карты
Ярда шешә җыеп йөри...

*17.06.83.*

* * *

Бар бездә төптән, тирәннән тамыр корытучылар.
Тамыр корытмый торсалар, кулы кычытучылар.

Мин үзем дә тамырлары төптән киселгән имән.
Төптән киселгән булсам да, дошманыма баш имәм.

Килер ул көн, бер чара юк,— гөрселдәрмен йөзтүбән.
Анда да калырмын өстә, тамыр корытучы — түбән.

*17.06.83.*

## Кырым

Җәйрәп ята күкерт-зәңгәр
Кара диңгез.
Дулкын сигез, диңгез тигез —
Безнең нигез
Сезне яшәртергә.
Илдә яшәтергә.

Дулкын тугыз булса, диңгез
Какшый төптән.
Кулым саптым, энҗе таптым —
Гомере үткән
Көтеп сезләрне.
Кара күзләрне.

Тозлы дала, яшел үзән,
Очлы таулар.
Очтан очка, очтан очка
Суздым баулар
Яшьне киптерергә.
Йөзем иктерергә.
Сезгә җиткерергә.

*30.07.86.*

## Диңгезгә

*Фәнзаман Батталга*

Бездә, җирдә, иң тигез җир — чокыр.
Күрәм, син дә түгел тип-тигез.
Кайсы дулкыныңа хокук яулап,
Болай котырасың, әй, диңгез,—
Синең белән мәллә без игез?!

Кайсы дулкын ярга үткәрелми,
Кайсы маяк сүнгән сөргендә?
Кайсы балык тыюлыкта яшәп,

Башкаларны йотып төркемдә,—
Уылдык ул чәчә иркендә?

Бу ахмак сорауга ахак җавап
Эзләп кергәч чоңгылларына,
Тау-тау күбек белән чүбекләнеп,
Күтәрдең дә бәрдең ярына,—
Рәхмәт сизгер мордарларына!

Дау даулап, яу-дага дөпелдәтеп,
Гөрселдәтеп, чыш-пыш сулкылдап,
Дөнья күзе — диңгез — челпәрәмә! —
Өлгеләре — зәңгәр дулкыннар,—
Әбиемнән калган чулпылар.

Чулпыларны тотам дип кул сузсам,
Ярларында чатный күк ташың:
Исерек дулкын Пушкиннардан калган
Тиле орлык ташый — чүп ташый.
Энже диеп аны корт ашый.

Батыр да син, матур да син, диңгез!
Батыр булмый түзмисең икән.
Матурлыкның яшрен хәвефеннән
Син дә мәгънә эзлисең икән —
Шуңа серле күзлесең икән!

...Шәфәкъ ятты — диңгез канга батты.
Күбек дулкын — гүя сарматлар,—
Кабилә арты кабилә упкын төшеп,
Мирасларын даулап, һай-һаулап,
Канда коендыра ак атлар.

Моны диңгез көн дә кабатлар.

*06.08.96.*

## Тйчк малі

*Зөлфия кызыма*

Күктүбәдә, диңгез култыгында,
Фирүзәле ярда, кичкырын,
Су кергәндә, син ун яшьлек кызчык,
«Дәүләт таптым!» — диеп кычкырдың.

Йөгереп килсәм, кулларыңа нәни,
Түгәрәк кара савыт тоткансың,
Капкачта латинча язу күреп,
Тын калгансың — телең йоткансың.

«Тйчк малі»... Төрек малы, димәк?
Күрик, нинди «дәүләт малы» икән?
Борып ачам,— теге ярдан безнең
Ярга чыккан итек мае икән!..

Итек мае — ирек малы түгел.
Без — дәүләтсез Казан баласы —
Горур идек: белеп, мондый малдан
Көлсәк, дингез туңып каласын.

Нинди көлү?! Телсез җыгълый идек!
Без — дәүләтсез төрки-тереклең
Җанын бер сүз белән монга салды
Хәтта итек мае төрекнең!..

Кош тоткандай, аяк очларына
Басып, диңгез аша офыкта
Җан эзләдек: аһ, газиз Төркия!
Күрче, безләр нинди кысыкта!

Алтайлардан Эһей диңгезгәчә
Ирек диеп төрки җан көя.
Йөрәгемне җан җиләгем итеп
Ярдан сузам — син ал, Төркия!..

Төрек малы... Ничә ай, бәлки, ел
Дәрьяда чайкалып, чалулап,
Кайсы дулкын сине безнең ярга
Бәргән — ниткән сизгер давыллар?

Ут-күршебез Мөсаббиха карчык
Кергән кебек бик вак йомышка,
Тимер чикләр аша бу «вак» мал да
Ничек үткән безнең улыска?

Сәвит колы — мин һич аңламадым:
Чын чекистлармы әллә калмаган?
Төрек малын — мондый «шпиун»ны
Ничек чиктә кулга алмаган?!

«Күрмиләрме?» Кулдагы савытны
Яшереп, як-якка карандык.
Гел каранып, без-төрки, ватансыз
Калдык — җиргә үксез таралдык.
Итек мае сыманаралдык.

Кызым, сиңа мин шулай Аң бирдем,
Син шул Аңга илне инандыр:
«Югалттым!» дип аны уйландырма,
«Дәүләт таптым!» дип гел куандыр...

*18.07.86.*

## Казан — Бакчасарай — Истанбул

*(Җыр)*

Кайсы яктан, кайсы тарафлардан
гөлбакчалар хуш ис бөркиләр?
Хуш ис бөркиләр.
Алтайлардан Әдрән диңгезгәчә

жир тетрәтеп үтә төркиләр.

Казан — Бакчасарай — Истанбул.
И-и-и,
Истә булмый диме, истә ул.

Алтайлардан Әдрән диңгезгәчә
жир тетрәтеп үтә төркиләр.
Үтә төркиләр.
Җәйләүләрне бергә җәйлик диеп
төркиләрем куллар селкиләр.

Казан — Бакчасарай — Истанбул.
И-и-и,
Истә булмый диме, истә ул.
Кул селки төркиләр тарихлардан
берләшик дип уртак нигездә.
Мин бүгеннән юлга чыгар идем,
басылганмы давыл диңгездә?

Казан — Бакчасарай — Истанбул.
И-и-и,
Истә булмый диме, истә ул.

*12.08.96.*

## Манара турында баллада

*Бәкер Нематуллаевка*

Бер мәчетсез калган Акмәчет[1]тә,
Алтмышлап елдан соң, урамда,
Бер айлы манара нигезен эзли,
Аһ, манара — даһи дивана!
Илдән чыгарсалар — җилгә кер!
Барыбер илгә кайттың син, Бәкер!

Кичәге талаучы юл күрсәтми,
Хәер сорый. Бирмә син аңа!
«Алсын,— ди манара.— Иман калсын!»
Аһ, манара — даһи дивана!
Күрәш иманга тиң бермә-бер.
Иман белән тере син, Бәкер!

Акмәчеттә тукталыр жир тапмый.
Сусыз таш далада, күр, әнә,
Галәмгә ук булып күтәрелде
Ак манара — даһи дивана!
Аптырама, Бәкер, күп мәкер.
Аерым чыккан җиргә бергә кер!

Ак мәчеткә елышып, йорт бетердең,
Дүрт тарафтан ундүрт эт өрде.
Гаиләңә Манара яшерми

[1] Акмәчет — Симферополь. (Автор.)

Су, ут, нан һәм иман китерде.
Син караңгы төшкәч, өйгә кер.
Нинди яхшы кеше син, Бәкер!

*14.08.96.*

## Дудай маршы

Ир дибез без, ир дигәндә күкрибез: ул син — Җәүһәр!
Җир дибез без, җир дигәндә тетрибез: ул син — Җәүһәр!

Ук дибез без, ук дигәндә күрәбез: ул син — Җәүһәр!
Ут дибез без, ут дигәндә беләбез: ул син — Җәүһәр!

Таш син безнең, яшь син безнең, син һава безнең, Җәүһәр!
Баш син безнең, аш син безнең, син дәва безнең, Җәүһәр!

Син үлемсез, синең кебек Җәүһәрләр мәңге үлми.
Синең рухың ирек даулап, чакыра — гүргә керми.

Безнең терәк, син куш йөрәк — Алладан килгән бүләк.
Җимерелсен империя — шул безнең изге теләк.

*23.04.96.*

## Җәмилә

Кояш мунча яккан ак тауларда,
Ташлар эреп аккан кырлачта,
Кыяга уелган мәгарәнең
Авызыннан эчкә узгач та
Караңгыда сүрән шәмдәл булып
Син шәйләндең... Ышан, Җәмилә,
Синдәй серле, гүзәл җан иясен
Күргәнем юк иде әлегә...

Мөмкинме бу салкын ташкапчыкта
Тын белән ком иләп, күл эчеп,
Кара икмәк, күк чәйдә җан асрап,
Кәҗә тиресендә төн кичеп,
Мөмкинме бу төпсез карашларның,
Бу күзләрнең эчке төрмәсен.
Хан гаскәре булып сакка баскан
Керфекләрнең сагыш сөрмәсен,
Иреннәрнең алсу элпәләрен,
Тешләрнең ак сөйкем-сирпемен,
Талчыбыктай буй-сын, түгәрәк түшләр,
Бармакларның тамчыл төркемен,
Мөмкинме, Җәмилә, хас рәссамдай,
Хансарайны түгел, җир астын
Бизәп, иҗат итү үзеңдәге
Гүзәллекне — милли мирасны?
Һич яшермим, мин буынсыз идем,
Мин зиһенсез идем, Җәмилә!

Шагыйрьләрчә алдыңа тезләнеп,
Ялвардым кайнар дәрт, чәм белән:
— Гашыйк иттең, инде колың да ит,
Синсез яши алмыйм бер көн дә!
Ташла бу тауларны! Идел-йортка
Китик — анда мул да, иркен дә!..

Каһкаһәләп көлдең. Мин тетрәндем.
Җирдән күтәрдең дә: — Юк! — дидең.—
Мин чүлдә сулганда ник килмәдең?
Тауларыма кайткач, ник килдең?
Куышым таш, әмма җылы миңа.
Тәнгә рәхәт — туган яктамын!
Учагымның кара корымыннан
Караймыйм — актан да акта мин!

Чәчкә аттым монда сөргеннәрдән
Очып кайткан зәгыйфь серкәдән.
Никахым да шуңа мәңгелеккә
Тик Кырым-йорт белән теркәлгән...

Син җөп булсаң, мин әлегә такмын.
Тәнем генә минем иректә.
Җаным исә сөргеннәрдән һаман
Кайтып килә — тимер читлектә...

Казаннарга син бездән сәлам әйт.
Дөрес, укымышлы казаннар
Тук яшәү хакына кальбен сатып,
Вакланганнар — ай-һай, азганнар...

...Җир тетрәде шулчак. Кинәт, кочып,
Җангүзәлем — милләттәшемне:
— Чигәмә сук! — дидем.— Соңгы тапкыр
Сөрт күземнән тозлы яшемне!..

*23.08.96. Акчокрак бистәсе.*

# Чәчмә әсәрләр

Рашат
Низамиев



## КАЙТАРЫГЫЗ!

хикәя

*Ир-егетнең йөрәгендә*
*Иярләнгән ат ятыр.*
Мәкаль.

Гомер йомгагы инде сүтелеп тә бара...

Әллә, киресенчә, көннәр җебе яшәү тәгәрмәченә бертуктаусыз уралган саен, бу йомгак отыры зураямы, калыная гына барамы? Хәтта агачларның кәүсәсендә дә бит, әнә, божра-божра булып еллар чалымы өстәлә тора. Шуларны «сүтеп» карый белсәң, никадәрле кышлар-җәйләр, карлар-яңгырлар, үткәннәрнең тагынтагын әллә ничаклы хатирәләре, колач җитмәслек вакыт агышы шәйләнер иде.

Гасыр яшьтәше Шәйхулла карт соңгы вакытларда үзендә ниндидер үзгәреш, сәер халәт, уйларының очы ерак-еракларга китә башлавын тойды. Юк, үлем турында уйламый ул, киресенчә, ничектер менә өр-яңадан яшәп карау кебегрәк бер хис җанында сулкылдый. Нилектән бу? Ул моны аңлата алмый. Аңының тирән төпкелендә моңа җавап та бар кебек, әмма томан белән уратылган бу дөньяның серенә тиз генә барып җитеп булмас шикелле.

Дөнья нәрсә бирде аңа? Инсан затыннан буларак, ул үзе бу җиһанга ни-нәрсә бирә алды? Намусың һәм кешеләр каршындагы бурычың, алыш-бирешең калмадымы — менә шундыйрак сорауларга җавап табылганнан соң гына, картның вөҗүденә тынычлану киләчәк.

...Кичке эңгер-меңгер вакыт. Аннары төн җитеп, авыл өстен серле, җылы, йомшак караңгылык каплады. Сиксән дүртенче елның июнь ае иде бу.

Шәйхулла карт бүген дә озак кына йоклый алмыйча ятты. Уйлары чуалды, чәбәләнде, томан пәрдәсе артында һаман да бер үк вакыйгалар тезмәсе җәйге рәшә сыман тирбәлде.

Өнме бу, төшме, саташумы?

Моны төгәл генә аңлату мөмкин дә түгелдер. Чөнки әлеге сәламәт саташуда төш һәм чынбарлык икесе бергә тәмам бербөтен булып кушылган иде.

* * *

Сәлам түбәле, читән коймалы авыл йортлары заманына күрә үз көче белән тын-салмак кына яшәп ята иде әле. Ләкин күпләр, бик күпләр сизенә — нәрсәдер булачак, тиздән үзгәрешләр шаукымы бәреп чыгачак. Кантоннан килгән вәкилләр һәм авылның башлап йөрүче куштаннары өзми-куймый һаман бер үк сүзләрне кабатлыйлар: илне текә күтәрергә, капкорсак капиталистның борынына чиртергә, аерым хуҗалыкларны берләштерергә кирәк, диләр. Кыскасы, колхозларга өндәү, аны оештыруның куәт алган чагы.

Биш-алты ел элек кенә гаилә корып җибәргән, хуҗалыгы, йортыкаралтысы, аяклы маллары булган егерме тугыз яшьлек Шәйхулла да уйга калды. Җитмәсә, арба-дирбияләре белән бергә, бүген-иртәгә атларны да «калхуз дворы»на җыя башлаячаклар икән...

Нишләргә?

Большевиклар каты куллы күренә, каршы килдеңме, барлык тормышыңны челпәрәмә китереп ташладың дигән сүз. Бәлки, чыннан да, яхшыгадыр әле бу үзгәрешләр. Анда, ил башында, акылсыз кешеләр утырмый лабаса, тормышны яхшыртачакбыз, дип вәгъдә итәләр ич әнә. Бер түбә астына берләшеп, бергә-бергә эшләүләр отышлырактыр да, бәлки? Әмма...

Әмма хәләл көчең белән тапкан мал-мөлкәтне тиктомалдан читкә бер дә җибәрәсе килми шул. Уртак казанда пешкән ботканың мае — кашыкны кем алданрак төртсә, гадәттә, шуның ягынарак агып төшүчән. Уртак малны эт ашамас, дигән бит бабайлар. Гаделлекне, тигезлекне кем саклар соң, ызгыш-талаш оясы булмасмы бу калхуз дигәннәре?..

Сораулар күп, вакыт дигәнең исә аз иде. Әнә шулай җан тартышы, шик-шөбһәләр арасында бәргәләнә торгач, ниһаять, Шәйхулланың кәләпүше астында бер карар өлгереп җитте.

Шулай ук эңгер-меңгер, җәйге кич, җан җылымлы июнь ае иде...

Шәйхулла, кеше-кара күзенә күренмәскә тырышып кына, җигүле атын урманга таба куалап китте. Урман якын, авылдан бер чакрым чамасы гына. Урманга якынлашыр алдыннан ул янә бер кат кабык арба төбенә салынган көрәген барлады. Шөкер, урынында. Юкса эше көрәксез барып чыгачак түгел ич аның. Арбада, инде теткәләнә башлаган торышша астында, ботаклы агач түмәрне хәтерләткән тагын бер нәрсәкәй бар. Аның агачтан түгел, тимердән ясалган икәнлеген арба хуҗасы үзе генә белә.

Урман битараф каршылады, эчкәре кергән саен эңгер-меңгер куера төште. Чү, агач кәүсәләре арасында шомлы күләгәләр чагылып китә түгелме? Ат — үтә сизгер хайван, аңа ышанырга кирәк. Җирәнсу атының бер дә икеләнмичә, тәртәгә типмичә генә тыныч атлап баруы күңелдә ышаныч уятты. Менә шуңаргамы, Шәйхулла тиз тынычланды. Аннары мондагы уймак-уймак аланнарны, һәр түмгәкне дигәндәй яхшы белә бит ул. Балачактан утынга дип коры-сары җыярга йөргәләде, әтисенә печән чабышты.

Урман юлы, ниһаять, уртасында бер ише чикләвек куаклары үсеп утырган аланга алып килде. Шәйхулла, атының аркалыгын бушатып, аңа үлән утларга ирек бирде дә арбада яткан көрәген кулына алды. Кич аяз, күктә болытлар булмаганлыктан, тирә-юньдәге биек агачлар ачык төсмерләнә иде.

Әнә ул яшь, чибәр, гайрәтле, янәшә-тирәсендәге агачларны узып китеп, күккә төртелгән таныш имән!

Шәйхулла кыю-тәвәккәл хәрәкәтләр белән әлеге баһадир имән төбеннән көньякка таба ун адым атлады да туктап калды. Көрәген җиргә кадады. «Урын шушында булачак!» Уйлары алга таба йөгерешә... Ике аршин чамасы итеп, чирәмле кәсләрне ватмый-җимерми генә, иң элек җирнең өстен бер кырыйга аласы булыр. Ярты метр чамасы казып төшкәч тә, чокыр әзер дигән сүз. Аннары инде җанга якын хәзинәне һәйбәтләп күмәсе-яшерәсе дә, Аллага тапшырып, кире кайтып китәргә генә кала.

Юк, кабер түгел бу... Җансыз әйберләрнең кабере була димени? Ә менә күңеленең кайсыдыр почмагында яшерен бер «кабер» уелып калачагын, еллар үткәч, картаймыш көндә аның кыймылдап куячагын Шәйхулла белми иде, билгеле...

Урман туфрагы мамык кебек йомшак.

Көндездән үк кайралган үткен көрәк өчен куак тамырлары да әлләни мәшәкать тудырмады. Чокыр дигәнең, кара авызын ачып, табышын көтеп, серне йотарга әзер булып тора.

Бер читтәрәк утлап йөргән атның аркалыгын янәдән күтәреп, Шәйхулла дилбегәне кулына алды. Йомшак үләннәр өстеннән барган тәгәрмәчле арбаның тавышы ишетелми диярлек. Чокыр янына килеп туктагач, ат хуҗасы торыпшаны сыңар кул белән генә әйләндереп ачты һәм ай яктысында төрәне ялтырап яткан тимер сабанга үрелде. Күпме буразналар сызган, эшли-эшли әнә шулай ялтыраган, күңелгә бик тә якын сабан иде бу.

Авылдашлары арасында Шәйхулла эштән-мәшәкатьтән курыкмый торган җегәрле ир-егетләрдән санала. Булсынга дип эшләде, әтисеннән калган йорт-җирне түгәрәк тотарга тырышты. Аяклы мал үрчетеп, иген үстереп, шуларны сатып, акча маясы туплавы бер дә юкка түгел иде. Тотты да көннәрнең берендә Теләче базарыннан төрәнле, кулсаплы сабан — тимер сука алып кайтты... Ай, аңардан күргән рәхәтлекләр! Атка тагасың да басудагы кишәрлеккә чыгып китәсең. Җирне, туфракны гөпердәгән мамык итеп актара да сала теге. Туган-тумача, күрше-тирә сорaганда вакытлыча биреп торудан кызганмады сука хуҗасы.

Менә шундыйрак тарихлы сука иде ул.

«Калхуз оештырабыз»,— дип кайберәүләр авыз суы корыта башлагач та нык уйланды Шәйхулла атлы ир-егет. Өстән, керү ирекле, дип әйтелсә дә, вакыты җиткәч, кыса-ашыктыра белде кызыл авызлар. Яңа оешып килгән «Күмәк көч» колхозы рәисе Мөҗип абзый Шәйхулланың ишегенә дә кагыласы итте. Янамады-нитмәде, ләкин тел төбе аңлаешлы иде.

— Сузма, әйдә, егетем,— диде ул, чакырган чәйгә дә кермичә, баскыч төбе аша гына сөйләшеп.— Бергәләп эшләрбез, яшәрбез, югалмабыз әле. Өстән кушалар бит. Совиткә каршы килү файдасыз... Җилгә каршы төкерү ярамас.

Шәйхулланың күңеле тулы икеле-микеле уйлар иде ул чакта.

Ат — әнә түгел сиңа, аны салам арасына яшереп булмый. Бирми нишләрсең, килешәсе булыр... Ә менә тимер суканымы?... Хәйләсен табарга, аны ничек тә бирми калырга кирәк! Беренчедән, бигрәкләр дә кадерле нәрсә ич ул Шәйхулла өчен. Икенчедән, кем белә, бу үзгәреп торучан заманада «айт» урынына «вайт» дип кычкырсалар, калхуз тәзүне туктатып куйсалар, эзләп табарсың аннары тимер сабанның сыңар тәгәрмәчен!..

Тизрәк урманга, ялгызрак урынга ашкынуының төп сәбәбе әнә шул иде.

* * *

Тимер суканы чокырга этеп төшерү әллә ни кыен булмады. Эшли-эшли шомарган төрән калагында янә ай нурлары ялтырап китте. «Әллә ай нурларын да җиргә күмәм инде?» Көрәге белән балчыкны ишә башлаган ирнең күңелендә әнә шундыйрак сәер уй чагылып узды. Аны бу уйларыннан аралыйсы килепме, кинәт баш очыннан, сискәндереп, төнге кош очып үтте. Канатлары белән һава сызгырта-сызгырта, аның артыннан ук дәү ябалакның атылуы гүя ки бу эшне тизләтергә куша иде...

«Хуш тимер сука! Бәлки әле очрашу насыйп булыр?»

Күңелдән генә, эчкәре бер моң белән шулай әйтелсә дә, тиз генә очрашулар насыйп булмаган икән шул. Үләнле кәс кисәкләре тимер суканы озакка, бик озакка җир белән тигезләп куйган икән ул чакта.

Икенче көнне, чынлап та, калхуз утарына атларны җыю, туплау, урнаштыру башланды. Күпләр бахбайларын теләр-теләмәс кенә үзләре китерделәр. Сузып-икеләнеп торучыларның өенә тиз арада «чабаталы активистлар» килеп җитте. Көнозын кырмыска оясыдай кайнады авыл, искелек белән яңалык көрәше һәркемнең язмышы һәм йөрәге аша сызылып узды. Көн уртасында Шәйхулла куе чәй төсендәге җирәнсу атын арбага җигеп кенә өлгергән иде, җилкапка ачылып китте. Анда, бернича активист белән, рәис Мөҗип агай күренде. Йорт хуҗасының күзләрендә сабырлыктан гайре рәнҗү-мазар күрмәгәч, турыдан әйтеп салды:

— Мин бит сине беренчеләрдән килерсең дип уйлаган идем, Шәйхулла, ә син, панимаешь...

— Үземнең дә исәп шулайрак иде, Мөҗип абый. Тик менә йорт-кура тирәсендә мәшәкать бетәмени? Күрәсең, әзерләнеп ятам ич.

— Ярый, соң булса да уң булсын алайса. Дирбияләрең тәртиптәме? Юкса анда ярлы Хәләй китергән йөгән-дилбегәләрне күрсәң, исең китәрлек. Тоткан җирдән өзелергә тора...

— Юкны кайдан алсын инде ул?— дип җаваплады Шәйхулла, авылдашын ни акларга, ни якларга белмичәрәк.

— Ярый. Менә синең кебекләр барында калхузыбыз бик тиз аякка басар, иншалла.

Шушы сүзләрдән соң рәис ни өчендер тукталып калды. Тамак кырып алгач, сүзен дәвам итте, тавышы көр һәм таләпчән иде:

— Безгә шәхси милекчелектән мөмкин кадәр тизрәк котылу кирәк. Партия шулай өйрәтә, берлектә — көч, ди. Калхузга кергәч, сиңа инде тимер суканың да кирәге бетәчәк. К-хым-м... Кат-кат йөрегәнче, син инде анысын да арбаңа салып дворга алып төшәрсең!

— Мөҗип абый! Үзем дә әйтергә җыенып тора идем,— диде Шәйхулла.— Ни бит әле...

— Нәрсә ни бит...

— Нәрсә дип, шул тимер сука турында инде. Мин аны, гадәттә, абзар артында тота идем. Урлаганнар...

— Ничек алай?— диде рәис, гаҗәпләнеп.

— Белсәм кем урлаганын, үз кулларым белән якасыннан тотып селкер идем!

Сүзенең азагында рәис болай диде:

— Кара аны, Шәйхулла, шаяртуың яисә ялганлавың булса, икебезгә дә җавап тотарга туры киләчәк.

— Шаяртыр чакмы соң, Мөҗип абый!

— Дөрес әйтәсең, хак монысы. Әмма авылда караклар үрчетүгә юл куймабыз...

Ничек керсәләр, шулай тиз генә китеп тә бардылар. Башкаларны агитлау өчендер инде.

Әйткән сүзләрен онытмаган икән рәис. Икенче көнне үк кайдандыр ике милиционер килеп, Шәйхулладан озак кына сорау алдылар. Абзар-куралы энә күзеннән үткәрделәр. Якындагы унбишләп йортны тентеп-тикшереп карасалар да, берни тапмадылар. Куркып калды Шәйхулла, эшләрнең болай ук тирәнгә китәсен күз алдына да китермәгән иде ул. Бәхетенә күрәме, әллә инде тегеләрнең башка эшләре күп булдымы, әллә югалган сука белән вакланасылары килмәдеме, ике милиционер бүтәнчә килеп борчымады.

Көн үтә торды.

Илдә күп нәрсәләр көне-сәгате белән дигәндәй үзгәрә иде.

Халык, гигант төзелешләрне күреп, бер яктан, илебез үсә-яңара дип шатланса, икенче яктан, гавамдә өске түрәләрдән, сәясәттән курку зәхмәте дә ифрат көчле иде. Илдә менә шушы ике хис, ике юнәлеш алмаштилмәш кайнаша иде.

Шәйхулланы колхозга ат караучы итеп билгеләделәр. НиШләсен, тотты да эшләп китте. Атларга башак болгату, ечән салу, су эчерү, асларын җыештыру, эштән кайтканнарын көтеп, аранга урнаштыру — болар һәммәсе дә аның җилкәсенә төшә торган көндәлек мәшәкатьләр.

Атлар арасында, ни әйтсәң дә, иң яратканы үзенеке иде. Җирән кашка үзе дә ерактан ук хуҗасын танып ала, иреннәрен медер-медер кыймылдатып, күзләрен мөлдерәмә тутырып карый. Өйдән ияреп килгән бәрәңге кабыклары, каткан ипи катысы — һәммәсе аның өчен. Печән-клевер ишене дә күбрәк салырга тырыша аңарга. Ул елларда атларга исем кушу гадәте әллә ни юк әле. Кирәге чыкканда, элеккеге хуҗаларының исеме белән атап, «Бикмулла аты» яисә «Сиражи аты» дип кенә сөйләшәләр.

Берсендә шулай каравыл өендә гәп корып, тәмәке пыскытып утыралар иде, кемдер кер-керешкә үк:

— Шәйхулла, атың колынлаган! — дип сөенче алды.

«Шәйхулла аты», ягъни аның элек-электән үз куллары белән сөеп, иркәләп үстергән Җирән кашкасы колынлаган!.. Ул моны инде байтактан бирле көтә иде. Менә бит, хәере белән булсын, җирәнсу малкай үзеннән соң токым калдыру кирәклеген дә онытмаган. Маладис аңа! Әмма нәкъ әнкәсенә, аның кечерәйтелгән сурәтенә охшаш бу колынкай нигәдер чирләшкәрәк туды. Заман шаукымына ияреп, атын бирде Шәйхулла, әмма колхозга колын биргәне булмады ич аның! Менә шуңа да үзенекен — үз колынын төнлә урлап кайтырга ныклап план корган иде ул баштарак. Уйлады-уйлады да, гаиләсен жәлләп, бу ниятеннән кире кайтты. «Контр!» диячәкләр — и вәссәлам... Ат карауның рәтен белгән Шәйхулла ахыр чиктә колынны бирәр айга гына булса да өендә тәрбия кылырга талпынып караган иде, тик кырыс холыклы Мөҗип рәис ике сөйләшергә урын калдырмаслык итеп әйтте:

— Син нәрсә, егетем, инде оешып беткән калхузны киредән таратырга җыенасыңмы? Партия моңа юл куймас! Контр сүз сөйләп үзеңне дә, минем дә язмышымны куркыныч астына куйма. Сүзем шул сиңа...

Аннары өстәп куясы итте:

— Теге чакта син тимер сукаң белән дә матавык чыгарып аптыраттың безне. Ярый әле эшне зурга җибәрмәделәр. Кара аны, алга таба ыштубы тәртип булсын!

Хаклык бар иде рәиснең сүзләрендә.

Сука димәктән, Шәйхулла аны ничек тә онытырга тырышты. Казып чыгардыңмы, кая куясың аны? Ә инде әгәренки кем дә булса күрә калса, идарәгә барып әләкләсә... Әһә, яшереп калдырырга теләгәнсең, калхузга каршы кеше, контр икәнсең, дип күзен дә ачырмаячаклар. Шуның белән генә тукталып калсалар ярый да бит... ГПУдан килсәләр, зинданга ябып куйсалар... У-у, уйларга да куркыныч!

Бер килсә килә бит ул, инде колын чирләшкәлеген җиңеп, тәмам үсеп-тазарып җитте дигәндә, әнкәсе көтелмәгән бәлагә юлыкты. Ул көнне «Шәйхулла атын» рәис ярдәмчесе җиккән иде. Ниндидер йомыш

белән күрше авылга бара, янәсе. Тегеләрнең күпере ташка үлчим булган күрәсең, барган шәпкә атның аягы ике бүрәнә арасына кысыла да шартлап сына... Мал врачы да, Шәйхулла үзе дә күпме тырышып карамасыннар, малкайны аякка бастыра алмадылар. Ул күзгә күренеп сула бара иде. Аны иткә озатудан бүтән чара калмады. Хушлашканда дымлы, түм-түгәрәк күзләреннән энҗе-энҗе яшь бөртекләре тәгәрәп төшкән иде бичаракайның...

Атлар кешеләргә күрсәтми генә елый, дигән сүзләр дөрес түгел икән.

Үз гомерендә күпне күрергә, күпне кичерергә туры килде Шәйхуллага. Ерак бер татар авылыннан хәрби хезмәткә чакырылып, фин сугышы кампаниясенә дә эләкте ул. Кыш иде, зәһәр салкын иде. Киез итекләр, сырма-бушлатлар гына җылыта алмагач, кар эченә күмелеп җылыналар иде. Бу сәер сугышта атлар белән дә очрашырга туры килде аңа. Бил тиңентен кар диңгезен ерып, алгы сызыкка йөге-йөге белән патрон, снаряд тартмаларын ташыйлар, мескенкәйләрем...

Нишлисең бит, сугыш кырында кануннар шулайрак инде: канлы бәрелешнең юнәлешен картада генераллар билгели, ә инде үлем белән якалашу исә кече офицерлар һәм солдатлар җилкәсенә төшә. Гитлер Германиясе белән бәрелешнең уртасына килеп эләккән Шәйхулла солдат бу ачы хакыйкатьне тиз аңлап алды. Әмма, матур киләчәк хакына, Ватанны фашизм афәтеннән коткарырга кирәк... Мәскәү яны сугышларыннан алып Кенисбергка кадәрге утлы чакрымнар — сержант Шәйхулла Сәйфетдинов үткән сугышчан юллар бу.

Танклар, артиллерия, авиация, тагын әллә ничаклы сугыш кораллары катнашсын, ләкин сугышта атлар да һәрчак кирәк икән. Һаман да шул тартмаларны, азык-төлекне, һәм, ниһаять, яралыларны яу кырыннан ташу өчен. Атларны да сугышка алалар икән шул. Кешеләр үлеменә караганда күкне тешли-тешли җиргә гөрселдәп авып төшкән атлар үлеме күпкә кызганычрак иде аңа кайчакта... Сугышлар тынып торган арада Шәйхулла авылын да, гаиләсен дә, хәтта җирәнсу аты бүләк итеп калдырган колынны да сагынырга вакыт таба иде. Ул бит инде киң күкрәкле айгыр булып җитешкәндер. Аны да сугышка алганнардыр, бәлки? Исән микән ул?

Өйләнеп кайткач белде Шәйхулла: айгырны чынлап та сугышка алганнар икән. Кайларга китеп, ничек гаип булгандыр ул — моны белүче юк иде.

* * *

Әнә шундыйрак саташулы төшләр күрде бүген Шәйхулла карт. Дисбе төймәләрен тарткандагы сыман, ничәнче тәүлек инде менә шушы вакыйгаларны берәм-берәм хәтеренең бу ягына таба авыштырырга тырышты.

Яшәүнең, үткәннәрнең кыйммәтен гомер бизмәнендә үлчәп караудан да кыенрак эш юктыр, ахрысы.

Уйлаган уйларының очы һаман да бер тирәгәрәк барып чыга: бу тормышта нидер эшлисе калган түгелме соң аның?..

Калган, әлбәттә!

Җавап табылганнан соң, ул таралып яткан уйларын янә бер кат тәртипкә китерде, ни эшләргә тиешлеген җентекләргә кереште. Хәзер инде уйлары гаҗәеп дәрәҗәдә аек, төгәл һәм аермачык иде.

«Барам, бернигә карамыйча барам,— диде ул, үзенчә бер үҗәтлек, ышаныч белән.— Сөйләп бирермен... Аңлар, аңламый калмас. Ул да бит Хода бәндәсе... Тиешлесен сорарга баруым лабаса. Тиешсезен таләп итүем түгел... Нәфесен тыя алмаган, дип берәү дә авыз чайкамас, шәт иншалла! Яшәмәдем түгел, яшәдем... Булган көчемне, хезмәтемне илгә,

кешеләргә бирдем... Тиешлесен таләп итәргә минем дә хәләл хакым бардыр ич? Сорамый калсам, гомерлек үкенеч булыр бу... Көн каршында бурычым да бар бит әле. Аннары инде алыш-бирешне үтәү дә кыен булмаячак... Хәерле сәгатьтә!».

Сакал-мыегын төзәтеп, кырынып алганнан соң карт җылы су белән тәһарәт алды, тагын бер кат бит кулларын юды, юылган күлмәк-ыштанын киде. Аның рухы күтәренке, тәне чиста, уйлары пакъ иде.

Шушы биеклеккә күтәрелү өчен ничә көннәр буе әзерләнде, ничә төннәр буе күңел газабы кичерде бит ул!

...«Күмәк көч» колхозының исемен өч тапкыр алыштырдылар. Гитлер дигән явызны җиңгәннән соң, Сталин исемендәге колхоз дип үзгәртелде ул. Әмма шәхес культы дигән нәрсәне фаш итеп ташлагач, инде бу исемнең дә кирәге калмады.

Инде менә «Коммунизмга» дигән өченче исеме белән яшәп яткан колхозның бүгенге рәисе — кырык яшьлек, басса бакыр изәрдәй, тотса тимер өзәрдәй булдыклы егет — Шәйхулла картка өченче буыннан чыбык очы тиешле Мортаза Гайнуллин иде.

Әлерәк кенә нәрәд биреп, әйтәсе сүзен әйтеп, кул астындагы гаярь егетләренең җилкәсенә яңа бурычлар өеп, ялгызы гына калгач, нервыларын тынычландыру өчен ул «Беломор» папиросын тәмләп кенә тарта башлаган иде. Шул чакны колхоз идарәсенә килүче Шәйхулла картны тәрәзәдән күреп алды. «Туган тиешле кеше, өлкән кеше, хезмәт һәм сугыш ветераны, аның алдында килешмәс»,— дип, яртылаш көлгә чыгып барган папиросын ярангөл төбенә басып сүндерде дә эш кәгазьләренә чумган кыяфәт ясады.

— Мөмкинме? Әссәламегаләйкүм!

— Вәгаләйкем әссәлам. Әйдүк, Шәйхулла бабай! Синең өчен безнең ишекләр һәрвакыт ачык!

Күрештеләр. Шәйхулла карт рәис каршындагы урындыкларның берсенә елышып утырды. Хәл-әхвәл, исәнлек-саулык сорашканнан соң, бабайга транспорт яисә печән-мазар кирәктер инде, дигәнрәк уйларын бер читкәрәк куарга тырышып, төгәллек яратучан Мортаза барыбер күпләр алдында әйтелә торган соравын кабатларга мәҗбүр булды:

— Ни йомыш соң, Шәйхулла бабай?

Уйларын тәртипкә китерергә теләгәндәй, Шәйхулла карт беркавым тын торды. Аннары гына гозерен-үтенечен турыдан-туры әйтеп салды:

— Беләсеңме, улым... Миңа ат кирәк!

Мортаза канәгать бер кыяфәттә рәхәтләнеп елмайды, ике кулын саллы өстәле сыртына куя-куя әйтте:

— Суң инде, Шәйхулла бабай, анысын гына табарбыз. Кирәк булса машинасын да... Проблема булмас. Кайчан кирәк, ничә сәгатькә?

— Мин бит ничәдер көнгә яисә фәлән сәгатькә сорамыйм. Бөтенләйгә соравым.

— Ничек инде бөтенләйгә? Иткә, көзлеккә сугымга соравың што ли?...

Карт яңадан тәнәфес ясап алды, кызмыйча-ашыкмыйча гына гозерен тәфсилли башлады:

— Беләсеңме, улым, күмәк хуҗалык оешкан чакта... ягъни моннан илле биш ел элек, мин арбасы һәм дирбияләр белән жирәнсу атымны калхузга тапшырган идем... Йөрәгемнән өзеп. Менә шул: атны кире кайтарыгыз миңа.

Яшь кенә булса да, инде байтакны күргән Мортазаның чәчләре кыймылдап куйды, маңгаена махмырдагы сыман салкын тир бәреп чыкты.

«Ничек инде болай?.. Бабайның акылы бераз гына алышынган, ахрысы»,— дип уйлады ул беренче мәлдә.

— Әллә кайчангы атларны сөйләмәсәнә, Шәйхулла бабай! Болар бит инде тарихта калган...

— Тарихта түгел, йөрәктә калган, улым. Йөрәк авыртуларына түзмичә килдем дә инде менә. Әле сез тумаган да чакта калхузны без оештырдык. Шуңа күрә сорарга хакым бардыр лабаса!

Мортазаның уйлары бөтенләй бүтәнчә яккарак борылып киткән иде. «Фетнә бу, фетнә! Ничек инде көпә-көндез илгә, хөкүмәткә, партиягә каршы шулай сөйләргә мөмкин? Җитмәсә, үз нәселең кешесе... Элегрәк булса, моның өчен башың Себер китәр иде... Хәзер дә күп сорамаслар... Бу картны ничек тә җайларга, уртак бер килешү табарга кирәк. Райкомда бу сөйләшүне белсәләрме — иртәгә үк артыңа тибеп озатачаклар...»

Мортаза калын бармакларын өстәл өстендә биетеп алды.

— Шәйхулла бабай, әйдәле, егетләрчә ачыктан-ачык сөйләшик. Бу яшеңдә нигә кирәк соң ул сиңа ат?

— Кирәк шул, бик тә кирәк... Әгәр кирәге булмаса, болай борчып йөрер идемме үзеңне!

— Атны кайтар, имеш... Син бит болай мине һәм гаиләмне куркыныч астына куясың. Аңлыйсыңдыр шуны. Малайларың Чаллыда, КамАЗда эшли. Безнең бу сөйләшүне өстәгеләр белә калса, аларның да башыннан сыйпамаслар.

— Мин бит атымны Чаллыга да, КамАЗга да түгел, калхузга бирдем... Шуны сорарга хакым бардыр ич ләбаса! Мин бит артыгын сорамыйм, үземнең малымны гына сорыйм...

— Тиеш нәрсәләр күп лә ул дөньяда...

— Менә шул шул. Тимер суканы бирмәдем ул чакта. Анысын сорамыйм ич.

— Нинди сука тагын?

Шәйхулла карт артыгын әйтебрәк җибәргәнен чамалады. Сүз сөрешен читкәрәк җибәрәсе итте:

— Ярый да сез хәзер эскерт чаклы тракторларны эшкә җиктегез. Элек бит буразнаны кул сукасы белән яралар иде...

— Үткәнне сагынудан ни файда? Хәзер — техника заманы. Аны мин уйлап чыгармаган...

— Монысы дөрес, улым. Бәхәсләшмим. Ләкин миңа ат кирәк! Колхозың бер аттан гына үлмәс әле...

— Синең арттан башкалар да сорый башласа, нишләрбез?

— Сорамаслар... Калхузны ул чакта оештырып йөрүчеләрдән бүгенге көндә мин берүзем калып барам бугай инде...

— Шул атны алып кына баерсыз микән соң, Шәйхулла бабай?

— Ә менә сез, ат кадерен белмәгәннәр, баерсыз микән? Мин баер өчен туган җан идем дә бит, әмма заманында ирек бирмәделәр. Бүген исә байлык туплау өчен гозерләнүем түгел, кирәктән соравым...

Бу сөйләшүдән бик нык гаҗәпләнеп калса да, Мортазаның уйлары аек иде.

— Шәйхулла бабай! Аңла инде, бу бит партиягә каршы килү булачак. Анда миңа рәхмәт әйтмәсләр...

Менә шушы сүзләрдән соң гына Шәйхулла картның күңелендә ниндидер борылыш ясалды. Чынлап та, нигә әле бер гөнаһсыз кешене, үзенең тумасын куркыныч астына куярга тиеш ул? Акыллырак булырга кирәк. Сүз сөрешен үзгәртү фарыздыр, бәлки?

Ниндидер могҗиза белән Шәйхулла карт үзенең иләс-миләс күңелендә яңа сүзләр эзләп тапты, хәйләгә таба китте:

— Ни бит, угълан... Картаймыш көнемдә ат җигеп, арбага утырып, яшьлек эзләремне гизеп чыгасым килә минем. Ат соравымның бөтен хикмәте шунда. Үкенечкә калмасын, дим...

Бу урында Шәйхулла карт тәмам елап җибәргәндәй булды, әмма күз яшьләрен күрсәтмәде.

«Юк, бу карт алышынмаган, кышын улларында шәһәрдә, җәен туган нигезендә гомер кичергәнлектән, просто хисләргә бирелә, күрәсең...»— дип, үзенчә бер нәтиҗә ясап куйды Мортаза. Аның сүзләре дә бик ачык һәм төгәл иде:

— Ярый, Шәйхулла бабай, атның иң һәйбәтен бирерләр сезгә. Әйбәт кенә йөреп кайта күр син!

* * *

Бер атна элек кенә Шәйхулла картны, сугыш һәм хезмәт ветераны буларак, мәктәпкә, туган як музеен ачу тантанасына чакырганнар иде. Вәт ичмасам бу пионер дигәннәрең булдырып та карый икән! Үзләре орчык кадәр генә, ләкин тау чаклы эш башкарып өлгергәннәр. Махсус ачылган бүлмәдә ул белгән-күргән ни-нәрсәләр генә юк: чупләмле сөлге, хәситә, энҗеле калфак, чигүле ашъяулык, аннары инде, чабагач, тешле урак, киле, чабата — тагын-тагын әллә ничаклы әйберләрне эзләп тапканнар, музейга җентекләп урнаштырганнар.

Музейдан һәм яшь-яшь буынның, укытучыларның мондый да изге, савaплы хезмәтеннән биһуш булды Шәйхулла картның күңеле. Ләкин бер нәрсә шыпырт кына күңелен тырнап алды: нигә соң теге заманнар истәлеге булган, кайчандыр аның кулларында балык шикелле уйнаклаган, солидол белән майлап «кабер»гә күмелгән иң кадерле тимер сукасы шушы музейның түрендә утырып тормый? Нигә?

Шушы эшне ул үзе башкармаса, кем башкарыр тагын?

Шәйхулла картның колхоз рәисенә керүе, аны күпмедер дәрәҗәдә аптырашта калдыруына сәбәпләрнең тагын берсе әнә шул иде.

Суканы ул урманда, җир астында берничек тә әрәм итеп калдырырга тиеш түгел!

Аннары уйлары тагын да алга табарак йөгерде аның. Нигә әле мәктәп музеена? Теләсә, ул бит музейның дәвамын үзенең ишегалдында да ясый ала! Ат биреләчәк, урманнан казып алып кайта да, ишегалдының уртасына матурлап бастырып куя тимер сукaны...

Шәйхулла картның күңеленнән уйлар ташкыны агылды да агылды...

Атка җигелмәгәч, ул тимер суканың кирәге бармы соң?

Сука кырыена ат кирәк. Кайтарыгыз атымны!

Ул яшәде. Ул эшләде. Сугышларны кичте. Ләкин ни рәхәт күрде соң әле дөньяда? Күкрәк көчен, зиһенен, гайрәтле елларын мәгыйшәткә исраф итте. Кая китте аның яшьлеге? Тагын яңадан яшәп була микән? Кычкырасы, чаң кагасы килә: кайтарыгыз яшьлегемне!

Картның колагына кинәт кенә колын кешнәве килеп бәрелде... Кайтарыгыз миңа колынны!

Ишегалды тар булса да, баш очында күкләр биек, өнсез иде. Өнсез микән? Әнә бит аның төпсез киңлекләрендә, дөньядан ярлыкау сорап, Шәйхулла карт күңелендәгечә итеп, кайтавазлар чыңы тирбәлә:

— Кайтарыгыз!..

* * *

Кичке якта Шәйхулла картның ишегалдына берничә кеше килеп керде. Җигүле ат урманнан әлерәк кенә төшкән ямь-яшел, сусыл печәнне салмак кына кештердәтә, ә инде нигез хуҗасы ишегалды уртасына куелган тимер сукaны кочаклап, тынып калган иде.

Белмәссең: әллә арып йокыга талган ул, әллә инде җаны гарешкә — йолдызлар һәм фәрештәләр генә сөйләшә торган михрабка күчкән...

*1996 ел.*

# ШИГЪРИЯТ



## Рәдиф Гаташ

### ГӨЛБАЛАГА ХАТЛАР

(ГАЗӘЛЛӘР)

* * *

Кариэм, дим, бармы сабрың? —
    әйт: белеп яшь яр кадрен,
Сагынып, бармы көткәнең —
    ут яныл, сызып бәгърең?!

«Яшь гыйшык келәт вата, ди —
    карт гыйшык — пулат хәтта!» —
Шундый көч-куәт бирсә хис,
    мактыйк без ярның «җәбер»ен!

Яшьлек соңындамы син, җан? —
    яндыра, дисең, җанан:
Бәхетебез йорты саныйк соң
    Күкне без — Ходай чатырын!

Сүз-битәрдән саклар безне,
    яшерер кинә-күздән;
Бүген без тәхеттә — шаh бер,
    вакытмы әйтер ахырын?!

Укы сабырың җитеп, кариэм:
    бу — чын гүзәлгә газәл...
Соңгы юлы: — Шашма, Гаташ!
    йә ташлар елар... Акрын!

* * *

Гомер таңында, җитәкләп, кулыңнан
Алдым сине: адашмассың юлыңнан!

(Кагылдым мин фәкать бармак очына —
Сискәнеп гүя сабыйлык җылыннан!)

Өнсез калдым аннан, ихлас тетрәнеп
Табигать бүләге — яшьлек җырыннан.

Юл башың бу! Минем дә шундый яшькә —
Йөрәкләрдән, бел, мәрхәмәт кылынган:

Фатиха бирде агайлар! Рәхмәт дим
Раббыма — мәңге бурычлы колыннан!

Инде сиңа изге юл тели догам;
Ышан: күңлеңә ихлас дус булыр җан!

Шагыйрь акылы да (төштән соң!) ялгышмас:
Җитәкләп алдың син дә бит кулымнан!

* * *

Сүзең балы җам — гөл таҗыннан артык!
Күзең нуры — җанга ялкыннан артык!

Яшьлектән, йә, дәрес алу — языкмы:
Сабый күңелең — картның акылыннан артык!

(Гомер хакына табылган тәҗрибәм!
Ярым хакы — синең хакыңнан артык!)

...Чырагтыр син: чәчләрең төсе миңа
Күзем эчкән Кояш-яктымнан артык!

Каләмем, әйт: сүздән Ярга бумы — таҗ? —
Харәзми йә Хафиз данынннан артык?

Ә бу мизгелдә кем лаек ул таҗга? —
Бармы синнән — тиңсез ярымнан артык?

* * *

Яннарыңнан куган — ул мин түгелме?
Җаныңнан аерган — минем күңелме?

Бәйгесендә сүзнең нишләсен бу баш?! —
Гөл баладан үзе теләп җиңелде.

Хис тулпарым алга чыгарды яшьне —
Җил белән узышу әллә җиңелме?

Моң күлләрем! Нидән арткан суыгыз? —
Күздән аккан ни ул кайнар? — түгелде...

Яныңнан... юк, җаннарыңнан кума, Яр!
Күңлемә ул — соңгы хөкем түгелме?!

* * *

Илбашының юлы бүген — Иранга!..
Якташың ул... Кагылырмы Ширазга? —

Сәясәттән бушап, форсат табармы
Шигырь кәгъбәсенә дә баш куярга?

Ул — Сәгъдиләр Гөлестанында бүген;
Түгел дәһри: юнәлде рухи Хаҗга!

«Хөрәсән ялкаулары» дип, мөгаен,
Татар шагыйрьләрен алмас мисалга?

...Беләсеңдер, Яр: без — Таһраннар өчен
Үз халык күптән! Мәгълүм бу — дөньяга!

Фарсы — төрки арасында юл иске:
Суытмадык эзне, хисне азга да!

Илбашыбыз — шуңа Хәйям кунагы:
Шагыйрь булып кайтсын илгә — Казанга!

* * *

Ни генә әйтер ак кәгазь? —
онытыла күп сүз — кала.
Язылла җанга! Серле күз
балкышыңнан эз кала!

Нинди ул — чорга лаек сүз?
Гасырны каргау җыры?
Халкым, киләчәгең бармы? —
Күп кавем телсез кала...

Бетәрме — кадимнән Иран
көндәше Туран нәсле?
Бәлки, шул җәүһәр тарихта:
җырда төрки Кыз кала?!

Оныттырмас халкы данын,
мәхәббәт шагыйрьләрен! —
Мәңгелеккә булыр сакчы —
чын татарча Күз кала!

Язның нәкъ үзедер син, Яр:
үзгәртер нур-көчең бар;
Бәлки, милләт тә яшәрер?
Соң түгелме: Көз — алда...

Күңеленә тапшыра Гаташ

быелгы җәй алмасын:
Тетрәнә җыр, хисләр таша —
сак кагыл, син, Кыз бала!

* * *

Сүзләрең — җыр, гел яңгырап барыр, дим!
«Сагындым, бел... Сагынам. Сагынырмын!» —

Шулар белән бүген минем җаныма
Ефәктән дә йомшак, матур кагылдың.

Җыр сүзең, дим, гади һәм бөек — анда
Борынгы һәм мәңгегә яшь сабый моң!

Шул моң белән кавышкан җанымны да
Бәхетле, дим, хәтта бөек саныйм мин!

* * *

Нур илендә гөл син! Гөлгә сокландым...
Гөл янында нурлар! Сезгә сокландым.

Ым белән тик ук-керфекләрен аткан —
Наз-вәгъдә белдергән Күзгә сокландым.

Ык тарафында челтерәр чишмә күк
Табигый аккан яшь Сүзгә сокландым.

...Шунда, ахры, газәлнең ахыры да:
Буй кыз атлы бөек Сергә сокландым!

* * *

Яндырды ник язганы син-баланың? —
«Хушыгыз... Сезне сагынып калам мин!..»

Борынгы хатлардан үрнәк «намә» күк:
Укыйм — бабайлар...балбаллар сәламен...

Йолдызларга ашкандыр күпме гашыйк:
Җандашлар — кай тарафында Галәмнең?

Сагынадыр безне алар, көтәдер:
Күкләрдән аваз ишетәм һаман мин!

Чыгаргандыр юлыма шулар Сине —
Милләтнең гүзәл мәхәббәт дәвамын.

Мәңгелек — ни? Гашыйкларга ул — ватан!
Хатыңны шулай аңлый җан — янам мин!

* * *

Кем кагылган синең сердәш-каенга?
Ак тәнеңдә яра — аккан каны ла...

Син кочкансың аны, апаң күк күреп,
Бар да туган сиңа — туган ягыңда!

Бу язда бит килде Кайгы сиңа да:
Зур югалту уйган эзен — җаныңда!

Яныңда, аһ, булмадым — юатырга,
Каендай, сызып, елаган чагыңда...

Иртәнге чык-яшь кибәр, китәр кайгы...
Тик, җыр башың — язмышың! — шул язында...

* * *

Нургөл, димме, Гөлйөзме? Кем дип атыйм? —
Кушыйм сиңа бер шигъри исем-ат, дим.

Эзлим нигә? Иң матуры — Гөлбала,
Табигатьнең үзе биргән җавап! — дим...

«Бисмилла!» дип күреп, шушы исемңне
Кабатласа газәл — бәлки, савап? — дим.

Әһле ислам көферлек тапса моннан?
Җан — чын диндә, юл адашмас кораб! — дим.

Шуңа өстәп: — Гөл исемле буй кызны
Җырыма ит мәңгелек яр, йә Рабб... — дим!

* * *

«Сәерҗан» мин күпләр өчен — күрәм мин.
Кайчак хәтта үз-үземнән көләм мин.

Яшь карашың кызганмасын чал башны:
Язмыш буенча, Яр, йөри бирәм мин.

Ә йөрәкнең яралы күпме кылы!
Сөюдән өзелер алар — сизәм мин.

Әмма сине үлемсез итәр Җырны
Уйнармын соңгы кылымда — беләм мин!

Шул бәхтемә олуг хак куйса Дөнья?
Түләрмен бер — сәер җаным белән мин!

* * *

Ил картлары! Рәхмәт, төшкә кердегез.
«Дингез кичерер димче»ме идегез?! —

Күздән кичереп яшь Гөлне — бәхтемә
Әдәп-вәкарь белән бәя бирдегез.

Куеп нәсихәт-вәгазьне, онытылып:
— Сөбханалла! Милләт кызы! — дидегез.

Тамак кырып, әйттегез мәдхияләр,
Нидәндер кызарган олпат йөзегез...

«Аһ, яшәреп, кабат яшәп булса!» — дип,
Зәңгәр күзләр сафлыгында йөздегез...

Җанга бу — кан, Тарих таушы идеме
Төштә сез биргән фатиха-сүзегез?!

* * *

Миллион халкы булган Казан — Синсез — буш!
Мин дә синсез калдым ушсыз — чын биһуш...

Күктән кошлар очып үтте. Ишеттем,
Синең исемеңнән әйтәләр: — Биһуш, хуш!

Узар алар сезнең йорт өстеннән дә:
Ак каурыен калдырсын бер моңлы Кош...

Хат язарсың шуның белән... Беләм тик:
Каләм тоту — яшь кулга «бик кыен» эш...

«Ямьле вә хуш» авылда син... Нигә соң
Уем — борчулы? Җан түгел һич тыныч?..

Миллионыңнан берәүне уйлыйм, Казан!
Юат мине: болай сагынмаска куш!

* * *

Синсез дөньям кошлары — ни? Кәгазьләр...—
Рух очышка мисал булыр бик азлар...

Шул кошларымнан да моңлы җыр көтеп,
Баш иделәр миңа гөлләр — раузалар.

Җан таушымда — тәҗрибә авазымда
Бар — салкын ярларга кайнар вәгазьләр!

Үзгәрттемме, янып, мин бу дөньяны?
Һаман сөюдә шул: сәүдә-базарлар!

Чын гашыйкка бирерме заман бер «хак»?
Үлгәч, аңларлар — кыйссаңны язарлар!

Синле дөньям: — Үзең яз,— ди,— зур Хисне;
— Биек оч! — дип, җаныма дәшә язлар!

* * *

Шигырь шәрабың бер авыз итәргә —
Кирәк булган ничә дәрья кичәргә?!

Сусаган җан! гомер уртасын узгач
Килде мәллә бәйрәм — янган хисләргә?

Багышлаган касәң, сизәм, ут тулы:
Исертмәсме яшьлек сүзе? Нишләргә?

«Тора, дисең, Яшәү — тоташ ялкыннан...»
Шуңа эссеме — сүрелгән кичләрдә?

Яндырды шигырь шәрабың — җавабың!
Дивана җан... Тели тагын эчәргә!

* * *

Иң матур шигырең синең — ни? беләмсең?
Ул — яшьлегең: тиңсез шуның белән Син.

Тик унҗиде яз күргән наз иясе!
Бардыр хакың — сүзләремнән көлсәң Син...

Матурлык бит күзеңдә үк: Күк төсе! —
Тугач ук шигърият таҗын кигән Син.

Ни генә ул сиңа — Гаташ язганнар? —
Бөек үрнәк — камил газәл икән — Син:

Унҗиде яз — Кояш, Табигать җыры! —
Ахры, Тәңре каләменнән иңгән Син?!

* * *

Рәхмәт, Газәл! Ярдәмеңә таяндым:
Назың берлән — Яр җанына таяндым.

Хезмәтенә тайяр булып, Гөл туташ,
Гашыйкларның базарына таяндым.

Бәһа куйдың зәгыйфь бу жыр кошына,
Канатландым — мактавына таяндым.

Бар дөньяга төрки сүзне таныткан
Шагыйрь ирләр мәйданына таяндым.

Яр каршында гажиз башымда минем —
Мең сорау... Бер җавабына таяндым!

* * *

Син якында, егерме беренче йөз!
Сиңа бер жыр жанымда — Ярга бер сүз:

— Арды, ташып узган чорлар сагышын —
Еллар моңын откан гашыйк ике күз!

Гөлбаланың гөл исле хуш уйлары!
Жуймассызмы мине мәңгелектә сез?

Бу диваным — ярсу бер ел йомгагын
Егерме бердә, алып бер, сүтәрсез!

Сагыштан, бәлки, куярсыз чайпалып,
Мине саклап йөрткән диңгез-күзләр, сез?!

...Егерменче йөздән Гаташ аһы бу:
— Нишли Дөнья минсез — рәдиф-газәлсез?!

*1996, июль — декабрь.*



# ШИГЪРИЯТ



## Әхсән Баян

### ОЧУ, ТӨШҮ...

### Йолдызлыгым

*Йолдызлыгым белән мин — Укчымын,*
*Аның өчен әле дә баламын,*
*Гәрчә исемен аклый алмадым.*

Малай чакта булды, күп булды
Уклар ясап аткан чакларым.
Йөрәгенә түгел, кешенең
Төбәгенә дә тик атмадым.
Мишень була килде үз йөрәгем,
Шундый оста, туры аттылар,
Чәчри торды күздән чаткылар.

Калкан сакламаган йөрәктә
Җәрәхәтсез калган урын юк.
Хәлдән таеп егылыр чакларда
Тылсымлы көч сипте Йолдызлык.
Тылсымлы көч — алсу төсләр Җирдә
Өмет кабыза килгән нурлардыр.
Шифа булып иңгән шулардыр.

Синнән көчләр алып, елмаям,
Үчле, көнче уклар атса да.
Йолдызлыгым, ерак чакта да
Яклавыңнан, зинһар, ташлама.
Ни дисәң дә, мин бит — Укчымын,
Ни дисәң дә, синең балаңмын,
Гәрчә исемең аклый алмадым.

*1996.*

* * *

Йолдыз очып төште ерак төндә,
Төште безнең урман өстенә.
Урман буйлап балачагым шуны
Әле булса эзләп интегә.

Ачылдылар күзләр дөреслеккә —
Йомылмаслар, ахры, кайчан да.
Инде күптән йолдыз яумый күктән,
Ышанмабыз сыман яуса да.

Без — акыллы, без — зур, алдыйм димә,
Кирәк исә мең-мең хәйлә тап.
Күккә күз ат — йолдызларның анда
Ак төсенә йоккан кара тап...
Узганнарны әгәр үзгәрталсак,
Йолдыз бәлки, кабат явачак?..
Бөтенләй үк китмә, әй, кире кайт,
Мең өметле, даһи балачак!

*1988*

## Урта гасыр авазы

### 1

Ишетегез, шундый безнең гасыр:
Морза, дворян, барсы — бихисап.
Шау-гөр килеп, атка, бәндәләргә
Кидерәләр камыт, ыңгырчак.

Йорт-сарайлар тулы соры кортлар,
Бал ташыган төсле — тыз да быз.
Мактау абруйлы да, тәмәкесез
Төпчек сыман ауный тик намус.

Куллардагы тәлинкәләр санын
Күптән узган ялчы, хезмәтче.
Ярыклардан, ишек-тишекләрдән
Дус-иптәшне күзли күзәтче.

Бөгелә-сыгыла атлый ялагайлар,
Монафыйклар мыжгый һәр төштә.
Юха сүздән мутлар үзләре күп,
Ә кыланыш — мисле фәрештә.

Ниятеңне, үч вә нәфрәтеңне
Наз белән тәр тостлар әйткәндә.
Түрәләргә тугрылыгың саклап,
Саф вөҗданлы ирне тапәлә.

Әшнә белән әшнә нинди әнә
Ихлас зурлый сыйлап бер-берсен.

Өстәлләрне сыккан ризык, хәмер —
Сабыйлар һәм толлар өлеше...

Утлы телмәр-сүзләр вә бәхәсләр
Гавам хакын хаклап яңгырыйлар.
Ачлык, юклык өчен узган чорлар
Батырларын хурлый, каргыйлар.

Ишетәсезме, шул бит гасрыбызның,
Шул бит төгәл һәм хак сурәте!
Оныкларга насыйп итмә, ходай,
Мондый үрнәк, мондый гыйбрәтне.

2

Урта гасырлардан килгән аваз,
Егерменче, сиңа нинди хас!
Егерме бер дигән яңа дәвер
Бу сүзләрне, бәлки аңламас.

Өметләрем минем килсәче рас,
Йә раббым,
Килсәче рас!

*1990*

## Аска очу

Аска очу шулай башланды,
Юк нәрсәгә бар дип ышанудан.
Яңа, канлы җиңүләрне зурлап,
Учлар чатнаганчы кул чабудан.

Микрофон һәм һава тетрәндергән
Ялагай һәм ялган нотыклардан.
Ишек төпләрендә — бүрек сузып! —
Бөлгенлек һәм хурлык көтеп торган.

Җәннәтләргә юллама дип белгән
Кәгазь вәгъдә безне кая илткән?
«Әфәнделәр, коткарыгыз!» — диеп,
Кычкырабыз бозлы түбәнлектән.

Очу, төшү... Нишләп ахыры юк?
Гүя төш күрәбез бастырылып.

*1995*

## Исәнмесез, бал кортлары

Исәнмесез, бал кортлары,
Мин сезне тәбрик итәм.
Рас килмәде куркуларым,
Сез әле исән икән.

Бу заманда исән калу
Үзе бер сәнгать дим мин.
Эшләүнең нәрсә икәнен
Онытмау әйбәт, димен.

Чәчәктән сезнең бал җыю
Гадәте, күрәм, калган.
Чага да беләсез икән,
Хак барын тойсын ялган.
Тик балыгыз нинди — әле дә
Дарумы мең зәхмәттән?
Бармы татлы тәм анарда,
Килә мәллә бүтән тәм?

Татлы булып истә генә
Калмас микән затлы бал?
Сезнең дә бит илдәгечә
Яшәвегез ихтимал!
Шөбһәләрем кичерегез,
Сезнең эш — изге, шиксез.
— Сез-з-з дә без-знеңчә яшәгез-з,
Дөрес яшәгез-з! — дисез.

Рәхмәт сезгә. Болай булгач,
Мәхрүм калмабыз балдан.
Сездә чынлык исән калган,
Күмсә дә безне ялган.
Рәхмәт сезгә!

*1996*

* * *

Кәккүк тавышларын тыңларга
Барасы юк иде урманга.
Үзе килеп чакыра иде кәккүк
Озын, гомер, ерак елларга.

Тургай сайрауларын тыңларга
Чыгасы юк иде кырларга.
Мин үзем бит кыр баласы идем,
Һәм юлдашым булды җыр анда.

Сандугачлар моңын тыңларга
Эзләмәдем бакча мин анда.
Яшьлек үзе бакча булгангадыр,
Былбылларым булды гел янда.

Таныш кошларымны тыңларга
Чыгар идем ерак юлларга.
Андый юллар кайда? Эзләп барыйм
Кайсы урман, нинди кырларга?!

*1995*

## Сугыш фәрештәсе

Җир урап, алга барамын.
Байрагым — төн карасы.
Җилфердәтеп төн карасын,
Шулай мәңге барасы.
Күмә барам барча төсне —
Яшелне, күкне, акны.
Тәрәзләрдән төн тутырам —
Калмасын өйдә якты.

Барам тырышып күмәргә
Айны һәм йолдызларны.
Чабамын Кояштан алда,
Җиткермәс өчен аны.
Чаба-чаба сөрән салам
Адәм кавемнәренә,
Кемнәр икәнен аларның
Аңлатып үзләренә.

Игълан кылам бөек ирек
Кавемнәрнең барына.
Ирек бирәм үтерергә,
Илләр басып алырга.
Мин аларның кулларына
Бирдем җәя, ук бирдем,
Бирдем хәнҗәр, бирдем кистән,
Мылтык бирдем, ут бирдем.

Сынатмады Җир улы һич,
Акланды ышанычым.
Җыйды көч Җир шартлатырлык,
Бүлгәләп атом төшен.
Берләштерде бөек нәфес
Кавемнәрнең куәтен.
Барчасына аңлашыла
Сугыш теле — уртак тел.

Шул телдә дөнья шаулатам,
Урнашсын Җирдә диеп:
Азатлык, Дуслык, Туганлык,
Тигезлек вә Гаделлек!
Сүзләремә чынлык төсе
Бирә яшәү шартлары,
Ядрәләрнең кыюлыгы,
Атом төше шартлавы.

Караңгыда һәркем үзенең
Җәнлеклегән күрәчәк.
Мин бүләк иткән Азатлык —
Шатлыклар тулы вәхшәт.
Чәчкән урмас, урган чәчмәс,
Кулында булыр мылтык.
Эше калмас яу шәрабен
Бер караганның йотып.

Икмәк тулган амбарларга
Ут төртүче чыра ул.
Сыер көтүен шаштырып
Чаптыручы укра ул.
Котырып янган җәһәннәмгә
Ул атасын атачак.
Мин бүләк иткән базарда
Ул анасын сатачак.

Минем кануным каршында
Гөнаһсы аның юк та.
Мин бүләк иткән иман бит —
Алтын, әфьюн, валюта.
Юл читендә аунап ята
Әнә иске хакыйкать.
Чыкты юкка иске канун —
Тугрылык, сөю, шәфкать.

Берсен-берсе уйлап йөргән
Яшьләрнең сөю дигән
Иске хисен алмаштырдым
Үтерү ләззәте белән.
Иске зирәклек — фәхишә,
Яманлый сугыш данын.
Мин куштым ласа коярга
Кечкенә илнең канын!

Гаделлек шул — басып алгач,
Җиңгән масая алмас.
Хезмәте башкарылгач та,
Корбан булачак палач.
Ияргән өчен артымнан
Зур рәхмәт, туганнарым.
Туктаусыз алга барамын,
Кулдан төшмәс байрагым!

Кара байрагым.

*1995*



**Шәриф Хөсәенов**

# БЕЗНЕҢ ПОДЪЕЗД ТӨБЕ

БЕР ПӘРДӘЛЕ ДРАМА

**КАТНАШУЧЫЛАР:**

Газета укучы ир.
Кәләпүш кигән ир.
Беренче хатын.
Икенче хатын.
Бибиси ханым.
Флакон.
Бакчачы карчык.
Айрат, җиде яшьлек малай.
Авыл карчыгы.
Авыл карчыгының улы.
Салып йөрүче ир.
Яшь кенә бер кыз.
Бер кыз.
Яшь кенә бер хатын.
Сүзсез ирләр, сүзсез хатыннар.

**Зур йортның подъезд төбе. Ишекнең ике ягындагы утыргычларда Газета укучы ир, Кәләпүш кигән ир, Беренче хатын һәм Икенче хатын утырган. Газета укучы ир бик бирелеп газета укый. Кәләпүш кигән ир колагына нәрсәдер әйткәч, Икенче хатын шаркылдап көлеп җибәрә, аңа кушылып башкалар да көлә башлыйлар. Беренче каттагы квартираның подъезд кырындагы тәрәзәсендә Яшь кенә бер хатын күренә.**

Яшь кенә бер хатын. Тавышланмагыз әле, зинһар, шул тиклем! Бала йоклый!

Икенче хатын. Нәрсә, синең балаң йоклый дип, безгә көләргә дә ярамыймыни инде хәзер? Яп тәрәзәңне! Безнең ни сөйләшкәнне тыңлар өчен ник ачып куйдың?

Яшь кенә бер хатын. Раббым, сезнең ни сөйләшкәнегезне мин тыңламасам да беләм!.. *(Тәрәзәсен ябып юк була.)*

Икенче хатын. Күрегез әле бу хәчтерүшнең кыланмышларын! Биш ел ир белән торып, көчкә бер бала тапты — анысын да кеше төсле итеп таба алмады бит әле, врачлар корсагын ярып алдылар. Кайдан килгән хан кызы! Аның баласы йоклый дип, сөйләшмә дә, көлмә дә! Алтын карыннан төшкән бала диярсең, ачуым да бер килмәгәе!

Газета укучы ир *(укуыннан бүленми генә)*. Хөкүмәте дурак булгач. Бала тапкан саен өчәр ел өйдә утыртып, аздырып бетерде хатыннарны.

Икенче хатын. Өч еллары тулгач та юньләп эшләмиләр алар хәзер, балалары

төчкерде исә больничныйга чыгалар. Әнә Фәнияне генә күрегез — әле бер баласы белән, әле икенче баласы белән, әле өченче баласы белән айлар буе больничныйда утыра. Эшендә ничек түзеп торалар икән шуңа?

Кәләпүш кигән ир. Сез, хатыннар, бер бала тапсагыз, Галәмгә менеп төшкән кебегрәк кыланасыз шул хәзер. Валентина Терешкова кебегрәк тотасыз үзегезне.

Икенче хатын. Терешкованы кем булган дип беләсең соң син? — утыртып җибәргәч,очкан инде. Ул бит анда бөтенләй адәм хуры булып беткән ди, куркуыннан бөтен ыштан төбен тутырган ди бит ул!

Беренче хатын. Бала тапкач дисез сез. Әнә минем кече улымның хатыны биш минутлык авырлы булуга саклана башлый. Бөгелергә дә ярамый, күтәрергә дә ярамый. Әле тегесен табып китер син аңа, әле монысын. Әле витамин, әле балык мае, әле кышның уртасында яңа пешкән помидор. Чын! Ташкенттан барып алып кайтып ашатты быелтыр улым шул помидорны... Үтте гомер, шулай иркәләнеп ятып булмады.

**Кулындагы транзистордан Габдулла Рәхимкулов башкаруында торналар турындагы популяр җырны яңгыратып, подъездан бер егет чыгып китә.**

Чылбырдай тезелеп,
Кайтыгыз, торналар,
Бу илдәй бәхетле
Ил тагын кайда бар?!..

Кәләпүш кигән ир. Кемдә кич куныш чыкты бу егет?

Газета укучы ир *(укуыннан бүленми генә)*. Укытучыда.

Беренче хатын. Укытучы өйдә юк дип әйтеп торам лабаса мин сезгә! Кичә күз алдыбызда Боровой Матюшинга гөмбәгә барабыз дип чыгып китте ләбаса!

Газета укучы ир *(укуыннан бүленеп)*. Димәк, бармаган. Кире кайткан.

Беренче хатын. Кайтмады!

Газета укучы ир. Димәк, без йокларга кереп киткәч кайткан.

Беренче хатын. Соң, бу егет сәгать сигездә үк килде ләбаса. Ул чакта укытучы өйдә юк та юк.

Газета укучы ир. Димәк, егетнең үзендә ачкыч бар. Димәк, укытучының ишеген ул үз ачкычы белән ачып кергән. Ә сез, ачык авызлар, подъездга килеп кергән кешенең кемгә килүен күрми калгансыз.

Икенче хатын. Туктагыз әле, әйдәгез тагын бер уйлашыйк. Беренче каттагыларда булуы мөмкин түгел, шулаймы? Икенчедә дә жыен карт-коры. Өченчедә — кырык биш, кырык алты, кырык җиде... Кырык сигездә булмас. Дүртенчедә кырык тугызлар авылда. Илле, илле бер... Илле бернең кызында түгелме икән?

Кәләпүш кигән ир. Егете бар, речной техникумда укый. Кичә каядыр барып, төнге уникедә генә кайттылар. Телефон будкасында ярты сәгать кочаклашып тордылар.

Икенче хатын. Кочаклашып кына тордыларны? Секс белән шөгыльләнмәделәрме?

Беренче хатын. Нәрсә белән?

Икенче хатын. Һай ходаем, әллә шуны да белми! Секс! Секс! Аны бит инде хәзер моның чаклы балалар да белә. Шөгыльләнмәделәрме?

Кәләпүш кигән ир. Юк. Өч тапкыр үбештеләр генә.

**Подъездга бер ир кеше кереп китә.**

Беренче хатын. Нәсимәләрнең киявләре тагын кайткан, ахры.

Икенче хатын. Узган атнада ук ич инде,— тагын күпме чыдар. Туктагыз инде, бутлдермәгез, санап чыгыйк!.. Илле ике, илле өч... Илле дүрттә булмас. Илле биштә дә шикләнерлек кеше юк.

Кәләпүш кигән ир. Катырма башыңны, илле алтыда куныш чыкты бу егет.

Икенче хатын. Бәтәч, илле алты — ул мин ич!

Кәләпүш кигән ир. Син шул.

Икенче хатын. Соң, мин монда утырам ич!

Кәләпүш кигән ир. Утырсаң. Төне буе монда утырмадың ла син.

Икенче хатын. Әй, китсәнә!

Кәләпүш кигән ир. Китмим. Берике йөз грамм салдырсаң, ач карынга ярыйсың әле син.

Икенче хатын. Синең шикеллесе туры килсә, йөз грамм түгел, бер чиләк эчерсәң дә толк чыкмас!

Кәләпүш кигән ир. Нигә чыкмасын. Эчереп караганың юк лабаса әле.

Икенче хатын. Карамасам да беләм. Хатының үлгәнгә ничә ел, булырлык булса, берәрсен алып кайткан булыр идең инде, көне буе безнең янда йомырка салып утырмас идең.

Кәләпүш кигән ир. Эзлим,— үземә тиң матурны таба алмыйм.

Икенче хатын. Һай ходаем, үлгән хатының бик матур иде инде — аяклары кәкре, авызы чалыш. Үзе тагын шадра!

Беренче хатын. Шадра йөрәк яндыра!

Кәләпүш кигән ир. Мин яшь чакта матур кызлар юк иде шул. Ул бит хәзер генә китте типкән саен матур кыз. Иртә дә өйләнмәдем, егерме сигез яшем тулганчы эзләдем, табып булмады матур кыз. Шуннан әлеге апагызны алып кайтырга туры килде, авызы чалыш булса да... Ходаның рәхмәте, өйләнгәч, зөфаф кичәсеннән соң, иртә торып урамга чыксам — бер юлы ике матур кыз очрады.

Икенче хатын. Әй, туктагыз әле, кирәкмәгән сүз сөйләп, бутлдермәгез! Соң, санап чыгыйм инде! Илле җиде, илле сигез, илле тугыз...

Беренче хатын. Илле тугызлар өйдә юк. Иданнәрен буяп, кич кунарга бакчага киттеләр.

Икенче хатын. Алтмышның да кызы практикада.

Кәләпүш кигән ир. Кызы практикада булса, ул үзе дә ялгыз йоклауны өнәп бетерми.

Беренче хатын. Үзе больницада ята.

Кәләпүш кигән ир. Ни булган?

Беренче хатын. Булмаган. Колхозга урып-җыюга җибәрмәсеннәр өчен ул бит ел саен шушы вакытта больницага кереп ята. Сенелесе врач булгач, рәхәт кешенең.

Газета укучы ир *(укуыннан тук-тап)*. Тагын бер кат кабатлыйм: ул укытучыда кунды. Идәнгә тәлинкә куеп тынладым, төне буе быдыр-быдыр килеп чыктылар. Ир кеше тавышы да бар иде. Бибиси сөйләгән буенча да шулай килеп чыга. Әнә, үзе дә кайтып килә, сөйләп бирсен!

**Кулына зур гына букча тоткан Бибиси ханым керә.**

Бибиси ханым *(букчасын җиргә куеп, лапылдап утыргычка утыра)*. Уф! Сельхоздан егерме кило борчак алдым әле, борчакка берни булмый ана... Теге чакта мин азык-төлек талонга калачак икәнне ишетеп, он-ярма җыя башлагач, миннән көлгән идегез. Дөрес булып чыктымы шул сүз? Чыкты! Инде менә хәзер бәяләр атна саен күтәрелеп торачак, имеш. Аракының бутилкәсе унбиш сум булачак, ди! Валлаһи, валлаһи! Сөт биш сум булачак! Бер кирпеч ипи әллә ун сум булачак диде инде, әллә унбиш сум. Валлаһи! Тоз белән шырпыга чират алдым әле, бер кило тоз ун сум булачак, ди! Бер тартма шырпы бер сум булачак! *(Букчасын асып подъездга кереп китә башлагач, туктап кала.)* Теге егет чыкмадымы әле?

Икенче хатын. Чыкты инде, менә хәзер генә чыгып китте. Шул хакта баш ватып утырабыз бит әле менә. Кемдә кунды ул?

Бибиси ханым. Кемдә икәнен өзеп әйтә алмыйм, әмма ләкин сигезенче катта. Ник дип әйтеп әйтсәгез, мин аннан сез кемгә киләсез дип сораган идем. Какое ваше дело, дип әйтеп әйтеп грубить итте. Шуңа ачуым килеп, ул подъездга кереп китүгә, мин әнә теге каршы йортка йөгердем. Ул менә, аннан күземне алмыйча мин менәм. Кайчак лифт эшләмәүнең дә файдасы тиеп куя! Җиденче катны үткәнен менә шушы күзләрем белән күреп тордым, ялганласам — ике күзем чәчрәп чыксын. Тугызынчыга менмәде, сигезенче катта юкка чыкты. Сигезенченең уты янмый иде, кемгә кергәнен күрми калдым.

Кәләпүш кигән ир. Нигә уты янмый иде сигезенченең? Лампочкасы янганмыни?

Бибиси ханым. Янмаган. Аны мин шул минутта ук менеп тикшердем. Борып җиткермәгәннәр иде.

Кәләпүш кигән ир. Аны укытучы үзе шулай борып киткән, димәк!

Газета укучы ир. Кәнишне үзе! Егетнең кемгә килгәнен күрмәсеннәр әле дип, ул аны юри шулай борып куйган.

Кәләпүш кигән ир. Сабыр итегез, апакайларым! Өендә телефоны бар лабаса аның! *(Кесәсеннән блокнот чыгарып актарына.)* Менә шунда булырга тиеш аның телефоны... Мин хәзер автоматтан гына шалтыратып алам да, өйдәме-түгелме икәнлеген беләм.

Бибиси ханым. Унбиш тиенлегең бармы?

Кәләпүш кигән ир. Нәрсәгә миңа унбиш тиен! Мин бит аннан свидание сорап сөйләшеп торырга җыенмыйм. Трубкасын алса, миңа шул җиткән, моның өчен унбиш тиеннең кирәге юк.

Бибиси ханым. Һай, баш эшли дә соң инде үзеннең, малай!

Кәләпүш кигән ир. Нишләп баш кына булсын, минем башка нәрсәләрем дә эшли әле, әлхәмделилләһи шөкер. *(Бибиси ханымның кофтасын караган булып, имиен капшап ала.)*

Бибиси ханым *(Кәләпүш кигән ирнең кулына сугып)*. Белмим шул, ул нәрсәнең рәте калдымы икән. Телеңдә гел шул. Телгә күчкәч, рәте беткән була инде аның.

**Подъездга ике яшь егет уза.**

Кәләпүш кигән ир *(егетләрнең артыннан карап калып)*. Болары кем булды инде тагын? Кемгә килүчеләр икән болар?.. *(Бибиси ханымга дәрт белән карап.)* Ну, малай, синең кыяфәтләр!

Бибиси ханым. Ни булган минем кыяфәткә?

Кәләпүш кигән ир. Шәп дип әйтүем!

Бибиси ханым. Аллага шөкер, бөтен җирем дефицит! Эчем дә, тышым да импорт!

Кәләпүш кигән ир. Әй, эчеңдәгеи импорт түгел лә инде!

Бибиси ханым. Импорт, анысы да импорт!.. Уф алла, тоз чиратым җитәдер, боларны кертеп бушатыйм да, йөгерим... *(Букчасын күтәреп подъездга кереп китә.)*

**Подъезддан бер хатын чыгып уза.**

Беренче хатын. Күз төбе тагын кара янып чыккан. Әллә ире кыйный микән бу Рәсимәне?

Кәләпүш кигән ир. Хатыным шундый булса, мин әле кыйнап кына калмас идем, буып үтерер идем. Бакча өйләрендә сөяркәсе белән тоткан лабаса ул аны!

Беренче хатын. Ай алла, ул үзе дә йөри бит, хатыны берәр җиргә китте исә, өенә хатыннар алып кайта.

**Подъездга бер хатын узып китә.**

Икенче хатын. Бу хәчтерүш безнең белән исәнләшми дә хәзер!

Беренче хатын. Баюлары житте, байлык күтәртә борынны. Нәрсәләре бар иде монда күчкәндә? Биш ел эчендә өйләрен мал белән тутырдылар. Ике холодильник, өч телевизор, магнитофон. Машина алдылар, гараж салдылар.

Газета укучы ир. Унбиш меңгә бакча алырга йөриләр дип ишеттем әле мин.

Беренче хатын. Кит ичмаса?!

Газета укучы ир. Китмим.

Беренче хатын. Абау җаным! Кайлардан гына ала икән кеше шул тиклем акчаны?!

Газета укучы ир. Алмыйлар, урлыйлар!

Беренче хатын. Тимерчелектә генә эшли диләр лабаса аны, анда нәрсә бар икән урларлык?

Газета укучы ир. Һәй, менә шул тимерчелектә дә инде хикмәт. Хөкүмәт тимереннән чардуган ясап кына да күпме эшлиләр... *(Икенче хатынга.)* Бишенче каттагы врачның хатыны авылга кайтып китте, яшь кенә бер нәмәрсә ияртеп кайтты бая. Карап төш әле шуларның тәрәзәләрен, нишлиләр икән. Йокы бүлмәләрендәге тәрәзәгә шітор кормаганнармы.

**Йөгереп диярлек Кәләпүш кигән ир керә.**

Кәләпүш кигән ир. Өендә! Трубкасын алды, өендә!

Газета укучы ир. Әйтеп торам лабаса мин сезгә!

Кәләпүш кигән ир. Номерын җыйдым да, тын да алмый тыңлап торам. Алло, алло, Рустемчик, ты что-ли? Что-то больно скоро доехал, ди. Мин җавап бирмәгәч, әй өрә трубкасына өф-өф итеп, әй өрә.

Икенче хатын. Егетнең исеме Рөстәм булып чыга болай булгач. Күрегез әле оятсызны! Үзе укытучы, үзе яшь буынга коммунистик тәрбия бирергә тиеш кеше. Өстеннән роного язып бирергә кирәк, эшеннән кудыртырга!

Газета укучы ир. Аңысын уйлашырбыз, әлегә кушканны эшлә. *(Икенче хатын чыга.)* Гомер эчендә безнең белән бер авыз сүз сөйләшмәгән кеше нигә бүген безнең белән сөйләшә икән дип уйлаган идем шул мин аны. Боровой Матюшинога кич куна гөмбә җыярга барабыз, имеш. Эз адаштыру өчен безнең белән сөйләшеп торган ул кичә. Инде менә беленде хәзер нинди гөмбә җыйганы. Төне буе тыңлап чыктым мин аларның ничек итеп гөмбә җыйганнарын.

Кәләпүш кигән ир *(борынын җыерып, Беренче хатынга)*. Һаваны синме соң бозып утырасың?

Беренче хатын. Утырсам — иснә!

Кәләпүш кигән ир. Кит инде, иманстыз!

Беренче хатын. Бер кая китмим! Җаны барның җиле бар. Саф һавада утырганда да кысталып утырыр хәлем юк әле.

**Сәхнәгә бик затлы киенгән бер хатын керә, утыручылар белән мөлаем гена исәнләшеп, подъездга кереп китә.**

Кәләпүш кигән ир. Колагына шул тиклем бриллиант асмаса, карак икәнлегемне белмәсләр дип курка ахры бу ахмак!

Беренче хатын. Иремнең әнисе бүләк итте ди ләбаса!

Кәләпүш кигән ир. Итте! Аның кайнанасы гомер буе текстильдә эшләде, алырсың текстильдә эшләп бриллиант.

Беренче хатын. Ире күп аладыр, бәлкем.

Газета укучы ир. Аның ире йөз сиксәнне ала. Ну, премиясы-ние белән үзенеке дә шул чама бардыр. Ике кызлары буйга җиткән, көн саен кием алыштыралар, колакларында да, бармакларында да алтын да, асыл таш. Менә моның үзенең колагындагы алкалар уникe меңгә алынган, диләр.

Беренче хатын. Әстәгъфирулла! Абау җаным, кайлардан гына ала икән кеше шул тиклем акчаны?!

Газета укучы ир. Алмыйлар, урлыйлар! Ул бит Татпотребсоюз кибетендә эшли. Сәүдә эшендә карак өстендә карак утыра лабаса анда.

**Сәхнәгә 35—40 яшьләр чамасындагы шактый алама киенгән бер ир кеше керә. Бу — Флакон. Ул Беренче хатын янына узып, колагына нидер әйтә. Беренче хатын ризасызлык белдереп башын селки.**

Флакон. Әни-бәгърем!

Беренче хатын *(катгый рәвештә)*. Юк!

Флакон. Бер генә сум, әни-бәгърем!

Беренче хатын. Сорама. Бирмим! Юк!

Кәләпүш кигән ир. Нәрсә, Флакон, баш авыртамыни? Нигә соң түзәтмисең?

Флакон. Шанс юк... Әни-бәгърем, бер генә сум! Кибеткә биш ящик тройной кайтты, сатып бетерәләр бит инде!

Беренче хатын. Бирәлмыйм, сорама. Пенсиягә хәтле әле биш көн яшисе бар, акчам ипилек кенә.

Флакон. Әни-бәгърем, бер генә сум!

Кәләпүш кигән ир. Җырла теге җырыңны, Флакон, үзем биреп торам бер сум!

Флакон. Кайсы җырны?

Кәләпүш кигән ир. Соң, бар лабаса инде синең әниеңнән аракыга акча сорап чыгарган җырың.

Беренче хатын. Җырлама!.. *(Кәләпүш кигән ирга.)* Баланы мыскыл итеп кушамат чыгарган — Флакон, имеш. Кайдан килеп Флакон булсын ул? Баланың законный исеме бар — Җәүдәт!

Кәләпүш кигән ир. Мин чыгарган кушамат түгел лә ул. Бергә эчеп йөргән алкаш дуслары кушкан бит ана Флакон дип. Тройной одеколон эчкәнгә күрә.

Беренче хатын *(Флаконның җырларга каршы түгеллеген күреп)*. Җырлама, балам, җырлама!

Кәләпүш кигән ир. Тыңлама син ананны, Флакон! Әйдә, җырла!

Беренче хатын. Җырлама дим, бичара бала! Алар бит синнән дә, миннән дә көләләр!

Флакон. Бир бер сум — җырламыйм!

Беренче хатын. Акча юк дип әйтеп торам лабаса мин сиңа!

Флакон *(җырлый. Ул җыр башлауга, Беренче хатын подъезд эченә кереп китә)*.

Әнием-бәгърем, кибеткә барырга,
Яртыны алырга биргәнсең аяклар,
Яртыны салгач та, исереп аугач та
Таянып кайтырга бирмәгән таяклар.
Куеның гөлбакча, шул бакчада — букчаң,
Букчаңда бар акчаң, бир инде бер сумың,
Бирсәң бер сумыңны, төзәтсәм башымны,
Ай белән кояшны бирермен үзеңә!

**Тыңлап торучылар шаркылдап көлешә-көлешә кул чабалар.**

Кәләпүш кигән ир. Молодец, Флакон, булдырасың! Илһам Шакировларың бер читтә торсын син җырлап торганда.

Шушы тиклем тавышың була торып, нигә соң син артист булып кына китмәдең?

**Подъездан Беренче хатын чыга.**

Флакон. Заводта эшләгәндә мине двореңка хорга чакырганнар иде. Бозылган-бозылган бозылып бетим инде дип, йөри дә башлаган идем — хатын ташлатты.

Кәләпүш кигән ир *(Флаконга бер сум биреп)*. Бурычка! Шабашкада акча эшләп алгач кайтарырсың!

**Флакон тиз генә чыгып китә.**

Беренче хатын. Баланы яраткан эшеннән дә аерды, сука, үзе дә ташлап китте. Шунда двореңка озаграк йөргән булса, бәлкем үзеннән берәр артист чыккан булыр иде. Мәктәптә бишлегә генә укыган бала бит ул. Ул укып чыккан китапларның исәбе-хисабы юк. Китапханә мөдире әйтә торган иде, китапханәдә синең малаең укып чыкмаган китап калмады инде, мин аңа хәзер китапларны өемнән алып килеп укытам, дип. Чыгарган шигырьләрен стена гәзитләренә баса торганнар иде. Ике шигырен хәтта балалар гәзитендә басып чыгардылар, ун сум акча да җибәргәннәр иде. Шул акчага үзенә ун мороженое, миңа торт алып кайтты. Класс җитәкчесе әйтә иде, синең бу малаең класста беренче, моннан йә берәр шагыйрь, йә берәр артист чыгар, дип. Шушы заводка кергәч кенә, эчәргә өйрәнеп кенә харап булды бит бу бала!.. *(Подъезд эченнән бер хатын чыгып китә.)* Әстәгыфирулла, әллә моның тагын корсагы бар?!

Кәләпүш кигән ир. Бүген күргән!

Беренче хатын. Әнекәчкенәем! Дүрт бала өстенә, бишенчегә!

Газета укучы ир. Менә шуңа азык-төлек талонга калды да инде хәзер. Дуңгыз шикелле балалап торгач, кайдан җитсен ул ризык.

Беренче хатын. Үскәч, кем була дип уйлыйлар икән ул балаларны? Барыбер алкаш булалар бит инде алар үсеп җиткәч. Йә берәр жулик. Монысының юньләп эшләгәне дә юк, бала таба да, бала таба. Ул эт көтүе хәтле бала-чаганы ашатып-киендереп бетерүе генә дә ни тора бу заманда.

Газета укучы ир. Урлыйлар! Аның ире бит хромда эшли.

Беренче хатын. Васька тагын салып кайтып килә. *(Үзен култыклаган кеше белән тарткалаша-тарткалаша подъездга бер исерек уза.)* Көн саен эчәргә кайдан акча ала икән бу?

Газета укучы ир. Урлый! Аның кайда эшләгәнен белмисең што-ли.

**Шактый зур әрҗәне икесе ике яктан күтәргән килеш, Бакчачы карчык белән Айрат керә. Бакчачы карчыкның икенче кулында варенье һәм компот банкалары салынган букча.**

Бакчачы карчык *(әрҗәне утыргычка куеп, янәшәсенә үзе дә утыра)*. Ух алла, эт булып арыдык!.. Утыр, Айрат улым, син дә утыр, бераз ял итеп алыйк... *(Айрат әрҗәнең икенче ягына утыра.)*

Беренче хатын. Бу нинди малай инде тагын?

Бакчачы карчык. Бу — үзебезнең детдом малае, Айрат. Иптәшләреңне кунак итәрсең дип, бакчага алмага алып барган идем. Иртәгә безнең Айратның туган көне бит, апасы... Ух алла, бик арыдык шул. Автобуска хәтле бик ерак барасы...

Беренче хатын. Ул банкыларда нәрсә, вареньемы? Бир әле безгә дә берсен, тәмләп бер чәй эчик әле!

Бакчачы карчык. Ә-ә, нигә соң карлыган җыешырга бармадың, варенье яраткач? Чакырдым лабаса мин сине. Үзеңә дә берәр чиләк җыеп кайтырсың, дидем. Бармадың. Үстергән карлыганны җыярга ирендең!

Беренче хатын. Соң, җәһәннәм арьягында дисең ләбаса син бакчаңны. Йокының самай татлы чагында торып китәргә кирәк.

Бакчачы карчык. Менә шул татлы йокыңны кабып эч инде алайса чәеңне дә. Заводта жир биргән чакта ник алмадың? Теләгән кешенең һәммәсенә бирделәр ләбаса ул чакта жирне. Син алмадың. Ул бакча үсеп житеп, жимеш бирә башлаганчы мин үләм инде диден. Утыртасың, үстерәсең бар иде. Үзең үлсәң, балаларыңа, оныкларыңа калган булыр иде.

Беренче хатын. Үзләре үстерсеннәр. Безгә кем, нәрсә калдырды?

Бакчачы карчык. Җәй аенда, җиләк-җимешнең өлгергән чагында, бер җиләк кабарга тилмереп утыр инде, алайса. Менә мин жир алдым да, утырттым, карап үстердем. Үләм дип тормадым, синнән картрак булсам да. Хәзер менә шаулап торган бакчам бар. Җиләк-жимешне кая куеп бетерергә дә белгән юк хәзер.

Беренче хатын. Бик беләсең. Базардан кайтып та тормыйсың.

Бакчачы карчык. Сатам шул. Сатам! Сиксәнгә житкән башым белән карап үстергәнне җыеп кайтып, әллә сиңа ашатыйммы?

Беренче хатын. Сатып алган җиләгең түгел ләбаса, күрше хакы — алла хакы дигәннәр, йә, бир инде безгә әнә шул бәләкәй банкыңны!

Бакчачы карчык. Алла хакы булса да бирмим. Үзең үстер! Җәмиләңне җәеп, көн озын ишек төбендә ләчтит сатып утырма!

Газета укучы ир. Мәңге яшәрмен дип уйлыйсың инде син, әби. Бер аягың гүрдә бит инде синең. Бар җыйган малың урам этләренә калачак.

Бакчачы карчык. Калса — менә шул калганын урам этләре белән бергәләшеп, сез дә ашарсыз. Риза-бәхил!.. *(Айратка.)* Балакаем, бу авыр әрҗәне анда алып менеп тормыйбыз инде, син шунда гына утырып тор, бәбкәм, ярыймы. Мин хәзер әйләнеп төшәм... *(Банкалар салынган букчасын күтәреп подъездга кереп китә. Икенче хатын керә.)*

Икенче хатын. Врач үзе кухняда чәй кайнатып йөри. Алып килгән мармилашкасы журнал карап утыра. Бая кереп киткән ике егет артистка ишеге төбендә маташа.

Газета укучы ир. Нишләп маташалар алар артистка ишеге төбендә,— алар өйдә юк лабаса. Үзе гастрольдә, малае — спортлагерьга китте.

Беренче хатын. Ай алла, кемнәр икән соң алар, өй басып йөрүчеләр түгелдер ләбаса?

Кәләпүш кигән ир *(Газета укучы ирга)*. Кайда, теге нәмәрсәнне биреп тор әле, күрше, үзем бер карап төшим әле барысын да... *(Газета укучы ир куеныннан бинокль чыгарып бирә. Кәләпүш кигән ир чыга.)*

Икенче хатын *(Айратка ымлап)*. Бу нинди малай инде тагын?

Беренче хатын. Детдом малае, ди. Әбиебез бакчага эшләтергә алып барган үзен. *(Айраттан.)* Бакчада ниләр эшләдең?

Айрат *(әрҗәгә күрсәтеп)*. Менә бит, алма җыйдым.

Беренче хатын. Тагын нишләдең?

Айрат. Алма ашадым.

Беренче хатын. Тагын?

Айрат. Кишер ашадым. Шалкан ашадым.

Беренче хатын. Тагын нишләдең, тагын?

Айрат. Салат ашадым, компот ашадым. Варенье белән чәй эчтем.

Беренче хатын. Тагын ниләр эшләдең, тагын, тагын?

Айрат *(исенә төшереп)*. Тагын борчак ашадым. Кара миләш ашадым.

Беренче хатын *(түземен җуеп)*. Кара, һаман ашадым да эчтем, ашадым да эчтем! Мин бит синнән ниләр ашадың дип сорамыйм, ахмак малай, ниләр эшләдең дип сорыйм!

Газета укучы ир. Җир казыдыңмы?

Айрат *(аңламыйча)*. Ничек?

Беренче хатын. Соң, җирне ничек казыйлар соң, ахмак! Көрәк тотып, менә болай-болай итеп җир казыдыңмы?

Айрат. Юк.

Беренче хатын. Чүп утадыңмы?

Айрат *(аңламыйча)*. Ничек — утадыңмы?

Беренче хатын *(тәмам кабынып китеп)*. Күрегез әле бу ахмакны! Менә болай-болай итеп чүп утадыңмы?

Айрат. Әби чүпне үзе себерде, себерке белән.

Беренче хатын. Күрегез әле моны! Соң мин бит ул чүпне сорамыйм, чүп үләннәр турында сорыйм, ахмак малай!

Икенче хатын. Йә, аптыратма баланы. Шәһәр баласы кайдан белсен инде ул чүп утауның ничек булуын!

Беренче хатын. Су сиптеңме соң?

Айрат. Уйнадык! Анда бер малай бар, әбинең күршесендәге бакчала. Исеме — Илгиз. Без аның белән шампунь савытына су тутырып, су сибешеп уйнадык.

Беренче хатын. Җир дә казымагач, су да сипмәгәч, чүп тә утамагач, көне буе нишләдең генә син анда?

Айрат. Әә, мин әле тагын урман чикләвеге ашадым.

Беренче хатын. Урманга да бардыгызмыни?

Айрат. Бармадык.

Беренче хатын. Урманга бармагач, кайдан килде соң сиңа урман чикләвеге?

Айрат. Әби бирде.

Беренче хатын. Бу әрҗәдә нәрсә?

Айрат. Алма.

Беренче хатын. Безгә дә бир әле алма!

Айрат *(әрҗәне кочаклап)*. Аа, бу бит санаулы! Мин үзем санап тутырдым. Мин инде йөзгә хәтле саный беләм!

Беренче хатын. Ишетәсезме, әбиегез алманы детдом балаларына да санап кына биргән! *(Айраттан.)* Ничә алма сыйды соң инде шушы әрҗәгә?

Айрат. Сиксән дүрт!

Беренче хатын. Ууу, бик күп икән ләбаса! Йә, бир инде безгә берәр алма!

Айрат *(әрҗәне тагын катырак кочаклап)*. Әйтәм бит, бу санаулы! Безнең детдомда кырык ике бала. Сезгә бирсәм, кемгәдер җитми кала. Иртәгә минем туган көнем! Һәр балага ике алма. Бер кызыл алма, бер сары алма. Үзем сайлап җыйдым!

Беренче хатын. Бик саран малай икәнсең син... Ничә яшь тула соң инде үзеңә?

Айрат. Җиде!

Беренче хатын *(әрҗәнең икенче кырына утырып, югарыга күрсәткән була)*. Карагыз әле, самолет очып барамы соң ул? *(Айрат каерылып күктән самолет эзләгән арада әрҗәдән берничә алма алып, альяпкыч итәгенә яшерә.)*

Икенче хатын. Очып китте инде самолет, очып китте, күрми калдың!

Беренче хатын *(кулын каш өстенә куеп)*. Алла, аллә тиен йөри инде теге агач башында?.. *(Айрат читкә борылып агач башындагы тиенне эзләгән арада тагын берничә алма урлый.)* Әтиең-әниең юкмыни синең?

Айрат. Бар!

Беренче хатын. Ай алла, әтиең-әниең булгач, нигә соң син детдомда яшисең?

Айрат. Минем әти летчик! Фашистлар үтергәннәр аны.

Беренче хатын *(аптырап)*. Фашистлар? Нинди фашистлар? Кайсы сугышта?

Газета укучы ир *(хәйләкәр елмаеп)*. Шуны да аңламыйсың инде, дивана. Аның әтисен немец фашистлары үтергән, Бөек Ватан сугышында. Моннан кырык ел элек. *(Айратка.)* Шулай бит?

Айрат. Ийе!

**Айраттан башкалар шаркылдап көлешәләр. Айрат аларның нидән көлүләрен аңламыйча, аптырап, әле берсенә, әле икенчесенә карый.**

Газета укучы ир *(көлүдән туктап)*. Синең әтиең бер билгесез солдат, зина баранчыгы. Йә булмаса, бер алкаш!

Айрат *(утырган урыныннан атылып чыгып, еларга җитәрлек хәлдә)*. Юк! Минем әти летчик! Минем әти летчик! Аны фашистлар үтергәннәр, Бөек Ватан сугышында!

**Олылар тагын да катырак итеп көлә башлыйлар. Кәләпүш кигән ир керә.**

Кәләпүш кигән ир *(биноклне Газета укучы ирга сузып)*. Чәй эчеп утыралар, грузинский, первый сорт.

Газета укучы ир. Өстәлләрендә шешә-мазар күренмиме?

Кәләпүш кигән ир. Юк, күренми.

Газета укучы ир. Ә теге егетләр артистка ишеге төбендә нишлиләр?

Кәләпүш кигән ир. Алар күренмиләр анда. Артистканың ишеге төбендә беркем дә юк.

Икенче хатын. Туктагыз әле, бу нәрсә була соң инде? Подъезддан чыкмадылар. Кая киткәннәр соң алар?

**Подъезддан Бакчачы карчык чыга.**

Бакчачы карчык *(Айрат янына килеп).* Әйдә, балакаем, үзебезгә кайтып, алмалырыбызны иртәгәгә хәтле берәр җиргә яшереп куеп торыйк... *(Әрҗәне икесе ике яктан күтәреп чыгып китәләр.)*

Беренче хатын. Туймаса да туймас икән кешенең нәфесе! Акчасын кая куя икән бу? Книжкедә микән? Юри-марый әйткәндәй, бер машиналык акчасы бардыр моның.

Газета укучы ир. Бер машиналык? Бер «Жигули»лек дисеңме? Әйттен сүз! Ай саен йөз егерме сум пенсиясы килеп торамы? Тора! Ай саен детдомнан йөз сумны каера. Күпме кыяр-помидор, күпме җиләк-җимеш сата. Бер ашка турарлык укропны да егерме тиенгә саталар лабаса алар! Ашап-эчүе детдомда — шушы ятим балалар өлешен ашап ята лабаса ул! Беләсең килсә, аның бит «Жигули» алырлык акчасы бар!

Беренче хатын. Әстәгыфирулла!

**Подъезддан шактый авыр капчык күтәреп Бибиси ханым чыга.**

Бибиси ханым. Чукынган! Зараза! Былтыр хлебзавод грузчигы Сәләхидән аракы биреп алган егерме кило оным кортлаган!

Беренче хатын. Кортлаган? Нишләтмәкче буласың соң инде ул онны?

Бибиси ханым. Нишләтим? — түгәм! Кортлаган он ашап утырырга ачлык ел түгел ич!

Беренче хатын. Ай алла, түкмә! Иләгәч, корты иләктә кала аның. Үземә бир!

Бибиси ханым *(капчыгын Беренче хатын алдына ташлап).* Мә!.. Һай җаным, тоз белән шырпыга чират алган идем, чиратым җитәдер... *(Йөгереп диярлек чыгып китә.)*

Беренче хатын *(капчыктагы онга кулын тыгып карап).* Полковникның бөтен байлыгына хуҗа булып калды да, кая басканын да белми хәзер... *(Альяпкыч итәгенә яшергән алмаларын чыгарып, Газета укучы ирга, Кәләпүш кигән ирга, Икенче хатынга бирә.)* Мәгез, апагыз исән чакта сыйланып калыгыз. *(Бер алманы кулы белән ышкып, ашый башлый.)* Алмасы тәмле икән үзенең. *(Икенче хатынга.)* Аша, алмасы бик тәмле!

Икенче хатын. Әй, әллә нәрсә, аппетитым юк әле бу арада.

Кәләпүш кигән ир. Әллә эләкте микән?

Икенче хатын. Әй, китсәнә!

Кәләпүш кигән ир. Кулыңны бик селтәмә әле син, бик селтәмә. Әнә беркөн радиодан сөйләп тордылар, әллә кайсы гына илдә житмеш яшьлек бер карчык бәби тапкан.

Икенче хатын. Китсәнә! Теге начар авыру булмаса ярый инде, шул булганда да аппетит бетә диләр бит.

Беренче хатын. Ай алла, нигә соң врач чакырмыйсың?

Икенче хатын. Аппетит булмаган өчен генә врачны өйгә чакырып китерү уңайсызрак инде. Вакыт табып, үзем бер барырмын әле.

Беренче хатын. Син үзең барма, өйгә генә чакыр. Үзең барсаң, аларның йә талоннары беткән була, йә врачлары булмый. Урыныңны җәеп куй да, берәрсенә кереп, телефоннан гына шалтырат. Чакыргач, килми хәлләре юк.

Икенче хатын. Урын өстенә ятып авырмагач, врачны өйгә чакырып китерү килешер микән соң?

Газета укучы ир. Нишләп килешмәсен! Хөкүмәт өчен эшли-эшли без күпме сәламәтлегебезне югалттык! Килсеннәр, карасыннар, тикшерсеннәр! Аларга бит хөкүмәт шунын өчен акча түли!

Икенче хатын. Безнең врачның үзен дә бик таза димиләр, кан басымы югары диләр.

Газета укучы ир. Кан басымы югары булса, йөрмәсен житмешкә житкәнче эшләп, пенсиясын ашап өендә генә утырсын!

**Подъезддан түшәк җәймәсенә төреп бәйләнгән шактый зур төен күтәреп, алдарак кереп киткән ике егет чыгып уза.**

Кәләпүш кигән ир *(чыгып китүчеләр артыннан авызын ачып беравык карап торганнан соң, шатлыгын яшерә алмыйча).* Артистканың японский телевизорын алып киттеләр ләбаса бу малайлар!

Беренче хатын. Ай алла, милициягә шалтыратырга кирәк!

Газета укучы ир. Кирәкми! Без берни күрмәдек, без бернәрсә белмибез.

Икенче хатын. Шаклар да каткыч яхшы күрсәтә дип әйткән иде инде аны кемдер.

Кәләпүш кигән ир. Күрсәтә генәме соң! Ул японский телевизорны бер күрсәң, безнең телевизорларга лачт иттереп төкерергә генә кала.

Икенче хатын *(урыныннан торып).* Карап төшим әле, ничек кердeләр икән. Ачкыч яраттылар микән, ишекләрен ваттылар микән...

Газета укучы ир. Урыныңда утыр! Анда менеп, бармак эзләреңне калдырып, милициягә таскать итүләрен телисеңме әллә? Ишетсен колагыгыз: без берни күрмәдек, без бернәрсә белмибез!

Кәләпүш кигән ир. Ну шәп тә эшләделәр соң бу малайлар! Тотылмасалар ярый инде.

Икенче хатын. Сез шунысын әйтегез әле, Японияга барып ун көн күтен селкеп биеп йөрде дә, дөнья хәтле мал төяп кайтты. Без монда гомер буе эшләп тә андый телевизорлар ала алганыбыз юк. Әллә жиде мең тора дип сөйләделәр инде шул телеви-

зорны. Ай, кызык та иттеләр соң артистканы!

Газета укучы ир. Карасын инде менә хәзер японский телевизор! Тагын бер кабатлыйм: без берни күрмәдек, без бернәрсә белмибез. Бибиси алдында ычкындырып ташламагыз тагын,— бөтен дөньяга таратыр.

**Сәхнәгә бер кыз керә.**

Бер кыз (*Икенче хатын янына узып*). Мин тагын сезнең янга килдем, Искәндәрова. Алыштырдыгызмы паспортыгызны?

Икенче хатын. Юк әле.

Бер кыз. Искәндәрова, йортлар идарәсендә паспортын алыштырмаган бер кеше калды. Ул кеше — сез. Оят түгелме сезгә?

Икенче хатын. Бәтәч, моның кайсы җире оят?!

Бер кыз. Сайлаулар якынлаша. Иске паспорт белән сайлауга катнаштырмаячаклар.

Икенче хатын. Катнаштырмасалар — бик исем китте! Мин болай да сайлауларга йөрмим. Иртәрәк барсаң, буфетта әфлисун була икән дигәч, сугыштан соң бер барган идем, шуннан соң барганым юк.

Бер кыз. Штраф салабыз!

Икенче хатын. Паспорт алыштырмаган өченме? Хакыгыз юк.

Бер кыз. Райсобеска хәбәр итеп, пенсиягызны бирдертмәячәкбез!

Икенче хатын. Бирдертми генә карагыз. Минем егерме ел эшләп алган пенсиямны бирдертми генә карагыз — судка биреп, күрмәгәнегезне күрсәтермен!

Бер кыз. Карагыз аны, Искәндәрова, барыбер сезгә карата чара күреләчәк. Начальник шулай дияргә кушты.

Икенче хатын. Бик исем китте минем синең жулик начальнигыңа! Мин үзем аның өстеннән язып бирәм әле... Беләсеңме нәрсә, үскәнем. Начальнигыңа кайтып әйт, әгәр ул чын ир булса, без пенсионерлар белән буташмасын, хәленнән килсә, әнә фотографиядагы халтурщикларга карата чара күрсен. Юри мыскыл итеп, әле илле яше генә тулган хатынны пәри карчыгы төсле итеп ясап бирәләр. Инде мин барып төшмәгән фотография Казанда калмады да. Берсендә дә фотокарточкамны кеше күзенә күрсәтерлек итеп ясап бирмәделәр.

Бер кыз. Кайда ул карточкаларыгыз? Китерегез, шуннан бер әйбәтрәген сайлап алыйк!

Икенче хатын. Сайламый гына тор әле, яме. Мин аларның алганын берен ертып ташлый барам. Гомер буе йөртәчәк паспортыма нишләп мин пәри карчыгы сурәтен ябыштыртыйм?!

Бер кыз. Ярый, алайса, Искәндәрова, сезгә тагын бер ай срок бирәм. Зинһар өчен дип әйтәм, алмаштырыгыз паспортыгызны. Ичмасам, мине кызганыгыз, ничә мәртәбә килдем бит инде.

Икенче хатын. Килсәң — эшең шул. Сиңа бит хөкүмәт шуның өчен акча түли!

Беренче хатын. Мине дә убырлы карчык төсле итеп ясап биргәннәр иде, мин ябыштырттым тагын шуны... Матур итеп карточкага төшерә белүчеләр бетте хәзер.

Кәләпүш кигән ир. Әйе шул, үлеп беттеләр барысы да. Карточкага яхшы итеп төшерә белүчеләр дә калмады, матур күрсәтә торган көзге ясаучылар да үлеп бетте. Вәт бар иде көзгеләр без яшь чакта! Хәзерге көзгеләргә карасаң, лачт иттереп төкерәсе килә.

Газета укучы ир. Урлыйлар чөнки. Көзгене дә, карточканы да аны бит көмеш кушып ясыйлар. Көмешен салып җиткермиләр, урлыйлар.

Кәләпүш кигән ир. Киленең «Тасмада» эшләгәч, син аны беләсеңдер инде, күрше.

Газета укучы ир. Беләм шул. Әллә син үзеңне карак түгел дияр идеңме? Безнең йортта гына түгел, менә бу күрше йортларның да идәннәре заводтан син урлап чыккан буяу белән буялган.

**Җырлый-җырлый, шактый кәефләнгән Флакон керә.**

Флакон (*җырлый*).

Чылбырдай тезелеп,
Кайтыгыз, торналар,
Бу илдәй бәхетле
Ил тагын кайда бар?!..

Бер кыз (*Кәләпүш кигән ир янына килеп*). Сезнең дә исегезгә төшерергә куштылар. Инде өч ай квартирга түләмәгәнсез.

Кәләпүш кигән ир. Түләмәгән шул.

Бер кыз. Теге чакта партия взносы түләмичә оятка калган идегез инде.

Кәләпүш кигән ир. Төзәтсеннәр башта балкон ишегемне! Нәрсә өчен мин сезгә еллар буе квартплата түләп киләм? (*Бер кыз кулын селтәп чыгып китә.*) Ярты ел буе кухнядагы краным ябылып җитми, шапырдап су агып тора. Инде слесарь ничә килеп китте. Яртыны бирмәгәч, аннан-моннан гына боргалый да, икенче көнне үк тагын ага башлый. Кайдан җиткерәсең һәммәсенә дә яртыны? — аны бит айга икене генә бирәләр. Аннары, минем үземнең авызыма да тай типмәгән бит әле.

Флакон (*Бер кыз белән Кәләпүш кигән ир арасындагы сөйләшүне игътибар белән тыңлап тора да, подъезд төбендәге инвалид коляскасына кереп утыра*). Яхшы түгел, күрше, яхшы түгел. Килешми!

Кәләпүш кигән ир. Нәрсә килешми?

Флакон. Синең партия взносы түләми йөрүең яхшы түгел. Килешми сиңа, иптәш-товарищ. Коммунист кеше аңлы булырга тиеш. Сез бит безнең акылыбыз да, намусыбыз да, вөҗданыбыз да!

Кәләпүш кигән ир. Вөҗдан дип инде, пенсиягә чыккач та партия взносы түләп ятуның ниемә хаҗәте бар?

Флакон. Партиядән пенсиягә китмиләр, иптәш күрше!

Кәләпүш кигән ир. Китмәсеннәр тагын. Утыз ел партия взносы түләп яттым — ни файда булды шуннан миңа?

Флакон. Во! Партиягә менә синең шикелле үзенә генә файда эзләүче бәндәләр кереп тулды, шуңа менә шулайрак булып китте безнең эшләр.

Беренче хатын *(Газета укучы ирнең Флаконга карап-карап алуын күреп).* Улым, күп сөйләшәсең, кирәкмәгән сүз сөйләмә, улым.

Флакон. Әнә кичә радиодан ишеттем. Инде бәрәңгене дә Япониядән сатып ала башлаганбыз икән. Адәм мәсхәрәсе! Юк, мин үзем гласность яклы. Булсын ул гласность. Тик шулай да шул тиклем хурлыкны бөтен дөньяга кычкыру кирәкмәс иде. Россия Япониядән бәрәңге сатып ала — моннан да артык рисвайлыкның булуы мөмкинме?! Җир шарындагы коры җирнең алтыдан бер өлешен тәшкил иткән ил Япониядән бәрәңге, Италиядән макарон, менә шушы бармак очы гына хәтле Голландиядән май, патша Россиясенең иң артта калган бер кырые булган Финляндиядән колбаса сатып ала. Дөрес, безнең ул колбасаны күргән юк. *(Газета укучы ирга күрсәтеп.)* Ул колбасаны әнә теге персональный иптәш-товарищлар ашый... Турысын әйткәнгә үпкәләмә, иптәш күрше, сез, коммунистлар, хөкүмәт башына менеп утырганда биргән вәгъдәләрегезнең берсен дә үтәмәдегез. Ил алдында торган бер генә проблеманы да чишмәдегез. Киресенчә, юк кына нәрсәләрдән проблема ясап бетердегез. Бар иде бер юаныч, кесәңдә акчаң барда бер яртыны алып, шуны дуслар белән эчеп, тормыштагы бу бардакны беразга гына булса да онытып тора идек. Инде ул да калмады, аннан да проблема ясадылар... *(Күл селтәп.)* Әй! Житмеш ел хөкүмәт башында утырып, имчәк балалары өчен житәрлек кадәр имезлек тә эшләп чыгара алмадыгыз бит сез!

Кәләпүш кигән ир. Аның каравы бездә ракеталар менә дигән иде, бездән бөтен дөнья куркып тора иде.

Флакон. Ә нәрсәгә миңа миннән бөтен дөньяның куркуы? Миңа миннән бөтен дөнья курку кирәкми. Курыкмасын, хөрмәт итсен мине дөнья, менә шунда хикмәт.

Кәләпүш кигән ир. Әә. Менә хәзер бөтен властьны демократлар яулап алса, сине бөтен дөнья хөрмәтли башлаячак. Көн саен йокыдан торышыңа баш тәзәтү өчен бер флакон тройной китереп торачаклар.

Флакон. Эһ, чын демократлар түгел шул алар... Власть өчен көрәшкәндә битлекләрен алмаштырган шул ук коммунистлар бит алар. Шул ук жуликлар!

Кәләпүш кигән ир. Коммунистлар, ичмасам, үзләре дә урлый, башкаларга да урларга мөмкинлек бирәләр иде. Тик кызып китеп, чамасын гына уздырып җибәрмә. Ә бу демократ дигәннәреннән үзләренә дә, халыкка да файда юк.

Флакон. Ә син кайдан беләсең үзләренә файда юклыгын? Файда булмаса, власть өчен шул тиклем талашмаслар иде. Леонид Ильич Брежнев өчен эшләнгән квартирга кем кереп утырды соң?

Кәләпүш кигән ир. Кем?

Флакон. Кем! Үзең шуны да белмисең, үзең сүз көрәштерәсең.

Беренче хатын. Улым, бар өйгә кер, бераз ятып ал!..

**Флакон әнисен читкә этәреп, «Хасбулат удалой» җырын җырлап җибәрә.**

Газета укучы ир. Ну, Флакон, бәхетең, иптәш Сталин юк. Иптәш Сталин булса, бу сүзләрең өчен чукындырыр иде сине!

Флакон. Ә сез, иптәш-товарищ персональный, тавышызны чыгармагыз, шыпырт кына утырыгыз! Чистайдан Казанга күчеп килгәч тә, сезнең кем икәнлегегезне белмиләр дип уйлыйсызмы әллә? Сезнең кебекләр шулай бит алар, персональный пенсиягә чыгалар да, шылалар. Чистайныкы — Казанга, Казанныкы — Мәскәүгә. Шулай итмәсәгез, еллар буе эшләп яткан этлекләрегез өчен сезне үтерәләр бит анда... Нәрсә, газета укыйсызмы? Укымагыз сез газета, иптәш-товарищ персональный, анда хәзер сезнең өчен сөенечле хәбәр булмас. Сез лучше белгән догаларыгызны укып утырыгыз, эчтән генә булса да. Кечкенә чакта әнкәгез бирәр дога өйрәткән булгандыр лабаса инде, әлхәмне генә булса да беләсездер. Варфоломей төне килеп житеп, халык үзегезне чукындырып куймасын. Гладилов урамындагы кибеттән ни өчен паек ашап ятканыгызны без бит беләбез! Икe сүзнең бере урлыйлар да урлыйлар. Урлыйбыз шул! Әллә сезгә генә урларгамы ил байлыгын? Халык бит сез, коммунистлар, акыллы булганга түгел, урлаганга күрә жан асрый.

Беренче хатын *(Флакон янында урсаләнеп).* И ходаем, азрак башына китсә, әллә ниләр сөйли башлый шушы бала! *(Газета укучы ирга.)* Күрше, сез, зинһар, исерек баланың сүзенә игътибар итмәгез!.. *(Флаконга.)* Кызыл билле машинага төяп алып китәләр бит сине, бала!

Флакон. Алып китмиләр, әни-бәгърем, курыкма. Беркая алып китмиләр. Үзең барып әйтмәсәң, ЛТП га да алып китмиләр. Тик син, әни-бәгърем, барып әйтмә генә... *(Яшь бала шикелле анасы куенына сыенып.)* Синнән башка минем бу дөньяда бер кемгә дә кирәгем юк бит, әни-бәгърем... *(Ике кулы белән маңгаен учлап, башын аска ия, акрын гына җыр башлый.)*

Чылбырдай тезелеп,
Кайтыгыз, торналар,
Бу илдәй бәхетле...

Юк, бәхетле түгел. Бәхетле түгел! Бәхетсез!.. *(Кәләпүш кигән ирга.)* Ә син, иптәш-товарищ күрше, ялганлыйсың. Партия взносы түләүдән файда булмады дип бөгештерәсең. Булды сиңа аның файдасы! Профком председателе чагыңда канат җәеп калдың син. Безнең ише партиясезләргә икенче сортлы кешеләр итеп кенә карый идең. Безнең өчен уйладыгыз, безнең өчен сөйләдегез. Ә безгә, рабочий класска, гегемоннарга, эшләргә, эшләргә һәм эшләргә. Җилкәгә менеп атланган унтугыз миллион түрәне ашатып туйдырырга кирәк бит!

Кәләпүш кигән ир. Әә, эшләп кинәндерәсең инде син!

Флакон. Ә нәрсә — бар иде минем эшләгән чакларым, начар эшләми идем. Минем мактау грамоталарым гына да бер кочак! Берсенә син дә кул куйган булгансың, профком председателе чагыңда... *(Уйга калып.)* Әйе, бар иде минем үз-үземне аямыйча эшләгән дурак чаклар. Хәзер менә эшләмим! Надоело! Во как надоело! *(Газета укучы ирга күрсәтеп.)* Әнә, сәләми колбасасы ашаучы персональныйлар эшләсен!

Газета укучы ир. Житте сина, Флакон, туйдырдың! Төш трибунадан!

Флакон. Төшмим! Сез житмеш ел буе трибунадан төшми лыгырдадыгыз, безгә сүз бирмәдегез. Инде менә хәзер безнең чират житте... *(Кәләпүш кигән иргә.)* Син бит бу квартираны да кызыл билетыңны селкеп алдың, Хисмәтуллиннарга тиешле квартира иде бит бу!.. Юк, үлгәнче взнос түләтеп торыр идем мин синең шикелле кәпәчле коммунистларны! Мин әле сезгә Нюренберг суды ясар идем. Атып үтерер идем мин сезнең ишеләрне!

Кәләпүш кигән ир. Атып үтерерлек минем ни гаебем бар? Сталин белән Берия эшләп яткан жинаятьләргә минем катнашым юк.

Флакон. Бар! Сез шундый булганга эшли алганнар алар ул эшләрне. Сез аларның һәр сүзенә сөләгәегезне агызып кул чабып утырганга!

**Подъездан Авыл карчыгының улы чыга.**

Авыл карчыгының улы. Исәннәрме сез, күршеләр, утырасызмы?

Флакон. Утырабыз, күрше, утырабыз. Әйдә, син дә утыр, дискуссияга катнаш.

Авыл карчыгының улы. Утырып ук торырга вакыт чамалырак шул... Әни һавага алып чыгыгыз дип аптырата. Жәй үтеп бетә инде, жәйне дә күрми калам бит, ди.

Икенче хатын. Соң, алып чыгыгыз. Алып чыгыгыз да, утыртыгыз үзен менә шунда. Килгәненә ничә ай, күрсәткәнегез дә юк әнигезне.

Авыл карчыгының улы. Йөри алмады шул ул, өч ай буе урын өстендә ятты.

Икенче хатын. Алып чыгыгыз, алып чыгыгыз. Сөйләшеп утырырбыз үзе белән матур итеп. *(Авыл карчыгының улы подъездга кереп китә.)* Кайда, теге әйберенне миңа да биреп тор әле, тагын бер карап төшим әле тегеләрне!.. *(Газета укучы ирдән бинокль алып чыгып китә.)*

Газета укучы ир. Әниләрен пропискага кертеп куеп, зуррак квартир сорап йөриләрдер әле болар. Череп баеп беттеләр дә, инде байлыклары өч бүлмәгә генә сыймый. Хәзер әнә кооперативта шухыр-мухыр китереп ята.

Кәләпүш кигән ир. Аена икешәр мең алалар, имеш.

Газета укучы ир. Хөкүмәте дурак булгач, алмыйча. Миллионер булып бетәләр ләбаса болар, эшләр болайга киткәч!

Флакон. Аның караvы эшлиләр дә. Иртән сәгать биштә чыгып китә, кичке тугызда кайта.

Газета укучы ир. Кайтса! Әллә без эшләмәдекме вакытында! Төннәр буе... Төннәр буе эшләп чыгарга туры килә иде кайчак. Обкомнан шалтыраталар, Черек күлдән шалтыраталар, Мәскәүдән шалтыраталар... *(Кәләпүш кигән иргә. Флаконга бик ишеттермичә.)* Белосеңме, берсендә Лаврентий Павлович үзе... Ничек кенә эшләргә туры килмәде, болар кебек кылана алмадык. Чөнки без честно яшәдек. Болар кебек урлашмадык. Милиция нәрсә карый торгандыр.

Флакон. Милициянең вакыты юк. Милиция безнең белән, алкашлар белән көрәшә.

**Бер кулына урындык тотып, икенче кулы белән анасын култыклап, Авыл карчыгының улы чыга.**

Беренче хатын. Куй менә шунда урындыгыңны! Утырсын шунда рәхәтләнеп.

**Подъезд ишеге төбенә урындык куеп, шунда Авыл карчыгын утырталар. Флакон инвалид коляскасына утырган жирендә йоклап китә.**

Авыл карчыгы *(күзләре кояштан чагылмасын өчен кулын каш өстенә куеп)*. Һай, көне бигрәк матур икән бүген, сөбханалла! Ух алла! Бу көнне күрер көнем дә бар икән... Саулармы сез, барыгыз да!.. Улым, син бар, барасы жиренә бар! Мин менә шунда тынны күреп азрак утырып торыйм. Миңа иптәшләр дә бар икән монда, бакчи...

Авыл карчыгының улы. Мин сөт кибетенә генә барып киләм, әни.

Авыл карчыгы. Бар, улым, бар!

Авыл карчыгының улы. Сез күзколак булыгыз инде, зинһар.

Беренче хатын. Күз-колак булырга, бала-чагамы соң ул. Әнигез туп кебек икән әле, чәчрәп тора.

Авыл карчыгының улы. Тыштан гына шулай күренә шул ул... Әни, мин сөт кенә алып кайтыйм, алайса. Син шушында күршеләр белән сөйләшеп утырып тор.

Авыл карчыгы. Бар, улым, бар! *(Авыл карчыгының улы чыга.)* Сөбханалла, ишек алдыгыз хәйран матур икән, агачлар күп. Сез шушы йортта торучылармы соң?

Беренче хатын. Әйе, шушы йортта торабыз, әби, шушы подъездда.

**Икенче хатын керә.**

Икенче хатын *(бинокльне Газета укучы иргә сузып)*. Чәй эчәләр.

Кәләпүш кигән ир. Ул нинди бетмәс чәй эчү булды инде. Йәле, тагын бер карап төшим әле! *(Бинокльне алып чыга.)*

Икенче хатын *(Авыл карчыгына)*. Нихәл, әби, исән-сау гынамы, терелдеңме инде?

Авыл карчыгы. Аллага шөкер, кызым.

Икенче хатын. Озак авырып яттың син, әби. Авылдан алып килгәннәренә ничә ай — күргән дә юк үзеңне.

Авыл карчыгы. Бик озак авырдым шул. Яз башында кайтып алганнар иде, инде менә жәй дә үтеп бара.

Икенче хатын. Кайсы жирең авырта соң синең?

Авыл карчыгы. Йөрәк дип әйтәләр инде, йөрәк. Приступлар була. Тик торганнан менә шушы жирдән китереп кысып ала кайчак... Бүген яд көнемени — эшкә бармагансыз.

Беренче хатын. Безгә көн саен ял, әби, без пенсионерлар. *(Авыл карчыгының*

*гаҗәпләнүен күреп.)* Эшләмәдек түгел, вакытында эшләдек.

Авыл карчыгы. Сөбханалла, бик яшь күренәсез ләбаса.

**Кулындагы кәгазьгә карый-карый яшь кенә бер кыз керә.**

Икенче хатын. Үскәнем, сез кемне эзлисез?

Яшь кенә бер кыз. Миңа җитмешенче квартира кирәк.

Газета укучы ир. Кем кирәк анда сезгә җитмешенче квартирада?

Яшь кенә бер кыз. Миңа Бикмиев Хәйрулла дигән кеше кирәк.

Газета укучы ир. Мин ул Бикмиев Хәйрулла. Йомышың нидә?

Яшь кенә бер кыз. Исәнмесез, абый!.. *(Бик зур сагаю белән, һәр әйткән сүзенең Газета укучы ирдә нинди тәэсир калдыруын күзәтеп.)* Мин сигезенче больницада медсестра булып эшлим, абый... Үзегез дә белә торгансыздыр инде, бездә бит сезнең энегез ята... Ничек диебрәк башлап китим икән... Хәле бик әйбәт түгел инде энегезнең, абый. Сәламәтләнүенә өмет бик аз дип әйтә врачлар... Энегезнең хәле бик начар, абый... Шушы бер-ике көн эчендә энегез үләчәк.

Газета укучы ир. Аңа үләргә күптән вакыт.

Яшь кенә бер кыз. Мине сезнең янга энегез җибәрде, абый. Ул үзенең үләчәген сизә. Аның сезнең белән бәхилләшеп үләсе килә.

Газета укучы ир. Бирмим мин аңа бәхиллегемне. Кайтып әйт үзенә, бәхиллегемне бирмим, мәңге бәхил түгел, дип әйтте диген. Тилмереп, изаланып, чукынып бетеп үлсен!

Яшь кенә бер кыз *(беравык аптырап карап торганнан соң)*. Үлем түшәгендә яткан кешегә шундый сүз тапшырырга сез мине кем дип беләсез, абый?!.. *(Чыга.)*

**Пауза.**

Авыл карчыгы. Шулай килешер микән соң, туган? Әҗәл белән тартышкан адәм баласына бәхиллек бирмәү ярап бетәр микән? Бер-береңә карата шәфкать-мәрхәмәтле булу кирәк дип әйткән ләбаса китапта да. Ачу саклау зур гөнаһ дигән. Барып бәхилләш син энең белән. Кем белә, бәлкем синең бәхиллегеңне ишеткәч, әҗәл газаплары җиңеләеп, терелеп китәр. Бу дөньяда без барыбыз да кунак кына. Аллаһы Тәгалә каршысына барасылар бар ләбаса әле. Шул вакытта ни дип җавап бирерсең Аллаһы Тәгаләгә?

Газета укучы ир. Юк ул Аллаһы Тәгалә, әби! Алланы аны менә синең кебек наданнарны куркытып тотар өчен байлар белән муллалар уйлап чыгарганнар.

Авыл карчыгы. Аллага ышанмасаң да, туганың белән барып бәхилләш. Алай ярамый.

Газета укучы ир. Бармыйм.

Авыл карчыгы. Һай ходаем, шулай бик каты рәнҗеткән идемени соң үзеңне?

Газета укучы ир. Кечкенә чакта үзенең сыбызгысы белән уйнатмый иде ул... Бервакыт шулай әти Казаннан икебезгә ике сыбызгы алып кайтып бирде. Була иде ләбаса элек, менә шундый гына, чыпчык рәвешле итеп балчыктан катырып ясаган сыбызгылар. Сызгыртам дип авызыма кабып өлгермәдем, кулымнан шуып төште дә, ватылды минем сыбызгым, бер мәртәбә дә сызгыртып карый алмадым. Ә моныкы калды! Тәки бирмәде миңа үзенең сыбызгысын, бер генә мәртәбә сызгыртып карарга да бирмәде. Төнлә йокларга ятканда да әллә кайларга яшереп ята иде...

Беренче хатын *(Икенче хатынга)*. Әнә, хәләл җефетең килеп бара!

**Полиэтилен капчыкка салып сыра күтәргән Салып йөрүче ир күренә. Икенче хатын аның каршысына йөгерә. Икәүләп кырыйдагы агачлар артына сыеналар.**

Салып йөрүче ир. Кабарга бирәр нәрсәң юкмы?

Икенче хатын. Юк. *(Сумкасыннан стакан чыгарып бирә.)* Теге көнне нигә килмәдең? Пилмән ясап көтеп утырдым.

Салып йөрүче ир *(стаканга сыра салып эчә)*. Шулай килеп чыкты инде.

Икенче хатын. Әй, беләм лә инде, шул Маһирәңнән аерыла алмыйсың. Нәрсәсен табасың икән шуның!

Салып йөрүче ир. Соң, синдә нәрсә булса, анда да шул инде... *(Икенче хатын тотып торган стаканга сыра салып эчеп җибәрә дә, кочаклап алып, арт якларын тупас рәвештә капшый-капшый чытырдатып үбеп ала.)*

Икенче хатын. Кит, имансыз! Унбиш ел бергә яшәп, законлы иремә дә үптермәдем мин... Кайчан кич куна киләсең? Алып куйган тавыгым бар!

Салып йөрүче ир. Шәп нәрсә ул тавык. Булса шуның янында бер савыт.

Икенче хатын *(Салып йөрүче ирнең күлмәк якасын төзәткән булып)*. Савытын үзең кыстырып кил.

Салып йөрүче ир. Ха! Савытым булса, мин шул инде, апаем, синең янга килмим!

Икенче хатын. Йә, кызлар шикелле ялындырма инде!

Салып йөрүче ир. Ал тавык янына бер савыт — киләм!

Икенче хатын. Тавыгым да булгач, савытын да куйгач, мин дә шул, матурым, егетнең синең шикелле шәлперәймәгәнен табам.

Салып йөрүче ир. Шулай дисеңме?

Икенче хатын. Шулай дим!

Салып йөрүче ир *(сырадан бушаган капчыгын Икенче хатынга сузып)*. Иртәгә шушы вакытларга тавыгыңны пешереп куй.

Икенче хатын. Куна киләсенме?

Салып йөрүче ир. Кич кундырасың килсә, савытың да булсын! *(Тиз генә чыгып китә. Икенче хатын подъезд төбендәгеләр янына килә.)*

Авыл карчыгы. Көн узмый монда. Көнгә чыккач, кичне җиткезә алмыйча газиз булам. Эшләргә эш юк чөнки.

Беренче хатын. Сиңа тагын нинди эш кирәк инде, әби, шушы яшькә җиткәч.

Авыл карчыгы. Без, авыл кешеләре, эшсез утырырга өйрәнмәгән шул.

Беренче хатын. Өйрәнмәгән булсаң — өйрән. Рәхәтләнеп ял итеп ят, җуләр. Синең белән безгә эшләгән каләресе дә бик житкән. Без эшләгәндә ите дә, мае да кибет тулып ята иде. Инде менә яшьләр эшләп күрсәтсен, без ял итик.

Авыл карчыгы. Бик туйдым шул инде ял итеп ятып та. Үләр алдыннан ялның нигә хәжәте бар! Ял итеп ятасылар бик күп ләбаса әле анда... Юк, бер дә күнелемә ятмый минем кала тормышы. Үтерәбез дисәләр дә калмыйм. Исән-сау кышны чыксам, яз башында авылга кайтып китәм, алла теләсә. Бер-ике каз сатып алырга уйлыйм. Шулардан бәбкә чыгартып, бер-ике оя каз үстерәм, ходай насыйп итсә. Әле ярый үлеп китмәдем бу авырудан, исән калдым. Үлеп киткән булсам, теге дөньяда да тынычлап ята алмаслык үкенечем кала иде. *(Яктырып китеп, горурлык белән.)* Минем бит унсигез оныгым бар! Шуларның унҗидесенә каз мамыгыннан мендәр ясап бирдем, Мәскәүдәге улымның унөч яшьлек кызына ясап өлгерә алмадым, чираты житкәнче, авырып киттем. Аңа гына мендәр ясап бирмичә үлеп киткән булсам, үсеп житкәч, сорар иде бит ул бала, ни өчен бу әби мине генә шулай нәүмиз итеп калдырды икән? Ни өчен миңа гына мендәр ясап бирмәде икән? — дип... Яз гына житсен. Авылыма кайтып китәм дә, бер-ике оя каз үстереп, шул балага мендәр ясап бирәм, алла теләсә...

**Серкә шешәләре тутырылган ике зур букча күтәреп, Бибиси ханым килеп керә, шалтыр-шылтыр килеп, букчаларын утыргычка куя.**

Бибиси ханым. Уф, үләм дип торам, көчкә кайтып життем!

Беренче хатын. Нәрсә алдың инде тагын шул тиклем? Әллә серкә алган инде. Нәрсәгә дип алдың бу серкәне шул тиклем?

Бибиси ханым. Утыз бутилкә серкә алдым. Серкә бетәчәк икән бит! Алкашлар серкәдән аракы ясау әмәлен уйлап тапканнар икән. Валлаһи! Җиденче цехтан әллә нәрсә генә дигән порошок урлап чыгалар икән дә, шуны менә шуңа салалар икән. Кыскасы, кичен йокларга ятканда шул порошокны менә шушы серкәгә салып ятсаң, иртә торган төшкә шушы чистый спирткә әйләнеп куя икән!

Беренче хатын. Кит ичмаса!

Бибиси ханым. Валлаһи!

Беренче хатын. Җиденче цехта минем танышлар бар. Нәрсә дигән порошок икән соң ул?

Бибиси ханым. Менә анысын әйтмәде шул әле. Әйтергә курка. Бик яшерен дәүләт сере икән ул. Моны миңа беләсеңме кем әйтте? Йортлар идарәсендә эшләп йөргән слесарь Револь бар бит әле? Менә шул әйтте.

Газета укучы ир. Аннан кудылар бит инде аны! Эчүенә түзә алмадылар!

Бибиси ханым. Хәзер эчми инде, эчми, ташлаган. Пиво гына эчә икән хәзер, миннән бер кружка пиволык акча алып торды... Кыскасы, тоз чиратында басып торган чакта белдем мин бу эшне. Күрәм — бер кеше илле шешә серкә ала. Ай алла, мин әйтәм, нигә бу кеше шул хәтле серкә ала икән, әллә серкәнең дә бәясе күтәреләме микән? Шулай аптырап торганда шушы Револь килеп чыкты. Аның бит белмәгән нәрсәсе юк. Менә шул Револь аңлатып бирде миңа эшнең нәрсәдә икәнен. Тик әлеге порошокның исемен әйтмәде. Яртыны куйсам — куям, барыбер әйттерәм әле мин аны, алла теләсә. *(Авыл карчыгына игътибар итеп.)* Бу кем бу?

Беренче хатын. Җитмешберләрнең авылдан алып килгән аналары.

Бибиси ханым. Ә-ә-ә, саф һава суларга чыкканмыни. Бик әйбәт булган. Таныш булыйк инде, алайса. Мин шушы подъездда торам, әби-җаным. Исемем Бибинур. Бибинур ханым дип йөртәләр.

Флакон *(инвалид коляскасында йокымсырап утырган җиреннән)*. Си!

Бибиси ханым. Нәрсә ди бу?

Флакон *(һәр иҗекне әйткән саен Бибиси ханымга төртеп күрсәтеп)*. Би! Би! Си!

Бибиси ханым *(берни аңламыйча беравык Флаконга карап торганнан соң)*. Бу бүген тәмам боламык булган икән.

Флакон *(йокысыннан уянып бетеп)*. Бибинур түгел, Бибиси ханым дип йөртәләр сине артыңда!

Бибиси ханым. Әнекәй генәм! Күрсәтермен мин сиңа күрмәгәнеңне, минем мулла кушкан исемемне бозып, кушамат чыгарганың өчен! Әллә син мине үзең дип беләсеңме? Флакон! Флакон! Тройной одеколон флаконы!.. Юк-юк, әби-җаным, Бибинур. Бибинур минем исемем. Безнеңчәгә күчереп әйтсәң, нурлы йөзле кыз бала була дип әйтә торган иде әни. *(Муенына асылган сәгатькә карап.)* Абау җаным, сәгать бишенче киткән ич! Сәгать биштә йортлар идарәсендә иптәшләр суды лабаса бүген!

Беренче хатын. Нәрсә, кемне тикшерәләр?

Бибиси ханым *(канәгатьләнү белән шат елмаеп)*. Менә боларны гына кертеп бушатыйм да, сөйләрмен... *(Шалтыр-шылтыр килеп, подъездга кереп китә.)*

Газета укучы ир. Утырткан икән теге алкаш Револь бу ахмакны төп башына!

Беренче хатын. Ник, порошок дигәне дөрес сүз түгел микәнни?

Флакон *(җырлый-җырлый коляскадан тора)*.

> Чылбырдай тезелеп,
> Кайтыгыз, торналар.
> Бу иләй бәхетсез
> Ил тагын кайда бар?!

*(Подъезд төбендә утырганнарга күз йөртеп чыга да, аларның үзен аңламаячакларына төшенеп, аянычлы рәвештә күз селти. Җырлый-җырлый чыгып китә.)*

**Кәләпүш кигән ир керә.**

Кәләпүш кигән ир *(биноклыне Газета укучы иргә биреп)*. Иң кызыклысы башлана гына дип торганда, авызларына төкерим, алып кайткан нәмәрсәсе илән юа башлады, бусы — өеннән үк чыгып китте.

**Подъезддан ашкынган-ярсынган Бибиси ханым атылып чыга.**

Бибиси ханым. Унҗиденче йорттагы теге Бүтәкә Саймәне беләсез бит инде? Теге, моның гына буе. Ап-ак этләре дә бар.

Беренче хатын. Беләбез, беләбез.

Бибиси ханым. Алар астында торган Баклажан борын Хәкимҗанны да беләсез, ул шәмәхә борынны белмәгән кеше юк. Хатыны Настя-алкаш, парлашып эчеп йөриләр. Менә шул баклажан борын Хәкимҗан Бүтәкә Саймәләрнең эте өстеннән язып биргән булган икән. Этләре балконга чыгып сия, балконда тозлап куйган бер кисмәк кәбестәм әрәм булды, дип. Закускалары кыш буена җитәрлек булган, янәсе. Аларның балконнары боларның балконнары астында гына бит. (Кулларын берсе өстенә икенчесен куеп күрсәтә.) Юк, боларның балконнары тегеләрнең балконнарының өстендә... Әй, юк ла, тегеләрнең балконнары боларның балконнары астында. Әй, ярар инде, аңладыгыз бит... Кыскасы, боларга кәмиссия килгән. Кәмиссия алдында Бүтәкә Саймә әйтә икән. Минем Аппагым синнән тәртиплерәк, ул синең кебек теләсә кайда исереп егылып, теләсә кайда аунап, астына җибәреп ятмый, көне буе алып чыкмасаң да түзә, өйне дә, балконны да пычратмый, дигән. Кыскасы, бик ачуы килгән Баклажан борынның бу сүзгә. Ә Бүтәкә Саймә дәвам итә икән. Безнең балконнан сезнең балконга йомгак хәтле Аппак түгел, син үзең дә туры китерә алмыйсың әле, дигән. Әйдә бәхәсләшик, туры китерә алсаң, менә сиңа поллитр дип, бер бутилкә аракыны өстәлгә чыгарып та утырткан. Кыскасы, аракы күргәч, Баклажан борынның күзе тәмам калайланган. Кәмиссия члennарыннан да оялып тормыйча, әй тырыша икән бу Саймәләр балконыннан үз балконнарына туры китерергә, әй тырыша икән. Ләкин туры китерә алмый икән. Кыскасы, кызып китеп, Баклажан борын балкон рәшәткәсе өстенә менеп баскан. Балкон рәшәткәсенә баскан килеш, үз балконнарына җиффәрә икән бу. Барыбер туры китерә алмаган. Тегеләрнең дүртенче каттагы балконнарыннан ларк итеп җиргә егылып төшкән. *(Авыл карчыгы бер кулы белән йөрәген тотып, икенче кулы белән кесәләрен капшый башлый.)* Кыскасы, сигез кабыргасын, өч кулын сындырып, биш ай больницада ятып чыккан Баклажан борын. Больничный да түләмәгәннәр үзенә. Шул балконнан сиптереп маташкан чакта салган булган икән, имансыз, каныннан аракы тапканнар. Эчкән килеш имгәнгәннәргә больничный түләмиләр бит! Кыскасы, шул больничный акчасы белән бер кисмәк кәбестәнең хакын Бүтәкә Саймәдән түләтмәкче булып, судка биргәннәр болар. Халык суды боларның гаризаларын карамаган, йортлар идарәсе янындагы Иптәшләр судына җибәргән. Менә бүген сәгать биштә шуларны тикшерәчәкләр. *(Сәгатенә карап.)* Абау җаным, соңга калабыз ич, сәгать биш тулып килә. Әйдәгез тизрәк, юкса утырырга урын калмый аннары, теге көнне дә басып торырга туры килде ләбаса!.. *(Йөгереп диярлек чыгып китә. Аңа Кәләпүш киган ир ияргә.)*

Авыл карчыгы *(чыгып китүчеләр артыннан китә башлаган Беренче хатынга).* Кардәш, йөрәгем! Йөрәгемнең приступы башланды! Валидолым тәрәзә төбендә калган! Валидолымны гына алып төшеп бирсәнче!.. *(Бу сүзләрне ишетеп торган Икенче хатын тиз-тиз чыгып киткәннәр артыннан йөгерә.)*

Беренче хатын. Ни, мин ашыгам шул, әби, барасы җирем бар минем. Анныры, шунда хәтле менеп йөрергә минем үземнең дә йөрәгем бик үк таза түгел. Сабыр ит азрак, малаең хәзер кайтып җитәр... *(Тиз-тиз иптәшләр судына китүчеләр артыннан йөгерә.)*

Авыл карчыгы *(яныннан узып барган Газета укучы ирнең кулына чытырдап ябышып).* Алла хакына, туганкаем, тәрәзә төбеннән валидолымны алып төшеп бир! Үләм ләбаса!

Газета укучы ир. Үлмисең, әби, үлмисең! Малаең хәзер кайтып җитәр, алып төшеп бирер... *(Җирәнеп, Авыл карчыгының кулыннан кулын тартып ала да, чыгып киткәннәр артыннан китә. Йөрәген кулы белән тотып урыныннан торган Авыл карчыгы подъезд ишегенә таба бер-ике адым атлый да, гөрселдәп җиргә ава. Сәхнәдән читтә Флаконның җырлаганы ишетелә.)*

Чылбырдай тезелеп,
Кайтмагыз, торналар.
Бу илдәй рәхимсез
Ил тагын кайда бар?!..

ПӘРДӘ.

*Сентябрь, 1989 ел.*
*Переделкино.*

# УЛ — ТҮРДӘ

Сөенечле хәл — әдәбиятыбыз олы булганлыктан, аның түре киң һәм югарыда. Лаеклы әдипләребез генә әнә шул түргә күтәрелә, чөнки анда менү өчен әдәби талантыңны йөк аты итеп җигәргә, әдәбият мәйданын үзеңчә бизәргә кирәк. Шундый егәрле һәм оста язучыларыбыз арасында Ибраһим Гази (Ибраһим Зарифулла улы Мингазиев) да бар.

Ул 1907 елның 4 февралендә Кама Тамагы районының Олы Карамалы авылында туа. Бала һәм үсмер чагы балалар йортында уза. Аннары комсомол эше, журналистлык хезмәте — егерме ике яшеннән ул «Авыл яшьләре» журналының һәм «Кызыл яшьләр» газетасының мөхәррире була. Нәкъ шул вакытта аның беренче хикәяләре басыла.

Ибраһим Гази әдәбиятыбыз хәзинәсенә күп санлы кечкенә һәм зур күләмле хикәяләрен, «Онытылмас еллар» трилогиясен салды. Дөнья һәм рус классиклары әсәрләрен татар укучысына җиткерүдә хезмәте зур булды, аның җәмәгать эшчәнлеге публицистик мәкаләләрендә дә чагылды.

Сүзгә үтә таләпчән булу, фикерен төгәл һәм үтемле итеп әйтә белү хас иде аңа. Бу сыйфатын, мондый осталыгын аның әдәби әсәрләрендә дә күреп була, үзен тотышында да сизеп була иде. Боларга язылган һәм әйтелгән ике генә җөмләсен мисал итик.

Менә аның Фатих Хөснигә биргән бәяләмәсе: «Фатих Хөсни — үзе бер дөнья». Мәкаләнең шушы беренче җөмләсеннән үк күренекле замандашы иҗатына төгәл-тулы бәя биреләчәгенә укучыны ымсындырды Ибраһим абый.

Икенче мисал. Язучылар берлегендә — Матбугат йортының Тукай клубында — телебез проблемалары турындагы җыелыш ике көн барды.

Сөйләшүнең кызган чаклары еш булды анда. Иркенәеп фикерләшү бик тә таләп ителә иде. Әмма алгы рәтләрдә партия өлкә комитеты аппаратында эшләүчеләр дә утыра. Шул чакта җыелышта рәислек итүче Ибраһим абый:

— Иркенләп сөйләшергә дә ирек бирмисез, киләсез дә утырасыз шушында,— дип, хәтта төртеп күрсәтеп, залга ярып салды.

Моның өчен исә иман тота белергә кирәк иде.

«Гади кешеләр» романы турында матбугатта төрлерәк фикерләр әйтелде. (Мин дә китап нәшриятында әсәрне тикшерүдә кимчелекләр табарга тырышкан идем). Тискәре фикерләргә Ибраһим абый бер мәкаләсендә гадәтенчә бик җете гыйбарә әйтте: «Мин җил тегермәнен яздым, җил тегермәненнән су эзләп башыгызны катырмагыз!»

Ибраһим абый кыска, хәтта бик кыска хикәяләр остасы да иде. Аның журналның «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» бүлегендә урын алырлык әсәрләре шактый. Әмма «Тургай картаямы икән?» исемлесенә тиңе юктыр. Без журналга шушы кешелекле, җылы хикәяне тәкъдим итәргә булдык. Бу хикәя беренче тапкыр «Казан утлары» журналының 1966 елгы 11 нче санында басыла. Шул елда ук язучының ике томлыгының беренче томында урын ала. Төзәтүләр юк диярлек — кайбер абзацлар һәм тыныш билгеләре генә үзгәртелгән, ахырдан икенче абзац — тәнкыйтьчеләр өчен аңлатма абзац, дияргә кирәктер аны — сызылган. Түбәндә китереләчәк хикәя тексты шул ике томлыкның беренче томыннан алынды.

...Ибраһим абыйга 1997 елның февралендә туксан яшь тулган булыр иде. Сиксән еллыгына аның әсәрләренең өч томлыгы чыгарылган иде. Ә туксан еллыгына? Габдулла Тукай бүләгенә ия булган язучыбызны онытырга маташабыз түгелме? Яман хәл...

Инде укучыларыбыз игътибарына Ибраһим абый Газиның әдәби мәсьәләдә таләпчәнлеген раслаучы (ул минем хикәяләргә кагылышлы) матбугатта басылмаган бер мәкаләсен дә тәкъдим итәбез.

Мәгъсүм ХУҖИН.
1996 ел, декабрь.

## Ибраһим Гази

# ТУРГАЙ КАРТАЯМЫ ИКӘН?

хикәя

Шәйхәттәр бабай җәй көннәрендә, урамга чыгып, үзләренең капка баганасына сөялеп торырга ярата. Үткән-сүткән кешеләр, аңа сәлам биреп: «Нихәл, бабасы?» — дип китәләр, ә телгә үткен-рәкләр: «Аумасын дип әйтәсеңмени, Шәйхәттәр бабай, капка баганасын терәп торасыңмыни? Колхоз трутдин түлиме соң аудармый тотып торган өчен?» — дип, карт кешенең кәефе китәсен-китмисен дә искәрмичә, шаяртып узгалыйлар.

Әллә капка баганасы елдан-ел үсә, калыная бара инде, әллә бабагыз кечерәя, югары, соңгы берничә елда багана янында солы көлтәсе хәтле генә булып калды. Авылда аңардан картрак кеше юк, дип сөйлиләр. Имеш, ул, Әби патша заманасында ук солдатка алынып, бер чиләк аракыны ялгыз башы чөмереп бетереп, әллә кемнәрнең генә кара мунчаларын нигезе-ние белән авылның икенче башына күтәреп илтеп куйган... Анысы, Әби патша заманасында дигәннәре бик карт дип әйтүләре генә инде, билгеле. Ә мунчаны күтәреп илтеп куйган диюләренә ышанырга да була, яшь чагында ул яман көчле булган, дип сөйлиләр. Аның каравы, хәзер... Әллә чынлап та капка баганасы үскәннән-үсә, юанайганнан-юаная инде!..

Авылда тагын бер карт кеше бар. Анысы Гөлҗиһан әби... Шәйхәттәр белән бер чама, дип сөйлиләр. Яшь чагында бик тә матур булган, имеш. «Гөлҗиһан әби, син авылда матурларның матуры булган, дип әйтәләр?» — дигәч, әбиегез:

«Ией, кызым, мин узганда, җәяүле җиргә ятып карар иде, атлы атыннан төшеп карар иде,— дип әйткән ди.— Хәзер генә ул мине күргән кеше куркып кала, теге вакытларда... иех!... Саргаючылар күп булды минем өчен, берсе әле дә исән»,— дип әйткән, имеш.

Саргаючыларның берсен әлеге шул капка баганасын терәп торучы Шәйхәттәр бабайга юрыйлар. Имеш, бусы җиткән егет, тегесе җиткән кыз чакта араларында нидер булган... Хәер, авыл телендә йөргәннең барысына да ышана китсәң...

Шулай да Шәйхәттәр бабагызның үзеннән сорап бакканнар. Картыгыз башта бик озак кына аңламаганга салышып торган, кабат-кабат сорагач кына, көлеп җибәрергә иткән сыман, иреннәрен кыймыл-кыймыл китергән дә: «Кхххм...» — дип куйган ди. Бу «кхххм»ны, булган иде, дип әйтте, дип баралар. «Чишмәгә су алырга килгән җирендә кочаклап үпкәч, көянтәсе белән җилкәгә кундырган иде: янәсе, кеше алдында кулыңны икенче бик озайтмассың! Ә кич белән, мунча артында күрешкәндә, үзе куенга кереп утыра иде, соңгы әтәчләр кычкырганга чаклы кочактан чыкмый иде», дип әйтте, дип баралар. Икенчеләр исә, бу «кхххм» карт кешенең тамак язып җибәрүе генә булды, безнең сорауны ул бөтенләй аңламады да, димәкче булалар. Белмәссең...

Аңламадымы икән, ай-һай... Шәйхәттәр бабагыз үткәннәрне бик яхшы хәтерли, гүя аның хәтере моннан күп еллар элек борып туктатылган да шуннан бирле бер тапкыр да яңадан җибәрелмәгән. Авыл моннан әллә ничә еллар элек нинди булган булса, Шәйхәттәр бабай шул авылны гына белә кебек... Казан артистлары, концерт куярга килгәч, баганага сөялгән бабагызны күргәннәр дә:

— Клубыгыз кайсы урамда? — дип сораганнар. Бабагыз:

— Мәчет каршында,— дип өйрәтеп җибәргән.

Авылда мәчетнең юклыгына инде утыз ел! Шәйхәттәрнең бөтен сөйләшүе шушы «мәчет каршында»га бик охшап тора. Фәләннәр коесы, фәләннәр тыкрыгы — аның гел әйтә торган сүзләре, ә ул кое инде күптән юк, колхоз авылга артезиан коесы казытканга әллә ни гомер, суны электр чыгара, ә фәләннәр тыкрыгы урынында хәзер колхозның алма бакчасы... Ә Шәйхәттәр бабай өчен аларның гүя берсе дә юк. Хәер, монда да кайберәүләр, ул мутлыгы белән генә шулай итә, аның белмәгәне юк, көн буе урамда сөялеп тора-тора бөтен авылның нишләгәнен энәсеннән җебенә тикле белеп тора, аның саңгырау булып кылануы да мутлыктан гына, үзенә кирәкне бик ишетә ул, әнә теге вакытны... дип, моннан берничә еллар элек булган бер вакыйганы сөйләп бирәләр. Бер тапкыр шулай, Шәйхәттәр абзагызны саңгырауга исәпләп, аның алдында колхоз рәисе Мөхип белән кырчылык бригадиры Салихҗан икәү авыл халкын сүгеп торалар икән: янәсе, ялкаулыкның чигенә чыктылар, үз тамакларын гына кайгырталар, колхоз эшенә йөрмиләр. Шәйхәттәр бабай, баганага сөялгән килеш, барысын да ишетеп тора, имеш. Менә бервакыт Мөхипне: «Кил әле, улым, бирегә»,— дип, кул изәп, үз янына чакырып китергән дә тотынган тегене иләп кенә... «Син авыл кешесенең тамагын туйдыр әүвәле башта, аннары ялкау дип әрләрсең. Ничә ел инде трутдингә чыпчык туенырлык та ашлык бирмисез, әле дә рәхмәт әйтерлек безнең авыл кешеләренә, ачлы-туклы көннәр буе эшләп йөри...»

Мөхип бик зур кеше бит инде авылда... Аңардан зуррак шул тау башында жил тегермәне генә бар. Ничә еллар инде авылга сыя алмыйча йөри, борын югары, район башлыклары белән әшнәлек зур... Аларга балны тәпәне-тәпәне белән генә биреп җибәрә. Алма бакчасында алма өлгергәч, «Волга» белән килеп, алманың яхшысын гына төяп китәләр... Итне, майны әйтәсе дә юк инде... Шушыларның барысын да әйбәтләп кенә тезеп чыккан Шәйхәттәр бабагыз рәис Мөхипкә. Мөхип, каршы бер сүз әйтә алмыйча, тыңлап тора, ди шул. Шәйхәттәр бабагыз: «Мин багана төбендә генә басып торсам да бияләй эчендә бармак кыймылдатканыгызга тикле сизеп торам, миннән яшерә алмассыз...» — дип әйткән ди. Шунда Мөхип әйтә, имеш: «Мае да, балы да әрәмгә китми, Шәйхәттәр бабай, курыкма. Шунсыз комбайнарга, тракторларга запчасть алып булмый, май белән майлагач кына, запчасть шалт итеп кайтып керә, эшләр чиратсыз йөри башлый»,— дип акланырга тырышкан ди. Менә әйт син шуннан соң бабагызны саңгырау дип... Шушы вакыйга булып узгач, Шәйхәттәргә сәлам биреп китүчеләр кинәт күбәйде, югыйсә, ул барыбер ишетми, дип, аның ягына карамыйча гына үтәләр иде.

Анысы, мутлыгы да бардыр, ләкин картлыгы да бар... Бу авыл аның күз алдында авыл булды. Ул малай чакта инеш башында барлыгы биш-алты йорт кына иде. Әнә теге юан өянкеләр, башларында бүрек-бүрек карга оясы... юк иде бит. Аларны Шәйхәттәр бабагыз үзе утыртты. Тал чыбыгы кисеп алып кайтты да су буена төртте. Хәзер әнә карагыз аларга... Бишәү килеп кочакласаң да, колачың җитмәс... Гомер дигәнең... Искән җил белән бер икән: үтте дә китте. Бүген бала-чага атасына әйләнеп картаеп баручыларның бишектә аяк бармакларын имеп яткан чакларын белә бит әле ул. Төпсез ыштан киеп, урамда чапкан чакларын... Имән бармакларыңны маңгаеңа мөгез итеп куеп, Мөхипкә бер акаеп карасаң, чырый-чырый елап өйләренә кереп кача торган иде, ә бүген район нәчәлникләрен майлап йөри, авыл халкы өстеннән зур башлык... Акаеп караганнан гына курыкмый инде хәзер, шулай да бер өркетергә кирәк иде үзен: юкса, ансат эшләргә гел үз кардәшләрен генә утыртып бетергән — тегермәндә аныкылар, умарталыкта аныкылар, китапханәдә тагын үз нәселе... Авыр эшкә якын да килмиләр...

Бүген Шәйхәттәрнең күңеле нишләптер гел егет чагына кайтып төшә дә тора. Кояш та бүтән иде, дип әйтерләр, ди, картлар. Юк, кояш шушы ук иде, тургайлар да шушылар ук, сандугачлар да... Гөлҗиһан белән

булды, һай, булды... Әнә теге йөгереп үтеп баручы кызчык та картаермы икән? Аны да сөячәкләр бит инде, аны да кочакка кысачаклар. Кояш күрмәс, ә ай күреп торыр. Ай дигәнең Гөлҗиһан белән Шәйхәттәрне дә гел күреп торды... Ай белән тургай картаймый, алар гел булачак, ә менә Шәйхәттәр юк инде. Гөлҗиһан да юк, бик күптән юк... Теге, йортлары мәктәп катындагы Гөлҗиһан карчык, дисезме? Сүз ул бетәшкән карчык хакында түгел. Юк, бөтенләй башка Гөлҗиһан... Буйлары Идел камышы, күзләре ут иде ул Гөлҗиһанның... Кочакка кыскач, сөлек булып бөтерелә иде. Мулла, тәкбир әйтә-әйтә, Шәйхәттәрне ут эченә озатмаган булса, Шәйхәттәр фронтларда озак югалып йөрмәгән булса, кем белсен... Колчак килә, дигәч, Шәйхәттәр авылдан чыгып качты. Күрше урыс авылының Чтапан карт базарга печән алып бара икән, рәхмәт төшсен, печән астына кереп посарга рөхсәт итте. Шул килеш кызыллар ягына фиут Шәйхәттәрең... Гөлҗиһан да ул әйләнеп кайтканчы фиут... Ашыкты. Тургай күпме яши икән? Колхоз башлангач, ике ат житәкләп, колхозга барып керде. Мөхип ул вакытта юл тузанында ыштансыз уйнап утыра иде. Хәзер бостон кия, йортның менә дигәнен торгызды...

Кешеләр капка баганасына сөялгән Шәйхәттәргә сәлам биреп узалар. «Вәгаләйкем», дип кала бабагыз авыз эченнән генә... Кая ашыгып баралар соң бу кешеләр көрәкләр күтәреп? Булды, һай, булды... Мулла тәкбир әйтеп сугышка озатмаган булса... ашыкты Гөлҗиһан... «Вәгаләйкем», дип кала бабагыз. «Вәгаләйкем! Кая баралар көрәкләр күтәреп?»

Мөхип, тарантаска утырып, авылдан чыгып бара. Дишми генә узармы, дәшәрме?

— Шәйхәттәр бабай, замандашың Гөлҗиһан әби үлде бит, кабер казышырга бармыйсыңмы?

Тарантас чабып узды... Әллә капка баганасы кинәт бик каты үсеп китте!.. Шәйхәттәр бабагыз идән себеркесе хәтле генә булып күренә... Мөхипкә ул бер җавап та кайтармады...Тарантастан соң урамда тузан болыты эленеп калган иде. Кара болыт бик озак тарала алмыйча торды. Бабагызның күзләре урамнан узучыларны таный алмый...

— Ашыкты... Тагын ашыкты...—дип пышылдый иде аның иреннәре...

## Ерганак юл ала

*(Хикәяләр җыентыгы)*

Мәгъсум Хуҗинда мин яңа буяулар таптым, бу үзенчәлекле егет икән. Әгәр башка эшкә ташланмыйча, әдәбият эшенә бирелеп эшләсә, бу егеттән кызыклы гына язучы чыгуы мөмкин. Ул үзенең хикәяләрен, плоскость өстенә җәеп салмыйча, берәр конфликт тирәсенә корырга ярата, бу — яхшы сыйфат. Аның баштагы өч хикәясен мин кызыксынып укып чыктым. Соңгысы, минемчә, артык чи, ләкин анысында да ниндидер бер нәрсә сизелә, тик әле эшләнеп бетмәгән.

Беренче хикәясе[1] хатыны куып чыгарган бер исерек кеше турында. Бу тема инде бөтен кешенең колагын сасытып, күңелен туйдырып бетергән, тик шулай да Хуҗин бу иске теманы ничектер яңартып, матур гына хикәя эшләп биргән. Әлбәттә, бу хикәядә искитәрлек берни дә юк, ләкин язу манерында ниндидер оригинальлек сизелә. Бу — куанычлы хәл, чөнки оригинальлектән яхшы язучы башланып китә бит.

«Ерганак юл ала» хикәясендә райком секретаре Шәймиева образы бик симпатичный, безнең әдәбиятыбызда кабатланмаган образ. Дөрес, ул бик кечкенә урын тота, эпизодик образ, ләкин матур булып хәтердә кала. Аннары Сәгый

[1] «Ишетелмәгән моң» исемле хикәя. Ред.

абзый белән Фәйзери бабай бар — болар да үтешли генә күренә торган образлар, әмма шулай ук оригиналь кешеләр, алар сөйләгән вакыйгалар — хикәянең иң матур урыннары...

Тулаем алганда, бу хикәя әле тәмам эшләнеп житмәгән. Ул ничектер аерым вакыйгалардан тора кебек. Анарда теге мәсьәлә дә, бу мәсьәлә дә кузгатылып куела, тик берсе дә хәл ителми. Шәймиевага каршы куелган формалист образы (фамилиясе Сабитов шикелле) бөтенләй эшләнмәгән, аны бераз күрсәтергә, ничектер образ буларак (эпизодик образ буларак) тәмамларга иде. Мөнир хикәянең башыннан ахырына кадәр барса да, аңа да шулай ук ничектер жан кереп житми. Валя белән аларның икесенә дә автор жан өреп житкерә алмаган: алар бик бертөрле, язучы аларның характерларында үзенчәлекле буяулар таба алмаган. Рәиснең дә исеме бар, үзе бөтенләй юк. Фәйрүзә бик аз күренә, анда да тонык, ул кыз бит Валяга каршы куелган, Мөнир аны ярата, укучының ул кызны тулырак итеп күрәсе килә, аны берничә эпизодта күрсәтәсе иде. Гомумән, хикәядә әле кереп, әле чыгып йөрүче кешеләр бик күп. Төп геройлар да шулар арасында бутала. Укучы өчен төп геройларның аерылыбрак торганы яхшы, кереп-чыгып йөрүчеләрне киметкән яхшы, укучыга комачауламасыннар. Автор үзенең геройлары хакында тагын бер уйласын иде, чыгарып ташларлыкларын чыгарып ташласын, калырга тиешләрен йомрырак итеп эшләсен иде. Кузгаткан мәсьәләләргә кагылышлары булмаган вакыйгаларны да бетерергә, кыскартырга кирәк. Аулак өйгә бик зур урын бирелгән, ә соңыннан хикәядә бу мәсьәлә әллә ни роль уйнамый. Төп мәсьәләләр булып, минемчә: жанлы эшкә формаль карау һәм шуңа каршы протест, икенче — яратып та яратыла алмау фажигасе тора кебек. Шул тирәдәрәк биергә, бүтән вакыйгалар белән артык мавыкмаска кирәк түгел микән? Юкса хикәя русның окрошка ашына охшый башлый...

Һәрхәлдә, ашыкмаганда, тизрәк басылсын, ничек басылса да барыбер, дип карамаганда, бу хикәядән яхшы гына нәрсә чыгарып булачак. Автор, бәлки, тагын һәм тагын эшләп багар. Булмаган жирдән эзләү, ягъни юкны төзәтеп тору да кирәкмәс иде, ә бу хикәядә бар бит, оеткы салынган, әйбәт булып кабарып килә, тагын бераз сабыр итәргә, көчне кызганмаска иде.

«Кечкентәй» хикәясендә язучы мондый мәсьәлә куйган: русча аны долг и любовь дип әйтергә була. Хәнәф исемле егет бер кызны яшьтән үк сөйгән, ләкин икенче кыз каршында бурычлы — шушыларның кайсы аның күңелендә жиңеп чыгарга тиеш? Рәшидәгә булган мәхәббәтеме, әллә Вәрыйгага бурычлы булу тойгысымы? Хикәядә ахырда мәхәббәт жиңеп чыга. Конфликт булу сәбәпле, хикәя мавыктыра. Ләкин, дип әйтергә туры килә, конфликтның укучыны ышандырырлык итеп нигезләнмәгән булуы, күзгә күрсәтеп ясап куелуы аркасында, хикәя укучыны канәгатьләндерми. Башлап шуны да әйтергә кирәк: сугышка китү, сугышта йөрү картиналары бик тонык, бу өлештә кызыгып укырлык нәрсә юк, һәм укыйсы да килми, хикәягә Вәрыйга килеп кергәч кенә конфликт башлана, хикәя дә шуннан соң гына кызыгаеп китә. Минемчә, хикәяне әнә шуннан башларга кирәк тә. Баш өлешен йә кыскартырга, йә кайтып сөйләргә була. (Хәер, автор, теләсә, монын хәйләсен миннән остарак табар). Конфликт, хикәядә конфликт үзе бик матур нәрсә булган өчен генә зур роль уйнамый бит инде. Аның максаты — йортның нигезе кебек, ягъни йортны тотып тору өчен генә кирәк. Аслан бит безнең өчен йорт үзе кирәк, нигезе түгел. Инде нигезсез йорт салып булмый икән, яшәсен нигез! Конфликтсыз хикәя корып булмый икән, тик бары шуның өчен генә яшәсен конфликт! Кызганычка каршы, иптәш Хужин конфликт өстендәге өскормага материал житкерә алмаган: аның образлары (Хәнәф белән Рәшидә образлары) кызыклы итеп, оригиналь итеп эшләнмәгәннәр. Шуның аркасында хикәягә салган идея, фикер сәнгать күлмәген кия алмыйча шәрәрәк булып калган. Әгәр шушы конфликттан файдаланып, автор үзенең шушы образларына (алар бит әле икәү генә дә түгел, өчәү!) ит кундырган булса, аларның рухи дөньяларын тирән итеп ачып биргән булса, аларның күңелләрендә кайнаган тойгыларында безне йөздерә алган булса, шул вакыт конфликт та әрәм китмәс иде. Дөреслек өчен әйтергә кирәк, хәзер дә образларның жаннары бар, ләкин эләгеп кенә торган жан, чыгып китәм-китәм, дип тора торган гына жан. Миңа калса, шушы табылган конфликтка таянып, тагын да эшләгәндә, образларның дөньясын тирәнәйткәндә, моңардан әйбәт хикәя килеп чыгуы бар...

**Ибраһим ГАЗИ.**

*Апрель, 60 ел.*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Мәхмүт Әхмәтҗан**

# ТОРМЫШ МИЗГЕЛЛӘРЕ

ПАРЧАЛАР

Яшәү — өзелмәс чылбыр ул. Әмма бу фани дөньяда күпме генә яшәмик-талпынмыйк, тормыш мизгелләрдән тора. Һәм моны, мөгаен, беркем дә кире кага алмастыр. Минем үземә калса, «мизгелләрнең» кайберләре, бигрәк тә хисләргә төрелгәннәре, мәңгелеккә хәтердә уелып калганнар. Фәндә «юнәлгәнлек» (направленность) дигән төшенчә бар. Бу үзе, нигездә, кешенең нәрсә белән кызыксынуына кайтып кала. Мәсәлән, мин үзем философиягә, тарихка, атаклы шәхесләр язмышына кагылышлы мәгълүматларны озак хәтердә тотам. Ә телефон номерлары, әйтик, «бер колагымнан керә, икенчесеннән чыга». Хәтер дигәннән, галимнәрнең әйтүенә караганда, кеше үзе күргән-ишеткәннәрнең 3 процентын гына исендә тота икән. Әмма моның да уңай ягы бар. Һәммәсен дә үзендә сакласа, кеше бик иртә акылыннан язар иде. Кемдәдер: «Алай булгач, нигә соң вузлар бетереп, гомер буе укып мәшәкатьләнергә?» — дигән сорау да туарга мөмкин. Җавап бер генә: уку абстракт уйлануны (ә бу исә фән өлкәсе) үстерә. Әмма тормышта һәр нәрсә үз вакытында эшләнергә тиеш. Сер түгел ич, бер-ике айга авылга, әби-бабасына илтеп куйсаң, бер кәлимә сүз белмәгән бала бер дигән итеп татарча сөйләшә башлый. Ә аңа кадәр ул «белмәс» кенә иде. Мөгаен, монда без белеп бетерми торган «феномен» бардыр. Мәсәлән, уртача авырлыктагы мидә (ә ул 1200—1250 грамм чамасы килә) 200 елга җитәрлек фикерләү запасы бар, диләр. Әмма склероз аркасында бу потенциянең бик аз өлеше генә «файдага эшли» икән...

Инде хәзер, кадерле укучым, менә шушындый керештән соң, кайбер «тормыш мизгелләрем» белән уртаклашырга да буладыр. Әмма бу һич тә язма авторының тәрҗемәи хәле түгел, бәлки заман һәм язмышлар хакында уйланулары гына... Сүзне туган авылдан башлау мантыйкка туры килер кебек...

Бервакыт классташым Наил әфәнде Шакиров (бу чакта ул мәктәптә укыта иде) миңа бер документ күрсәтте дә: «Анда безнең авыл тарихына кагылышлы белешмәләр бар», — диде. Табигый, бу сүзләр мине шактый кызыксындырды. «Җиде буын шәҗәрәңне бел», — дигәнне еш ишетсәк тә, моңа ныклы киртәләр салынды. Мәсәлән, нәселеңдә «халык дошманнары булу» (ә алар минем нәселемдә дә шактый иде...), шулар белән аралашудан качу шәҗәрә җебен өзә дә куя килде. Ләкин Наил күрсәткән документ күп кенә нәрсәләрне ачыкларга булышты.

...Безнең авылга нигезне 11 татар гаиләсе салган. Язуда гаилә башлыкларының исемнәре күрсәтелгән, аларны «служивые люди» дип атаганнар һәм хөкүмәт хисабына аена 1 сум акча түләгәннәр. Минемчә, «служивыйлар» шул тирәдәге «патша юлын» саклаганнар. Документта (ул татар телендә, гарәп имлясында

төзелсә дә, аны урысчага күчергәннәр, мин шул нөсхәсен күрдем) болай диелгән: **«Без, Каратаулы башкортлары, иң зурыбыздан алып иң кечкенәбезгә кадәр, үз теләгебез белән бу мишәрләргә шул җирләрне (картасы бар, җирнең чикләре күрсәтелгән — *М. Ә.*)** бирәбез һәм киләчәктә бу хакта бәхәс күтәреп йөрмәбез. Татарларга 25 йорт салырга, тегермән төзергә, колмак җыярга рөхсәт итәбез. Әмма бөркеткә тию тыела, бөркет — безнең кош».

Бу рәсми кәгазьгә Уфа вице-губернаторы, җир эшләре буенча губернаторның урынбасары да кул куйган. Мөһер дә сугылган. Документ 1757 елның 9 мартында гамәлгә кергән. Моңа өстәп бер-ике сүз генә әйтәсе кала: хәзер авылда 600 хуҗалык бар... Башкортлар җир мәсьәләсендә ызгыш чыгармабыз дисәләр дә, күп мәртәбәләр сүзләрен бозганнар, татарларга һөҗүм итеп, җирләрен тартып алганнар. Эш судка барып җитә торган булган. «Мәскәү тавы» дигән җирнең кичкенә тарихы шуңа ачык мисал булып тора: Мәскәүдәге Югары суд ул җирне татарларда калдырган. Беренче карашка җир ничек кенә күп булып тоелмасын, көн күрү өчен барыбер җитәрлек булмаган, шунлыктан, татарлар Лагыр, Шәрекъ, Сибаркүл башкортларыннан да җир сатып алганнар. Татар белән башкортны ызгыштырып тоту (асылда алар берләшсә, көчәерләр дип курку!) — патша түрәләренең рәсми сәясәтенә әверелгән. Мәсәлән, татар егетләренә башкорт кызларына өйләнү тыелган. Мондый нәрсә эзсез калмаган. Мисал: «Сәнәк сугышы» вакытында (1918) Куркино тегермәнчесе Водолеев, 14 башкорт авылы кешеләреннән зур отряд оештырып, безнең туган авылга — Нәсибашка һөҗүм иткән. Баш күтәрүчеләр авылга кереп бернічә урында ут төрткәннәр. Ниятләре бөтен халыкны кырып бетерү булган. Алар моны яшермәгәннәр дә. Бәхеткә, ерак түгел Блюхерның Урал эшчеләр азатлык армиясе частьлары торган. Шуларның берсе — Туманов җитәкчелегендәге батальон — сәнәкчеләрне тар-мар иткән.

## Тәүге мизгелләр

Минемчә, тормышта һәркем үзенең бала чагы, тәүге хатирәләре турында уйлана торгандыр. Әнә ич, М. Горький үзенең «Балачакта» дигән әсәрендә иң беренче булып хәтерендә калганны болай яза: «Әтинең каберенә (бу Әстерханда була — *М. Ә.*) су җыелган, шунда бер бака сикерә иде». Л. Н. Толстой исә «Балачак» повестенда иң элек исендә калган вакыйга турында болай дип яза: «Әнкәйнең ак куллары гына истә калган...»

Минем тәүге хатирәләрем (2 яшьләр чамасында булганмындыр дип уйлыйм) шул: кара-каршы салынган куш өй. Берсендә — ишек алдына карый торганында без — әткәй, әнкәй һәм мин — яшибез. Ике өй чолан белән тоташтырылган. Урам як өйдә Гафур абыйлар (әткәйнең бертуган энесе) яши... Картәни (күршеләр өчен «Фатыйха җиңги», «староста карчыгы») бик тәмле итеп печеньеләр, майда бавырсак пешерә. Җәй көне ачык тәрәздән хуш ис тарала...

...Күп булса, миңа өч яшь булгандыр. Колхоз төзелә башлаган чак. Әлегә Бурлы бия — лапаста. Җәй уртасы. Картәни атны җикте дә, без аның белән икәү юлга чыктык. Бөтен дөнья ямь-яшел. Кошлар сайрый. Чәчәкләрдән хуш ис аңкый. Бер-ике мәртәбә тау менеп, тау төштек. Ниһаять, бер авылга килеп җиттек. Картәни әйтә, бу башкорт авылы Лагыр булыр, ә безгә су аша чыгып, Мөхәммәтҗан коданы күрергә кирәк, ди. Моның өчен Өй елгасын кичәргә туры килә икән. Пароход-мазар йөрмәсә дә, шаяра торган су түгел: шактый тирән. Әмма кичү урыннары бар икән, картәни шул урынны ничек төгәл белгәндер, әйтүе кыен. Арба төбенә су кергәч, ул аягына торып басты да мине кулына алды. Шулай итеп, елганың теге ягына чыктык. Мөхәммәтҗан кодаларның өе яр буеннан ерак түгел икән. Кода бу авылда бердәнбер татар кешесе, калганнары — башкортлар. Ул үзе Бөгелмә ягыннан. Тегүче. Бу якларда тун-толып һәм башка төр өс киемнәре тегеп гомер кичергән. Башкортлар аның эшен яратканнар, ахрысы, безнең авылга күчеп кил, үкенмәссең, дигәннәр һәм сүзләрендә торганнар. Коданың бердәнбер улы Хәбибрахман һәм өч кызы шул авылда үскәннәр. Кызларын безнең авыл егетләренә кияүгә биргән, улын — Хәбибрахманын картәнинең бердәнбер кызына — авылның иң чибәркәе Өммеһанига өйләндергән. Шуннан соң үзе дә безнең авылга күчеп килгән. Йорт сатып алып яши башлаган. Табигый, мин боларны соңыннан, үсә төшкәч белдем...

Безнең район Салават Юлаев исемен йөртә, аңа кадәр Малаяз районы иде (район үзәге Нәкый Исәнбәтнең туган авылы иде). Районда 50 дән артык башкорт, 5 урыс авылы бар. Татар авыллары 7: Нәсибаш, Малаяз, Чирапан (аргы

Малаяз), Лаклы, Миәшәгәр, Таймый һәм Шәрип... Әнә шулар халык язучысы Нәкый Исәнбәтне, генераллар Хәбиб Ганиев һәм Рәфкать Вәлиевны, күренекле әдәбият галиме, үзбәк халкына Алишер Нәваи иҗатын табып-барлап бирүче профессор Габдрахман Сәгъдине, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, күренекле телче Фуат Ганиевны, кыргыз халкының «Манас» дастанын беренче язып алучы һәм чыгаручы Каюм Мифтаховны, Россия һәм Татарстанның халык артисткасы Зилә Сөнгатуллинаны, Башкортстанның халык артисткасы Фәридә Камалетдинованы, күп кенә фән кандидатларын, журналистларны, тәрҗемәчеләрне, җәмәгать эшлеклеләрен бирде. Кызганыч һәм үкенечле, соңгы 20 ел эчендә районгагы татар авылларыннан күренекле бер генә шәхеснең дә чыкканы юк. Халыкның әйтүенә караганда, моның бер төп сәбәбе шунда ки: Башкортостанда татар мәктәпләрен башкорт мәктәпләре итеп үзгәртү башлангач (бу административ юл белән эшләнде), аларда укыту урыс мәктәпләре уку планы, программалары нигезендә алып барылды. Татар теле предмет буларак та укытылмады. Нәтиҗә — утырып еларлык...

...Бу песи баласы безнең өйгә ничек килеп эләккәндер, хәтерләмим, чөнки әле бик бәләкәй идем. Мин аны искиткеч яраттым. Әмма гомере кыска булган икән: ишеккә кысылып үлде. И еладым да инде шуннан соң. Әнә шуңа күрә бүген дә утка песи ыргытучы малайларның явызлыкларын күреп: «Боларның ата-аналары ни карый икән? Киләчәктә алар үзләренең ата-аналарына ук көн күрсәтмәячәкләр бит»,— дип уйлыйм. Һәм бу һич кенә дә арттырып әйтү түгел... Тагын хәтер сандыгын ачам: Актырнак исемле этебез бар иде. Зур гәүдәле, йонлач. Бик юаш. Мин белгәндә шактый картайган булган, ахрысы, язын күбрәк кояшта кызынып яту ягын карый, кышын оясыннан чыкмый. Тавышы-тыны да юк. Җәй башы кебек истә калган: Актырнак юк булды. Эзләп-эзләп тә карадык — тапмадык. Тик шулай да бераздан аның «хәбәрен» алдык, күрше Мәгафүр бабай кереп әйтте: «Савылга (ни өчендер авылдан 200 метрлардагы каен урманын бездә Савыл дип атыйлар) барган идем, Актырнакны күрдем. Ул үлгән» — диде. Бу хәбәр безне бик борчыды да, гаҗәпләндерде дә, башка: «Ишек алдында, оясында гына җан бирергә ярамады микәнни?» — дигән уйлар килде. Ләкин Актырнак «дөрес эшләгән, эт егетлеге күрсәткән» булган икән. Этләр әҗәл килгәнен сизгәч, кеше күзенә күренми генә дөнья белән хушлашалар икән. Укыганым бар: филләр дә, көтүдән аерылып, куе агачлык эченә кереп үләләр, ди...

Һәркем шулайдыр инде: ата-анама, әби-бабама, мине дөньяга китергән, тәрбия кылып, олы тормыш юлына аяк бастырган-озаткан өчен, мең рәхмәтлемен. Түбәндә сүз әлеге изге, бөек җаннар турында барыр.

## Картәни нәсихәтләре

Безнең Уфа ягы татарлары дәү әнине «картәни», «картинәй», «картнәй» дип атап йөртәләр. Мин дә шулай димен.

Әй бу гомер дигәнең: картәнинең фани дөньядан бакыйга күчкәненә дә 50 елдан артык вакыт узган! Әмма ул һаман да тере килеш күз алдымда тора: буйга зур түгел, төскә-биткә шактый чибәр — кечкенә генә түгәрәк авызлы, бит очында — чокырлар. Сиксәнне тутырса да, йөзе нурлы һәм җыерчыксыз. Билгеле инде, старшина улына матурны сайлап алганнар...

Картәни табигате белән «өй тавыгы» булса да, туганнарын күрергә дип, Мирсаяф, Галим, Гариф энеләренә, Мөхәммәтҗан кодасына йөгереп барып кайта. «Исән-саулар, әйбәт кенә яшәп яталар, Аллага шөкер, күңелем тынычланды»,— ди иде ул кайтып керешкә. Сүз озайтырга яратмый (теләге дә, вакыты да юк), бервакытта да гайбәт сөйләми, андыйларны тыңламый да. Аш-суга бик оста: ул пешергән итле аш, каймактай катык (куе сөткә каймак куша иде) әле дә авызыма тәм биреп тора. Бавырсак, крәндил, печенье, кош теле, тагын әллә нәрсәләр пешерә. Бервакыт күрше Миңлевафа әби: «Көтмәгәндә кунак килеп төшсә, үзебезнең хәзинәдә булса да, Фатыйха җиңгигә ипигә йөгерә идек. Чөнки аның ипие ашап туйгысыз була иде»,— дип искә алды. Бу хакта картәнигә әйткәч, ул берни булмагандай: «Хәзер инде хәтерләмим андый вак-төякне. Алып торганнардыр. Мин камырга чүлмәге белән май сала торган идем шул»,— диде. Тик шуны гына әйтәсе кала: мөгаен, бу хәл колхоз чыкканчы булгандыр. Чөнки колхоз төзелгәнче тырыш кешеләр берничә сыер тотканнар, дәүләткә сөт тапшырып (бушлай!) интекмәгәннәр... Картәни каен агачыннан тау кадәр чыра телә һәм аларны киптереп мич башына өеп куя. Шуңа күрә, казан астын күз ачып йомганчы аса, самавыры да интектерми — «эһ» дигәнче кайнап та чыга.

Картәнине балалары бик хөрмәт итә. Җәй көтү бик иртә китә. Башка чыккан уллары көтү куа да, картәни яткан тәрәзә янына килеп (ә тәрәзәләр ачык була), һәм йомшак кына тавыш белән хәл-әхвәл сорашалар: «Әни, киленең самавыр куеп калды, әйдә безгә чәйгә кер»,— диләр иде. Ул рәхмәтен әйтә, әмма берсенә дә бармый, берсенә барсам, икенчесе мәхрүм булыр, үпкәләр, дип уйлый, ахрысы. Дөнья бит, бервакыт картәни бик каты авырып китте. Берничә ай урын өстендә ятты. Инфаркт булды, бугай. Әмма ни өчендер табибка мөрәҗәгать итмәделәр, әллә район үзәгенә барасылары килмәде микән? Хәле бик авыр булса да, картәни акрынлап аягына басты һәм аннан соң кимендә 15 ел яшәде, сугыш бетәр алдыннан гына вафат булды. Күзе әйбәт күрә, колагы яхшы ишетә иде. Минемчә, картәнине терелткән нәрсә нигезендә үзенә булган игътибар ятты. Галимнәр дә яшәү стимулының төп этәргече булып башкаларга кирәклегеңне тою тора, диләр ич... Авылдагы балалары авырганда яныннан китмәделәр, читтә яшәүче якыннары (балалары, оныклары) дару, күчтәнәч алып кайталар. Иң кыйммәтлесе — тизрәк терелүен телиләр иде.

Картәни чыннан да бик затлы әби-карчык иде. Бервакыт, ниндидер очрак уңаеннан сүз чыккач, әнкәй болай дип сөйләде: «Ачлык елны без Фәүзия килен белән бер-бер артлы бу йортка килен булып төштек. Аңа да, миңа да күптән түгел генә 15 яшь тулган чак. Мин дә үги әни кулыннан тизрәк китү ягын караганмындыр инде. Төшкән йортыбыз турында начар сүз йөрмәде. Атлары, сыер-сарыклары бар иде. Ирләр завод жирендә акча эшләп, он, шикәр, ярма юнәтәләр иде. Шуңа күрә ач та, ялангач та булмадык. Бервакыт шулай, ирләр юк чакта, әни безне үз янына утыртты, сөйләшәсе сүзләр бар, диде. Кыскача аның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт булды: «Киленнәр хәлен мин яхшы беләм. Үзем дә бик затлы-хәлле йортка килен булып төштем. Кагарлар, эшләп өлгерә алмам дип курыктым. Мал-туар күп иде шул. Әмма әти — авыл старшинасы Әсәдулла карт — һәм аның хатыны Гөлзадә әни әйбәт кешеләр булып чыктылар. Урыннары оҗмахта булсын. Бераздан өй салып, мал-туар биреп, безне башка чыгардылар. Картым да бик яхшы күңелле, тыныч һәм тырыш кеше булып чыкты. Менә хәзер сез минем киленнәрем. Сезне какмам-сукмам, тамагыгыз тук, өстегез бөтен булыр. Кушканнарымны үтәрсез. Артыгын таләп итмәм. Урамга сүз ташымагыз. Кеше генә көләр». Әнкәйнең әйтүенә караганда, картәни чыннан да сүзендә торган. Уллары, карты алдында киленнәрен мактарга яраткан. Их, башка бөтен каенаналар да шулай булса...

Әткәй-әнкәйләр эшкә киткәч, без — ике гаилә балалары, җәмгысы 11 сабый — шул кечкенә карчык янында җыелып кала идек. Шаярулар, көлүләр, елаулар да булгандыр инде — без бала-чага ич... Монсы гаҗәп түгел, гаҗәбе башкада: картәни моңа ничек түзде икән? Холкы белән ул житди, таләпчән, әмма гадел иде. Тагын, аңа нинди сыйфатлар хас иде, дисәләр, акыллы һәм горур иде, дияр идем. Безнең колакка еш тукый торганы шул булды: «Горур булыгыз, юк-бар белән аралашып, вакытыгызны әрәм итмәгез, исереккә сәлам бирмәгез. Вакчылланмагыз. Кешедән йөзегезне яшермәгез. «Я кто!» — дип, җиргә нык басып йөрегез! Кешедән көлмәгез, үз тиңегезне табыгыз». Минемчә, бу сүзләрдә буыннан-буынга күчеп килгән татар халкының борынгы традицияләре чагыла.

Кайчак картәни улларының исемен бутый, һәммәсен рәттән санап чыга иде. Дөресенә юлыккач кына туктый. Ул сабыр кеше иде. Златоустта гимназия тәмамлаган (ул заман өчен сирәк күренеш) дүрт улының (Шакир, Галим, Сабир, Газиз) өчесе гражданнар сугышында юк булганнар. Диварда аларның зурайтылган рәсемнәре эленеп тора. Сагынгандыр ул аларны, әмма бер генә вакытта да күз яшьләрен күрсәтмәде. Ленинградны саклаганда, төпчек улы Гафур абый һәлак булды, Фәүзия җинги кулында 6 бала торып калды. Брест крепостенда картәнинең яраткан оныгы (Сабирының улы) Касыйм абый күмелгән. Башка кайгылары да аз булмаган картәнинең, әмма ул бервакытта да җебеп төшмәде, югалып калмады. Горур, түзем татар карчыгы гомерлеккә күңелебезгә әнә шулай булып кереп урнашты...

## Әнкәйнең кыйссалары

Безнең әнкәй юаш, искиткеч итагатьле, авыл советы депутатын да Аллаһ илчесе итеп кабул иткән, төскә-биткә матур булган, мөлаем бер татар хатыны иде. Ул бервакытта да, беркемгә дә ачуланып, кычкырып эндәшмәде. Гайбәт сөйләмәде, гайбәтчеләрдән ерак йөрергә тырышты. Аллаһка чын күңеленнән ышанды, гөнаһ кылудан уттан курыккандай курыкты. Без гаиләдә

дүрт малай үстек. Соңгысы кыз бала булып туды. Табигый, шаярганбыз инде. Югыйсә, өйдә шаярып ятмасын дип, Шакирҗан энемне вакытыннан алда укырга бирмәсләр иде. Мескенкәем, бер ай чамасы өй эшләрен онытып кайтса да (елаштырып та ала иде), тиздән бик яхшы укып китте. Соңыннан да шулай булды.

Без: «Баланы гаиләдә дөрес тәрбияләргә кирәк»,— дибез һәм дөрес әйтәбез. Әмма «дөрес тәрбия» дигәнне һәркем үзенчә аңлый һәм тәрбия алымнарын шуннан чыгып сайлый. Тик шуны онытмыйк: тәрбия процессында вак-төяк булмый. Тормыш тәҗрибәсеннән күренгәнчә, шәхси үрнәк аеруча зур әһәмияткә ия. Тормышта берне сөйләп икенчене эшләүдән дә яманы юк.

Әнкәй мәрхүмә бик чиста хатын иде. (Шуңа микән, мин хәзер дә өстәлдә юылмаган савыт-саба торса, утырып ашый алмыйм.) Һәммәбез дә тамак туйдыргач, әнкәй казаннан җылы су алып, савыт-саба, кашыкларны юа, киптергәнче сөртә, аннары гына урыннарына куя. Акрын гына тавыш белән: «Савыт-саба чиста булмаса, канатларын талдырып, фәрештәләр шуларны каплап торалар»,— дия торган иде. Аңлашыла ки, фәрештә канатын талдырып, кем олы гөнаһка батарга риза булсын ди?!. Ятар алдыннан әнкәй авыз-борынын чистарта, су белән чайкый. «Шунсыз шайтан иреннәрне үбәргә мөмкин»,— ди. Ә кемнең шайтаннан үптереп, иренен чабырттырасы килсен ди?! Минем берничә мәртәбә язып чыкканым бар, һәм күкрәгемдә йөрәгем типкәндә, шул ук сүзләрне кабатлаячакмын: татар халкының әхлак кануннары, нормалары Ислам тәгълиматы белән сугарылган. Ә бу дин исә пакълыкка һәм сафлыкка өнди. Татар үзен мөмкин кадәр пөхтә, чиста, итагатьле итеп тотарга тырыша икән, бу әнә шуннан килә. Чын татарның йөзендә нур уйный, дигәнне күпләрнең ишеткәне бардыр. Гомер буе эчмәгәч, тартмагач, әхлак кануннарына таянып яшәгәч, нигә аның йөзе нурлы булмаска тиеш ди соң? Дин ул бөек тәгълимат-идеология генә түгел, күңелгә сафлык, ышаныч, тынычлык бирә торган көч тә. Беләбез ич: ышануларсыз яшәве бик авыр яки мөмкин дә түгел.

Әнкәй көйләп бәетләр сөйләргә ярата иде. Иртәнге йокы тәмле була, әмма тиздән торасы, мәктәпкә барасы бар. Әлегә әнкәй тәгам әзерли, үзе бик моңлы итеп көйли. Ул Йосыф пәйгамбәр кыйссасын бик ярата иде, безне дә шуңа күндерде. Гомумән, без бөтен пәйгамбәрләрнең исемнәрен яттан белә идек...

Бервакыт әнкәй «Сак-Сок» бәетен көйләп сөйләде. Безне — балаларны иң дулкынландырганы һәм мәңгегә күңел көзгесенә язылып куелганы шул булды: ана, ялгышуын аңлап, күз яшьләре белән Аллага түбәндәгечә мөрәҗәгать итә: «Ходаем, гаеп миндә генә. Түзәлми, ялгышып, балаларымны каргадым. Зинһар, балаларымны элекке хәленә кайтар». Монда күпләр әһәмият биреп җиткерми торган ике бик мөһим момент бар. Беренчесе — балалар өчен ана Аллаһтан да зуррак. Шуңа күрә Ходаның балаларны элеккеге хәленә кайтарырга кодрәте җитми. Икенчесе — түзем булырга кирәк, баланы, ашыгып, каргарга ярамый. «Сак-Сок» бәетен тыңлаганнан соң болар хакында әлләни сүз озайтып торасы да юк: һәммәсе ап-ачык, уч төбендәге кебек. Шуңадыр: юаштан да юаш әнкәбезгә беребез дә, бервакытта да авыр сүз әйтмәдек. «Ят уйлар» килсә дә, телебез тотлыкты. Ул безнең өчен Мәрьям-ана кебек бөек зат булды...

Сәбәбен өзеп кенә әйтә алмыйм: ни өчендер әнкәй Сөләйман пәйгамбәр кыйссасын сөйләде. Эчтәлеге бик гади: Сөләйман пәйгамбәр чит илләрдә патша булып, шактый баеган һәм шуннан соң атасын күрергә дип кайткан. Әмма ул әтисен ат өстеннән төшми генә сәламләгән. Бу бик зур гөнаһ саналган, шуңа күрә Аллаһ аңа зур җәза биргән: башка пәйгамбәрләрдән аермалы буларак, үлгәннән соң, Сөләйман пәйгамбәрнең гәүдәсе черегән. Нәтиҗәне без — кыйссаны тыңлаучы балалар ясадык һәм шул уй-фикер аңыбызга мәңгелеккә язылып калды: бала өчен ата да бөек җан иясе икән! Өзеп кенә әйтә алмыйм, мөгаен, әлеге кыйсса йогынтысыдыр: без — балалары — әткәйгә каршы сүз әйтү түгел, кырын да карамадык. Гомер буе шулай булды.

## Әткәй васыятьләре

Гомер үткән, еллар мәңгелеккә кереп югалган саен, адәм баласы үзенең үткәннәрен барлый, күз алдыннан үткәрә, сагына, кайчак нигә болай итмәдем икән дип өзгәләнеп тә куя. Болай дигәндә мин газиз әткәмне, ул әйтеп калдырган васыятьләрне искә төшермәкче булам...

Шулай берчак, бөтенләй көтмәгәндә, әткәй А. С. Пушкинның «Боже, царя храни» (совет чорында бу бөек әсәрне «Иван Сусанин» дип атап йөрттеләр) дигән

әсәрен һичбер акцентсыз, матур аһәң белән сөйләп чыкты. Татар гадәте буенча, мин аңа бертөрле дә сорау бирмәдем. Әмма гаҗәпләнүемне күреп, ул үзенең Земская школаны тәмамлавын әйтте. Поэманы шунда ятлаган икән... Әлегә кадәр мин бу хакта белми идем. Земство әгъзасы, меценат алпавыт Кропачинский (Уфа белән Чиләбе арасында, Көньяк Урал тимер юлының бер зур станциясе Кропачево дип атала) тырышлыгы белән безнең авылда (волость үзәгендә) Земская школа ачылган. «Урыс булудан курыкмаган ата-аналар» балаларын шул мәктәпкә укырга биргәннәр. Алар арасында әткәй дә булган...

Иптәшләренең сөйләвенә караганда, әткәй бик яхшы укыган. Ә чыгарылыш имтиханнарында катнашкан Кропачинский әткәйне кочаклап, елап җибәргән, кесәсеннән бер сумлык көмеш акча чыгарып бүләк иткән. Мактау грамотасы да биргәннәр. Әмма, минемчә, иң кыйммәте башкада булган: мәктәп әткәйдә китапка мәхәббәт тәрбияли алган. Шулай дип уйларга урын бар: кая гына барса да, ул безгә китаплар алып кайта торган иде. Бу да үзенә күрә балалар күңелендә китап сүзенә ихтирам тәрбияләү булып тора.

Бу — мактану түгел, татар өчен гадәти күренеш кенә — без әткәйне яраттык та, тирәнтен хөрмәт тә иттек. Ул акыл сатарга яратмады, шулай да биргән киңәшләрен тотарга тырыша идек. Әткәй туры мәгънәсендә асл кеше иде. Шулай да ул үз әтисен искә төшереп елый иде. Ә мин исә бүген, газиз әткәйне сагынып, балавыз сыгам. Радиодан туган як җырларын-көйләрен тапшырсалар, бәгырьләр өзелә генә. Әткәйне сагынырлык та шул: ул безгә, балаларына, кул күтәрү түгел, авыр сүз дә әйтмәде. Ә болай караганда житди кеше, колхоз рәисе булган ич ул! Сугышта өч мәртәбә каты яраланып илгә кайткач тагын «рәис камытын» киде. Тормыш бик авыр иде. Әмма шул шартларда да халык белән эшли белде, кеше күңелен төшермәде, алар белән әйбәт мөгамәләдә яшәде. Шуңа аны яраттылар да.

Әткәй, күп нәрсәдә, безгә үрнәк булды дияр идем. Яраткан сүзе шул иде: «Бервакытта да кешедән көлмәгез, аны кимсетмәгез, һәркем үзен хаклы дип саный. Мөгаен, моңа хокукы да бардыр. «Мин болай да, мин тегеләй» дип, мактанмагыз-масаймагыз, сезгә бәяне халык бирсен». Тагын бер васыяте истә калган. «Дөньяда урлашудан да хурлык нәрсә юк. Үзен хөрмәт иткән кеше тырышып эшләргә һәм шул хисапка яшәргә тиеш. Кырын эш кырык елдан соң да беленә. Хәрәм — кешене харап итә. Үзең тапканны ашасаң, ашың — тәмле, йокың — татлы була»,— дия торган иде ул еш кына.

Соңгы мәртәбә мин әткәй белән, үләренә ярты ел калгач, очрашкан идем. Һич тә әле генә дөнья куяр дип уйламадым. Картәнисе Гөлзадә 106 яшьтә үлгән ич аның. Әткәйнең битендә, муенында җыерчык-фәлән юк иде. Яшькелт-зәңгәрсу күзләре тыныч карый. Кыскасы, матур бер татар кешесе иде ул. Әмма фронттан исән-сау әйләнеп кайткан солдатны булдыксыз медсестралар харап итте — кайнатылмаган энә белән теш казнасына новокаин салганнар. Шуннан каны бозылды, саклап алып калып булмады...

Соңгы күрешү вакытында әткәй, шулай ук көтмәгәндә дияр идем, Аллаһ турында сүз кузгатты. Фиркасыз булса да (шул нәрсә аны 37 еллар мәхшәреннән коткарып калды бугай), үз вакытында коммун булган, колхоз рәисе булган ич ул. Шуңа күрә әлеге сүзләре мине бераз гаҗәпләндерде дә, сагайтты да. Ул сүзне шуннан башлады: «Улым, син Аллаһка тел-теш тидермә». Мин: «Әткәй, андый эш белән шөгыльләнергә теләгем дә, вакытым да юк»,— дидем. Аны бу җавап кына канәгатьләндермәде бугай. Өстәп болай диде: «Аллаһның сиңа, зыян салганы бармы?». Моңа каршы мин: «Юк. Киресенчә, мин аңа, язмышыма бик рәхмәтлемен»,— дидем. Аннан соң ул: «Кеше дөньяга бер генә мәртәбә килә. Үлем — котылгысыз. Мин үзем үлемнән курыкмыйм. Аның нәрсә икәнен фронтта бик күп күрдем. Минә дигән авылдашларым моннан кырык ел элек Калинин, Ржев тирәләрендә мәңгелеккә ятып калдылар. Кешегә әҗәл дә бер генә килә. Кайчак: «Ул тегеләй эшләсә, үлмәс иде»,— диләр.— Алай уйлау дөрес түгел. Үләр сәгатең җиттеме — сәбәп табыла». Ул моны тормыштан алып әйтте бугай. Чөнки шактый мисаллар китерде.

Әткәй тормышыннан канәгать булып яшәде. Минә аның фани дөньядан китүенә дә 14 ел тулып үтеп китте. Әмма мин аны үлгән дип хис итмим. Кайда гына булмыйм, ул — минем белән, аның рухы миңа көч бирә. Авыр минутларда мин аның белән киңәшләшәм, сөйләшәм.

Ул елдагы сентябрь кояшының алтын нурлары иркәләвен әле дә битемдә тоям. Без ул чакта чиксез бәхетле идек. Чөнки без яшь, киләчәк — безнеке; һәммәбезгә бөтен юллар ачык — ул чактагы ышануыбыз шундый иде. Авылыбыз зур. Бер елны 80 бала дөньяга килгән. Һәм менә без беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап үтәргә хәзерләнәбез. Табигый, ике класс ачарга кирәк булган. Әмма районо дигән оешма җитәкчеләре: «Акча юк»,— дип, бер генә класс ачтырганнар. «Без бәхетлеләр», — дигәннең мәгънәсе шуннан гыйбарәт: укырга 50 малай һәм кызны гына алдылар.

Кояш битне иркәли, җиләс җил чәчләрне тарый. Яшел чирәмгә тезелешеп бастык. Бер абый — ул мәктәп директоры икән — безне һәм әти-әниләрне яңа уку елы башлану һәм беренче класс укучысы булу белән котлады. Аннан соң югары класс укучылары безгә кыр чәчәкләре бүләк итте. Шулчак кайбер әниләр кульяулыклары белән күзләрен сөртә башладылар. Мөгаен, алар кечкенә чакларын искә төшергәннәрдер, балаларының үз елында, үз иптәшләре белән укырга керүләренә сөенгәннәрдер. Күп тә үтмәде, кыңгырау чыңлады һәм безне укытучыбыз — Әкълимә апа, ике рәткә тезеп, мәктәп эченә алып кереп китте.

Дөресен әйтәм: мин укырга шактый пошынып кердем һәм әле дә өзеп кенә моның сәбәпләрен әйтә алмыйм. Бәлки сул кул белән язган өчен ачуланырлар дип борчылганмындыр. Әмма җан биргәнгә, җүн бирә дигәндәй, әнкәй гозерен үтәп, Әкълимә апа мине «кешечә» язарга өйрәтте. Җиңел эш булмады бу, ләкин ел ахырына бөтенләй «уңга» күчтем. Хәзер дә уң кул белән язам, сулы белән эшлим. Кем әйтмешли, ике кеше урынына бер үзем. Шулай да соңрак аңлавыма үкенәм: кайсы кул белән язу хәлиткеч нәрсә түгел икән. Хикмәт ничек һәм нәрсә хакында язуда. Американың әле дә исән өч президенты: Рейган, Буш, Клинтон сул кул белән язалар. Америкада балаларны уң кул белән язарга өйрәтү ялгыш гамәл дип карала. Чөнки «кул алмаштыру» баланың нерв системасын боза икән. Хәер, болары сүз уңаенда гына.

Әлбәттә, табигать сәләтне барлык балаларга да бер тигез, бертөрле итеп бирми. Әйтик, берәүгә сүз әйтүең була, ул аны шундук тотып ала һәм хәтерендә саклый. Икенчеләр исә музыкага һәвәс, өченчеләр кул эшен тиз үзләштерәләр һ. б., һ. б. ... Шулай итеп, сәләт алшартлары һәркемдә була. Ләкин бу әле сәләтнең үзе дигән сүз түгел. Аны вакытында күреп-белеп үстерү зарур. Болары — гаиләнең һәм мәктәпнең бурычы.

Тиздән безнең класста «кемиең кемлеге» ачыла башлады. Илле бала белән эшләү укытучыга җиңел булмагандыр, әлбәттә. Моны фараз итеп торасы да юк. Өендә уку өчен тиешле шартлар булмау, белем алу кебек кыен хезмәткә әзерләнеп җитмәү сәбәпле, илле баланың уникесе класста икенче елга утырып калды.

Бервакыт Әкълимә апа безгә: «Өйдә бер куплет җыр өйрәнеп килегез, шуны музо дәресендә (ул чакта җыр дәресе «музо», рәсем дәресе «изо» дип атала иде) җырлап күрсәтерсез»,— диде. Без шулай иттек тә. Беренче булып Мәхмүт Галиев җырлады:

Сары самавырлар төсле
Сары минем йөзләрем;
Кайгылардан яшем ага,
Күрми инде күзләрем.

Укытучы аңа ачуланмады, башка мондый кайгылы җырларны җырламаска, ә монысын онытырга кушты. Аның артыннан такта янына Хизбуллина Мөсирә чыкты һәм нечкә тавыш белән җырлый башлады:

Урысларның исемнәре
Иван белән Стапан;
Үзем җырлап үзем эчәм,
Үземә тигән стакан.

Класс «пырх» итеп көләргә тотынган иде дә, укытучы күз карашы белән безне шундук туктатты. «Мөсирә, җыр сайлаганда, әниең белән киңәшәсең калган. Бүтән мондый җырны отма»,— диде. Чират колхоз рәисе малаена җитте. Ул болай башлады:

Алга дибез, алга дибез,
Алга таба барабыз;

Алга барырга кушкан бит
Безгә Ленин бабабыз.

Бу жырны, табигый, укытучы апабыз ятатты. «Тагын шундыйрак жыр белмисеңме, белсәң жырлап күрсәт әле»,— диде күңеле булып. Малай көттермәде:

Биек тауның башларына
Менәсебез бар әле;
Втаруй питилитканы
Тутырасы бар әле.

Җырланган жырларга карап кына ниндидер гомумиләштерүләр ясарга жыенмыйм, тик шуны гына әйтәсем килә: кем ничек жырлады, шулай укып та китте. Сәбәп көн кебек ачык иде: Мәхмүтләр, Мөсирәләр уку кебек «кое казу эшенә» бөтенләй хәзерлексез булганнар, шуңа күрә фикер йөртү куәтләре дә шактый сыек, зәгыйфь булган...

Гомумән алганда, класста укуга омтылыш шактый зур иде. Шулай бервакыт бөтен мәктәп «шигырь язу чире» белән авырый башлады. Монда, һичшиксез, укытучыларның йогынтысы зур булгандыр дияесем килә. Халыкта: «Оясында ни күрсә — очканында шул булыр» дигән мәкаль бар. Бәхетебезгә, безне әдәбият сөюче укытучылар укытты. Шуларның берсе — Сабир Гофрай улы Гыйззәтуллин. Авыл халкы аны яратып, үз итеп «Сабир учитель» дип йөртә иде. Сабир абый дәрескә шигырь сөйләп килеп керә:

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Без бу тамашага шаккатып басып торганда, ул берни булмагандай дәвам итә:

Буря мглою небо кроет,
Вихри снежные крутя,
То как зверь она завоет,
То заплачет как дитя.

Озын буйлы, эре сөякле, чем кара чәчле, кара кашлы таза, чибәр ир-егет иде Сабир абый. Утыз жиденче еллар мәхшәре аны да читләтеп узмады. Авыл куштаннарыннан берәү: «Сабир учитель дәресләрендә совет властен, иптәш Сталинны мактап телгә алмый»,— дип, прокурор исеменә шикаять язган. Кулга алынгач, ул: «Пушкин, Лермонтов, Гоголь, Крылов әсәрләрен өйрәнгәндә, бөек юлбашчының исемен ничек кертеп жибәрергә белмим»,— дип, жинел генә котылмакчы булган. Шулай да Сабир абый бәхетле булып чыкты. Сталин «тимер нарком Ежовны» юк иттергәч, күпләрне иреккә чыгардылар. Алар арасында Сабир абый да бар иде. Дөрес, ул бик йончып, бронхит эләктереп кайтты. Әмма беркемгә дә ачу сакламады кебек. Сугыш беткәнче мәктәптән кайтмый, көн-төн эшләде.

«Шигырь белән авыру» эзсез генә узмады. Безнең мәктәпне тәмамлаучылар арасында классташларым Марат Галимов, Рәхимә Вәлиәхмәтова кебек шагыйрьләр, Рифкать Исмәгыйлов кебек прозаик, драматурглар, күп кенә галимнәр, журналистлар һ. б. үсеп чыкты.

## Бүре Фәридә. Сылу кыз Миңнури

Бу хәл өченче класста чакта булган кебек истә калган. Төп мәктәп бинасы янында ике генә бүлмәлесе дә бар. Элек бай йорты булган, диләр. Уртадан такта белән бүленгән, шуның бер ягында без укыйбыз. Мин иң арткы партада Рәүф белән утырам. Сәбәбе шул (мин моны сонрак үзем мәктәптә эшли башлагач кына белдем): Рәүф бик шук малай, туктаусыз шаяра, укытучыга комачаулый, ә мин — яңасе, отличник, Казан, Уфа балалар газеталары хәбәрчесе — Рәүфкә уңай йогынты ясарга тиешмен икән. Әмма һәр нәрсәнең чиге була — бер көнне укытучы апа мине Рәүф янынннан алды да алдарак партага күчереп утыртты, минем урынны «юаш Наил» алды. Ләкин бу көн башкасы белән хәтердә калган: укытучы мине «Бүре Фәридә» янына күчерде, ә мин сумканы парта астына куйдым да, үзем утырмыйча басып тордым. «Тынлаулы,

тәртипле укучы» дигән исемем булуга да карамастан, үзем дә белмәстән, Фәридә янына утырмадым, укытучының берничә мәртәбә кисәтүен дә искә алмадым, 45 минут буе киреләнеп аяк өсте тик басып тордым. Ярый әле бу соңгы дәрес иде. Ә шул төнне без укыган мәктәп янды, иртән килүгә көлләр генә өелеп ята иде. Шулай итеп, «Бүре Фәридә кайгысы» да бетте...

Күңел ни өчен Фәридәне кабул итмәде икән? Мин бу хакта соңыннан, күп еллар үткәч тә уйланып карадым. Мөгаен, болай булгандыр: Фәридәләр «бүре» кушаматлы иде. Әтисе мәктәпкә килгән иде, уң колагы артында бармак сыярлык тишек бар икәнен күреп калдым. Әллә шуңа күрә аларга бүре кушаматы бирделәр микән? Йә, кушамат та бирсеннәр ди, әмма аңа карап кына кеше бүрегә әйләнми ич. Бүген шулай дип уйлыйм да, балачакта бу хәл бөтенләй башкача кабул ителгән, ахрысы. Фәридә зәңгәр күзле, сап-сары чәчле бер кыз иде, көлгәндә күзләреннән яшь коела. Кызу сөйләшә. Боларына түзеп тә булыр иде. Әмма Фәридәне кешеләр алдында бигрәк тә ике нәрсә түбәнсетә. Беренчесе — Сабит абыйсы. Ул күбрәк коридорда басып тора. Чөнки дәрес алып барырга нык комачаулагач, аны укытучылар класстан куып чыгаралар. «Сабит» дип әйтү белән тәртипсез, өлгермәүче башкисәр күз алдына килә дә баса иде, ул хулиганлык синонимына әйләнде. Шуның шәүкыймы Фәридәгә дә тиде, ахрысы. Икенчедән, Фәридә бер класста икенче елын укый. Тик һаман да өлгереше яхшы түгел. Ләкин ни генә әйтмик, мин хаксыз булганмын ул чакта. Бервакыт, авылга ялга кайтканда, Фәридәне ире белән бергә очратырга туры килде. Күршеләре аларны һәм мине кунакка алдылар. Фәридә әлләни үзгәрмәгән дә кебек. Оялып кына утырды. Мәктәп елларын искә алып, минем тарафка да җылы сүзләр әйтте. Ә мин: «Фәридә теге чактагы дорфалыгым өчен миңа рәнҗеми микән?» — дип уйланып утырдым... Их, балачак яңадан килсә икән, бөтенләй башкача булыр иде.

...Миңнури күрше Сыбаркүл (татарлар Чибәркүл дип йөртәләр) авылы кызы. Йомабикә апасы тракторчылар курсында укыганда (ә МТС безнең авылда), Риза исемле безнең егеткә кияүгә чыккан булган. Миңнури шуларда тора. Авылларында урта мәктәп булмагач, безгә килгән. Ана теле башкорт теле булса да, татарчаны да яхшы белә. Картәнисе Казан ягы кызы икән, Миңнури әйтә, мин картәнигә охшаганмын, ди. Димәк, охшаш булгач, ул әби дә бик тә чибәрдер.

8 класста 30 укучы бар. Шуларның 29-ы — кызлар һәм ...малайлардан мин берүзем. Военрук Зәфәр абый (ул сугыштан яраланып кайтты, бер кулы йөрмәс дәрәҗәдә иде) минем белән дәрес уздырып тормый, журналга «дәрес булды» дип язып кую белән чикләнә. Мин — учком рәисе. Бик «җитди зат». Шуңа күрә кызларга еш кына: «Нигә дәрес калдырасыз? Нигә өй эшләрен үтәмисез?» — дип купыраеп алам. Ач булуларын да онытам. Ә минем хәл бераз яхшырак. Чөнки мин — колхоз бригадиры ярдәмчесе. Аз-маз он бирәләр. Ярап куя шунда, очын очка ялгарга.

...Минем бер сәер гадәтем бар иде, кызлардан ояла идем. Бу нәрсә гомерлеккә дәвам итте. Әгәр «чая кызлар әләктермәсә» бәлки өйләнмәс тә идем әле. Бер көнне, гадәттәгечә, мәктәптән кайтуга әнкәй сөтле бәрәңге пешергән. Бик тә тәмле ис килә. Ашарга утырдым. Оялып кына әнкәй дә яныма килеп утырды. Ул, нәрсәдән тотыныйм микән дигәндәй, акрын гына сүз башлады: «Әле генә Йомабикә килен килеп китте. Аның сеңелесе Миңнури сине бик тә ярата, хәтта төшендә күрә икән». Шул сүзләрне ишетүем булды, кызарып китеп, ашаудан туктадым. Каракны урлашканда тотканнар мыни? Җавап биреп тормадым, колхоз идарәсендә эшем бар иде дип, тиз генә чыгып сызу ягын карадым. Икенче көнне, класста Миңнурины күргәч тә, эндәшмәдем. Әйтерсең лә апасы бездә бөтенләй булмаган да... «Мәсьәлә» шуның белән хәл ителде дә куйды...

Шулай шул, һәр халыкның үз гадәтләре бар. Башкорт халкын мин чынчынлап хөрмәт итәм. Әмма аларның үз менталитеты бар икәнен дә беләм. Мәсәлән, аларда гаилә төзү эше гадирәк, реальрәк төс ала. Әлеге очракта да, мин — ачык авыз — кызның яратуын сизмәгәнмен икән, монда Миңнури гаепле түгел ич, ләбаса. Ул «егетлек» күрсәткән һәм дөрес эшләгән булган. Тик шунсы үкенечле, бу «кыйсса» фаҗига белән тәмамланды: мин Казанда университетта укыган чагында (1945—1950 елларда), Миңнури Уфада бер башкорт егетенә кияүгә чыккан һәм күп тә тормый бала тапканда үлгән... Җәен ялга кайткач Йомабикә җиңги белән берничә мәртәбә күрешеп сөйләшкәнем булды. Ул бервакыт миңа болай диде: «Язмыштыр инде. Шунда әйбәт кенә дуслашып, йөреп киткән булсагыз, бәлкем, бергә дә яшәр идегез, Миңнури да 18 яшеннән кара җир астына кереп ятмас иде.» Кем белә бит? Моңа җавап табуы җиңел түгел...

## Кызым атлый алмый, сулышы кысыла

**1945** елның декабрь башлары иде. Мин — университет студенты. Мине тайгалы таулар иле Уралдан язмыш Казанга алып килгән заман. Лекцияләргә бәйрәмгә йөргән кебек йөрим. Иң алдагы өстәлгә утырып, бөтен лекцияләрне язып барырга тырышам. Чөнки дәреслекләр юк. Мәсәлән, Тимофеевның «Теория литературы» дигән китабы Казанда берәү генә — дәүләт китапханәсендә. Ярты төннән чиратка торып укуын укыдым, әмма башка фәннәрдән китаплар табып булмый. Ләкин ни генә булмасын, гомернең иң мәгънәле, якты чоры — студентлык еллары, дип исәплим.

Кафедра мөдире Рәбига Афзаловна Хәкимова — безнең тулы хокуклы хуҗабикәбез. Тирән белемле. Искиткеч таләпчән. Шулай да традиция буенча, ахрысы, фронтовик егетләргә ташламалар ясый. Ә безнең кебек әле генә парта арасыннан чыгып килгәннәргә таләп икеләтә. Һәм монын өчен аңа мең рәхмәт! Лекция беткәч, Рәбига Афзаловна белдерү ясады: «Атна ахырында Г. Камал театрына культпоход оештырабыз. Профком һәммәбезгә дә билет алды. Егетләргә сүзем шул: сез хәзер авыл малайлары түгел. Кызларны, тамаша беткәч тә, култыклап алып, тулай торакка кадәр озатып куярсыз.» Һәм кемгә кайсы кыз «тиясен» әйтте. Миңа Энҗе Тимбикова (күренекле прозаик Кояш Тимбикованың бертуган апасы) туры килде. Бераз уйга калдым. Чөнки бервакытта да кызлар култыклап йөргәнем юк иде, димәк, бу «эшне» бөтенләй белми идем. Шулай да сер дә бирәсе килми. Тулай торагыбыз, бүгенгәчә әйтсәк, Ленин урамында, элекке геология факультеты бинасында (бик күп еллар үткәч, ул факультет кабат үз бинасына кайтты) урнашкан. Бер бүлмә-аудиториядә 45 студент яши. Арада булачак халык язучысы Аяз Гыйләҗев та бар...

Көн салкын. Өстә кием юка. Ләкин башта бер генә уй кайный: егет кеше озата баручы кызын кайсы яктан култыкларга тиеш соң? Сугыш беткән ел. Ир заты бик аз. Хәрбиләр «подручком» үтәләр үтүен. Әмма аларга ышанып булмый, чөнки алар честь бирә торган кешеләр. Ике сәгать буена урамда туңып йөрүләр нәтиҗәсез калмады: кыз кеше уң якта булырга тиеш икән! Тамаша бетте. Урамга чыктык. Мин Энҗене култыклап алдым. Әмма шул чак көтелмәгән хәл килеп чыкты: кызым тораташтай катты да калды, тынын да ала алмый. Куркып киттем. «Ни булды икән?» — дип әллә нинди караңгы уйларга төштем. Иптәшләрем кайтып киттеләр, ә без кузгала алмыйбыз гына бит. Артык дулкынланудан, әлбәттә... Шулай да бераздан юлга чыктык. Сөйләшми генә кайттык. Менә нинди иде ул чакта татар кызлары!

## Ун кашык арыш оны

Ярый, тагын балачакка, авылга кайтып килик әле.

Миңа 6 яшь. Димәк, 1933 елны була инде бу. Өебез ике бүлмәле. Ул да төп йорттан күчерелеп салынган. Дөрес, өскә тайга урманы авып тора. Картайган, муртайган агачлар да күп, чөнки якын тирәдә леспромхозлар юк. Әмма агач кисәргә ярамый. Властьлар өчен авыл кешесе — ят элемент, кулак җанлы, димәк, пролетарий түгел. Коймалык тактаны да әткәй күршеләрдән сатып алды. Түр якта бер капчык он тора. Арыш оны. Шуны әткәй — колхоз рәисе — кашыклап колхозчыларга тарата. Менә бер абзый килеп керә. Кулында хатыны биреп җибәргән чиста баш яулыгы. Әткәй шуңа кеше башына бер кашыктан ун кашык он сала. Он шул кадәр аз, үлчәп бирерлек түгел. Югыйсә бит Көньяк Уралның табигате искиткеч бай: кара туфраклы, уңдырышлы җирләр, бихисап кырлар, болыннар, елгалар, күлләр авылны гына түгел, каланы туйдыра алган булыр иде. Революциягә кадәр ул шулай булган да. Чөнки авыл кешесенә теләгән кадәр мал-туар тотарга, бакча утыртырга рөхсәт бирелгән. Дөресрәге, бу мәсьәләгә властьлар бөтенләй катнашмаганнар. Халык ничек теләгән — шулай яшәгән. Хәтерлим: авыл уртасында мәһабәт бина бар, аны «мәгажи» дип йөртәләр иде. Картлардан бу бина тарихын сорагач, болай диделәр: «Анда кимендә йөз мең пот ашлык саклана иде. Байлар хәер итеп тапшырган икмәк. Корылык булган елларда, ашлык начар үскәндә, шуннан халыкка икмәк бирелә, ашлык уңгач, алар шуны процентсыз кайтарып бирәләр иде». Менә ул ничегрәк булган элегрәк авыл җирләрендә. Ә колхозлар вакытында авыл һәрчак ач һәм ялангач булды. Хезмәт көненә 200—300 грамм икмәк бирелгәч, ничек ач булмыйсың ди. Бер сыер, ике сарык тотарга, 10—12 сутый бакча үстерергә рөхсәт бирелә иде.

Кешеләр кебек, мал-туар да ач була. Әмма ел саен бушлай хөкүмәткә 44 килограмм ит, 300 литр сөт, 100 данә йомырка, 2 тире һ. б. авыл хуҗалыгы продуктлары тапшырырга кирәк. Бүгенге күзлектән караганда, болар күп тоелмас, бәлкем. Әмма ач замана өчен бу «натурплата» салым авыл кешесе өчен үлем белән бер иде.

Авылыбызның бер кешесе — бик тә тырыш Зәйнулла абзый «элекке заманнарны» сагыныптыр инде, саксызлык белән, күршесе алдында болай дип җырлаган:

Николай патша,— дурак,—
Сигез сыер саудырган;
Иптәш Сталин,— акыллы,—
Бер кәҗәгә калдырган.

Шул ук төнне әлеге абзыйны район үзәгеннән килеп, «кара машинага» утыртып алып киткәннәр. Хатыны, балалары белән хушлашырга да рөхсәт бирмәгәннәр.

Миткә абзый Потаповны мин дә яхшы хәтерлим. Чөнки безгә кергәләгәне булды. Әткәй — колхоз рәисе, ә Миткә абзый — колхозның умартачысы. Әлбәттә, эш белән килә. Керәшен абзый бик тырыш кеше иде. Яшәргә кирәк бит, кайберәүләр, Миткә абзый белән сөйләшеп, урманга, аның карамагына умарталарын куйганнар. Теләкләре изге — бал сатып налог, заем түләү, бала-чага өстен карау. Әмма ялкау-люмпеннарның моңа бик ачуы килде. «Миткә кулаклар үрчетә»,— дип тавыш күтәрделәр, үч алу турында хыялландылар. Сәбәбе дә табылып тора бит әле аның. Миткә абзый, татар авылында эшләвеннән «файдаланып», күптәнге хыялын тормышка ашырырга булган. Мөэзингә: «Мин мөселманлыкка күчәр идем»,— дип ычкындырган. Шул теләк белән җәйге караңгы төндә мөэзиннең өенә килгән һәм чыннан да мөселманлыкны кабул иткән, Мөхәммәт дигән исем алган. Шымчылар моны күзәтеп торганнар һәм авыл милициясенә (озын буйлы башкорт Камаловка) шундук хәбәр житкергәннәр. Икенче көнне иртән үк Миткә абзыйны райүзәккә алып киттеләр. Бер айдан шул билгеле булды: «Ислам динен көчәйткәне өчен» аны Уфа төрмәсенең базында атканнар. Хатыны, 5 баласын ияртеп, Урыс Илчекәе дигән авылга күченеп китте.

Боларын исә өлкәннәр сөйләве буенча гына беләм: Саба районының кайсыдыр авылыннан (исемен хәтерләмим) 5—6 гаилә безнең авылга күченеп килгәннәр. Безне «татар», аларны «Казан татары» дип йөрттеләр. «Казан татарлары» бик уңганнар, берничәшәр һөнәр беләләр иде. Халык аларны бик яратты. Шуларның берсе — Фәтхулла абзый Хәйруллин Карамалы елгасына (авылга 200 метр булыр) тегермән корган. Халык бик канәгать булган. Әмма һаман шул ач күзләр — элекке батраклар — иркен яшәүчеләрне күрә алмаганнар. Абзыйның тегермәненә ут төрткәннәр дә «Фәтхулла аны үзе яндырды, дәүләткә бирәсе килмәде», дип, гауга чыгарганнар. Шулай итеп, бу абзыйны да аттылар. Кыскасы, колхоз төзелә башлагач, авылның иң эшчән кешеләрен, дин әһелләрен Архангельгә, Себергә озатканнар. Нәтиҗә күз алдында: бер-ике елдан халыкка икмәкне кашык белән таратырга туры килде...

«Итоги второй мировой войны» дигән 45 табаклар чамасындагы бер китап бар. Шуны укыгач исләрем китте: Алманиядә генә түгел, башка сугышучы илләрдә дә халык ачлык афәтен кичермәгән икән. Ә безнең халык соң дәрәҗәдә ач иде (бу хакта алда сүз булыр әле). Алай гына мени, Сталин үлгәнче, колхоз авылы нәкъ сугыш вакытындагы кебек, ач-ялангач булды!

## Бәрәңгенең мае юк

**1941** елның июль башы. Мине колхоз идарәсенә (халык әйткәнчә, «правление» иде) чакырып алдылар. Кәрә-керешкә колхоз рәисе болай диде: «энекәш, күп сөйләп торасы юк, радио тыңлыйсың, гәзит укыйсың, хәлләрне беләсең. Ирләр сугышка китеп бетте. Әмма монда да фронт — икмәк, ит, майны фронтка да, шәһәрләргә дә озатырга кирәк. Лозунг та эленеп тора: «Бөтен нәрсә — фронт өчен, бөтен нәрсә — Җиңү өчен!». Без монда киңәштек тә, сиңа җаваплы эш тапшырырга булдык: икенче бригаданың бригадир ярдәмчесе итеп куябыз. Бүтән кеше юк. Дөрес, годукларың бар, әмма кулай кандидатура — син. Әтиең колхоз рәисе иде, сиңа да аның сыйфатлары йоккандыр. Укуыңны ташлама, кайткач, әтиең ачуланырлык булмасын. Бригадир итеп Садыйк бабайны билгеләдек. 75 яшьтә, укый-яза белми, ләкин башка кеше юк».

Бер хәл дә итеп булмый, тешне кысып булса да, ризалашырга туры килде. Алга китеп булса да әйтим: ике ел буена миңа өч бригадир белән эшләргә туры килде. Садыйк бабайдан тыш, армиядән яраланып кайткан Хөжжәт абзый, аны бераздан сугышка алып киткәч, шулай ук фронтовик Рәхмәтулла абзый белән эшләдем. Аллага шөкер, аңлашып, тату яшәдек.

...Сугышның соңгы ике елында «Сталинец-6» комбайнында комбайнчы идем. Салават Юлаев туган җирдәге башкорт кырларында икмәк урдым. Беренче елны ярдәмче итеп Мәүлихә апайны, икенче елда сугыштан яраланып кайткан Ишхуҗа агайны бирделәр. Сынатмадык, әйбәт эшләдек.

...1942 елның җәе. Бик авыр чак. Немец Сталинградка үрмәли. Совинформбюро, безнекеләрнең, бик каты сугышлардан соң, яңадан-яңа шәһәрләрне калдыруын әйтә. Авылга көн дә диярлек «кара хатлар» килеп тора. Эчтәлеге стандарт: «Ватан өчен батырларча көрәшеп... һәлак булды...» Ашау такы-токы булса да, Ходайга шөкер, әлегә узган елгы бәрәңге бар. Халык күбрәк шуның хисабына яши.

Җиңгиләр, апалар печән чабалар. Эшкә җәяү баралар. Төшке аш алдыннан, җиләк, бөрлегән, кымызлык, кыр юасы һ. б. җыялар. «Теш арасына кыстырырга» алары да ярап куя. Сизәм: хатыннар нык арыйлар, шулай да көнлек планны үтәргә тырышалар. Карарга кызганыч: ябыклар, карашларында нур сүнгән. Араларында «похоронка» алганнары да бар. Фәүзия җиңги, Мәрзия апа, Каюмәттәй, Хатимәттәйләр... Еламыйлар, күз яшьләре беткән, ахрысы. Кайчак болай диләр: «Их, бәрәңгенең мае булса, хәл керер иде дә, юк шул мае». Шулаен шулай да, 1943 елның җәендә бәрәңге дә юк иде инде...

Атлар авыр эштән, азык җитмәүдән, корчаңгыдан кырылдылар. Ат — акыллы җан иясе ул. Үз хәлләрен аңлыйлар кебек. Моңсу күзләреннән яшь тама. Алар үлеп беткәч, монгол атларын китерделәр. «Гәүдәгә кечкенә булсалар да, көчлеләр, азыкка талымсызлар алар»,— дигәннәр иде. Әмма алар да түзмәде... Бөтен эш хатыннар, яшүсмерләргә — тиңдәшләремә йөкләнде... Авыр, бик авыр иде, әмма халык соңгы көчен биреп тырышты... Миннән торса, фронттагыларга гына түгел, тылда тырышып эшләгән апа, җиңгиләргә дә һәйкәл куяр идем... Шул чакта район газетендә басылган «шигыремнең» бер куплеты хәтердә сакланган:

> Язгы ташкын ера буаларны,
> Авырлыктан атлар үләләр.
> Үзәкләре әллә корыч микән?—
> Тик хатыннар гына түзәләр.

Вөҗданым газапламый: сугыш вакыты хатыннары, яшүсмерләре хакында матбугатта шактый гына чыгышлар ясадым. Тик өзеп шуны әйтәсем килә: бездә кеше кадерен белү юк. Сугыш елларында көн-төн эшләгән апалар, җиңгиләрне кайгырту юк. Югыйсә, алар күпне дә таләп итмиләр...

1945 елны БМОның беренче Генераль секретаре Трюгве Ли (милләте белән норвег) үзенең бер чыгышында болай дигән иде: «Бәрәңге белән тукланган урыс халкы дөньядагы иң көчле сугыш машинасын җимерде — герман армиясен җиңде. Дан аңа!». Минемчә, Генсек әфәнде бу очракта кимендә ике зур хата җибәрде: беренчедән — СССРның (урыс империясенең) ярты халкы урыс түгел. Икенчедән, югарыда әйтелгәнчә, халык сугыш елларында бәрәңгегә дә туймады. Моны мин мең кат расларга әзермен...

## Турат «кыйссасы»

Авылда туып үскән бик күпләрнең, бигрәк тә ир затларының атларны яратуы гаҗәп түгел. Чөнки авыл тормышын атсыз күз алдына китерүе кыен. Мин дә — авыл баласы. Шуңа күрә, ярты гасыр гомерем шәһәрдә узса да, балачагымны искә төшергәндә (ә бу бик еш була), атларның язмышы турында уйланам. Ат бик тә күңелгә ятышлы, акыллы зат ул, аны хәтта хайван дип тә атыйсы килми.

Бу очракта мин авылыбызның даны булган Турат турында берничә сүз әйтмәкче булам.

Ел саен район үзәгендә, Йөрүзән елгасы буенда Олы сабантуй була иде. Табигый, һәр сабантуйның иң дулкынландыргыч мизгеле ул — атлар чабышы. Безнең якның күпчелеге башкорт авылларыннан торгач, моның бәясе тагын да

арта. Чөнки, кем әйтмешли, башкорт ат өстендә туа, ат өстендә җан бирә. Башкортлар чабышка үзләренең иң яхшы атларын чыгаралар. Шулай да биш ел рәттән беренчелекне безнең Турат алып килде. Ул бөтен авылыбызның горурлыгына әйләнде. Исеме телләрдән төшмәде. Без, малайлар, аңа багышлап такмак та чыгардык:

Турат ул бер генә, алтын ялы бөдрә,
Шундый гүзәл җан иясен сөймәс икән кем генә.

Әмма табигатьнең аяусыз, үз законнары бар. Турат олыгая башлады һәм соңгы чабышта икенче урынга калды. Ике-өч адымга гына. Турат бу җиңелүне күтәрә алмады бугай, гөрс итеп үзен җиргә ыргытты да шундук җан бирде. Әйтерсең лә борынгы рим гладиаторы инде... Шуның белән сабантуйның яме китте, халык тиз генә тарала башлады. Ә безгә бу хәл яшен суккандай тәэсир итте.

Бу хакта мин халык язучысы Гомәр ага Бәширов белән дә сөйләшкәнем бар. Үз чиратында, ул миңа менә нәрсәләр әйтте: «Врангельны тар-мар иткәч, безнең частьне Көньяк Украина далаларына — Таврияга күчерделәр. Миңа ат бирделәр. Ашау-эчү такы-токы, атларга да азык-төлек юк дәрәҗәсендә. Әмма мин, җаен табып, атны сыйлау ягын карый идем. Үзен чиста тоттым. Шуңа күрә ул миңа бик нык ияләште. Атлар акыллы бит алар. Менә хезмәт срогым да тулды. Минем өчен иң кыены атым белән аерылышу булды. Аны бала сөйгән кебек маңгаеннан сыйпадым. Ә ул башын иң башыма салып, авыр сулады, күзләреннән яшь тамды».

Мин үзем атлар турындагы, гомумән, хайваннар дөньясына багышланган китаплар укырга яратам (моңа үзенә күрә Турат сәбәпче булды дип уйлыйм). Г. Ибраһимов, Л. Толстой, С. Аксаков кебек язучыларның әсәрләрен кат-кат кулыма алам. Г. Сабитовның Ерак Көнчыгыштан, армия хезмәтеннән качып, туган Минзәлә төбәгенә кайтып җиткән ат турындагы хикәясе, А. Хәлимнең «Өч аяклы ат» повесте да күңелемне дулкынландыра. Инглиз язучысы Дж. Олдрижның «Монгол айгыры» исемле әсәре үзе генә әллә ни тора! Акыллы шул атлар, акыллы!

## Шаярган гына, имеш

Кешенең киләчәк язмышы туганчы ук маңгаена язылып куелган була диләр. Хактыр, ахрысы.

Күрше Гыйззәт абзый бер үк вакытта колхозның да, сельпоның да хисапчысы булып эшләде, тормышлары әйбәт-җайлы бара иде. Әмма ул озак яшәмәде, үпкә авыруыннан үлеп китте. Аның артыннан дүрт улының икесе дөнья куйды. Халыкның авызын каплап булмый, хатыны явыз, шуңа күрә Аллаһ аңа күтәралмаслык кайгы сала, диделәр.

Гыйззәт абзыйның хатыны Шәрәфниса җиңгинең бертуган энесе Рәхим абыйны, чулак дип, сугышка алмадылар. Халык: «Рәхим бик хәйләкәр, карак, колхоз малын урлый»,— дип гайбәт таратса да, бу сүздән ары узмады. Алар хатыны белән 7 бала үстерәләр иде. «Иде» дип әйтүнең мәгънәсе шунда, котелмәгәндә икесе дә һәлак булдылар. Ул болай була. Рәхим абый сугыш вакытында бездән 35 чакрымнар ераклыктагы Мөрсәлим станциясеннән комбайн, тракторларга ягулык ташыды. Бервакыт юлга хатынын да алган. «Стансада үзеңә дә, балаларга да чүпрәк-чапрак карарсың»,— дигән. Яз. Тирә-як искиткеч матур ди,— яшеллек. Кошлар сайрый. Кояш балкый. Юлның ике ягы да чәчәкләргә күмелгән. Әйтерсең лә табигать тә сугышның бетүенә куана. Ир белән хатын әнә шулай дөньяның матурлыгына хозурланып барганда, ниндидер кечкенә самолет түбәнәйгәннән-түбәнәя башлап, торган саен боларга таба килә икән. Башкасын алар белми дә калалар. Чөнки самолет тәгәрмәчләре белән атны да, ир белән хатынны да бәреп үтерә. Моны шуннан ерак түгел генә җир сөреп яткан тракторчылар күреп торганнар.

Судта очучы үзен аклау өчен болай дигән, имеш: «Мин һич тә җан ияләрен үтерермен дип уйламадым. Ниятем — атны куркыту гына иде. Азрак төшереп алгач, шаяртасым килде». Суд очучыны яклау юлына баса, аны нибары 5 елга ирегеннән мәхрүм итү турында карар чыгара. Ә ул бер ел да утырмый, амнистия белән иреккә чыга. Ятим калган җиде баланы төрле шәһәрләрдәге балалар йортларына урнаштыралар.

## Гайния әби һәм аның балалары

Гайния әби безнең авылга Кыйгыдан килен булып төшкән. Кыйгылылар, халык әйтүенә караганда, уңганнар, әмма усаллар да. Сүзгә «кый» кушып сөйләргә яраталар. Ул хакта җыр да бар. Имеш, бер егет Сидыкый исемле кызга гашыйк булган. Ә кыз аңа ачык йөз күрсәтми икән. Аптыраган-йөдәгән егет кызга җыр белән мөрәҗәгать иткән:

> Ар(ы) якта да Сидыкый,
> Бир(е) якта да Сидыкый;
> Чакырдым кый, килмәдең кый,
> Җаннарымны кыйдың кый.

«Кый» Гайния бик тә юаш ирен — Гариф абыйны санлап яшәгән. Чөнки татарның традицияләре шулай булган. Өч ир, ике кыз бала тапкан. 1914 елда Гариф абзыйны герман сугышына алганнар. Яраланса да, фронттан исән-сау әйләнеп кайткан. Әмма күп тә үтми аны гражданнар сугышына алып киткәннәр һәм ул шуннан гаип булган. Уллары Барый, Шөгаеп, Хәмәтнур абыйлар тиздән әнисенең кул арасына керә башлыйлар. Яңа йорт өлгертәләр. Барый абый белән Шөгаеп абый авылыбызның чибәрләренә — Салиха һәм Фәрзәнә апаларга өйләнделәр. Матур гына яшәп киттеләр. Балалары туды. Хәмәтнур абый исә 1940 елда армия хезмәтен тутырып кайтты. Өйләнде. Гариф абыйның кызлары Таһирә һәм Камәрия апалар кияүгә чыкты. Бәхетлеләр иде алар. Халык та, Гариф аганың балаларына карап шатланды. Әмма башланып киткән сугыш бар булган бәхетне бер селтәнүдә юк итте дә куйды. Җыеп кына әйткәндә, Гайния әбинең өч улы һәм ике кияве ерак җирләрдә, сугыш кырларында ятып калдылар. Разведчик Шөгаеп абый 1945 елның апрель ахырында һәлак булган, «кара хат»та шулай диелгән иде.

Җәйге ялга кайткан саен, мин Гайния әбиләргә кереп чыга, сөйләшә идем. Сүз дә юк, Гайния әбигә бик кыен булган тормышта. Әмма ул көчле рухлы һәм горур кеше иде. Бервакытта да кайгы-хәсрәткә баш имәде, күз яшен күрсәтмәде.

## Шурка

Көндәгечә, бер төркем малайлар, дөньяны онытып, төрле уеннар уйныйбыз. Шул чак Әкрам: «Зелин Сабир» абзыйлар («Зелин» кушаматы нәрсәне аңлатадыр, әлегә кадәр белә алганым юк. Әмма шунсы хак, «партизан Сабир абзый» озын буйлы иде) Бохарадан кайткан, Шурка исемле уллары да бар икән. Аны Фаик абый үзе күргән», — дигән хәбәр җиткерде. Без тынып калдык. Чөнки моңа кадәр андый исемле малай турында ишеткәнебез юк иде әле. Әнә безнең исемнәр ничек гади — Наиб, Наил, Әкрам, Зәки Шакирҗан, Рәфыйк, Нургали, Мәҗит, Биктимер, ә монданиндидер Шурка исеме... Кызыксынуыбыз зур иде. Әмма тиздән «мәсьәлә» үзеннән-үзе чишелде дә куйды — бер көнне Шурка урамга чыкты. Өстендә вельвет костюм, башында үзбәк түбәтәе, аягында сандали. Рәфыйк түзмәде: «Менә нинди була икән ул кала малайлары! Безнең беребездә дә андый киемнәр юк. Яланаяк йөрүе әйбәтен әйбәт инде җәйләрен. Әмма аякта сандали булса, бөтенләй башкачарак сөйләшер идек тә бит... Юк, шул, юк», — дип куйды.

Шушы беренче танышудан соң Шурка урамга, безнең янга ешрак чыга башлады. Башта бер-беребезне аңламыйчарак торсак та, бу хәл озакка сузылмады. Шурка татар сүзләрен «су кебек эчә башлады». Теләсә, ник өйрәнмәсен ди. Урыстан башка, теләсә кайсы милләт вәкиле башкаларның, күршеләрнең телен шактый тиз үзләштерә (урыс теләми, колларымның теле миңа кирәкми дип уйлый).

Бер ярты ел үтте микән, без Шурканың урыс малае икәнен оныттык та. Кайчак сорау туа: Шурка үзен урыс дип уйлады микән? Валлаһи, безнең өчен генә түгел, өлкәннәр өчен дә ул гади бер малай — Шурка иде. Сабир абзый Шурканы балалар йортыннан асрамага алган икән. Малайның ата-анасы исәнме, әллә ялгыз ана аннан баш тартканмы — ул хакта уйлаучы да, чүбек чәйнәүче дә булмады. Халык Шурканы кызгана иде, чөнки бервакытта да аның тамагы ипигә, өсте киемгә туймады. Сабир абзый аракы эчү белән мавыкмаса да, эш сөймәде. Мал-фәлән тотмады. Сәбәбен әзеп кенә әйтүе дә кыен, әмма, күршеләр әйтмешли, батрактан батрак туа дигәннәр хак булгандыр, ахрысы.

1943 ел урталарында Шурканы армиягә алдылар. Башта хатлары еш килә, полковая школада укыйм, дип яза иде. Әмма безнең гаскәрләр Курск дугасында сугыш алып барганда, авылдашыбыздан хәбәр килү туктады. Сабир абзый да ничектер кечерәеп калгандай булды. Күңеле дөрес сизенгән икән, бераздан «кара хат» килде. Часть командиры кул куйган хатта рәсми сүзләрдән соң: «Улыгызны сугышчылар бик ярата иде, без аның үлеме өчен дошманнардан үч алачакбыз. Александр Сабирович ике Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән иде, аны сезгә район хәрби комиссариатында тапшырырлар. Медальләрен дә алырсыз»,— диелгән иде.

Урысларда кешенең яшенә карап исеме үзгәрә. Мәсәлән, Саша Шуркага, Шурка Александрга әйләнә. Әмма безгә яшьлек дустыбыз Шурка гына элеккечә якын һәм кадерле. Һәм соңгысы: кеше язмышын уйласаң, исләрең китмәле...

## Уйнап әйтсәң дә уйлап әйт

Бригадир ярдәмчесе булып эшләгән чагым. Көз башы иде — хатын-кызларны уракка өндәп йөрим. Күршедә генә Шәрифулла абзый белән Минҗамал җиңгиләр яши. Иртәнге чәй вакытлары иде, ахрысы, гафу үтенеп, җиңгигә гозеремне әйттем. Әмма ул, бөтенләй көтмәгәндә, ут кебек кабынып китте. Юк, миңа ачуланмады, ирен тиргәргә керեште. Тик Шәрифулла абзый гына, авызына су капкандай кызарынып утырды. Ни дисәң дә ир заты бит, ятлар алдында сүз озайтасы килмәгәндер инде. Минҗамал җиңгинең авызыннан чәчрәп чыккан утлы сүзләре әле дә — бүгенгедәй — колак төбендә яңгырап тора: «Маеңа чыдый алмыйсың, үзеңне әллә кем дип белдеңме әллә? Халык сугышта кан түгә, үлә, ә син монда... Сиңа да чират житәр әле...»

Шәрифулла абзый — Саба ягыннан. Бик уңган кеше. Көннәр буе колхозның тимерче алачыгыннан чыкмый, чүкече кулыннан төшми. Халык: «Бу казан татарының кулыннан гөлләр тама, нәрсә сорыйсың, шуны коя да куя»,— дип Шәрифулла абзыйны мактап бетерә алмый иде. Ул төскә-биткә дә матур кеше: кап-кара чәчләр, кашлары да шундый, күзләре — коңгырт. Кечкенә авызлы. Мәһабәт буйлы. Эчми, тартмый, итагатьле. Кыскасы, коеп куйган чын татар иде. Сугыш башлангач, МТС директоры Әмиров Шәрифулла абзыйны үзенә эшкә чакырган да, шуңа «бронь» биргәннәр, чөнки ул аның нинди һөнәр иясе икәнен яхшы белгән. Һәрвакыт аның белән горурланган, тимерчене башкаларга үрнәк итеп куйган. Әмма да ләкин Минҗамал җиңгинең сүзләрен фәрештә ишеткән һәм «амин» чагына туры килгән, күрәсең... Була бит шундый хәлләр: МТС директоры Уфада ниндидер киңәшмәдә чакта, Шәрифулла абзыйның «бронь» срогы чыккан. Директор үзе өйдә булса, хәрби комиссариатка шалтыратыр иде дә (хәрбиләр тыңламаса, райком бар бит әле), эш шуның белән бетәр, Шәрифулла абзый машиналар белән мәш килүен дәвам итәр иде. Комиссариатта татар яки башкорт кешесе эшләсә дә, мәсьәлә бөтенләй башкача хәл ителер иде, мөгаен. Комиссар шуны белә: план бар, ә алырга кеше юк, фронт исә туктаусыз сугышчылар таләп итә. Ул, «форсаттан файдаланып», Шәрифулла абзыйны Уфага озата. Бу чакта өлкә хәрби комиссариаты «маршевый батальон» төзи икән. Шәрифулла абзыйны шунда билгеләгәннәр. Батальон турыдан-туры Курск дугасындагы сугышка барып кергән. Киткәненә ай да тулмаган иде, Шәрифулла абзыйның «батырларча көрәшеп һәлак булуы» турында «кара хат» килеп төште. Бу хәбәрне алгач, чит җирдә 4 баласы белән торып калган Минҗамал җиңги үкереп елады. Иптәш хатыннарына: «Уйнап әйтсәгез дә, уйлап әйтегез, әнә ничек килеп чыкты бит»,— дип әйтә торган булды. Әмма үткән эшкә салават, диләр, үкенү соң иде инде.

## Батрак кызы Хатимәттәй

Өебезнең урам яктагы тәрәзәләре Нәфыйк абыйлар йортына карап тора. Мин белгәндә, Нәфыйк абый Хатимәттәй белән көн итә иде. Халык әйтүенә караганда, Хатимәттәй өй эшенә бармак аша караса да, ире белән шактый тату торган. Агалы-энеле Нәфыйк абый белән Нәҗип абый ятим үскәннәр, күп авырлыклар күргәннәр. Шуңа күрә хатын-кыз җылысы алар өчен бик тә тансык булган, күрәсең. Колхозда тырышып эшләгәннәр. Әмма кайбер «каммуннарга» кеше җәберләү, бүрәнә аша бүре күрү, үртәп такмак чыгару бер ни дә тормаган. Шуларның берсен мин дә хәтерлим:

Нәфыйк белән Нәҗип,
Колхозга бодай чәчеп,
Таптылар җинел кәсеп:
Бодайны урладылар,
Шатланып җырладылар.

Бар иде «комактивның» кеше җанын ашаган чаклары, моның өчен һич бер җавап бирмәгән, халыкны хаксызга биеткән чаклары. Авылның иң юаш, мескен кешесен сельпо кибетенә сатучы итеп куйдылар. Күп тә үтмәде, «коммун Билал» (анасын кыйнап келәткә ябып куйган бер дәҗҗал) сатучы абзыйга да такмак әйтергә керешә:

Бие, бие, Гайфулла,
Биегән кеше бай була;
Кооперация малларын
Ашамасаң ни була?

Форсат чыккач, бу такмакларның «авторы» Билал абзый Исмәгыйлов турында бер-ике генә сүз әйтәсем килә. Авыл советы рәисе булып алгач (ул — батрак баласы ич, инкыйлабка кадәр мунчада көн иткән ич!), тегермәнче Фәтхулланың өен тартып алып, аның гаиләсен урамга куып чыгарды. Ләкин Бөек хакыйкать бар: 40 яшьтә үпкәсе череп үлде. Картлардан берәү дә аны җирләүгә катнашмады. Моңа бәлки күпләр ышанмас та, әмма дөреслек шул: 30 елларда коммунистларга 30х20 см зурлыкта мрамор такта тараттылар. Янәсе, үлгәч, шул ташка коммунистның исемен язып куячаклар. Билал абзыйны чыннан да ташка язып куйганнар иде, әмма кабере убылганда (мөгаен, ләхетне каплаган библ такталар тиз черегәндер. Коммунистка бәлки ләхет тә алмаганнардыр...), ташы да юкка чыккан. Картларның: «Дәһринең җир убасы көн кебек ачык иде, күптән җәһәннәм утында яна», — дип сөйләгәннәре истә калган.

Тагын Нәфыйк абыйга кайтыйк әле. Сугыш башланып ике атна узды микән, тиңдәшләре белән бергә Нәфыйк абыйны да армиягә алдылар. Берничә айдан соң «сапер Заһировның батырларча көрәшеп, Ватан өчен гомерен бирүе» турында «кара хат» килде. Колхоз авылында тормыш бервакытта да җиңел булмады. Сугыш елларында исә хәлләр бөтенләй мөшкелләнде. Халыкны нигездә бәрәңге, яшелчә, аз санда булса да мал-туар, Ходай бүләге — табигать байлыклары (җиләк-җимеш, тамыр азыклар, гөмбә) ач үлемнән коткарды. Әмма Хатимәттәй нигәдер бу «вак-төяккә» әһәмият бирмәде. Ул хәзер мәрхүмә инде, мин аны һич тә ялкау димәс идем. Әмма торышы-табигате белән дөнья көтәргә җайланмаган иде дип уйларга урын бар. Мәсәлән, ул күршеләргә бакча казый, бәрәңге, яшелчә утыртыша. Печән хәзерләшә. Ләкин үзе хакында уйламый да. Әйтерсең лә яз, җәй ел буе дәвам итәчәк. Күрше хатыннар аны ачуланалар: «Хатимә, синең башың-уең бармы, 4 баланны ачка үтерәсең килә мени? Әйдә, казы бакчаңны, бәрәңге орлыгы бирәбез», — диләр.

Ул көч-хәл белән, бөтен кешедән соң, бәрәңгесен җиргә төртеп чыга. Авылда эш туктап тормый. Бәрәңге җирен утарга, төбен өяргә-күмәргә кирәк. Хатимә апа аларга эшләшеп йөри, тик үзенекен генә карамый. Әйтә-әйтә, аны да бакчасына күз салырга мәҗбүр итәләр. Көз җиткәч, тагын шул хәл кабатлана: Хатимәттәй күршеләргә бәрәңге алыша, үзенеке шул килеш ята. «Бүре түгел, урманга качмас», — дип кенә җибәрә. Түземлеге беткән күрше хатыннар Хатимәттәйгә бәрәңге алыша, үзе әйбәт, ярдәмчел кеше, диләр. Тагын шул: Хатимәттәйнең бәрәңгесе язга җитми. Әмма күрше-тирә аны ярдәменнән ташламый.

Бервакыт мин күрше Мәгафүр бабайдан Хатимәттәйнең нигә шул кадәр ваемсыз булуы хакында сораштым. Ул болай диде:

— Батрак Ихсан кызы булганга ул шулай. Андыйларны йортлыксыз дип дөрес атыйлар. Халыкта: «Оясында ни күрсә — очканында шул булыр», — дигән тирән мәгънәле әйтем бар. Улым, күреп торасың, бездә кара туфраклы уңдырышлы җирләр. Шуларны эшкәртеп, бик яхшы итеп, мул тормышта яшәргә була. Печәнлек тә бихисап. Өскә урман авып тора. Колхозга кадәр шуңа күрә халык тук яшәде. Шул ук вакытта авылда мал-туар тотмаган, кош-корт асрамаган, бәрәңге утыртмаган берничә гаилә була. Андый кешеләр күрше хутордагы урысларга яллانып, ашлык уралар, печән чабалар, шулар бәрабәренә бераз икмәк, бәрәңге алалар. Яңа елга ашарларына калмый (ит, май, йомырка кебекләр турында сүз дә юк), яңадан урысларга барып ялланалар. Аларны батраклар дип атыйлар иде. Шул батракларның берсе Ихсан абзый иде. Хатимәдә шуның каны, гадәтләре сакланган.

Миңа калса, бабайның сүзләренә бер төрле дә аңлатма бирергә кирәкми дип уйлыйм.

## Безнең авыл кешесендә беренче дуңгыз

Бүгенге татар авылларында дуңгыз тотуга шул кадәр күнегелгән ки, әйтерсең лә татар гомере буена чучка асраган инде. Ләкин онытмыйк: ислам дуңгыз итен хәрам ризык ди, икенче төрле әйткәндә, аны тыя. Мин моны бик соң гына белдем: чучка итендә бик күп зарарлы матдәләр бар икән. Әмма «социализм юлыннан атлаучы» татарда да үзгәрешләр була икән шул. Бигрәк тә нужа бабай жилкәдән эләктерсә.

Хәтерем ялгышмаса, бу 193§ ел иде. Әткәйнең бертуган энесе Гафур абый күрше Бунаково урысларыннан бер кечкенә чучка баласы сатып алып кайтты. Моңа картәнине ничек ризалатканнардыр, әйтүе кыен. Әмма, күршеләр әйтмешли, факт остается фактом. Дуңгызны беркемгә дә күрсәтмәделәр, абзар эчендә генә тоттылар. Сәбәбе дә булгандыр: ят хайванны этләр өзгәләп ташлавы бар. Фәүзия жиңги башта бик жирәнеп йөрсә дә (ул бик чиста кеше иде), кая барсын, тиздән күнде-өйрәнде, чучка баласын коендырды, көненә берничә мәртәбә ашатты. Сәбәбе шул: дуңгызга бик зур өметләр багланган булган. Боларның һәммәсен соңыннан, үсеп житкәч кенә белдек.

«Дуңгыз тоту тарихы» болай: Гафур абый белән Фәүзия жиңги көн-төн колхозда эшләсәләр дә, хезмәт көннәре һәрвакыттагыча кысыр булып кала бирде. Аллага шөкер, властьлар ни генә кыланмасын, табигать законнарын боза алмадылар: балалар туа, ачлы-туклы булса да үсәләр иде. Әмма иң кыены — кием мәсьәләсе. Бу гаиләдә 6 бала булып киткән икән. Шул хакта баш ватканда, күрше авылның «знакумы» Илья Гафур абыйга болай ди: «Гафурка, не горюй. По-дешевке я отдам тебе поросенка. Он быстро растет, только хорошенько покорми. Свинья — денежный клад».

Хәтерлим: жәй үтеп китте. Теге озын борынны әткәй белән Гафур абый суйдылар. Ничә пот ите чыккандыр, безгә әйтеп тормадылар. Икенче көнне Усть-Катавка (аңлашылсын өчен: Татарстан шәһәрләре урамнарында бүген йөри торган трамвайларның 90 проценты Усть-Катавта чыккан машиналар) барып, итне саттылар. Табыш ярыйсы булган, ахрысы, абыйның күңеле күтәренке иде. Бу урында туктап тагын бер нәрсәне искә төшерәсем килә: картәни таләбе белән дуңгызны салып тунаган иске өстәлне яндырдылар, суйган пычакны чүплеккә ыргыттылар.

Бер-ике көн үтте микән, Гафур абый Мөрсәлим заготскотына барып, мал озатучы булып ялланды (беренчедән, вагонда малларны карап барган өчен акча түләнә; икенчедән, билет аласы, паспорт тикшерерләр дип баш ватасы юк!). Бер атнадан Мәскәүне урап кайтты. Каты борын игелекле булып чыккан: Гафур абый балаларының һәммәсенә өс-баш, аяк киемнәре алган. Жиңгине, картәнине дә онытмаган. Мөгаен, ул киемнәрнең иң очсызын, хакы төшерелгәннәрен алгандыр. Әмма бүләк хужалары ул хакта уйламый, башлары күккә тигән иде.

## Язмышмы, нәрсә бу?

**1946** елның гыйнвар уртасы. Университетта укыйм. Беренче семестр имтиханнарын тапшыргач, авылга кайтып килергә уйладым. Яшьлек, тәжрибәсезлек шул. Акыл чамалы. Нәрсәм калган минем ул ач авылда? Дөрес, әткәй-әнкәй, туганнар анда. Әмма тагын ярты ел түзеп булмас иде мени? Әнә тиңдәшләрем инде икенче ел армиядә хезмәт итәләр. Түзәләр ич (армиягә алынмавымның сәбәбе бер генә: комбайнчы буларак, «бронь» биргәннәр иде). Ә мин? Аның юлы юл мени, ул чакта Казан — Уфа поезды йөрми әле. Ләкин тиле яшьлек үзенекен итте: Сызрань, Куйбышев аркылы кайтырга туры килде. Күңел һич тә курыкмый һәм үкенми. Шулай булмый, мин университет студенты! Көньяк Урал урманнары арасыннан чыккан бер бөжәк татарның мәркәзендә белем ала. Уфада университет юк әле. Ә минем университетта укыйсым килде. Моның кимендә ике «сере» бар. Беренчесе — сугыш вакытында Белоруссиядән эвакуация белән килгән Георгий Севастьянович Хомутовский безнең мәктәптә рус теле һәм әдәбиятын укытты. Күпне белә торган бу педагогны мин чын күңелемнән якын иттем. Кайсы вузны тәмамлавын (Минскидагы университетны) белгәч, күңелдә университетка

керү омтылышы туды. Икенчедән — әле генә сугыштан яраланып кайткан авылдашым Рашат Гайнанов та университет турында хыяллана икән. Шулай итеп, бер авылдан, гомумән, Уфа ягыннан ике «яшь-жилкенчәк» Казанга, безнең яктагылар өчен сихри дөнья булган Казанга беренче булып юл тоттык.

1946 елның 10 феврале. Мөрсәлим станциясе. Чиләбе — Мәскәү поезды бер генә минутка туктый. Салкын. Дөм караңгы. Вокзал алдында бер генә лампочка жемелди. Билет сатылмый. Чөнки урын юк. Шулай да әткәй (ул чакта Мөрсәлимдә колхоз рәисе иде) ничектер поездга билет тапкан. Әлбәттә, вагон күрсәтелсә дә, анда урын юк, чөнки билет юк икәнне белгән килеш сатылган. Төн уртасында мине озатып калды. Нәрсә дип уйлады икән әткәй шул минутларда? Аякта кирза итек. Өстә — көзге пальто. Кулда — агач чемодан. Поездның тукталуы булды — ике вагон арасындагы аралыкка сикереп мендем. Һәм поезд кузгалып та китте. Салкын, бик салкын. Өстәвенә тормоз өстендәге тимер кисәге туктаусыз «бии», вагон астына төшеп китүең бик мөмкин. Сизәм — тамбур эчендә кешеләр бар. Үземнең кем икәнлегемне әйтеп ялварам, кызгануларын, кертүләрен сорыйм. Эндәшмиләр. Ахрысы, арада миһербанлысы да булган — бераздан ачтылар. Мин кердем. Урын да юк икән. Шулай да кысыла торгач, сыйдым. Вязовая станциясенә килеп життек. Анда поезд 5 минутлар тора. Ишетелә: тормозга кемнәрдер кунаклады. Алар тамбур ишеген шакып, кертүне таләп итә башладылар. Без эндәшмибез. Ачкыч белән йозакны ачсалар да, ишек ачылмады. Чөнки аны эчтән тимерчыбык белән бәйләп куйганнар икән. Тормоздагылар бик каты итеп сүгенәләр. Кропачевога (зур станция, бригада алмашына, поезд ярты сәгать туктап тора) гына житик, вагон аша үтеп, барыгызны да кырга ыргытачакбыз дип, акырынырга керештеләр. Һәм сүзләрендә тордылар. Барыбызны да перронга ыргыттылар. Бүрегем, чемоданым әллә кая барып төште. Нишләргә? Кропачевода калу нәрсә бирә? Иртәнгә кадәр башка поездны көтеп, тормозга утырып китәргәме? Бу уйлар яшен уты кебек мине яндырып алды. Һәм, яңадан тормозга сикереп менеп, юлга чыктым. Хәзер инде «тегеләргә» — безне карга ыргытучыларга ялварам. Җавап урынына урыс маты да зәһәрле көлү. Әмма мин «үз эшемне» дәвам итәм. И. Аллам, шунда берсе сорау бирде: «Син кайсы авылдан?» Авылыбызның исемен атадым. Теге кеше: «Не может быть. Тогда скажи: знаешь ли Сабира Ахметьянова?» — ди. Яшем мөлдерәп ага, шулай да үземне кулга алып: «Он родной брат моего отца. Может быть слышали, мой отец был председателем колхоза?» — дип җавап бирдем. Шуннан соң тамбур ишеге ачылды. Һәм Сызраньга кадәр жылыда бардым. Бәхеткә микән, язмышмы әллә, әмма әлеге урыс Сабир абзыйга (бу чакта ул «зур урында» эшләгән) өй салуда катнашкан. Ул зур өйне, матур верандаларын әле дә хәтерлим. Абзый, Урта Азиядән ялга кайтып, гаиләсе белән җәй көннәрен шул өйдә үткәрә иде. «Заказчик» акчаны кызганмаган, мул итеп түләгән. Әнә шулар һәммәсе бергә мине салкында туңып үлүдән коткарды, бугай.

## Бер группада 16 идек

Дәресрәге, 22 идек, әмма төрле сәбәпләр (нигездә, тормыш авырлыгы) аркасында 16 га калдык. Һәм шул килеш вузны тәмамладык та. Шактый тырышырга туры килде, әлбәттә. Һәр лекциягә бәйрәмгә барган кебек йөрдем дисәм, һич тә арттыру булмас. Ул чакта мин бу хакыйкатьне аңламый идем әле: вуз бетергәннәрнең белем дәрәҗәсе бервакытта да бер төрле булмый. Бу студентның үзеннән, аның сәләт алшартларыннан тора. «Кызыл диплом» алучылар арасында энциклопедик белемлеләр еш булмый икән, моның сәбәбе дә сәләткә кайтып кала. Әлбәттә, тырышмасаң, сәләт үзе генә белем бирми. Үземне мактарга жыенмыйм — бу ахмаклык булыр иде. Әмма төпле белем алу теләге мине, лекцияләрдән соң, китапханә ябылганчы, шуның уку залында «бикләп тотты». Чөнки, ышануыбызча, диплом алгач, күк капусы ачылачак, гел көяшлы көннәр булачак иде.

Бөек Ватан сугышы безнең җиңү белән тәмамланса да, тормыш барыбер рәтләнмәде. Чөнки Сталин «бөтен дөнья революциясен кабызу» уеннан кайтмый. Ә моның өчен Европаны яулап алырга (Америка язмышы, янәсе, сонрак хәл ителәчәк) кирәк иде. Себердә яңадан-яңа хәрби заводлар төзелде. Чимал чыганакларын табу көчәйтелде. Эшче көчләр табуның сыналган методларыннан берсе — йөз меңнәрчә, хәтта миллионнарча гаепсезләрне ГУЛАГка «туплау» бара иде. Сугыштан соң бу эш конвейерны хәтерләтте. Университет студентлары да бу мәхшәрдән читтә калмадылар. Шуларның берсе — Мәжит Рәфыйков белән соңгы

мәртәбә 50 елның 9 мартында китапханә коридорында күрешеп сөйләштем. Бу кичке сәгать 9 да булды. Мәҗит Гете поэзиясе турында диплом эшен бетерүен, күчереп язасы гына калуын әйтте. Мин дә Такташ поэзиясенә багышланган диплом эшен тәмамлавымны белдердем. Ә бу вакытта тулай торакта Мәҗитне ике КГБ офицеры көтеп утырган. Урын-җирен комендантка тапшырып ук куйганнар. Бүлмәсенә килеп керүе булган, ордер күрсәткәннәр дә, ишек алдында торган «кара каргага» утыртып алып киткәннәр.

Мин Мәҗит турында мактап та, хурлап та сүз әйтә алмыйм. Бәлки әнә шул нәрсә мине коткаргандыр да: икебез дә Уфа ягыннан булуга да карамастан, аның белән аралашып яшәргә туры килмәде. Газеталарда урыс һәм татар телләрендә шигырьләре басыла. Шуңа микән, бераз масая иде кебек. Бервакыт кулыма И. Ильф, Е. Петровның «Одноэтажная Америка» исемле китабы эләкте. Аны укып чыккач, ай буена үземне тирән пычрак чокырга ыргытылгандай мескен итеп сиздем. Америкадагы тормышның никадәр яхшы икәненә төшенгәч, ниләр уйларга белмәдем. Ходай эше микән, бу сирәк китапны (ул 1946 елда ун мең тираж белән басылды. Сатуга чыгуы булды, шундук җыеп та алдылар, матбугатта: «Авторлар исән булса, бу китапны бастырмаслар иде»,— дигән рецензияләр чыкты.) укуым хакында беркемгә бер сүз әйтмәдем. Әйтсәм, харап булыр идем, билгеле. Группада ике «сексот» булган (алар моны соңыннан, Сталин үлгәч әйттеләр. Әлбәттә, алар бу эшкә үзләре теләп бармаганнар, моңа мәҗбүр ителгәннәр).

Бервакыт «космополитизмны», «вейсманизм-морганизмны» көн-төн сүгү, алай гына түгел, аяусыз сәяси кампания башланды. XIX йөз рус әдәбияты курсын бик тә итәгатьле, чын мәгънәсендә, зыялы, гаҗәеп кешелекле профессор А. Н. Вознесенский алып барды. Мин аның лекцияләрен чын күңелемнән яратып тыңлыйм, шуңа имтиханнарны да гел «5»кә тапшыра идем. «Космополитизмга каршы тиешенчә көрәшми», дип аны деканлыктан алып ыргыттылар. «Гаебе» шул икән: «XIX гасырда Европа әдәбияты рус әдәбияты, аның классиклары Пушкин, Лермонтов йогынтысында гына алга киткән»,— дип ышандырып әйтми икән. Кызганыч иде профессорга каравы. Мин, иң алдагы өстәл артында утырганга күрә, аның лекция текстларын күрә идем: һәр юлның астына икешәр-өчәр мәртәбә кызыл сызыклар сызылган. Текстны укырга мәҗбүр, берәр саксыз сүз җибәрермен дип курка иде бугай. Ничек курыкмыйсың, 200 студент утырган залда 20—30 шымчы булсын әле! Александр Николаевич, Пушкин, Лермонтов көнбатыш әдәбиятына йогынты ясаган дип әйтсә дә, безнең күңел моңа ышанмый иде. Чөнки беләбез: И. С. Тургенев Франциядә ярым испан, ярым француз кызы балерина П. Виардо өендә яши башлагач кына, көнбатыш язучылары рус әдәбияты белән танышалар лабаса. Ә Пушкин, Лермонтов исә, билгеле булганча, аңа кадәр иҗат иткәннәр. Профессорларыбыз аеруча фронтовик коммунист студентлардан куркалар, ничек кенә җавап бирмәсеннәр, аларга әйбәт билге куялар иде.

Күпләр академик Марр теориясен беләләрдер. Аның нигезендә «Тел дә революцион көрәш законына буйсына»,— дигән мәгънәсез концепция ята. Әй тукыдылар да инде безгә шул теорияне! Бер акыллы гына телче галимебез «кояш» сүзенең барлыкка килү процессын болай аңлатты, минемчә, ул үзе моңа ышанмый иде: (урысның «яркий» сүзеннән татарның «ярык» сүзе хасыйл булган, чөнки «яркий — якты» ярыктан керә. «Яркий», «ярык» сүзләрендә «к» хәрефе (ә ул мишәр булганга күрә, аның өчен «к» да «къ» да бер иде шул) бар. Әнә шушы «к»дан «кояш» сүзе туган». Аңлата, ә үзе көлми дә. Шул ук вакытта өзеп, кистереп әйтәм: университет профессурасына мең рәхмәт! Алар мине яктылыкка омтылырга, актан караны аерырга, тормыш агышын сиземләргә өйрәттеләр, бөек тәгълиматка — әдәбиятка — гомергә сүнмәс мәхәббәт тәрбияләделәр. Яшәсен Казан университеты!

## Әрмәнстанда булып, Американы ачтым

**1960** ел язы. Ил Бөек Ватан сугышының җиңү белән тәмамлануына 15 ел тулуны бәйрәм итәргә хәзерләнә. Шул уңайдан мин Ереванга очарга, сугыш вакытында атаклы 65 армиянең политбүлек начальнигы булып хезмәт иткән генерал Хәбиб ага Ганиев белән очрашырга, аның хакында очерк язарга тиеш идем. Берничә редакциягә мөрәҗәгать итсәм дә, ачык йөз күрсәтүче кеше «Татарстан яшьләре»нең баш мөхәррире Шәех Зәбиров кына булды.

Ереван — матур, үзенчәлекле шәһәр. Союздаш республика булгач, азык-төлек проблемасы юк. Урамнар чиста. Яшеллек күп. Кая барсаң да, әрмән халкының

атаклы улларына куелган һәйкәлләр күрәсең. Үзәк урамның асфальт астыннан электр чыбыгы уза икән, ун метр саен асфальттан «башын калкыткан» лампочкалар яна, төнен алар шәһәргә сихри төс бирәләр, «Мең дә бер кичә» әкиятләрен искә төшерәләр.

Шәһәрдә 10 көн яшәгәч, шактый кешеләр белән танышырга туры килде. Әрмәнстан компартиясе Үзәк Комитетының Политик агарту Үзәк йортында татар кызын очраттым. Ул әлеге Йортның мөдире икән. Республикада чыга торган газета-журналларны карап чыктым. Урыс телендә бер генә газета нәшер ителә икән — «Коммунист Армении» дип атала. Якташыбызның әйтүенә караганда, әрмәннәрдә милләтчелек хисләре бик көчле икән. Хәер, тиздән моның чагылышын үз күзләрем белән күрдем. 27 апрель иртәсе. Шәһәрнең үзәк мәйданы. Мин яшәгән «Арарат» кунакханәсе тәрәзәсеннән бөтен мәйдан күренеп тора. Мәйданның теге ягында «Әрмәнстан» кунакханәсе. Тәүлек әйләнәсендә шуның алдында бик күп халык була. Арада яшьләр бик күп. Генералдан: «Хәбиб ага, кемнәр алар һәм нигә көн дә җыелалар икән?» — дип сорадым. Ул: «Чит илдән килгән әрмәннәр халыкны бәйсезлек алырга өндиләр. Бу теләк яшьләрдә бигрәк тә көчле. Мәхмүт, шуны онытма, күпме генә вакыт үтмәсен, форсат чыгу белән, әрмәннәр бәйсезлек игълан итәчәкләр. Бәлки ул вакытны син дә күрерсең һәм минем сүзләремне искә төшерерсең», — диде. Бик тә белеп әйткән икән...

...Ул көнне Ереванда зур демонстрация булды. Колонналарда «Даешь Карабах!», «Даешь Нахичевань!», «Мы за свободный Айастан» (Әрмәнстанның борынгы исеме — М. Ә.)!» дигән лозунгларны күтәреп баралар иде. Властьлар демонстрацияне туктату теләге белән юлларга аркылы автобуслар тезгәннәр. Әмма халыкны аның белән генә туктатып була мени! Икенче көнне белдем: демонстрация үткән төнне бик күпләрне кулга алганнар. Берничә көннән Мәскәү Әрмәнстан компартиясенең беренче секретаре Заробянны эштән алды. Янәсе, милләтчелеккә юл куйган. Мин боларны ни өчен сөйлим соң? СССР исемен йөрткән урыс империясенең таркалуы һич тә очраклы хәл түгел. Аңа каберне күптән казыдылар. Шуларның берсе — мактауга лаек, бик тә цивилизацияле әрмән халкы. Халык шагыйре Туманян революциягә кадәр: «Кайберәүләр (кемнәр икәне билгеле! — М. Ә.) билләренә үлән бәйләп, чи тиредән тегелгән киемнәрдән йөргән чакта, без китап чыгардык, коммуналь хуҗалык инфраструктурасын булдырып, шуннан файдаландык», — дип язган, әлбәттә, моңа Мәскәүнең җен ачуы чыккан. Үзләре мине ачулансалар да, мин әрмәннәрне, яратып, үз итеп киттем (журналларында язмаларымны бастырдым). Үпкәләмәдем дә. Чөнки әрмән зыялылары хаклы иде. Миннән алар болай дип сорадылар: «Казанда татар мәктәпләре күпме, гомумән татар теленә мөнәсәбәт нинди?» Миңа Казанда татар мәктәпләре, балалар бакчаларының бетеп баруы турында әйтергә туры килде. Алар: «Сез тарихка бөек халык буларак кергәнсез. Аз гына горурлык хисе юк мени сездә, ничек инде үз ана телендә белем алмау мөмкин? Бездә укыту әрмән телендә генә бара», — диделәр. Кайчак мин: «Әрмәнстанда, шул җөмләдән, Ереванда совет власте бар микән?» — дип шикләндем дә. Әмма бер мәйданда Ленинга куелган һәйкәлне күргәч кенә, эшнең асылына төшендем кебек. Әрмәнстан халкының 90 проценты — әрмәннәр. Бераз гына әзәрбайҗаннар, көрдләр бар. Мин көлеп: «Сездә яһүдиләр дә юк мени, сез моңа ничек ирештегез?» — дип сорадым. Алар кыска гына итеп: «Читләргә бездә эш юк», — дип җавап бирделәр. Ереванда китаплар тарихы йорты — Матедаран бар. Мин анда ике мәртәбә яртышар көн булдым һәм бик бай Дәүләт музейларына карап таң калдым...

## «Татар бетмәскә тиеш!»

**1975** елның сентябре. Республиканың «Белем» җәмгыяте идарәсе мине Әгерже районына, лекцияләр уку торышын тикшерергә җибәрде. Районның авылларында да булдым. Шуларның берсе — Кырынды. Әгерҗедән 40 чакрым чамасыераклыкта. Мине Кырындыга Казан егете — уңыш җыярга ярдәм итү өчен шул районга җибәрелгән шофер алып барды. Махсус түгел, юл уңаенда гына. Ул Кырынды икмәген Әгерже элеваторына ташый икән. Шулай килештек: өч көннән ул мине Әгерҗегә алып кайтырга тиеш. Билгеләнгән көнне шофер туктаган өйгә бардым. Ул чыннан да өйдә иде. Кызмачарак. Көтмәгәндә елап җибәрде. «Агайэне, ни булды?» — дип аптырашта калдым. Яшь аралаш ул: «Энекәш, ничек еламыйсың, күз алдында татар халкын бетерәләр. Кемгә ни зыяны тиде икән аның? Әйтегез әле, татар милләтен нигә бетерәләр?» — дип үкседе. Бу минем дә авырткан җирем. Мин дә: «Вак милләтләрнең» бетүенә үтә борчыла һәм «ин-

тернациональ дуслык булгач, ни өчен бер милләт уннарча милләтләрне йота? Шул партиянең милли сәясәте чәчәк ату үрнәге була мени?» — дип үз-үземә сораулар куя идем. Әмма ул вакытта әлеге сорауларга җавап табу бик кыен иде шул. Мин шофер милләттәшемә болай дидем: «Дөнья бер көн белән генә бетми. Үзгәрешләр булачак. Милләтебезнең киләчәге бар. Мин моңа чын күңелемнән ышанам»,— дидем. Шофер бераз тынычлангандай булды. «Татар бетмәскә тиеш!» — дип, кулларын йомарлап, югарыга күтәрде...

Икенче көнне без Әгерҗедә идек. Аңа күпме еллар үткән. Әмма Казан егетенең «Татар бетмәскә тиеш!» — дигән сүзләре бүгенгедәй колагымда яңгырап тора.

## Кем ул Михаил Львов?

Сугыштан соңгы урыс әдәбиятын, бигрәк тә шигъриятен укып-күзәтеп баручылар әлеге сорауга: «Михаил Львов бик үзенчәлекле һәм киң колачлы урыс совет шагыйре» — дип җавап бирерләр. Ләкин күпләр бу талант иясенең тәрҗемәи хәлен һәм иҗат юлын бөтенләй диярлек белмиләр. Ә Михаил Львовның тормышы да, иҗат юлы да башкаларныкына һич тә охшамаган. Ул шактый кызыклы һәм гыйбрәтле.

Югарыда әйтелгән иде инде: безнең Нәсибаш авылы волость үзәге булган һәм земство анда урыс телендә эшли торган мәктәп ачкан. Аның укытучылары булып Златоуст гимназиясен тәмамлаган ирле-хатынлы Габитовлар — Дәүләтша ага һәм Гөлҗиһан апа эшләгәннәр. Алар — Михаил Львов исеме белән урыс поэзиясендә урын алган шагыйрьнең ата-аналары. Ике уллары туган. Олысы — Рәшит, кечесе — Рифкать. Кызганычка, тиздән малайлар әнисез калганнар. Олысына — 2 яшь ярым, кечесенә — 8 ай чакта. Дәүләтша абый, шәһәрдә булганда, хатынына якага дип кеш тиресен сатып алган. Апа аны бер көн генә муенына салып йөреп калган... Тиредә ваба авыруының микроблары булган икән. Бәхетсезлек бер килсә, килә бит ул, ди халык. Революцион китаплар тараткан дип, патша түрәләре Дәүләтша абыйны кулга алып, еракка озаталар. Шуннан соң сабыйлар төрле кеше кулында тәрбия алалар. Соңыннан бу хакта М. Львов түбәндәгечә язган:

> О, деревенские женщины,
> Спасибо вам,
> Накормили нас досыта:
> Меня и Рашита.

Михаил Львов белән мин беренче мәртәбә 1964 елда очраштым. Моңа кадәр аның авылдашым икәнлеген бөтенләй белми идем. Әмма «серне» галим Рашат Гайнанов ачты: бер юньсезе Гөлҗиһан апа каберендәге мәрмәр ташны үз баласы каберенә алып куйган имеш. Шуңа әткәйнең дә кәефе китеп йөргән иде. Менә шулар мине СССР Язучылар союзы идарәсенә — Михаил Львовка хат язарга мәҗбүр итте. Аның кыскача эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт иде: «Мөхтәрәм Михаил әфәнде! Җәйгә безнең авылга кайтсагыз иде. Без сезгә әниегезнең каберен тәртипкә китерергә булышыр идек». Җавап озак көттермәде. Аның кыскача эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт: **«Дорогой Махмут Рахимович! Ваше письмо глубоко взволновало меня. Спасибо за большое человеческое сердце. У меня нет слов, чтобы передать те чувства, которые я испытал, прочтя Ваше письмо. Снова хлынули в душу ощущение своей трагический судьбы, боль сиротства... Современность закружила, закрутила меня. Я созвонюсь и спишусь с Рашитом, и мы летом сделаем все, что в наших силах, для могилы, для памяти матери. Стыдно и горько, но большая часть жизни у меня была посвящена ничтожнейшей борьбе за существование... Разрешите послать Вам одно из своих стихотворений о матери и книгу, в которой тоже есть стихотворение о матери. Я собираюсь в конце декабря прилететь в Казань, тогда поговорим по душам.**

**С сердечным приветом, ваш М. Львов. 25/XI-1964 г.»**

Шагыйрь сүзендә торды. Җәй көннәрендә Рәшит абый белән авылыбызга кайттылар. Картларны ияртеп зыяратка юнәлдек. Гөлҗиһан апаның каберен эзләргә тотындык. Үкенечкә, таба алмадык. Чөнки күпләр фронттан кайтмаган. Картлар да үлеп беткән диярлек. Элегрәк хатын-кызларны зыяратка, бигрәк тә мәет җирләргә кертмәгәннәр. Дәүләтша абый исән булса, бәлки каберне табарга булышыр иде. Әмма ул, татар балаларына 40 елдан артык урыс теле һәм

әдәбияты укыткан Башкортстанның атказанган укытучысы, моннан берничә ел элек үлгән иде. Кабере — Кыйгы районының Тугызлы авылы зыяратында.

Тагын бер гыйбрәтле нәрсә... Гомер буе татар иле, аның мәркәзе Казанда яшәгән күп кенә татарлар ата-анасының телен белмиләр. Хәтта шул наданлыклары белән мактаналар да әле. Рифкать абыйның бөтен аңлы гомере урыс арасында үтсә дә, татар телен белә, хөрмәт итә иде. Үлеп Казанны яратты. Башкалабызда булуны бәхеткә санады. Күп язучылар, шагыйрьләр, җәмәгать эшлеклеләре белән дуслашты. Мәскәүдә татар булуы белән горурланды. Бу хакта яшермәде. Бер шигырендә: «Безнең күзебез шуңа кысыграк — гомер буе дошманга төбәп ук аттык; аякларыбыз шуңа төз үк түгел — гомер буе ат өстеннән төшмәдек»,— дип язды. Урыс шовинистлары М. Львовны кан дошманы итеп күрделәр. Шундыйларның берсе Львов иҗатын мыскыллап «Крокодил»да пасквиль язып чыкты һәм үзе тиздән аракы парында янып үлде. Я. Смеляков дигән карагруһ: «татар теле урыс тегермәнендә он булып тартылды»,— дип кукрәк какты. Ул бәндәгә башкорт халык шагыйре Нәҗәр Нәҗми җавап шигыре язып, Мәскәүдә бастырып, татар теленең бөек һәм үлемсез икәнен раслады. Ә шовинистлар улады һәм алар бервакытта да пычрак эшләреннән тукталмадылар. СССР Язучылар союзы М. Львовның әсәрләрен Ленин премиясенә күрсәткәч, ни генә кыланмадылар шовинистлар. Премия комиссиясе әгъзалары арасында шулай ук Львовны җаны-тәне белән күрә алмаучылар бар иде. Ятим үсү, фронтта алган күпсанлы яралар, ниһаять, адым саен күргән гаделсезлекләр шагыйрьне вакытсыз кабергә тыктылар. Ул 70 яшь өстендә якты дөнья белән хушлашты. Әмма бу бөек шәхеснең 30 дан артык җыентыгы, андагы әсәрләр озак еллар яшәрләр, халык күңеленә җылылык өстәрләр.

Һәм соңгысы. Рифкать Дәүләтша улы Габитов ничек Михаил Давыдович Львовка әйләнгән соң? (Бу бит аның псевдонимы гына түгел, паспортка теркәлгән исем-фамилиясе дә...) Мондый сорауны мин Львовның үзенә дә, Рәшит абыйга да биреп карадым. Әмма конкрет җавап ишетмәдем. Элегрәк кемнәндер ишетеп калган идем: Рифкать абый яһүд гаиләсендә тәрбияләнгән. Лев, Давыд — яһүдләрдә еш очрый торган исемнәр. Тирән белемле, искиткеч итагатьле булуы да шул фаразны раслагандай тоела. Тагын бер фараз бар: шовинистларның татарны күрә алмавы башка исем алырга мәҗбүр иткәндер. Бу буш хыял түгел. Казан университетын тәмамлаган Минзәлә егете Ринат Суфиев үзенең беренче романына кереш сүз язуны үтенеп, Константин Симоновка мөрәҗәгать итә. Ул риза була һәм болай дип өсти: «Сез моннан соң Роман Солнцевка әйләнерсез». Кем-кем, әмма яһүд кавеменнән булган Симонов урыс менталитетын яхшы белгән. Монда шик юк. Бәлки берәр шундый зат Рифкать абыйга да исемен үзгәртергә киңәш биргәндер. Әмма моны хәзер беркем дә белә алмый инде.

## Кемнең теле затлырак

Мәскәүдә, СССР Педагогия фәннәр академиясе системасында аспирантура тәмамлап, диссертация яклагач, Казан дәүләт пединститутында эшли башладым. Педагогика фәне өчен авыр саналган музыка-педагогика факультетында, рус филологиясе, тарихчылар бүлекләрендә укытуны миңа йөкләделәр. Музыкантлар белән эшләүнең авырлыгы шунда, алар музыкаларын гына беләләр. Интеллектуаль базалары сай. Әмма үзләре турында югары фикердәләр. Аллага шөкер, мин алар белән уртак тел таба алдым. Шулай да күктә гел генә кояш балкып тора алмый ич.

Өченче курста педагогика тарихын укытам. Лекциягә кердем. Аудитория дәррәү аякка басты. Исәнләштем дә, гадәттәгечә, кул белән ишарәләп утырырга куштым. Бөтен курс утырды. Тик Мөхәммәтҗанов дигән студент кына басып торуын дәвам итте. Мин моның сәбәбен сорадым. Ул: «Моңа кадәр түзеп килдем. Әмма башка булдыра алмыйм, бөтен курс алдында сезгә әйтергә мәҗбүрмен: урыс кызлары минем фамилиямнән көләләр»,— диде. Мин студентка утырырга куштым. Һәм болай дип дәвам иттем: «Сез инде бала-чага түгел, ә үзегезне сабыйлар кебек тотасыз. Фамилияне сайлап алмыйлар, ул ата-анадан килә. Шулай да, әйдә «Мөхәммәтҗанов» фамилиясенә кинрәк тукталыйк әле. Мөхәммәт — пәйгамбәрнең исеме, гарәп сүзе — «макталган» дигәнне аңлата. «зян»га килгәндә, ул да гарәп сүзе — «җан»ны аңлата. Татарда «җаным» диләр икән, шул күз алдына килә: син генә, бер генә, башка беркем дә түгел (мин «Мөхәммәтҗанов» сүзен гарәпчә, латинча, кириллица белән тактага язып куйдым). Урыс фамилияләре күбрәк кушаматка барып

тоташалар. Мәсәлән, «Баранов», «Козлов», «Волков», «Медведев», «Свининин», «Белкин», «Коровин», «Курочкин», «Петухов», «Гусев», «Конев» һәм тагын әллә нәрсәләр. Әмма безнең бервакытта да ул фамилияләрдән көлгәнебез юк. Ломоносовка хөрмәтебез бик зур, ә бит аның фамилиясе «ломать нос» сүзләреннән ясалган.

Боларны сөйләгәндә, аудиториядә чебен очканы да ишетелерлек иде. Шул чак, мин сөйләшүне башка юнәлешкәрәк бордым: татар теленең дөнья күләмендәге 14 телләр исәбенә керүен әйттем һәм аларны санап чыктым (инглиз, француз, немец, испан, итальян, португал, гарәп, татар, урыс, кытай, япон, һинд, урду (Пакистан), бенгал (Бангладеш)). Студентлар моңа кадәр бу «яңалыкны» бөтенләй белмәгәннәр булып чыкты. Тәнәфес вакытында шактый студентлар үз исемнәренең мәгънәсен белергә теләүләрен әйттеләр. Күбесенең исемнәренең мәгънәсен шундук әйтә алдым. Калганнарын алдагы лекция алдыннан аңлатырмын, дидем.

* * *

Тормыш мизгелләрдән тора диген идек. Бу — хак. Әмма һәммәсен дә сөйләп чыгып булмый. Шуңа күрә кайберләренә генә тукталырга туры килде. Башкалары белән уртаклашу — киләчәк эше.

**РЕДАКЦИЯДӘН.**

**Галим һәм публицист Мәхмүт Әхмәтҗан исеме укучыларга яхшы таныш. Аның республикабыз матбугатында дөнья күргән күп кенә мәкаләләре — мөһимлеге, актуальлеге, татар халкының рухи уянышы, борчу-гамьнәре уңаеннан игътибарга лаек. Мәхмүт ага Әхмәтҗанга быелның февраль аенда 70 яшь тула. Без аны күркәм юбилее уңаеннан котлыйбыз, аңа саулык-сәламәтлек һәм яңа иҗат уңышлары телибез.**



# ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Әдәбиятыбызның проза жанрындагы бүгенге хәлләр күпләрне борчый. Уңышларыбыз да, борчуларыбыз да җитәрлек. Шуны искә алып, редакция байтак кына әдипләргә түбәндәге сораулар язылган анкета тараткан иде:

**1. Бүгенге прозаның кайсы яклары Сезне сөендерә? Соңгы елларда басылган кайсы проза әсәрләрен яратып укыдыгыз? Нинди яңа авторларга аеруча зур өмет баглыйсыз?**

**2. Бүгенге прозаның нинди җитешсезлекләрен күрәсез? Аларның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?**

**3. Прозабызны үстерү өчен хәзер нәрсәләр эшләргә кирәк дип саныйсыз?**

**Беренче саннан башлап редакциягә алынган җавапларны урнаштыруны дәвам итәбез.**

**Әдипләрне, галимнәрне һәм укучыларны шушы сөйләшүдә катнашырга чакырабыз.**

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН:**

**1.** Егерменче гасыр үтеп бара. Исән-имин булсак, тагын өч-дүрт елдан яңа меңъеллыкка аяк басабыз. Ике меңенче елның беренче таңы яңа гасырның гына түгел, зур бер меңъеллыкның да тәүге мизгеле булачак. Бу хәл әлеге көннең әһәмиятен күп тапкырлар арттырачак. Гасырлар чиге бер йөзъеллыкның икенчесе белән гадәти генә алмашынуы түгел ул. Гадәттә, мондый чакта рух үзгәрүе дә күзәтелә.

Узып баручы XX гасырны гына алыйк. Аның беренче еллары ук әдәбиятка бик зур сикереш бирде. 22 яшьлек Гаяз Исхакый, үз милләтенең хәлен тәфтишләгәннән соң, яңа гасыр таңында «Тормышмы бу?» дигән сорауны куйды. Үзе үк моңа җавап бирергә алынды. Нәтиҗәдә, «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен язды. Бу — милләт язмышы өчен бөтен җаны-тәне белән янган шәхеснең киләчәгебез хакында үзедәй зыялылар белән берлектә уйлануы, ягъни аларның да игътибарын тән йокыларын качырырдай шул мәсьәләләргә юнәлтүе иде. «...Инкыйраз» чыңы, чыннан да, татар җәмгыятен йокымсыраган хәленнән арындырды, күзе ачылуга сәбәп булды. Аның артыннан Г. Тукай, С. Рәмиев кебекләрнең көчле шигъри авазлары яңгырады.

Ләкин 1917 елның октябреннән соң татар «инкыйраз!» дип аваз салудан мәхрүм ителде. Бу сүз эчкә яшеренде. Гасырның соңгы унъеллыгында бу кисәтү янәдән яңгырады, чөнки халкыбыз үз хәлен «көлке бүлмәсе»ндәге кыек-мыек көзгеләрдән түгел, бәлки гадәти, тигез пыялалы көзгедән карау мөмкинлеген алды һәм... исе-акылы китте. Әгәр Г. Исхакый милләтнең бетүе 2100 нче еллар тирәсендә мөмкин дип юраса, баксаң, инде ике меңенче ел якынлашканда ук шушы хәлгә тарый язганыбыз беленде. Менә ни өчен язучыларыбыз да милләт язмышы мәсьәләсен үзәккә куеп иҗат итә башладылар.

Бу мәсьәләдә беренчеләрдән булып чаң сугучы өлкән әдибебез Ә. Еники булды. Ул милләтебезнең бетүгә баруы турында кисәтеп матбугатта язып чыкты, бу үтә җитди мәсьәләгә карата җәмәгатьчелекнең фикерен уятып җибәрде. Менә минем кулымда аның «Кояш баер алдыннан» дигән китабы, ул әле шушы өч-дүрт

ай эчендә генә басылып чыкты. Бу китапның кулыма килеп керүе минем өчен бик истәлекле булды. 19 сентябрь иде. Бер төркем язучылар белән, Чистай районының Яуширмә авылында булганнан соң, Казанга кайтышыбыз. Саескан Тавы янындагы кичүдән Чулман елгасы аша чыгабыз. Паром акрын гына кыймылдый. Мин, култыксага күкрәгем белән ятып, суга карап барам. Шулвакыт берәү яныма килде. Әмирхан ага икән. «Менә, юлга алып чыккан соңгы китабымны сиңа бирәсе иттем»,— диде. Өлкән әдипнең көтмәгәндәге илтифатыннан мин каушап калдым. Рәтләп рәхмәт тә әйтә белмәдем шикелле. Китапның беренче ачылган битен укып киттем: «...менә инкыйразга (бетүгә) шома гына якынлашабыз. Йөз баланың туксаны урыс мәктәпләрендә укый. Урыс теле гаиләләребезгә керде. Авылдан килгән әбиләребез оныкларыннан урысча сукаларга өйрәнәләр... Әдәбиятка яңа килгән татар яшьләренең шактый өлеше урысча гына яза. Ә без, өлкән язучылар, татар теле безнең гомергә җитәр әле дип юанган булдык». Әлеге кичкенәрәк кенә китапны мин бер утыруда укып чыктым һәм шундый нәтиҗәгә килдем: бу — бүгенге көннең «Инкыйраз»ы дәрәҗәсендәге басма. Әмирхан ага Еники тарафыннан язылган булуы андагы фикерләрнең күңелгә тәэсир итүен күпкә арттыра.

Быел укыган китаплар арасында аеруча тетрәндергәне Р. Мөхәммәдиевнең «Утлы таба өстендә» дигән әсәре булды. Мин бу әсәр белән күпләргә караганда алданрак та танышкан идем. Шушы елның март аенда без Ринат Сафа улы белән төрек язучыларының чираттагы корылтаена бардык. Бер көнне кич Әнкараның «Эч кала» кунакханәсендә Ринат миңа китапның байтак өлешен кульязмасыннан үзе укып күрсәтте. Төн таңга авышканчы автор укуында шушы китапны тыңладым. Бирегә язылганнар миңа бик көчле тәэсир итте. Кешеләр белән аралашканда да күреп торам: әсәр аларны да тетрәндергән. Соңгы елларның дәһшәтен бу дәрәҗәдә әчтән белеп, кыю һәм ачык итеп әйтеп биргән башка бер әсәрне белмим. Иң мөһиме шунда: Р. Мөхәммәдиевнең боларны язарга хакы бар, чөнки ул бу хәл-әхвәлләрне үзе кичергән. Шуңа күрә аның әйткәннәре ышандыра, укучыны биләп ала. Әйе, көрәшче татар әдәбиятының олы традицияләрен дәвам итү бу. XX гасырның туксанынчы елларындагы вакыйгаларны аңларга теләгән кешеләр кулларына «Утлы таба...»ны алачаклар.

А. Хәлимнең китабы «Гомернең ун көне» дип аталса да, анда татар халкының 1552 елдан соңгы фаҗигасе, шуннан соң кичергәннәренең бүгенге көнгә килеп җиткән нәтиҗәләре турында әрнеп языла. Татар милләтен бетерү максатына ирешүнең тагын бер юлы — татар һәм башкортны маңгайга-маңгай китерүчеләрнең кара эшләре ачып салына. Күрәбез, монда да инкыйраз мәүзугы башыннан ахырынача сузыла.

Г. Тавлинның «Афәт», Ә. Баяновның «Урланган ай», М. Насыйбуллинның «Кайтаваз», Р. Кәраминең «Каргышлы этаплар» әсәрләре белән дә шул ук хәл. Каләмдәшләрнең фидакарьлек белән иҗат итүләренә күңелдә рәхмәт хисләре уяна.

Мине тагын бер олы шәхесебезнең иҗаты куандыра. Ул — Зәки Зәйнуллин. Халкыбызның олпатлыгын һәм затлылыгын гәүдәләндергән бу ил агасына Ходай Тәгалә язучылык талантын да кызганып бирмәгән. Аның «Үрләр аша», «Галимулла агай күгәрченнәре», «Сугыш алды малайлары», «Урам» повестьлары һәм хикәяләре күпләрнең игътибарын җәлеп итәләр. Аз гына мәйданда кеше холкын ачу осталыгы, халыкчан теле, хикәяләүне җинел алып баруы — авторның төп өстенлеге. Тәлгат Галиуллинның да прозада үз урынын ала баруы шулай ук сөендерә.

**2.** Татар әдәбияты, ни генә әйтсәң дә, шигъри әдәбият булып аваз биргән. Проза, драматургиянең чын-чынлап ныклы нигездә үсеп китүләренә бер генә гасыр. Шигърият тарихы исә меңъеллык тарих төпкелләренә китә. Менә ни өчен әдәбиятыбызның олылыгын, абруен һәрвакыт диярлек шигърият билгеләп килде. Кыюлар, батырлар, туры сүзлеләр шигъриятта булды. Дөрес, прозаның да олы традицияләре барлыкка килде. Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Галәү, Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Ә. Еники... Нинди олы исемнәр! Боларның һәрберсе аерым-аерым гына да казанып булырдай әсәрләр иҗат итеп, үзләренең әдәбияттагы асыл урыннарын яуладылар, ә инде бер әдәбиятта шундый исемнәрнең булуы кайсы халык бәхетенә туры килгән икән? Шуларга тагын җитмешкә җиткән яки илле белән җитмеш арасындагы дистәгә якын зур прозаикларыбызны китереп кушсаң, әдәбиятыбыздагы бу тармакның олпатлыгы тагын да арта.

Бер абруйлы язучы «бездә 1917 елдан соңгы чорда проза булмады» дип әйткән иде. Миңа мондый кискен фикерне инкар итеп чыгыш ясарга туры килде.

Иң саллы фикерем итеп болай дидем: димәк, сезнең үзегезнен әсәрләрегезне дә юк дип исәпләргә кирәк. Болай дию аны сискәндереп җибәрде! Әйе, мондый шәрә рәвештә кире кагулардан сак булырга кирәк. Булганны күрә белү дә бик мөһим. Р. Төхфәтуллин, А. Расих, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, Н. Фәттах, М. Маликова, М. Хәсәнов кебек язучылары булган проза әдәбиятыбызны инкар итү өчен йә күзен күрмәү, яки тагын да хәтәре — акылың сәламәт булмау кирәк.

Шулай да проза үсешендә кыенлыклар бар. Аның сәбәпләре күп инде. Мин аларның барысын да санап чыгарга өлгермәм, башкалар да бу мәсьәләгә үз карашларын белдерерләр. Кайберләрен әйтсәм болай була: беренчесе — прозаикларыбызның күпчелегенең, шагыйрьләрдән аермалы буларак, «амбразурага ташланырга» кодрәтләре җитмәве; Г. Тукай кебек, «кулда каләм була торып... курку белән өркү харам» дип «мангъларны тибеп аударып» бармаулары. Исәп-хисаплык, салкын канлылык әсәрне дә салкын акыллы итә. Мондый нәрсә, билгеле инде, укучы күңелен җылытмый. Моның белән әйтергә теләгәнем шул: язучы уйда, фикердә, хистә бәйсез булырга тиеш, ягъни ул үзе теләгәнен язсын.

Каләм әһеле үз милләтен ихлас мәхәббәт белән яратырга тиеш. Бу ярату мәҗбүриятлек белән түгел, бәлки чын күңелдән булганда гына кыйммәт. Шул очракта гына «Батырша» (Ж. Рәхимов), «Сәет батыр» (В. Имамов), «Сөембикә» (Р. Батулла), «Хыянәт» (Ф. Латифи) кебек әсәрләр туар. Бүген татарның тарихын фәнни һәм эстетик өйрәнүдән, аны үзебезгә һәм башкаларга танытудан киләчәгебез бәйле. Халык бүген тарихи дөреслеккә сусаган. Аның ихтыяҗын үзешчәнлек дәрәҗәсендә генә түгел, намуслы тарихи дөреслек кенә канәгатьләндерә ала. Ягъни бирелә сүз белеп язу турында бара. Белү дәрәҗәсе бүгенге чынбарлыгыбызны сурәтләгәндә дә җитми. Хәзерге укучыны язучының хыялы белән генә тудырылган әсәрләр канәгатьләндерми. Аңа, дистәләрчә еллар буена ярым-йорты мәгълүмат белән туенганнан соң, хакыйкатьне белү кадерле.

3. Прозаның үсүе — бүген тормыш таләбе. Прозаикларыбызның яше нык олыгаеп бара. Яшь каләмнәрне барлауга, аларны рухландырырга игътибар туплаларга, язганнарын укучыга җиткерергә булышырга кирәк. Монда дәүләтебез дә ярдәменнән ташламаска тиеш.

**Радик ФӘИЗОВ:**

Кайчагында зыялылар арасында мена мондый фикерләр ишетергә туры килә. Соңгы еллардагы үзгәрешләр уңаеннан безнең татар әдәбияты сүлпәнләнде, кайбер әдипләр югалып калдылар, тема таба алмый интегәләр, гомуми төшенкелек сизелә, имеш. Мин, шәхсән, мондый юраулар белән һич тә килешергә теләмим. Соң бит, уйлап карасаң, хәл бөтенләй үзгәчә! Вөҗдан иреге, сүз иреге бирелү безнең татар әдипләренең дә ничәмә еллар буена рухларын, иҗади фикер йөртү рәвешләрен ныклы бер кысада, чикләрдә буып тотып торган богауларны чишеп ташлады. Хөрмәтле әдибәләр вә әдипләр! Рәхәтләнеп, иркенләп, җәелеп иҗат итәргә тулы мөмкинлекләр бар бит хәзер! Күңелеңдә булганны, вөҗданың кушканны берсен дә яшереп тормастан, курыкмыйча әйтергә! Әле кайчан гына әдәби әсәр язарга утырсак, тегеләй хәерче тегүчеләр сыман, җиде кат үлчәп, җиде кат кисеп җәфа чигә идек. Әдәби яктан эшкәртүне әйтмим дә инде мин, ә иң әүвәле фикере белән өстәгеләргә ярап булырмы дип. Без хәзер бөтенләй икенче шартларда. Үзгәртеп коруларны никадәр генә тиргәсәк тә, алар китергән мена бу казанышны күрмичә, хупламайча тору да дөрес булмас.

Бу мөмкинлекләрдән, бу хөрриятләрдән әллә без, татар әдипләре дә файдаланмыйбызмы? Рәхәтләнеп, тулысынча файдаланабыз бит. Кайда әле монда тема таба алмыйча аптырап, төшенкелектә калып, кулдан эш төшеп торулар!? Тормышның иң тирән чоңгылларына төшеп китте, бөтен катламнарын актарып өскә, дөнья яктысына чыгарды прозабыз соңгы елларда. Аның темасы никадәр киңәйде! Әдәби әсәрләр, документаль әсәрләр, истәлекләр, җинаятьчелекне ачып салган тулы романнар, мажаралы хәлләр... Соңгы елларда әдипләр күтәреп чыккан темаларны санап бетерү дә мөмкин түгел. Ничәмә еллар ишетеп тә белә алмаган Сталин золымы корбаннары хәле, алар кичергән газаплар күз алдыбызга килеп басты. Бу уңайдан мина иң ошаган әсәрләр Гурий Тавлинның «Афәт» романы һәм Ибраһим ага Сәләховның «Колыма хикәяләре» булды.

Мин үзем, шәхсән, күп еллар буена татар әдәбиятында шигърият өстенлек итә дигән фикердә тордым. Әмма мена соңгы вакытларда бу ышануым какшый бара әле. Фикер тирәнлеге белән, ихтимал, шигърият дөрестән дә алда барадыр.

Әмма тормышны колачлавы, төрләнүе һәм кыюлыгы белән проза үз сүзен ныклап әйтте түгелме соң хәзер? Һәм, иң әһәмиятлесе, укучыларны үзенә җәлеп итүе белән. Моның өчен зур араны алып, төрле күзәтү һәм исбатлаулар белән шөгыльләнеп торуның кирәге дә юк. Кыска гына вакытка, үзебезнең иң мәртәбәле журналыбыз «Казан утлары»ның 1996 елгы саннарында дөнья күргән проза әсәрләренә күз салу да җитә.

Тәлгат Галиуллинның «Тәүбә» романы прозада яңа бер киң адым, әле без бар икәнен абайлап кына йөргән бер катламны күтәреп, аның бөтен әшәкелекләрен, кара йөзләрен ачып салу булды. Дөрес, фикерләү рәвеше, җөмләләр төзелеше, ягъни язу манерасы белән Тәлгат язганны ошатмаучылар да күренгәли. Кимчелекләр өчен тиргәү кирәктер, әлбәттә. Әмма авторның бу әсәре прозабыз өчен барыбер яңа күренеш, зур бер адым. Алга таба. Төбендә әнә шул хөрриятнең бер җимеше бит бу. Элекке еллар булса, мондый әсәр язу буш бер эш саналыр иде, чөнки аны бер журнал да үз битләрендә дөньяга чыгармас иде.

Ерак Урал артындагы Чиләбедә яшәп иҗат итеп яткан кардәшебез Рөстәм Вәлиевнең «Фининспектор һәм бабай» хикәясе. Аны укыганда мин гел гаҗәпләнү хисе кичерә тордым. Карале, бетмәсә бетми икән бит бу адәм баласында шәхси башлангыч, нәни генә булса да эшкуарлыкка омтылу, ошбу дөньяда үзенчә яшәү хисе. Бүрек тегеп саткан бабайны тиргиләр, куркыталар, штрафка тарталар, аннан үз улы йөз чөерә. Ул тәүбәгә килә, сүз бирә һәм... һаман да үзенекен дәвам итә. Тәмам аяктан егылганчы! Рөстәмнең бу хикәясе дә татар әдәбиятында моңарчы әйтелмәгән, өр-яңа фикер, минемчә.

Хөррият бирелгәч, яшьләр һәм өлкәннәр дә әдәбиятыбызга яңа көчләр кебек булып, яңа әсәрләре белән килеп керделәр. Якташыбыз, бөек Тукайның авылдашы Әнәс ага Галиев әле күптән түгел генә вафат булды. Ничәмә еллар почмакка посып, пыскып кына янарга мәҗбүр иде ул. Әйтәсе килгәнне әйтә алмыйча. Ә менә соңгы елларда, инде олыгайгач, нинди күләмле, кызыклы романнар язып күрсәтте! Журналны укучылар өчен өр-яңа исем Роберт Айзатуллин «Ирекле тоткыннар» дигән беренче романы белән килеп керде. Бу авторларның әсәрләрендә үткән тормышыбызны аңларга, аңа бәя бирергә омтылу бар. Алар безгә тормыш дөреслеген күрсәтә, социалистик төзелешне тупикка алып килгән сәбәпләрне ачып сала. Җ. Рәхимовның «Әҗәл вагонында» дигән хикәясендә дә шул ук тормыш дөреслеге.

Соңгы елларда документаль әсәрләр дә әдәбият мәйданында үзләренә урын яулап киләләр. Чөнки алар тормыш дөреслеген әдәби әсәрләрдән дә үткәреп ачып бирәләр, шуңа күрә укучыларда да кызыксыну уятыйлар. Шушы саннарда басылган Гариф абый Ахуновның «Тимерханның авыл юллары» дигән документаль повестен да әдәбиятыбызның шушы чордагы казанышы дип танырга була бит.

Әйтәм бит, соңгы вакытларда прозабыз җиң сызганып эштә, анда тыгыла, монда күз сала, бер дә күрмәгәнен калдырмый. Госман Гомәрнең «Мөһер» дигән җыйнак кына һәм кызыклы гына маҗаралы повесте без моңарчы белмәгән, башка да китермәгән нәрсәләрне ачып сала. Тагын килеп Илдар Низамовның парчалары, Марсель Галиевнең «Догалы еллар» эссесе.

Җәмәгать, кайда әле монда тема таба алмыйча аптырап торулар? Яисә шаблон эчендә калулар? Юк бит алар! Һәрхәлдә, укучы буларак, мин аларны күрмим. Һәм анкета соравына җавап: прозаның менә шушы яклары, аның эре һәм ышанычлы адымнар белән алга атлавы мине сөендерә.

Кимчелекләргә килгәндә, бүгенге прозабызда алары да бар. Без, зур күпчелек әдипләр, үткәннәрне хәтерләү, аларга бәя бирү белән мәшгуль. Шуннан чыгып инде зарлану, сукрану, әллә кайчан үтеп киткән залимнәргә арттан йодрык күрсәтү. Әлбәттә, аның болары да кирәктер. Әмма, алай да, менә бүгенге тормышка тирәнтен үтеп керә алсаң, бүгенге хәлләргә бәя бирергә көчеңнән килсә, бу мөһимрәк булыр иде. Халыкны, димәк, укучыны, аны бит бүгенге тормыш күбрәк кызыксындыра. Ә әдипләр күзеннән төшеп торган нәрсәләр җитәрлек. Әйтик, бүгенге көндә халыкның катламнарга аерылуы бара. Авыр хәлдәге эшчеләр, эшсезләр, йорт-җирсезләр, авыл һәм шәһәрләрдә юл биштәрен күтәреп йөргән вак сәүдәгәрләр, урта катлам, баеп киткән югары катлам... Болар бит барысы да — халык. Хәтта бүгенге колхозчы да кичәге түгел хәзер! Аның да аңында үзгәрешләр, бирелгән ирektән файдаланырга омтылу бар. Гомумән, халык аңында үзгәрешләр бара. Халык әсәрләребезне яратып укысын, китапларыбызны сатып алсын дисәк, безгә тормыштан артта калмау, аның белән бергә атлау зарури. Хәтта азрак киләчәкне күзаллап карасаң да бер дә зыян итмәс иде. Әдәбият бит ул әле кайчан гына юл күрсәтүче буларак та бәяләнә иде. Проза-

гы бүгенге кимчелекләрнең сәбәбе халыкның үзен, тормышын начар белүебез дип саныйм мин. Хәер, ул элек тә шулай иде. Бөтен әдәбият тарихында шулайдыр.

Алга таба прозабызны үстерү өчен ни эшләргә? Болай дигәч, әлбәттә инде, иң беренче булып әдипләрнең тормыш шартлары, аларның хезмәтенә түләү күз алдына килә. Ләкин, шәхсән минем уемча, иң мөһиме бу түгел. Минем әдипләрне бик өнәп бетермәгән бер танышым: «Әгәренки акча түләүдән туктасалар, сез язудан туктыйсыз инде. Акча өчен генә утырасыз сез!» ди торган иде. Юк, дөрес фикер түгелдер бу. Соңгы вакытта каләм хакының күләме дә бик кимеде, түләү сроклары да әйбәт резина кебек сузылды. Әмма аңа карап кына бер әдип тә язуын да ташламады, хәтта киметмәде дә. Әлбәттә инде, әйбәт түләү бик әйбәт булыр иде. Ә шулай да, түләүгә карап кына безнең язучы халкы иҗат эшенә тоткарлык салмас дип уйлыйм мин. Чөнки әдәби иҗат ул — рухи ихтыяҗ, җан таләбе. Һәрхәлдә, безнең буын әдипләр өчен шулай.

Прозаны үстерү өчен язучыларның күнелен дә үстерергә, ягъни газета-журналларда аларның әсәрләренә урынны киңрәк бирергә кирәк. Әмма аннан да мөһиме — яшь талантлар. Аларны эзләп табу, үзләренә, әсәрләренә дә ихтыяр-игътибарлы булу. Хәзерге өлкән буын әдипләр үзләренең әдәбият дөньясына никадәр зур кыенлыклар, киртәләр, күрәләтә гаделсезлекләр аша килгәннәрен яхшы хәтерлидер. Ул заманнарда әдәбияттагы чиновниклар тормышның бүтән тармакларындагы чиновниклардан бер дә ким түгел иде... Хәзерге талантларга кытлык заманында да мондый киртә булмасын иде инде. Ә халыкта талантлар бар, бар алар!

**Рәшит ФӘТХЕРАХМАНОВ:**

Проза турында, әдәбият турында бәхәсләр журнал битләрендә әледән-әле булып тора. Дискуссиянең иң кайнары, өермәлесе 1983 елда булган икән. Танылган язучы Аяз Гыйләҗев кузгаткан давыл ул чакта шактый әдипләрне, тәнкыйтьчеләрне иярткән, хисләр кайнарлыгы фикерләр бәрелеше белән мавыктырган иде. Аннан соң үткән 14—15 ел тарих өчен, әдәбият өчен әллә ни зур вакыт булмаса да, яшәешебездә, аңыбызда бик күп үзгәрешләр барлыкка килгәнлеген исәпкә алсак, әдәби агымның бертуктаусыз хәрәкәттә булуын онытмасак, яңа зур сөйләшүнең дә житлеккәнлеген күрербез. Дөрес, сөйләшүләр булмады түгел. Журнал әдәби тәнкыйтьнең мондый отышлы формасын берничә тапкыр оештырып карады. Тик, шулай да, субъектив фикерләр бәрелешен объектив нәтиҗәләргә китердәй югарылыктагы чын дискуссияләрнең сирәгрәк булуын танырга кирәк.

Соңгы еллар татар прозасында документаль юнәлеш өстенлек алган икән. 1996 елның басылып чыккан «Казан утлары» саннарында гына да берничә документаль әсәр урын алган. Дөресен әйтик, араларында укучыны мавыктырып, үз артыннан ияртеп китәрдәйләре дә аз түгел. Әйтик, Р. Мөхәммәдиевнең «Утлы таба өстендә» романы детектив әсәрләрдән ким мавыктырмый. Шунысын да таныйк: Р. Мөхәммәдиев каләме белән мондый темага төссез әсәр язылса, ул гайре табигый күренеш булыр иде. Язучы шәхесенең югары орбитада әйләнүе, аңа тагын да колачлырак әсәрләр тудырырга ярдәм итәр дип ышанасы килә.

Р. Фәизовның «Узган гомер — янган күмер» исемле повесте да үткән тормышка кара якмыйча, аның уңай якларын барлавы, язучының аны бүтәнрәк яссылыкта күзәтүләре белән кызыклы. Дөрес, автор белән кайвакыт бәхәсләшәсе килгән очраклар да булып куйгалый. Берьяклы гына бәяләр, медальнең икенче ягын әйләндереп карамаска тырышу сизелә өлкән язучыда. Кирәк булганда бик җинел генә алсу күзлекне киеп куя да, аны салырга онытa бит авторыбыз. Эшчеләр тормышындагы уңайлыклар турында сөйләгәндә, аларның крестьян канын сыгу бәрабәренә икәнлеген (мин моны ассызыклап әйтәм) күрмәскә тырышу нык сизелә бит Радик абыйда.

Тик шулай да бер нәрсәне танымыйча булмый: үз принципларыннан баш тартмаган язучы автобиографик әсәрдә кайбер авторлар кебек, әҗәткә бирелгән ике йөз сум акча түбәнлегендәге конфликтлар белән мавыкмый, хезмәттәшләренә тирән ихтирам белән карый, шәхесне кимсетми, начар якларның да сәбәбен аңларга тырыша. Бу — зыялылык билгесе, укучыга әйбәт үрнәк. Сүз уңаеннан шунысын да билгеләп үтик: Радик Фәизов — татар әдәбиятының оста хикәячесе, стиле булган язучы, беркайчан да үзенә ласк бәяне ала алмады.

Хөрмәтле язучыбыз Гариф ага Ахунов та журналда документаль әсәре белән катнашып килә. Укучыга тәкъдим ителә торган повестьлар циклында Гариф Ахунов каләменең көче сизелә, язучының осталыгы (файдаланып бетмәгән осталыгы дип тә өстик) повестьны укылырлык итә. Тик, өлкән әдибебез гафу итсен,

«Хәзинә» янында, «Чикләвек төше», «Идел кызы», «Йолдызлар калка» янында яңа әсәр тоныкланыбрак кала.

Автобиографик яисә документаль повестьларның үз өстенлекләре булган кебек, кимчелекләре дә байтак кына. Документальлек белән нык мавыгып, образлылыктан ераклашмыйлар микән язучылар? Әдәби алымнарның файдаланылу мөмкинлекләрен тарайта бит документаль проза. Һәрхәлдә, язучы ижатының хасияте,көче образлылыкта, әдәби типлар тудыруда сынала. Документаль проза көн кадагына сугуы, актуаль проблемалар күтәрүе белән көчле булса, әдәбият мәңгелеккә омтылышы белән куәтле.

Бүгенге проза кайсы яклары белән сөендерә соң? Тормышны бизәмичә, шомартмыйча сурәтләве белән, акны ак, караны кара дип әйтүдән курыкмавы белән. Уйлап карасаң, кызыклы, гыйбрәт алырдай әсәрләр аз язылмады соңгы елларда. Моннан ун-унбиш еллар элек язылса, кыюлыгы белән дан тотардай әсәрләрнең бүгенге көндә гадәти темага язылган булып кабул ителүләре бераз уйландыра да. Заманмы шулай каралды, үзебезме шулай ваемсызландык: «Тәүбә» кебек романның әдәби җәмәгатьчелектә «шартлау» тудыра алмавы нәрсә белән аңлатыла соң? Югыйсә үзенең элгәрләре «Кенәри — читлек кошы» һәм «Балта кем кулында?» кебек романнар зуррак резонанс тудырган төсле иде. Әдәби мохиттә алар кузгалткан дулкыннар әле дә сизелеп тора.

Миңа калса, бу бәхәстә «Идел» журналында Нәбирә Гыйматдинованың Марсель Галиев белән әңгәмәсендәге фикерләрне искә алу да кызыклы булыр иде.

«...Татар прозасы урыс прозасы җирлегендә формалашкан. Аңарда шәрык йогынтысы юк. Шуңа күрә мин Чеховны, Купринны бик ярата идем...»

«...Әйе, җанга, аңга фикер бирә торган әсәрләрне урыстан, ә бәлки Аурупа прозасыннан алганмындыр».

«...Укырдай әйбер тапмыйм. Ркаил Зәйдуллиннар буыныннан соң саекты чишмә»...

Болар барысы да Марсель Гали фикерләре. Заманында шундыйрак «бомбаны» Аяз Гыйләҗев шартлаткан иде. Татар прозасын түбәнәйтми, кимсетмиме язучы? Бу әйтелгәннәр аның үз ижатына да кагыламы? Кагылса, юбилее уңаеннан чыккан мәкаләләрнең пафосы нәрсә белән аңлатыла?

Сорауларга берьяклы җавап бирү, әлбәттә, кыен булыр. Марсель Гали сүзләрендә хаклык күп. Тик аларның чын татарча, безнеңчә икәнлеген дә танырга кирәктер. Үз-үзенең башына сукмаса, мескенләнмәсә, татар татар буламыни соң?!

1995 елда «Казан утлары»нда Аяз Гыйләҗевнең «Камыш бармак, көмеш тырнак» дигән повесте басылган иде. Повесть күптән, рус язучысы Валентин Распутинның атаклы әсәреннән алдарак язылган, хәтта рус телендә тәрҗемәдә дә чыккан икән. Мине иң нык шаккаттырганы повестьларның сюжетындагы охшашлыкның (аерым урыннарда, әйтергә яраса, тәңгәллекнең) зурлыгы булды. Мәсьәләнең икенче ягы шуннан килеп чыга: ни өчен Распутинның «Живи и помни» әсәре ил күләмендә шаулады, вуз программаларына кертелде, авторын биеклекләргә күтәрде дә, А. Гыйләҗев повесте татарча басыла да алмады? Сюжетның сәнгатьчә ачылу ягы аксый идеме? Һич юк. Сәбәбе — шул яманаты чыккан татарлык. Без әле дә «Өч аршын җир»не бөек әсәр дип әйтергә куркабыз. Татарга бөеклек хас түгел, төс түгел дип уйлыйбыз. Бөек язучылар Европада, руста гына була дип фикер йөртәбез. Әдәбиятыбызның, прозабызның кимчелекләре дә шуннан килми микән? Татарда зәвыклы укучы юк дип, түбән зәвыкка йөз тотмыйлар микән прозаикларыбыз? Бездә прозаиклар юк дип, аларны читтән эзләмиме икән укучылар? Югыйсә, һәр хальқта да зәвыклы укучылар процент ягыннан азчылыкны тәшкил итә бит. Татардан процентлап алсак, бик кечкенә сан чыга шул.

Без традицияләребезне, бөекләрне олылауны да онытып барабыз. Мәхмүт Галәү кебек язучы башка халыкта булса, дөнья күләмендә шаулар иде. Күптән түгел генә 110 еллыгы билгеләп үтелгән М. Галәүнең туган авылында мемориаль такта да юк. М. Мәһдиев әйтмешли, шту син, татарда бөекләр күп буламыни?! Лимит Тукай белән Исхакыйга гына бирелгән! Бүтәннәрне татар күңеле сыйдыра алмый. Бөекләрен оныткан әдәбиятның, «Мөһаҗир»ләрен оныткан прозаның киләчәге якты булуы бераз шикләндерсә дә өметне өзмик. Гурий Тавлин бугай, татар әдәбиятын феникс-кошка тиңләгән иде. М. Галәү романнары да бит феникс кебек янганнан соң терелделәр.

Русның Ю. Либединский дигән язучысы утызынчы елларда: «Мин үземнән талантлырак бик күпләрне беләм, ләкин алар бит язмый»,— дигән. Талантлар ник язмый?! Җавапларымны шул сорау белән тәгәллисем килә. Чыннан да,

кайчагында тормышта теле-телгә йокмый, сюжетларны коеп кына куя торган шәхесләрне очратасың. Үзләре бер юл язып карамаган булырлар! Бу хакта вакытында Т. Миннуллин да әйткән иде шикелле.

Прозаны үстерү өчен иң әһәмиятле бер нәрсәне эшләргә — талантларны күтәрә белергә кирәк. Мин аңлы рәвештә башка проблемаларны күтәрмим. Монда стиль турында да, сюжетның тыгызлыгы, хисләр, вакыйгалар, фикерләр динамикасы турында да, яшь язучылар иҗаты турында да (әйтик, М. Закирның «Төшкә керүче елан»ы, Р. Сабыр хикәяләре) сөйләргә булыр иде. Тик бер сорау: талантлар ник язмый?!

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ:**

Фикер алышу өчен «Казан утлары» журналы куйган сорауларга азмы-күпме тулырак итеп җавап бирү бүген кайчандагыга караганда да кыендыр. Эш шунда ки, бүгенге проза дигәндә, күпләребез шул прозаны тәшкил иткән әсәрләрнең бер өлеше буенча гына фикер йөртә ала. Чөнки нәшриятларда китап булып чыгарга чират һәм мәрхәмәтле кулдан акча көтеп яткан хикәя, повесть, романнарның никадәр булуын да, аларның сыйфатларын да белмибез. Китапларның чыккан кадәрләре дә аз данәдә була һәм авыл кибетләренә, акчасыз китапханәләргә соң гына килә яисә килеп тә җитми. Яңа иҗат ителгән проза әсәрләренең бөтенесен «Казан утлары» белән «Идел» дә сыйдырып, укучыга житкереп бетерә алмыйдыр. Әмма югарыда язылганнар да бүгенге прозабызның бик үк куанычлы булмаган хәле турында сөйли. Ул хакта нәкъ менә хәзер әдәбият белгечләре, әдипләр һәм укучылар бергәләп бер сөйләшеп алу урынлы, вакытлы гамәлдер.

Милләтнең азмы-күпме рухи жанлануына, укучының «Без кемнәр, кайдан килдек һәм кайсы кыйблага карап юл тотабыз, асылыбыз ни?» дип ара-тирә булса да уйланып алуына бәйле рәвештә, шул милләтнең мең еллар буе туплаңган әдәбен гәүдәләндерүче әдәбият та сыйфат үзгәрешләре кичермичә кала алмыйдыр. Проза бүгенге тормыш чынбарлыгын, иҗтимагый үзгәрешләр барышын чагылдыруга бик акрын күчә, артта кала дип күңелсез нәтиҗәләргә килгәләсәк һәм авторларны ашыктырырга теләсәк тә, яңалыкларны да күрмичә калырга ярамастыр. Ринат Мөхәммәдиевның «Сират күпере», беренчеләрдән булып, әнә шул ярыш дулкынында тумадымыни? Урынлы итепме, әллә бераз ипсезрәк төстәме, авторның романнар язу осталыгы һәм тәжрибәсе, теманың ничек ачылуы, баш каһарманның ни дәрәҗәдә тулы яктыртылуы хакында, билгеле, төрле фикер әйтергә мөмкиндер һәм алар инде әйтелде дә. Әмма ул әсәр — бар, ул укыла. Флүс Латифиның «Хыянәт» повесте, Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» романы халкыбыз язмышындагы үтә фажигале чорны хәтерләрдә яңартып, уйландыралар, дәүләтчелегебезне югалтуга китергән сәбәп һәм ялгышларны күрсәтеп, бу катлаулы заманда аларны тагын бер кабатламаска чакыралар. Мөсәгыйт Хәбибуллин романында Мәскәү түрәләренең эш-гамәле һәм яшәү рәвеше шулкадәр заманча тасвирлана, алардагы күп исемнәрне бүгенгегә күчереп укып китәсе килә башлый. Бу ике әсәрнең нәкъ бүген язылуында тагын бер мөһимлек бар: авторлар шагыйрь Мөхәммәдъяр, Шәех Колшәриф кебекләрне калку һәм үзәктә биреп, ил башларын мондый четерекле заманда акыллылар сүзенә, милләтнең әдәп-әхлагына колак салырга чакыралар, ә акыл иясләрен бердәмлеккә бер кыйблага тугры калырга өндиләр.

Бүгенге чор прозасында Нәбирә Гыйматдинова аерым урын билләп килә. Аның «Күке төкерегe», «Болан» кебек гайре табигый (ә, бәлки, үтә табигыйдер?) вакыйгаларны тасвирлаган повестьларын да чорыбыз куйган: «Кемнәр без, асылыбыз ни?» дигән сорауларга җавап эзләве дип аңларга кирәк. Дөрес, җавапны ул бик үзенчәлекле вакыйгалар жирлегендә эзли һәм шуның белән безне... үткәннәребезгә кайтара. Нәбирә күтәргән темалар, ул сынландырган героинялар татар фамилиясеннән чыккан дип исәпләнүче А. Купринның «Олеся»сыннан, Кол Галиләрдән һәм легенда-дастаннардан ук килә. Аерма шунда гына, Нәбирә героинялары, чорыбыз холкына тәңгәллек саклагандыр, ныграк ачулылар һәм хәтәррәкләр. Алар изгелекне дә, кирәксә, явызлыкны да зуррак итеп эшли алачаклар, һәм бу хәлләр әсәрләрне кырыс тормыш чынлыгына тагын да якынайталар. Алардагы изгелекнеңме, әллә явызлыкныңмы җиңүе автор ихтыярыннан да тормыйдыр кебек тоела. Повесть каһарманнарын без ничек аңлыйбыз, үз әхлагыбыз кысаларында аларның яшәешләрен кайсы якка алып китәбез — нәтиҗә шуларга бәйле булыр. Хәер, әдәбиятның гомуми хәле дә укучы ихтыярыннан, аның ничек кабул итүеннән тора түгелмени соң?

Бүгенге әсәрләр үзләренең төрле яктан катлаулылыклары — «Сөембикә ханбикә...»дә вакыйгаларның акыл җитмәс киңлеге һәм «таныш шәхесләр»нең күплеге, Нәбирә Гыйматдинова повестьларында җаннар тартышы, Тәлгат Галиуллинның «Тәүбә» романында мафия башлыгын ил башы дәрәҗәсендә киң акыллы һәм мәгълүматлы итеп тасвирлау һәм башкалар белән шактый әзерлекле укучыга исәп тотып язылганнар. Әйтик, «Тәүбә»не укыйбыз да, котырынган «милли мафия» темасы әдәбиятыбызга ничек шулай ябырылып килеп керде соң әле, җинаятьчелек үзе тормышыбызда әкренләп кенә тамыр җәйде бит, дип гаҗәпләнәбез. Ә чынлыкта, «кинәт»ме соң? Болай гаҗәпләнмәс өчен чак кына элегрәк Фәүзия Бәйрәмованың «Кара урман»ын укырга кирәк булгандыр бәлки... Әдибә анда, үзе күз алдына китергән һәм сурәтләп, гомумиләштереп бирә алган биеклектә, җәмгыять җинаятьчелегенең тамырларын да ачып күрсәтә.

Тәнкыйтьче Мансур Вәлиев «Шәһри Казан»дагы бер язмасында прозаның терелеп килү галәмәте турында бер өметле сүз әйтергә батырчылык итте. Ләкин ашыкмадымы, хыялны чынбарлык итеп күрсәтмәдеме ул? Бу сорауга җавап эзләгәндә «Казан утлары» журналының, мисал өчен, узган елгы унберенче санын (бу юллар язылганда уникенчесе килмәгән иде әле) тагын бер карап чыгыйк. Аның эчтәлегендә, минемчә, кызыклы саналырлык берничә күренеш бар. Зәки Зәйнуллинның «Ат каралары» романы халкыбыз үткән тормышның соңгы чорларга кадәр язылмаган гыйбрәтле хәлләрен тасвирлый, ат караклыгын да, милләтнең гореф-гадәтләрен һәм әдәбен дә төрле чор вакыйгалары җирлегенә куеп, укучыны уйланырга, үз-үзен танырга чакыра. Игътибар белән укыганда, тыгызсыз холыклы әдип бу романын да тыныч яза алмаган дигән тәэсир кала. Нәкъ шушы ягы белән әсәр бүгенге татар прозасының гомуми халәтен дә чагылдыра кебек. Язучы әле баш каһарман Рәвилнең, мескен Ярулланың гамәлләрен бик оста табылган детальләр аша нечкә тасвирлау белән укучыны сокландыра (дүрт аяк сеңерләре киселгән Кара Кашканың үз котүенә кайтып бару күренешен искә төшерик), әле халкыбыз тарихы сәхифәләрен тыныч-сүрән язуга күчә (әдәбиятыбызда сурәт-тасвирсыз, вакыйганы сөйләп чыгуга корылган тулы әсәрләр дә бар инде), әле хәрбиләр кискенлеге һәм ачу белән (күңелгә яктылык бирмичә, пошаманга төшерә торган әсәрләр күбәя, чынбарлыгыбыз әдәбиятка әнә шулай да үтеп керә) финагент Зәйнәп ишеләрне хөкем итә.

Журнал санында бүгенге татар прозасының гомуми халәтен ачарлык тагын бер күренеш — Барлас Камаловның «Күңелдәге сүзләр», Рөстәм Кутуйның «Ир кешеләр», Фәрит Нәгыймовның «Кыңгырау» хикәяләре. Эш, минем карашка, менә нәрсәдә. Барлас Камалов хикәясе әле өлкән буын әдипләренең аз сүзле, әмма матур-матур әсәрләр иҗат итә алуын искә төшереп куандыра. Соңгы чорларда гына Мәгъсүм Хуҗин «Идел»дә укучы күңеленә якты бирерлек хикәяләр чыгарды.

Рөстәм Кутуйның «Ир кешеләр» әсәрен «Шәп хикәя нинди була?» дип сораучыларга җавап итеп күрсәтергә мөмкин. Теманың яктылыгы, тасвирлаудагы җанлылык, кара-каршы сөйләшүдә тышкы яктан балаларча эзлексезлек, самимилек һәм эчке мантыйк, көтелмәгән мәгънә борылышлары... Монда кат-кат сайланмыйча, урынсыз алынган бер генә сүз дә юк. Ул ягы, ихтимал, тәрҗемәче Әхмәт Рәшитов уңышыдыр. Хикәянең үз телебезгә тәрҗемәче аша кайтуы да кызык уйга этәрә: шулай шәбрәк микән әллә? Бер генә автор мондый хикәяне бар итә алмыйдыр, бәлки?

Фәрит Нәгыймовның «Кыңгырау» әсәре дә урыс телендә иҗат ителеп, Рашат Низамиев тәрҗемәсендә татар хикәясенә әверелгән. Хәзерге прозаның бик авыр ягы да шул тел инде. Чөнки, әсәрләрнең бер өлешен укыгач, элек Гомәр Бәшировлар, Фатих Хөсниләр, Хәсән Сарьяннар роман-повестьларын сандугачтай сайратып бер дә юкка тырышканнар мәллә, дәвамчылары бик аз калды түгелме, дип тә уйлап куярсың. Алар да бит тел очындагы егерме-утыз сүзне төрле вариантларда гына кабатлап җиңелрәк яза алганнардыр? Тик нигәдер алай итмәгәннәр. Шөкер, әле дә телгә сак караучылар бар. Әйтик, Рафаэль Сибатның «Ике гашыйк һәм җыр тыңлаучы ат» повесте нәкъ менә йөгерек теле белән күпне ота.

Җәмгыятьтәге хәзерге борылыш чоры әдәбиятта да үзара сайлашу белән үзенчәлекледер кебек. Әдипләр төрле жанр, төрле тема арасында бәргәләнәләр. Проза яңача таләпләр белән үз даһиларын һәм ачык күңелле, китап кадерен белгән укучыларын эзли. Ә укучы исә әдәп-әхлак тәрбиясенә мохтаҗ, тик ул тәрбияне кайдан аласын гына белми. Эзләнүчеләр бер-берсен табышсыннар өчен бөтен яктан да бик ипле һәм бик нечкә эш кирәктер.



**Әбрар Кәримуллин,**
академик

# ТӨРКИЯДӘ «КАЗАН» ЖУРНАЛЫ

## Төркиядә төрки-татарлар

Идел-Урал буеның болгар-татарлары хәзерге Төркия дәүләте җирләренә кайсы заманнарда сукмак сала башлаганнар — тарихтан бу турыда мәгълүматлар очратканым юк. Ничек кенә булмасын, Бөек Болгар дәүләтендә яшәгән ерак бабаларыбыз өчен Анатолия, Кече Азия ят җир саналмаган. Хәзерге Төркиянең үзәгендә, көнчыгыштан көнбатышка сузылган йөзләгән чакрымлы таулар чылбырының «Болгар таулары» дип аталуы да күктән төшмәгән. Төркия, Иран, Әзербәйҗан топонимиясендә «болгар» исемнәре очрау да шул заманнардан килә дип саналырга хаклы. Кара диңгезнең төньягында, төньяк Кавказда, Азов диңгезе буенда, Иделнең түбән агымында яшәгән — Бөек Болгар дәүләтен тудырган халыкның бер өлеше Кече Азиядән бу якларга күчеп килгән төрки-болгарлар булуын төсмерләп була.

Кубрат хан заманында Бөек Болгар дәүләтенең хазарлар (әзериләр) тарафыннан басып алынуы аркасында болгарларның бер өлеше Дунай буйларына күчеп, анда Дунай Болгариясен барлыкка китерсә, икенче өлеше Иделнең урта агымына менеп Идел Болгариясе дигән дәүләт кора, ә өченче өлеше Кавказ тауларына елышып, соңыннан карачай-балкар исеме астында билгеле була. Болгарларның бер өлеше, һичшиксез, хазарлар кул астында да калган. Бөек Болгар дәүләте җимерелгәнче һәм җимерелгәч тә болгарлар Кече Азия юлларын онытмаганнар. Күренекле рус тарихчысы тюрколог Д. Е. Еремеев «төрекләрнең билгеле бер дәрәҗәдә Кече Азия халкының варислары» булуын таный (Д. Е. Еремеев. Этногенез турок.— М., 1971.— Б. 21—22). Шунда ук бу галим «инде III—IV гасырларда ук төрки халыклар Кече Азия, Кавказ һәм Балкан халыкларының күп санлы һәм даими күршеләре булганнар» дип яза. Икенче төрле әйткәндә, ул безнең эраның III гасырларында ук Кече Азиядә, Кавказда, Кара диңгезнең төньягында һәм Балканда төрки халыкларның киң таралып, күпләп яшәүләрен таный. Ә бәлки алар бу регионнарда аннан да элек яшәгәннәрдер — кем белә.

Идел буе Болгар дәүләте барлыкка килгәч тә безнең бабаларыбыз өчен Кече Азия, Кавказ юлларына чирәм үсмәгән. Идел буе Болгарстанына инде VIII—IX гасырларда ук ислам дине керә башлау, 922 елда аны рәсми кабул итү нәтиҗәсендә Кече Азия белән элемтәләр үсә, ныгый барган. Мәккә вә Мәдинә юллары төркиләр яшәгән Анатолия аша узган, ә инде Госман империясе барлыкка килгәч, дини элемтәләргә сәүдә, мәдәни бәйләнешләр дә өстәлгән.

Хәзерге төрек теленең диалектларыннан иң күп таралганы — кыпчак диалекты. Ә әдәби төрек теле исә Кече Азиягә сәлҗукләр үтеп керүе нигезендә формалашкан. Сәлҗукләр — угыз телле төркиләр. Төркиянең күршеләре төрекмәннәр, әзериләр, кырым татарлары да угыз төркеменә керә. Хәзерге төрек теленең кыпчак диалекты бәлки Кече Азиядәге борынгы төркиләр теленә барып тоташа торгандыр? Бөек Болгар дәүләте җимерелгәч, аның халкының бер өлеше Кече Азиягә дә күченеп киткән булуы мөмкин бит. Идел буе төркиләренең Кече Азиягә күченүе Идел Буе Болгарстаны заманында да дәвам иткән. Бу күренеш Алтын Урда чорында тагын да активлашкан. Кече Азияда, Мисырда «мәмлүк» исеме белән йөртелгән гавәм кыпчаклардан, Идел буе, Төньяк Кавказ, Азов буйларыннан барып чыккан халыклардан торган. Идел, Урал, Азов, төньяк Кавказ болгарлары да кыпчак телле халык.

Бу тарихи экскурсның максаты — хәзерге төрек халкының формалашуында болгар-кыпчакларның да өлеше булуын күрсәтү. Кече Азиягә күченеп килүче болгар-кыпчаклар аерым төрки халык булып формалашмаган, алар «төрекләшкәннәр». Дөрес, әле XIX гасыр ахырында да Төркиядә «болгар» исемен йөртүче этник группалар булуы турында төрек әдәбиятында искә алына.

XIX йөзнең соңгы чирегенә хәтле болгар-татарларның Идел-Урал буйларыннан авыл-авыл булып, зур төркемнәр белән Төркиягә күченеп килүләре турында мәгълүматларны очратканыбыз юк. Кайсы чорларда, кайсы яклардан һәм күпме төрки-татар Төркиягә күчеп килгән, биредә аларның тормышлары ничек булган — бу турыда кулга алырлык бер тикшеренү дә юк.

Гөләчйөз Хәйретдин «Казан төрекләре» күпләп беренче мәртәбә Төркиягә 1893 елда килделәр дип яза (Казан,—1978.—№ 22.—Б. 53). Бу күченү Госман дәүләте падишаһы Солтан II Абдулхәмит белән алдан сөйләшү һәм аның рөхсәте буенча башкарыла. Шул елны Төркиягә 3000 ләп төрки-татар күченеп килә. Чыгышлары буенча алар Уфа, Стәрлебаш, Стәрлетамак, Балтач, Әчтерхан, Хан урдасы, Оренбург, Чесноков, Бөгелмә, Чакмак шәһәрләре һәм ул тирәдәге авыллардан булалар. Аларның бер өлеше Төркиянең Иске шәһәре тирәсендә авыллар төзеп тормыш башлап җибәрәләр. Ул авыллар әле дә исән. Ә бер өлеше шәһәрләргә урнаша.

Казан «төрекләренең» икенче тапкыр күпләп Төркиягә күченүе 1900—1901 елларда, Николай II заманында була. Бу юлы күченеп килүче «Казан төрекләре» Казан, Бөгелмә, Самара, Киркәле, Куакбашы, Шөгер, Иске Иштирәк, Яңа Иштирәк, Яхшы Каратай дигән шәһәр һәм авыллардан кузгала. Бу юлы 2000 ләп төрки-татар Төркиягә килеп урнаша.

Төркиягә күченеп килү гаять мәшәкатьле була. Бер яктан — иң башта Төркия солтаныннан рөхсәт алу кирәк, икенче яктан — Русия хакимиятеннән күченеп китү өчен паспорт һәм рөхсәт алу тагын да катлаулырак. Әмма шушы ике күченүгә рөхсәт итәргә мәҗбүр булган патша хакимияте инде яңа күченүгә рөхсәт бирми.

Күчкән кешеләрнең барсы да «Казан төрекләре» генә булмаган, Төркиягә бару юлында аларга карачайлар, балкарлар, ногайлар да кушылган. Патша хөкүмәте чик куймаган булса, әлбәттә монда күченүләр ике генә тапкыр булмас иде. Дөрес, Төркиягә, Төркия аркылы гарәп илләренә, Мәккә вә Мәдинәгә хаҗга, укырга һәм сәүдә эше белән Кече Азиягә, Африкага барып чыккан төрки-татарларның Төркиядә төпләнеп калулары да булган, ләкин андый кешеләр күп түгел.

1917 елгы рус инкыйлабыннан соң Русиядә власть башына килгән большевиклар нинди «җәннәт» ясаячагын төшенгән, чын мәгънәсендә урыс сәясәтенең нәрсә икәнен аңлаган татар зыялылары, сәүдәгәрләре, байлары советлар эзәрлекләүләреннән качып Ерак Көнчыгыш илләренә, Финляндиягә, Төркиягә качып китәләр. Алман сугышында әсирлеккә төшкән татар солдатларының да бер өлеше Төркиягә күчеп килә. 1917—1920 елларда советлар терророннан качып меңләгән төрки-татарлар Ерак Көнчыгыш илләренә — Кытайга, Кореяга, Япониягә юл тота. 1940 еллар уртасында (Цинзянны искә алмаганда) бу көнчыгыш илләрендә 5—10 мең төрки-татар яшәгән дип искә алалар. 1945 елгы совет-япон сугышында Япония җиңелгәч совет гаскәрләре белән бергә Маньчжуриягә басып кергән «органнар» вәкилләре биредәге татарларның зыялыларын кулга алып, совет төрмәләренә тутырдылар. Кытайда коммунистлар властька килгәч тә Маньчжуриядәге төрки-татарларга яшәү мөмкинлеге калмады. 1950 еллар башында биредә калган татарлар төрле юллар белән Австралиягә, Канадага, Америкага киттеләр, бер өлеше Төркиягә килеп урнашты. Маньчжуриядән Төркиягә күпме татар күченеп килүе турында да мәгълүматлар юк, һәрхәлдә, алар бер-ике мең тирәсе булгандыр дип уйларга мөмкин.

Икенче Бөтендөнья сугышында алманнарга әсирлеккә эләккән татар солдатларыннан азмы-күпме бер өлешенең дә Төркиягә килүләре билгеле.

«Төркиядә күпме төрки-татар бар?» дигән сорауга без туры, тулы җавап бирә алмыйбыз. Шуңа күрә бабаларыбызның соңгы йөз елда бирегә килеп урнашулары турында безгә билгеле булган хәбәрләрне күзәтү белән генә чикләнәбез. Төркиядә күпме төрки-татар яшәве белән кызыксынган профессор Надир Дәүләт 1975 елда Анкарада 900—1000, Истанбулда 500—600, Иске Шәһәрдә 300—400, Измирдә 20—30, башка якларда 90—100 ләп «Казан төрекләре» яшәве мөмкин дип яза (Дәүләт Н. Төркиядә казанлылар) (Казан.— 1975.— № 15.— Б. 31).

А. Хәкимоглы Төркиядәге татарларның саны 25 мең чамасы дип яза (A. Hekimoglu. Antiislamische Propaganda inder Sowjetunion // El Mu&arirun (Berlin).—1967— № 8/9— S. 10).

Надир Дәүләт бу санны артык күпертелгән дип саный. Татар-төрек дуслыгы җәмгыятенең рәисе Ф. Фәтхелисламов исә үзенең «Казан утлары» журналында басылган «Телдә, фикердә, эштә берлек» мәкаләсендә (1994.— № 6.— Б. 183—187) Төркиядәге татарларның санын күрсәтмәсә дә, андагы милләттәшләребезнең 35,9 проценты — Россиядән, 45,9 проценты Кытайдан, 18,2 проценты Япония һәм Кореядән килгән дип күрсәтә. Кызык килеп чыга: бу автор Төркиягә килеп урнашкан татарларның ничәшәр проценты кайсы илләрдән булуын күрсәтә, ә Төркиядәге татарларның «төгәл санын күрсәтү бик кыен», дип яза. Парадокс!

Моннан ике-өч ел элек шагыйребез Әхмәт Гадел Татарстан телевидениесендәге чыгышында Төркиядәге татарларны миллионлап санады. Күрәсең, бу санга ул Төркиядә яшәүче кырым татарларын да кертәндер.

Ничек кенә булмасын, Төркиядә күпме Идел-Урал һәм Себер төрки-татарлары яшәве хәзергә хәтле билгеле түгел. Төркиягә күченеп килүче татарлар турындагы өстәге күзәтүгә таянсак, анда кимендә бер ун меңләп төрки-татар булырга тиеш. Алар, әлбәттә, өйләнешкән, балалар тапкан, үрчегәннәрдер. Димәк, бу сан да артырга тиеш иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, Надир Дәүләт китергән саннар дөреслеккә якындыр дияр идем. Эш шунда — Төркиягә күчеп килгән татарларның төрекләр белән тел һәм дин якынлыгы нәтиҗәсендә икенче-өченче буында инде алар төркиләшкәннәр. Барсы булмаса да, абсолют күпчелеге. Мин моны Садри Максудиның кызы Адиләнең дә төрекләшүеннән, оныкларының татарча бөтенләй белмәүләреннән чыгып әйтә алам. Г. Баттал-Таймас, Йосыф Акчура, Әхмәт Вәли Мәңгәр, Рәшит Рәхмәти Аратларның икенче буыннары инде тулысынча төрекләшүенә дә таянып әйтә алам.

Төркиягә килеп урнашкан төрки-татарлар арасында 50 нче еллар уртасына хәтле милләтчелек идеясе булмый. Төрекләр белән бер дин, телләр якынлыгы, уртак миф-легендалар булуы, гореф-гадәтләрнең дә якынлыгы аркасында бирегә күчеп килгән төрки-татарлар биредә үзләрен чит халык дип сизмәгәннәр. Балаларын төрек мәктәпләренә биргәннәр, махсус татар мәктәпләре ачу турында уйламаганнар, гарәп шрифты белән басылган төрек китапларын аңлау алар өчен зур проблема булмаган. XIX гасырда бирегә килгән милләттәшләребез арасында зыялылар булуы да шикле, булса да — алар аз булган. Күчеп килүчеләр — авыл халкы, кул көче белән яшәүчеләрдән торган.

Ә 1917 елдан соң Төркиягә күп кенә татар зыялылары килгән. Ләкин болар арасында да милләтчелек идеясе тарафдарлары, милли мәгариф, мәдәни эшләрен торгызу, милли клублар, кичәләр оештыру, яшьләр белән эшләү, татар китабы басу артыннан йөрүчеләр булмаган. Бу зыялыларның абсолют күпчелеге төрек мәдәнияте фәне, икътисады, тарихы өлкәсендә эшли башлый, Төркиянең сәяси, иҗтимагый, фәнни тормышында тирән эз калдыра. Рәшит Рәхмәти Арат, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Муса Акъегетзадә тиз арада Төркиянең күренекле галимнәре, җәмәгать эшлеклеләре булып танылалар. Төрек теле, тарихы, юриспруденциясе, фәлсәфәсе буенча китап артыннан китаплар...

Дөрес, Төркиягә килеп чыккан төрки-татар зыялыларының барсы да бу юлдан китми, кайберләре үзләренең кем икәнлекләрен онытмый, үз милләте турында да кайгырталар. Г. Баттал-Таймасның бөтен иҗаты диярлек татар халкының тарихын өйрәнүгә, аның зыялыларының тәрҗемәи хәлен торгызуга, төрек укучысын төрки-татар халкы тарихы белән таныштыруга багышлана. Зәки Вәлиди, Фоат Туктаров, Ләбиб Каран, Мәхмүт Таһир, Наилә Бинарк, Гаяз Исхакый (Төркиядә яшәгән елларында) «шимали төрекләре» өчен җан атучы әдип, галимнәр булып калалар. Дөрес, монда килеп төркиләшкән чыгышлары Идел-Уралдан булган өстә искә алынган галимнәр дә үзләренең шимали төрекләре уллары булуларын онытып бетермиләр, милләтебез тарихы, әдәбияты буенча хезмәтләр язгалыйлар. Бары тик Садри Максуди гына бу кагыйдәдән чыгарма була.

Төркиядәге төрки-татарлар арасында милли идея 50 нче еллар уртасында барлыкка килә. Бу эш Төркиягә Ерак Көнчыгыш илләреннән килеп чыккан төрки-татарлар эшчәнлегенә бәйләнгән. Маньчжурия, Япониядә милли мәктәпләр оештырган, газета-журналлар, китаплар басуны аякка бастырган, милли музыка-сәнгать кичәләре, яшьләр, хатын-кызлар өчен төрле җәмгыятьләр оештырган, шундый юллар белән Ерак Көнчыгыш илләренә килеп чыккан милләттәшләребезне милләт булып саклап калу өчен Гаяз Исхакый башлап җибәргән бу изге эшне Маньчжурия, Япониядән Төркиягә килгән милләттәшләребез кузгата. Алар 1954 елда Истанбулда «Идел-Урал төрекләре култур вә социал ярдәм дәргәне» (җәмгыяте) оештыралар. 1957 елда Ләбиб Каранның актив катнашы белән шунда ук «Сөембикә култур җәмгыяте» эшкә керешә һәм бу җәмгыять татар телендә китаплар басу эшен дә башлап җибәрә. 1963 елда Анкарада «Тукай исемендәге яшьләр клубы» оештырыла һәм ул «Тукай бюллетене» дигән журнал басуга керешә.

## «Казан» журналы вә Әхмәт Вәли Мәңгәр

**1970** елның 5 маенда Анкарада «Енә газета» исемле газета дөнья күрә. Аны «Казан култур вә ярдәмлек дәрнәге» чыгара башлый. Тиздән ул «Казан төрекләре культур вә ярдәмләшмә дәрнәге» дип үзгәртелә. Бу өстә искә алынган «Идел-Урал... дәрнәге»нең яңа исеме булырга тиеш. Тиз арада бу газета урынына күрсәтелгән җәмгыять «Казан» дигән журнал оештыра. Аның беренче саны 1970 елның июлендә Анкарада басылып чыга. Бу журнал ун ел дәвамында нәшер ителә, аның 23 нче, соңгы саны 1980 ел башында дөнья күрә.

1—22 саннары Анкарадагы «Аййолдыз» матбагасында, ә соңгы 23 нче саны «Сан» басмаханәсендә басыла. Журналның күләме 64 биттән тора, форматы белән «Аргамак» журналы чамасы. Журналның беренче саны Япониядән килгән Рифат Мөхмәсип баш редакторлыгында (имтияз сахибе), ә калган 2—23 саннар доктор Мәхмүт Алукай редакторлыгында басыла. Беренче — бишенче саннарының «язу эшләре мөдире» — Надир Дәүләт, калганнарының «язу эшләре мөдире» (җаваплы секретаре) — Рәшит Аги. 2—16 саннарында «секретарь» буларак Саидә Арсланбәк күрсәтелә, калган саннарда «секретарь» күрсәтелмәгән. Журналның редколлегия әгъзалары: доктор Әхмәт Тәмир, Мәхмүт Таһир, Рифат Мөхтәсип, Надир Дәүләт; 12 саныннан редколлегия составына Наилә Бинарк, 21 саныннан Әмрулаһ Аги кертелә. Әхмәт Тәмир — 20 еллар башында Әлмәттән Төркиягә килгән галим, ә Наилә Бинарк — Финляндиядән килгән татар кызы. Калганнары — 50 еллар башында Ерак Көнчыгыш илләреннән килгән Гаяз Исхакый шәкертләре.

Журналның матди ягы исә тулысынча диярлек Әхмәт Вәли Мәңгәргә (1891—1978) бәйле. Ул журналны оештыручыларның берсе дә. Аның атасы Казан артындагы Мәңгәр авылыннан. Ә Әхмәт Вәли Мәңгәрнең хатыны Сабабаш авылыннан (хәзерге Саба районына керә торган авылдан). Ә. В. Мәңгәр үзе Кызылъяр (Петропавловск) шәһәрендә туа. Яшьтән үк сәүдә эшләре белән Монголия, Кытай юлларын таптый. 20 еллар башында Маньчжуриядә кала, сәүдә, менеджерлык эшләре белән шөгыльләнә. Бирседә ул Алманиянең «Мерседес-Бенц» фирмасы белән элемтәләр урнаштыра, Кытайга бу фирмадан машиналар кайтарта башлый. Ул үзенең килеренең күп өлешен Маньчжуриядәге татарларның мәдәниятен күтәрүгә, ярлыларга ярдәм итүгә, мәчетләр салуга, мәктәп-мәдрәсәләр, газета-журналлар, китаплар басуга тота. Маньчжуриянең Мукден, Харбин кебек татарлар күпләп урнашкан шәһәрләрдә генә түгел, Кытайның Шанхай кебек халыкара сәүдә үзәгендә дә Ә. В. Мәңгәр татарлар өчен мәдрәсә ачу юлларын таба. Бирседә дә аның ярдәме белән татар журналы басыла башлый. Гаяз Исхакый Маньчжуриядә оештырган «Идел-Урал» җәмгыятенең эшләре өчен дә, «Милли байрак» газетасын чыгару өчен дә ул зур матди ярдәм итеү килә. Ә. В. Мәңгәр 1939 елда гаиләсе белән Төркиягә күчеп килә, бирседә дә сәүдә-менеджерлык белән шөгыльләнә. Хәзерге көндә Төркиядә җитештерелә торган «Мерседес-Бенц» автомашиналары фирмасы аның эшчәнлегенең нәтиҗәсе: Алманиянең шул исемдәге фирмасы белән килешеп Төркиядә әлеге маркадагы автомашиналар җитештерүне ул башлап җибәрә. Төркиядә ул бирседәге татар зыялылары Рәшит Рәхмәти Арат, Хәмит Зөбәер Кошай, Йосыф Уралгәрәй, Адилә Аида, Наилә Бинарк, Гаяз Исхакыйлар белән аралашып яши. Х. З. Кошай, А. Аида, Н. Бинарк, Муса Ярулла Бигиләрнең әсәрләрен үз хисабына

бастырып чыгара. Маньчжуриядә «Милли байрак»ны чыгару чыгымнарын үз өстенә алган булса, биредә «Казан» журналының спонсоры була. Азия, Европа, Америка илләре белән эш алып барган бу олуг бизнесмен үзенең татар халкының улы икәнен бервакытта да онытмый, үзе тапкан малның күп өлешен милләтенең мәдәниятенә, мәгарифенә, матбугатын үстерүгә, бу илләргә килеп чыккан халкыбызны милләт буларак саклап калу эшенә тота. Ә. В. Мәңгәр талантлы бизнесмен генә түгел, киң эрудицияле зыялы да, халкыбызның тарихы, мәдәнияте, сәнгатенә гашыйк булган зат та. Ул яшьлек елларында Казан, Троицк, Түбән Новгород, Оренбург, Кызылъярдагы зыялылар белән аралашкан, дуслашкан. Аның дуслары арасында татар артистлары, язучылары, җәмәгать эшлеклеләре, атаклы сәүдәгәрләр, педагоглар да аз булмаган. Бу аның «Казан» журналы битләрендә басылган хезмәтләреннән дә күренә. (Ул талантлы журналист та булган.) Журнал битендә аның түбәндәге мәкалә һәм истәлекләре басылган. Атаклы артистыбыз белән очрашулары турында «Габдулла Кари» дигән мәкаләсе «Казан» журналының беренче санында ук бар. Атаклы татар педагоглары Бубилар һәм алар оештырган Буби мәдрәсәсе турында ул «Буби мәдрәсәсе вә Буби кардәшләр» дигән истәлек һәм уйлануларын яза (№ 3). Аның каләменнән «Татар театры хакында» (№ 12), «Гали әкә Умаров» (№ 19), «Агафуровлар вә Вәлиевләр хакында хатирәләрем» (№ 20), «Имтиязлы бохаралылар» (№ 4), «Газиз Булат хакында хәтеремдә калганнар» (Атаклы казакъ мәгърифәтчесе, музыка белгече) (№ 15), «Нигъмәтулла Хаҗи Карамшак хакында хатирәләр» (№ 16), «Мәкәрҗә ярминкәсеннән хатирәләр» (№ 17), «Казан төрекләренең милли, мәдәни фагыйльләтендә имам вә түҗәрләрнең роле» (№ 6), «1922 елда Татарстанда ачлык сәфаләти хакында белгәннәрем» (№ 17)... һ. б. язмалар төшә.

1980 елда Төркиядә төрле партияләрнең эшчәнлеге туктатылу сәбәпле «Казан төрекләре культура вә ярдәмләшмә җәмгыяте» дә эшләүдән туктый һәм ул чыгара торган «Казан» да басылмый башлый.

1970 елда «Казан утлары»нда (№ 5) М. Госмановның «Тарихтагы тирән эзләр» исемле мәкаләсе чыкты. Галим анда мәдәни, тарихи мирасыбызны барлау, туплау мәсьәләләрен дә күтәрә һәм укучыларга бу изге эштә ярдәм итүләрен сорап мөрәҗәгать итә. Шушы мөрәҗәгатькә җавап йөзеннән Ә. В. Мәңгәр Петропавел, Петербург, Уфадагы танышларында саклана торган кульязма китаплар, татар матбугаты, аерым зыялылар, татар фольклорына караган материаллар турында мәкалә язып чыга (№ 14). Ә. В. Мәңгәр күп кенә казакъ зыялылар белән дә таныш булган, аралашкан. Аның өстә искә алган Газиз Булат турындагы һәм журналның 13 санындагы «Мир Якуб Дулатов» дигән казакъ язучысы, мәгърифәтчесе турындагы истәлек-мәкаләсе шул турыда сөйли. Журналның 18 һәм 20 саннарында «Әхмәт Вәли Мәңгәрнең хатирәләре» дигән истәлекләреннән аның татар җәмгыяте хәйрияләре, аларның спонсорлары, күренекле рус һәм алман эшмәкәрләре белән аралашулары турында кызыклы мәгълүматлар белән очрашабыз.




Ә. В. Мәңгәр Татарстаннан татар китаплары, татар журналлары да алдырып торган. Алдырып кына тормаган, аларны укып та барган, гомер буе СССРда коллыкта яшәүче милләттәшләре язмышы белән кызыксынып яшәгән. Төркиягә барып чыккан татар, башкорт вәкилләре белән очрашырга тырышкан.

Ә. В. Мәңгәр дөньякүләм танылган бизнесмен генә түгел, милләтпәрвәр зат та булган. Татарны милләт буларак саклап калу өчен көрәшүче изге җаннардан булган. Бу яктан мин Әхмәт Вәли Мәңгәрне татар халкының бөек уллары Гаяз Исхакый, Г. Баттал-Таймаслар белән бер рәткә куяр идем. (Аның тормышы белән кызыксынучы-

ларга аның кызы Сафия Имре язган «Әтием» дигән истәлекләре белән таныштырга киңәш итәм. Бу әсәр 1994 елда Казанда татар теленә тәрҗемә ителде, «Ватан» җәмгыяте тарафыннан аерым басма буларак басылып та чыкты, «Казан утлары»нда да дөнья күрде — 1994 ел, 7 сан).

«Казан» журналын оештыру гаять актуаль, изге максатлардан чыгып эшләнә. Беренче максат: туган иленнән аерылган милләттәшләребезне ассимиляциядән саклап калу өчен аларның милли, тарихи аңнарын үстерүгә ярдәм итү. Икенчесе: Кече Азиягә килеп яши башлаган милләттәшләребезнең төрки-болгар икәнлеген кардәш төрек укучысына аңлату. Аларның аңына «татар»ны монгол белән бер дип сеңгән ялганнан арындыру, төрек вә шимали төрекләренең тугандаш халык булуын аңлату. Шуңа күрә журнал үзенең битләрендә бер урында да диярлек безне «татарлар» дип атамый, «Идел-Урал төркиләре», «Казан төрекләре», «Шимали төрекләре» дип кенә язып килә. Төркиягә барып чыккан, анда тарихи темаларга хезмәтләр тудырган безнең милләттәшләребез дә төрки-болгарлар тарихы, Казан ханлыгы тарихы турында язганда да Төркиядә дә, Европада да сүгенү белән бер саналган «татар» этнонимын кулланмыйлар. Бөтен дөньяда монгол басып алучылары исеме белән бер мәгънәдә кулланылган «татар» сүзен Гаяз Исхакый да кабул итә алмый, шуңа күрә үзенең «Инкыйраз»ында бары тик «болгар» этнонимын гына куллана.

## Журналда басылган хезмәтләрнең эчтәлеге

Журнал үзенең эчтәлеге белән шактый универсал, тематикасы буенча ул заманда чыккан безнең кайбер басмалар белән чагыштырганда бай. Аны мин татар теле, әдәбияты, фольклоры, сәнгате, иҗтимагый фикер тарихы, төрки-татар тарихы буенча үзенә күрә бер энциклопедия дип санар идем. Бу журнал Татарстан һәм Русия китапханәләрендә булмаганга күрә, анда басылган материаллар турында бирәдә тулырак белешмә биреп китү кирәк дип саныйм. Ул материалларны аерым темаларга бүлеп, классификацияләп бирү дөрес булыр.

## Татар әдәбияты һәм фольклоры буенча материаллар

Журналда татар матур әдәбиятына һәм фольклорына зур урын бирелә. Бу аңлашыла да. Милләтнең рухы, эстетик аңы, милли үзенчәлеге әдипләр иҗатында шактый тулы чагылыш таба. Әдәбият — халык күңеленең көзгесе дә. Теге яки бу әдип үз халкының хәлен һәм язмышын, уй һәм теләкләрен нихәтле чагылдыра алган — аның бөеклеге, әсәрләренең халык күңеленә үтеп керүе, популярлыгы әнә шуларга бәйле. Журнал матур әдәбият әсәрләрен басуда эстетлык күрсәтмәгән. Шуңа күрә төрле әдәбиятлар, һәм дөньяның аерым классикларын пропагандалау белән дә шөгыльләнмәгән. Хәтта төрек әдипләре әсәрләренә дә урын бирмәгән. Журналда дөнья күргән әсәрләр барсы да — татар әдипләренең шигырьләре, хикәяләре. Максат бер генә — чит илгә килеп урнашкан милләттәшләребезне төрки-татар әдипләре иҗаты белән таныштыру һәм шулай итеп аларны милли рухта тәрбияләү, туган теленә, гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләү...

Журнал битләрендә кайсы чор әдипләре һәм аларның нинди әсәрләре басылган соң? Бу мәсьәләгә киңрәк тукталу безгә кайсы әдипләребезнең әсәрләре халык күңеленә якынрак булуын ачыклау өчен дә әһәмиятле.

Татар матур әдәбияты әсәрләре белән беррәттән журнал битләрендә аерым әдипләр тормышы һәм иҗаты турында, әдәбиятыбыз тарихы турында да шактый күп хезмәтләр басыла. Исфәндияр Ишгайның «Сәиф Сараиның яңа табылган әсәрләре» дигән мәкаләсе әдәбиятыбызның ерак чорларына караган әдипләребезнең берсенә багышланган (№ 22). Бу хезмәттә әдипнең чорына һәм иҗатына, аның турында дөнья күргән материалларга, шул исәптән Хатип Миңнегуловның «Казан утлары» (1972, № 6), Хуҗи Мәхмүтовның шул ук журналда (1969, № 11), һәм үзбәк галиме Н. Дәүранның 1968 елда Ташкентта Сәиф Сараи турында чыккан хезмәтләренә анализ ясалган, әдипнең әсәрләреннән журналда үрнәкләр дә китерелгән.

Журнал битләрендә унбишләп татар әдибенең, шул исәптән совет чоры язучыларының да әсәрләре басылган. Кайбер очракларда журнал аерым әдип-

ләрнең тормышы һәм иҗаты турында мәкаләләр басу белән генә чикләнә, аның әсәрләреннән үрнәкләр китерми. Бу бигрәк тә прозаикларыбызга карый. (64 биттән торган журналда проза әсәрләренә күп урын бирү мөмкин түгеллеге дә аңлашыла.) Советлар Берлеге һәм чит илләрдә яшәп иҗат итүче әдипләребезнең әсәрләрен басканда, аларның тормыш юлы, иҗаты турында мәкаләләр бирелми, кыскача гына биографик белешмә китерү белән чикләнелә.

Башта журналда әсәрләре басылмаган, ә тормышы һәм иҗаты турында мәкаләләр генә бирелгән әдипләрне санап үтик. «Шакир Мөхәммәд» (1865—1923) — әдипнең вафатына 50 ел тулу уңае белән авторы күрсәтелмәгән мәкалә (№ 10). Алга таба авторы күрсәтелмәгән мәкаләләрне «а.к-мәгән» дип билгеләп барырбыз; профессор Әхмәт Тәмирнең «Татар әдипләреннән Зариф Бәшири: 1888—1962» (№ 23), Надир Дәүләтнең «Габдрахман Ильяси: 1856—1895» (№ 5), Наилә Бинаркның «Муса Акъегетзадә: 1865—1923» (№ 15), авторлары күрсәтелмичә басылган «Сәгыйть Рәми: 1880—1926» (№ 13); «Фатих Кәрими: 1870—1937» (№ 2) дигән мәкаләләр. Журнал битләрендә Каюм Насыйри әсәре «Фәвакиһел җөләсә»дә үрнәкләр бастырыла (№ 9).

«Казан» битләрендә иң күп урын Габдулла Тукай әсәрләренә бирелә. Шагыйрьнең журналда түбәндәге шигырьләре, поэмалары дөнья күргән: «Туган тел», «Шүрәле», «Васыятем» (№ 13), «Өзелгән өмед», «Кемнән ярдәм эзләргә» (№ 10), «Таз», «Теләнче», «Нәсихәт» (№ 11), «Мөхәрриргә» (№ 12), «Су анасы», «Кадер киче» (№ 16), «Шиһап хәзрәт» (№ 7—8), «Эш», «Бишек җыры», «Иссез чәчәк», «Ата белән бала», «Бәхетсез бала», «Сабыйга» (№ 10), «Театр» (№ 14).

Г. Тукайның һәм башка әдипләрнең әсәрләре журналда татар телендә һәм төрек теленә тәрҗемә итеп — янәшә биреләләр. Тукайның үз әсәрләреннән тыш «Казан» битләрендә әдипнең тормышы турында хезмәтләр дә басылып торган: Маньчжуриядә вафат булган язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Хөсәен Габдуш (№ 10) мәкаләсе, Әхмәт Тәмирнең «Тукай дәвере һәм Казан шагыйрьләре» (№ 3), «Габдулла Тукай» (№ 10), Надир Дәүләтнең «Казан төркләре вә Габдулла Тукай» (№ 3). Бу мәкаләләрдә Тукай иҗаты турында гына түгел, аның заманы, татар халкының язмышы, тарихы турында да сөйләнә, XX гасыр башы татар әдәбияты тарихы да карала. Тукайның әсәрләрен төрек теленә Наилә Бинарк һәм Надир Дәүләт тәрҗемә иткән, ә кайбер тәрҗемәләрнең авторлары күрсәтелмәгән. Наилә Бинарк шагыйрьнең «Таз» шигыреннән файдаланып балалар өчен интермедия дә язып бастырган, ул «Мәдрәсәдә булган хәл» дип исемләнгән.

Фатих Әмирханның вафат булуына 60 ел тулу уңае белән журналда аның тормышы һәм иҗаты турында Наилә Бинарк мәкаләсе һәм әдипнең «Шәрыкъ йоклый» хикәясе дә басыла. М. Гафуриның тууына 90 ел тулу мөнәсәбәте белән аның турында биографик очерк (авторы күрсәтелмәгән), һәм әдипнең «Хан мәчете» исемле шигыре дөнья күрә (№ 2), ә журналның 12 санында әдипнең икенче әсәре — «Ачлык пәйгамбәре» шигыре чыга.

Надир Дәүләтнең «Закир Рәми — 1859—1921» дигән мәкаләсе басыла (№ 4), мәкалә белән бергә әдипнең «Шагыйрьгә» дигән мәкаләсе төрек теленә тәрҗемә итеп урнаштырыла. Н. Дәүләт «Мирхәйдәр Фәйзи (1891—1928)» дигән мәкаләнең дә авторы (№ 4), аның тәрҗемәсендә язучының «Табигать мөназарасы» дигән шигыре дә басыла.

Журнал төрек телендә нәшер ителә. Анда басылган материалларның исеме биредә тәрҗемә итеп китерелә. Ә менә татар әдипләренең әсәрләре барысы да оригиналда да һәм төрек теленә дә тәрҗемә итеп янәшә урнаштырыла. Бу телен оныта башлаган милләттәшләребез өчен дә, татар теле белән кызыксынган төрек укучылары өчен дә эшләнгән.

Советлар Берлеге тиранлы дөмеккәч, илдә «җепшек» еллар башлангач, чит илләрдә дә «Казан утлары» журналына язылырга мөмкинлек туа башлый. «Казан» журналы совет чоры татар әдәбияты белән дә танышу мөмкинлегенә ирешә. Һәм менә шул вакытта «Казан» журналы битләрендә совет чоры татар әдипләренең әсәрләре дә басыла башлый. Дөресен әйткәндә, аларның барысы да — татар балалар әдәбияты әсәрләре. Журнал мондый әсәрләр арасыннан соцреализм калыпларыннан ераграк торган шигырь һәм мәзәкләрне сайлап алырга тырышкан. Алар барысы да «Балалар почмагы» исеме астында басылганнар. Журналда С. Хәкимнең «Казан арты» (№ 10), Гамил Афзалның «Китаплар язмышы» (№ 16), Шәүкәт Галиевнең «Хәзинә» (№ 14), Зәкия Туфайлованың «Ана сүзе» (№ 14), Мәхмүд Газизовның «Бармаклар» (№ 13), Зәки Нуриның «Ял көне» (№ 14), Вахит Монасыйповның «Салават күпере», «Кем белән кем» (№ 13),

«Төп-төгәл сәгать» (№ 14) әсәрләре бирелгән. Боларны төрек теленә Наилә Бинарк тәрҗемә итә.

Балалар әдәбиятында эшләмәгән совет чоры язучыларыннан бары Фәтхи Бурнашның гына «Тынлык авазы» шигыре басылган һәм аның вафатына 25 ел тулу белән Надир Дәүләтнең мәкаләсе дөнья күргән (№ 5).

1917 елдан соң Русиядә башланган тираниядән качып чит илләргә барып чыккан татар әдипләре дә каләмнәрен ташламаганнар, бирегә килеп икенче ватанын тапкан галим-голәмә дә әдәбият өлкәсендә каләмен тибрәтеп караган. Чит илләрдә дә язучылык белән актив шөгыльләнгән Гаяз Исхакыйның әсәрләре «Казан» битләрендә ике тапкыр дөнья күргән. Аның берсе — «Тәүбә иткән хатын хикәясе», ә икенчесе әдипнең сәяси карашларын чагылдырган фикерләр туплан-масы (№ 12). Ә аның тормышы, иҗаты турында журнал битләрендә шактый күп хезмәтләр дөнья күргән. Алар — кызы Сәгадәт Чагатайның «Атам Гаяз Исхакыйның соңгы көннәре», «Гаяз Исхакый турында хатирәләр», Наилә Бинаркның «Гаяз Исхакый Иделле» (№ 12), Хәсән Агайның «Гаяз Исхакыйның кыскача тәрҗемәи хәле», Әмрулла Агинең «Мөхәммәд Гаяз Исхакыйны искә алу» (№ 22) исемле хезмәтләр. Болар үзләренең документаль булуы белән дә әһәмиятле язмалар.

Өстә без Хәсән Габдүшнең исемен искә алган идек. Маньчжуриядә язучылык таланты ачылган бу зыялыга журналда шактый урын бирелгән. Журналда аның «Ерак Шәрык» (№ 5), «Уртак вөҗдан» (№ 2), «Пәрәмәч машинасы» (№ 9), «Тормыш юлы ыгы-зыгысында» (№ 13), «Милли төс», «Үзебез өчен» (№ 11) исемле хикәяләре басыла. Аның белән Маньчжуриядә еш аралашып яшәгән Мәхмүт Таһир һәм Мәдинә Сәлихмәтнең аның турында истәлекләре дә дөнья күргән (№ 11). 1901 елда Троицкида туган, 1917 елда Харбинга килеп чыккан, 1944 елда анда вафат булган бу талантлы әдибебез турында журналда Солтан псевдонимы астында Әхмәд Виргазның «Хөсәен Габдүшкә» дигән шигыре дә басыла. Бу кеше турында бездә мәгълүматлар юк, күрәсең, ул да Харбинда яшәгәндер. Х. Габдүшнең Г. Тукайга багышланган шигыре дә бар. Ул «Шагыйрьгә» исеме белән басылган (№ 3).

Кытайда татар әдәбияты дөньясына килеп кергән икенче әдип тә бар. Ул — Илдар Келәүле (1900—1970). Ул Рианоглу Келәүле, Илдар Келәүле, Илдар Шаһвәли исемнәре белән дә билгеле. Надир Дәүләт аның «Казан төрекләреннән» булуын, алты яшендә әнисе белән Кызылъярга килеп чыгуын, яшьтән ятим калуын, биредә мәдрәсәгә укырга керүен, 1918 елда Байкал ягына барып чыгуын яза (№ 1). Ул Чита, Хабаровск аркылы Кореягә килә, аннан Кытайның Шанхай шәһәрендә Кашшаф Сәлихмәт оештырган Казан төрекләренең «Мәдәният җәмгыяте»ндә эшли. Биредә татар телендә журнал басуны да оештыра. Соңыннан аны Мукденга, «Милли байрак» газетасына эшкә чакыралар. Аннан ул да Төркиягә барып чыга, Гаяз Исхакый белән якын аралаша. Илдар Келәүле журналист, җәмәгать эшлеклесе һәм шагыйрь дә. Аның да берничә шигыре «Казан» битләрендә дөнья күрә: «Милли кайгыдан» (№ 1), «Милләт сүзе» (№ 2), «Тукай эзеннән» (№ 3), «Байкал буенда» (№ 5), «Гүзәл Истанбул» (№ 7—8), «Яшь буынга» (№ 11), «Корбан бәйрәмендә» (№ 13).

1900 елда Казан арты Иске Әҗемдә туган, Төркиядә дөньякүләм атаклы галим булып танылган, төрек, инглиз, немец телләрендә китаплары дөнья күргән Рәшит Рәхмәти Арат та Төркиядә татар телендә шигырьләр язу белән мавыккан. Аның «Нинди нур», «Батыр егет» исемле шигырьләре «Казан» битләрендә басылган (№ 2). Шушы ук сүзне Ләбиб Каран (1887—1964) турында да әйтеп була. Ул һөнәре буенча табиб, университет укытучысы, җәмәгать эшлеклесе буларак билгеле. Өстә без аның «Сөембикә» исемле татар мәдәни җәмгыяте оештыруы турында искә алган идек. Ул Төркиядә яшәүче татарлар арасында татар тарихын, әдәбиятын пропагандалау, аларны милли рухта тәрбияләүгә, милли азатлык өчен көрәшкә әзерләүгә күп көч түгә. Төркиядә ул беренчеләрдән булып татар тарихы, фольклоры буенча татар телендә китаплар язып бастыруга да керешә. Аның медицина буенча чыккан китаплары да бар. Шул ук вакытта ул шигырьләр язу белән дә мавыга. Аның үзенең туган авылы турындагы «Каран авылы» (Казан артында), «Милләт нәрсә ул?» дигән шигырьләре дә «Казан» битләрендә (№ 20) урын таба. Журналда Идел-Дим дигән авторның аның турында «Доктор Әхмәү Ләбиб Каран: (5.I.1887—30.VII.1964): тууына 60 ел тулу мөнәсәбәте белән» дигән очеркы да басылган (№ 20).

Татар манкортлары өчен зур сәяси дивидендлар китергән «Советский Татарстан: Теория и практика ленинской национальной политики» дигән (Лондон, 1974. Рус телендә) китапның авторы, Алманиядәге югары уку йортларында

профессор булып эшләгән Тамурбәк Дәүләтшин дә, фән белән генә түгел, әдәбият өлкәсендә дә шөгыльләнгән. Аның «Кеше» исемле философик шигыре Өязибәк псевдонимы белән татар һәм төрек телләрендә «Казан»да дөнья күргән (№ 17).

Журналда Әсфәндияр Чинбай дигән авторның «Менә күренә авылым» (№ 13), «Чын батырлык» (№ 15) исемле очерклары, «Юлга», «Үрнәк» (№ 6), «Туган бер кеше» (№ 22) шигырьләре басылган. (Аларның исемен төгәл тәрҗемә итә алмадык). Аларда автор XX гасыр башы зыялылары, әдипләре турында, Себердәге татарлар, колхозлардагы хәлләр, халыкның авыр тормышы, дин әһелләрен эзәрлекләүләр турында уйлана. Алар үзләренең язылу рәвеше буенча нәсер жанрына тартым. Авторның язучы кеше булуы мөмкин.

Миңа бу фамилиянең очраганы бар иде. 1930 елда СССР халыклары үзәк нәшриятында чыккан «Ызансыз кырлар жыры» дигән жыентыкта Ә. Чинбаев дигән кешенең «Колхоз кызы» шигыре, 1929 елда Свердлауда чыккан «Урал бүләге» дигән жыентыкта «Обь суында» дигән шигыре, 1938 елда Оренбургта чыккан «Үсәбез» дигән жыентыкта шушы исем белән «Давыл алдыннан», «Ротфронт», «Сигнал жырлый» дигән шигырьләре басыла.

Күрсәтелгән очеркларыннан Ә. Чинбаев дигән кешенең Себер якларыннан икәнлеге күренә, бу аның шигырьләреннән дә заманында шул якларда дөнья күрүе белән раслана. Төркиягә барып чыккач ул инде Чинбай дигән исем белән яза башлаган. Без алда «И. Чинбай» исеме белән «Казан»да бер мәкалә басылуын күргән идек, анда аның исеме «Исфәндияр» дип күрсәтелгән иде. Бу «ике» кеше шул бер Әсфәндияр Чинбай булырга тиеш.

Минһаж (Исмәгыйли) исеме татар укучысына инде шактый таныш. Сугышта Чолганышта калып алманнарга әсирлеккә эләккән бу лирик җанлы мишәр озак еллар Германиядә яши, инженер булып эшли. Инде ул берничә мәртәбә туган якларына да кайтты, туган авылында үз акчасына мәчет тә төзеде. Аның аерым шигырьләре соңгы елларда татар матбугатында да басылды. Яшьтән үк милли мәктәптә белем алган бу зат та озак еллар чит илдә яшәсә дә, туган теленә, әдәбиятына, тарихына тугры калган, ул гына түгел, татар халкы ихтыяжларын кайгыртып мәкаләләр дә язган, шигырьләр дә иҗат иткән. Хәтта ул 1952 елда Мюнхенда татар телендә үзенең «Шигырьләр жыентыгы»н да бастыруга ирешкән. Аның шигырьләренең бер өлеше «Казан» битләрендә дә басыла. Алар «Казан» (№ 4), «Төрек дөньясы» (№ 6), «Ватанны сагыну», «Табынып идем» (№ 7—8), «Төркиләр тарихыннан» (№ 10), «Даһи Тукайны искә алу» (№ 22), «Фатыймага хат» (№ 16). Ул узган ел вафат булды.

Хәзерге көндә АКШта, Сан-Франциско да яшәүче Нәркиз ханым Дәүеш-Гейлингның «Әнием ә бүләк» (№ 16), «Тукайга хөрмәтләр белән» (№ 18) әсәрләре журналда урын алган.

«Мисыр пирамидаларына», «Кыр казларына сокланып» исемле шигырьләр (№ 15) дә журналда урын алган. Аларның авторы да хәзер АКШта яши. Ул — Әхмәт Гәрәй, төрки-татар, Үзбәкстанда туган, алманнарга әсирлеккә эләккән, аннан Италия, гарәп илләренә барып чыккан, Төркиягә килгән, тора-бара океан артына күчеп киткән.

«Казан» журналының беренче санында «Даһига» исемле мәкалә бар. Аның авторы — Заһидә Таһир. Ул 1907 елда Пенза губернасының Будгал авылында туган, Маньчжуриягә килеп чыккач, анда укытучы булып эшләгән. Төркиядә аның шигырьләре «Милли байрак» вә башка басмаларда да дөнья күрә. Төркиягә килгәч Казан төрекләре жәмгыятендә эшли, яшьләр өчен кичәләр оештыруда актив катнаша, шигырьләр язуын да дәвам итә. Аның икенче шигыре «Уйларым» исеме белән журналның икенче санында дөнья күрә.

Чит илләргә барып чыккан төрки-татарлар арасыннан шагыйрьләр генә түгел, шагыйрәләр дә үсеп чыкканлыгын күрәбез. Шундыйлар арасында Сания Гыйффәт Уган (1899—1957) да бар. Аның «Углымның жыры», «Яшьләргә», «Сагынганда» исемле шигырьләре «Казан»да дөнья күрә (№ 20). Аның турында шул ук журналда Наилә Бинаркның мәкаләсе дә басылып чыга (№ 20). Сания ханым Чистай шәһәрендә туган, Иж-Буби мәдрәсәсендә белем алган, яшьтән үк әдәбиятка гашыйк бу кыз шигырьләр яза башлаган, аларның кайберләре «Сибирия», «Ил» газеталарында, соңыннан Гаяз Исхакыйның чит илләрдә чыгарган «Милли байрак», «Яңа милли юл» газета, журналларында басылып торган. 1931 елда ул Финляндиягә килә. Аерым әсәрләренең Финляндиядә, Эстониядә, Румыниядә дә басылуы билгеле. Берничә пьеса авторы да. Вафаты — Анкарада.

Чит илләрдә яшәгән, «Казан» журналында әсәрләре югарыда искә алынган әдипләр турында азмы-күпме мәгълүматлар билгеле. Ә менә берничә шагыйрә, шагыйрь турында «Казан» журналында мәгълүматлар күренми. Аларның

«Казан»да басылган әсәрләрен һәм үз исемнәрен атап үтик. Бу «Казанлы кардәшләр» (№ 1), «Нисан янгыр» (№ 7—8), «Абдулкадыйр Инан» (№ 19) шигырьләренең авторы Сания Ишекәй; «Балта сабы» (№ 9), «Гаепсезләр зары» (№ 13), «Яшь үсмер» (№ 15)нең авторы И. Ишгай; «Анама», «Билгесез кабер» (№ 7—8) авторы Ш. Нигъмәти.

Надир Дәүләт бу шигырьләрнең авторларының барысы да Казан төрекләре булуын әйтте.

Болардан тыш журналда Камалетдин Юлдашның «Милли телдә» исемле (№ 2) шигыре басылган. Ул шигырь заманында Казанда чыга торган «Йолдыз» да дөнья күргән була. Газетадан алынып бу шигырь революциягә хәтле Казанда берадәран Кәримовлар чыгарган «Милли тавышлар яки моңлы шигырьләр» дигән җыентыкка да кертелгән була.

Аннан бер өзек:

Сискәнеп китте татарлар эшләре һич уңмагач,
Кычкырдылар: «Без ничек яшик газиз тел булмагач?»
Барчасы тоткан каләм, аһ-ваһ белән әзли сине,
ач никабың (пәрдә, битлеген — Ә. К.) әй, мөнәввәр (нурландыручы — Ә. К.) тел, күрикче без сине.

Журналның 19 санында заманында әдәбият юлында каләм сынап караган, татар халкының азатлыгы өчен көрәшчегә әйләнгән, соңыннан Төркиягә килеп күренекле җәмәгать эшлеклесе, галим, профессор булган Садри Максуди турында аның кызы Айдалы (Адилә Айда)ның «Садри Максудиның «Мәгыйшәт хикәясе» дигән мәкаләсе басылган.

Матур әдәбият һәм әдәбият тарихына караган материаллар өстә күрсәтелгәннәр белән чикләнә. Әдипләрнең төрек теленә тәрҗемә ителгән әсәрләренең тәрҗемәчеләре барысында да күрсәтелми. Аларның тәрҗемә авторлары — редколлегия әгъзалары Надир Дәүләт, Наилә Бинарк, әдипләр турында чыккан һәм авторлары күрсәтелмәгән мәкаләләрнең авторлары Надир Дәүләт, Мәхмүт Таһир булырга тиеш. Бу турыда мин аларның үзләреннән ишеткәнем бар.

«Казан» журналының татар әдәбиятын пропагандалавы нихәтле әһәмиятле булуы турында күп сөйләргә мөмкин. Ләкин бу безне икенче якка алып керәчәк, ә максатыбыз исә журналда басылган материалларның тематикасы, диапазоны белән генә таныштыру. Киләчәктә «Казан» журналының татар әдәбияты тарихындагы роле махсус өйрәнелер дип ышанасы килә.

Татар әдипләре иҗаты белән таныштырудан тыш журнал әдәбиятыбыз тарихы турында да материаллар бастыргалаган. Алар арасында аерата әһәмиятлесе итеп, беренче буларак мин Г. Баттал-Таймасның «Яңа Казан төрек әдәбияты» дигән зур мәкаләсен (№ 21) күрсәтер идем. Анда урыс инкилабы һәм аннан соңгы чорда татар әдәбиятының үткәне турында шактый тулы мәгълүмат бирелә. Мәкаләдә Каюм Насыйри, Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев, Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхретдин, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Галиәсгар Камал, Фатыйх Кәрими, Сәгыйт Рәмиев, Дәрдемәнд, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди, Габдулла Тукай, Кәрим Тинчурин, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Габдрахман Сәгъди, Фәтхи Бурнаш, Нәкый Исәнбәтләрнең татар мәдәниятында тоткан урыны, иҗаты, әдәбиятыбыздагы роленә җентекле анализ ясала. Г. Баттал-Таймасның бу хезмәте соңыннан Франциядә чыккан «Фундамента Тюркика» җыентыгында да басыла.

Профессор Әхмәт Тәмирнең «Казан вә шимали төрекләренең иске әдәбияты» дигән мәкаләсендә Болгар, Хазар, Кыпчак, Алтын Урда, Хорезм, Казан ханлыгы чорларында, төбәкләрдәге төрки-татар әдәбиятларны ачыклауга, анда искә алынган әдипләрнең аерым төрки халыклар мәдәниятында тоткан урынын билгеләүгә багышланган (№ 4). Ә аның икенче хезмәте беренче хезмәтнең дәвамы рәвешендә шул чор төрки-татар әдәбияты чыганакларына багышланган (№ 5). Әдәбиятыбыз тарихы буенча чыккан бу хезмәтләрнең тагын бер әһәмияте шунда — алар әдәбиятыбыз тарихына караган, төрле илләрдә, төрле телләрдә дөнья күргән басмаларның библиографиясе белән дә баетылган. Бу хезмәтләрдә татар әдәбиятының үсешендә зур роль уйнаган татар басма сүзе тарихына да югары бәя бирелгән.

Журналда фольклор буенча материаллар күп түгел. Журнал битләрендә «Акыллы килен», «Агай казны ничек бүлгән», «Зирәк карт», «Өч кыз» (№№ 1, 7—8, 15) кебек әкиятләр, «Салават бәете» (№ 9), «Сак-сок бәете» (№ 1), «Алыпның тормышы һәм Болгар шәһәренең салынуы» (№ 1), «Хан кызының торгынлык авыруыннан терелүе» (№ 7—8) кебек бәет һәм легендалар, ноталар белән

халык җырлары (№№ 1, 2, 7—8, 9) басылган. Басылган җырларның исемнәрен санап үтик: «Япанчылар җыры», «Тәфтиләү», «Бишек җыры», «Умырзая», «Ямьле Агыйдел буйлары», «И анам, бик сагынам», «Галиябану», «Әпипә»...

## Тел белеме

Тел белеме буенча журналда берничә мәкалә басыла. Без бу материалларны санап үтү белән генә чикләнәбез. Аларның өчесе «татар» һәм «башкорт» этнонимнарының этимологиясе турында: Тәмир Әхмәт. «Татар» сүзенең мәгънәсе хакында. (№ 3). «Башкорт» сүзенең мәгънәсе хакында легендалар. (№ 9), Таһир Мәхмүт. Төрле телләрдә «татар» исеме астында нинди халыкны атыйлар. (№ 20).

Ике мәкалә «Дивану логать әт-төрки»гә карый: «Дивану логать әт-төрки» вә Кашгарлы Мәхмүд (№ 6). Билге Килисли Рифат. «Дивану логать әт-төрки» Әмре әфәнде. (№ 6).

Боларга Надир Дәүләтнең «Хәрефләребез хакында ачыклама» (№ 1) дигән язмасын өсти алабыз. Анда латин графикасында басылачак «Казан» журналында төрки-татарларга хас авазларны ничек бирү, ничек язу турында аңлатма бар.

Төрки-татар халкының исеменә караган фикерләр милләтебезнең тарихы буенча басылган хезмәтләрдә дә еш очрый. Милләтебезнең «татар» дип йөртелә башлавы аркасында тарихыбызга багышланган күп хезмәтләрдә «татар»ны «монгол» белән бутаудан килеп чыга торган буталышларны һәр автор аңлатып үтәргә мәҗбүр була.

## Сәнгать

Кайда әдәбият — шунда сәнгать, алар бер-берсеннән аерым яши, үсә, камилләшә алмый. Төркиягә Ерак Көнчыгыштан, Финляндиядән Гаяз Исхакый тәрбиясе үткән «Идел-Урал»чылар килү Төркиядәге төрки-татарларның әдәби тормышына гына түгел, аларның мәдәни, сәнгати тормышына да шактый зур үзгәрешләр кертә. Анкара, Истанбул кебек төрки-татарлар яшәгән шәһәрләрдә яшьләр клублары ачыла, төрле музыкаль, әдәби кичәләр оештырыла башлый, үзешчән театр булдыруга да керешәләр. Балалар өчен музыка кичәләре оештыру да гадәткә кереп китә. Төрле бәйрәмнәр уңае белән тантаналар үткәрелә башлый. «Казан» журналының беренче саныннан башлап Төркиядәге татарларның мәдәни, сәнгати, мәгариф, икътисади тормышы турында хәбәрләр басылып килә. Нинди очрашулар, нинди әдәби-музыкаль кичәләр булу, яшьләр клубының планнары турында журнал битләрендә мәгълүматлар басылып тора. «Хроникаль хәбәрләр», «Истанбул хәбәрләре», «Анкара хәбәрләре» исеме белән төрле кичәләр, очрашулар турында информацияләр белән беррәттән, төрки-татарлар арасында туйлар, өйләнүләр, үлем-китем, Төркиягә килгән яки башка илләргә күчеп китүче төрки-татарлар турында хәбәрләр басылып тора. Төркиядәге төрки-татарлар тормышындагы яңалыклар, бүләкләнүчеләр, танылган кешеләр турында хәбәрләр күренә. Ничек җанлана башлануын аңлату мөмкин түгел. Бу үзгәрешләр «Казан» журналы битләрендә басылган материалларда да чагылыш тапкан.

Журналда Наилә Бинаркның «Казан уеннарында кулларның торышы» (№ 16, 18) исемле мәкаләсе басыла. Ул татар балетмейстеры Гай Таһирның 1960 елда Казанда чыккан «Татар биюләре» китабы буенча язылган. Шушы ук авторның «Казан халык уеннарында кыз вә хатыннарның киемнәре» (№ 14), «Казан уеннарында ирләр киемнәре» (№ 15) дигән күләмле мәкаләләре басыла. Күрәсең, алар Төркиядәге Казан төрек яшьләре үзешчәннәре өчен кулланма буларак басылганнар. Мөхтәсиб Рифатның «Казан татарларында кичке җыелулар» (Аулак өйләр) дигән мәкаләсе (№ 2) дә юкка гына басылмаган. Берничә хезмәт татар театры тарихына һәм аның артистларына багышланган: Таһир Мәхмүтнең — «Габдулла Кариев» (№ 1), Таһир Мәхмүт — «Казан театрлары хакында: театр уйнаучылары һәм караучылары» (№№ 14, 15). Ә. В. Маңгәрнең дә татар театры турында мәкаләсе-истәлеге басылуын искә төшерик. Алар икесе дә театрга гашыйк кешеләр булганнар, ахры. Таһир Мәхмүтнең Харбин, Хайлар, Мукдендагы төрки-татар театрлары турындагы «Русия тышындагы казанлыларның театр эшчәнлеге» (№ 21) исемле мәкаләсе дә шуны раслый.

Идел буе төрки-татарлар музыкасына карата ике мәкалә басылган. Берсе Таһир Мәхмүт белән Надир Дәүләт тарафыннан язылган «Казан төрекләрендә музыка» (№ 7—8), икенчесе — Мурат Бардакчының шул ук исемдәге хезмәте (№ 14). Һөнәрчелек сәнгате буенча Рәшит Латинның «Казан төрекләрендә көмешчелек сәнгате» (№ 7—8), Динә Вәлиеваның «Болгар сәнгате сәхифәләреннән» (№ 21) дигән 1977 елда «Казан утлары»нда басылган хезмәте. Аны төрек теленә Шамил Алукай тәрҗемә иткән.

Сәнгатькә караган тагын ике материал басылган. Аның берсе татар үзешчәннәренең Мәскәүдәге кичәләре турында (№ 6), ә икенчесе Кырым татарлары үзешчәннәренең Төркиядәге гастрольләре турында. Бу информациянең беренчесе 1972 елда АКШта чыккан «San Francisko Chronicle, 37 № 4. Tines Service» журналыннан алынган. Саидә Арсланбәкнең «Сәнгать хәбәрләре» журналының 19, 21 санында дөнья күргән.

## Тарих буенча хезмәтләр

«Казан» журналы тарих буенча хезмәтләргә күп игътибар биргән. Аларның абсолют күпчелеге төрки-татарлар тарихына карый. Берничә хезмәт гомум төрки халыклар тарихына багышланган. Төркия тарихы буенча да берничә материал басылган. Бу материалларны без аерым бүлекләргә туплап, библиографик тасвирлама юлы белән бирүне уңайлырак дип саныйбыз.

## Берничә төрки халык тарихына караган материаллар

**1.** Курат Әкъдәс Нигмәт. Малазгирт Зәфери язмалары буенча Идел буе вә Кара диңгезнең төньягында төрек кавемнәр (№ 7—8). (М. Зәфери — XI гасыр кешесе).

**2.** Курат Әкъдәс Нигмәт. 1917 ел февраль революциясе вә Русия төрекләре. (№ 14).

**3.** Бинарк Наилә. Төректә (төркиләрдә) хатын-кыз һәм ана. (№ 16).

## Төрки-татарлар тарихына караган материаллар

**4.** Таһир Мәхмүт. Матди культурабыз. Акчалар. Үлчәү берәмлекләре. Авырлык үлчәүләре. Сыеклык үлчәүләре. Мәйдан үлчәүләре. Башка үлчәмнәр (№ 5).

**5.** Каратаев М. Татарлар хакында кайбер фикерләр. (№ 6). АКШтагы «Новое русское слово» (1971, 25 июль) газетасыннан тәрҗемә.

**6.** Бөек Болгар дәүләте вә аның тарихы. (№ 7—8).

**7.** Баттал-Таймас Г. Казанның басып алынуы: 420 ел тулу уңае белән (№ 9).

**8.** Таһир Мәхмүт. Идел буенда ислам дине. (№ 9).

**9.** Мишәрләр. (№ 10).

**10.** Дәүләт Надир. Советлар Берлеге эчендә татар-башкортлар. (№ 10).

**11.** Тарихның мәшһүр төрек хатын кызларыннан Казан падишасы Сөен Бикә. (№ 11).

**12.** Таһир Мәхмүт. Мәһкаме-и шәргыя вә мөфтиләребез. (№ 13).

**13.** Дәүләт Надир. Советлар берлегенең халыклары вә татарларның хәле. (№ 13).

**14.** Тәмир Әхмәт. Типтәрләр. (№ 13).

**15.** Сакмар А. М. Казан тарихыннан яфраклар. (№ 15).

**16.** Казан төрекләре белән бер очрашу. (№ 16).

**17.** Милли хаятебез: Гаилә вә кардәшлек. (№ 16).

**18.** Максуди Садри Арсал. Соңгы дәрес сабаклары. (№ 19). — Милләтебез язмышы турында уйланулар.

**19.** Халиков Альфред. Казан шәһәре кайсы заманда мәйданга килгән? (№ 19). — «Татарстан коммунисты» (1974, № 19). А. Халиков, В. Иванов, И. Ионенко мәкаләсе. Төрек теленә Шамил Алукай тәрҗемә иткән.

**20.** Патша Русиясе вә Совет режимының руслаштыру политикасы (№ 20).

**21.** Кошай Хәмит Зәбәер. Идел-Уралдагы төрекләрнең килеп чыгышы хакында. (№ 20).

**22.** Бинарк Наилә. Казан төрекләренең үткәне һәм бүгенге. (№ 22).

**23.** Максуди Садри Арсал. Мөхмәр Казан төрек дәүләтенең конституциясе. (№№ 22, 23).— Милли идарә рәисе Садри Максуди кул куйган, «Мөхтәрият» журналының 1918 ел 5 февралендә басылган. Шуннан тәрҗемә.

**24.** Бинарк Наилә. Казан ханлыгы. (№ 23).

**25.** Таһир Мәхмүт. Казан төрекләрендә таһсил (мәгариф, уку — Ә. К.) вә белем. (№ 1).

**26.** Таһир Мәхмүт. Казан төрекләрендә тәхсил-белем. (№ 9).

**27.** Таһир Мәхмүт. Казан төрекләрендә тәхсил-белем: Ысулы җәдидилек хәрәкәте, ысулы җәдид мәдрәсә: мәктәпләр (№ 2).

**28.** Таһир Мәхмүт. Казан төрекләрендә тәхсил-белем: 1. Мәдрәсәи «Хөсәения». (№ 3). Кәм инде өстә искә алынган:

**29.** Мәһгәр Әхмәт Вәлинең «Буби Мәдрәсәсе вә Буби кардәшләр»е. (№ 3). Журналда Идел-Урал буе төркиләренең мөстәкыйльлек өчен көрәшенә багышланган бер мәкалә басыла. Аның авторы — Аучыоглы Доган дигән төрек галиме. Аның бу мәкаләсен «Туранчылык күренешен Русия төрекләре китерде» дип тәрҗемә итәргә мөмкин. Бу мәкалә Төркиянең «Җөмһүрият» газетасында 1977 елның 14 декабрендә басылган була. Ул «Казанның 21 санында кабат басыла. Мәкаләдә Идел, Урал, Себер татарларының милли-мәдәни мөхтәрият төзү алып барган көрәше турында шактый киң мәгълүмат китерелә, аның лидерларының эшчәнлеге яктыртыла. Бу хәрәкәтнең лидеры Садри Максуди эшчәнлегенә югары бәя бирелә, бу мәсьәлә буенча Гаяз Исхакый, Зәки Вәлидиләрнең позицияләренә дә тукталына. Шушы мәкалә унаеннан Садри Максудиның кызы Адилә Айда шул ук газетаның 1977 ел 30 декабрь санында «Төрекләрнең тарихын язучы өчен бер ачыклама» дигән мәкаләсе басыла. Мәкаләдә Адилә Аида Доган Аучыоглының кайбер бәяләре белән килешмәвен яза. Бу мәкалә дә «Казан» журналында төрек тарихчысының мәкаләсе белән бергә китерелә.

## Төрки-татар диаспоралары тормышыннан

### *Берничә илдәгеләре турында*

**30.** Дәүләт Надир. Башлады. (№ 1).— Дөньяда татар диаспорасы һәм «Казан» журналы чыгаруның максаты.

**31.** Таһир Мәхмүт. Русия тышында Казан төрекләре. (№№ 1, 2).

**32.** Мөхтәлиф хәбәрләр. (№ 2).— Европа, АКШ, Азия илләре уку йортларында белем алучы төрки-татар яшьләре.

**33.** Таһир Мәхмүт. Ерак шәрыкта дини-милли җәмгыятьләребез. (№ 14).

**34.** Дәүләт Надир. Советлар берлеге вә Чин халык җөмһүриятендә төрекләр. (№ 17).

### *Австралиядә*

**35.** Мансур Рәшит. Австралиядәге татарлар тормышыннан. (№ 14).

**36.** Мансур Рәшит. Австралиядәге Казан төрекләре. (№ 20).

### *Америка Кушма Штатларында*

**37.** Пластинкаларда милли җырлар. (№№ 5, 6).

**38.** Аги Әмрулла. Милли җырларыбызның онытылмас бер кичәсе. (№ 10). АКШ төрки-татар яшьләренең Төркиядәге концертлары.

**39.** Америка хәбәрләре. 8 яшьлек яшь художник Наилә Бадайның уңышлары, Президент Никсон кызы Юлия белән дуслыгы. Әнвәр Одан — Анкарада университет тәмамлап АКШта Бруклин университетында докторлык диссертациясе яклаган, Нью-Йоркта эшләүче күренекле архитектор. «Американ Төрек-Татар дини вә Культур җәмгыяте» чыгара торган «Бюллетень»нән өзекләр.

**40.** Сан-Франциско вә Бурленгамнан хәбәрләр. (№№ 12, 13, 15, 16).

**41.** Америка берләшкән дәүләтләрнең Нью-Йорк шәһәрендәге бер талибыбызның (Шамил Юлай) уңышлары. (№ 17).

**42.** Америка берләшкән дәүләтләрнең хәбәрләре. (№№ 17, 18).

**43.** Апакай Шәмсия. Мин Казанда: (АКШта яшәүче ханымның Казанга килүе һәм тәэсирләре).— (№ 17).

**44.** Апакай Шәмсия. Казан хатирәләрем. (№ 21).

**45.** Таһир Мәхмүт. «Мең ел җәми». (Харбиндагы Төрек-татарларның дини вә милли җәмгыяте).
**46.** Таһир Мәхмүт. Харбиндагы төрек-татарларның дини вә милли җәмгыяте. (№ 7—8).
**47.** Акчура Иниятулла. Мукден шәһәрендәге татарларның дини вә милли җәмгыяте. (№ 7—8).
**48.** Таһир Мәхмүт. Пограничныйдагы төрек-татарларның дини вә милли җәмгыяте. (№ 9).
**49.** Таһир Мәхмүт. Көнчыгыш Кытай тимер юлы буенда яшәгән татар-лар«казанлылар. (№ 10).
**50.** Таһир Мәхмүт. Хайлардагы төрек-татарларның дини вә милли җәмгыяте. (№ 11).
**51.** Таһир Мәхмүт. Маньчжурия шәһәрендә төрек-татар җәмгыяте. (№ 16).
**52.** Таһир Мәхмүт. Чан-Чун (Цинь«Цзянь) төрек-татар җәмгыяте. (№ 18).
**53.** Бадай Ибраһим. Ибраһим Бадайның Харбин хатирәләре. (№ 18).
**54.** Таһир Мәхмүт. Һун һул Дидә төрек-татар җәмгыяте.— Ил-Дуга җәмгыяте.— Шанхай шәһәрендәге төрек-татар җәмгыяте.— Тензин төрек-татар җәмгыяте. (№ 22).

## Төркиядә татар диаспорасы тормышы һәм тарихы

Истанбулдагы төрки-татар тормышыннан хәбәрләр «Истанбул хәбәрләре» исеме белән журналның 12—22 саннарында басылган. Тик 17 санда басылган информациянең авторы күрсәтелмәгән, ә калганнарының барсының да авторы Әмрулла Аги.

Төрки-татарларның Анкарадагы тормышлары турында «Анкара хәбәрләре» исеме белән дә информацияләр басылып тора. Алар журналның 12, 14, 15, 16, 17, 18, 20, 21 саннарында басылган. Авторлары күрсәтелмәгән, редакция әгъзалары тарафыннан хәзерләнгән булырга тиеш.

Төркиянең аерым шәһәрләрендәге татарларның әдәби, мәдәни тормышына багышланган гомуми характердагы бер мәкалә дә чыга. Ул «Журнал хәбәрләре» исеме белән 2 санда дөнья күрә.

Өстә искә алынган «Мөхтәлиф хәбәрләр» журналның 1, 4, 5, 6, 7—8, 9, 10, 11, 13, 14, 19 саннарында басыла. Аның тик 10, 11 саннарында басылганы гына «Төркиядән мөхтәлиф хәбәрләр» дип атала, калганнары Төркиядәге генә түгел, башка илләрдәге татарлар тормышына да карый. Болары да редакцион материаллар, авторлары күрсәтелмәгән.

Әмрулла Агинең «Казан төрекләренең культура һәм ярдәмләшмә оешмасының яңа бинасы асылыш истәлеге» (№ 22), Таһир Мәхмүтнең «Анкара Казан культура һәм ярдәмләшмә журналының яңа бинасы» (№ 16) дигән мәкаләләре дә Төркиядәге төрки-татар диаспорасы турында.

Журналда Казан төрки-татарларының Төркиягә күченү һәм андагы тормышы турында дүрт фәнни тикшеренү басылган. Алар түбәндәгеләр:

**1.** Дәүләт Надир. Төркиядә Казан төрекләренең кемнәр икәнен белдерү ничек тора (№ 2).
**2.** Таһир Мәхмүт һәм Дәүләт Надир. Төркиядә яшәүче казанлыларның социаль фагыйльләтләре статистикасына бер караш (№ 6).
**3.** Дәүләт Надир. Төркиядә казанлылар. (№ 15).
**4.** Гөләйөз Хәйретдин. Казан татарларының таралуы вә күченешләре (№ 22).

Төркиядә төрки-татарларның тормышы өстә искә алынган материаллар белән генә чикләнми. Журналның һәр санында диярлек бер генә җөмлә яки бер генә абзац белән бирелгән мәгълүматлар да очрый. Аларның исемнәре юк. Андагы хәбәрләрне санап үтсәң, бу зур урын сорар иде.

## Финляндиядә

Журналның 4 һәм 7, 8 саннарында Финляндиядә яшәүче төрки татарлар үзләренең мәктәп-мәдрәсәләренә укытучылар эзләп игъланнар бастыралар. Калган мәкаләләрдә Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең тормышы турында шактый киң мәгълүматлар китерелә.

1. Бинарк Наилә. Финляндия төрекләре тарафыннан шәһәр бәйрәме мөнәсәбәте илә 21.XI.1971 тарихында Хельсинкида үткәрелгән балалар көне. (№ 6).
2. Акай Садия. Финляндия төрекләре кардәшлеге. Шигырь. (№ 10).
3. Финляндиядән кыска хәбәрләр. (№ 10).
4. Финляндия хәбәрләре. (№№ 16, 17, 18, 20).
5. Сафиулла Абделхак. Финляндиядә Ярвенпаэ шәһәрендәге культура бәйрәме. (№ 12).
6. Сафиулла Абделхак. Ярвенпаэ җәмгыяте. (№ 14).
7. Бинарк Наилә. Финляндиядә оештырылган җәмгыятьләр. (№ 15).
8. Мольерның «Жимри» (Саран — Ә. К.) комедиясе: Финляндиядә төрекчә уйныйлар. (№ 17).
9. Бинарк Наилә. Финляндия вә фин-төрек мөнәсәбәтләре. (№ 20).

## Төркия тарихына караган материаллар

Төркиядә чыккан журнал буларак ул Төркия тарихы турында дәшми үтә алмаган. Мондый материаллар саны нибары ундүрт кенә. Аларның да күпчелеге Төркия җөмһүрияте юбилейларына багышлап басылган хезмәтләр, Төркиянең гимны, маршлары. Төркиядәге төрки-татарлар төрек телендә белем алганнар, төрек телен яхшы үзләштергәннәр, Төркия тарихын мәктәпләрдә дә үткәннәр, әдәбият буенча да белгәннәр. Шуңа күрә «Казан» журналы үзенең битләрендә Төркия тарихын киң планда яктыртуны кирәк дип санамаган. Бу яхшы аңлашыла. Төркия тарихына карата нинди материаллар басылуы белән танышыйк:

1. Бинарк Наилә. Мәхмәт Акиф Эросой вә истикълал (мөстәкыйльлек) Маршы (50 ел тулу мөнәсәбәте белән). (№ 3).
2. Эрсой Мәхмәт. Истикълал маршы (текст). (№ 3).
3. Бинарк Наилә. Шанлы төрек җиңүе — Малазгирт мәйданындагы сугышка 900 ел тулу белән: 1971, 26 август. (№ 4).
4. Инан Абдулкадыйр. Ататөрек һәм тыш төрекләр. (№ 5).
5. Арсланоглу Җәмәндәр. Төркиләрдә һавачылык тарихында төрекләр (№ 7—8).
6. Җөмһүриятнең илленче елы вә Ататөрекнең бөек идеалы. (№ 10).
7. Чамлебил Фарук Нафиз һәм Чаглар Бәһчәт Кемал. Унынчы ел маршы. Җамал Рәшит Бәй музыкасы. (№ 5).
8. Эрдоган бәкир Ситкы. Илленче ел маршы. (№ 5).
9. Җөмһүриятнең 50 еллыгына котлау (№ 5). Журналда авторы «Н. Б.» дип кенә куелган.
10. Арсланбәк Саидә. Җөмһүриятебезнең 50 еллыгы мөнәсәбәте белән үткәрелгән мөһим конференцияләр. (№ 5).
11. Бинарк Наилә. Кече Ватан Кибрис. (№ 12).
12. Икенче төрек пресс-конференциясенең алтынчы комиссиясендә (халык, мәдәният вә дәүләт конференциясе) тәкъдим ителгән проектлар. (Кабул ителделәр). (№ 15).
13. Төркиянең премьер-министры Демирел Хельсинкида Казан төрекләре илә җомга намазына килде. (№ 16).
14. Максуди Садри Арсал. Бер урыс партия конгрессында Босфор мәсьәләсе. (№ 19).

## Кырым ханлыгы

Бу бүлеккә без Кырым ханлыгы тарихына турыдан-туры багышланмаган бер материалны кертәбез. Ул Тансәл Фәүзиянең «Кырым ханы IV нче Мәхмүд Гәрәйнең күңелләрне тетрәтә торган бер шигыре» (№ 7—8) дип атала. Автор шагыйрь-ханның әсәрен Кырым ханлыгы тарихына бәйләп карый, шуңа күрә аны тарихка караган хезмәт дип тә санап була.

## Алтын Урда

Бу темага ике мәкалә басылган. Аның берсе профессор Әхмәт Тәмирнең «Түрк-монгол империаторлыгы дәверендә социал вә гаскәри тәшкилат» (№ 7—8). Күләмле бу хезмәт Чыңгыз хан, монголлар империясе тарафын-

нан басып алынган территорияләр һәм андагы халыклар язмышы, «төрк» исеменең ничек итеп «татар»га әйләндерелүе, шушы «татар» исеме астында башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, уйгур, карачай, балкар, әзериләр һәм башкаларның саналуы һәм монын Идел буе төрки-татарларнын тарихын бозып күрсәтүгә юл ачуына да туктала. Бу мәкаләне бездә басып чыгару хәзерге көндә татар тарихы буенча күренә башлаган шалтыравык «концепцияләр»нең чын йөзен ачарга ярдәм итәр иде.

Икенче мәкалә «Алтын Урда каганлыгы» дип атала, авторы — Наилә Бинарк (№ 23). Алтын Урдага биргән бәясе һәм аның Идел-Урал болгарларына мөнәсәбәте белән ул да, нигездә, Әхмәт Тәмир мәкаләсе белән тәңгәл дияргә була.

Әлбәттә, «Казан» журналының эчтәлеге әле моның белән генә чикләнми. Анда шактый күп санда рецензияләр дә басыла, татарның күренекле шәхесләре турында байтак кына язмалар да дөнья күрә. Ләкин алар хакында сүз алып бару өчен инде аерым бер мәкалә сорала.

# ПОЛЬША-ЛИТВА ТАТАРЛАРЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН

XV гасыр урталарыннан башлап Аурупа үзәгендә польша-литва татарлары дигән этник төркем формалаша башлый. Чыгышлары белән алар нигездә Алтын Урдадан булсалар да, бу кысага гына кереп бикләнү дөреслеккә хилафлык китерү булыр иде. Чөнки бу этник төркем арасында Төньяк Кавказ, Дагъстан, Идел буе халыклары вәкилләре дә була. Кайбер күченеп килүчеләрнең чирмешләр — марилар икәнлеге дә тарихи документлар белән раслана. Әйтик, Белоруссиядә яшәүче татарларның тамырлары дагъстаннарга, Вильнюстагыларнын — кыпчакларга, Бутурлюнистларының нугайларга барып тоташа. Бүгенге көндә Польша, Литва, Беларусь җирләрендә яшәүче бу этник төркемнәр, ана телен, милли мәдәният һәм гореф-гадәтләрен онытуга, хәтта төрле диндә булуларына да карамастан, үзләренең аңнарында тумыштан татар халкына нисбәтле икәнлекләрен горурланып саклап киләләр. Аларның милли-иҗтимагый аң үсеше инкыйлап алды елларында, аеруча инкыйлаптан соң сизелерлек булды һәм карашлары бабаларының туган җирләренә — Казанга, Кырымга, Кавказга табан төбәлде. Шулай икән, 1918 елда Кырым Республикасының беренче премьер-министры итеп 16 мөселман корпусының элеккеге яу башы булган польша-литва татары генерал Мацей Сулкевичның сайланып куелуы бер дә гаҗәп тоелмаска мөмкиндер, мөгаен. Кырым парламентында — Милли фиркадә да польша-литва татарлары күпчелекне тәшкил итте. Шул җөмләдән, Якуб Богданович Симферополь шәһәрендә татар гимназиясенең директоры булып тора. Егерменче елларда ул, Казанга килеп, медицина институтында да укыта. Тик гомере генә вактысыз өзелә, большевиклар аның дворян-морзалар нәселеннән булуын кичерә алмыйлар һәм ул 1937 ел мәхшәрендә юк ителә.

Шунсын да искәртеп үтик, Рәсәйнең үзәгендә барган милли-азатлык хәрәкәте гомумән бик тә үзенчәлекле төсмерләргә ия һәм польша-литва татарлары биредә дә зур активлык күрсәтәләр. Әйтик, утсыз төтен булмаган кебек, Татарстан республикасын торгызу өчен көрәш барган көннәрдә генерал Сулкевичның Идел буе кан кардәшләренә ярдәмгә ашкынуы турындагы риваять юктан гына тумагандыр. Полковник Адам Байрашевич исә бөтенроссия Мөселман Хәрби Шурасының хакыйкый әгъзасы итеп сайлана. Сөләйман Ловчицкий, Гайшә Раецкаю һәм Разия Богдановичлар да Шурада эшлиләр. Искәндәр Тальковский I Идел буе

татар укчылар бригадасы командиры булып хезмәт итә. Соңыннан Татарстан өлкә башкарма комитеты исемендәге татар-башкорт хәрби мәктәбе белән житәкчелек итә. 1941 елда, Кырым дивизиясе командиры булып хезмәт иткән чорында, хаксызга репрессияләнә. Аның әтисе дә Рәсәй армиясендә генерал-майор дәрәжәсенә күтәрелгән хәрби була. Тальковскийның туганы Зинаида ханым, ире Якуб гаиләсендәгечә әйтсәк, Зөләйха Апакаева, икенче шәһәр шифаханәсендә акушер-табип булып эшли. Аларның да гомерләре фажигале төстә киселә: Якубны НКВД органнары 1937 елны аталар, Зинаида Тальковская исә 1942 елда үлә. Алар турындагы якты хатирәләр Апакаевлар гаиләсендә бүген дә саклана.

1920 елларда Казанга Беганскийлар гаиләсе күченеп килә. Беганскийларга 1819 елда шляхтич — Польшаның вак дворяны — дәрәжәсе бирелә һәм ярымай нәсел гербы итеп раслана. Алар арасыннан Польшаның милли-азатлык хәрәкәте башында торган Тадеуш Костюшканың адъютанты майор Сөләйман Беганский аеруча күренекле шәхес. Измаил Беганский гражданнар сугышында катнаша, 30 еллар уртасында исә Татарстанның сәламәтлек саклау халык комиссары була. Аның язмышы да ул чордагы халык комиссарлары язмышы белән уртак. 1937 елда Измаил Беганскийны атып үтерәләр, хатынын ун елга лагерьга озаталар. Абыйсы Салих Беганский сәүдә системасында эшли. Хәзерге вакытта да бу нәселнең берничә вәкиле Казанда яши. Софья Салих кызы моторлар төзү берләшмәсендә, Евгения Салих кызы китап басучы, Искәндәр Салих улы буяучы булып эшләп, һәркайсы кешеләрнең ихтирамын казандылар.

Тамерлан Кинскийлар гаиләсе Казанга Беренче Бөтендөнья сугышы барган жирләрдән 1914 елда күченеп килә. Мицкевичларның татар тамырыннан булган хатыны Роза ханым вафат булгач, ут туганнары янынарак — Минскига күченеп килә, ә улы — Мостафа Тамерлан — Ленинградның автомобиль юл төзелеше институтын тәмамлый, Бөек Ватан сугышыннан соң Советлар илендәге иң эре автомобиль юлларын төзүдә катнаша. Илленче еллардан ул Казанда яши, хәзер лаеклы ялда. Улы Олег Казан дәүләт университетын тәмамлады һәм Димитровградтагы атом-таш комплексының өйрәнү, күнегүләр ясау бүлеге башлыгы, кызлары Надежда — Казанда, экономист.

Бу жәһәттән алда телгә алынып үтелгән Якуб Богдановичның улы Үзбәк Богдановичның язмышы аеруча гыйбрәтле. Әнисе ягыннан ул беренче милли парламент — Милли мәжлес тарафыннан юстиция министры итеп билгеләнгән атаклы жәмәгать эшлеклесе Фуад Туктаровның туганы. Шул ук вакытта туган-нан-туган апасы большевик Хөсәен Ямашевның хатыны була. Әтисе ягыннан туган тиешле абыйсы Али Богданович диңгезче офицер патша Николай Икенче аңа сугышчан батырлыклары өчен үз кулы белән Коръәни Кәримне бүләк итә; соңрак Парижда вафат була. Әти-әнисе репрессияләнеп ятим калса да Үзбәк Якуб улы Богданович юлдан язмый: медицина институтын тәмамлап табип була, Бөек Ватан сугышында Ленинградны саклауда катнаша, сугыштан соң исә медицина фәннәре докторы дигән югары дәрәжә ала, травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү институтын житәкли. Кыскасы, меңнәрчә кешеләрне чын мәгънәсендә аякка бастыра. Лаеклы ялга чыкканнан соң да республиканың атказанган фән эшлеклесе Үзбәк Якуб улы гамәли медицинадан китми, шул ук институтта кинәшче профессор хезмәтен башкара. Аның балалары да фән юлын сайлыйлар: улы Али да, кызы Ляля да фән кандидатлары, доцентлар.

Шегедевичлар Богдановичларга туган булып торалар, алар кенәз-морзалар нәселеннән. Аларның нәсел башы булып 1460 елларда яшәгән Ураз баба хисаплана. Бу нәселнең бер вәкиле Шегедевич Гассан Измаил улы 1928 елдан Казанда яши башлый. 1933 елда Казан коммуналь хужалык институтын тәмамлый. Аннары Симферополь шәһәрендә яши һәм... кырым татарлары белән бергә Үзбәкстанга сөрелә. Жан тартмаса, кан тарта дигәндәй, хәзерге көндә аның улы Динар әфәнде «Татводоканал» берләшмәсендә баш инженер булып эшли.

Минә дистә елдан артык инде Казан белән алман шәһәре Брауншвейг арасында дуслык мөнәсәбәтләре яшәп килә. Һәм бу көтелмәгән нәтижәләр дә бирде. Әйтик, житмеш биш яшьлек алманлы Герхард Мурза Казан жирендә — Богдановичлар һәм Шегедевичлар сыйфатында — күптәнге туганлык жепләрен ялгап жибәрде.

Белмим, бу үзәктән махсус оештырылган, бер төзек системага салынган аулау булганмы, әллә очраклы хәлме (мөгаен, беренчесе хаклыкка туры киләдер), Казанда яшәгән польша-литва татарларын гел кара язмыш көтеп торган. Якуб Александр улы Полторжицкий, мәсәлән, чыгышы белән дворяннар нәселеннән булган өчен генә 1931 елда ук кулга алына (аның әтисе патша армиясендә генерал була). Гаепләүнең беренчи әхлакый кысаларга сыймавын аңлаган тоткын ачлык

игълан итә һәм аны азат итәргә мәҗбүр булалар. Шулай итеп, ул кабаттан эзәрлекләүләрдән куркып, Казанны ташлап китә. Аның Казанда улы Искәндәр торып кала, ул спорт дөньясында 25 тән артык спорт остасы хәзерләгән тренер-педагог буларак билгеле. Искәндәр аганың да язмышы фаҗигале тәгәлләнә. 1982 елда, 38 яшендә, аның улы үлеп китә, аннары хатыны Ия дә якты дөньядан китеп бара. Билгеле, мондый кинәттән килгән авыр кайгы Искәндәр аганы аяктан ега һәм ул укучысы, спорт мастеры Рафик Әмир улы Якушев кулында кала. Ул, күрәсең, бик киң күңелле, якты җанлы кеше булгандыр, укытучы белән укучы арасында мөнәсәбәтләр, хәзер инде истәлек булып кына калган күп санлы фоторәсемнәр әнә шул хакта сөйли.

Күренә ки, польша-литва татарлары шактый кызыклы язмышка дучар ителгән этник төркем булып тора һәм аның язмышы поляк тикшеренүчеләре тарафыннан шактый ук яхшы өйрәнелгән, әмма кызганыч, Татарстанда алар турында бик аз беләләр. Ә бит әлеге татарлар инкыйлабка кадәр мөселманнар арасында укымышлы булулары белән аерылып торганнар (сүз уңаенда искәртеп үтик, Йозеф Пилсудскийның иң якын көрәштәше, аны Рәсәй төрмәсеннән коткаручы һәм Польша социал-демократ партиясен төзүчеләрнең иң күренекле эшлеклесе дә татар — Александр Сулкевич була). Кайбер тарихчылар бу төркемнең милли үзаңын саклап калуда Ислам дине зур роль уйнаган, дигән фикер әйтәләр. Билгеле, монда күпмедер хаклык бар, әлбәттә. Әмма, алай гына микән, 16 гасырда ук христианлыкны кабул иткән әлеге татарларның борынгы баба тамырҗепләрен югалтмавын, алай гына да түгел, саклап килүен ничек аңлатырга? Биредә, күрәсең, Польша һәм Литва хөкүмәтенең татарларга карата, икенче дини мәзһәбтә торуларына да карамастан, мәрхәмәтле сәясәт уздыруы, аларны шляхтич — дворян дәрәҗәсенә күтәрүе дә билгеле бер уңай роль уйнагандыр. Рәсәй, Польша, Литва, Беларусь дәүләтләре арасында туктаусыз барган сугышлар нәтиҗәсендә яшәгән җирләре кулдан-кулга күчеп йөргән татарлар тарихы менә шулай барлыкка килгән. Ничек кенә булмасын, бу горур халык үзенең кайсы тарихи киңлекләрдән яшәү көче алганлыгын, үзенең кем икәнлеген беркайчан да онытмаган.

1926 елдан Казанда яшәүче Мария Андреевна Сергеева борынгы Корицкийлар нәселеннән, ә алар, үз чиратында, Идегәй каһарман токымыннан киләләр. Мария Андреевна утыз елга якын Казан медицина училищесы директоры булып торды. Аның әнисе, Корицкая, вакытында шөһрәтле Александр кызлар институтын тәмамлаган булган, әтисе патша армиясендә — генерал. Ә бабасы 1812 елгы сугышта катнашкан. Шунысы кызык, Мария Андреевнаның христиан динендәге бабасының әтисе руслар ягыннан торып сугышса, туганнан-туган бабасының әтисе — Ибраһим Корицкий Наполеон армиясендә татар полкын оештырып, русларга каршы күтәрелә. Билгеле ки, бу сугышта Рәсәй кабаласыннан котылу идеясе белән яшәгән Польша дәүләте Наполеон ягына баса, ә польша-литва татарлары исә үз илләренең — Речь Посполитаның — ялкынлы патриотлары булалар. Әлбәттә, татарларның Бөек Литва кенәзлегендә яши башлауларына 500 ел тулган көннәрдә фәнни җәмәгатьчелек тә, иҗат әһелләре дә Польша, Литва, Беларусь киңлекләрендә чәчелеп яшәүче кан кардәшләребез алдында торган проблемаларга йөз белән борылырлар, аларга гамәли ярдәм күрсәтерләр дип ышанасы килә.

Әйе, ышанасы килә. Чөнки ике арадагы рухи күпер өзелмәсен, сәйләннәр бүтән чәчелмәсен иде.

**Равил КАШАПОВ.**

**Дөррия Рамазанова**

# ПЕРМЬ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ТЕЛЕ ҺӘМ ТАРИХЫ

Статистик мәгълүматларга (1979) караганда, Пермь өлкәсендә 160 мең чамасы татар яши. Болардан тыш тагын 32 мең башка милләт (безнең уебызча, «башкорт») вәкилләре татар телен ана теле дип саныйлар. (Вестник статистики, № 7—1980:). Алар Тол (Тулва), Муллы (Мулянка), Ирен, Сөлил (Сылва), Сеп (Сыпь), Шауба (Шаква), Бөрмә (Бырма) һәм аларның кушылдыклары буйларында яшиләр.

Аларның үз араларында үзләрен икегә бүлү гадәткә кергән: Гәйнә ягы һәм Көңгер ягы. Ләкин Гәйнә ягы вәкилләре үзләрен болай атауны яратып бетермиләр. Мондый бүленешнең сәбәпләре пермь татарлары кичергән тарих белән бәйләнгән. Казан ханлыгы җимерелгәч һәм аның протекторатындагы җирләр әкренләп Рус дәүләтенә кушылган чакта пермь татарлары ике административ үзәккә карый башлыйлар.

Гәйнәләр дип хәзерге Барда районында яшәгән татарларның бер өлешен атыйлар. Революциягә кадәр алар Оса өязенә кергәннәр. Рус язма чыганакларыннан күренгәнчә, Оса Казанның бистәсе булып саналган (Борынгы документларның үзәк дәүләт архивы — БДҮДА, 1209 ф., 1 тасв., 153 китап).

Билгеле булганча, Урта Кама тирәләре, Агыйделнең түбән агымы борынборыннан Урта Идел татарлары белән бер үк тарих кичергәннәр. XV—XVI гасыр язма чыганакларда Агыйдел җире, башкорт улуслары, Нугай Урдасы кебек мөстәкыйль бүленешләр булган. Урта Кама һәм Түбән Агыйдел тирәләре, билгеле бер традицион чикләр эчендә, мәйдани-административ нисбәтлек ягыннан тотрыклы даимилек саклыйлар: Болгар дәүләте составында,— ул монгол яулары тарафыннан җимерелгәч,— аның дәвамчысы Казан ханлыгында, ул Рус дәүләтенә кушылгач, Казан Приказында, аннан соң Казан өязендә. Бу традицион административ нисбәтлек 1728 елга, ягъни губерналар оешканга хәтле, сакланып килгән.

Казан ханлыгы җимерелгәч, «бөтен Көнтабыш Уралны Рус дәүләтенә кушарга мөмкинлек туа» (История Урала. Т. I, 1976.) һәм Түбән Агыйдел-Оса төбәге Казан Приказына кертелә, ә пермь татарлары яши торган мәйданның калган көнчыгыш өлеше Себер Приказына (башта Чердын өязенә, аннан соң Көңгер өязенә) карый башлый. Көңгер өязенә кергән татарлар ясаклы крестьяннар катламына (сословиясенә) язылалар һәм ясаклы татарлар дип атала башлыйлар. Ягъни аларга карата татар этнонимын куллану дәвам итә.

Оса тирәсе татарларының язмышы исә бераз катлаулырак. Казан үзәгенә караган Уфа провинциясе (соңрак: өязе) оеша. Аңа Оса тирәсе, бөтен хәзерге Төньяк Башкортостан җирләре кертелә, андагы җирбиләүчеләр — татармы, чувашмы, удмуртмы — барысы да башкорт дип аталып китәләр, аларга үз җирләрен вотчина хокукында биләргә рөхсәт ителә. Башкортостан тарихын архив документлары нигезендә өйрәнүгә күп еллар буе зур көч куйган У. Х. Рәхмәтуллин

[1] Мәкаләнең бай библиографик чыганаклары кыскартылды яки гомумән төшереп калдырылды.— Редакция.

күрсәтүенә карaганда, хәтта руслар да башкорт булып аталып китәләр (Крестьянство и крестьянское движение в Башкирии в XVII — начале XX вв. Уфа, 1981). Шулай итеп, пермь татарларының бер өлеше — хәзерге Барда районы тирәсендә булган берникадәр авыллар «башкорт» катламына кереп кала. Башкорт сүзенең билгеле бер тарихи чорда административ атама да, катлам да, милләт тә белдерә торган термин буларак кулланылуы тарихчыларга билгеле. Бу турыда киңрәк мәгълүмат аласы килгән кешегә түбәндәге хезмәтләрне карап чыгу кызыклы булыр дип уйлыйбыз: Гурвич Н. А. Племенной состав населения Уфимской губернии и приблизительная численность его в 1878 г. 1880; Кузеев Р. Г. Происхождение башкирского народа. Уфа, 1974; Рамазанова Д. Б. История формирования татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984; Исхаков Д. М. Из этнической истории татар восточных районов Татарской АССР до начала XX века.— К вопросу об этнической истории татарского народа. Казань, 1985; һ. б.

Башкорт катламына кергән кешеләр ясакны чагыштырмача азрак түлиләр, солдатка алынмыйлар, Рус дәүләтенең көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләрен саклауда катнашырга тиеш булалар, шулай итеп башкорт дигән, берникадәр өстенлекләре булган йомышлылар катламы барлыкка килә. Бу хәл яңа күчеп килгәннәрнең дә башкорт исеменә керергә тырышуына, «башкорт» иконлекләрен бик тырышып сакларга омтылуга китергән. Башкорт җирләрен тартып алып бетергәч, Себер җирләрен үзләштерә башлагач, Рус хөкүмәтенә башкорт дигән йомышлы катламның кирәге бетә һәм XIX гасырның урталарында бу катлам юкка чыгарыла, ә «башкортлар» исә башка крестьяннар белән бертөсле үк катламга кертеләләр. Ләкин «башкорт»ларга җан башына җир күбрәк бирелгән булган һәм алар революциягә кадәр үзләренең җирләрен аерым биләүне дәвам итәләр. Шул рәвешле, беркадәр өстенлекле катлам булу сәбәпле, «башкорт»лар берничә гасыр буе аерып йөртеләләр. Хәтта бер үк авылда «башкорт», «типтәр» яки «ясаклы татар» яшәгән очракта да, алар җирләрен аерым биләләр, төрле икътисади мәсьәләләрдә аерым идарә ителәләр.

Менә бу фактлар Оса башкортлары һәм Көнгер татарлары дигән ике төркемнең бүленеп чыгуына китерә, ул халык күңеленә дә сеңә бара. Шуңа күрә хәзерге Барда районында «без башкорт татарлары» яки «без ни башкорт, ни татар» дигән сүзләрне ишетергә мөмкин.

Әмма ләкин бу ике төркемнең тормыш үзенчәлекләре дә, сөйләм телләре дә бертөсле. Бу турыда тарихчылар да (Историко-географическое описание Пермской губернии, сочиненное для Атласа 1800 года. Пермь. 1801: § 37, § 38; Чупин Н. К. Географический и статистический словарь Пермской губернии. Т. 1, Вып. I. 1873; вып. II, 1875; вып. 3, 1876; т. II. 1878—1880; һ. б.), телчеләр дә (Бессонов А. Г. О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам. Журнал Министерства народного просвещения. Ч. 216, СПб., 1881; Сарманаева Д. М. Урта Урал татарлары телендә диалекталь үзенчәлекләр. Канд. дисс. Казан, 1948; Бурганова Н. Б., Махмутова Л. Т. К вопросу об истории образования и изучения татарских диалектов и говоров // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962; һ. б.) күрсәтеп үтәләр.

Шушы ук хезмәтләрдә пермь татарлары сөйләшенең татар теленә бик якын торуы төрле-төрле материаллар белән исбатлана. «Татар теленең диалектологик атласы» да (Казань, 1989), беренчедән, пермь сөйләшенең бөтен таралыш территориясендә дә бертөсле булуын, икенчедән, татар теленә каравын, бигрәк тә урта диалект сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтүен дәлилләде.

Билгеле булганча, халыкның теле аның тарихы белән турыдан- туры бәйләнгән, тел халыкның төп билгеләреннән берсе булып тора. Этносның үсеш-үзгәреше барышында булып үткән барлык мәдәни-икътисади һәм башка вакыйгалар аның матди һәм рухи мәдәниятендә генә түгел, бәлки телендә дә теге яки бу дәрәҗәдә эз калдыралар. Шуңа күрә дә теге яки бу халыкның телен өйрәнү аның этник нисбәтлеген билгеләүдә әһәмиятле роль уйный дип уйлыйбыз.

Пермь татарлары сөйләшенең тел үзенчәлекләрен тикшерү, шул сөйләш вәкилләренә кагылышлы тарихи-этнографик әдәбиятны өйрәнү әлеге этнографик төркемнең этник яктан формалашу юлы үзенчәлекле һәм катлаулы булуын күрсәтте. Пермь татарларының барлыкка килүе Урта Иделдә, Уралда һәм Себердә барган катлаулы тарихи вакыйгалар белән бәйләнгән. Ул ерак гасырларга барып тоташа һәм, әлбәттә, татар халкы формалашу шартларында барган. Татар халкы этник составы һәм теле ягыннан Урта Идел һәм Урал алды тирәләрендә скиф-сармат чорларында ук җирле төрки һәм төркиләшкән фин-

угыр кабиләләренең бергә тупланып укмашуы нәтиҗәсендә формалаша башлый. I меңьеллыкның IV—V гасырларында Идел-Кама ареалында төркиләшүнең әһәмиятле яңа чоры башлана: бу җирләргә төрки телле кабиләләрнең күпләп килүе күзәтелә (История Татарской АССР. Казань, 1968). Археологик тикшеренүләр бу җирләрдәге каберлекләрнең соңнарнеке булуы турында сөйлиләр (В. Ф. Генинг; А. Х. Халиков; Н. А. Мажитов; П. Н. Старостин; һ. б.). Урта Иделгә һәм Урал алды җирләренә төрки кабиләләр болгарларга чаклы ук күпләп килгәннәр. Болгар дәүләте чорында, мәсәлән, IX гасырда, фин-угырлар белән бергә суар, эскел, суаз, бортас һ. б. кабиләләр яшәгәнлеге билгеле.

Этнолингвистлар күрсәтүенчә, бу атамаларның составында ас — аз, яс, ус, уз, ош, иш, уш компоненты бар. Ул компонент башка төрки халыкларны белдерә торган сүзләрдә дә күзәтелә. Бу яктан караганда, пермь татарларының бабаларына карата кулланылган остяк сүзе зур кызыксыну уята. М. З. Зәкиев бу сүз дә ас компонентына нигезләнгән дип саный (Проблемы языка и происхождения волжских татар. Казань, 1986.). Хәзерге көндә асларның төрки булганлыгы турында да күп кенә фикерләр тупланган. Бу сүз белән печенегларны, болгарларны һәм бортасларны да, карачай-балкарларны да атаганлыклары мәгълүм (кара: шунда ук). Шунысы кызыклы, Оса (шәһәр исеме) атамасының да нигезендә шушы ук компонент булуы мөмкин. Революциягә хәтле пермь татарларының бер өлеше Оса өязенә караган була.

Шулай итеп, кайчандыр пермь татарларының бабаларын белдергән остяк сүзендә Идел-Урал ареалында булып узган бик борынгы тарихи вакыйгаларның эзе сакланып калган, дип фараз итәргә мөмкин.

Тарихчылар хәзерге Пермь өлкәсенең көньяк яртысында, ягъни хәзер пермь татарлары яши торган җирләрдә, кайчандыр угырлар яшәгән булган дип санийлар; аларның бер өлеше руслашкан, бер өлеше татарлашкан, ә бер өлеше исә көнчыгышка һәм төньякка таба күчеп киткән дип аңлаталар (А. А. Дмитриев. Пермьская старина. Вып. I. 1884—1990; һ. б.).

Шунысын аерып күрсәтеп үтәргә кирәк, Сөлил, Чусовая бассейннарында һәм Урта Кама тирәсендә IX—XV гасырларда яшәгән кабиләләрнең культурасын археологлар «сылва культурасы» дип аерып чыгаралар (Генинг В. Ф. Очерк этнических культур Прикамья в эпоху железа.— Труды КФ АН СССР. Вып. 2. Казань, 1959. Бадер О. Н., Оборин В. А. На заре истории Прикамья. Пермь, 1958). Бу культура Агыйдел һәм Ык елгаларының түбән агымы буендагы шул ук чорга караган культурага якын тора (Казаков Е. П. Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1978. Исхаков Д. М. Из этнической...; һ. б.).

XVI гасырдан башлап пермь татарлары турындагы мәгълүматлар рус телле язма чыганакларда да чагыла башлый. Түбәндә шуларның кайберләрен күрсәтеп үтәбез.

1570 елларда Пермь җирләренә Трифон Вятский килгән, шундагы халык арасында яшәгән. Бу турыда «Житие св. Трифона Вятского» дигән әсәр языла. Моннан күренгәнчә, Сылва буе остякларының князьләре Амбал булган, ә Югары һәм Түбән Муллы елгалары буендагы остякларның князьләре Зевендук булган. Остяклар татарлар белән аралашып яшәгәннәр, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре белән дә алар бер-берсеннән аерылмаганнар (Дмитриев А. А. Критические заметки по истории Перми Великой XVI века. Пермь, 1893.).

1579 елда пермь татарлары беренче мәртәбә М. И. Яхонтов тарафыннан сан буенча исәпкә алыналар, тик бу кенәгәләр югалган. XIX гасыр тарихчыларының хезмәтләренә кереп калган кайбер өзекләргә караганда, бу кенәгәләр буенча, әлеге җирләрдә татарлар һәм остяклар яшәгән.

М. Кайсаровның 1623—1624 елгы кенәгәләреннән күренгәнчә, Ирен, Сөлил, Шауба, Тол, Муллы, Бәрмә, Сеп һәм аларның кушылдыклары буенда татарлар һәм остяклар яшәгән. Шунысы характерлы, кенәгәләрдә татар һәм остяк сүзләре бәрабәр этнонимнар буларак, бер үк халыкка карата кулланылганнар (Шишонко В. Писцовые книги Пермьской губернии Соликамского и Кунгурского уездов. Пермь, 1872.). Бу кенәгәләрдә дә пермь татарлары ике өлешкә («улус») бүлеп язылган: Карьево өлеше һәм Рожин өлеше. Татар һәм остяк атамалары берничди аермасыз, бертиң атамалар буларак кулланылуыннан чыгып булса кирәк, А. А. Дмитриев, XVI гасырда бу ике төркем бер-берсеннән бер дә аерылмаган, бертөсле үк тормыш алып барганнар, дип яза. Аларның төп шөгыльләре аучылык, балыкчылык, умартачылык булган, сөреп иген игелә торган җирләре дә булган. Димәк, алар, Идел буе татарлары кебек үк, утрак тормышта яшәгәннәр.

Пермь татарлары турында кызыклы фактларны чагылдырган тагын бер язма чыганак бар. Бу — 1679 елгы исәпкә алу кенәгәләре. Аларда остяклар искә алынмыйлар инде. Икенче яктан, татарлар яши торган әлеге җирләрдә чувашлар, удмуртлар һәм марилар да барлыкка килгәннәр. Тагын шуны ассызыклап үтәргә кирәк, бу кенәгәләрдә пермь татарларының Көнгер өязенә караганнары гына, ягъни көнгер татарлары гына исәпкә алынган. Алар дүрт чиреккә бүлеп йөртелгәннәр, анда ясаклылар, оброкчылар, захребетниклар, күршеләр, күршеләрнең кул астындагылар дигән катламнар аерылып чыга (БДҮДА, 1209 ф, I тасв., сакл. берәмлеге 226, 241—354 битләр). Түбәндә шул кенәгәләрдән өзекләр китерәбез (авыл исемнәре документтагы язылышта бирелә).

1) Карьево чиреге (Түбән Ирен бассейны, хәзер Көнгер районы): Байсино, Усть Турка, Старая Карьево, Шелканка, Большой Ашап, Малый Ашап, Казаево, Янычево авыллары. Аларда 73 йортта 222 ясаклы татарлар, 1 йортта 5 оброк түләүче татар, 2 гаилә захребетниклар (10 кеше) һәм аларның күршеләре 5 татар, күршеләрнең кул астындагылар 3 кеше һәм 3 захребетник, 6 мари; 3 йортта 7 оброк түләүче удмурт, 2 йортта 4 оброк түләүче чуваш, 4 йортта оброк түләүче марилар яшәгән.

2) Югары Ирен чиреге: Телес («Курамышево тож»), Медянка, Старая Курмашева, Новый Телес, Крым Сараево, Исынбаево, Верх Сарс, Сарс, Кошманаково авыллары. Анда 71 йортта оброк түләүче татар, 2 йортта 3 ясаклы мари һәм күрше кул астындагы мари, 6 йортта 11 оброк түләүче чуваш һәм аларның күршеләре ясаклы 2 татар, 24 йортта оброк түләүче мари, 3 йортта 8 оброк түләүче удмурт һәм аларның күршеләре ясаклы 2 татар яшәгән.

3) Шауба чиреге: Девяткильдеево, Исенеево, Починок Багишево, Атламышево, Юрман, Линделине, Косельтаево, Уразово, Ураскова, Копчиково, Таз, Солянка авыллары. Бу авылларда 62 йортта 189 ясаклы татар, 1 йортта 4 оброк түләүче татар, 2 йортта 6 ясаклы мари, 2 йортта 4 оброк түләүче мари, 2 йортта 5 оброк түләүче чуваш яшәгән.

4) Югары Сөлил чиреге: Красный Яр, Кобеняковы, Актыбаево, Медяшево, Верхний Батам, Нижний Батам, Малый Каратай, Большой Каратай, Арий («Бисерть тож»), Еноктаево, Верхний Чис, Бекбулатово, Тюриш авыллары. Аларда 41 йортта 115 оброк түләүче мари һәм аларның күршеләре, 10 мари белән күрше ясаклы татар, шунда ук күрше кул астындагы ясаклы 1 татар һәм оброк түләүче 7 мари һәм аларның захребетниклары 3 мари; 43 йортта 135 ясаклы татар, 25 йортта 78 ясаклы мари яшәгән.

Бу кенәгәләрдән күренгәнчә, көнгер татарлары Тол елгасының югары агымы бассейнында да булганнар. Тол буйларындагы татарларның зур өлеше бу кенәгәләргә кертелмәгәннәр, чөнки алар Уфа провинциясе составындагы Оса өязендә булганнар, бөтен Башкирия[1] халкы кебек, башкорт-вотчинниклар исеме астында аерым исәпкә алына торган булганнар. Кызганыч ки, «башкорт» ясак кенәгәләре шулай ук югалганнар, безгә килеп җитмәгәннәр.

Пермь татарлары тарихына ачыклык кертә торган тагын бер әһәмиятле чыганак бар. Бу документ «О начале и происхождении разных племен иноверцев» дип атала. Ул 1784 елда төзелгән (Пермь өлкәсе дәүләт архивы, 316 фонд, 1 тасвирлама, 78 саклану берәмлеге). Бу документта башта Пермь тирәсендәге Кояново, Култаево һәм Янычево (хәзерге Югары Муллы һәм Пермь районнары) авыллары халкының килеп чыгышы турында риваять китерелә: аларның бабалары тархан нәселеннән булганнар һәм бу урыннарда бик борынгы заманнардан бирле яшиләр. Иван Васильевич Казанны алгач, алар Россия державасына буйсындырылганнар, ә аңа кадәр алар башлыклары нугай ханы кул астында булганнар... Алга таба аларның яшәү рәвешләре бәян ителә: алар күпсанлы һәм гадәттәгечә итеп салынган йортлары булган авылларда яшиләр; аларның бөтенесе дә ак келәтләре, ак бүлмәләре булган өйләрдә һәркем үз гаиләсе белән яши; өйләре һәм өй җиһазлары бар, үзләренә җитәрлек сөрү җирләре һәм чабынлыклары бар, һәрберсе булдыра алганча терлек тота...

Бу өзекләр пермь татарларының бабаларының утрак тормышлы булулары, зур, чиста, матур өйләрдә, зур-зур авыллар булып яшәүләре турында сөйли. Аларда үз чорларына карата шактый алга киткән игенчелек булган.

Шунсы бик кызыклы, әлеге документның 68 нче битендә тагын бер «Сведение...» китерелә. Ул Гәйнә (башкортлар), Таныл (татарлар) һәм Иштирәк (ясаклы татарлар) волостьларында яшәүчеләргә карый, анда югарыда китерелгән өзекләр сүзмә-сүз кабатланалар.

[1] Казан ханлыгы яулап алынгач, Рәсәйгә көчләп кушылмаган өлкә күздә тотыла.

Шулай итеп, бу документтан күренгәнчә, хәзерге Пермь өлкәсе Пермь, Барда, Орда, Чернушка, Өя (Уинский), Көнгер һәм Октябрь районнарында яшәүчеләрнең бабалары килеп чыгышлары буенча да, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре буенча да бер булган, ә аларны «гәйнә башкортлары», «көнгер татарлары» дип бүлеп йөртү сонрак барлыкка килгән. Югарыда күрсәтеп үткәнчә, мондый бүленеш өчен җирлек Башкирия составында Оса өязе, Себер Приказы составында Көнгер өязе барлыкка килгәч кенә килеп туган булырга мөмкин. Кызганыч, кайбер хәзерге татар тарихчылары да аларны гәйнә башкортлары һәм пермь татарлары дип икегә бүләргә маташалар. Әмма мондый бүленеш өчен тел ягыннан да, аларның матди һәм рухи мәдәниятләре ягыннан да берниндн нигез юк.

Пермь татарлары турында мәгълүматлар туплаган төп чыганаклар, нигездә, менә шулар. Күргәнебезчә, аларның килеп чыгышы, кайчан бу регионда урнашулары, этник нисбәтлекләре турында төрлечәрәк фикерләр бар. Бу чыганаклар пермь татарларының бабаларына карата остяк сүзенең кулланылуы, аның кайчан кулланыштан төшеп калуы турында ачык сөйлиләр.

XVI гасыр ахырында — XVII гасыр башында остяк сүзе белән пермь татарларының көньягындагы күрше халыкларны да атаганнар, монда да татар һәм остяк сүзләре берниндн аермасыз кулланыла. Мәсәлән: «Ирендә Аксиев волосте Белокан, Кошчы, Балыкчы татарлары һәм остяклары сату итә башласалар...» Яки: «Чердын өязе Сөлил, Ирен буйларына рус сәүдәгәрләре һәм Казан, һәм Уфа өязләреннән татарлар һәм остяклар килеп сату итәләр»... (документ 1618 елга карый) (Исхаков Д. М. К вопросу об «остяцком» компоненте пермских татар и его связи с носителями сылвенской культуры.— Проблемы средневековой археологии Урала и Поволжья. Уфа, 1987).

Соңрак, Уфа краендагы җирбиләүче халыкка карата һәм катлам, һәм административ эчтәлекле «башкорт» термины ныклап урнашкач, әлеге өзекләрдә телгә алынган татарлар һәм остяклар башкорт булып аталып китәләр.

Тарихи чыганакларны һәм әдәбиятны өйрәнү остяк сүзенең төрле халыкларга карата кулланылуын күрсәтә. Руслар хантларны остяк дип атаганнар, хантлар исә үзләрен алай атамыйлар. М. Е. Бударин (Прошлое и настоящее народов северо-западной Сибири, Омск, 1952) болай дип яза: хантларны себер татарлары кимсетеп уштяк дип атаганнар, ә руслар бу сүзне остяк дип үзгәрткәннәр. Казакълар иштәк дип башкортларны йөрткәннәр. Остяк дип мансиларны да атаганнар.

Пермь татарлары бабаларының кайчандыр остяк дип йөртелүе турында соңрак чорда язылган документларда да фактлар теркәлгән. Мәсәлән, Ирен буендагы Басино авылы татарлары 1798 елда Пермь губернасы идарәсенә җир турында язган үтенечләрендә югарыда телгә алынган М. Кайсаров кенәгәләреннән мондый өзек китерәләр: «Бу авылның җирләре безнең бабаларыбыз Байса Албашев, Урамет Таисин һәм аның бертуганы Батырныкы булган, алар элек остяк дип аталганнар, хәзер исә шул ук авылда без татар дип аталабыз» (Пермь гыйльми архив комиссиясе хезмәтләре, 3 чыгарылыш. Пермь, 1896.).

Пермь крае тарихчыларыннан берсе В. Шишонко да үзенең «Пермь елъязмасы» (Периоды I—V, 1881—1887) дигән хезмәтендә болай дип күрсәтә: 1578—1579 елларда анда остяклар яшәгән, хәзер алар татар дип аталалар.

С. В. Бахрушин (Остяцкие и вогульские княжества в XVI—XVIII веках. Л., 1935.) хәзер пермь татарлары яши торган территориядә XVI гасырда мансилар яшәгән дигән фикердә тора. А. А. Преображенский (Очерки колонизации Западного Урала в XVII — начале XVIII вв. М., 1956.) башта бу фикерне яклаган да, соңга таба Сөлил тирәсендәге халыклар хантлар булган дип нәтиҗә ясый һәм XVIII—XIX гасырларда мансилар Көнгер өязендә Бабенки, Копчик, Красноуфим өязендә Кленовское авылларында гына калганнар, дип яза. Д. М. Исхаков исә «Пермские татары» (Казань, 1983) дигән китаптагы мәкаләсендә Кленовское авылында яшәүчеләрнең бер руслашкан татар нәселе икәнен ачыклый һәм мансилар белән бер күләмдә ясак түләгәннәрне, нинди милләттән булсалар да, «вогул» дип атап йөртә торган булганнар дип нәтиҗә ясый. Шулай итеп, XVIII—XIX гасырларда Ирен — Сөлил регионында мансилар булуы турындагы фикерләр бик үк нигезле түгел. Әлеге факт патша хөкүмәтенең халыкларны бары нинди ясак түләвен белдерә торган катламнарга гына аерып исәпләвен тагын бер мәртәбә раслый. Димәк, теге яки бу халыкның яки аның бер этнографик төркеменең этник нисбәтлеген билгеләргә тырышканда югарыда китерелгән фактларга бик җитди игътибар бирелергә тиеш.

Бу җәһәттән, безнең тарафтан өйрәнелә торган әлеге тарафтагы халыкларга карата XV—XVI гасырларда нинди атамалар кулланылганын күздән кичерик.

Моның өчен В. Шишонконың «Пермь елъязмасы» дигән хезмәтен файдаландык. 1481 елгы вакыйгалар турында сүз барганда «Пермь иленең» көньяк һәм көньяк-көнчыгыш күршеләре «Ибраһимовның ясаклы татарлары» дип аталганнар. Ибраһимовлар дигәндә Казан ханнары күздә тотыла. Ә 1536 елда Пермьгә «казан татарлары» һөҗүм иткән. Бөек Пермь җирләренә 1546 елда һөҗүм итүчеләр «нугай татарлары» дип аталганнар. 1547, 1552 еллардагы хәбәрләрдә дә шулай ук. 1570 елга караган язма документларда «нугай кешеләре» дигән сүзтезмә очрый, шунда ук беренче мәртәбә «Ирен һәм Сылва татарлары» телгә алына. Аларның көньяк күршеләре 1572 елда инде «башкортлар» дип аталганнар, анда тагын буйлылар («буинцы») дигән атама да очрый (шундагы Буй елгасы исеменнән). Шул ук елгы патша грамотасында мондый юллар бар: «Безгә салым түли торган чирмешләр, остяклар, вотяклар һәм нугайлар». В. Шишонконың «Елъязма»сында хәзерге Башкортстанның төньяк-көнбатыш районнарындагы халыкка карата «нугай» атамасы соңгы мәртәбә 1581 елгы документта күзәтелә. Шуннан соң пермь татарларына карата «сылвинские и иренские татары», ә аларның көньяк күршеләренә карата — «башкиры» атамалары кулланыла. Күргәнебезчә, «нугай» атамасының төньяк-көнбатыш Башкирия халкына карата кулланылышы тарихи шартлар белән бәйле: Казан ханлыгының хәле авыраю, Нугай берләшмәсендәге кабиләләрнең активлашып китүе һ. б. ш. Төньяк-көнбатыш Башкириядәге халыкны татарлар һәм остяклар дип атау XVII гасырның 30 нчы елларына хәтле дәвам иткән.

Күрәсең, кайчандыр остяклар киңрәк территориягә таралган булганнар дигән фикер бик хаклы (Закиев М. З. Проблемы...; Исхаков Д. М. К вопросу...). Беренче рус чыганакларында алар татарлар белән аралашкан хәлдә яшәгәннәр итеп күрсәтеләләр. Соңга таба Балыкчылар (Балыкчинцы) һәм Кошчылар (Кущинские) яшәгән территория Уфа провинциясе (аннары Башкирия) составында калалар һәм, милли яктан кем булуларына карамастан, башкорт исемендә йөртелә башлыйлар. Хәзерге Пермь өлкәсе Барда районында яши торган пермь татарларының да бер өлеше шундый ук язмышка дучар була, чөнки кайчандыр Казан ханлыгы составындагы Оса төбәге, традицион чикләр буйлап, Казан Приказы Уфа провинциясенә кереп кала, ә андагы халыкның язмышы Башкириядәге җирбиләүчеләр белән бертөсле була.

Бу яктан, пермь татарларын үзе барып күргән кешеләрнең фикерләре белән дә танышу әһәмиятле.

Галимнәр, ориенталистлар һ. б. пермь татарлары арасында булып, якынрак танышкач, аларның документлардагы атамалары һәм үз араларында кулланыла торган атамаларның туры килмәвенә игътибар иткәннәр. Мәсәлән, П. И. Мельников Пермь өязе Кояново авылында була һәм «Көнгергә бару» дип аталган мәкалә язып бастырып чыгара (Московитянин, 1841, Ч. III. (№ 5—6). М., 1841). Н. К. Чупин Кояново һәм Култаево авылларының халкын бөтенләй татарлашып беткәннәр дип күрсәтә һәм болай дип яза: инде күптәннән телләре белән дә, тормыш итү рәвешләре белән дә янәшәләрендәге татарлардан кечкенә генә дә аерылмыйлар һәм руслар аларны шул исем белән атап йөртәләр дә (Чупин Н. К. Географический..., Ч. I—II.), ягъни татар дип атыйлар.

Менә мондый шартларда халыкның этник нисбәтлеген ачыклау шактый четерекле. Бу төп үзәкләрдән читтә, еракта яшәгән, әле яңа гына буйсындырылган тарафлардагы ныклап ачыкланып җитмәгән кечкенә төркем халыкларга карата аеруча катлаулы мәсьәлә булып тора.

Нәтиҗәдә, пермь татарларының бабалары турында мондый фаразларны ассызыклап китәргә кирәк.

1) Бу мәйданда хантлар, мансилар яки угырлар төркеме яшәп, аларның бер өлеше төркиләшеп киткән булырга мөмкин.

2) Пермь татарларының борынгы бабалары рус чиновниклары тарафыннан остяк дип аталып китүендә аларның хантлар яки мансиларның бик якын күршеләре булулары да билгеле дәрәҗәдә роль уйнарга мөмкин.

3) Кайчандыр остяк«иштәк» дигән этник төркем яшәгән булырга мөмкин. Бу фараз безнең тарафтан 1970 елда ук әйтелгән иде. Аңа киңрәк тукталыйк.

Пермь татарлары сөйләшендә татар теленең төп диалектлары булып санала торган мишәр һәм урта диалектларда булмаган, ә себер диалектлары, көнчыгыш төрки (хакас, алтай, шор һ. б.) телләр белән уртак булган бер төркем күренешләр бар. Шунсы әһәмиятле, алар телнең өч (фонетика, грамматика, лексика) катламында да күзәтелә торган, тулы бер системаны тәшкил итәләр. Тагын бер үзенчәлекле якны ассызыклап үтәргә кирәк: бу система пермь татарлары сөйләшенең бөтен урынчылыкларында да табыла. Шуңа күрә дә әлеге системаны

себер татарларының соңгы чорларда ясаган йогынтысы нәтиҗәсе генә итеп карый алмыйбыз. Дөрес, бу ике төркем арасында үзара бәйләнешләр булган, бу бәйләнешләр борынгы уртаклыкның һаман да саклана килүенә булышлык иткәннәр.

Пермь татарлары сөйләшенең себер диалектлары һәм көнчыгыш төрки телләр белән уртак булган күренешләре борынгы чордагы катнашлык белән бәйле булырга тиеш, чөнки сөйләштә әле тагын уйгыр һәм борынгы уйгыр телләре белән уртак үзенчәлекләр дә бар.

Бу борынгы күренешләр башкорт теленең көнчыгыш диалектында да, өлешчә генә булса да, табылуын басым ясап күрсәтергә кирәк. Шунысы игътибарга лаек, көнчыгыш диалект вәкилләренең бабалары арасында Р. Г. Кузеев тарафыннан иштәк дип билгеләнгән кабиләләр (мәсәлән, тамьяннар, әйлеләр һ. б.) дә булган. Башкорт диалектологлары кайбер башкорт сөйләшләрендә себер диалектлары белән уртак күренешләр дә булуын билгеләп үткәннәр.

Менә шушы фактларга таянып, без пермь татарларының этник формалашуында ниндидер борынгы көнчыгыш төрки компонент та катнашкан булырга тиеш, бу компонент исә себер татарлары һәм кайбер башкорт кабиләләре өчен уртак булган дигән фикер белдергән идек. Бу компонент шушы остяклар белән бәйләнешле булган булса кирәк дип фараз иткән идек, чөнки XVI гасырның ахырына, XVII гасырга караган сан алу кенәгәләрендә һәм башка документларда остякларның исемнәре төрки исемнәр: Бисердачко Батырев, Кунчурайко, Тасимко, Ураско Урмаметов, Алейко, Ишимбайко, Айгиндейко, Тогаберде (Дугаберде), Камалтинко, Кичкеняшай, Колычбаев, Болонтай, Сигизяков, Мурзакилдейко, Кузембердей, Турчебей, Терегулов, Янып Толгузин, Козебахта Карьев һ. б. ш.

Без югарыда остяк/иштяк дип кемнәрне атаганнарын күрсәтеп үттек. Шунсы кызыклы, хәзерге Башкортстанның төньягыннан чыккан әдипләребезнең дә кайберләре үзләрен иштәк дип атаганнар. Мәсәлән, шәҗәрәләрдән билгеле булганча, Т. Ялчыгол үзен «болгарлык иштәк» дип санаган.

Р. Кузеев («Происхождение»...) иштәк сүзен төркиләр һәм аларның төньяк күршеләре угырлар арасындагы бәгланышлар белән бәйләп карый, иштәкләрне төркиләшкән угырлар дип саный, әмма хезмәтенең азагында иштәкләрне төрки телле күчмә кабиләләргә кертә.

Ф. Фасеев аштәк — остяк — иштяк — истяк кабиләсе (ул аны «этноплеменное образование» дип атаган) төрки-остяк бәйләнешләре дәвамында төрки телне үзләштергән, дип күрсәтә.

М. Зәкиев пермь татарлары чыгышлары белән болгар булганнар, үзләрен остяк дип атап йөрткәннәр, дип саный. Аныңча, остяк — ос/эс + тык/лек, ягъни ос/ас кешеләре дигән сүз; ос компоненты исә күп кенә төрки этнонимнар (ягъни кабилә исемнәре) составында бар: огуз — ак + оз, таулас — таулы ас, суас — су + ас һәм башкалар. М. Зәкиев асларның төрки телле борынгы кабиләләр булуын, остяк сүзенең борынгы ас (яс) этнонимыннан килеп чыгуын күп кенә фактлар китереп исбат итә.

Соңгы елларда остяк мәсьәләсе Д. Исхаков тарафыннан да кат-кат каралган. Ул остякларны пермь татарларының бабалары дип саный, диалектологларның, этнографларның хезмәтләрен һәм башка әдәбиятны, архив документларын да файдаланып, Урал алды территориясендә XVII гасырга хәтле иштәк-остяк кабиләсе яшәгән дип карый. Ул: «Күргәнегезчә, XV гасырда Кама, Агыйдел һәм удмуртлар яшәгән районнарда, күрәсең, Пермь краенда, бәлкем тагын да киңрәк ареалда да, аерым остяк территориясе булган. Башкирия бу вакытта мөстәкыйль җир булган» (Исхаков Д. М. «К вопросу»...; Аныкы ук. «Из этнической»...) — ди.

Остякларның этник нисбәтлеген исә Д. Исхаков төрлечәрәк билгели: төбендә угыр булган кабиләләр Урал алды территориясендә төркиләшкән булган; «характеры ягыннан угыр (төрки-угыр)» һ. б. Д. Исхаков пермь татарлары тарихы турында берничә хезмәт язды (Күрсәтелгән һ. б. хезмәтләр).

Безнең уебызча, пермь татарларының бабалары формалашуында көнчыгыш төрки компонент катнашкан, ә Урал алды мәйданында ул Идел буе төрки компоненты белән бәйләнешкә керә.

**Идел буе төрки компоненты.** Безнең карашыбызча, шушы компонент пермь сөйләше вәкилләренең казан татарларының бер этнографик төркеме булып, аларның сөйләше татар теленең урта диалектына караган бер сөйләш буларак формалашуда төп хәлиткеч рольне уйнаган.

Галимнәр Идел буе — Урал алды бәйләнешләрының мәдәни-икътисади гына түгел, бәлки еш кына сәяси характерда да булуын кабат-кабат күрсәтеп киләләр.

Кайбер галимнәр Агыйделнең түбән агымы тирәсендәге җирләр Болгар дәүләте составына кергән булган, ә халкы исә салым түләп торган, дип язалар.

Төньяктарак яшәгән халыклар да Болгар дәүләтенең көчле йогынтысы астында булганнар. А. А. Дмитриев зыряннар, пермяклар үзләренең тормыш-көнкүрешен, сәнәгатьләрен болгарлар тәэсире астында нык үстерделәр һәм күршеләреннән шактый аерылып торалар иде, дип яза.

Идел-Урал бәйләнешләре күзлегеннән караганда, М. Зәкиевның этнонимнарга тел материалы буларак ясаган анализы игътибарга лаек. Ул Пермь атамасы биарм сүзенә кайтып кала дип саный, ә биар — болгар — буләр — биләр — бигер тәңгәллекләре Урта Идел һәм Урал алды регионнарында генетик яктан бертөрле кабиләләр яшәгәнлеген күрсәтә дип яза. (Закиев М. З. Проблемы...: 54—60). Н. И. Золотницкий фикере буенча, биарлар Бөек Болгариядә яшәүчеләр, соңгысына исә Пермь җирләре дә кергән булган (Лингвистическая заметка о названиях Булгар, Биляри, Моркваши: Читано в 1878 г. Казань, 1884.).

Билгеле, бу өлкәдә эзләнүләр әле дәвам итә.

Идел буе төркиләренең һәм пермь татарларының борынгы чыгышлары уртак булуы төрле фактлар белән дәлилләнә. Мәсәлән, Т. А. Хлебникова үзенең болгар керамикасын өйрәнүгә багышланган хезмәтендә Олы Тархан каберлегендә табылган һәм борынгы болгар чорына караган керамиканың Сөлил бассейнында һәм Төньяк Башкортстанда табылган шул чорга караган керамика арасында зур уртаклык булуын дәлилли.

Пермь крае археологлары Болгар дәүләте Югары Кама бассейнындагы кабиләләргә йогынты ясаган, дип язалар; бу йогынты сәүдә бәйләнешләре аша таралган; XIII—XIV гасырларда болгар һөнәрчелегенең йогынтысы күзәтелә, металл эшкәртү алга китә, бизәнү әйберләре коеп ясау үсә; тары чәчелә башлый һ. б.

Күп кенә галимнәр бу тирәләргә XIII—XIV гасырларда болгарлар күчеп килгән дип саныйлар (Халиков А. Х. Происхождение татар Поволжья и Приуралья. Казань, 1978; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Казаков Е. П. Памятники... һ. б.).

Билгеле булганча, монгол яулары Идел буе җирләрендәге халыкларның составын үзгәртеп кенә калмады, ә бәлки бик зур күчешләр дә китереп чыгарды. Урта Идел буендагы утрак тормышлы халыкның бер өлеше яңа җирләр, чагыштырмача тынычрак урыннар эзләп, күптән таныш һәм элек-электән аралашып килгән юллардан, аеруча Кама буенча төньякка һәм төньяк-көнчыгышка таба күчәргә мәҗбүр була. XIII гасырда Чепца (хәзерге Киров өлкәсе һәм Удмуртия) елгасы бессейнына болгар кабиләсе күчеп килә (Юсупов Г. В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М. Л. 1960; Смирнов А. П. Волжские Булгары — Труды Государственного исторического музея. Вып. 19. М., 1951). XIII—XIV гасырларда Ык бассейны һәм Түбән Агыйдел буйларына кече, кәлчер, йомран, буләр, еней, юрми кабиләләре күчеп утыра; алар Болгар дәүләте составында булалар; Ык буена урнашып калган байлар кабиләсе дә болгарлар белән тыгыз мөнәсәбәттә булган (Кузеев Р. Г. Происхождение...). Кайбер чыганакларга караганда, Пермь краенда төркиләр барлыкка килү дә шушы ук вакыйгалар белән бәйле. Мәсәлән, бер хезмәттә мондый юллар бар: «Кайбер башкортлар (биредә пермь татарларының Оса өязендә яшәгән өлеше күздә тотыла — Д. Р.) һәм татарлар, бигрәк тә Болгар илендә яшәүчеләр, монгол яуларыннан соң монда (Пермь краена — Д. Р.) күчеп килделәр... Башкорт һәм татар исеме белән билгеле булган кайбер болгарлар Пермь губернасында урнаштылар;.. Пермь губернасы башкортлары һәм татарлары үзләре дә легендаларында Шәһри Болгар дип аталган җирдән күчеп килгәнлекләре турында сөйлиләр (Историко-географическое... § 38). Революциягә кадәрге тарихи әдәбиятта «Кама Болгарстаны, Идел-Кама Болгарстаны, Кама буендагы болгарларның да, Идел буендагы болгарларның да атамалары», кебек тәгъбирләр очрый. А. А. Дмитриев (Исторический очерк Пермского края. Пермь, 1896.) фикеренчә, Идел-Кама Болгариясенең төньяк-көнчыгыш чикләре булып Оса һәм Красноуфим өязләре торган.

Үзләренең килеп чыгышлары турындагы легендаларында Оса һәм Пермь өязе «башкортлары» һәм татарлары: «Без чыгышыбыз белән тарханнардан булабыз, бу җирләргә бик борынгы заманнарда күчеп килгәнбез, аннан соң Нугай хан кул астында булдык», дип күрсәтәләр. (Пермь өлкәсе дәүләт архивы, 316, ф. 1, оп. сакл. берәмл 78). Димәк, алар, Иван Казанны алганчы ук, шушы урыннарда яшәгәннәр. Икенче чыганакта исә, алар үзләрен, Шәһри Болгар дип атала торган илдән күчеп килдек, Болгар илен XIII гасыр ахырларында калдырдык, дип аңлаталар (Историко — географическое...: § 37).

Р. Кузеев фикеренчә, гәйнә-тарханнар этник яктан болгар чорына караган кабилә булганнар. Автор, бик күп фактларга таянып, гәйнә-тарханнарның нигезе болгар булуын, Урта Идел халыклары белән бер булуларын исбатлый һәм болай дип нәтиҗә ясый: «Гәйнәләрнең бабалары, юрматы, юрми, бүләр, кече кабиләләре белән бергә, болгар-угыр чолганышында булганлыгын каттый расланган факт, дип билгели алабыз». Автор гәйнәләрнең Тол буйларына килеп чыгуын XIII—XIV гасырларда булган дип исәпли (Кузеев Р. Г. Происхождение...: 342—347).

Шунсы әһәмиятле, Р. Г. Кузеевның нәтиҗәләре тел материаллары белән тагын бер кабат раслана. Әле генә санап үтелгән кесе, юрми һ. б. кабиләләрнең Көнбатыш Башкортстанда яши торган дәвамчы оныклары, гәйнә-тарханнарның оныклары кебек үк, саф татар телендә сөйләшәләр, аны үзләренең туган теле, ана теле дип саныйлар; аларның телендә башкорт теленә хас булган аерымлыклы, үзенчәлекле күренешләр бөтенләй юк (Махмутова Л. Т. О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР.— Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962; Рамазанова Д. Б. Формирование...; Аныкы ук: К истории формирования татарских говоров северо-западной Башкирии (по данным архивных и исторических источников).— Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Казань, 1985. Хайрутдинова Т. Х. Бирский говор среднего диалекта татарского языка.— Шул ук җыентыкта: 36—92; Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья и Комментарии к Атласу... Казань, 1989; һ. б.).

Әмма гәйнә һәм тархан сүзләренең бер үк этнографик төркемгә карата кулланылуының сәбәпләре, тарханнарның күчеп килү датасы һәм гәйнәләр белән бәйләнеш үзенчәлекләре әлегә ачыкланмаган.

Тарханнарның билгеле бер катлам вәкиле булулары турындагы фикер хаклы. Д. Исхаков та шуны ук яклый.

Рус телендәге язма чыганаклар пермь җирләренә күчеп килгән татарларның биләр булуы турында сөйли: Урак би, Сөендек би. Аларның әтиләре мулла булган (Югары һәм Түбән Муллы елгаларының исемнәрен шуннан калган дип аңлаталар). Күрәсең, ул миссионер буларак шактый зур нәтиҗәләргә ирешкән, чөнки XVI гасырда Трифон Вятский килгәндә әлеге җирләрдә татарлар һәм остяклар яшәгәннәр инде. Һәм иң әһәмиятлесе, бу ике халык тормыш-көнкүреш белән дә аерылмаган, исемнәре дә төрки исемнәр булган.

Бу мөнәсәбәттә караганда бездә бер сорау туа: гәйнә атамасын «башкорт» Килейко Акзкильдин һәм аның иптәшләре алып килмәдеме икән?

Беренчедән, 1596 елга караган, К. Акзкильдиннең бу җирләргә кертелүе турындагы документта (Материалы по истории Башкирской АССР. Ч. Т. М.— Л., 1936:) әлеге төбәк Ульвинская (рус скорописендә т хәрефе өскә чыгарып языла торган булган, шуңа күрә ул төшеп кенә калган булырга мөмкин, ягъни, «Тулвинская?» дип аталган) әле гәйнә термины кулланылышта булмаган.

Икенчедән, алга таба да гәйнә атамасы хәзерге Барда районына туры килә торган мәйданда билгеле бер төбәктә генә яшәп калган. Бу төбәк К. Акзкильдинга бирелгән җирләр белән туры килергә мөмкин.

Өченчедән, гәйнә атамасы белән бәйле җир, авыл исемнәре, Пермь өлкәсендә түгел, Көньяк-көнбатыш Башкортстанда сакланып калган (Миякә төбәгендә). Күрәсең, гәйнәләр шунда яшәгән булганнар.

Дүртенчедән, башкорт күчмә кабиләләренең төньяктагы урманлы җирләрдә яшәве бик шикле. Бу мәсьәләгә карата Р. Г. Кузеев та болай дип яза: «Урманлы җирләргә башкортларның күчүе масса төсендә булмаган; башкортларның тик кечкенә төркемнәре генә, төп башкорт халкыннан аерылып, баерак ау урыннары эзләп булса кирәк, төньякка күчеп утырганнар» (Кузеев Р. Г. Очерки по исторической этнографии башкир. Ч. 1. Уфа, 1957.).

Бишенчедән, гәйнә (Гайни — Гайнетдин атамасының килеп чыгуы турындагы риваятьтә дә чагыштырмача соңгырак чорга караган вакыйгалар чагылган булса кирәк: Гайни Югары Урал алды тирәсендә җир ала һәм елына бер тиен тиресен Чердынга илтеп түләргә тиеш була (Ахметзянов М. И. Историческое предание об образовании пермских татар.— Пермские татары. Казань, 1983.). Югарыда әйтелгәнчә, Чердынга ясак түләү, Казан ханлыгы җимерелгәч, Урал тирәсендәге җирләрдә Себер Приказы оешкач (Чердын — шунын бер өязе; Көнгер өязе бераз соңрак төзелә) булган.

Шулай итеп, гәйнә атамасының килеп чыгышы соңрак килеп кушылган компонент белән бәйләнгән булырга да мөмкин. Тик ул Идел төрки компонентына зур йогынты ясый алмагандыр.

Пермь татарларының борынгы чыгышлары Идел буе төркиләре белән уртак икәнлеген исбатлый торган дәлилләрне фәннең тагын башка өлкәләренә караган фактлар да куәтли.

Пермь татарлары яши торган регионның топонимикасына игътибар итик.

М. Зәкиев пермь сүзенең килеп чыгышын би + ирем (кешем) кушма сүзе белән бәйләп аңлата (курс. хезм.: 54; Аныкы ук. Отношение Биармии к Волжской Булгарии.— Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. Казань, 1992; һ. б.).

Красноуфим шәһәре янында Болгары дип атала торган сырт бар. Академик И. И. Лепехин 1770 нче елларда бу сыртның урыны-урыны белән җимерелгән урыннары бар һәм алар ниндидер борынгы бина калдыкларын хәтерләткән кебек, дип язган (Сборник материалов для ознакомления с Пермской губернией. Вып. III. Пермь, 1981.).

Пермь районында Болгары авылы бар.

О. Н. Бадер һәм В. А. Оборин Очер районындагы Черти авылы халкының яртысын әле дә болгар дип йөртәләр, дип язалар (Бадер, Оборин, шунда ук).

Пермь краеның җир-су атамалары, нигездә, пермь-фин-угыр характерында. Мәсәлән: Сылва, Шаква, Тулва һ. б. ш. Аларның «ва» компоненты татарча су дигән сүз. Гәрчә бу елгаларның бик матур яңгырашлы татар вариантлары да бар. Мәсәлән, пермь татарлары аларны Тол суы, Сөл иле дип атый. Ирен гидронимы Иртеш гидронимы белән бер үк тамырдан булырга мөмкин.

Пермь һәм Югары Муллы районнарында Югары Муллы, Түбән Муллы гидронимнары пермь татарларының борынгы бабаларыннан калган атама. Риваятьләрдә Югары Муллы бассейнында Урак би Мәмәтколов, ә Түбән Муллы тирәсендә аның энесе Ирак би, Сөендек би Мәмәтколов яшәгәнлеге турында хәбәр ителә.

Авыл исемендә дә төрки чыгышлы сүзләр бар. Мәсәлән: Әри түз (Усть Арий), Башап түз, Тәләс түз, Тор түз һ. б. Истәк авылы исемендә остяк сүзенең бер варианты чагылган.

Менә шул рәвешле топонимикада эз калдырырлык борынгы халык булган пермь татарларының бабалары.

Пермь татарларының формалашуында Идел буе төрки компонентының хәлиткеч роль уйнавын тел материаллары да раслый: пермь татарлары сөйләше безнең әдәби телебезнең формалашуында нигез ташы булып торган урта диалектка карый. Алай гына да түгел, ул әлеге урта диалектның бераз читтәрәк урнашкан, борынгылыкны аеруча нык саклап килә торган сөйләшләре (нократ, касыйм, подберезье, керәшен) рәтенә керә. Танылган телче Л. Мәхмүтова бик хаклы рәвештә бу сөйләшләрне аерым бер төркем итеп билгели; бу төркем сөйләш вәкилләренең бер чордарак, чагыштырмача зур булмаган тарихи аралыкта мәйдани, сәяси, икътисади яки мәдәни яктан казан татарларыннан берникадәр аерымланган булганлыкларына басым ясый (Махмутова Л. Т. Некоторые наблюдения над лексикой касимского говора татарского языка.— Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2, Казань, 1962.).

Бер-берсеннән шактый ерак урнашкан төбәкләрдә булуларына карамастан, бу сөйләшләр бер төркем борынгы күренешләре белән үзара берләшәләр. Мондый хәл, беренчедән, аларның кайчандыр бергә, бер берләшмә эчендә яшәгәнлекләрен турыдан-туры күрсәтә. Икенчедән, казан татарлары сөйләм теленең төп билгеләре шул вакытта ук формалаша башлавы турында сөйли (Бурганова Н. Б. О формировании татарских говоров Заказанья.— К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. Казань, 1985.).

Шушы чорда ук татар теленең төп сүзлек составы да ныгый башлаган. Әлеге сөйләшләр бер төркем борынгы сүзләр белән дә зур уртаклык күрсәтәләр. Пермь татарлары сөйләшенең болгар чоры белән зур бәйләнешен күрсәтә торган сүзләргә игътибар итик: иләсә (чув. алса) — бияләй, озан (чув. осан, себер. осан) — көртлек, кәлүәт — тукыма төре (Кыйссаи Йосыфта да шулай ук), йемеш — яшелчә; мордва-каратай, Коман мәҗмугасы (1303 нче елда төзелгән), И. Хәлфин сүзлегендә — шулай ук һ. б. ш.

Бу күзлектән караганда, пермь татарлары сөйләше һәм карачай-балкар телләре арасындагы параллельләр аеруча игътибарга лаек:

| кар.-балк. | мәгънәсе | пермь-сөйләше | мәгънәсе |
|---|---|---|---|
| чара табак | зур табак | чара табак | шулай ук |
| чукук | очкылык | чыкык | шулай ук |
| чукук этарге | очкылык тотарга | чыкыклау | шулай ук |

| | | | |
|---|---|---|---|
| эгер | бурзай, ау эте | әкәр | песи һәм этнең ата булганы |
| ёч | хас, яратучан | үч | шулай ук |
| балгъа ёч | бал яратучан | балга үч | шулай ук |
| туч | аллюминий | туч балдак | арзанлы металлдан эшләнгән йөзек |
| генчарыкъ | тиредән тегелгән аяк киеме | конҗорыйк | шулай ук |

Конҗорыйк сүзенең таралыш даирәсе бик чикле, ул тагын күрше златоуст сөйләшендә бар. Башкорт теленең дә төньяк-көнчыгыш Башкортстандагы сөйләшләрендә генә билгеләнгән, ә Кавказ телләренең барысында да таралган. Күрәсең, бу сүзне пермь татарларының борынгы бабалары — болгарлар шул яклардан алып килгән булганнар.

Шулай итеп, тарих, археология, этнография, топонимия, тел материаллары пермь татарларының формалашуында Идел буе төркиләренең роле зур һәм хәлиткеч булуын бик ачык күрсәтәләр.

Урта Идел һәм Урал алды халыклары арасындагы этник бәйләнешләр соңга таба да көчәя, тирәнәя барган (Татары среднего...; История Татарской АССР. Казань, 1968. История Татарии...; һ. б.)

Күп кенә татарлар, чукындырудан качып, Урал якларына качалар. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң Идел буеннан, татарлар белән бергә, чувашлар, марилар, удмуртлар да күчеп киләләр.

Күчеп килүчеләр татарлар яши торган мәйданның төрле төбәкләреннән килгән булырга мөмкин. Мәсәлән, пермь татарлары сөйләшенең тау ягы сөйләшләре белән аерым уртаклыгы бар. Ә сылва урынчылыгында татар теленең урта диалекты мамадыш сөйләшендә генә табыла торган үзенчәлекләр бар, мәсәлән, бардым дагын әйттем, күргән дәген сөйләгән һ. б. ш. Пермь районы тирәсендәге авылларда нократ сөйләше белән уртак үзенчәлекләр күзәтелә.

Революциядән соң Идел-Урал бәйләнешләре радио, мәктәп һәм матбугат аша бара.

Шулай итеп, борынгы чорларда ук булган тарихи бергәлек берничә гасырлар буе дәвам итеп килә. Күп кенә галимнәр пермь татарларының казан татарлары белән якын икәнлекләрен аерым ассызыклап күрсәтеп килгәннәр. И. Г. Георги (Описание всех обитающих в Российском государстве народов. Спб., 1799.) пермь татарларын «алар шул ук казан татарлары», дип яза.

Тел үзенчәлекләре ягыннан да пермь татарлары татар теленә якын торалар, аларның сөйләше башкорт теленнән бик нык аерыла. Мәсәлән, аларның сөйләшендә ч, с авазлары үзләре әйтелә (сарык, чәч, су, сал, чәчә һ. б.), ягъни авазлар составы, сүзлек хәзинәсе, сүзләрне ясау яки төрләндерү (агастар түгел, ә агачлар, һарыкты түгел, сарыкны, һүзде түгел, ә сүзне һ. б. ш.) үзенчәлекләр һәм башкалар барысы да аларның татарча сөйләшүен күрсәтеп торалар. Кыскасы, пермь татарлары татар халкының аерылгысыз бер этнографик төркеме булып тора. Тарихи чыганаклар да, археологик тикшеренүләр дә, ономастик материаллар да, тел үзенчәлекләре дә шушы фикерне нигезле рәвештә раслыйлар.

# ШАмил МАНнап

## Батыевны нигә «тыңламаганнар»?

Заманында шагыйрь Нур Гайсин фатир алырга йөри икән. Йөрепйөреп тә эш алга китмәгәч, Югары Совет рәисе Батыевның үзенә барып карарга була бу. Ни дисәң дә, якташлар бит, ярдәм итми калмас, дип уйлый Нур Гайсин.

Бара бу Югары Советка. Батыев аны чиратсыз кабул итә. Якташ буларак, хәтерли икән, рәхмәт төшкере.

— Аһа-һа, Нурулла якташ, нинди гозерең төште миңа? — дип, бик ачык каршылый. Шагыйрьне тыңлаганнан соң: — Күптән үземә киләләр аны,— дип, Нур Гайсинның гаризасына кызыл кара белән ачык итеп: «Фатир бирергә!» — дип язып, имзасын сырлап куя.

Нур Гайсин кош тоткандай шушы кәгазьне тотып, горисполкомга йөгерә. Шәһәр башлыгының сәркатибе Батыевның язуына күз сала да елмаеп, шагыйрьнең гаризасын өстәл тартмасына салып куя.

— Фатир булгач, үзебез чакырырбыз, абый...— ди.

Ләкин атналар, айлар үтә, ел да узып китә, әмма Нур Гайсинны чакыручы да, фатир бирүче дә юк. Шуннан бервакыт шагыйрь янә теге сәркатип янына бара. Ләкин аның белән сөйләшергә дә теләмиләр. «Фатир юк!» — дип кенә җибәрәләр. Аптырагач, сорый Нур Гайсин:

— Иптәш Батыевны тыңламаска сезнең ни хакыгыз бар? — ди.

Шулай дип, бәйләнә торгач, сәркатип кыз серне ачмыйча булдыра алмый:

— Игътибар иттегезме, сезнең гаризагызга иптәш Батыев нинди кара белән кул куйганын? — дип, тартмасыннан теге язуны тартып чыгара.— Күрәсезме, кызыл кара белән салган ул резолюциясен. Бу инде, бирсәгез дә ярый, бирмәсәгез дә — мәйлегез, дигән сүз. Әбизәтелне бирергә дигәннәргә ул яшел кара белән кул куя. Аңладыңмы инде, абзый кеше?!

## Өй тулы тавык!..

Язучы Афзал Шамовның республика гәзитендә хәбәрче булып эшләп йөргән вакытында була бу хәл. Октябрь районыннан шикаять-хат килеп төшә редакциягә. Анда колхозчы Заһидулла абзыйның кырдан туктаусыз башак кыркып кайтуы, шуның белән үзенең тавыкларын сыйлавы турында язылган була. Хатны урынга барып тикшерү өчен хәбәрче Афзал Шамов Октябрь районына чыгып китә. Килеп җитә кирәкле авылга, эзләп таба Заһидулла абзыйлар өен. Керә. Хуҗа үзе дә өйдә икән. Чакырылмаган кунакны Заһидулла абзый да, хатыны да, өй тулы балачагасы да сагаеп кына каршылыйлар.

— Сезнең ничә тавыгыгыз бар? — дип сорый Афзал абый, «үгезне мөгезеннән» алырга ниятләп.

Хуҗаның йөзе карала, ул ачуланып, ишек алдына ук чыгып китә. «Тавыкларын санарга чыккандыр»,— дип уйлый гәзитә хәбәрчесе. Берараздан керә хуҗа.

— Йә, санадыңмы, абзый кеше, ничә тавыгың бар? — дип соравын кабатлый Афзал Шамов.

Хуҗа тагын сикереп тора да ишекне каты ябып чыгып китә. Бу юлы тагын да озаграк торып керә бу.

— Ай-яй, озак санныйсың, агай, тавыкларың бик күп, ахры, синең? — ди гәзитә хәбәрчесе.

Бу юлы хуҗа кеше дә телгә килә:

— Күп кәнишне, әнә өй тулы тавык белән,— ди ул, борыннарын тартып, күзләрен елтыратып карап торучы бала-чагасына ымлап,— карчыгым белән үземне дә исәпкә-санга кертсәгез, җиде тавык булабыз!

Аңлаша торгач, төшенә Афзал абый: Заһидулла абзыйларның кушаматы ТАВЫК икән бит! Өй тулы — тавык, ә ишегалдында бер кош-корт әсәре дә юк икән ярлы колхозчы агайның...

## Үзе дә аңлаган...

Казан университетында тел гыйлеме (языкознание) дигән бик авыр вә буталчык фәннән озак еллар Әнвәр абый Ахунҗанов укытты. Ул конспектларына күз сала-сала сөйли дә студентлардан: «Аңлашылдымы?» — дип сорый. «Юк» — диләр студентлар. Әнвәр абый конспектына иелеп карый-карый, тагын аңлата. «Аңладыгызмы инде?» — дип сорый. «Тагын бер кат аңлатсагызчы, Әнвәр абый?» — дип үтенә студентлар. Тагын аңлата укытучы. Аннары: «Инде сез түгел, үзем дә аңладым наканис!» — дип, дәресен тәгәлли торган иде.

## Бөекләр кушымчасы

Шагыйрь Равил Фәйзуллинга каләмдәшләре сорау биргәннәр:

— Инде барыбыз да диярлек фамилияләребездәге «ов», «ев», «ин» кебек урыс кушымчаларын алып ташладык. Син һаман Фәйзуллин булып калдың. Сәбәп нәрсәдә?

— «Ов-ев»ларда эшем юк, әмма «ин» ул — бөекләр кушымчасы. Моны раслау өчен Пушкин, Державин, Дарвиннарны атау да җитә,— дигән ди Рәвил Фәйзуллин.

## Күренекле булуның сере

Бервакыт язучы Шамил абзый Бикчуринны урамда үзе яшәгән Лениногорскида райкомның идеология секретаре очратып, битәрли башлый:

— Шамил Мотыйгуллович, үзегез язучы, үзегез айныткычка эләккәнсез. Ярамый бит алай... эчәргә.

Шамил абыйның зәңгәр күзләрендә хәйләкәр очкыннар кабына:

— Нефтьчеләр әйтмешли, мәчебашлы ябалак кына эчми хәзер, иптәш кем. Чөнки дә көндез мәчебашлы ябалакның күзе күрми, ә төнлә — кибетләр ябык,— ди ул.

— Ну бит,— ди секретарь,— эчкән тәкъдирдә кеше-кара күзенә чалынмаска кирәк хәтәбе. Сез бит күренекле кеше...

Шамил Бикчурин алгы эре тешләре белән балкып елмая:

— И-и дивана... Ярый ла салган вакытыңда сине өеңә озатып куярга персональ машинаң бар. Минем машинам юк бит, шуңа мине бөтенесе күрә. Машинам булмаганга күренекле мин...— ди.

## Үзенекен — маяга

Йөзек кашы төсле гүзәл әсәрләр иҗат итеп калдырган Фатих ага Хөсни җор телле, шаян-шук кеше иде, мәрхүм. Мәсәлән, аның яшьрәк вакыттагы шуклыкларыннан берсе турында замандашлары болайрак искә алалар.

Фатих Хөсни, көндез язып арыганнан соң, кичкә таба Язучылар союзы бүлмәсенә килеп керә дә, түш кесәсеннән биш сум акча чыгарып, өстәлгә куя һәм:

— Эш сәгатегез бетеп килә, егетләр. Йә, тагын кемнәр «калхузга» керә? — дип, тамак астына чиертеп ала.

Өйгә кайтып китәр алдыннан бераз гына кәефне күтәреп алганда да зыян итмәс шул, дип, һәркем кесәсен капшый башлый. Кайсы берлек, кайсы өчлек чыгара. Фатих абыйлары өстәлгә җыелган сәмәнне санап карый да:

— Эһе-һе, монда шактый байлык бар икән. Моның шаены эчеп бетерә алмабыздыр. Бу бишлекне әлегә калдырып торыйк, — дип, теге, үзе башлап чыгарган акчаны алып, янә түш кесәсенә салып куя. Һәм кет-кет көлеп, болай өсти: — Бусы киләсе юлы «калхузга» кергәндә кирәк булыр. Бусы — маяга...

## Биргән кеше үзе беләдер...

Бервакыт Рәшит Әхмәтҗан «Казан утлары» редакциясендәге бүлмәдәшләренә зарланып тора иде:

— Миннән бурычка акча алган кешеләр кире кайтарып бирмиләр. Нури (Арслан) абыйга гына күпме бирдем инде, түләргә уенда да җук...

Замана ахырында кемне сөйләсәң, шул алдыңа килеп чыгар, дигән сүз дөрес, ахры, нәкъ шул вакыт бүлмә ишеген киң ачып, шәп ат ялыдай чәчләрен җилфердәтеп, Нури абый үзе килеп керде. Рәшит тынып торды да, баягы сүзен башка алым белән дәвам иткәндәй:

— Нури абый, синең кешегә әҗәтең күпме? — дип сорады.

Нури абый, гадәтенчә, киң елмайды да:

— Биргән кеше үзе беләдер инде, — дип куйды.

## Ике төрле гаҗәпләнү

Яшь шагыйрь Расих Шамский үз әсәрләрен күрсәтеп, киңәш-уңаш алыйм дип, Рәшит Әхмәтҗанның фатирына бара. (Кичә ахириләре белән бераз «күңел ачып» утырганлыктан, кыяфәте бик үк шәптән түгел үзенең). Килсә, ни күрсен: Рәшитләрнең фатир ишеге бикле түгел. Шуңа күрә кыңгырауны басып тормыйча гына эчкә уза бу. Хуҗа кеше, чакырылмаган булса да, кунакны ачык йөз белән каршылый. Шулай да сорыйсы итә:

— Туктале, «саф һава директоры», син ничек керә алдың монда?

— Ишегегез бикләнмәгән ләбаса, — ди Шамский.

— Җук, эт ничек кертте сине, дип сорыйм мин. Ничек каптырып алмады үзеңне?

— Нинди эт? — Шамский шунда күреп ала ишек төбендә беләк буе телен салындырып яткан алабайны.

— Әстәгъфирулла! Ничек миннән куркып, чыгып качмаган бу мәхлүк? Миннән бөтен этләр шүрли ләбаса! — дип, Расих Шамский үзенчә гаҗәпләнә.

## Ул ягын уйламаган

Татарстан Язучылар берлеге каршындагы шагыйрьләр секциясе утырышы бара. Яшь шагыйрь Мәннафның иҗатын тикшереп, аны Язучылар берлегенә әгъза итеп алырга дигән тәкъдим кертәләр. Секция утырышында катнашучылар бу тәкъдимне нигездә хуплап, чыгыш ясыйлар. Нәби Дәүли генә бер читтә дәшмичә утыра.

— Ә синең фикерең ничек, Дәүли?—дип сорый секция рәисе Хәсән Туфан.

— Союз члены булу-булмау шагыйрьнең иҗатына берни дә өстәми,—ди Нәби Дәүли.— Мин үзем, миңа ничек карауларын белер өчен, Союздан чыгып карар идем...

— Кирәкмәс, Нәби абый...—ди Хисам Камалов сүзенә ике төрле мәгънә салып. Моны, Союздан чыгарга кирәкмәс, дип, тә, яшь шагыйрьгә аяк чалырга кирәкмәс, дип тә аңларга була, ягъни.

Ә Разил Вәлиев Нәби абыйны икенче яктан «эләктереп ала»:

— Союздан чыгуын чыгарсыз да бит, аннары кире алырга теләмәсәләр, нишләрсез?—ди ул, мыек астыннан елмаеп.

— Шылаймы, шылаймы?—ди Нәби Дәүли ашыгып.— Мин ул ягын уйламаганмын икән шул, их-ха-ха-ха!

## Ба-а, ни булган бу Батуллага?

Әлегәчә гел коммунистларны гына яманлап йөргән Батуллага ни булган? Инде коммунистларны властьтан куып төшереп, үзләре менеп утырган демократлар да ошамый икән аңарга. Имеш, тегеләре дә, болары да, ике чабата — бер кием. Икесе дә башка милләтләргә ирек бирергә атлыгып тормыйлар, шовинистик фикерлеләр, фәлән-фәсмәтән. Әле кайчан гына Солженицынны тәнкыйтьләп шигырь язгансың, дип, Мәннафка бәйләнеп йөргән Батулла бүген үзе Солженицынның «кирәген бирә». Янәсе, теге «кәҗә сакал» Казакъстанда күпчелек урыслар яши, шулай булгач, ул җир Россиянеке булырга тиеш, дигән...

— Ни булган бу Батуллага?—Шушы сорау белән Мөдәррис Әгъләмгә мөрәҗәгать иткәч, ул болай дигән, ди:

— Ниһаять, Батуллага да акыл керә башлаган икән... Хәер, демократ битлеген кигән коммунист-түрәләр Батулланы гына түгел, Рәсәй халкын дагын акылга утырттылар...

## Рәсеме үзеннән әйбәтрәк

Шагыйрь Мәннафның рәсеме «Казан утлары» журналының тышлыгында басылып чыккач, каләмдәшләре әйтәләр:

— Ай-һай, Мәннаф дус, рәсемең шәп чыккан!

— Үземнән дә шәбрәкмени?—дип сорый Мәннаф.

— Әйе, үзеңнән дә җиллерәк.

— Алайса, минем рәсемем иҗатыма охшаган икән,—ди Мәннаф.

## Картаймау сере

Шагыйрьләрдән Әхсән Баян, Равил Фәйзуллин һәм Мәннаф сөйләшеп торалар.

— Элек заманда илле яшькә җиткән кешене без инде карт дип хисаплый идек,—ди Әхсән Баян, фәлсәфәгә бирелеп.— Хәзер ул яшьне үзебез узып киткәч, бер дә карт сыман түгелбез. Моның сере нәрсәдә икән?

Равил Фәйзуллин сүзне шаяруга борып җибәрә:

— Бу турыда минә Мәннафтан сорарга кирәк. Ул бер дә картая белми.

Мәннаф та җавапсыз калмый:

— Башкалар турында әйтә алмыйм,— ди ул,— ә үземә килгәндә, болай: мине Язучылар берлегенә үз эшләремнән ун елдан артык вакытка соңлабрак алдылар. Бик озак яшь шагыйрьгә санап йөрттеләр. Шулай итеп, картаерга да соңга калдырдылар, рәхмәт төшкерләре!

## Соравына күрә җавабы

Рәссам Әхсән Фәтхетдинов үз иҗаты белән Г. Тукай исемендәге премиягә лаек булгач, газитә хәбәрчесе аңардан интервью алырга килә.

— Әхсән абый, сез соңгы вакытта нәрсә ясау белән мәшгуль?— дигән сорау бирә ул рәссамга.— Нәрсәләр ясыйсыз?

Әхсән Фәтхетдинов яшь вә тәҗрибәсез хәбәрченең соравын яхшы аңласа да, шаяртып җавап бирә:

— Нәрсә ясыйм дип... Умарта рамнары ясыйм, аннары... бик шәп самогон аппараты ясап куйдым әле. Сынап карыйсы гына калды.

## Запчастьләрсез Габделхәй

Язучы Габделхәй Сабитов гомер буе шаян вә җор телле булды. Ул еш кына үз-үзеннән дә көләргә ярата иде. Бу мәзәк аның үзе сөйләвеннән чыгып язылды.

Бервакыт Габделхәй Сабитов белән шагыйрь Разил Вәлиев Чистай якларына сәфәр чыгалар. Юллар чокыр да чакыр. Үзләре утырып барган «уазик» шоферына Разил әйтә:

— Чү, туган, машинаңны акрынрак алып бар, югыйсә Габделхәй абыйның сөякләре таралып китүе мөмкин. Ичмаса, сөякләрен кире җыю өчен схемасын да алмаган идек,- ди.

Габделхәй җирән сакалын дерелдәтеп көлә:

— Һы-һы-һы! Схемасы гына түгел, запчастьләрем дә Казан ашханәсендә калды әле. Теге, ашарга кергәч, син кимереп, минем алдыма өйгән идең бит, сиңа запчастька дип, шулар онытылган,— ди ул.

## Буташтырганны килештерү

Заманында Әнәс Камал үзенең язучы гына түгел, рәссам да булуын әйтеп, күз хәтеренең шәплеге белән мактанып алырга ярата иде. Алар шагыйрә Гөлшат Зәйнашева белән Язучылар берлегенең «Тынгысыз каләм» газитен матурлап-бизәп чыгаручы булдылар. Әнәс абый күз хәтере белән мактанса да, бервакыт аның күзләре нык кына сыната. Газит чыгарганнан соң, үз пәлтәсе дип, Гөлшат Зәйнашеваныкын киеп кайтып китә бу. Гөнаһ шомлыгына, икесенең дә пәлтәсе бер төсле драптан, якалары да бер-берсенә охшаган булгангамы, әллә инде кара төнгәчә эшләп, күзләре әлҗе-мөлҗе килгәнгәме, ялгышкан Әнәс абый. Бу ялгышуны Гөлшат Зәйнашева өенә кайтырга җыена башлагач кына күреп ала. Чөйдә үзенеке урынына Әнәс Камал пәлтәсе эленеп тора! Гөлшат апа шушы пәлтәне өстенә киеп, тиз генә Нариман урамындагы Әнәс Камал фатирына йөгерә.

Ишек төпләренә килеп җиткәч, өй эчендәге тавыш-гауганы ишетеп, туктап кала Гөлшат Зәйнашева. Әнәс абый гөбедән чыккан тавышы белән гөрелдәп, хатынына бәйләнә:

— Сәлимә дим, Сәлимә! Нишләп минем пәлтә төймәләрен сул якка күчереп тактың? Мин хатын-кызмыни сиңа! Шул яшеңә җитеп, төймәне дә дөрес тага белмисең, пнимаешь...

— Нишләп сул якка тагыйм? — ди хатыны. — Каяле-каяле? Бәй, бу синеке түгел бит! Бу — хатын-кыз пәлтәсе ләбаса! Ах, сәрхүш баш! Әле чит хатыннар белән чуалып йөрисеңмени?! Бирермен мин сиңа төймәнне! Күзләреңнән төймә-төймә утлар чыгар!..

— Тукта-тукта, Сәлимә, воздержись!

Шулвакыт ишектән атылып-бәрелеп Гөлшат Зәйнашева килеп кермәсә, эшләр ни белән бетәр иде, нәмәгълүм.

— Сәлимә апа, минем пәлтәм ул. Әнәс абый Язучылар союзыннан, вешалкадан үзенеке белән буташтырып, киеп киткән! Без бит, үзең беләсең, гәзит чыгарабыз икәү... — ди ул тынына кабып.

Сәлимә апа Әнәс абый өстендә уйнаткан уклавын читкә куя.

— Гәзит кенә чыгарсагыз ярар анысы, — ди ул. — Юкса бу дивана башкасын чыгарырга да, мине бүтән хатыннар белән буташтырырга да күп сорамас...

Ул арада Әнәс абый куелган пластмасс тешләрен елтыратып елмая да янә гөрелдәп куя:

— Сине башкалар белән буташтырырга мөмкин рәзе? Синнән усалрак телле хатын бармыни ул Казанда? Хи-хи-хи! Мин бит сине күз хәтере белән генә түгел, колак хәтерем белән дә әллә каян таныйм, Сәлимә җаным.

Шулай итеп, Әнәс Камал буташтырганны Гөлшат Зәйнашева җайлапкилештереп кайта...

## Үз илендә җире булмаса да...

Әзәрбәйҗанның атаклы улы, дөньяга мәшһүр җырчы Мөслим Могамаевның юбилей кичәсендә дуслары аңа сюрприз ясарга уйлыйлар. Астроном-галимнәр яңа ачкан планетаны Мөслим Могамаев исеме белән атыйлар. Бу турыда җырчыга белдергәч, ул болай ди:

— Үз илендә бер аршын да җире булмаган кешегә тулы бер планета күбрәк булмасмы соң?

— Күп булмас, — ди галимнәр. — Әле шуңа өстәп, җәмәгатең — Тамара Синявская исемен дә кечерәк бер планетага куштык. Җирләрен үзегез эшкәртә алмасагыз, оныкларыгызга калыр...

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

## ПРЕЗИДЕНТЫБЫЗГА — ЧӘЧӘКЛӘР

Татарстан Республикасының Беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә 20 гыйнварда 60 яшь тулды. Шул уңайдан, Татарстан Дәүләт Советының тугызынчы пленар сессиясендә аның адресына күп кенә җылы сүзләр әйтелде, кочак-кочак чәчәк бәйләмнәре тапшырылды.

Җөмһүриятебез Илбашын котларга Мәскәүдән Россия Федерациясе Президентының аппарат җитәкчесе А. Чубайс, РФ вице-премьеры В. Илюшин, Уфадан Башкортостан Республикасы Президенты М. Рәхимов һ. б. күпсанлы кунаклар килгән иде.

А. Чубайс М. Шәймиевнең, РФ Президенты Указы нигезендә, Россия дәүләтчелеген, халыклар арасында дуслык һәм хезмәттәшлекне ныгытуга һәм үстерүгә зур шәхси өлеш кертүе өчен, II дәрәҗәле «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены белән бүләкләнүе турында белдерде һәм юбилярга Б. Ельцин котлавын җиткерде. В. Илюшин исә Татарстан Президентына, РФ Премьер-министры В. Черномырдин кушуы буенча, Россия Хөкүмәтенең Мактау грамотасын тапшырды.

ТР Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин юбилярны Хөкүмәт һәм башкарма хакимиятнең башка органнары, хезмәт коллективлары исеменнән тәбрик итте. Рәислек итүче — ТР Дәүләт Советы Рәисе, РФ Федерация Советы Рәисе урынбасары В. Лихачев РФ Федерациясе Советы Рәисе Е. Строев, РФ Дәүләт Думасы Рәисе Г. Селезнев, Әзәрбәйҗан Республикасы Президенты Г. Алиев, Казагыстан Республикасы Президенты Н. Назарбаев, Кыргызстан Республикасы Президенты Ә. Акаев җибәргән, Иран Ислам Республикасы, Словения, Төркия, Бөекбритания, Австралия, Польша, Куба һ. б. илләрдән килгән котлау телеграммалары белән таныштырды.

Соңыннан ул, М. Шәймиев юбилее уңаеннан, кабул итү мәҗлесе уздырды.

## М. ШӘЙМИЕВКӘ — ЖУРНАЛИСТЛАР ДИПЛОМЫ

Россия Журналистлар берлеге Секретариаты Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевне, «Матбугат белән ихлас аралашканы өчен», Почетлы диплом белән бүләкләде. Андый дипломга ия булучылар арасында Мәскәү шәһәре мэры Ю. Лужков, Россия Федерациясенең Тышкы эшләр министры Е. Примаков, ЮНЕСКО Генераль директоры Ф. Майор да бар.

## НИГЕЗ ТАШЫ САЛЫНДЫ

Изге Рамазан аенда, 17 гыйнварда, Татарстан башкаласында дулкынландыргыч тантана булып узды: Казан Кремле территориясендә торгызылучы Кол Шәриф мәчетенә нигез ташы салынды. Әлеге бәйрәмдә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, ТР Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары И. Хәйруллин, Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков һ. б. җитәкчеләр катнашты.

Мәчет төзүне Төркиянең Истанбул шәһәреннән «Ильк Умут» («Беренче өмет») фирмасы башкара. Аның президенты Йосыф Аккош, тантанада чыгыш ясап, Кол Шәриф мәчетенең манарасы җәй ахырына кадәр торгызылыр, дип ышандырды.

## КАЗАН МЕТРОСЫ ТӨЗЕЛЕШЕНДӘ

Яңа Ел бәйрәменнән соң ук, «Казметрострой» тресты Казанның Идел буе базары янында җир казу эшләрен башлап җибәрде. «Җиңү проспекты» дип аталачак әлеге станциядән башланган линия Авиатөзелеш районына кадәр барачак. «Комсомолец» кинотеатры белән «Яшьләр үзәге»н тоташтырачак линияне 2004 елда төзеп бетерергә уйлыйлар. «Азино»дан «Тимер юл вокзалы»на илтүче линия аңа параллель рәвештә төзеләчәк. «Оргсинтез» белән «Борисково» 2014 елда тоташачак... Болар турында Татарстан Республикасы хөкүмәтенең Казан метрополитенын төзү программасы буенча кабул иткән карарында әйтелә. Республика бюджетыннан әлеге төзелешкә быел 29 млрд. сум акча бүлеп бирелгән.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ — БӨТЕНДӨНЬЯ ПЕН-КЛУБЫНДА

Мексиканың Гвадалахара шәһәрендә Интернациональ ПЕН-клубта әгъза булып торучы язучыларның 63 нче Бөтендөнья конгрессы булып үтте. Аның эшендә дөньяның 124 иленнән 400 гә якын вәкил катнашты.

Республикабыздагы Татар ПЕН-үзәгеннән бергә Рафаэль Мостафин, Разил Вәлиев, Вахит Юныс, Әхәт Мушинский килгән иде. Конгресста ПЕН-үзәкнең вице-президенты, Татарстан халык депутаты Р. Вәлиев татарча чыгыш ясап, Татар ПЕН-үзәгенең халыкара мөнәсәбәтләр буенча сәркатибе В. Юныс аның сөйләвен инглиз теленә тәрҗемә кылып, бик күпләрнең игътибарын, мәхәббәтен яулыйлар. Татарстан, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге, әдәбиятыбыз-мәдәниятебез, язучыларыбыз турындагы шул

чыгышлардан соң, 12 ноябрьдә Татар ПЕН-үзәге, бертавыштан, Бөтендөнья ПЕН-клубына (Президенты — Рональд Харвуд) әгъза итеп кабул ителә. Залдагылар татар язучыларын аягүрә басып алкышлыйлар.

## МИСЫРГА СӘЯХӘТ

Иҗат һәм ял итү максаты белән, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллин Мисырда булып кайтты. Каһирә, Луксор, Хургада шәһәрләрендә сәяхәт кылды, борынгы заман цивилизациясенең бөтендөньяга мәгълүм тарихи һәйкәлләре белән танышты.

## ТУРАН ЯЗГАН — КДУ ДОКТОРЫ

Казан дәүләт университетының Гыйльми Советы, язучы-академик Т. Галиуллин тәкъдимен искә алып, Истанбул университеты профессоры, икътисад фәннәре докторы, Истанбул парламенты депутаты, «Төрек дөньясы» мәркәзе җитәкчесе Туран Язганны, бертавыштан, данлыклы уку йортының мактаулы (почетлы) докторы итеп сайлады.

Т. Язган — 20 дән артык монография авторы, күренекле галим һәм озак еллар дәвамында Татарстан һәм Казан белән тыгыз элемтәдә яши. Аерым алганда, ул КДУның көнчыгыш телләр кафедрасына рухи һәм матди ярдәмен даими күрсәтеп тора. Инде берничә төркем студентлар һәм укытучылар, аның ярдәме белән, Төркиядә белемнәрен күтәреп кайттылар. Т. Язган КДУ китапханәсенә төрек телендә нәшер ителгән меңнән артык китап та бүләк итте.

## *ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ БЕРЛЕГЕНДӘ*

## ГЕНЕРАЛЬ КОНСУЛ БЕЛӘН ОЧРАШУ

14 гыйнварда ТР Язучылары берлегендә Төркия Җөмһүриятенең Казандагы генераль консулы Алыпхан Шолен әфәнде белән очрашу булып үтте. Аның барышында Төркия белән Татарстан арасында әдәби-мәдәни багланышларны тагын да үстерү мәсьәләләре тикшерелде. Очрашуда ТР Язучылары берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, язучы-академик Т. Галиуллин, әдипләрдән М. Маликова, Р. Батулла һәм идарә рәисенең урынбасарлары Ә. Гадел, Р. Әймәт катнашты.

## ИҖАТ ОСТАХАНӘЛӘРЕНДӘ

ТР Язучылар берлегенең «Шигърият остаханәсе» (җитәкчесе — Татарстанның халык шагыйре И. Юзеев) үзенең 27 декабрьдә булган чираттагы утырышын Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе профессоры Рифат Җамал (Корбанов)ның шигъри иҗатын тикшерүгә багышлады. Чыгыш ясаучылардан Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, Р. Низамиев, Зөлфәт, М. Вәлиев, Ш. Мостафин, К. Сәгъдәтшин һ. б. яшь авторның әле генә дөнья күргән «Күңел сурәләре» исемле беренче китабына, нигездә, уңай бәя бирделәр, шигъри осталыгын тагын да камилләштерү буенча файдалы фикерләр әйттеләр. Утырышта катнашучылар Р. Җамалны бертавыштан Татарстан Язучылары берлегенә әгъзалыкка тәкъдим иттеләр.

* * *

«Проза, драматургия һәм публицистика остаханәсе» (җитәкчесе — Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов) 22 гыйнварда прозаиклардан Госман Гомәр, Мансур Шәһимәрдән һәм очеркист-публицист — «Ватаным Татарстан» газетасының әдәбият вә сәнгать бүлеге мөдире Асия Юнысова иҗат иткән әсәрләр буенча зур сөйләшү үткәрде. Фикер алышуларда Р. Мингалим, Р. Хәмид, Л. Бадыйкшан, Р. Кәрами, Ә. Гаффар, М. Әгъләмов һ. б. катнашты. Тикшерелүче каләм ияләренең һәркайсы Татарстан Язучылары берлегенә әгъзалыкка тәкъдим ителде.

Шул ук утырышта хикәяләр язу өлкәсендә мәгълүм уңышларга ирешкән әдипләрдән иң нәтиҗәле эшләүчеләре Татарстанның халык язучысы Фатих Хөсни исемендәге әдәби бүләккә кандидатлар итеп күрсәтелде.

## С. ХӘКИМ МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ

Татарстанның халык шагыйре Сибгат ага Хәкимнең тууына 85 ел тулу уңаеннан, 17 гыйнварда фронтовик-язучының туган ягында — Әтнә районының Күлле-Кимә авылында олы бәйрәм үткәрелде. Бирегә Татарстан Дәүләт Советының даими комиссиясе рәисе Р. Миннуллин җитәкчелегендә бер төркем язучылар, ТР Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы вәкилләре килде. Аларның һәммәсе авылдагы урта мәктәп бинасында С. Хәкимнең әдәби музеен ачу тантанасында катнаштылар. Чыгыш ясаучылардан ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, ТР Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, министр урынбасары, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы Х. Гайнуллин, Татарстан берләштерелгән Дәүләт музееның әдәби бүлек мөдире — әдип В. Нуруллин, шагыйрәләрдән Г. Зәйнашева, Л. Шагыйрьҗан, Ф. Зыятдинова, ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Р. Әймәт һ. б. Сибгат ага турында үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар. Искә алу кичәсендә С. Хәкимнең улы — күренекле сәясәтче һәм галим Рафаэль Хәкимов та катнашты.

## ИҖАТ КӨЧЛӘРЕНӘ ИГЪТИБАР АРТА

Мамадыш районына хакимият башлыгы итеп Әгъзәм Самат улы Гобәйдуллин билгеләнгәч, бирегә иҗат көчләренә игътибар күпкә артты. Мәдәният бүлегендә дә мөдир булып танылган җырчы — Бөтендөнья «Татар җыры» конкурсы лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гөлнәзирә Талипова эшли башлады. Бергәләп тотынгач, район үзәгендә дә, авылларда да

кызыклы кичәләр, мавыктыргыч очрашулар еш үтә башлады. Үткән ел азагында гына, мәсәлән, жирле шагыйрьләрдән Сәяф Сәйфи, Нәкыя Йосыповаларның иҗат кичәләре гөрләп узды. 17 гыйнварда исә Мамадыштагы «Дуслык» кинотеатрында район халык театры ветераны, оста җырчы, «Мин авылга гашыйк», «Җырларымда — гомерем дәвамы» исемле шигъри җыентыклар авторы Вахит Галиевнең 70 еллыгы зурлап билгеләп үтелде. Бер үк вакытта Татар иҗтимагый үзәгенең Мамадыш төбәгендәге җитәкчесе, район аксакаллары шурасы рәисе дә булган ил агасын котларга, Казаннан да, күрше-тирә шәһәр-авыллардан да кунаклар күп килгән иде. Район хакимияте башлыгы урынбасары Шамил Хәсәнов, Татарстан Язучылары берлеге идарәсе рәисе Әхмәт Гадел, юбилярның җырчы туганы — Татарстанның халык артисты Мингол Галиев, Татарстан Җөмһүриятенең Аксакаллар шурасы сәркатибе Госман Гомәр, «Ватаным Татарстан» газетасы хәбәрчесе Люция Фәршатова, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Шаһинур Мостафин һ. б. Вахит агага иң изге теләкләрен җиткерделәр, бүләкләр тапшырдылар. Һәр мизгел видеотасмага төшереп алынды.

Хәзерге вакытта районда шагыйрь Әхмәт Гаделнең, Кече Кирмән авылындагы урта мәктәп директоры — күп кенә шигъри җыентыклар авторы Рафаэль Газизовның һәм Мәскәүдә яшәп иҗат итүче журналист, прозаик һәм драматург — бередәге Татар зыялылары клубы директоры, «Азатлык» радиостанциясенең Россия башкаласындагы үз хәбәрчесе Нәзифә Кәримованың иҗат кичәләрен үткәрергә хәзерлек бара.

## «КЫЗЫЛ ТАҢ» ЛАУРЕАТЛАРЫ

Уфада татар телендә чыгып килүче «Кызыл таң» газетасы соңгы елларда үз битләрендә басылган иң яхшы әдәби әсәрләргә бүләк-призлар бирүне гамәлгә керткән иде. 1995 елда бу бүләккә, Башкортстан әдипләре белән берлектә, Татарстаннан күренекле шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе, ТР халык депутаты Роберт Миңнуллин лаек булды. 1996 елда исә махсус бүләк-приз иярәре арасында «Казан утлары» журналының шигърият бүлеге мөхәррире, танылган шагыйрь Рәдиф Гаташ та бар — аның «Кызыл таң»да дөнья күргән шигъри шәлкемнәре укучылар күңеленә хуш килгән.

## ЯҢА ЖУРНАЛ

Чаллы шәһәре хакиме Р. Алтынбаев фәрманы нигезендә, бередә татар һәм рус телләрендә «Фән һәм мәктәп» («Наука и школа») дигән яңа журнал чыга башлады. Айга бер мәртәбә нәшер ителүче әлеге журналда укыту-тәрбия эшен тагын да җанландыру, аны заман таләпләре югарылыгына күтәрү юнәлешендә кызыклы вә файдалы язмалар, алдынгы тәҗрибә, дәрес үрнәкләре урын алган.

Яңа журналның баш мөхәррире — язучы Факил Әмәк (Сафин).

## РАМАЗАНГА БАГЫШЛАП

Мәркәзебезнең Г. Тукай музеенда 17 гыйнвардан 10 февральгәчә изге Рамазанга — Ураза аена багышланган махсус фотокүргәзмә булып үтте. Танылган фотосурәтче Рамил Галиевнең йөзгә якын рәсемендә республикабызда яшәүче мөселманнарның тормышы һәрьяклап киң яктыртылган иде.

## МУСАНЫ ДӨНЬЯ ТАНЫЙ

Татар халкы үзенең Мусалары белән данлыклы. Күренекле шагыйрь — Советлар Союзы Каһарманы Муса Җәлил дөньяны үлемсез «Моабит дәфтәрләре» белән тетрәткән булса, талантлы яшь җырчы Муса Маликов үзенең кабатланмас моңнары белән миллионлаган күңелләрне сөендерә. Быел ул 10 гыйнварда Мәскәү телевидениесенең ОРТ каналы аша «Югга моң белән чыгам» дигән фильм-концертын тәкъдим итте. Хәзер әлеге видеотасманы дөньяның күп кенә илләре үзләрендә булдырган.

## «ПОЛЬША ТАТАРЛАРЫ» КҮРГӘЗМӘСЕ

Варшава каласында «Польша татарлары» дигән күргәзмә ачылды. Ул март аена кадәр эшләячәк. Күргәзмәгә һәртөрле татар әләмнәре, шәмаилләр, Коръәннең төрле телләрдә кулдан язылган вариантлары куелган. Бирегә килгән кешеләр шулай ук намазлыклар, дин әһелләренең киемнәре, яу башлыкларының кораллары һ. б. тарихи истәлекләр белән таныша алалар.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Россия Федерациясе Президенты Б. Ельцин Указы нигезендә, мәдәният өлкәсендәге казанышлары һәм озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен, Татарстан Республикасының «Мәгариф» милли нәшриятының баш мөхәррире **Кәлимуллин Җәүдәт Хәлим улы** «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Бакый Урманченың «Кышкы иртә» картинасыннан фотокүчермә.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. **Җил — вакыт ул...** *(Кыска шигырьләр)* — Казан: Мәгариф, 1996. — 287 б. рәс. белән. Тиражы — 10000 данә.




Равил Фәйзуллинның кыска шигырьләр остасы булуы киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм хакыйкать. Әлеге басма — кыска шигырьләрнең чагыштырмача тулы басмасы. Анда шагыйрьнең утыз елдан артык дәвердә иҗат ителгән әсәрләре тупланган.

Бер-ике юллыклар... Иң озын дигәннәре дә сигез юлга сыеп бетә. Шигырьләрдә биш-ун сүз, күп дигәндә егерме-утыз сүз...

«Минемчә, чын шигырь һәр төр иҗаттагы кебек, җанның максималь киеренке чагында, уй-фикерне әйтми, бүтәннәр белән бүлешми кала алмау халәтендә, илаһи гаҗизләнү минутларында туа. Иҗатчының бу мәлдә күңеле, сабыйларныкы кебек саф һәм ихлас, ә фикере исә — хөкемдар-хакимнәрнеке кебек төгәл һәм хикмәтле булырга тиеш. Шул чакта гына Сүз, мәгънәсе һәм эмоциясе буенча, дөньяда беренче туып яңгыраш алгандагыга якын булырга мөмкин. Сүз кадәр Сүз бит ул! Сүзгә сакчыл булу — ул Аңа инану, табыну. Аның кодрәте алдында баш ию, «рәнҗешеннән» курку... Моны тоеп, аңлап эш иткән иҗатчының сүзе, һичшиксез, табигый яңгырар. Күзләрдән яшь китерерлек шатлык килгәндә, ауда атакага күтәрелгәндә, иң кадерлесен назлап иркәләгәндә, соңгы сулышларын алып васыять әйткәндә — Кеше иң табигый сөйләшүдә булып, шул чакта иң кирәк, иң төгәл, бердәнбер мәгънә белән яңгырашлы сүзләрне тапмый мени?.. Димәк, кыскалык — уйлый белүнең үзгә бер формуласы ул...» дип яза автор «Сүз — болын, җыр — чәчәк» дип исемләнгән кереш сүзендә.

Китап, сувенир басмаларга хас, югары зәвык белән заманча полиграфик ысулда затлы итеп нәшер ителгән.

Индекс 73210



Әдәби тәнкыйтьче һәм язучы Мансур Вәли.

Д. Бунтуков фотосы.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЫ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)